ӘЛФИЯ АВЗАЛОВА

Истәлекләр



Казан
«Халкыбыз мирасы»
нәшрияты
2019

УДК 793
ББК 85.32
Ә53

Китап Татарстан Республикасы Президенты ***Р.Н.Миңнеханов****,*
Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм итү фонды,
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы,
Казан шәһәре мэриясе,
Җырчы Әлфия Авзалованың иҗатын саклау һәм үстерү фонды
ярдәмендә нәшер ителде.

Книга издана при поддержке Президента Республики Татарстан ***Р.Н.Минниханова****,*
Фонда поддержки развития культуры при Президенте Республики Татарстан,
Министерство культуры Республики Татарстан,
Мэрия города Казани,
Фонда сохранения и развития творчества певицы Альфии Авзаловой.

Проектның авторы һәм китапны төзүче – ***Зөлфия Нигъмәтҗанова-Авзалова***
Зульфия Нигмедзянова-Авзалова – *автор идеи и составитель книги*

Китапны әзерләүдә катнаштылар:
Г.З.Авзалова, Р.Ә.Нигъмәтҗанов, Р.М.Сәрвәров, Ә.И.Һадиева, Р.Р.Минһаҗ, Р.Г.Сәетгәрәева, А.А.Низамиев, Ф.С.Маликова, Ш.Ә.Мостафин, К.Ә.Фәйзрахманов, Ә.И.Авзалов, И.Р.Исхакова, Л.Р.Нигъмәтҗанова, Р.Р.Нигъмәтҗанова, А.М.Гафиятуллин, Ш.З.Абдюшев, В.Н. Зотов, А.М. Бикмөхәммәтова, Р.Х.Сабиржанов.
Ноталар җыентыгы Казан дәүләт институтының соло җырлаучылар эзерләүче кафедрасы тарафыннан эшләнде, төзүчеләр – ***В.Ә.Ганиева, Г.Б.Бабаева, Л.З.Бородовская***

В подготовке книги приняли участие:
Г.З.Авзалова, Р.А.Нигмедзянов, Р.М.Сарваров, А.И.Хадеева, Р.Р.Мингазов, Р.Г.Саитгареева, А.А.Низамиев, Ф.С.Маликова, Ш.А.Мустафин, К.А.Файзрахманов, О.И.Авзалов, И.Р.Исхакова, Л.Р.Нигмедзянова, Р.Р.Нигмедзянова, А.М.Гафиятуллин, Ш.З.Абдюшев, В.Н. Зотов, А.М. Бикмухаметова, Р.Х.Сабирзянов.
Нотный материал подготовлен кафедрой сольного пения Казанского государственного института культуры, составители – ***В.А.Ганеева, Г.Б.Бабаева, Л.З.Бородовская.***

Ә53 **Әлфия Авзалова.** Әлфия Авзалова: истәлекләр / проект авторы һәм төзүче З.Нигъмәтҗанова-Авзалова. – Казан: «Халкыбыз мирасы» нәшрияты, 2019. – 544 б.: фото, ноталар + mp3 диск.

А53 **Альфия Авзалова:** воспоминания / автор проекта и сост. З. Нигмедзянова-Авзалова. – Казань: Халкыбыз мирасы, 2019. – Казань: Издательство «Халкыбыз мирасы», 2019.– 544 с. с.: фото, ноты + mp3 диск.

Китап бик күп бүләкләр яулаган, мактаулы исемнәргә лаек булган, татар эстрадасында вокаль сәнгатенә нигез салган, дөньяның 17 телендә җырлар башкарган бөек татар җырчысы Әлфия Авзаловага багышлана. Аның тормыш һәм иҗат юлы халык хәтерендә озак сакларга һәм хөрмәткә лаек. Ул халкыбыз өчен янып яшәде.

Книга посвящена великой татарской певице Альфие Авзаловне Авзаловой, удостоенной многих наград и званий, основоположнице татарского эстрадного вокального искусства, исполнявшей песни на 17-ти языках мира. Ее жизненный и творческий путь достоин уважения и памяти народной, во имя которого она жила.

© З.Г.Нигъмәтҗанова-Авзалова, 2019
℗ ҖЧҖ «Халкыбыз мирасы», 2019

© З.Г.Нигмедзянова-Авзалова, 2019
℗ ООО «Наследие нашего народа», 2019

ISBN 978-5-905160-13-4



Кадерле дуслар, хөрмәтле милләттәшләр!

Сезнең кулыгызда даһи җырчыбыз, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Әлфия Авзалованың истәлекләре тупланган китап.

Әлфия Авзалова – милләтебезгә армый-талмый хезмәт иткән бөек сәнгатькәребез, мәшһүр җырчыбыз. Аның репертуарына борынгы һәм заманча халык җырлары, Солтан Габәши, Александр Ключарев, Мансур Мозафаров, Заһид Хәбибуллин һәм башка композиторларның катлаулы әсәрләре, дөньяның 17 телендә башкарыла торган җырлар кергән.

Кабатланмас матур тавышка ия булган җырчыбыз гомере буе мәдәниятебезне, җыр сәнгатен үстерү юлында фидакарь хезмәт итте. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә, 50 елдан күбрәк Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә алдынгы солистларның берсе булып танылган Әлфия Авзалова татар җыр эстрадасы башкаручылары арасында беренчеләрдән булып санала.

Татарстан Республикасы, Россия һәм чит илләрдә Әлфия Авзалованы зурлап күп кенә чаралар уздырыла. Шулар арасында – Әлфия Авзалова исемен йөртүче I Халыкара фестиваль-бәйге, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә Әлфия Авзалованы искә алу кичәсе, Әлфия Авзалованың истәлек китабын бастыру, аудиоальбомын, документаль фильмын чыгару.

Әлеге истәлек китабы барлык укучыларга Әлфия Авзалованың бөеклегенә, фидакарьлегенә һәм сәнгатькә бирелеп хезмәт итүенә, киң кырлы талантына төшенү өчен тагын бер этәргеч булыр дип ышанам.

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ,
Татарстан Республикасы Президенты

КЕРЕШ СҮЗ

Әлфия Авзалова – бик күп бүләкләр яулаган, күренекле исемнәргә лаек булган бөек татар җырчысы – элек тә, хәзер дә халыкның игътибар үзәгендә. Ул сәнгать дип яшәде; татар, башкорт җырларын традицион музыка коралларына кушылып башкарды; үз чыгышларын беренче тапкыр джаз белән бизәп, татар эстрадасында вокаль сәнгатенә нигез салды.

Әлфия Авзалова башкаруындагы яңа җырлар тиз арада бик киң таралды. Аларны Татарстан авыллары һәм шәһәрләрендә генә түгел, милләттәшләребез яшәгән союздаш республикаларда, чит илләрдә отып алалар иде.

Болай тиз танылуының сере әле дә ачылмый кала бирә. Аларны татар халкының үзенчәлекле сыйфатларын чагылдыручы могҗизалы күренеш, милли горефгадәтләргә, сәнгатькә тугры калу үрнәге дип тә әйтергә буладыр.

Татар халкы һәр заманда да талантларга бай булды. Хәзерге заман композиторлары, музыкантлары, җырчылары яңа музыкаль әсәрләр яза, тавыш яңгыратуда булган казанышларның төрле мөмкинлекләрен файдалана, сәнгатьтә яңа агымнар, юнәлешләр пәйда була.

Шул ук вакытта барча яңа дигәнең үз чыганагына, халык иҗатының хасиятен билгели торган нигезенә әйләнеп кайта. Әлфия Авзалова мирасы – гасырлар дәвамында сакланып калачак шул нигез дә инде. Хәзерге танылган артистларның ул башкарган җырларны җырлавы һич тә очраклы түгел.

Әлфия Авзалова, бөек җырчы булып калган сурәттә, иҗатында зур уңышлар яулаган гади татар хатыны булып калды, тормыш юлының дәвамын тәшкил иткән ике кыз, оныклар тәрбияли алды.

Аның дөнья халыклары җырлары кысасында тормышка ашкан иҗади ниятхыяллары вакытны узып гамәлгә керде, җырчының сәнгатьне нинди тирән кабул итүен хәзер генә аңларга, чамаларга мөмкин.

Ул дөнья халыкларының унҗиде телендә җырлар башкарды; инде болай да җиһанның төрле тарафларында күренекле җырчы буларак танылуы турында уйлап тормыйча, күп илләр гизәргә, чит илләрдә татар теленең һәм җырларының матурлыгын күрсәтергә хыялланды.

Әлфия Авзалова дан-шөһрәткә омтылмады, уңышлары белән мактанып йөрмәде. Ул һәрвакыт халыкның яраткан җырчысы, йөзек кашы булды. Халкым дип яшәде, бар булмышын газиз милләтенә багышлады.

2017 елның 15 июнендә арабыздан китеп барган Әлфия Авзалова турында китап чыгару уй-фикере гаиләбездә туды һәм аны Татарстан Республикасы җитәкчелеге хуплап чыкты. Әлеге басма төрле яшьтәгеләргә, төрле буыннарга файдалы һәм кызыклы булыр дип ышанабыз.

Китапның беренче өлешендә Әлфия Авзалованың үз хатирәләре урын алды, икенче өлештә аны шәхсән күреп белгән шәхесләрнең истәлекләре тупланды.

Кушымтада моңарчы мәгълүм булмаган һәм архивта саклана торган билгесез фотосурәтләр, җырчы репертуарындагы ноталары белән йөз җыр һәм җырчы башкаруында йөз җырдан торган MP3 диск бар.

Зөлфия НИГЪМӘТҖАНОВА-АВЗАЛОВА

ВСТУПЛЕНИЕ

Альфия Авзалова – великая татарская певица, удостоенная многих наград и званий, была и остается горячо любимой народом. Она жила искусством, исполняла татарские, башкирские народные песни в сопровождении традиционных музыкальных инструментов, став основоположницей татарского эстрадного вокального искусства, впервые использовав в своих выступлениях джазовые аранжировки.

Новые песни в исполнении Альфии становились в короткое время настолько популярными, что их знали во всех городах и селах Татарстана, союзных республиках, зарубежом, где проживают наши соотечественники.

Секрет ее популярности до сих пор остается нераскрытым, неразгаданной тайной, чудесным явлением, олицетворяющим самобытные черты татарского народа, примером верности и преданности национальным традициям, искусству.

Татарский народ во все времена был богат талантами. Современные композиторы, музыканты, певцы создают новые музыкальные произведения, используются возможности достижений в воспроизведении звука, возникают новые течения, направления в искусстве.

Вместе с тем, все новое неизбежно возвращается к истокам, тем основам, которые характеризуют творчество народа. Наследие Альфии Авзаловой и есть та основа, которая останется навеки. Не случайно, современные популярные певцы в своих выступлениях исполняют с неизменным успехом песни из ее репертуара.

Альфия Авзалова при всем своем величии оставалась простой татарской женщиной, сумевшей достичь незаурядных успехов в творчестве, смогла воспитать двух дочерей, внуков и правнуков, которые стали продолжением ее жизненного пути.

Творческие планы, мечты, реализованные в программах под названием «песни народов мира», намного опережали время, и только сейчас можно осознать, насколько глубоким было ее восприятие искусства.

Она исполняла песни на 17-ти языках мира, мечтала увидеть многие страны, показать красоту татарского языка и песен за рубежом, не всегда думая о том, что она с годами уже стала всемирно известной.

Альфия не стремилась к славе, не выставляла свои заслуги напоказ, она всегда оставалась певицей, почитаемой и любимой благодарным народом, с которым она была всегда, во имя которого жила и посвятила всю свою жизнь.

Решение издать книгу возникло в нашей семье и было поддержано руководством Республики Татарстан. Был избран формат книги таким, чтобы это издание стало полезным для всех возрастов и поколений.

Первая часть настоящей книги посвящена воспоминаниям самой Альфии Авзаловой, вторая часть состоит из воспоминаний тех, кто знал Альфию Авзалову. В Приложение включены архивные фотоматериалы, известные и публикуемые впервые, а также 100 песен и нот к ним из репертуара певицы, музыкальный MP3 диск из 100 песен в ее исполнении.

Зульфия НИГМЕДЗЯНОВА-АВЗАЛОВА

INTRODUCTION

Alfiya Avzalova is a great Tatar singer, awarded many prizes and titles, was and still is a beloved singer of the people. Art was her life; she performed Tatar and Bashkir folk songs accompanied by traditional musical instruments, having become the founder of Tatar pop vocal art, and being the first one who used jazz arrangements in her performances.

New songs performed by Alfiya became so popular in a short time that they were known in all cities and villages of Tatarstan, the Union republics and abroad where our compatriots live.

The secret of her popularity remains unrevealed, unspoken mystery, a wonderful phenomenon, personifying the distinctive features of the Tatar people, an example of loyalty and devotion to national traditions and art.

The Tatar people are always rich in talents. Modern composers, musicians, and singers create new musical works, profit from the possibilities of achievements in reproducing sound, new trends and directions in art appear.

At the same time, everything new inevitably returns to the sources, the foundations that characterize the people's creativity. The legacy of Alfiya Avzalova is the foundation that will remain forever. It is not by chance that modern popular singers in their performances sing songs from her repertoire with the unfading success.

With all her grandeur, Alfiya Avzalova remained a simple Tatar woman who managed to achieve outstanding success in her work and raised two daughters, grandchildren and great-grandchildren who became the continuation of her life path.

Creative plans and dreams, realized in programs called «Songs of the peoples of the world», were far ahead of time, and only now, we can understand how deep her perception of art was.

She performed songs in 17 languages of the world, dreamed of seeing many countries, show the beauty of the Tatar language and songs abroad, not thinking about the fact that over the years she had already become world famous performer.


Alfiya was not striving for fame, did not flaunt her merits, she always remained a singer, respected and loved by the grateful people she was always stood up, whom she lived for and which she devoted her entire life to.

The family of Alfiya Avzalova had the idea to publish a book about Her legacy. This idea has not only been supported by Alfiya Avzalova's (who passed away on June 15, 2017) family, but also by the leaders of the Republic of Tatarstan. The format of the book was chosen to make this publication useful for people of all ages and generations.

The first part of this book is dedicated to the memories of Alfiya Avzalova herself, the second part consists of priceless memories of those who knew Alfiya in person. The material was compiled by the author during personal conversations in Russian and Tatar languages.

The annex comprises archival photographs, both known and published for the first time, as well as 100 songs from the singer's repertoire and notes to them.

Zulfiya NIGMEDZYANOVA-AVZALOVA
author, compiler



Әлфия Авзалова

ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Кереш сүз

Миннән еш кына балалык, яшьлек елларың ничек узды, ничек җырчы булдың, хәзер ничек яшисең, дип сорыйлар. Гомумән, моң турында, җырның ничек тууы турында кызыксыналар, төрле-төрле сораулар бирәләр. Артистлар белән шулай кызыксыну, мөгаен, сәнгать кешеләренә халкыбызның игътибары, мәхәббәтедер. Тамашачыларның кызыксынуын тою күңеллесен-күңелле дә, тик ул сорауларга җавап бирергә дә кирәк бит. Бу – җаваплы эш.

Мин соңгы унбиш-егерме елда бу җаваплылыкны үз өстемә алып, концертларымда тамашачыларның кайбер сорауларына кыскача гына булса да җавап бирәм, чыгышларымда биографиямнән кайбер сәхифәләрне сөйләп алам. Үземә калса, алар концертларымны да җанландырып җибәрә сыман. Тамашачылар белән ике арада ниндидер күзгә күренмәс киртә бетеп, иркенлек, ихласлык тантана итә башлый, җыр сөючеләр белән чын дуслык, якынлык туа.

Әлбәттә, концерт – концерт инде ул, анда тамашачылар кызыксынган барлык сорауларга да җавап биреп булмый. Шулай сөйли-сөйли җырлаганым өчен тәнкыйтьләп тә чыктылар үземне. Сөйләвемнән гаеп табып, газеталарда язып чыгучылар булды. Уңышсыз сөйләгән чакларым да буладыр. Минем сөйләвем берәүләргә ошыйдыр, берәүләргә ошамыйдыр. Ничек кенә булмасын, концертымда мин эчкерсез холкым белән, ихластан сөйлим. Тамашачы бит ул барысын да белергә тели. Аның күңеле тулы сораулар. Менә шуны истә тотып, бигрәк тә яшь тамашачыларның сорауларына җавап булыр дип, үземнең тормыш һәм сәхнә юлым турында язарга, дигән уйга килдем. Үзегез беләсез: мин язучы да, журналист та түгел, фикерләрем миемдә кайнап торса да, килештереп яза белмим. Шулай да, бик тырышсаң, ташка кадак кагарсың, диләр бит. Мин дә шулай бик тырышсам, бәлки, бераз киртәсенә кертермен дип, кулыма каләм алдым һәм яза башладым. Холкым шундый: эчемдәге – тышымда! Шул эчкерсезлегем белән язып киттем. Бөтен балачагым, яшьлегем, үткән тормышым, кинокадрлар кебек, бер-бер артлы күз алдыма килеп, мине бөтереп алды.

Язылган дәфтәрләремне каралама хәлендә язучы дусларыма укыдым. Кайбер тормыш сәхифәләремне сөйләп чыктым. Дусларым минем язганнарымны тәртипкә китереп, килешмәгән җирләрен төзәтеп, мин сөйләгәннәрне язып алып, бу кулъязманы яңадан эшләп бирде. Шулай итеп мин, якын дусларым ярдәмендә, бу эшне башкарып чыктым шикелле. Укучы дустым! Алдан ук гафу үтенәм: гаеп итмәссең инде, булдыра алганча, күңелемдәгесен җиткезергә тырыштым. Кызыксынып укыган кешеләргә алдан ук рәхмәт әйтәм. Кемнеңдер укыйсы килмәсә – укымас, үпкәләштән түгел, бигайбә!..

Яшьтән бирле хәсрәт йотып...

Иртә белән тышка чыксам,
Каршы тауга кар яуган.
Яшьтән бирле хәсрәт йотып,
Йөрәгемә кан сауган...
(Халык җыры.)

Мин үземнең балачагымны бишенче яшем белән барган чагымда булган хәлләрдән башлап хәтерлим. Әнием миңа биш яшь тулгач үлде. Ә мин әниемнең әле исән чакларын, бөтен булган хәлләре белән үк булмаса да, шактый ачык хәтерлим. Димәк, миңа әле ул чакта дүрт кенә яшь тулган булган. Әнием үлгәнгә кадәр булганнарны язам.

Бик нык хәтеремдә калган: Кабан* дигән авыл. Ике кечкенә генә тәрәзәле, салам түбәле тәбәнәк өй. Менә көннәрдән бер көнне әтием эчеп-исереп кайтып керде. Мондый көннәр бик еш була иде. Ишекне юньләп япмады да. Тыштан өйгә салкын кереп тулды. Мин ике яшьләр чамасындагы сеңелем Флүрә белән мич башында утырам. Өс-баш фәкыйрь, шулай да әнием безнең чәчләрне тарап үргән, кулыбызга чүпрәктән үзе теккән курчак тоттырган. Сеңелем белән курчаклы уйныйбыз. Ишектән кереп тулган салкыннан бөрешеп, әтигә карыйбыз. Әтинең күзләре акайган, төкерекләре чәчелә, ямьсез сүзләр әйтеп сүгенә. Әни тиз генә безгә таба йөгереп килеп, мич башына менде, утыннар артына качты. Күреп өлгердеме, әллә балалыгым белән әниемнең кайдалыгын мин әйттемме, әти йөгереп килеп, әниемне утыннар арасыннан өстерәп төшерде дә кыйнарга тотынды. Мин бик каты кычкырып елый башладым. Сеңелем дә акырып елап җибәрде. Әти әнине кыйный, ә үзе безне юатмакчы була. Минем муеныма крендельләр тезелгән бау кигезде. Бавы белән крендель кигезсә дә, мин акырып елыйм: «Әнигә тимә! Әнигә тимә!..» – дип акырам. Әниемне чәченнән өстери-өстери кыйный да кыйный. Башларына суга, эчләренә тибә (бу юлларны язганда күземә яшь, бугазыма төер тыгылды.) Әниемне шулай кыйнаулары аның бик еш була торган иде.

Бер көнне әнине кыйнады, сыерны алып чыгып китеп, сатып эчеп кайтты. Минем: «Сыерны алып кайт!.. Сыерны алып кайт!.. Кая куйдың безнең сыерыбызны?! Безнең сыерыбыз нинди матур иде, нигә аны алып киттең дә кире алып кайтмыйсың?..» – дип, такмаклый-такмаклый елаганым исемдә. Минем әти Афзал шул Кабан авылында даны чыккан бер ялкау адәм булган.

---

* Башкортстанның Калтасы (хәзер Краснокама) районындагы авыл.

Авыл халкы аны Ялкау Афзал дип йөрткән. Ялкаулыгы өстенә, эчкече, соңгы ыштанын сатып эчә торган тәрбиясез кеше булган. Сыерны сатып эчкәч, әни бик кайгырды. Ач калабыз дип, безне кочаклап елый иде. Чөнки авыл кешесенең бар карап торганы шул сыер бит. Игеннәр уңмагандыр инде, ипи юк, кеше сөт белән генә диярлек көн күрә. Без сөтсез калдык. Әтинең гамендә дә юк. Ул эчеп кайта да сугыша, кайта да сугыша. Җитмәсә, авыл җирендә каян чыккандыр ул гадәт: карта уйный, кемнәрдәдер карта уйнап, оттырып кайта да өйдәге әйберләрне чыгарып сата. Сыер да шулай картада оттыруыннан сатылгандыр, мин, сабый, аңламаганмындыр. Хәтта өс киемнәрен дә картага оттыра иде.

Бүгенгедәй хәтеремдә: бер көнне әти ыштан-чалбарын оттырып, итәге тубыктан хатын-кыз күлмәге киеп кайтып керде. Кырык ямаулы шул иске күлмәкне киеп урам буйлап кайтырга ничек оялмагандыр, хәзер уйлыйм-уйлыйм да шаккатам. (Үз әтиең турында мондый сүзләр язу яхшы түгел, әлбәттә, үземә дә авыр, нишлим соң, дөресе шулай.) Озак вакытлар шулай хатын-кыз күлмәге киеп йөргәне исемдә калган. Әзрәк аек көннәре дә булгандыр инде.



1946 ел

Төшемдә күргәндәй булып кына чабата ясап утырганнары, чабата ясаганда, бик моңлы итеп, йомшак кына тавыш белән әкрен генә җырлаганнары искә төшә. Кайчакта уйлыйм: эчмәсә, эшләсә, үзе болай ярыйсы гына кеше булган булыр иде. Әмма ләкин бик яхшы кешеләрне дә кешелектән чыгарган аракы безнең әти кебек йомшак, булдыксызларны бигрәк тиз бозып, гамәлдән чыгара бит ул.

Әнием, бәхетсез, нинди бәндәгә тап булган бит!.. Актаныштан шушы Кабан авылына килен булып төшкәч, әтинең туган-тумачасы, күрше-тирә әниемне бик яраткан. Холкы-фигыле белән әнием бик күркәм булган. Төскә-биткә дә матур, буйга-сынга да зифа булган. Гүзәллек мәгънәсендәге Миңямал дигән исем дә үзенә туры килеп, килешеп торган. Күз алдымда һаман да тере кебек: кара бөдрә чәчле, коңгырт кара күзле, түгәрәк йөзле, кечерәк гәүдәле, бик сөйкемле иде ул. Йомшак кына тавыш белән әкрен генә көйли, җырлый иде. Кечкенә сеңелләремне бишеккә салып тирбәткәндә, бик моңлы нәфис тавышы белән әкрен генә нинди көйләр көйләде икән?.. Кызганычка каршы, мин әле ул чагымда көйләр отып алыр яшьтә булмаганмындыр, откан булсам да онытканмындыр. Колагымда әнинең әкрен генә көйләгән моңнары тибрәнеп торса да, көйләре хәтердә калмаган. Шулай да такмаклаган сүзләре исемдә:

Әлли-бәлли итәдер,
Бәләкәй, матур бәбкәем,
Еламаса, йокласа,
Рәхмәт укыр әнкәең...



1947 ел

Әнием бер генә кешегә дә авыр сүз әйтә алмый торган йомшак холыклы булган. Юкса, эчеп-исереп кайткан әтигә каршы сүз әйтер, үзен шулай кыйнарга ирек бирмәс иде. Хәер, башы-күзе тонган исерек ир кешегә хатын-кыз, бигрәк тә әни кебек ябык кына, чандыр гына яшь хатын-кыз ничек каршы тора алсын?! Әнием шушы газаплы тормышка дучар булуын әтием белән бергә тора башлагач та аңлап алган. Тора башлаганнарына биш ай тулганда, әни әтидән аерылып, Актанышына кире кайтып киткән. Әтинең күрсәткән михнәтләреннән котылмакчы булган. Мин ул вакытта әни карынында дүрт айлык кына булганмын. Мин Актанышта туганмын. Ләкин әти безнең арттан Актанышка килгән, әнигә, эчмәм, сугышмам, кадерләп кенә йөртермен дип, антлар биргән. Әни әтинең вәгъдәләренә ышанган, мине дә әтисез итәсе килмәгәндер инде, ризалашып, әтигә ияреп тагын Кабанга килгән. Шулай итеп, болар яңадан бергә яши башлаган. Әмма ләкин әти яхшы якка үзгәрмәгән, эчүен дә, карта уйнавын да дәвам иттергән, йорт-җирне карамаган, эшләмәгән, дөнья көтәргә, балаларын тәрбияләргә уйламаган. Бөтен авырлык әни җилкәсенә төшкән. Минем арттан дөньяга сеңелем Флүрә, аның



Хәмит Раянов белән.
1948 ел

артыннан сеңелем Гөлсирин туган. Без – кыз балалар, якты дөньяга туганбыз да, әмма ләкин безне караңгы көннәр, шомлы төннәр каршылаган. Безнең баш очыбызда ятимлекнең кара пәрдәсе, ачлык тырнаклары көтеп торган. Әнием исән-сау яши алган булса, бәлки, без әнинең канаты астында ятимлек тоймаган, ул кадәр үк ачлык күрмәгән булыр идек тә бит, бәхетсезлеккә каршы, әниебезнең гомере бик кыска булган шул. Ул 30 нчы елларның урталарында безнең якларда бик таралган, бик күп кешеләрнең гомерен өзгән тиф авыруыннан 26 яшендә вафат булды.

Әниемнең авырган, үлгән көннәре дә бүгенгедәй хәтеремдә, һич күз алдымнан китми. Ишек алдыбызда ике йорт иде. Безнең кечкенә генә өйдән башка анда тагын бер өй бар иде. Анысында әтинең бертуган энеләре яши иде. Әтинең энесен мин Шәкерт абый дип, аның хатынын Мулла җиңгәй дип йөртә идем. Әтинең энесе Шәкерт абый йомшак күңелле, юмарт кеше иде, ләкин аның хатыны Мулла җиңгәй бик саран, каты холыклы иде. Шәкерт абыебыз безгә – кечкенәләргә берәр ризык заты бирсә, Мулла җиңгәй усал итеп, Шәкерт абыйны үтерердәй булып карап тора торган иде. Без сеңелем белән аларга керергә курка идек. Шулай да бер ишек алдында торгач, туганнар да булгач, аралашып, йомышка керешеп яшәгәнбездер инде. Бер көнне сәкедә тезелеп, ямаулы иске юрганны баштан ук ябынып ятабыз, минем бер ягымда – әнием, икенче ягымда – Флүрә сеңелем, әнинең теге ягында тагын иске-москы чүпрәккә төрелгән бернәрсә кыймылдый, анысы безнең кече сеңелебез – бер атналык кына Гөлсирин икәнен елап җибәрүеннән аңладым. Әниемнең тәне тимер мич кебек кайнар, мин аңар елышып яткач, туңмыйм, миңа хәтта эссе... Шул чакта өйгә Шәкерт абый белән әти килеп керде. Әти әниемне яткан урынныннан күтәреп, урамга алып чыгып китте. Әнине капка төбендәге ат җиккән чанага салып, урам буйлап алып киттеләр. Без – өч бала, иске юрганнарыбызга төренеп, сәкедә ятып калдык. Мин тәрәзә төбенә басып, бозлы пыяланы тыным белән эретеп, чана артыннан карап калдым. Әниемне кая алып киттеләр икән, дип елый башладым. Миңа кушылып сеңелем Флүрә дә елый. Гөлсирин дигәненең елавы юрган астыннан ишетелеп тора. Өй салкын, шыксыз. Тышта шомлы, сызгырып җил улый. Күпмедер вакыт үткәч, хәтеремдә калмаган, безне иске-москыга төреп, өебездән алып чыктылар да, Шәкерт абый белән Мулла җиңгәй үз өйләренә алып керделәр. Нәрсәләр ашатканнардыр, нинди сүзләр әйткәннәрдер, алары истә калмаган, ләкин үзәк өзгеч, әле дә йөрәкне чеметеп алып авырттыра торган хәлләр хәтердә калган. Без Флүрә белән сәкедә уйнап утырабыз, ә җиңгәй бала имезә.

Аның үзенең дә ими баласы бар иде, безнекеннән шактый зур иде. Күзем төште – аның баласы безнең баланың күзенә төртә!.. Мин үзебезнең баланы жәлләп елыйм. Җиңгәй миңа усал итеп карый, үз баласын имезә-имезә дә иркәләп бишеккә сала. Безнең бала ачыккан, авызын кыеш-мыеш китереп ими эзли, аңа ими бирүче юк... Минем елаганны күрепме, үзенең намусы

уяныпмы, җиңгәй сөте имелеп беткән күкрәкләрен минем сеңелем авызына каптырган булды. Сеңелем Гөлсирин, елый-елый арыган кечкенә җан иясе, сөтсез имчәкләрне суыра башлады... Җан-фәрманга суырды газизем. Әзрәк тыныч лангандай булу белән, җиңгәм имчәкләрен бала авызыннан тартып алды. Мин үксеп-үксеп җыладым.

Әти кайтмый да кайтмый. Без кешедә яшибез. Сөйләшәләр, мин шул сөйләшүләрдән аңладым: әни бик каты авырган икән, аны больницага салганнар икән. Әнинең шулай каты авырып больницага керүен ишетеп, Актанышта гы апабыз, әнинең бертуган апасы Закирә апа килде. (Без аны Җыракай дип йөртә идек. Соңыннан минем балаларым – кызларым Гүзәл белән Зөлфия дә аны шулай Җыракай дип йөрттеләр. Җыракай – ерак әнкәй дигәнне аңлата.) Закирә апа – Җыракай безне үз өебезгә алып чыгып, безнең белән өч-дүрт көн торды бугай. Безне үз янына утыртып сөйләгәннәре әле дә исемдә.

– И балакайларым, Аллаһы Тәгаләдән ялварам: әниегез тазарып чыксын иде дә, сезне үзе тәрбияләп үстерсен иде. Кеше кулларына калмасагыз иде, ятимлеккә төшмәсәгез иде...

Мин ятимлек дигән сүзне белмим, аңламыйм, ул сүзне әйтергә телем әйләнми. Әйтә алмасам да, ятимлеккә төшү дигәне ниндидер караңгы упкынга, чокырга төшеп китү кебегрәк аңлашылып, мине куркуга сала. Мин куркам, дер калтыранам, Закирә апама сыенам.

Закирә апам әнием янына больницага барган, бу турыда ул әллә безгә сөйләмәгән, әллә сөйләп тә хәтердә калмаган. Ул безне өебезгә алып чыкканнан соң, без шунда торып калдык, ахрысы. Актаныштан килгән апа булгангамы, безнең өйгә Мулла җиңгәй, тагын башкалар керәләр, сөйләшәләр, елашалар, без тыңлап торабыз да аларга кушылып елыйбыз. Сүзләре бәгырьне телеп, һаман колакта яңгырый:

– Миңямал тиф белән бик каты авырый икән, аңын да жуеп җибәрә икән... Аңына килгән минутларында больницадан чыгып качарга уйлаган, караватына бау белән бәйләп куялар икән... Балаларым, балаларым дип кычкыра икән... күкрәге сөт белән тулып ташый икән, кечкенәмне, Гөлсиринемне имезеп кенә килимче, дип ялвара икән...

Актаныштан килгән апам кире Актанышына кайтып китә. Безне – өч кечкенә баланы, салкын өйдә үзебезне генә калдырып, ни җаны белән кайтып киткәндер, нинди туганлык инде ул?.. Хәзер уйлыйм да шаккатам. Әти һаман кайтмый да кайтмый...

Икенче көнне, ахрысы, җиңгәйләргә бер апа килеп әйткән:

– Афзал хатыны бүген үзен әйбәт сизә, безнекеләргә кереп әйт, зинһар, Әлфиямне күрәсем килә, алып килсеннәрче, дип үтенде, – дигән. Шундук җиңгәй мине җитәкләп больницага алып китте. Без ашыгып больницага килеп җиткәндә, бер апа очрап:

– Барып йөрмәгез, Миңямал дөнья куйды инде... – диде. Мин бу сүзләрне

аңламадым, җиңгәй елый, мин бер сүз дә дәшми торам. Кире кайта башлагач, нигә борылдык дип сораганмындыр, җиңгәй тагы да катырак елап: «Әниең үлгән бит!» – диде. «Үлгән» дигән сүз дә миңа барлык мәгънәсе белән аңлашылып җитмәде әле. Үлгән кеше мәңге кайтмаска китә дигән аң әле минем сабый башыма килеп җитми. Кайттык, җиңгәйләр өенә кердек, мин тәрәзә төбендә уйнап утырам. Буш шырпы тартмалары белән уйнап онытылып киткәнмен. Кинәт тәрәзәгә карасам, атка утырган әти кайтып килә. Шундук әнине алып кайтуын аңлап алдым – аны без ябынып йоклый торган юрганга төреп салганнар. Әниемне каршы алырга дип, йөгереп ишек алдына чыктым. Әнине үзебезнең өйгә күтәреп керттеләр, идәнгә сузып салдылар. Сеңелем Флүрә белән сәкегә менеп әнигә таба карап сузылып яттык. Икебез дә әнигә карыйбыз. Әнинең башында чәче юк, пәке белән кыркып алганнар. Күзләре азрак ачык. Күршеләр керде, халык җыелды, бар да елыйлар. Әбез сеңелем белән уйныйбыз, үлгән дигәннең чын мәгънәсенә төшенмибез. Күрәсең, кич җиткәндер, сукыр лампа яндырып әни янына куйдылар. Мин әни аша атлап үрелеп, нигәдер лампаны алмакчы булдым. Лампа лып итеп сүнде. Караңгыда мин дә лап итеп әнием өстенә утырдым. Шунда тәнем чымырдап китте, әнием боз кебек салкын иде. Шунда мин үксеп елый башладым, үлем дигәнне, нинаять, аңлавым булгандыр. Әниемнең салкын гәүдәсенә капланып, бик озак еладым, аңымны жуйганмындыр, шуннан соң ниләр булганын хәтерләмим. Нигә утка үрелгәнмен, ничек янгын чыгармаганмын, мине кемнәр әнием гәүдәсеннән күтәреп алган, аларын белмим, хәтерләмим.

Икенче көнне әниемне юалар. Кемдер: «Балаларны алып чыгыгыз, куркырлар», – диде. Безне җиңгәйләргә алып чыктылар. Бераздан, әниегез белән саубуллашырга керегез дип, безне кире өйгә алып керделәр. Әниемне төреп сәкегә салганнар. Өй тулы әбиләр. Безгә акча бирделәр. «Флүрәгә зурны, нигә миңа кечкенә акча бирдегез?!» – дип елыйм. Әниемне күтәреп алып чыгып киттеләр. Чанага салдылар. Аты пошкырып көтеп тора. Әкрен генә кузгалып киттеләр. Халык сөйләшә: «Актаныштагы түтәйләре күмәргә дә килмәде... Менә сиңа туган...», – диләр. Закирә апабыз әллә ишетми дә калган, анысын мин белмим, авыл аралары ерак бит. Бәлки, ишетмәгәндер дә. «Өч бала, өчесе дә бәләкәй, боларны кая куярга?» – диешәләр. Җиңгәй: «Үз балаларым да бар, мин боларны карый алмыйм», – ди. «Күкрәк сөтем аз, үз балама да җитми», – ди. Сөйләштеләр, сөйләштеләр дә:

– Давай, бу бәләкәй баласын үтерәбез! – диләр. Ничек?.. Ничек үтерәләр?.. Аңлар-аңламас торам. Минем колакка керә: Гөлбану исемле апа әйтә: «Тыштан салкын сөт алып кереп эчерик», – ди. Барысы да шул фикер белән килештеләр. Мин нишли алам? «Юк, юк, тимәгез сеңелемә!» – дип акыра башладым. «Юк, юк, тимибез, сөт кенә эчертәбез», – дигән булалар. Әзрәк зуррак булган булсам, ул сөтне эчерттермәгән булыр идем... Тыштан шешә белән салкын сөт алып керделәр, бер шешә сөтне эчертеп бетерделәр. Бала

таш кебек катты. Белмим, Гөлсирин, бәгърем, ничә көннән соң үлгәндер, берике көн торды микән?.. Үлде бала... Гөлсирин!.. Гөлсирин!.. Гөл кебек матур, сөйкемле, җанга якын нәни сеңелем!.. Җанлы курчагым минем!.. Хәзер дә йөрәгем өзелеп киткәндәй булам!.. Бигрәк кызганыч!..

«Менә әнисе үлгәнгә бер атна булды дигәндә, баласы үлде», – диләр, димәк, әнидән соң нибары бер атна гына яшәгән. Шулай газаплар күреп үләр өчен дөньяга туган бала икән. Әти бәләкәч Гөлсиринебезне күтәреп алып чыгып китте дә әни янына күмеп кайтты. Әтиемә мәңге рәнҗим. Тормыш авыр булса да, башка кешеләр яшәгән бит, эшләгән, ашаган, семьясын саклаган. Безнең әти эшлексез, ялкау, эшләргә яратмыйча, әнине кыйнап, хәлдән тайдырып бетермәсә, бәлки, әни тиф авыруына шулай тиз бирешмәгән булыр иде. Яшәр иде, безне ятим калдырып үлеп китмәс иде. Хезмәт сөйгән кеше эшләсә, бервакытта да ач булмый. Безнең әти шулай эшлексезлеге аркасында үзе дә рәхәт күрмәде. Үзенең дә гомере кыска булды. Ярый, бу турыда соңрак язармын. Әнием үлгәч, әти тагын каядыр китте. Эш эзләргә китте микән, диешәләр. Без өйдә ике бәләкәй кыз икебез генә калдык. Кемнәрдер кереп чыккалый. Нәрсә ашаганбыздыр, ничек яшәгәнбездер, хәтерләмим...

Кыш үтеп, җәй җиткән. Көннәрдән бер көнне әти алып кайтты бер әни. Мәрхәмә исемле иде ул. Ягымлы гына апа булып истә калган. Ләкин никтер ул апа бездә озак тормады. Безне кочаклап үпте дә: «И сабыйлар!..» – дип башыбыздан сыйпады да чыгып китте һәм кире килмәде. Әти тагын юкка чыкты. Әллә берәр җиргә ялланып эшкә кереп йөри, әллә эчеп-исереп өйгә кайтмый. Белмим. Без инде ачлыктан шешенә башлаганбыз. Кемдер, хәтерләмим, бер апа кереп безгә бер бәләкәй чиләк бирде. «Бәбкәйләрем, халык сепарат аерган җиргә барыгыз, ни булса да бирерләр, ачтан үтермәсләр», – диде. Без сеңелем Флүрә белән җитәкләшеп, сепарат урнашкан йортка киттек. Кулыбызда әлеге бәләкәй чиләк. Өс-баш начар, юка, аяк ялангач, язмы, әллә көзме, белмим, бик суык. Апалар безне җәлләп чиләкләребезгә аерткан сөт салалар. Без шундук чиләкне күтәреп эчәбез. Салкын сөт эчне авырттырса да түзәбез. Таш идәнгә баскан аякларыбыз күк-күмгәк булган. Шулай да без риза, ачлыктан котылабыз. Үзара сөйләшәләр:

– Нигә бу балаларны дитдумга бирмиләр икән соң?.. Әтиләре дә әллә кайда гидайлыкта йөри... Әтиләре булганга, аларны дитдумга алмыйлар икән...

– Нинди закун икән соң ул? Хөкүмәт ни карый икән?.. Әтиләре бар дип соң, андый әтинең булганыннан булмаганы артык... И балалар, балалар, кругум ятимгә әйләнеп баралар бит!..

Бу әтиемнең авылы Яңа Кабан халкы гомер-гомергә Актанышка базарга йөргән. Чабата ясап, Актаныш базарына илтеп сату белән шөгыльләнгән. Бер көнне базарга чыгып, Закирә апам: «Монда Яңа Кабаннар бармы?» – дип кычкырып сорап йөргән. Шунда аңар: «Бар кабаннар, менә без – Кабанныкы», – дигәннәр. Апам шул Кабан кешеләренә: «Минем Миңямал атлы сеңелем үлеп

1952 ел



китте, өч баласын калдырып... Ул балалар исән микән? Ни хәлләре бар икән?» – дигән. «Әтиләре дә күренми, әллә кая киткән, балалар җитәкләшеп урамда җылап йөриләр, ачтан үлмәсәләр ярар инде...», – дигән Кабан кешеләре. «Икенче атна базарына килсәгез, шул балаларны саламга булса да төреп алып килегезче, зинһар!» – дип, елый-елый үтенгән Закирә апам. Бер абзый шунда: «Нинди әйбер булса да табармын, икесен дә төреп алып килермен», – дип, вәгъдә биргән, һәм безне, Флүрә белән икебезне, киндер җәймәләргә, чыпталарга төреп, кул-аякларыбызны салам белән каплап, чанага утыртып, шул абзый Закирә апаларга китерде.

Апабыз безне елап каршы алды. Зур булмаса да, чиста җыештырылган, җылы, ямьле өйләренә килеп кергәч, рәхәт булып китте. Җитәкләшеп ишек төбендә басып торабыз. Апамның ире бар икән. Өстәл артында зур-зур кабып ашап утыра. Эчкә баткан ач яңаклы, әллә нинди сөйкемсез кеше. Безгә усал итеп карап-карап ала. Безне ашарга чакырмый. Закирә апам бала китермәде. Шулай да ул бала җанлы иде. Безне җәлләп елап тора. Ә жизни тиешле кешенең күңеле таш кебек икәнлеге йөзенә чыккан. Безгә бер кәлимә сүз дә әйтми, ичмасам. Апабыз узыгыз дип, чакырырга куркамы, без шактый озак шулай җитәкләшеп ишек төбендә басып тордык. Апабыз бәлки курыккандыр да, чөнки бу кеше аның икенче ире икән, яшькә дә ападан яшьрәк икән, беренче ире үлгәч, апам иренең энесенә – яшьрәк кешегә чыккан. Яшьрәк булгангадыр, бу адәм үзен бик эре тота. Безне алып килү турында сүзгә дә килгәннәрдер, бәлкем. Шактый озак ишек төбендә басып торгач кына, апам безне кече якка – аш-су пешерә торган бәләкәй генә бүлмәләренә алып кереп,

сәкегә утыртты. Юындырып, алдыбызга ашарга куйды. Сәкедә парларын бөркеп мичкә тәгәрәтеп пешергән кабыклы бәрәңге, җамаяк белән катык, алабута кушып пешергән кап-кара ипи телемнәре... Без сеңелем белән күз ачып йомган арада сәкегә җәелгән ашъяулык өстендәге ризыкларны ялт иттердек. Апабыз безгә карап, алъяпкыч итәге белән күз яшьләрен сөртеп елап тора.

Без шулай апамнарда яши башладык. Ашау урыныбыз да, йоклау урыныбыз да шул кече якта. Җизни янына – олы якка чыкмыйбыз да. Җизни безне яратмый. Апабыз безгә ризык бүлеп бирә башласа, җизнинең чырае караңгылана. Без кашык тотарга да куркабыз. Без кашык тотсак, ул килеп безнең кулдан кашыгыбызны тартып алыр кебек тоела. Сеңелем куркып елый. Мин дә бик тиз сизеп алсам да, еламыйм, түзәм.

Закирә апа – саклык кассасында җыештыручы, ә җизни тиешле кеше шунда каравылчы булып эшли иде. Ул эшкә киткән җирендә төннәрен куна кала иде. Ул кайтмаган төннәр безнең өчен бәйрәм була иде. Без – Закирә апа, мин, сеңелем Флүрә, ул кайтмаган кичләрдә рәхәтләнеп сөйләшә идек, әниебез үлде дип боегып йөрсәк тә, бала бала бит инде, апабыздан әкиятләр сөйләтә идек. Апабызның якты йөзе, тәмле сүзе безнең күңелләрне күтәрә иде. Апама шулай да бик авыр булгандыр. Чөнки хезмәт хакы аз алалар, ашау яклары бик кысынкы. Җитмәсә, җизни дә безне артык кашык күрә. Алар безнең хакта еш кына сүзгә килешәләр иде. Шунлыктан апам саклык кассасы мөдире Нажия апа Бәшировадан үтенә: – Нажия җаным, безнең шушы ятим балаларны дитдумга урнаштырырга ярдәм итсәңче, – ди, елый-елый.

– Икесен дә бирәсеңмени? – дип сорый Нажия апа. Закирә апа күз яшьләрен сөртеп, авыр сулап әйтә:

– Флүрәсен генә бирәм, Әлфиясен үземә алып калам!

Шулай итеп, Флүрә сеңелемне балалар йортына бирделәр. Мин апамда торып калдым. Җизни кырын күз белән караса да, мин апам янында җылы өйдә идем.

1939 елда мин беренче класска укырга кердем. Өстемдә Закирә апамның иске күлмәгеннән кечерәйтеп кул белән кемдер тегеп биргән, зәңгәргә манган күлмәк, кулымда киндердән теккән букча. Букча төбендә Закирә апага саклык кассасыннан кемдер: «Әлфиягә бир!..» – дип, тоттырып чыгарган бер-ике дәфтәр белән карандаш. Букча тотып, кояшлы сентябрь иртәсендә мәктәпкә бару, ягымлы укытучы апаларның безне елмаеп каршы алулары күңелле, бик күңелле сәгатьләр булып истә калган. Бу инде ниндидер татлы сер белән, якты өмет белән тулы рәхәт вакытлар иде. Укытучыбыз Нәфисә апа Акмалова мине бик ярата иде. Башымнан сыйпап, аркамнан сөеп кенә тора иде. Менә бер көнне җыр дәресе булды. «Мияу, мияу, пескәем!» дип җырлана торган бик күңелле, бик матур җыр өйрәтте Нәфисә апабыз (соңыннан белдем: Муса Җәлил сүзләренә Җәүдәт Фәйзи язган җыр булган икән ул.) Икенче көнне Нәфисә апа:

– Әлфия, бас әле, кичәге җырны кабатлап җырлап күрсәт әле, – диде. Мин урынымнан торып бастым да җырлап җибәрдем. Ни хикмәттер, җырның көе дә, сүзләре дә хәтеремә кереп, күңелемә уелган, бер дә ялгышмыйча җырлап бетердем. Нәфисә апа сокланып тыңлап утырды да бөтен класс алдында мине мактады:

– Балалар, ишеттегезме? Әлфия җырны ничек матур итеп җырлады!.. Тавышы матур икән. Хәтере дә яхшы икән. Бер сүзен дә ялгыштырмады. Булдырдың, Әлфия, молодец!.. – диде. Беренче класста укыганда бер башкорт көен дә яратып җырлый идем. Соңыннан белдем, «Карлыгач» дигән спектакльдән Карлыгач исемле кыз җыры булган икән ул:

Түгәрәк күл матур була,
Су белән тулса гына.
Тусын анадан кыз бала,
Бәхете булса гына...



Баянчы Хәмит Раянов белән. 1953 ел

Бик матур моңлы көйгә җырлана торган бу җырны барысы да ярата иде. Әмма ләкин Нәфисә апа аның сүзләрен болай итеп үзгәртте:

Тусын анадан кыз бала,
Отличник булса гына...

Ул заманда халык җырларын шулай фикер ягыннан бөтенләй киресенчә итеп үзгәртеп, «бәхетле балачак» ясап, шомартып җырлау гадәти хәл иде.

Шуннан Нәфисә апа безнең өйгә килеп йөри һәм миңа җырлар өйрәтә башлады. Салкыннар җитте. Кар төшә башлады. Минем өскә киеп урамга чыгарга бер җылы киемем дә юк. Закирә апам, җизнинеке булгандырмы, белмим, ниндидер иске җилән, бишмәт кебегрәк нәрсә кигезде. Өсте кырык ямаулы, аяк йөзенә җитеп торган шул озын бишмәт, аякта чабата. Нәфисә апа тагын яулык, оек кебек үзеннән арткан иске-москысын алып килә. Иске-москыдан алама киенсәм дә, җырлыйм да җырлыйм, өйдә ялгыз гына калсам, әйтерсең, патефон борып куялар, нинди җыр ишеткәнмен, барысын да отканмын, «концерт бирәм»... Нәфисә апа өйрәткән «Шахта», «Ал Мәрфуга, гөл Мәрфуга», «Нурия»ләрне сибәм генә... Җыр күңелемә юаныч бирә, ятимлегемне, ач-ялангачлыгымны оныттыргандай була, ниндидер якты өметләр белән киләчәккә ымсындыра, дәртләндерә...

Менә 1941 ел. Сугыш... Авыл халкы елый. Көн саен атларга төялеп, ирләр, егетләр сугышка китә. Алар әллә нинди үзәк өзгеч моңлы гармун тавышына кушылып, җырлый-җырлый урам әйләнәләр. Җырлары да хәтердә:

Без урамнардан үтмәсәк,
Казлар кузгалмас иде.
Без бәхетле бала булсак,
Герман кузгалмас иде...
Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде, каласың.
Мин киткәч, кемнәр иркәләр
Син сандугач баласын...

Сугышка китүчеләрне авылдан чыкканчы яше-карты, бала-чагасы елый-елый озата бара. Авыл өстендә урамнар тутырып ниндидер бер шомлы аһәң чыңлап тора. Әйтерсең, авыл өстенә күк ишелеп төшкән дә, шуның коточкыч өне калган. Сугышка китүчеләр авылдан чыгып китеп ерагайгач, авыл кинәт тынып кала, үлек чыккан йорт кебек, урамнарны шомлы тынлык баса. Этләр дә өрми. Кешеләр дә сөйләшми. Мин дә җырламыйм. Җырлый алмыйм, тамак төбемдә ачы төер, шул төер менә-менә ачы күз яшьләре булып агып китәргә тора.

Мин әле сугышның бөтен фаҗигасен тулысы белән аңлап та җитмим. Шулай да сугышның коточкыч кара болыт булып авыл өстенә җәелгән бер дәһшәт, афәт икәнен күңелем белән сизәм, тоям. Җан өшеткеч сугыш җиле безнең өйгә дә килеп керде – җизнәмне сугышка алалар. Закирә апа елый, яулык читенә яшен сөртә-сөртә, җизнинең юл капчыгын тутыра. Җизни китте. Закирә апа үксеп сәкегә капланды. Мин тын гына торам. Сугышка киткән бөтен күрше-тирә, бөтен авыл кешеләрен бик жәлләсәм дә, нигәдер миңа җизни бер дә жәл түгел. Еламыйм да. Күрәсең, минем үзәккә үткән, кырын караулары, мине артык кашык санаулары белән ул минем күңелемне суыткан, мине рәнҗеткән. Ни гажәп, аның китүенә хәтта шатландым да бугай, чөнки апа белән икәү генә калу минем өчен бәхет иде. Кешенең сугышка китүенә шатлану яхшы түгел инде, нишлисең, балалык белән мин ул турыда бик тирәннән уйлый алмаганмындыр. Чынлап та, ярлы булсак та, без Закирә апам белән икәү генә тыныч, рәхәт яшәдек. Ач тамагым, тыныч колагым дигәндәй, өйдә кычкырыш-талаш юк, миңа күзен акайтып караучы да юк. Ул чакта, бәлки, җизнине жәлләргә кирәк булгандыр, балалыгым белән мин аны жәлләмәгәнмен, ул да сугышта һәлак булып калды, мәрхүмкәй, ул да – сугыш корбаны. Нинди генә булса да, яшьли һәлак булган кеше, мин инде аны күптән бәхилләдем, урыны җәннәттә булсын, күңелемдә аңа карата бер рәнҗү дә калмады.

Безнең мәктәп, I–IV класслар, Актанышның иске мәчетенә урнашкан иде. Без шул иске мәчеттә укый идек. Җыр дәресләрен көтеп алам. Җыр дәресе башландымы, мине җырлаталар, башка класс бүлмәләреннән дә безгә кереп тыңлап торалар. Шулай итеп, III–IV класста укыган чагымнан ук мине мәктәп концертларында сәхнәгә чыгарып җырлаталар иде инде. IV классны тәмамлагач, мине Актаныш районының агитбригадасы составына кертеп, авылларга концертлар куярга алып чыга башладылар. Язгы чәчү, печән өсләрендә, урып-җыю вакытларында агитбригада авыллардан кайтып керми иде. Миннән олырак кызлар, берике яшүсмер егет тә бар иде. Җырлыйбыз, биибез, шигырьләр сөйлибез, күмәк җыр – хорыбыз да бар. Кыр станнарында, печәнчеләр янында концертлар бирәбез, кичләрен клубта чыгышлар ясыйбыз. Клубларда сукыр лампалар яндырып кына куйсак та, концертларыбызны халык бик ярата иде. Клублар шыгрым тулы була иде. Мин сәхнәдә әлеге «Шахта», «Ал Мәрфуга, гөл Мәрфуга», «Нурия»ләрне җырлыйм. Радиодан шул елларда чыккан «Өй артымда шомыртым»ны отып алган идем. Ул җыр бик озак еллар модада булды. Халык аны «Шомыртым» дип кенә йөртә башлады. «Шомыртым» минем иң яраткан җырым булып китте.

Өй артымда шомыртым бар,
Яннарында бөрлегән.
Бөрлегәндәй матур булып,
Чәчәк ата ил генәм.



Баянда – Х. Низамиев.
1953 ел

Коточкыч сугыш бара... Ачлы-туклы яшибез. Өс-баш алама. Көн саен авылга кара пичәтле похоронкалар килеп тора. Ә җырларның сүзләре – «матур булып, чәчәк ата ил генәм...» Ничек ил чәчәк атсын инде?! Ил өстендә сугышның кара болыты куерганнан-куера бара... Мин җырлыйм, сүзләренең нигә алай икәнен уйлап тормыйм, уйласам да, аңламас идем. Күп еллар үткәч кенә аңладым. Ул елларда без сәнгатьтә, бигрәк тә җыр сәнгатендә тормышны аллы-гөлле генә итеп, матурлап күрсәтергә тиеш булганбыз икән. Сәнгатьтә бу «лакировка» дип атала икән. Чынбарлыкны бизәп, ялтыратып, шомартып күрсәтү... Бу җырны радио аша шул елларның иң популяр җырчысы Зифа Басыйрова җырлый иде. Соңыннан, инде үзем җырчы булып киткәч белдем, бу җырны танылган баянчы Рокыя Ибраһимова белән Зифа Басыйрова гастрольдә йөргәндә халыктан отып алып кайткан икән. Шундый шатлыклы «чәчәк атып торган» ил турындагы сүзләрне Зифа Басыйрова үзе чыгарган икән. Җырлар шатлыклы, оптимистик рухлы булырга тиеш, башкача җырларга рөхсәт юк – җитәкчеләр куйган таләпләр шундый булган. Җырчы үзе дә шат күңелле булырга тиеш булган... Зифа апа мәрхүмәкәемнең эче тулы

ут булгандыр, чөнки аның сөекле ирен, Гений Республиканецны*, 37 нче елгы репрессия елларында халык дошманы дип кулга алып, ерак Себергә – төрмәгә озаталар. Зифа апа кечкенә улы белән ялгыз кала, аны халык дошманы хатыны дип төрлечә эзәрлеклиләр. Ә Гений Республиканец бик укымышлы, эшлекле кеше була. Казандагы Ленин музейларын беренче башлап оештырган, ачкан, совет властена чын күңелдән бирелгән, тугрылыклы коммунист... Менә шундый асыл кеше төрмәләрдә акылдан язып һәлак була... Ә аның җырчы хатыны сөеклесен һәлак иткән илне мактап, «чәчәк ата» дип җырларга мәҗбүр булган...

Шулай итеп, безнең агитбригада да сукыр лампага салырга керосин юкта, «чәчәк ата ил генәм» дип җырлый... Бер караганда, җырларның шулай булуы ярагандыр да... чөнки халыкның күңелен, рухын күтәрергә кирәк бит. Авыл кешесе сугыш китергән михнәтләрне беразга булса да онытып, ял итәргә тиеш. Аларны эшкә, хезмәткә дәртләндерергә кирәк. Сүзләре шатлыклы булса да, ул җырның көе барыбер бик моңлы, сагышлы иде. Ул җырны җырлаганда мин әллә нинди моңлы бер сагышка бирелә идем, тамашачылар да аны тыңлап моңаялар, уйланалар иде. Концерт беткәч, тамашачылар килеп, минем ябык аркамнан сөеп, рәхмәтләр әйтәләр иде. Авылларда йөргәндә тамак тук була иде. Агитбригада әгъзаларын һәркайда аш әзерләп көтеп алалар, тамак туйганчы ашаталар иде. Шулай мин озак еллар агитбригадада җырлап йөрдем. Мине район халкы белә иде. Район үзәге Актанышның зур урамында бөтен тирә-якка яңгыратып сөйләп торган радиоалгыч бар иде. Еш кына Казаннан концертлар тапшыралар иде. Багана башына беркетелгән шул түгәрәк репродуктор бөтен Актанышны яңгыратып бик матур җырлар, көйләр тапшыра торган иде. Ни хикмәттер: бер тыңлауда отып та ала, шундук кабатлап җырлый да башлый идем. Ул елларда радио аша Гөлсем апа Сөләйманова, Зифа апа Басыйрова, Рәшит абый Баһаповларның җырлауларын мин җаным-тәнем белән бирелеп, йотылып тыңлый идем.

Алар шул елларның иң популяр җырчылары иде. Халык аларның радио аша җырлауларын көтеп ала, бик яратып тыңлый. Искиткеч моңлы тавышлары, берсеннән-берсе матур җырлары белән алар халыкка бик якын иделәр. Халыкның үз көйләрен, йөрәкләре аша үткәреп, күңелләрендәге сагышка, моңга төреп, чын мәгънәсендә халыкчан итеп башкарып, алар тыңлаучыларның зур мәхәббәтен казанган олы талант ияләре, күренекле җырчылар иде шул. Аларның җырларын сабый чагымнан ук өйрәнеп җырлый башлаганыма күрә, мин аларны үземнең укытучыларым, остазларым дип саныйм. IV класста гына укыган кыз бала, мин әле ул «остазым» дигән сүзне белмим дә, андый сүзне ишеткән булсам, мәгънәсен дә аңламаган булыр идем. Әмма ләкин беркем әйтмәсә дә, беркем алардан үрнәк ал димәсә дә,

* Бик кечкенә килеш, ташландык бала хәлендә балалар йортына килеп эләгә, бу исем-фамилия аңа шул балалар йортында кушылган.

мин үзлегемнән алардан үрнәк ала, өйрәнә идем, алар кебек җырларга омтыла идем. Көйләрдәге моңлы бормаларны нәкъ аларча алып, аларча бормаландырып җырларга тырыша идем. Аларның җыр, моң дөньясындагы серле, тылсымлы гүзәл аһәңнәре мине күзгә күренмәс куллар белән тотып, әллә кая биеклеккә, йолдызларга алып китә кебек тоела, җилкендерә, ашкындыра иде...

Кышларын агитбригада авылларга йөрми, Актанышта гына концертлар биргәли. Мин инде күбрәк өйдә торам, мәктәптә укыйм. Еллар көннән-көн авырая бара. Сугыш бетми дә бетми. Колхоз эшен эшләрлек бөтен ир-егет сугышка китеп бетте. Авылларда хатын-кыз, бала-чага, карт-коры гына калды. Колхоз кырларын чүп басты. Игеннәр уңмый. Иген уңган елда да кырдан тиешенчә җыеп алып бетерергә кеше юк. Икмәк кырда, басуда кала. Ачлык. Күзләрен акайткан, яңаклары эчкә баткан коточкыч кыяфәтле ачлык авыл буйлап кешеләрне йотып килә. Закирә апам белән безнең ашарга локма ризыгыбыз юк. Йорт-җир зур булып, мал асраган кешеләр түгел, апамның малы-хайваны юк. Хезмәт хакын да бәләкәй ала. Умач уып бер-ике тапкыр аш пешерерлек арыш оны сатып алыйм дисәң, бөтен айлык хезмәт хакыңны түләргә кирәк. Көннәрдән бер көнне аш пешереп ашыйк дисәк, бер кашык оныбыз калмаган. Баздагы бәрәңгебез дә, кыш салкын килү сәбәпле, өшеп черегән. Ике-өч көн буена бер ризык заты пешереп ашамадык. Ике-өч көн ач утырдык. Закирә апа мине үз янына чакырып алды да, күзләренә килгән яшьләрен тыя алмыйча:

– Әлфия кызым, нишлибез инде, ачка үләбез! – ди. – Йөзләреңә саргайды, балакаем, күзләреңә эчкә батты, ниләр генә кылыйм, сине ничек кенә саклап калыйм?!.

Мин елый да алмыйм, ашыйсы килә, эчне борып-борып ашыйсы килә. Күз алларым караңгылана, башларым әйләнә. Башымны көчкә күтәреп, апама карап тик торам. Бераздан Закирә апа миңа бәләкәй генә бер киндер капчык тоттырды да, болай диде:

– Бар, балам, хәер сораш! Илдә чыпчык үлми, диләр. Ил бар, халык бар, ни булса да бирерләр, борып чыгармаслар. Борып чыгарсалар тагы... чыгарсың да китәрсең... Хәер сорашуның гөнаһысы юк, дөньясы шулай булгач. Ачлык китереп кыскач, хәер сорашмый нишлисең?.. Әзрәк тамагыңны туйдырырлык ризык заты бирмәсләрме?.. Бәлки, мин дә бер-ике кабармын...

Кемнәргә керергә, кемнәр хәллерәк, кемнәр саран түгел, юмартрак – шуларның өйләрен күрсәтеп, өйрәтеп, апам мине урамга чыгарып җибәрде. Мин капчык тотып урамга чыктым да апа өйрәткән кешеләргә кереп киттем. Ике чи бәрәңге бирделәр. Тагын берәүләргә кердем, алабута кушып пешергән ярты телем бәрәңге кәлҗемәсе бирделәр. (Бүгенге яшьләр кәлҗемә дигәнне аңламыйлардыр да инде, ул черек бәрәңгегә алабута оны кушып әвәләп пешергән кабартма, коймак сыман нәрсә.) Ипи дигәнне күргән дә юк.

Ипи ашаучы кешеләр авылда бар микән, юк микән – белмим. Байтак йөрдем. Кемнең моржасыннан төтене чыга, шуларга керәм. Урамда миңа тагын бер ятим кыз бала иярде. Капчыкларыбызны тотып йөрергә оялабыз. IV класс укучылары бит инде без. Җитмәсә, мине бөтен авыл белә, таный, агитбригада концертларында җырлап йөргән башым белән хәер сорашам... Җырлау, җырлар башымнан бөтенләй чыгып китте... Тавышым да чыкмый... авызны ачып сүз әйтергә дә хәл юк... Ашыйсы килүдән башка күңелдә бер уй, бер теләк юк... Хәер сорашу бик авыр икән... Хәлсез аякларыбызны көчкә өстерәп кеше ишек төпләренә килү шулкадәр кыен. Хәзер исемә төшсә, тәннәрем чымырдап китә – ничек түздек, ничек кулларыбызны сузып кеше биргәнне алдык икән?.. Менә алты балалы бер апаларга кердек. Әтиләре сугышта, бер хәбәре дә юк икән. Балалары сәкедә тәгәрәп авырып яталар. Өйләре суык, бер локма ризыклары юк. Әниләре колхоз эшенә киткән. Тагын берәүләргә кердек, аларның да өендә шул ук хәл. Балалар авырып ята, өйдә сукыр әбиләре генә кармаланып йөргән була. Без бүтән беркемгә дә кермичә, өйләребезгә кайтып киттек. Капчыгыбыз буш, тамагыбыз ач. Ашыйсы килүдән күз аллары караңгыланып китә. Шулай да егылмаска тырышам. Күз алдында сәкедә тәгәрәп авырып яткан балалар... Авызларыннан кан килә... Бавыр-бавыр кан косалар... Бәргәләнәләр... Бер-ике көн үттеме икән, әлеге алты балалы өйдә өч бала бер көн эчендә вафат булды. Ул алты бала алтысы да үлеп беттеләр. (Әлеге өч бала үлгән көнне бер урамда барысы тугыз бала үлгән иде.) Хәлем булмаса да, кешеләргә ияреп зиратка бардым. Үз күзләрем белән карап, күреп тордым: зур бер чокыр казыдылар да, чыптага төреп, тугыз баланы тезеп салып, бер кабергә күмделәр. Ачлык ул елларда безнең яклардан бик күп кешене, бик күп балаларны гүргә кертте. Кырда калып кышлаган, агуланган башак җыеп ашаган бик күпләр бу дөньядан вакытсыз китеп әрәм булды.

Үлсәң дә хәер сорашып йөрергә мөмкин түгеллеген аңладым һәм Закирә апама да аңлаттым. Без икәүләшеп елаштык та, үлсәк үләрбез, хәер сорап беркемгә дә кермәбез, дигән уйга килдек. Базыбыз төбендә өшеп черегән бәрәңгеләрне пешереп ашаган булып, җан саклыйбыз.

Ике ач янына, көтмәгәндә-уйламаганда, тагын ике ач тамак килеп кушылды: Ленинградтан әниемнең бертуган сеңелесе Мәсрүрә апа кайтып керде, кулында яшь баласы, аркасында буш капчыгы... Ленинград блокадасын мең бәла, мең михнәт белән кичереп, ил буйлап хәер сорашып, кем нинди ризык бирә алса, шуны ашап кайтканнар. Безнең Актанышка кайтып җиткәндә, бөтенләй авызларына ризык кермәгән, шешенә башлаганнар... Үзебезнең авыздан өзеп, Ленинградтан кайтып егылган апа белән кечкенә сеңелем Инсөяне ашатабыз, аякка бастырырга тырышабыз. Черек бәрәңге боткасын кеше башына бер-ике кашык бүлеп ашыйбыз... Мәсрүрә апам Ленинградтан киеп кайткан күлмәкләрен сата башлады... Хәтерләмим, каяндыр, кемнеңдер сыерын алып кайттылар. (Әллә берәрсе үзе карый алмаганга безгә биреп торды,

әллә безнекеләр сатып алды – исемдә юк), әзрәк тамак туя башлады. Ләкин озакка бармады, бу сыерны сатарга туры килде, чөнки аны асрарлык печән булдыру безнең көчтән килми иде. Закирә апам колхозга эшкә йөри башлады. Күлмәкләренә, бигрәк тә ыштанына зур итеп кесәләр текте. Шул кесәләргә басудан бодай, арыш, борчак тутырып алып кайта иде. Шуларны мичтә киптереп, караңгы базга алып төшеп, ярма яргычта ярып, ярма ясый идек, өйрә пешереп ашый идек. Балаларны тикшереп тормыйлар икән дигәч, Җыракай мине дә басуга ияртеп алып барып, минем ыштанга да ашлык тутырырга булды. Тездән югарырак ике аягымны да бау белән бәйләде дә, өске яктан ыштаныма бодай тутырды. Ыштан балакларым кабарып торса да, киң күлмәк итәгем озын, ул-бу сизелми кебек. Тик атлап булмый, ботлар «юанайды», кылчыгы-ние белән тутырылганга, кылчык кадала, бот төпләре, тагын әллә кай төшләр авырта, мин елыйм. Җыракай: «Ачка үләсең килмәсә, җылама», – дип, мине әрли. Шулай берничә көн мин дә ыштан төбемә тутырып, шактый бодай алып кайттым. Без генә түгел, авылның күпчелек колхозчылары шулай кесәләренә тутырып, басудан орлык урлап кайтырга мәҗбүр иде ул елларда. Нишлисең, ачтан үлмәскә тырышасың. Бәрәңге шулпасына шул ярманы салып өйрә пешерәбез, хәйран тамак туйгандай була.

1944 ел иде бугай... Ашамый-эчми мәктәпкә китәм... Мәктәптә көне буе ач утыргач, ач килеш өйгә кайтам... Ленинградтан кайткан сеңелем инде үсеп килә, сөйләшә, сабыйларга хас беркатлылык белән әйтеп куя:

– Без аш ашадык инде... Әбекәй табакны юып куйды... – ди. Миңа шулкадәр авыр булды... Ашның исе генә калган өйдә, хәлсез утырам... Син бит бүген ашамаган, диюче юк... Кеше баласы – кеше баласы шул... Кеше баласы беркемгә дә кирәкми... Әниемнең бертуганнары бит, югыйсә, үз карыныннан өзелеп төшмәгән шул, үз бәгырьләрен кисеп, дөньяга тудырмаганнар шул... Үзе дөньяга тудырмаган кешегә кеше баласы кеше баласы инде... үз әниең түгел... Их, үз әнекәем булса... үз авызыннан өзеп, ризыгын баласына – миңа калдырыр иде... Шул вакытта Флүрә сеңелем белән бергә мине дә балалар йортына биргән булсалар дип, бик каты елап алдым. Флүрә кайдадыр, ни хәлдә яшидер – берни белмибез. Закирә апама да, Мәсрүрә апама да, икесенә дә рәнҗеп; үпкәләп йөргән көннәрем күп булды... Кыш беткәнне тилмереп көтә идем... Инде V класста укыйм. Күңел укуда түгел, күңел язны көтә. Чөнки кышларын агитбригада авылларга йөрми, мин кышны ачлы-туклы үткәрәм, яз җиткәч, чәчү башлангач, җәйләрен кыр эшләре кызган көннәрне агитбригада авылларга чыга, ә авылда инде тамак тук була...

Мин VI класста укыганда Ленинградтан кайткан апам кызы Инсөя белән вербовка буенча Казанга китте, анда җитен комбинатында эшли башлады. Без Җыракай белән икебез генә калдык. Тамак туя башлаган иде. Җыракай колхоз басуыннан еш кына кесәләрен тутырып кайта... Ләкин бу туклык озакка бармады... Бер көнне Җыракайны бодай белән тоткаллар. Кесәләренә

тутырган бодаен бушатып, үлчәгәннәр – дүрт кило бодай чыккан. Апамның эше харап. Аны судка бирделәр. Колхоз җитәкчеләре бик каты тоталар, дәүләт ашлыгын урлаучы корткычларны төрмәгә ябарга, диләр... И Ходаем, минем Җыракаемны корткыч, диләр... Ачтан үлмәскә әллә нидә бер кесәгә салып алып кайткан орлык өчен корткыч бул!.. Колхоз үзе бер грамм бирми, уракка төшеп, ашлыкны суктыра башлагач, хезмәт көненә йөзәр грамм он бирәчәкләр, диләр. Шул көннәр җиткәнче адәм баласы ничек яшәргә тиеш? Ирексездән «карак», ирексездән «корткыч» булырсың! Җыракай, менә килеп алып китәләр, менә алып китәләр, дип, көне-төне калтырап, ут йота. Үзен төрмәгә алып киткәнче мине берәр кая урнаштырырга уйлый. Әлеге Нажия апа Бәширова белән сөйләшеп, киңәшеп, Җыракай мине Яңа Әлем авылына детдомга бирергә булды. Нажия апа миңа кирәкле белешмәләрне, документларны әзерләде. Мин күрше Яңа Әлем авылына чыгып киттем. Безнең Актаныштан 6 чакрым ераклыкта. Кулымда иске клеенкадан теккән букча. Аның эчендә бер-ике дәфтәр, китаплар салынган. Авызга кабарлык бер ризык заты юк букчамда. Аягымда берсе – хатын-кыз чабатасы, берсе – ир-атныкы, кем биргәндер, хәтерләмим. Әллә үзем берәр җирдән алып кигәнмен, кешеләр иске чабаталарын ыргытмыйлар, киртә казыкларына элеп куялар иде, берәрсе алып кисен, диләр иде микән?.. Менә шулай аякта иске чабаталар, өстә кырык ямаулы иске бишмәт...

Өйдән чыгып киткәндә, Җыракай еламады да бугай... елаганы хәтердә калмаган... Актанышны чыгып биек тау башына менеп җиткәч, туктап, артка борылып карадым... Апамның йорты күренә... Бәләкәй генә, мескен булып... Моржасыннан төтене дә чыкмый... Аякларның хәле юк, тау менгәндә бөтенләй хәлсезләнгәнмен... Ашыйсы килә... Озак карап тордым... Бергә укыган дус кызларымның моржаларыннан төтен чыга... Тәмам күңелем тулды... үксеп елап җибәрдем... Нигә мине Җыракай шушы тауга кадәр дә озата менмәде икән?.. Бу кадәр рәхимсез түгел иде бугай бит ул?.. Ни булды соң аңар? Үз кайгысы каты иде шул, төрмә көтә иде аны... Сугыш бетми дә, бетми... Сугыш башланган елларны бу кадәр үк авыр түгел иде бугай... Инде өчдүрт ел барган сугыш тәмам илне бөлгенлеккә төшергәндер, елдан-ел авырлаша бара, елдан-ел ачлык көчәя... Ашыйсы килү Җыракайга булган үпкәләрне дә оныттырды. Тирә-якка карыйм, ап-ак кар... кар... бер тырпаеп калган салам заты да юк, ичмасам... Салам кабып чәйнәр идем... Яңа Әлем күренми. Юл буе берьялгызым атлыйм... Кыш башы гына әле. Ярый, көн артык суык түгел. Шулай да кар күп...

Ул елларда кеше ачлы-туклы яшәсә дә, бер-берсен кыйнау, талау, үтерү кебек хәлләр бик сирәк ишетелә иде. Бигрәк тә минем кебек яшүсмер кыз бала берүзе генә юлга чыкса, куркыныч хәлләргә тап булыр дип уйлау, курку юк иде. Хәзер генә ул хулиганнар чыгырдан чыкты, хатын-кызларга, яшүсмер кыз балаларга ялгыз гына юлга чыгу куркыныч. Ул елларда «хулиган» дигән

1952 ел



сүз бик сирәк ишетелә иде. Ап-ак карга күмелгән тип-тигез кырлар буйлап сузылган юлдан барам. Шулай да, ничектер, куркып та куям... Ә менә качкыннар турында күп сүзләр йөри иде. Урманнарда сугыштан качып кайтучылар, яки сугышка китмәс өчен яшеренеп ятучылар турында куркыныч сүзләр сөйлиләр иде. Куркыныч дисәм дә, ул качкыннар беркемгә дә тимиләр икән, дип әйтәләр иде. Аларның кыяфәтләре генә куркыныч икән. Аннан соң шунысы – тота калсалар, аларның үзләре өчен куркыныч икән. Милицияләр андыйларны тотса, аякларын җиргә дә тидермичә – сөргенгә, әллә кая ерак Себергә озата икән, дип сөйлиләр иде. Качкыннар бит, газизкәйләрем, ихтыярсыздан качаклыкта йөргән үз кешеләребез булган, лабаса. Алар шул туган төбәкләренә якынрак урманнарда качып яшәгәннәр, бәлки, өйләренә дә кергәләп, төннәрен хатыннарын, балаларын күргәләп чыгучылар да, әзрәк ризык алып китүчеләр дә булгандыр... Андыйлар турында да сүзләр йөри торган иде. Кайбер качкыннарны үз күзләре белән күргән кешеләр дә бар иде. Бер апа арыш басуында, башаклар тулышып килгән көннәрдә, арыш уып ашап утыручы бер качкынны күрә. Сакал-мыек баскан, ди... Үзе хатын-кыз күлмәге кигән, ди... Апаны күргәч, иелеп кенә йөгерә-йөгерә, урманга кереп

юк булган, ди... Әлеге апа һушсыз булып катып калган, куркудан теле тотлыккан, әзрәк аңын җыйгач, авылга йөгергән, качкын күрдем, котым очты, дигән. «Кешегә сөйләп йөрмә, күргән җиреңдә калсын... Бичара качкын, бәлки, үз авылыбыз кешеседер», – дигәннәр бу апага.

Еракларга сузылган кырлар өстендә ниндидер кара шәүләләр кыймылдаган кебек... Кыш көне качкыннар түгелдер инде... Ул елларда безнең якларда бүреләр бик азган иде. Ир-ат – сугышта, бүреләргә атучы юк, бүреләр, мыltык тавышы ишетелмәгәч, рәхәтләнеп үрчиләр... Еш кына караңгы төннәрдә авылларга килеп, абзарларда калган юклы-барлы сарыкларны буып, ашап китәләр... Кыймылдаучы кара шәүләләр – бүреләрдер... Килеп мине урап алсалар?.. Йөрәгем уч төбемә төшкәндәй өзелеп китә... Сулышым кысыла... Бер атлыйм, бер йөгерәм... үземнең хәлсез аякларыма үзем абынып егылам... Тагын торып йөгерәм... Бүреләр ашап, сөякләре генә калган кыз турында кемдер сөйләгән хикәят исемә төшеп, күз алларым караңгыланып китә... Шулай берүзе генә күрше авылга әбиләренә барырга чыккан бер кыз баланы бүреләр өзгәлән бетергән, кап-кара чәчләре, сөякләре генә җиргә сибелеп калган, ди... Шулай курка-курка бара торгач, авылга якынлаштым. Инде, ниһаять, бүреләр килеп чыкса да, авылдан ишетелгән этләр өрүеннән шүрләрләр, миңа ташланмаслар, дип уйлыйм. Менә Яңа Әлемгә килеп җиттем. Исеме Яңа Әлем булса да, иске өйләр – барысы да диярлек салам түбәле... Урамда очраган апалардан сорыйм:

– Дитдум кайда?.. Балалар җыя торган урын?..

– Әнә, ишек алдысы да юк, салам түбәле бер йортны күрәсеңме? Шул инде безнең дитдум, – диләр апалар.

Шул йортка таба киттем... Урамдагы апалар, минем арттан карап:

– И мескен бала!.. Ятимдер инде... Ятим булмаса, килмәс ие... Чабатасы теткәләнеп беткән... Ерактан килә микән?.. – диешеп калдылар. Дитдум дигәннәренә килеп җиттем. Карап торам: балалар яланаяк, яланөс, йөгереп тышка чыгалар да, баскыч төбендә генә пес итеп, йөгереп кире өйгә кереп китәләр. Авыр ишекне көчкә ачып кердем. Ни күзем белән күрим: Актанышта үземне укыткан Гөлсәйдә апам басып тора. Мине күрү белән, елый-елый, кочаклап алды:

– И-и, Әлфия, бәбкәем!.. Син дә килдеңмени?.. И-и, ятимем минем! – дип, аркамнан сөя-сөя, чишенергә булышты. Суыктан күшеккән кулларымны сулышы белән өреп җылытты. Минем иң яраткан укытучы апам бу балалар йортына үзенең өч баласын иярtеп, аларны ачтан үтермәс өчен, тәрбияче булып эшкә килгән икән. Мин шулкадәр куандым: иңнәремә канат үсеп киткәндәй булды. Бәләкәй генә өй эче тулы бала... Мич башына карасам, җылыда бер-берсенә сыенып, өч-дүрт-биш яшьлекләрдер, балалар утыра. Озын сәке, анда да балалар... Сәкенең бер башында өстенә киндер күлмәк, тишек ыштан кигән бер малай утыра, карасам, тома сукыр икән. Берни күрми... Габделхәй исем-

ле бу малайны бик жәлләдем. Сөйләшми дә... V–VII классларда укучы кыз балалар күп иде. Алар белән бик тиз дуслаштым. Мәктәпкә бергә барабыз, бергә кайтабыз. Бергә укып, бергә дәрес әзерлибез. Укудан соң уйныйбыз. Күңел күтәрелеп китте. Тамак тук, өй җылы. Балалар йортының директоры – Шәрәпов абый, аның хатыны – тәрбияче Роза апа – бик яхшылар, безне яраталар, жәллиләр.

Безнең балалар йортына киемнәр кайта башлады. Америка җибәргән киемнәр икән, диләр. Әлбәттә, болар яңа киемнәр түгел, искеләр, шулай да бик матурлар, безгә өләшәләр, без куанып киябез. Ашарга икенче йортка йөрибез. Икенче йорт, дигәне ашханәдер инде. Урын-җир ярлы-ярлысын, ак җәймәләр-фәләннәр юк, киндер капчыкка тутырылган салам яки печән түшәкләр, шулай да зарланмыйбыз, бер гаилә балалары кебек дус, тату яшибез. Әлеге тома сукыр Габделхәйне миңа беркеттеләр. Мәктәпкә дә, ашарга да җитәкләп йөрим. Минсез бичаракай беркая бара алмый. Ятимлек, сабыйлык булгандыр, ул вакытта оялу дигәнне белмибез, гел җитәкләшеп йөрибез. Алга китеп шул турыда языйм әле: бу сукыр Габделхәйне мин озак еллар үткәч, инде артистка булып, танылып, ерак гастрольләрдә йөри башлагач, Урта Азиядә очраттым. Минем концертыма килгән иде. Сәхнә артына керде, кочаклашып елаштык. Укыган, югары белем алган, сукырлар мәктәбенең директоры булып эшли икән. Югалмаган, төшеп калмаган, менә дигән кеше булган. Гаилә корган, балалар үстергән. Акыллы малай иде шул ул. Сукыр булса да, укырга тырыша иде. Кешелекле, сабыр холыклы иде. Габделхәй белән Ташкентка барган саен очрашабыз, ул мине үзенә кунакка алып китә, сабый чакларыбыз, ятим үскән балачакларыбыз турында сөйләшеп, елашып утырабыз. Мин аның шулай укып, директор дәрәҗәсенә ирешеп, эшлекле кеше булуына куанып бетә алмыйм.

Балалар йортында яшәгән чакларым һич тә күз алдымнан китми. Дәрес әзерләргә утырсак, ручкалар җитми иде, ручкага чират тора идек. Дәфтәрләр дә бик күп эләкми иде, кәгазь дигән нәрсәне саклап кына тота идек. Газета-журналларның ак җирләре калган булса, без аны кисеп алып, файдалана торган идек. Хәзерге балалар, яшүсмерләр кәгазь кадерен белмиләр, дәфтәрләрен саклап тотмыйлар, әз генә язгалый-сызгалыйлар да чүплеккә ыргыталар. Мин урамнарда, чүплекләрдә башланган да ташланган дәфтәрләрне күреп әрним. Өлкәннәрнең дә кәгазьгә саксыз булуларына ачуым килә. Теләсә кем теләсә ничек кәгазьне исраф итә. Кәгазь бит – бик кыйммәтле әйбер. Аны ясауга күпме агач материал китә, күпме кеше хезмәте керә. Бер яктан, кәгазь җитми, кәгазь җитмәгәнгә күрә, теге яки бу китапны чыгара алмыйбыз, дип сөйләнәләр, икенче яктан, кәгазьне теләсә ничек исраф итәләр.

Балалар йортында яшәгәндә, үзенә күрә, күңелле дә иде. Ни дисәң дә, тамак тую – тамак тую инде. Җырлыйсы да килә башлады. Концертлар

оештырып, үзебезчә күңел ачабыз. Мин башлап йөрим. Җырлыйм да, биим дә, концертны алып та барам. Миннән күреп, башкалар да катнаша. Төрле җирләрдән килгән ятим балалар бик матур, бик моңлы көйләр беләләр иде. Дәрестән калган вакытларыбызда җырлашып, моңаешып утыра торган идек. Ул елларда «Хуш, авылым» җыры бик модада иде. Соңыннан белдем, Салих Сәйдәшев җыры икән. Сәйдәш шулай безнең күңелләргә сабый чактан кергән:

Туган җирем, сөйгән авылым,
Бигрәк якын күңелгә.
Кай илләрдә яшәсәм дә,
Оныта алмам гомергә...
Хуш, авылым, сау бул!..

Барыбыз да авыл балалары шул... Авылларыбызны сагынабыз... Балалар йортында бик күп көйләр, җырлар отып алдым. Күбесе аларның татар-башкорт халык көйләре булган. Шулай VII классны тәмамладым. Инде үстегез диеп, безне балалар йортыннан чыгардылар, колхоз эшенә йөрергә, кырдан башак җыярга куштылар.

Мин балалар йортына китеп, бер-ике көн узу белән, Җыракайны кулга алганнар, биш елга төрмәгә утыртырга хөкем иткәннәр. Свердловск өлкәсендәге ниндидер төрмәдә утыра икән. Шулай Җыракаем «җинаятьче» булып, төрмәдә җәфа чигә икән. Актанышның халык судында ул елларда Рифкать абый Габитов эшли иде. Аның әнисе Марзия апа Габитова гомере буе укытучы булып эшләгән бик әйбәт апа иде. Шушы гаилә минем Җыракаем өчен бик борчылып, Җыракаемны коткарырга тырышып, Казанга хат артыннан хатлар, ятим бала карый ул, дип, гаризалар язып, бөтен халыктан кул куйдырып, бик зур яхшылык, игелек эшлиләр. Ниһаять, биш ел урынына, апама ике генә ел бирәләр.

Балалар йортыннан чыгаргач, кая барасың, Актанышка кайтырга булдым. Шул Актаныш инде... Тик менә кая, кемгә кайтып керергә?.. Җыракай төрмәдә... Башка туган-тумача юк... Актанышның тау башына килеп җиттем дә кемгә кайтып керим икән дип, уйга калдым. Актаныш тын гына моңаеп утыра... Ниндидер моңлы көй көйләгән кебек... Күршебездә генә яшәүче Хөббетдинова Гашия апаларга кайтып керергә булдым. Гашия апалар белән бик йөрешеп, күршеләр буларак бик тату, дус яши идек. Гашия апа, бишкуллап каршы алгандай, якты чырай белән каршыма йөгереп чыкты. Өстәлендә самавыры кайнап тора. Алабута кетеркәе капкалап, бик рәхәтләнеп, сөйләшеп, көлешеп чәй эчтек. Гашия апа балалар йорты турында сораштыра. Мин аңар күңелле булсын дип, гел кызыклы хәлләр сөйлим, бер дә балалар йортындагы ятимлек, кайгы-хәсрәтле хәлләрне искә төшермим. Гашия апага сөйләп,

көлдереп утырган бер шаяруым турында языйм әле. Бала – бала бит инде ул. Детдом баласы булса да, уйный да, шаяра да... Без дә, тәрбияче апаларыбыз күрмәгәндә, шаярып ала торган идек. Бер кичне шулай мин берүзем концерт куйдым. Җырладым, шигырьләр сөйләдем, биедем. Габдулла Тукайның «таз малае» булып, аркама поднос куеп, «Таз» шигырен сөйли-сөйли театр уйнадым. Бер малай казый булып, минем подноспы аркама чаж-чож талчыбык белән сукты. Уйный торгач, «таз малай»га мин мичтән корым алып мыек та ясап куйдым. Кызлар каршына килеп, мыекларымны бөтергәндәй итеп, җырлап та җибәрдем:

Сызылып киткән кара мыек,
Ничек үбәрсең кыеп?..



1965 ел

Концерт әле дәвам итәр иде дә, сукыр лампаның керосины бетте. Ут сүнде. Арып-талып сәкегә барып аудым. Иртән торгач, мәктәпкә барыр алдыннан комганнан бер-беребезгә су салып торып, битне-күзне юа торган идек тә, бу юлысы соңга калыбрак уянганмын да, юньләп юынып тормыйча гына, ашыгып мәктәпкә чапканмын. Укытучы апа миңа карый да көлә, карый да көлә... Ахры, түзмәде, минем янга килеп, түгәрәк көзгесен минем борыныма терәде:

– Әлфия!.. Әллә төнлектән төштеңме син? – ди.

Көзгегә карасам, мыегым бөтен битемә сыланган!..

Ятим үссәм дә, ачлы-туклы булсам да, шаярырга ярата идем шул. Шук идем. Балачагымдагы шуклыкларым, бәлки, ятимлегемне оныттырып торган булгандыр. Шуклык, шаяру гомерем буена юлдаш булды инде анысы. Чәй эчкән арада Гашия апаны көлдереп, Яңа Әлемдә өйрәнгән такмакларны җырлап күрсәттем:

Атлас түгел, ефәк түгел –
Синең дә кигәннәрең.
Чыпчык булып чыктымыни
Сандугач дигәннәрең?..

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Биктимер.
Ярларыңны җепкә тез дә
Клиндер итеп кимер.

Сусадым су буенда,
Булмыйм, җаный, туеңда,
Булмасам-булмам туеңда,
Күп йокладым куеныңда.

Гашия апа: «Каян бу хәтле кызык җырулар оттың?» – дип шаккатты. Үзем чыгардым дип кенә җибәрәм.

Гашия апаларда торам. Бары – бергә, югы – уртак дигәндәй, бер кабымлык ризыкларын минем белән бүлешәләр, әйтерсең лә, үз балалары...

Балалар йортыннан кайткач, VIII класска укырга бардым. Өч-дүрт айдан елын тутырып, Җыракай кайтып төште... Ходай аны күркәм, сылу итеп яраткан иде. Ап-ак түгәрәк йөз, чем-кара күзләр, чем-кара кашлар, кап-кара бөдрә чәч... Шуларның барысы өстенә, чын татар хатыннарына хас ягымлылык... Сулып, ябыгып, төсе китеп кайтып керде Җыракаем. Түгәрәк йөзе, ничектер, озынча булып калган, бит очлары эчкә батып кергән, гәүдәгә кечерәеп киткән кебек, ничектер, бөкрәебрәк йөргән шикелле. Бик жәлләдем үзен. Яңа



1955 ел

Әлемгә киткәндә озата бармаганы өчен үпкәләвем дә онытылды. Кочаклашып елаштык. Ихатасыз калган салам түбәле өебезне ачып кердек. Өебез дә үзебез кебек ятим. Кыйгаеп, авышып, җимерелеп бара. Шулай да җаны бар – мич артында чикерткә сайрый... чикерткә сайраганын ишеткәнегез бармы?.. Шундый моңлы итеп сайрый ул... Җан өзгеч тавышлар чыгарып, бәгырьне кисеп-кисеп ала... Иске фәкыйрь өйләрдә, ятим кешеләр яшәгән өйләрдә сайрый ул... Чикерткә, бәгырькәем, безне тилмереп көткәндер... Чикерткә тавышын ишеткәч, сәкегә утырып тагын бер елаштык... Бу өйнең коймаларын, абзар-кураларын кемнәрдер сүтеп алып ягып бетергәннәр. Баскычларын, түшәм такталарын, хәтта идәннәрен дә сүтеп алгалаганнар. Кеше торырлык түгел инде. Шулай да Җыракай белән ул өйдә берничә ай торып карадык. Торып булмаслыгын аңлагач, икәүләп Гашия апаларда тора башладык. Без икәүләп Гашия апаларның үз кешеләренә әйләнеп беттек. Гашия апаның яшькә миннән олырак Сажидә исемле кызы бар иде. Без ул Сажидә белән, күршеләр буларак, гел бергә уйнап үстек. Сажидә Вагыйз исемле абыйга кияүгә чыкты. Вагыйз абый Ильясов сугышларда йөреп кайткан, утны-суны кичкән фронтовик – бик яхшы кеше булып чыкты. Сажидә белән бик матур гомер итәләр. Миңа да, Җыракайга да Вагыйз абый үз туганнарына караган кебек карап, гомер буе мәрхәмәтле булды. Бер гаилә кебек, бер табыннан ашап, барын-югын уртаклашып, кайгы-хәсрәтне бүлешеп яшәдек.



Флүрә Авзалова, аның кызы Светлана, ире Иван, Закирә апа (Җыракай). 1957 ел

Бу елларда мин инде агитбригада концертларында бик күп җырлый идем. Минем катнаштан башка бер генә концерт та булмый иде. Бу инде минем үземчә тамак туйдырырлык эшли башлавым иде. Актаныш район партия комитетының беренче секретаре Сәхаби абый Камалиев мине бик ярата иде. «Минем талантлы кызым» диеп йөртә иде. 16 яшем тулып килгәндә, «бу кыз бала буй җитеп килә, бераз өс-башын карасын», дип, Камалиев абый һәм районның культура бүлеге мөдире Кәримә апа Рәяновалар мине Актаныш МТСының кечкенә клубына эшкә урнаштырдылар. Бу клубның уку бүлмәсе – китапханәсе бар иде, мин шунда МТС эшчеләренә китаплар бирәм, концертлар оештырам. Актанышта ул елларда бик яхшы баянчылар бар иде. Фотограф булып эшләүче Мәрзия апа Юнысова әнә шундый яхшы баянчыларның берсе иде. Ул мине үз янына чакырып ала иде дә, төрле-төрле матур көйләр өйрәтә иде. Нинди генә матур, моңлы көйләр өйрәтмәде ул апа миңа! «Әллүки», «Зиләйлүк», «Уел», «Кәккүк», «Гөлҗамал»... Каян шулкадәр көйләр белгәндер ул Мәрзия апа!.. Баянда искиткеч матур итеп уйный иде. Кайда, ничек, кемнән шулай матур көйләр откандыр, ничек шулай матур, моңлы итеп уйнарга өйрәнгәндер, кем аны шулай өйрәткәндер, яшьлегем белән мин сорашмаганмын, ул үзе әйтмәгән. Хәзер уйлыйм да исләрем китә, хатын-кыз – фотограф, хатын-кыз – баянчы!.. Авыл җирендә түгел, шәһәр җирендә дә сирәк очрыйдыр. Аның кебек сәләтле хатын-кызлар сугыш вакыты, сугыштан соңгы елларда, ир-егетләр аз калганлыктан, кулына фотоаппарат, баян алгандырмы, белмим, һәрхәлдә бу Мәрзия апа искиткеч талантлы, уңган, ты-

рыш апа иде. Мин яшүсмер вакытымда аның кулына эләгүем белән бәхетле булганмын. Ул миңа халкыбызның моң дөньясын ачкан, миңа моң гыйлемен өйрәткән икән. Ул чорда авыл җирләрендә музыка мәктәпләре юк иде. (Алар әле хәзер дә юк диярлек, бик аз.) Башлангыч музыка белеме алу дигән нәрсә авыл баласы өчен башка да килгән эш түгел иде. Ә менә Мәрзия апа миңа, үзе дә сизмәстән, миңа да белдермәстән, башлангыч музыка белеменнән башка да бик кадерле, бик әһәмиятле нәрсәләр – халык көйләренең тел белән әйтеп, аңлатып бетермәслек хиссиятләрен ачып биргән. Рәхмәт, мең рәхмәт аңар!..

Мәрзия апа халык көйләрен генә түгел, шул еллардагы композиторларның җырларын да өйрәтә иде. «Юксыну» (Ш. Мәҗитов музыкасы, С. Хәким сүзләре), «Сагыну» (З.Хәбибуллин музыкасы, М. Җәлил сүзләре) җырларын миңа Мәрзия апа өйрәтте. «Су буйлап», «Кошлар кебек», «Рамай» шикелле халык көйләрен, гомумән, шул елларда чыккан барлык көйләрне, җырларны өйрәтеп, Мәрзия апа минем белән көннәр буе эшли, вакытын кызганмый иде. Агитбригада концертларында җырлар өчен минем репертуар инде шактый зур иде, берүзем бер сәгать җырларлык җырларым бар иде. Агитбригада белән авылларга чыккач, үземнең тамак тук булу гына түгел, Җыракайга да ризыклар алып кайткалый идем. Бераз акча да алам, өс-башны да карыйбыз. Кайсыдыр ил – тагы шул Америка җибәргән бугай, ятимнәргә киемнәр бүлеп, өләшеп чыктылар. Район җитәкчеләре миңа да бер пальто, ике күлмәк бирделәр. Яңа түгел, киелгән инде, шулай да бик куандым. Актанышта бергә уйнап, бергә укып үскән дус кызларым Сажидә, Мәнфүсә, Гөлүсә, Ләйсән, Демфира, Нәкыяларны гомерем буена сагынып искә төшерәм. Бигрәк акыллы, инсафлы кызлар иде. Миңа аларның әйбәт тәэсире йоккан, аларның тәрбияле булулары миңа уңай йогынты ясаган, мин, начар юлларга кереп китмичә, буй җитеп, үз көнемне үзем күрерлек тормыш юлына аяк атлаганмын.



Иптәш кызларым белән

1950 ел ахырындамы, мине Камалиев абый: «Талантыңны әрәм итмә, кызым, Казанга бар, укы», – дип үгетләп, Казанга җибәрде. Хәмит абый Гафаров мине алып килеп, Казанның музыка училищесына укырга урнаштырды. Тулай тораклары юк, квартирада торырга кирәк. Квартирага түләргә акча каян аласың?.. Укый алмадым мин, кире Актанышка кайтып киттем. Агитбригадада җырлавымны дәвам итәм. Сәхнәдән төшмим. Безнең район җырларенә танылган артистлар – Рәшит Вahапов, Зифа Басыйрова, Әзәл Яһудин, Гани Вәлиев, Сара Садыйкова, Рокыя Ибраһимовалар еш килеп концертлар бирә иде. Мине җырлатып карыйлар иде дә: «Бу кыз җырчы булачак, талантын сүндермәгез, Казанга җибәрегез», – диләр иде. Зифа апа, мәрхүмәкәем, бервакыт мине җырлатты да, аркамнан сөеп: «Син тумыштан җырчы икәнсең бит, сеңелем!» – диде. Әзәл абый Яһудин да: «Сиңа, һичшиксез, Казанга китәргә, җырчы булырга кирәк!» – диде. Нишләптер, минем бер дә Актаныштан китәсем килми иде. Актанышның комсомол райкомы секретаре Марсельеза Газетдинова, мине райкомолга чакырып алды да, Казанга китәргә үгетли башлады:

– Комсомол өлкә комитеты белән сөйләштем. Казанга – Җыр һәм бию ансамбленә алалар, җитәкчесе Зөләйха Әхмәтова риза, «килсен, көтәм», диде. Әйдә, җыен, Әлфия, киләчәгең зур сәхнәдә булырга тиеш синең, – ди. Үземнең якташым, Актаныш районының Уразай авылында туып-үскән күренекле язучы Риза абый Ишморат та ялга кайткан арада безнең агитбригада концертын караган иде. Ул да Казанга баргач, тиешле кешеләр белән сөйләшермен дигән иде, киңәшләрен биргән иде.

Уйладым-уйладым да Казанга китәргә булдым. Чынлап та минем киләчәгем сәхнәдә булырга тиеш, дигән карарга килдем. Чөнки җыр бөтен тормышымның якты маягы шикелле мине гел дәртләндереп, татлы җилкендереп тора. Мин гел җырлыйм, гел яңа җыр өйрәнәм, гел җырлау турында гына уйлыйм... Башка бер эш, бер һөнәр мине кызыксындырмый...

Мин Актаныш халкына мәңге рәхмәтлемен, үземне Актаныш халкы алдында мәңге бурычлы саныйм. Чөнки актанышлылар миңа һәрвакыт ярдәмчел булды. Мине бер генә кеше дә рәнҗетмәде, һәркем кулыннан килгәнчә ярдәм итте... Сажидә, Вагыйз абый, Бибинур апа, Җәннәт апа кебек күрше-колан ятимлегемне белеп, минем хәлемә керде, ятимлегемне онытырырга тырышып, күңелемне күрергә омтылды. Авыр сугыш елларында да миңа Актаныш иң матур, иң ямьле җир булып тоела иде. Актаныш кешеләре дөньяда иң яхшы күңелле кешеләр булып хәтердә калган. Берәм-берәм исемә төшеп, мин аларны сагынып куям. Актанышта бездән башка тагын Авзалов фамилиялеләр бар иде. Алар мине үз туганнары кебек күрәләр иде. Зәйтүнә, Нәсимә апа Авзаловалар фамилиядәш кенә булсалар да, туганнарым кебек исемдә калган. Нәсимә апа Авзалова мәктәптә безне укыта иде. Әтиләре колхозда бригадир иде. Мин аларга көн саен диярлек керә идем. Аларның тор-

мышлары ярыйсы иде. Нәсимә апа минем күземә карап барысын да аңлый торган бик кешелекле апа иде. Күземә генә карый иде дә:

– Әлфия сеңелем, син бүген ашамагансыңдыр, – дия иде. Мине үзләренә алып кереп, тамагымны туйдыра иде. Сеңелесе Зәйтүнә белән бергә укыдык, бик дуслар идек. Бергәләп чишмәдән көянтә-чиләкләп су ташый идек. Чишмәгә үзем генә китсәм, Зәйтүнә, тәрәзәләреннән карап, мине күрә иде дә, йөгереп чыгып: «Нигә миннән башка гына төштең чишмәгә», – дип, чиләкләремә балчык тутырып шаяра иде. Мин, елый-елый, тагын чишмәгә китә идем. Зәйтүнә шулай шаян, шук кыз иде. Үзе бик мәрхәмәтле иде. Еш кына ул мине кулымнан җитәкләп, чоланнарына алып керә иде дә чоланнарында сакланган сохариларын ашата иде. Миңа кушылып, үзе дә тәмләп сохари кимерә иде. Капчыкны ертып, сохариларны ашап бетердек. Әле дә онытмыйм: Зәйтүнә миңа зур-зур телем сохарилар тоттыра иде. Бу сохарилар сугышта югалган абыйларына дип киптереп куеп сакланган икән. Икебез дә куркабыз, сохари өчен җәзасын бирерләр, дип шүрлибез. Кыйнамадылар анысы, бик нык ачуландылар. Абыйларының «исән» дигән хәбәре килде, шул шатлыктан безне гафу иттеләр. Шатлыкларыннан, мине әле киендерделәр дә. Сөенечләреннән миңа киез итек бирделәр. Олтан салынган булса да, бу итеккә бик куандым, ул итек бик җылы иде. Нәсимә апа Авзалова гомере буе укытучы булып эшләп, пенсиягә чыкты. Хәзер Кукмарада яши. Үзен саусәламәт сизә. Тормышы әйбәт. Бик еш күрешәбез, бертуганнар шикелле елашып аерылышабыз. Актанышта тагын Нәҗибә апа Гаязова мине үз сеңелесе кебек якын күрә иде. Казанга китәр алдыннан урамнан үтеп барам, Нәҗибә апаларның тәрәзәләре ачылды да, берәү миңа эндәшә. Карыйм, Нәҗибә апа. Кояштай балкып, миңа әйтә:

– Әлфия сеңелем, Казанга китәсең икән, дип ишеттем, җырчы булачаксың икән, кер әле безгә, сиңа истәлеккә бер әйбер бирәм, – ди.

Өйләренә кергәч, Нәҗибә апа сандыгын ачты да:

– Минем кулларым җиңел булсын, җырчы артистка булып кит! Менә сиңа бүләгем! – дип, бик матур, шикәр кебек ап-ак батист кофтасын миңа бирде. Бик матур итеп чигелгән бу ап-ак кофтаны киеп карадым. Эчендә җаны гына юк. Шундый матур, нәфис итеп чигелгән, көзге каршына килеп карадым: үз күземә үзем ышанмыйм, мин микән бу, дип торам. Шундый килешә!.. Агач – яфрак, кеше – чүпрәк белән, диләр шул. Мондый затлы кием кигәнмени әле мин, үз гомеремдә мондый кофта киярмен дип хыялланганым да юк иде. Нәҗибә апа чәйләр эчереп, сыйлап чыгарды үземне.

– Әлфия, матур җырлыйсың, тавышың Ходай биргән, җырла, артистка бул, әмма ләкин безне онытма! Борыныңны күтәрә күрмә, яме!.. – дип, тәрәзәдән карап, кул болгап калды. Һаман да күз алдымда тора: нинди ягымлы, нинди кешелекле, юмарт апа!.. «Менә нинди ул актанышлылар!» дип, яши-яши искә төшерәм...



Закирә Камашева (Жыракай). 1971 ел

Районның җитәкчеләреннән алып, укытучылары, гади кешеләре белән Актаныш минем күңелемдә – иң мәрхәмәтле, иң газиз туган җирем булып, җырларымның чыганагы, моңнарымның чишмәсе булып калды. Актанышны ташлап китү авыр иде. Хәтта китәсе дә килми иде. Ничектер, Казан үзенә тартып торса да, Актаныштан китү күңелне нечкәртә, елыйсыны китерә иде. Җыракайны калдырып китү дә авыр. Аны юатырга тырышып, болай дидем:

– Җыракай, Алла боерса, әйбәт кенә эшләп китсәм, үз тамагымны үзем туйдыра башласам, сиңа да ярдәм итәрмен. Әйбәтрәк фатир тапсам, кайтып, сине үз яныма алып китәрмен!

Җыракай, аркамнан сөеп:

– Бәбкәем, үз тамагыңны туйдыра алсаң дә риза мин. Илдә чыпчык үлми, мин монда ничек тә яшәрмен, эшләрмен. Дус-иш, күрше-күлән белән бергә-бергә гомер итәрбез. Гашияләр, Сәҗидәләр, Вагыйзләр исән булсын, – дип, озатып калды.

И Актаныш!.. Җырлы-моңлы Актаныш!.. Хуш! Сау бул!.. Хуш, минем нарасый, ятим балачагым!.. Хуш, ятим үткән яшүсмер елларым!.. Хуш, сау булыгыз, дус-ишләрем!.. Хуш, Агыйдел!.. Актанышны назлап тын гына ага бир, гүзәл Агыйдел!.. Шул елларда сәхнәләрдә җырлап йөргән иң яраткан җырым – «Хуш, авылым» минем күңелемнең юлдашы булды, мин шул җырны җырлап, Актаныш белән саубуллаштым:

Хуш, авылым, сау бул,
Сәламнәр көт таң җилләре искәндә.
Мин җырлармын, сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә...

Шәмдәлләрдә генә утлар яна...

(Зур сәхнәдә беренче адымнарым)

Шәмдәлләрдә генә утлар яна,
Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер җеп
эрлиләр...
(Татар халкының борынгы җырыннан)

Шәмдәлләрдә генә түгел, минем йөрәгемдә утлар яна... Мәңге сүнмәс утлар... Утлы йөрәгем белән Казанга килергә чыктым... Казан үзе дә мине утларын балкытып, кайнар кочагына алырмы?.. Казан бит бөтен татар дөньясының иләһи зур шәмдәле!..

1951 ел. Менә мин Казанда. Тукай, Сәйдәш җырлары, Тукай, Сәйдәш моңнары дөньяга килгән мәшһүр Казан!.. Мин-ятимне үз кочагыңа ал! Ниләр көтә мине Казанда?.. Җырлап китеп кеше була аламмы? Әллә бу зур калада югалып каламмы?.. Күңелдә билгесезлек.

Җыр һәм бию ансамбленә килдем. Ансамбльнең художество җитәкчесе Зөләйха апа Әхмәтова мине ягымлы каршылады. Ансамбль артистлары бары да тезелешеп утырган, репетиция башланачак. Чибәр-чибәр апалар, абыйлар... Бар да мине күзәтәләр... Актаныш кызы килгән, диләр. Мине җырлатып карарга булдылар.

– Нәрсә җырлыйсың, кызым? – ди Зөләйха апа. Мин, ничектер, кыю гына:

– «Кәккүк»не, яки «Гөлҗамал»ны, – дим.

– Oho! – диешә болар, бер-берсенә карашып. Композитор Александр Ключарев та ансамбльдә эшли икән, пианино янына утырды да миңа аккомпанировать итәргә җыенды. Мин, Аллага тапшырып, «Кәккүк» белән «Гөлҗамал» көйләрен җырладым. Барысы да кул чабып хупладылар. 1951 елның сентябрендә шулай итеп мине ансамбльгә кабул иттеләр. Александр Ключарев, башын кыңгыр салып:

– Бу көйләрне кем өйрәтте? – дип сорады. Мин аңар үзебезнең Актанышның атаклы баянчысы Мәрзия апа Юнысова өйрәткәнен әйттем.

– Сулышны күкрәк түреннән алып, авызны зур ачып җырларга да шул апаң өйрәттеме? – ди Зөләйха апа.

– Әйе, – дим мин, кыюсыз гына.

– Сине дөрес сулыш алып, авызны дөрес ачып җырларга өйрәткән ул баянчыга рәхмәт! – диде Ключарев. – Син, сеңелем, Казанга әзер җырчы булып килгәнсең!.. Молодец!.. – диде. Шулай татарча әйтте. Ключарев милләте буенча рус кешесе булса да, татарча яхшы сөйләшә иде. Мин аның шулай



1955 ел

татарча дөрес, матур сөйләшүенә гомерем буе сокландым. Җае чыккач, язып китим. А. Ключарев – татар халкына зур хезмәт күрсәткән рус композиторы. Татар халкының талантлы уллары – күренекле композиторлары С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин, хатын-кыз композиторларыбыздан беренчесе һәм халкыбызның сөекле композиторы С. Садыйкова белән бер заманда яшәп иҗат иткән, шул композиторлар традициясендә бик күп җырлар тудырган мәшһүр композитор. Татар һәм башкорт халык көйләрен җыеп эшкәртүче, йөзләгән халык көйләрен туплап зур-зур җыентыклар төзүче бик эшлекле кеше иде мәрхүм А.С. Ключарев. Халык арасында күп йөри, җыр һәм бию ансамбле өчен махсус халык көйләре алып кайтып эшкәртә иде. Ансамбль репертуарында бу көйләр озак еллар сакланды. Мин халыктан ул алып кайткан бик күп көйләрне, шулай ук ул язган күп кенә җырларны беренче булып башкардым. Соңрак инде А. Ключарев минем өчен махсус җырлар да язды. Шундый җырларның берсе – «Ватанымның гади бер кызы мин» дип атала. Бу җырның, үзенә күрә, бер тарихы бар. А. Ключарев, бер көнне мине туктатты да:

– Әлфиюшка, синең үзеңә генә, син башкарсын өчен генә специально бер җыр язасым килә. Сүзләр кирәк, – ди. Мин инде, дустым шагыйрә Гөлшат Зәйнашевага әйтик, дидем. Ключарев та Гөлшат белән бик дус иде, шул минутта ук, көлемсерәп:



1954 ел

– Киттек Гульшаткага!.. – диде.

Гөлшат Зәйнашевага бу фикеребезне әйттек. Минем тормыш юлыма багышлангандайрак сүзләр язарга вәгъдә итте һәм берничә көннән мондый шигырь язып бирде:

Ватанымның гади бер кызы мин,
Туып-үстем Идел буенда.
Чәчәк җыйдым хәтфә болыннарда,
Җыр өйрәндем Сабан туенда...

Бу шигырьне без бик яраттык. А. Ключарев бу сүзләргә бик матур көй язды. Татар халык көйләренә тартым, шул ук вакытта профессиональ яктан камил, бик үзенчәлекле музыка булды бу. Мин аны рәхәтләнеп, яратып җырладым һәм пластинкага яздырдым. Композитор Ключарев һәрвакыт миңа игътибарлы булды. Художество советы утырышларында җырлавымнан гаеп табып, мине хурлап сүз әйтүчеләргә ул һәрвакыт каршы чыга иде. Ә хурлау-

чылар була иде. Әле тегеләй, әле болай бәйләнеп, консерватория бетермәгән, профессиональ югары белеме юк дип, миңа аяк чалырга тырышучылар күп булды. (Бу турыда алдарак язармын әле.) Шундыйларга Ключарев: «Әлфия ул – Актаныш туфрагыннан табылган самородок!» – дия иде.

Зөләйха апа Әхмәтова да мине үз кызы кебек якын итте. Минем җырчы булып китүемдә аның роле әйтеп бетергесез зур булды. Ул мине, музыкаль башлангыч белеме дә булмаган авыл кызын, музыка белеме дөньясына алып кереп китүче беренче остазым булды. Мине бернинди сынау сроклары үткәреп тормыйча, ансамбльгә алып, зур сәхнәгә юл күрсәтүче бу апага гомерем буена рәхмәтлемен!

Казанда яшәп китү җиңел генә булмады. Ансамбльнең тулай торагы юк. Миңа бер квартира табып бирделәр. Бик әйбәт квартира булды бу. Хуҗа апа – Һаҗәр исемле бик яхшы күңелле хатын иде. 45 сумлык айлык хезмәт хакымның (80нче еллардагы акча бәясе) 15 сумын квартира өчен бирә идем. Калган 30 сумын өс-башымны кararга, ашарга тотам, шуны җиткерергә кирәк. Әлбәттә, ул акча җитми иде. Хуҗа апаның бөтен эшләрен эшлим, өен җыештырам, идәннәрен юам, суын ташыйм. Өйләрен бик чиста тотып, ярдәм итешеп торгач, Һаҗәр апа мине ярата иде, уенын-чынын бер итеп, киленебез булырсың, дия иде. Армиядә хезмәт итүче уллары бар иде, шул улыбызга алабыз сине дип, гел үз балаларына караган кебек итеп карыйлар иде. Уен-көлке белән күңелле итеп яши идек. Менә ансамбль Себергә китәргә җыена. Мине Себергә алып китмәделәр, чөнки әле аларның репертуарларын белмим. Танылган җырчы Сөләйман Йосыповның хатыны җырчы Рәйсә Йосыпова, бәби табарга декретка чыгып, гастрольгә китми калды. Мине шушы апага беркеттеләр, шул апа белән репертуардагы җырларны өйрәнә торырга куштылар. Минем тавышны 1нче альт дип таптылар. Ансамбль репертуарындагы бөтен җырларны өйрәнеп бетердем. Ансамбль Себердән гастролен тәмамлап кайтты. Зөләйха апа минем өйрәнгән җырларымны җырлатып, тикшереп чыкты. Яхшы өйрәнгәнсең дип, бөтен коллектив алдында кочаклап үпте. Җырчыларның күпчелеге минем өчен куанып елмаештылар, арада кайберләре минем җырларны шулай тиз өйрәнеп, дөрес җырлавыма ачулары килеп, ямьсез күзләре белән кырын-кырын да карап куйдылар. Мин бу карашларны күрмәмешкә, сизмәмешкә салыштым. Күпчелекнең миңа мәрхәмәтле булуына куандым.

Араларында мине чын күңеленнән яратучы, кешедән бер дә көнләшми торган күркәм холыклы Разия апа Тимерханова турында аерым язасым килә. Разия апа бик матур сопрано тавышлы, ягъни нечкә тавыш белән җырлаучы артистка, ул инде монда ансамбль оешкан көннән башлап эшли. Нечкә тавыш белән, әмма ләкин чәрелдәми торган, киң күкрәктән чыккан көчле, яңгыравыклы, шул ук вакытта куе каймак сыман матур тавыш белән җырлый, халыкчан бормаларны матур итеп ала, музыкаль хәтере яхшы, бер тыңлауда җырны отып ала, сүзләрне чын татарча итеп, дөрес дикция белән әйтә. Казанда туып-үскән,

музыкаль белеме бар, музыка училищесын тәмамлаган, пианино янына утыра да, шаулатып, рәхәтләнеп теләсә нинди көйне үзе уйнап та җибәрә. Разия апага мин тәмам гашыйк булдым. Үзе зәп-зәңгәр күзле, ап-ак түгәрәк йөзле, зифа буйлы, кигән киемнәре килешеп тора... Уен-көлке ярата, бөтен залны яңгыратып көлә. Аңа карап кына торасы килә. Мин бу апага бертуган апама сыенгандай сыендым. Яңа җырлар өйрәнгәндә ярдәм итеп кенә калмый, Разия апа миңа үзенең кайбер киемнәрен дә биреп тора. «Үземә кечерәеп киткән...», – дигән булып, миңа матур-матур күлмәкләрен бүләк итә. Разия апа Казан кызы булгач, күлмәкләре, киемнәре шәһәрчә модный тегелгән, мин аларны киеп, көзге каршына басам да, үз-үземә ышанмый шаккатып калам: матур кием кигәч, чын-чынлап артисткага охшап китәм!.. Разия апа миңа көрән төстәге модный итеп тегелгән язгы-көзге пальтосын да бирде. Мин рәхмәтләр әйтеп, яратып озак кидем бу пальтоны. Разия апаның бу яхшылыкларына мин дә яхшылык белән җавап кайтарырга булдым, аңа өй эшләрендә булышырга теләвемне әйттем. Разия апаның ике ир баласы бар, кыз баласы юк. Өй эшләрендә үзе генә бөтерелә. Туп кебек ике ир баланы кararга, шул ук вакытта яңа җырлар өйрәнеп, репертуар әзерләргә кирәк. Мин килеп өйләрен җыештырам, идәннәрен юам. Разия апаның тормыш иптәше Сабир абый да бик яхшы кеше, ул да миңа мәрхәмәтле булды. Бу гаиләгә килсәм, мин үземне үз туганнарымда кебек рәхәт хис итә идем. Разия апа миңа музыка белеме бирергә, нотага карап җырларга өйрәтергә дә вакыт таба иде. Пианиносы янына бастырып, гаммалар җырлата, мине тональностларны дөрес алырга өйрәтә иде. Ансамбльдә ул минем чын остазым, өлкән дустым булды. Безнең бу дуслык гомерлек дуслыкка әйләнде. Хәзер дә без Разия апа белән туганнар кебек.

Ансамбль артисткаларыннан тагын биюче Фәйтүнә Абдуллина белән дә шулай бик тиз якын дуслар булып киттек. Фәйтүнә миннән бераз олырак яшьтә булса да, мине гел үзенә тиң итте. Ул да – Казан кызы, шәһәрчә матур киенә. Үзе дә бик матур, сөйкемле. Күбәләк кебек очып бии. Аяклары җиргә тими шикелле. Гастрольгә чыксак, кунакханәләрдә мине гел үз янына ала, өеннән алып чыккан тәмле ризыклары белән уртаклаша. Фәйтүнә белән дә без гомерлек дуслар булып калдык. Соңгарак мин үземә аерым бригада төзегәч, Фәйтүнә минем коллективта берничә ел биюче булып эшләде. Тамашачылар аның биюләрен бик ярата иде.

Ансамблгә яшь җырчылар килде. Минем тавышта җырлаучы кызлар Рәмзия, Гөлҗиһаннар белән бергәләп дус-тату эшләп йөрибез. Күңел күтәрелеп китте. Ансамбльдә эшләп китүемә куанып бетә алмыйм. Ансамбль артистлары мине бик тиз үз иттеләр. Мин дә үземнең авылча гадәтләрем белән булса да, аларга тиз ияләштем. Шәһәр кызларының русча сөйләшеп йөрүләре генә бераз ачуны китерә иде. Мин бит русча бөтенләй белми идем. Русча сөйләшә башласалар, миннән яшерен сүзләре бардыр, миңа белдерәселәре килмидер, дип уйлый идем.

1953 ел



1952 елның ямьле җәендә безнең ансамбль (мин инде хәзер безнең ансамбль дип кенә җиббәрәм!..) Ленинградка гастрольгә барды. Халкыбызның «Сарман» көен мин башлап җырладым, ягъни «солировать» иттем. Бу минем ансамбльгә – шундый зур хорга кушылып беренче тапкыр җырлавым иде. Бу бик җаваплы эш иде. Мин каушармын, матур җырлый алырмын микән, дип бик дулкынландым. Тамашачылар яратып тыңлады. Зөләйха апа да канәгать иде. Ленинградта без озак яшәдек. Илебезнең шундый зур, мәшһүр каласында яшәү, ансамбль артисткасы булып сәхнәдә җырлау минем өчен зур вакыйга булды. Өстемдә Разия апа биргән киемнәр генә булса да, урамнардан узып барганда шундый горурлык хисе кичерәм, әйтерсең, чын-чынлап артистка булып киттем. Күзләр яңа, битләр кыза, миңа карыйлар микән дип, узган-барганнарга күз төшерәм. Күңелдә дәрт уянган чаклар, егетләр карый микән дип, йөрәк дөп-дөп тибә... Кибетләр яныннан узганда зур-зур тәрәзә-витриналарына көзгегә караган кебек карап үтәм, буем кыска булса да, хәйран гына җиткән кызларга охшыйм бит, бала-чага димәссең. Кронштадтка барып концерт куйдык. Концерт бетү белән безне моряклар урап алды. Күбесе – татар һәм башкорт егетләре... Ансамбльнең иң чибәр биюче кызлары Фәйтүнә белән Ләлә бу моряклар белән бик тиз танышып алдылар, көлешеп сөйләшәләр. Миңа да бер егетнең күзе төште бит әй!.. Башкортстаннан, үзе татар егете, Хәмит исемле,

бик сөйкемле, көлеп җибәрсә, ике бите чокыраеп китә. Сөйләшүеннән күренеп тора, акыллы егет... Икенче ранг капитаны дәрәҗәсендә... Егет ошый, ләкин мин оялам, сөйләшергә дә базмыйм. Ул мине кунакханәгә кадәр озата килде. Үзе дә оялчан, ипле егет, кулымнан тотарга да кыймый. Шулай берничә көн очрашып, сөйләшеп йөрдек. Хәрби егетләр миңа бик ошый иде. Гомумән, без, кызлар, яшь чакта хәрби кешеләргә, бигрәк тә моряклларга гашыйк була идек. Мин бу Хәмиткә гашыйк булдыммы, юкмы, әйтә алмыйм, шунысын әйтәм, ул миңа ошый иде. Ә гашыйк булуның, мәхәббәтнең нәрсә икәнен мин әле чын мәгънәсендә аңлап җитмәгәнмендер. Шулай да мин аңар Казандагы адресымны язып бирдем. Отпускыга кайтып барышлый ул Казанга кереп мине эзләп тапты. Фатир хуҗаларымнан рөхсәт сорап, мине урамда йөреп керергә чакырды. Без аның белән бик озак урамда сөйләшеп йөрдек, шәһәр бакчасына кереп мороженое ашадык. Әллә ни җитди сөйләшүләр, вәгъдәләшүләр булмады. Икебез дә бик яшь идек шул әле.

Еш кына тавышың матур, матур җырлыйсың, шулай да музыкаль белемең юк, ә музыкаль белеме булмаган җырчының киләчәге юк дип, минем күңелемне төшерүчеләр очрый иде. Бигрәк тә филармониянең художество җитәкчеләре: музыкаль белемең юк, сине эштән чыгарабыз дип, гел йөрәккә курку салып торалар иде. Ансамбль җитәкчесе, үзем нең турыдантуры җитәкчем Зөләйха апа мине яратса да, җырлавымнан канәгать булса да, филармониянең аңардан югарырак җитәкчеләре миңа да, минем өчен аңар да гел бәйләнеп тора иде. Музыкаль белемем булмаганга, мин үзем дә бик борчыла идем. Барлык кешегә дә: мин ятим үстем, мин – авыл кызы, авыл кызына кая инде ул музыка мәктәпләрендә укып белем алу, дип акланып йөреп булмый бит. Тәвәккәлләп музыка училищесына укырга керергә булдым. 1953 елда Казан музыка училищесына укырга кердем, 2 елга якын укып йөрдем. Вокал буенча төрле укытучы укытты, төрлесе төрлечә укыталар. Берсе миннән халыкчан җырлавымны таләп итә, икенчесе опера җырчысы итеп укытмакчы. Тавышым, табигый тавышым югала башлады. Мин куркуга төштем. Бу турыда училище директоры, танылган дирижер Ильяс абый Әүхәдиев тә уйлана икән, мине чакырып, үзе шул турыда сүз башлады:

– Әлфия сеңелем, бәлки, син үзеңнең табигый тавышың белән җырлавыңны дәвам итәрсең?.. Уку – яхшы гамәл, әмма синең табигый тавышың матур, шул тавышың белән җырлавың хәерлерәктер... Музыкаль белемеңне үзлегеңнән күтәрерсең, үз өстеңдә үзең эшләрсең, тавышың табигать тарафыннан куелган, вокал укытучылары аны үзгәртмәсен инде, – диде. Мин кире филармониягә киттем. Мине инде ансамбльгә түгел, эстрада бүлегенә алдылар һәм Гани Вәлиев җитәкләгән бригадага беркеттеләр. Гани абый Вәлиев – танылган баянчы, бик оста оештыручы-администратор да иде. Берничә ел мин шушы бригада белән гастрольләрдә йөрдем. Концертларыбызны яратып карыйлар иде. Гани абый, музыкант буларак, мине күп нәрсәгә өйрәтте. Ул

бик яхшы аккомпаниатор иде. Аның баянына кушылып җырлау минем өчен үзенә бер мәктәп булды. Гастрольләрдә бик тату һәм күңелле йөрдек. Юлларда машиналар ул елларда сирәк, җәйләрен генә эләгә иде. Кыш көннәрендә ат җигеп, чаналарга толыплар киеп утыра идек. Толыпларны авыл кешеләре биреп тора иде. Мин толып кисәм, бөтенләй чумам, аякларымны атлый алмыйм, Гани абый көлә. Кайчакта без биюче кыз белән икебез бер толыпка сыя торган идек.

Бу елларда безнең филармония директоры булып рус кешесе, ләкин һәр милләтне тигез күрә белүче, олы җанлы Михаил Федорович Боголюбов эшләде. Ул Казанда булган безнең концертларны берсен дә калдырмыйча карап бара иде, талантлы кешене талантсыздан аера белә, эшләгән кешенең кадерен белә иде. Художество җитәкчеләре миңа еш кына бәйләнсәләр дә, мин Боголюбовка кереп зарланмый, түзә идем. Г. Вәлиев бригадасыннан соң мин күренекле җырчыбыз, ул елларда бик популяр җырчыбыз Усман абый Әлмиев җитәкләгән эстрада бригадасында эшләп алдым. Усман абый сәхнәдәге беренче адымнарымнан ук мине күзәтеп килгән һәм минем сәләтемә ышанган. Үзенең бригадасына бик теләп чакырды. Без аның белән яңа программа төзеп, Урта Азия якларына озак гастрольгә киттек. Мин Усман абыйга бик рәхмәтлемен, ышанып мине үзе белән зур гастрольгә алды, сәхнәдә үзеңне ничек тотарга, ничек репертуар сайларга өйрәтте. Мин ул гастрольләрдә «Кара урман», «Актаныш басмалары», «Шомыртым», «Кәккүк» кебек җырларны башкардым. Тамашачылар мине җылы каршы алдылар. Шул гастроль вакытында минем «Гөлҗамал»ны бик җырлыйсым килә иде. Ул елларда «Гөлҗамал»ны халык бик яратып тыңлый иде. Бу җырны Усман абый үзе җырлый иде. Аның башка җырларына гөрләтеп кул чапкан тамашачы бу җырына, ничектер, теләр-теләмәс кенә кул чаба кебек тоела иде миңа. «Гөлҗамал» кызлар җыры бит. Бу җыр аңа бик килешеп бетмәгәндер, бәлки. Хәзер шаккатам, япь-яшь башым белән ничек җөрьәт иткәнмендер, ничек шулай кыюланганмындыр, бер концерттан соң Усман абыйга болай дидем:

– Усман абый, «Гөлҗамал»ны бик җырлыйсым килә, үзем генә җырлыймсана шул җырны!..

Усман абый бик гажәпләнсә дә, риза булды. Я, Ходаем, кыюлыгым булгандырмы бу, итагатьсезлегем булгандырмы: Усман абый алдында һаман да әле үземне оятлы хис итәм. Шулай итеп «Гөлҗамал»ны җырлый башладым. Тамашачылар да бик яратып кабул итте бу җырымны. Усман абыйлар белән бергә йөргән чакларны сагынып искә төшерәм. Күңелле йөрдек. Уен-көлке белән гомернең үткәнен дә сизми идек. Бервакыт нәрсәдер ярамаган ризык ашап, мин бик каты авырып киттем. Эчем бик нык авырта. Температурам күтәрелде. Хәлем юк. Ниндидер кышлакларда йөрибез. Врач юк. Усман абый: «Врач булса да күренмисең, ун-унбиш көнгә больницага салырлар, концертларыбызның рәте китәр», – дип, миңа төрле дарулар эчертеп, үзе генә

дәваларга булды. Кемдер, агулангандыр бу, эчен юдыртып, клизма ясарга кирәк, диде. Безнең коллективта хатын-кызлардан мин берүзем генә. Кем куйсын инде ул клизманы? Хәзер искә төшерәм дә, көлсәң-көл, еласаң-ела дигәндәй, шаклар катам, Усман абый куйды бит миңа клизманы!.. Оялам дип, якын да китермәскә тырышам, Усман абый ачулана:

– Син минем янымда бала гына әле, оялма! – ди. Мин карышам. – Шушы кышлакта үләсең киләмени?.. Концертлар өзелсенмени?.. – дия-дия, тәки куйды бу клизманы. Бер-ике көннән аякка бастым, тазардым, концертларыбызга зыян килмәде. Менә шулай инде ул артист тормышы. Ә Усман абый ул бик ярдәмчел, кеше хәленә керә белә.

Аннары танылган баянчы Гали Җәмлиханов җитәкләгән бригадада эшләп шактый тәжрибә тупладым. Сәхнәдә үземне иркен хис итә башладым, кыюрак җырлыйм, эстрадада үз йөземне табарга, үз юлымны билгеләргә омтылам. Тамашачылар мине таный башладылар. Җырлаган җырларым да халык арасында популярлаша бара: «Яшь наратлар» (Ж. Фәйзи музыкасы, И. Юзеев сүзләре), «Кайтам инде» (С. Садыйкова музыкасы, И. Юзеев сүзләре), «Яшьлегемнең кайнар хисләре» (Ш.Мәҗитов музыкасы, Г.Сәгыйдуллин сүзләре), «Почтальон» (Т.Кәримов музыкасы, Ш.Насыйров сүзләре), «Сине сөйдем, гүзәлем» (Т.Вәлиев музыкасы, Ф.Әхмәдиев сүзләре) кебек җырларны тамашачылар яратты, кая барсам да, бу җырларның популярлашканын күреп йөрү бик күңелле иде. Башкорт халкының күңелле көйләреннән «Элмәлүк», «Шәл бәйләдем», татар халкының күңелле көйләреннән «Гармунчы булсын ярың», «Төймә-төймә», «Бәгърем» һ. б. шундый көйләр миңа сәхнәдә үз юлымны табарга ярдәм итте. Бу елларда мин әкрен генә, тормыштагы һәм сәхнәдәге кыенлыкларны җиңә-җиңә, үземнең иҗат юлыма чыкканмындыр. Хәзер уйлыйм да шундый бер фикергә киләм: Казан!.. Бөтен татар халкының илаһи зур шәмдәле булган Казан мине үз кочагына алды, якты нурлары белән минем тормыш юлымны балкытты, сәхнәгә күтәрде. Югалып калырмын кебек тоелган балалык куркуларым юкка булган, мин югалып калмадым, дөресрәге, мине дусларым, остазларым, яхшы күңелле өлкән артистлар югалтмады, шулай итеп җыр мәйданына кереп киттем һәм зур, киң юлга чыктым, беренче нык адымнарымны атладым. Бу зур, киң юлга алып чыккан мәрхәмәтле кешеләр, рәхмәт сезгә – сез кабызган шәмнәр яктысында нык атлап барам! Мин бәхетле!.. Шул елларда яратып җырлаган бер җырымның сүзләре белән әйтсәм:

Сахраларда ялгыз йөргән чакта,
Җилләр исеп чәчне тарата.
Бәхет бит ул, дуслар,
Шуны онытмагыз –
Ул саф йөрәкләрне ярата!..



1970 нче еллар

Яшьлегем чәчәк атканда

(Җырдан-җырга беренче уңышларым)

Яшьлегем чәчәк атканда,
Сине сөйдем, гүзәлем!
Тик берүзем генә белдем,
Үзәгем өзелгәнен...

Тормышым, иҗат юлым турында, сәхнә язмышым хакында язганда, менә шушы урынга җиткәч, мәхәббәт, сөю, үземнең кемне яратуым, кемгә тормышка чыгуым турында бер сүз дә язмый калдырсам, бик бер яклы гына язылган булып килеп чыгар иде. Кеше тормышы мәхәббәт, сөюләрсез генә булмый. Ә артистлар инде, үзегез беләсез, бигрәк тә нечкә күңелле, кайнар хисле халык, алар инде мәхәббәтнең утында дөрләп янган, мәхәббәт диңгезенә төшеп айкалган, аның дулкыннарында бәргәләнеп чайкалган, кыскасы, мәхәббәтнең газап-михнәтләрен, бәхет-шатлыкларын күп татыган, мәхәббәт дөньясында күпне күргән халык. Минем репертуарымдагы дистәләгән җырлар меңләгән җыр сөючеләрнең күңелләрендәге мәхәббәт хисләрен чагылдырганын мин белә, сизә идем. Үз күңелем дә мәхәббәт белән тулган яшь, дәртле чак, мәхәббәт серләрен җырга салып, хыял канатларында очкан елларым!.. (Бәлки, әле бу мәхәббәтнең үзе булмагандыр, яратырга, яратылырга теләп, хыялга бирелү генә булгандыр, шулай да яшь йөрәк бит хыялны да мәхәббәт дип, ярсып тибә!)

Аяз күктә ай елмая,
Күңелләргә дәрт биреп.
Син дә ялгыз, мин дә ялгыз,
Ай йөзә безне күреп.

Шушы сүзләргә җырланган бик матур көй бар иде. (Ф. Әхмәдиев музыкасы, М. Латыйфуллин сүзләре.) Мәхәббәт турында үзәкләрне өзәрлек җыр иде ул. Менә шушы матур җыр кебек күпме мәхәббәт җырлары җырладым мин үз гомеремдә! Мәхәббәт дигән изге хисне үз йөрәгемдә тоймасам, мәхәббәтнең учагында үзем дөрләп янмасам, утлы мәхәббәт җырлары җырлый алыр идем микән? Күңелем тулы мәхәббәт тойгылары минем җырларыма гомерем буе юлдаш булды. Әйе, яшерен-батырын түгел, мин мәхәббәт дөньясында күпне күрдем.

Әлбәттә, мин ишеткәлим, минем мәхәббәт дөньям турында халык арасында арттырып сөйләүләр дә бар. Ни хикмәттер, безнең кайбер тамашачыларыбыз артистлар турында, бигрәк тә аларның шәхси тормышлары ту-

рында, сөю, мәхәббәт эшләре хакында берсеннән-берсе арттырып сөйләргә яраталар, артистлар турында төрле имеш-мимешләр, мажаралар уйлап чыгаралар. Мажараларга, имеш-мимешләргә ышанмагыз, мин үземнең тормыш һәм иҗат юлыма бәйләп, мәхәббәт эшләрем турында да үзем язарга булдым һәм чын күңелемнән, чын дөресен язам. Хәер, хәзер инде минем яшь вакытларым түгел, дөресен язмыйча нишлим, яшьлек үткән-киткән, яшьлек белән бергә мәхәббәт тә үткән-беткән, дигәндәй... Мәхәббәт бит ул – яшьлек юлдашы. Яшьлек уза, мәхәббәт туза, диләр бит. Мин хәзер инде үткәннәрне искә төшереп кенә язам. Үткәннәрне искә төшереп хәзер язарга була... Ә яшь чакта... ул мәхәббәт дигәненең утында дөрләп янган чакларда, кешегә үз мәхәббәтләрең турында сөйләп, «мин яратам», «мин сөям» дип, һич тә язып булмас иде, мәхәббәт бит ул йөрәк түрендәге иң газиз, иң яшерен хис... Үзең генә белә торган, үзең генә яна торган ут... Инде үткән эшкә салават дигәндәй, хәзер ул хисләр үтеп киткәч, сүрелгәч, уенын-чынын бер итеп кешегә сөйләргә дә, кәгазьгә язарга да буладыр... Мәхәббәт бер генә була, диләр. Белмим, кайбер кешенең мәхәббәте бер генә буладыр, бәлки. Бер генә кешене яратып, гомере буена шул кешегә генә табынып, шул кешегә генә тугры булып яшәүчеләр дә бардыр. Алар, әлбәттә, бәхетле кешеләрдер. Мин бер генә кешене яраттым, гомерем буена шул кешегә генә тугры булдым, дисәм, ышанмаслар иде. Алай дип язарга җыенмыйм да. Алай язу кылану булыр иде. Мин бер генә кешене яратмадым, яраткан кешеләрем берничә булды. Әмма ләкин чын йөрәгем белән озак еллар, егерме елдан артык, аңа гына туг-



Беренче ирем – Зиннур Биккин, кызым Гүзәл, сеңелем Флүрәнең улы Зөлфәт. 1966 ел

ры булып яраткан кешем бер генә булды. Менә ул, мөгаен, чын мәхәббәтем булгандыр. Аның кем булуын алдарак язармын әле. Хәзер мин ничек итеп кияүгә чыкканымны, ничек итеп гаилә корып җибәргәнемне язам. Кияүгә чыкканымны сизми дә калдым дигәндәй, берничә көн эчендә хәл иттем дә, чыктым да куйдым. Әллә яраттым, әллә юк, аңламадым да. Шунысын әйтим, яратасы бик килә иде. Шул яратасы килү теләге ярату булып тоелгандыр инде. Шулай тиз хәл итүем, бәлки, яшьлегем белән җиңел акыллылык күрсәтүем булгандыр. Әлеге Кронштадт морягы Казанга кайтып мине эзләп тапса да, өйләнәм, дип әйтмәде бит, кыюлыгы җитмәде булса кирәк. Бик ошатсам да, мин дә аны яратып ук китмәдем, ахрысы, ничек килеп чыккандыр, ул егет томан эчендә эреп юкка чыккандай югалды. Минем каршымда З. пәйда булды. Сугышларда йөреп, утны-суны кичеп кайткан, миннән, әлбәттә, ун яшьләр чамасы өлкән Биләр егете З. кыю булып чыкты. Менә бер көнне мин торган фатирга килде. Хәрби киемнән. Офицердыр инде бу, дип уйлыйм. Офицерларны яратабыз бит инде без. Фатир хуҗалары никадәр кыстаса да, нигәдер плащын салмый бу. Плащының сәдәфләрен ычкындырып җибәргәндә, иңбашындагы гап-гади погон тасмалары күренеп китте-китүен. Мин ишек төбенә озата чыктым. Вәгъдәләштек. Мин аңар кияүгә чыгарга ризалык бирдем. Эчми-тартмый икән, күрергә ипле егет. Өйгә кергәч, фатир хуҗалары әйтте, ул офицер түгел икән, гадәти хәрби хезмәткәр, гади солдат икән. Минем бераз кәеф китте-китүен, әлбәттә. Хуҗа апам көлә, офицер-офицер дип уйлаган идең, гади солдат кына инде, ди. Солдат булса-булыр, бер вәгъдә биргәч, оялмыйча ничек вәгъдә бозып, сүземне кире алыйм. Икеләнеп калсам да, вәгъдәмне бозмаска булдым. Яратам да, яратмыйм да кебек, ә кияүгә чыгасы килә. Кемгәдер сыенасы, кем беләндер серләшеп гомер итәсе килә, ялгызлык куркыта. Кеше өстендә тору да кыен. Без яшь чакта вакытында кияүгә чыгу әдәплелек санала иде. Бозык юлга киткәнче, кияүгә чыгуны хуплыйлар иде. Мин дә шулай вакытында чыгарга булдым. Әмма ләкин кияүнең дә торыр җире юк икән. Берәүләрдә фатирда тора, ишек төбендәге бер караватта гына йоклый икән. Бу турыда белгәч, бөтенләй кәеф китте. Вәгъдәмне әллә кире алыйм микән, дип уйланып йөри башладым. Квартира яклары да рәтләнер, тора-бара яратырмын дип, киләчәккә өмет белән тәвәккәлләдем. Менә бер көнне З. мине алырга килде. Фатир хуҗаларым берсе дә өйдә юк иде. З. киләсен алдан белеп, өйдән чыгып киткәннәр иде бугай. Мине беркем дә хәерле юл, хәерле тормыш теләп озатып калмады. З. белән икәү генә китеп бардык. З. заводта эшли, инженер, эшендә үзен яраталар. Төскә-биткә ярыйсы, җыйнак гәүдәле, тыныч холыклы, миңа тагын кем кирәк инде?.. Язмышым шулдыр, дип уйлыйм. Гашыйк булып, өзелеп сөеп йөрмәдем. Ул елларда гашыйк булып, өзелеп сөеп йөрер кешем әле очрамаган булган икән шул. Өзелеп сөеп йөрер кешем – чын мәхәббәтем тормышым юлында соңрак очрады... Я, ярый, бу турыда соңрак язарга булдым бит.

З. белән аның фатирында торабыз. Кеше почмагында тору бик авыр. 1956 елда кызым Гүзәл туды. Үзем гастрольләргә чыгып киткәндә, аны кararга Актаныштан Җыракайны алып килдем. Сеңелем Флүрә бер кызын – Светланасын миңа ташлап, кияүгә чыгып, Свердловск (хәзерге Екатеринбург) ягына китеп барды. Ул кызны да сыендырдык. Шулай зур гаилә булып, кешедә яшәү бик авырлашты. Мин квартираны үзем эзли башладым. Аерым квартира, кечерәк кенә аерым йортка кертүче хуҗа табылмасмы дип, сорашып йөрим. Адреслар табып, тегендә барам, монда чабам. Ялгыз кешене, яки ирле-хатынлы гаиләне генә кертәләр. Ничек яшәргә?.. Филармониядән квартира сорау – кая инде, башыма да килми. Миңа түгел, миннән алда килгән артистларга да, миннән шәп җырчыларга да юк. Филармония квартира бирә алмый. Ирем эшләгән заводта да меңләгән кешеләр квартира чиратында егермешәр, утызар ел торып тилмерә. Ятимлек белән үсеп, инде кияүгә чыккач та адәм рәтле тормышка ирешеп булмый. Күңел үсми, бер эшкә кул бармый... Яңа җырлар өйрәнергә кирәк. Искеләре дә баштан чыгып бара, тормыш баса, тегесе җитми, бусы юк. Хәерче тормышында яшибез. Бер көнне көянтә-чиләгемне асып, урамдагы колонкага суга чыктым. Җиңел генә гәүдәле бер апа су агызып алды да, миңа карап елмаеп, болай диде:

– Сеңелем, син теге җырчы Әлфия түгелме соң? Бер концертта күргән ием... Нигә шулкадәр боектың? Берәр кайгы-хәсрәтең бармы әллә?

Мин бу апага үземнең квартира эзләп йөрүемне, таба алмый интегеп бетүемне сөйләп бирдем. Берәр квартирага – аерым йортка – сыпушкага кертүчене белмисеңме, дидем. (Сыпушка дигәннәре – такта арасына пычкы чүбе тутырып салынган кечерәк кенә, мунча хәтле генә өй инде.) Шуңа бик риза булыр идек, дидем. Рәхмәт төшкере, шушы апа табышты, без Киров районының Гончаров урамында бер ишегалды түренә салынган сыпушкага күчтек. Хуҗаларыбыз бик әйбәт кешеләр булып чыкты. Үзләре шушында яшәгән. Хәзер үзләренә йорт салып куйганнар. Алар шул яңа зур йортка күчте, ә без – сыпушкага. Безгә җитәрлек мебельләре дә бар: өч карават, шкаф, өстәл, урындыклар... Бу сыпушка мебельләрен хуҗаларыбыз яңа йортларына күчереп тормадылар, ә безгә шул да зур шатлык булды. Шулай итеп сыпушка гына булса да, бер мунча хәтле генә булса да, үзебезгә аерым, хуҗалар күзенә карап торасы түгел.

Кызым Гүзәл үсә, Җыракаем да канәгать... Минем йөрәгем түрендә генә ниндидер бушлык... З. үзе сизәме, юкмы, белмим, минем яратырмын әле дип уйлаган уйларым, өметләрем акланмады. Күңелдә бушлык, мәхәббәт тә, нәфрәт тә юк, бер хис тә юк. Өйдә тынычлык, иминлек, үпкәләшү дә, ачуланышу да, кычкырышу да юк һәм... мәхәббәт тә юк. Бик күңелсез, бик ямансу тормыш... Бу турыда кешегә әйтү түгел, ул чакта үзем уйларга да куркам. Бу минем ялгышыммы, язмышыммы – белмим...

1957 елда татар сәнгате дөньясында зур вакыйга булды, шаулап-гөрләп,

зур уңышлар белән Мәскәүдә татар сәнгате декадасы үткәрелде. Мине яңадан ансамбль составына куштылар. «Кәккүк»не башлап җырлауны миңа тапшырдылар. Шундый җаваплы эшне миңа тапшырулары өчен шатландым да. Ничек кенә җырлармын икән дип, куркуга төштем. Ходайның рәхмәте, яхшы җырлаганмындыр инде, Мәскәү тамашачылары бик озак итеп, гөрләтеп кул чапты.

Кәккүк тавышы бигрәк матур тыңларга,
Кәккүк, күк-күү, күк-күү!..
Кәккүкләрне сайратырлык мәхәббәтем бар сиңа.
Тыңла, иркәм, гөл генәм,
Кәккүк тавышын бер генә,
Кәккүк, күк-күү, күк-күү!..

Шулай кәккүк булып сайрап, Мәскәү сәхнәләрендә җырлау минем өчен искиткеч зур бәхет иде!.. Филармония җитәкчеләре, хөкүмәтебез җитәкчеләре – барысы да мине котлап, «Кәккүк»не башлап җырлаучы буларак мактап, минем җырлавыма югары бәя биреп сөйлиләр. Миңа бик күңелле. Мәскәүдән Казанга дәртләнеп кайттым. Иңемә канатлар үскән кебек, очып кына йөрим. Тик менә әлеге тәбәнәк, иңе-буе өч метрлы сыпушкага кайтып кергәч, аның тынчу һавасын иснәгәч, юеш идәнендә уйнап утырган кызымны күргәч, кинәт күңел төште, адәм рәтле квартирада яшәр көннәрем булырмы инде дип, Җыракай белән зарланышып елап та алдык. Бу декададан кайткач, «Совет Татарстаны» газетасында минем турында зур мәкалә басылып чыкты. Аны язучы Гариф Ахунов белән яшь тәнкыйтьче Илдус Ахунҗановлар язган иде. Алар минем тавышымны мактаганнар, миңа зур өметләр баглаганнар иде. Сүз уңаеннан язып китим, сәхнәдәге беренче адымнарымнан ук минем иҗатыма игътибарлы булган язучы Гариф Ахунов миңа гомере буе хәерхаһлы булды, берничә ел үткәч, Әлмәт язучылары оешмасы җитәкчесе булып эшләгәндә, минем концертым турында тагын язып чыкты, минем сәхнә эшчәнлегемне уңай бәяләде. Гомумән, һәрвакыт миңа карата дустанә мөнәсәбәттә булды, миңа ярдәм итте. Мин үзем дә аның иҗатына ихтирамлы булдым, аның сүзләренә язылган җырларны яратып башкардым.

Яратырмын әле, күнегермен, дип тормышка чыгуымның ялгыш булганлыгын да декададан кайткан елларда мин бик нык аңладым. Яшьләргә гыйбрәт булсын өчен, дөп-дөресен язам, яратып китеп тә, күнегеп тә булмый икән. Мин З.ны яратып китә алмадым. Без, әлбәттә, начар тормадык. Әрләшмәдек тә, кычкырышмадык та, тату гына аерылыштык. Хәтта, әйтергә кирәк, дуслар булып аерылыштык һәм дуслар булып калдык та. Кайвакыт мин аңар бертуган абыема караган кебек карыйм. Ул кызым Гүзәлгә яхшы әти булды. Кызыма һәрвакыт ярдәм итте. Әти буларак, һәр айны тиешле ак-

часын кызымның саклык кенәгәсенә күчереп барды. Хәзер дә ул аңар әйбәт әти. Әлбәттә, З. башкага өйләнде. Хатыны Тәнзилә белән бик яхшы торалар. Тәнзилә белән без дуслар. Ул миңа бертуган сеңелем кебек. Без туганнар кебек йөрешеп, бер-беребезгә ярдәм итешеп яшибез. Тәнзилә – уңган хатын, бик ярдәмчел, миңа күп кенә эшләремдә ярдәм итә. Кызганыч, ул, көтмәгәндә 1993 елда фаҗигале үлем белән вафат булды. Ике җиткән малае белән З. ялгыз калды. 1960 еллар иде. Филармония җитәкчеләре Илһам Шакиров белән минем өчен «Сәхнәдә – яшьләр» дип аталган яңа бер бригада – яшьләр бригадасы оештырдылар. Матур итеп «Сәхнәдә – яшьләр» дигән яңа афиша ясаттылар. Бу бригада составында Илһам белән миннән башка тагын талантлы яшь скрипкачы Марат Әхмәтов, яшь нәфис сүз остасы Рафаэль Галиев, яшь баянчы Рифкать Гомәров бар иде. Бик күп афишалар эленеп, Казанда безнең беренче концертларыбыз башланды. Яшь артистлар концерты дип, халык дәррәү кубып йөрде. Күңелебез бик күтәрелде. Тамашачылар телендә – Илһам белән мин. 1961 елда шушы состав белән Уфага гастрольгә киттек. Уфа халкы әле безне белеп җиткермәгән, концертларыбызда башта халык ярты зал гына булды. Аннары көннән-көн тамашачылар арта, күбәя барып, соңгы концертларыбыз инде аншлаглар белән үтте. Культура сарайлары ишеге төбендә безнең концертларга билет сорап торучылар бар иде. Уфага тагын ике елдан соң бардык. Тагын шундый зур уңышлар белән кайттык. Ташкент-



Алдагы рәттә (сулдан уңга): Х. Сәлимҗанов, мин үзем, Ф. Кудашева, Б. Гайсин, (?); икенче рәттә (сулдан уңга): И. Шакиров, Җ. Сәйфиева, Р. Галисв, (?). 1957 ел

ка гастрольгә киттек. Ташкент халкы инде безне белә икән, поездга төшеп үк каршы алдылар. Меңәр кеше сыя торган зур залларда тамашачылар шыгрым тулы булды. Шулай итеп, Илһам белән минем бригада зур уңышлар белән эшләп, филармониягә зур керемнәр алып кайта идек. Өлкәнрәк артистларның кәефе китте, яшь кенә артистлар шулай зур уңышлар белән концертлар бирәләр дип, көнләшүчеләр дә бар иде. Без бу көнләшүләрне сизмәмешкә салышып, тын гына йөрибез. Әмма арада безнең уңышларга шатланучы артистлар да бар иде. Шундыйлардан Зифа Басыйрова, Разыя Тимерхановалар безнең уңышларыбыз өчен шатлана иде. «Менә безне алыштырырга яшь талантлар килде, аларның уңышларына куаныйк», – дип, җыелышларда сөйлиләр иде. Бу бригаданы икегә бүләргә кирәк, Әлфияне аерым бригада, Илһамны аерым бригада итеп чыгарырга кирәк, дигән фикерне иң беренче булып җыелышта Зифа апа әйтте. Һәм безне ике бригадага бүлеп чыгарырга, дигән карарга килделәр. Минем өчен бу зур шатлык иде, әлбәттә. Үземә генә аерым бригада белән концертлар бирү минем зур сәхнәгә юлым ачылу, дигән сүз иде. Шулай да бик куркыта иде. Үзем генә гастрольләргә чыгып, адәм көлкесенә калмаммы, дип куркам. Җитәкчеләремнең өметен аклый алырмынмы, халык минем концертларыма йөрерме, дип борчылам. Илһам Шакиров белән бер бригада булып йөргәндә, җан тыныч иде. Илһам консерватория тәмамлаган, тавышы яхшы, көчле, матур җырлый, тамашачылар аны бик тиз яраттылар, үз иттеләр. Ул бик тиз популярлашты. Концертларда аңар аркаланырга, ышанырга була иде. Халкыбызның иң матур көйләрен, борынгыларын да, хәзерге заман көйләрен дә, композиторларыбызның яңа матур җырларын да бердәй зур осталык белән башкара. «Иске карурман»ны, «Менәргә иде Урал тауларына», «Ык буйлары»н җырлап җибәрсә, тамашачылар тын да алмый. Әлбәттә, аның белән бер бригадада концертлар куеп йөрүем белән мин бәхетле идем!

Илһам миңа бик уңай тәэсир ясады. Мин аңардан күп нәрсәгә өйрәндем. Ул үзенең зур музыкаль белеме белән мин аңлап җитмәгән күп нәрсәләрне аңларга ярдәм итте. Җырларның тирәндә яткан моңын ачарга, музыканың иң нечкә хасиятләрен табарга өйрәтте. Мин аны үземнең остазым, өйрәтүчем дип саныйм. Илһам белән без бригадабызда бик дус, тату эшләдек, һәр нәрсәне киңәшләшеп, һәр нәрсәне уртаклашып, гастрольләрдә туганнарча йөрдек. Ике бертуган кебек йөреп, күңелләребез шулкадәр якынайды, хәтта мин аңар гашыйк булдым. Гел аны гына уйлыйм. Сәхнәдә бергә, юлларда бергә, азга гына күрешми торсак та, миңа ямансу була башлый. Гел аңа гына карап торасым, гел аның җырлавын гына тыңлап торасым килә. Әллә үзенә, әллә сихерле тавышына гашыйк булдым. Ул елларда Илһамга гашыйк булмаган хатын-кыз калдымы икән безнең татар дөньясында?.. Яшь кызлардан алып, олы яшьтәге түтәйләр – барысы да Илһамга гашыйк булгандыр. Шундый сүзләр дә сөйлиләр иде: Илһам бер түтәйдә фатирда тора иде, түтәйнең



Илһам Шакиров белән.
1957 ел

Илһам яшендә улы бар икән, консерваториядә Илһам белән бергә укып йөри икән, шул түтәй дә үлеп Илһамга гашыйк икән, улыннан ныграк тәрбияли, сыйлый, ризыкларының иң тәмлесен Илһамга ашата икән, дип сөйлиләр иде. Мин генә ничек Илһамга гашыйк булмыйча калыйм ди?.. Илһам үзе дә миңа гашыйк шикелле тоела иде, әллә миңа гына шулай тоелган. Әллә минем үлеп гашыйк булуымны сизеп, җавап рәвешендә генә үзен миңа гашыйк кебек тоткан. Кыскасы, арабыз бик серле иде. Гел сөйләшеп, серләшеп йөрибез, серләшеп сүзебез бетми. Халык арасында Илһам белән Әлфия бер-берсен яраталар икән, өйләнешәчәкләр икән, дигән сүзләр дә йөри башлады. Чынлап та, Илһам: «Әлфия, әйдә өйләнешәбез!» – дип тә әйтеп куйды. Әллә тирәнтен уйлап әйтте, әллә уйлап-нитеп тормады. Мин ул сүзне уенга борган булдым. Ни дисәң дә, ул миннән яшьрәк, мин инде ирдән аерылган балалы хатын. Авызым пешкән. Ярый әле, өйләнешмәгәнбез, барыбер аерылган бу-

лыр идек. Ике тәкә башы бер казанга сыямыни?! Икебез дә бер-беребезгә юл куймас холыклы, сәхнәдә ярышып җырлаган шикелле. Аннары ул гыйшык уты нигәдер минем күңелемдә озакка бармады, сүнде, сүрелде. Илһамның үзенең дә күңелендә миңа карата мәхәббәт уты дөрләмәде булса кирәк, без дуслар гына булып калдык. Дуслар буларак бик күңелле көннәребез булды. Илһам кешегә ярдәмчел (әлбәттә, иҗатта ярдәмчел, тормыш итүдә, дөнья көтүдә диюем түгел), киң күңелле, шул ук вакытта шаян да, минем кебек үк уен-көлке ярата. Шаярабыз, төрле шуклыклар, көлкеләр китереп чыгарабыз. Бер концертта мондый кызык булды. Мин яшь чагымда бик ябык, чандыр идем. Ачлы-туклы үсеп, буйга да бала-чага кебек кенә калганмын. Менә бер авылга концерт белән килдек. Бераз соңгарак калганбыз. Юл бик начар булды, яңгыр койды, юкса, алай соңга калмый торган идек. Билетлар сатылып беткән, клуб ишегеннән билетларны тикшереп кертеп торучы бер агай артистларны күрде дә:

– О!.. Артистлар үзләре дә килеп җитте! Әйдәгез, әйдәгез! – дип, барын да эчкә үткәреп тора. Озын, зифа буе белән иң элек Илһам кереп китте. Аны таныйлар да. Аннары берәм-берәм башка артистлар керде, иң ахырда мин калдым. Мине танымыйлар да, артистка, дип уйламыйлар да. Өс-башым да әллә ни түгел инде, әлбәттә.

– Кая барасың син, кызый?.. Бала-чаганы кертмибез!.. Бар, бар, дәресеңне кара да, ятып йокла, иртәгә мәктәпкә соңга калырсың!.. – ди, ишек төбендәге әлеге абзый. «Мин артистка Әлфия Авзалова» дип әйтергә җөрьәт итмим, кызарып тик басып торам. Ишетеп торган, ахрысы, Илһам артына борылып карады да:

– Керсен, керсен, ул – безнең фатир хуҗасының төпчек кызы, әнисе җибәрде, юкса, без концерт беткәч, кая кайтасыбызны белмибез, безгә юл күрсәтүче ул кызый, – диде. Шулай итеп, кайчакта мине бала-чагага исәпләр иде. Төрле шаярулар искә төшә. Әлеге дә баягы, шул ябыклык, бала-чага кебек чандыр гәүдәле булудан үзем дә төрле кызыклар китереп чыгара идем. Гәүдәм ябык, күкрәкләр юк. Такта да такта, мин дә такта, дигәндәй... Сәхнәгә бит әзрәк кеше күзенә күренерлек булып чыгасы килә. Әзрәк күкрәкләр беленеп торсын өчен үземчә хәйлә таптым. Бюстгальтер кигән булам да, аның ике оясына да мамык тутырам... Бер концертта шулай сәхнәгә чыгар вакыт җитте, бюстгальтерыма тутыра торган мамыгымны таба алмыйм гына бит. Кемдер тиште, мамыкны Илһам алып яшергән икән. Мин дә күп уйлап тормадым, Илһам үзе күрмәгәндә генә оекбашларын алдым да, бюстгальтер оясына икесен ике якка тыгып куйдым. Шулай сәхнәгә чыктым, җырладым. Бик шәпләп кул чаптылар. Кыяфәтем шәп, күкрәкләр тулы булып, күпереп тора. Сәхнә артында минем артымнан сәхнәгә чыгасы Илһам дөнья бетереп оекбашларын эзли икән...

Менә шулай, Илһамга гашыйк булып йөрүләрем чын мәхәббәтемне



Кызым Гүзәл белән.
1957 ел

табуым булмаган... Чын мәхәббәтемне соңрак таптым дип язганымча, әйе, соңрак, соңрак очрады минем чын, олы мәхәббәтем... Ул соңрак дигәнемә менә тиздән килеп җитәбез...

Бала белән ирдән аерылдым дип тормыйсың икән, яшь чак, күңел мәхәббәткә омтыла. Чибәр-чибәр егетләр очрый. Кайсылары бик әйбәт кебек күренәләр. Күз төшә, күңел уйный... Бер-ике ел үткәч, мин тагын кияүгә чыгып куйдым бит әй!.. Үзе чибәр, үзе сөйкемле, үзе шаян холыклы, бик оста сөйләшә, теле телгә йокмый... Бер-ике очрашуда гашыйк итеп, күңелне яулап алды бит, каһәр!.. Ни аяныч, бу юлы да мин чын мәхәббәтемне, бәхетемне тапмаган булып чыктым. Чибәр, сөйкемле, шаян холыклы, сүзгә оста кешем – Г. минем сәхнәдә җырлавымны, сәнгать кешесе булуымны, халык алдында җаваплы зур эш башкаруымны аңламады. Юк-барга бәйләнеп, көнләшеп, үзәгемә үтте. Концертлар беткәч, сәхнә артына, яныма кереп тавыш чыгарып, бергә чыгыш ясаучы артистлардан көнләшеп, миңа кул күтәрә башлады. Мин аңардан да аерылырга мәҗбүр булдым. Бу турыда язып торасым да килми. Ләкин язам, башкаларга гыйбрәт булсын, димен. Ашыкмаска кирәк, үзеңнең чын мәхәббәтеңне табуыңа тәмам ышангач кына кияүгә чыгарга кирәк икәнен аңлатасым килә. Мин әле менә 1991 елда гына бер яңа җыр җырлый башладым. Анда мондый сүзләр бар:

1966 ел



Гашыйк булу – сөю түгел,
Сөю – утка ташлаган ул.
Мәхәббәтең бер очрар,
Әле сине тапмаган ул.
Башкаеңны кайгыларга салма әле, салма әле,
Мәхәббәтең, чын сөюең алда әле, алда әле...

Һәр гашыйк булу әле ул чын мәхәббәт, чын сөю түгел икәнлеген яшь чакта аңлап җитмисең шул. Шушы җырда әйтелгәннәр хәзер бик аңлашыла да, ул чакта булган булса бу җыр, бәлки, мин «мәхәббәтем алда әле» дип, көтеп йөргән дә булыр идем... Юк, яшьлек – жүләрлек дип белеп әйтәләрдер, көтеп йөрмисең шул яшь чакта, күрү белән кабынасың. Хәерлегә булсын дигәндәй, бу ялгыш адымымнан бер яхшы гамәл булды: минем икенче кызым – Зөлфиям дөньяга килде.

Мәхәббәтеңдә уңасыңмы-уңмыйсыңмы, сәхнәдәге эшеңне дәвам итәргә кирәк һәм җырчы буларак төшеп калмаска, үсәргә кирәк. Бу минем башымнан бер генә минутка да чыкмый торган уйларым, максатым.

...Илһам белән берничә ел бергә йөрдек тә, 1962 елда безнең бригада

икегә бүленде. Илһам Шакировка халык яхшы йөрер инде, миңа йөрмәсләр дип, бик борчыла башладым. Чөнки ни дисәң дә, Илһам инде ул консерватория тәмамлаган, аннары бездә бит күбрәк тамашачылар – хатын-кызлар, ә хатын-кыз тамашачылар ир-егет җырчыларны ныграк ярата. Башта безгә, ничектер, бер үк маршрут буйлап йөрергә туры килде. Илһам артыннан ул концерт биргән урынга килеп төшәбез, зал тулы халык. Аның концертларына да, минем концертларыма да тамашачылар бердәй яратып йөриләр. Шулай итеп ике бригада булып эшләп киттек.

Шушы елларда филармониягә художество җитәкчесе булып музыка белгече, хормейстер Рәйсә Кәримовна Волкова килде. Ул инде миңа бөтенләй башкача карый иде. Мөмкин кадәр миңа ярдәм итәргә, минем җырчы буларак үсеп китүемә шартлар тудырырга тырышты. Үзе теләп алынып, миңа нота грамотасын өйрәтте. Минем белән аерым музыка дәресләре үткәреп, вокал күнегүләре алып барды. Мин аңар гомер буе рәхмәтлемен. Төрле телләрдә җырлап китүемне дә шушы Р.Волкова оештырды. Менә ничек килеп чыкты бу: үземә яхшы карашта булганын белгәнгә күрә, бер көнне мин аңар үтенеч белән кердем.

– Рәйсә апа, минем төрле телләрдә җырлыйсым килә. Берәр өйрәтә торган җир булса, шунда барып өйрәнеп кайтыр идем, сүзләрен белмәсәм дә, көйләрен көйли беләм, – дип, һинд, гарәп халыкларының көйләрен көйләп күрсәттем. Рәйсә апам кызыксынып китте, бу уемны бик хуплады. Директорыбыз М. Боголюбов белән киңәшеп, бер фикергә килеп, мине укырга җибәрергә булды. Ул вакыттагы культура министры Рәхмәтуллинга Рәйсә Волкова үзе барып, мине укырга җибәрергә рөхсәт алды. Инде укытучы гына табасы калды. Рәйсә Кәримовна бу эшне тәмам ахырынача үзе башкарып чыкты: Мәскәүгә барып, укытучысын тапты, мине Мәскәүгә укырга – командировкага җибәрде. Юл чыгымнарын, кунакханәгә түләүләрне барысын да министрлык күтәрде. Мин бик тырышып укыдым. Укытучым СССРның халык артисткасы, төрле халык җырларын оста башкаручы, танылган педагог Ирма Яунзем иде. Ул минем белән бик теләп шөгыльләнде. Көнгә ике сәгать җырлый идек. Айга якын вакыт эчендә 13 телдә җырларга өйрәнеп кайттым. Әлбәттә, минем кебек авылдан килгән җырчы өчен бу җиңел булмады. Яхшы педагог кулына эләгүем бәхетемә булгандыр. Казанга кайткач, икенче көнне художество советы утырышы булды. Культура министрлыгыннан да килгәннәр, бик игътибар белән минем төрле халыклар телендә җырлавымны тыңладылар һәм яхшы бәя бирделәр. Шулай итеп, мин, Ильяс абый Әүхәдиев әйткәнчә, үз өстемдә эшләвемне дәвам иттердем. Ул елларда минем бары тик үземә генә хас репертуарым бар иде инде. «Гөлҗамал», «Шахта», «Өй артында шомыртым», «Болын», «Сарман», «Минзәлә», «Гармунчы булсын ярың», «Шома бас», «Элмәлүк», «Шәл бәйләдем» кебек татар һәм башкорт халык көйләренә композиторлардан А.Ключарев, М.Мозаффаров, Ж.Фәйзи, Р.Яхин,

С.Садыйкова, Ш.Мәҗитов, Ф.Әхмәдиев җырлары, аларга дөнья халыклары, илебез халыклары җырлары өстәлде.

Репертуарымның шулай баеп китүе сәхнә иҗатымның үсеп китүенә юл ачкандыр. Күңелем дә баеп, сулышым да иркенәеп киткәндәй булды. Бу елларда кая гына гастрольләргә барсак та, концертларыбыз турында мактап газеталарда язып чыктылар.

Сәхнәдә җыр, күңелдә... ә күңелдә мәхәббәт. Кемгә?.. Билгесез кешегә... Яратасы, яратыласы килә, ә яратыр кеше очрамый... Бу елларда «Җилләр, җилләр» (Ф.Әхмәдиев музыкасы, М.Латыйфуллин сүзләре) дигән бик матур бер җыр популяр иде. Мин ул җырны яратып, озак вакыт җырладым. Нәкъ шул җырда әйтелгәнчә, мин чын мәхәббәтемне көтәм, эзлим...

Күзләремнең нурын сирпеп,
Сине эзлим, гүзәлем!
Җилләр дә хәбәр китерми.
Өзелә минем үзәгем.

Йолдызларга очар идем,
Сине анда дисәләр.
Кайда соң син?..
Кайда соң син?.. –
Җилләр дә әйтми исәләр.

Менә шулай «Кайда соң син?..» дип, үз дигәнемне көтеп йөргән бу еллар күңелдә матур җырлар булып уелып калган. Бу елларда мин баянга кушылып, халыкчан планда гына җырлый идем. Минем өчен ул елларда Зифа апа Басыйрова үрнәк иде. Аны кабатлап түгел, аңардан өйрәнә идем. Баянчысы белән матур мөгамәләгә кереп, баянчысына елмаеп карый-карый җырлаучы Зифа ападан үрнәк алып, мин дә баянчыма карый-карый, аның белән бер ансамбль тудырырга омтылып җырлый идем. Ләкин бу мине канәгатьләндерми иде. Күңел ниндидер яңалык тели, сәхнәдә Зифа апага да һәм башкаларга да охшамаган үз юлымны, үз сәнгатемне тудырасым килә. Бөтен ил сәхнәләрендә яшь, матур, зифа буйлы Эдита Пьеха концертлары зур уңыш белән гөрләп бара. Мин аның белән бергә Мәскәү сәхнәләрендә фестиваль концертларында катнаштым. Ул сәхнәдә үзен шундый иркен, матур тота, тавышы ягымлы, җырлау манерасы үзенчә, мин аңардан күземне алалмыйча, сәхнә артында сихерләнеп карап торам. Сокланам, кызыгам, их шулай җырларга иде, дип хыялланам. Эдита Пьеха минем кумирым иде. Бу елларда эстрадада барлык илләрдә дә инструменталь ансамбльләргә кушылып җырлаучылар тавышы гөрли. Музыкада яңа ритмнар, яңа аһәңнәр яңгырый. Мин радио тыңласам да, телевизор карасам да, шундый ансамбльләрне үзебезнең татар җыр сәнгатенә



1970 ел



1973 ел

кертергә иде, дип хыялланам. Яңача чыгышлар ясарга, заманча җырларга иде, хәтта сәхнә киемнәремне дә үзгәртергә иде, дип уйланам. Эдита Пьеха кебек, озын, яңа модалы күлмәкләр киясем килә. Үзебезчә, татарча милли күлмәкләр тектерсәм дә, ниндидер яңалык өстәп, яңа элементлар кертеп, мода журналларыннан үрнәкләр алып, заманча костюмнар әзерләдем. Филармония җитәкчеләре белән киңәшләшеп, кечкенә генә инструменталь ансамбль төзедем. Башта бу ансамбль составы гади генә триодан гыйбарәт иде: баян, саксофон яки кларнет, гитара. Бер-ике елдан соң контрабас һәм бәрмә уен коралы – барабан өстәлде, квартет, квинтет хасил булды. Шулай итеп, мин инструменталь ансамбльгә кушылып җырлый башладым.

1961 елны Мәскәүдә уздырылган Бөтенроссия эстрада артистлары конкурсында җиңүгә ирешеп, конкурс лауреаты дигән исем һәм диплом алуыма күп тә үтмәде, Хөкүмәтебез миңа «Татарстанның атказанган артисткасы» дигән мактаулы исем бирде.

Менә инструменталь ансамбльгә кушылып җырлап, гастрольләрдә йөрим, һәр яңалык башта төрле каршылыкларга, киртәләргә очрый бит. Минем инструменталь ансамбль каршысында да киртәләр... Кайбер тамашачылар, барабан тавышын яратмыйча, хәтта концерт барышында: «Нигә чиләк төбе кагасыз?..» – дип кычкырып утыралар. Татар тыңлаучысының колагы тальян гармун, баян тавышына күнеккән, саксофон, контрабас, барабан та-

«Казан утлары».
Кларнетта – Алексей Черкасов, баянда – Илдар Җаббаров.
1969



вышына ничек күнектерермен икән, дип борчылам. Чигенәсе килми, бөтен дөньяда инструменталь ансамбльләр модада, үзебезнең татар сәхнәсендә дә инструменталь ансамбльләрне кертәсе килә. Ә күңелдә шикләр туа: эстрадада инструменталь ансамбльгә кушылып җырлап, халыкчанлыкны саклап булырмы? Мин бит халыкчан башкаручы, халыкчанлыктан китмимме? Халыкчан җырлау дигән кыйммәтле сыйфатымны югалтмаммы? Бу инструмент тавышларын яратмыйча, авыл агайлары, авыл җиңгиләре концертымны ташлап, клубтан чыгып китмәсме? Куркуым юкка булган, тамашачы мине аңлады, беренче концертларымнан ук инструменталь ансамбльне кабул итте, гажәпсенеп утырса да, инкарь итмәде, әкренләп бөтенләй күнекте, хәтта ярата башлады. Тора-бара «чиләк төбе кагасыз» дип залдан кычкырып утырулар бетте. Бу кечкенә ансамбль, үзенә күрә, кечкенә оркестр иде. Әле күпчелек авыл сәхнәләрендә тальян һәм баяннан башка инструмент яңгырамаган бер заманда, бу ансамбль, үзенә күрә, бер яңалык иде. Мин әкренләп хыялымда йөрткән теләгемә ирешә барам.



«Казан утлары» ансамбле: Барабанда – Виталий Самойлов, бас-гитарада – Николай Вележинский, соло-гитарада – Кәрим Габидуллин. 1975 ел



Бу инструментларга бәйле төрле кызыклар истә калган. Бигрәк тә контрабас төрле кызыклар китереп чыгара иде. Авылдан авылга йөрибез. Менә Мөслим районында бер авылга килеп төштек. Машинадан инструментларны бушатабыз. Көянтә-чиләге белән судан кайтучы бер апа килеп туктады да контрабаска карап шаккатты.

– Кешедән дә биек нинди олы скрипкә бу? – ди.

– Контрабас була бу, апакай!.. – дип, контрабасчы егетебез «олы скрипкә»нең калын тавышлы кылына нык кына итеп бер-ике чиертеп алды. Апа, куркып, читкә тайпылды, иңбашыннан көянтә-чиләге төшеп китте.

– Әстәгыфирулла!.. Тавышы трактор тавышыннан да яман! Бигрәк котсыз нәрсә икән бу нәмәстәкәегез!.. – диде.

Клуб мөдире, яшь кенә кыз, бик үткен, чая булып чыкты:

– Апа, бу олы скрипкәле егетне, әнә теге барабан кагучысын, труба кычкыртучысын фатирга сезгә кертәм, туйганчы бер тыңларсың, артистлар килә калса, үземә керт, дип әйтә идең, алар әле концерт башланганчы өегезне яңгыратып репетиция ясарлар, тулы концерт булыр, – диде.

– Юк, юк, сеңелкәем, бу дыңгырдыкларыңны үзегезгә алып кайт, безгә әнә Әлфия үзе керсен, ул кермим дисә, әнә әргән уйнаучысын алып китәм, – диде апакай. Әргән уйнаучысы дигәне – баянчы Зиннур Гыйбадуллин. Ул, күрдегезме, абзагызны үзләре чакырып тора, дип мактангандай, елмаеп тора. Әлбәттә, аны фатирга бик теләп алып китәләр иде. Кыяфәте дә ярыйсы, баяны да шәп, хатын-кызлар баянчыларны ярата бит алар. Зиннур җирән чәчләрен җилфердәтеп (чәче агара башлагач, ул буяп йөри иде, кайчакта буявы нигәдер кып-кызыл була, чәче җирән түгел, кызылга әйләнә), чәче төсле кызыл баянын сыздырып җибәрсә, хатын-кызлар «ah!» итә. Бу апа Зиннурны иярtеп алып китте. Апаның катыгын, сөзмә-каймагын туйганчы ашаган Зиннур, әмма ләкин баянын бик ялындырып кына уйнаган. Аның андый гадәтләре бар иде. Катык дигәннән, ансамбль егетләре авылларга килеп төшү белән катык кайгыртырга керешәләр. Чөнки катыкны бик яраталар. Рус егетләре катык күрсәләр, минут эчендә сыпыртып ашап бетерәләр. Фатирларга кергәндә, капкадан ук:

– Апа, катык бармы? – дип сорыйлар. Зиннур инде катык белән генә калмый, каймак та таптыра.

Инструменталь ансамблгә контрабасчы егет Юсыф килгәч... минем йөрәккә ут капты – үзенә генә түгел, олы скрипкәсе – контрабасына да гашыйк булдым. Бу гашыйк булу инде элеккеләре кебек тиз генә сүнеп, сүрелеп китмәде, киресенчә, көннән-көн дөрләп яна барган ялкынга, ялкынга гына түгел, вулканга әйләнде. Юсыф үзе дә миннән күзен алмый. Сәхнәдә мин җырлаганда, контрабасын чиертеп, арттарак бер читтә елмаеп тора, карап алсам, күзләр очрашып, икебез дә уңайсызланып куябыз. Аның зәңгәр күзләре төпсез диңгез кебек серле, карап куйса, йөрәк әллә нишләп китә. Контрабасы кебек зифа буйлы, ак йөзле, сүзен үлчәп кенә сөйли, акыллы, укымышлы,

консерватория тәмамлаган. Миннән яшьрәк, әлбәттә. Яшь аермалары турында уйлау башка да килми, мине мәхәббәт бөтереп алды. Ул да шулай миңа башыннан чумып гашыйк шикелле. Арабызда, күзгә күренмәс җепләр булып, ниндидер сихерле дулкын йөри. Мин контрабас дигән инструментны юньләп белми дә идем, ныклап күргәнем дә юк иде. Кая инде безгә, авылда үскән чабаталарга, контрабас кебек Европадан килгән инструментларны күреп белергә, аның тавышын яратырга?.. Исем китеп тыңлыйм, контрабас шундый моңлы олы скрипкә икән, кара урман шаулавын, диңгез ярсуын, буранлап искән җилләрне хәтерләтә, әллә нинди татлы уйлар уйлата, хыяллар дөньясына алып китә... Аның үз моңы, әллә нинди серле үз аһәңе бар икән.

Безнең арабызда йөргән сихерле дулкынга шушы контрабас чыңлавы кушыла. Шактый вакыт шушы сихерле дулкында гына тирбәлеп, бер-беребезне яшерен генә сөеп, мәхәббәтебез турында сүзләр сөйләмичә генә, күзгә-күз карашып йөрдек. Күз карашлары барысын аңлата бит ул. Сүзләр кирәкми дә. Без дә артык күп сүзләр сөйләнеп аңлашмадык, сүзләргә урын юк иде, күз карашларыбыз белән аңлаштык һәм мин аңладым – чын мәхәббәтем шушы икән, минем йөрәгемә чын сөю, олы мәхәббәт килде. Минем еллар буе эзләгән, көткән кешем Юсыф икән... Җәй ахырларында, җил дә исми торган йомшак август аенда без отпуск алып, Кырымга, җәйге ялыбызга китеп бардык. Коллективтагы артистларыбыз белми дә калды. Хәтта иң якын дусларыбыз Гөлшат белән Зиннурга да әйтмәдек. Кырымда ял итеп, кояшта янып, икебез дә бик канәгать булып Казанга кайтып төшсәк, барысы да хәйран калды, без инде бер җан, бер тән булып, кайнар мәхәббәт утына башыбыз белән чумып, бик бәхетле кешеләр идек. Поезддан төшкәч тә, вокзал янында гына кечкенә квартираларында матур итеп гаилә корып яшәгән Гөлшат белән Зиннур дусларыбызга кердек. Алар «ah» итеп безне каршы алды. Матур итеп табын әзерләделәр. Табын янында гөрләшеп утырдык. Гөлшат әйтә:

– Әллә инде өйләнешәсезме?.. Өйләнешсәгез, без бик шат булырбыз. Әйдәгез, туегызны ясыйк!..

Без, әлбәттә, өйләнешмәдек. Мин үземнең ике балам белән ничек аңар кияүгә чыгыйм? Ул миннән сигез яшькә кечерәк. Әниләре, әбиләре дә каршы кебек күренә. Өйләнешмәсәк тә, бик озак еллар буена без бик якын дуслар булып, яратышып йөрдек. Минем тормышымда, иҗатымда Юсыф бик зур роль уйнады, һәр эшне дә булдыра торган, уңган, тырыш, талантлы музыкант Юсыф миңа бик күп эшләрдә ярдәм итте. Ул, гомумән, бик ярдәмчел, кешелекле. Кызларымны тәрбияләште. Кызларым аны бик яраттылар. Юсыф абый дип, аңа бик ияләштеләр. Җыракай да аны хөрмәт итә иде. Безгә килгәндә Юсыф безнең өйдә туганыбыз кебек, үз кеше иде. Мин дә аларга барып йөрдем, ләкин мин аның әнисе һәм әбисе алдында үземне уңайсыз хис итә идем. Әлбәттә, аның әнисе дә, әбисе дә, мин килгәч, якты чырай белән каршы алалар, кунак итәләр. Шулай да бу өйдә миңа каршы куелган, күзгә

күренмәгән ниндидер бер киртә бар кебек иде. Юсыф белән гомерлеккә бергә була алмаячагыбызны мин сизә, тоя идем. Гомерлеккә бергә була алмавыбызны белсәк тә, без Юсыф белән зур кайгыга төшмәдек. Безгә шул вакытлыча бәхет тә – зур бәхет иде. Юсыф минем гомер юлым буйлап, янәшәмдә әле барыр, мин әле алда аның белән бергә булган елларым турында тагын язармын. Бу чорда мин күп кенә яңа җырлар өйрәндем. Репертуарымдагы «Күл буена килсәң иде» дигән җыр күңелемдәге мәхәббәтемне сөйләп биргән кебек, яшь йөрәгемнән кайнап чыга иде:

Ялгыз үскән бер төнбоек
Тирбәлә суда.
Төнбоек та сине сагына,
Сине юксына.
Күл буена килсәң иде,
Уйларымны белсәң иде,
Зифа камышларга карап,
Юксынам сине.

Бер генә сәгатькә күрми торсам да, мин Юсыфны әнә шул җырдагыча юксына, сагына идем. Бу мәхәббәт минем ижатыма канатлар үстерде.

1964 елда танылган язучы Ләбибә апа Ихсановаңың «Социалистик Татарстан» газетасында минем инструменталь ансамбльгә кушылып җырлаган беренче концертларымны хуплап язган мәкаләсе басылып чыкты: «Композиторлар тарафыннан ижат ителгән җырлар гына түгел, татар халык моңнары



«Казан утлары» ансамбле. 1970 ел

да музыкаль инструментлар ансамбле башкаруында матур, көчле яңгырый». Мондый мәкаләләрне уку минем үз-үземә ышанычымны ныгытты. Инструменталь ансамбльне хуплап язулары ансамбль егетләренең дә күңелләрен үстереп җибәрде, без тагын да ныграк тырышып эшләргә сүз бирештек.

Башыма Мәскәүдән Ирма Яунземнан өйрәнеп кайткан чит ил җырларын татарча да җырларга, дигән уй килде. Чит телдә җырлаганда тыңлаучы берни дә аңламыйча утырмасын, җырда ни турында сүз барганын аңласын дип, бер-ике куплетын чит телдә, бер-ике куплетын татарчага тәрҗемә итеп, татар телендә җырлый башладым. Тыңлаучыларга болай җырлау ошый. Татарчага тәрҗемә итү эшендә шагыйрә дустым Гөлшат Зәйнашева ярдәм итте. Һинд җыры «Айлы төн», гарәп халык җыры «Матур кыз», үзбәк халык җырлары «Гөлнара», «Яр-яр», «Кем үзе» кебек матур җырлар ике телдә җырлаганда тагын да матуррак яңгырый. «Айлы төн»не аеруча яратып җырладым. Ул җырны тәрҗемә итәргә үтенеп Гөлшат янына барганым әле дә хәтеремдә. Кышкы салкын бер кич иде. Гөлшатларга килеп кердем. Салкыннан битләрем яна.

– Нәрсә булды, кышкы буранда әллә кош тоттыңмы? – ди Гөлшат, елмаеп.

– Кош түгел, җыр тоттым, – дим. Башыма килгән уемны әйтәм. Кулымда һинд җырының Мәскәүдән алып кайткан нотасы һәм русчага тәрҗемә ителгән сүзләре. – Бик тиз генә татарчага тәрҗемә ит әле, – мин әйтәм. – Чишенеп, «Айлы төн»не һинд телендә җырлый да башладым.

– Бу җырны тәрҗемә итү кирәк тә түгелдер, – ди Гөлшат. – Бу бит без аңламаган телдә җырланса да, бик яхшы аңлашыла, шундый матур, нәфис җыр, мәхәббәт җыры икәнлеге күренеп тора... Шулай һиндча гына җырлый бир син бу җырны, һинд кызлары кебек, тел очында гына йомшак итеп җырлыйсың.

– Юк, – мин әйтәм, – һичшиксез, бер-ике куплет татар телендә кирәк, – дим.

Гөлшат бөтен эшен ташлап, кулына кәгазь-каләм алып, язу өстәле янына килеп утырды. Мин дә аның янына утырып, һинд телендә «Айлы төн»не җырлыйм. Гөлшат русча сүзләргә карап, татарча сүзләр эзли, бер-ике юл тәрҗемә итеп миңа бирә, мин җырлап карыйм, нигәдер, җырлап булмый.

– Көйгә килми, – дим. Дүрт-биш сәгать уйланып, эзләнеп утыра торгач, ниһаять, беренче куплеты булды кебек:

Җәйге төн, айлы төн,
Йоклый гөлләр,
Кошлар тынып калган.
Ә мин керфек какмыйм,
Сине көтәм һаман...



1970 ел

Төне буе утырып, бергә җырлап карый-карый, тәрҗемә итеп, бер калыпка керттек. Мин ул төнне өемә кайта да алмадым. Гөлшатларда кунып калдым. Тәмләп йоклап яткан Зиннурны уятып, җырны җырлап күрсәттем, татарча җырлау аңа да ошады, һинд җырының нәфислеге, матурлыгы күңелләрне биләп алган, сихерләнгәндәй, өчәүләп таң атканчы йоклый алмадык.

Икенче көнне мин гастрольгә киттем, шул ук көнне «Айлы төн»нең ике куплетын татар телендә җырлый башладым. Шулай итеп, чит телдәге башка җырларны да Гөлшат тәрҗемә итеп бирде. Ике телдә җырлау рәхәт, күңелле иде. Чит ил һәм үз илебез халыкларының җырларын тырышып өйрәнеп сәхнәләребездә җырлавым өчен, Республикабызның Тынычлык комитеты мине 1965 елда Мактау грамотасы белән бүләкләде.

1960 елларда халкыбызның бик матур җырлары – «Болын», «Умырзая», «Вәгъдә» (соңгы елларда гына белдем, без халык көе дип җырлаган бу матур җырның музыкасын Зиннур Мөхәммәтдинов язган икән, илебездә сугыштан соң барган репрессиягә эләгеп, ул озак еллар сөргендә йөргән, автор буларак, аның исемен әйтергә рамаган, шундый матур көйнең авторын безбелмәгәнбез); «Бәгърем, диярмен», «Көймә генә килә генә», «Гармунчыгыз өйдәме?», «Күбәләгем», «Шәл бәйләдем» кебек көйләрне бик яратып җырладым. Шулай ук татар һәм башкорт композиторларының «Мәхәббәтем» (Ф. Латыйпов музыкасы, Ә. Ерикәй сүзләре), «Туган авылым» (Х. Әхмәтов музыкасы һәм сүзләре), «Йөрәк сере» (С. Садыйкова музыкасы, И. Ганиева сүзләре), «Яратам, дисең син» (А. Монасыйпов музыкасы, Ә. Давыдов сүзләре), «Кил, иркәм, кил инде» (Б. Гайсин музыкасы, Р.Янбулатова сүзләре), «Тамчылар»



Риф Гатауллин, Мөдәррис Әгъләмов, Гөлзадә Сафиуллина белән. 1980 ел

(А. Монасыйпов музыкасы, Г.Зәйнашева сүзләре) җырларын җырлап репертуарымны баеттым. Шулай ук һәвәскәр композиторларның бик күп җырларын репертуарыма алып, яратып башкардым. Ф. Әхмәдиев, Л. Айтуганов, С. Хәбибуллин, В. Әхмәтшин, З. Гыйбадуллин, М. Имашевларның берсеннән-берсе матур яңа җырларын беренче булып җырладым, популярлаштырдым. «Сөясеңме дип, ник сорыйсың?», «Эзләдем, бәгърем, сине» кебек искиткеч матур җырлар язган Сәяр Хәбибуллинны, «Мәңге яшисе килә», «Җәйнең матур аяз таңнарында», «Солдатлар» кебек берсеннән-берсе матур җырлар язган Фәтхерахман Әхмәдиевне, «Күл буена килсәң иде», «Яшь гомер», «Сәяхәтче җыры» кебек халык яратып кабул иткән җырлар язган Зиннур Гыйбадуллинны, шулай ук башка һәвәскәр композиторларны ул елларда җитәкче урыннарда музыка өлкәсендә эшләүчеләр яратмый, ул композиторларның җырларын репертуарыма керткән өчен художество советы утырышларында миңа бик бәйләнәләр иде:

– Үзешчән композиторларның мәхәббәт турындагы җырлары белән репертуарыңны чуарлыйсың. Ленин, Коммунистлар партиясе турында җырламыйсың, менә фәлән профессиональ композиторларның җырларын җырла! – дип, күрсәтмә бирәләр.

Шуңа да карамастан, күп кенә һәвәскәр дип йөртелгән композиторларыбызның матур-матур җырларын сәхнәдә җырлап кына калдырмадым, радиога барып, магнитофон тасмасына яздырдым, ул җырлар радио аша бүген дә яңгырый. Һәвәскәрләр дип йөртелгән бу композиторлар барысы да музыкант, төрле уен коралларында, бигрәк тә баянда оста уйныйлар, музыка уку йортла-



Баянда – Зиннур Гыйбадуллин. 1962 ел

рында укыганнар, кайсылары консерватория дә тәмамлаган. Дөрес, композиторлар әзерләүче бүлектә укымаганнар, күбесе сугыш вакытларында үсеп, тиешле музыкаль белем ала алмаган. Алар табигый талантлары белән иҗат итәләр. Мин аларны ихтирам итәм, матур җырларын әле хәзер дә бик теләп башкарам.

Нинди законга нигезләнептер, ул елларда һәвәскәр дип йөртелгән бу композиторларга җырлары өчен акча да түләнми иде. Мин аларның җырлары өчен автор буларак акча түләнергә тиеш дип, филармония җитәкчеләре, радиокомитет редакторлары белән бәхәскә керә идем. Профессиональ композитор дип исем алган кайбер композиторларның җырлары өчен (ул җырларны тыңлаучылар яратмаса да) зур гына суммада акча түләнә, ул җырларны җырчыларның репертуарына көчләп диярлек кертәләр иде.

Һәвәскәр дип йөртелгән композиторлар арасыннан (соңгы елларда «һәвәскәр» дигән сүзне әйтми башладылар) Зиннур Гыйбадуллин җырлары турында аерым язып китәсем килә. 60–70 нче елларда мин аның Гөлшат Зәйнашева белән бергәләп иҗат иткән «Күл буена килсәң иде», «Сәяхәтче җыры», «Язгы җыр», «Күңелле ял итегез», «Яшь гомер», «Гармунчыга» кебек берсеннән-берсе матур җырларын беренче булып җырладым, ул җырлар халык арасында бик тиз популярлашты, һәркайда аларны яратып җырлыйлар иде. Бу җырлар миңа җырчы буларак үсәргә ярдәм итте. Зиннур белән озак еллар бергә гастрольләрдә йөрүебез дә сәбәп булгандыр, Зиннур белән Гөлшат бу җырларын махсус минем өчен язды. Алар үзләре дә нәкъ менә шушы җырлары белән халык арасында танылды, чын мәгънәсендә иҗат юлына аяк басты. Без – Зиннур, Гөлшат һәм мин, яшьлек дәртебез белән бергәләп иҗат

иттек, бергә-бергә үстек. Мин аларга бик рәхмәтлемен! Алар минем чын сәхнә дусларым булды һәм хәзер дә бу дуслык дәвам итә. Зиннур белән Гөлшатның ул җырлары ни өчен шулай халыкның мәхәббәтен яулады икән, дисәгез, мин болай дип җавап бирер идем: ул җырларның көйләре дә, сүзләре дә халыкчан стильдә язылган, яшьлеккә хас дәрт белән иҗат ителгән, алар җырларга уңай һәм аңлаешлы. Ул җырлар чын мәхәббәткә, дуслыкка дан җырлыйлар. Ул җырлардагы мәхәббәт, дуслык хисләре илгә, Ватанга тугрылык, туган җиргә мәхәббәт хисләре белән үрелеп яңгырый. «Сәяхәтче җыры»н искә төшерик:

Таныш түгел юллар буйлап
Мин озак йөрдем,
Туган ягым күренерме дип,
Тауларга мендем.
И гүзәл туган ягым,
И ямьле туган ягым,
Тау башында бакча булып,
Төшемә кердең.

Туган җиреңне сөю нинди гади, шул ук вакытта матур итеп әйтелгән!.. Бу җырларның тууы, иҗат ителүе минем күз алдымда булды. Шуңа күрә ул җырларның туган чакларын сагынып искә төшерәм. «Сәяхәтче җыры» иҗат ителгән көннәр бүгенгедәй хәтеремдә. Артист халкының гомере тәгәрмәч өстендә үтә бит. Без, артистлар, кайларга гына барып чыкмыйбыз да, кайларда гына йөрмибез. Ил буйлап сәяхәт итәбез. Юлларыбыз чит илләргә дә барып чыга. Шулай юл йөреп, арып-талып, сәяхәттән өйгә кайтып егылабыз. Өйгә кайтуның шатлыгын юлда күп йөргән артист халкы гына беләдер. Өйгә кайткач, өең, балаларың, гаиләң исән-сау икәнлекне күргәч, шатлыктан юлда йөргәндәге күргән барлык авырлыкларың онытыла.

Менә көннәрдән бер көнне Зиннур белән ерак юлдан – Урта Азия якларында озак гастрольдә йөреп, арып-талып, сагынып Казанга кайттык. Мин, гадәтемчә, икенче көнне үк Гөлшат янына йөгердем. Хәл-әхвәл сорашып, чәй эчеп утырабыз.

– Менә безнең кебек озак итеп юлда йөрүче сәяхәтчеләр турында бер матур җыр язар идегез, – дидем мин Гөлшат белән Зиннурга. Зиннур бу фикеремне күтәреп алды, гастрольдә йөргәндә Казанны ничек сагынуы турында сөйли башлады.

– Казан күренмәсме дип, тауларга мендем, – диде. Һәм тиз генә кулына баянын алды да бик матур бер көй уйнап җибәрде. Бу көй безгә бик ошады.

– Менә сәяхәтче җыры! – диде Гөлшат. – Бу көйдә хәрәкәт, ритм бар. Нәкъ менә юл җыры!..

Юлдан кайту тәэсире белән уйнап җибәргән бу көй, чынлап та, «Сәяхәтче җыры»ның тууы иде.

«Таныш түгел юллар буйлап...», – дип башланган беренче куплетын Гөлшат шул көнне үк, бик тиз арада язды. Мин шул беренче куплетны җырлап карадым. Бик матур яңгырый, көйгә ярашып тора. Ләкин Гөлшат калган куплетларын озак яза алмыйча, эзләнеп, бик авырлык белән язып бетерде. Миңа әллә ничә вариант язып күрсәтте. Кайбер вариантларының сүзләре көенә килми, кайберләренә тел әйләнми, җырларга авыр иде. Кайберсе миңа ошый, Зиннурга ошамый, яки киресенчә, Зиннурга ошый, миңа ошамый. Без Гөлшатны аптыратып бетердек. Әмма Гөлшат безгә ачуланмый, үпкәләми, һаман яңа вариант яза, эзләнә, ниһаять, соңгы вариантны тапты, язып бетерде:

Туган яктан ерак китеп,
Диңгезләр кичтем.
Сагыш дигән тирән күлнең
Суларын эчтем...

кебек шигъри юллар нәкъ безнең, юлларда күп йөргән артист халкының хисләрен, туган якларны сагыну тойгыларын әйтеп бирә, йөрәкне чеметеп алып, әллә нишләтеп куя. Сагыш дигән тирән күлләрнең суларын күп эчтек шул без!.. Мин бу җырны бик яратып җырладым, озак еллар репертуарымнан төшмәде. Хәзер дә әле тамашачыларның сораулары буенча еш кына сәхнәләрдә җырлыйм. Шулай. Җырлар бик җиңел генә дөньяга тумый, җиңел генә язылмый. Озак уйланулар, эзләнүләр белән туган яңа җырны композитор һәм шагыйрь иҗат итәләр, ләкин җырны беренче башлап җырлаучы дөньяга чыгара. Җырлар нотада чакта әле җансыз бер скелет кебегрәк кенә була. Нота әле ул мамыксыз канат шикеллерәк. Җырчы аңа мамык өсти, җырны шомарта, майлый, баллый. Шуңа күрә кайбер җырлар үзенең чын башкаручысын тапмый, әрәм була. Башка җырчылар ничектер, белмим, мин үзем җырны җырларга дип алгач, иң элек сүзләрен укып карыйм. Сүзләре матур, күңелгә керерлек булса, эчтәлеге тирән, мәгънәле булса, аннары җырның көен тыңлап карыйм. Көе ошаса, өйрәнә башлыйм. Матур көй бер тыңлауда күңелгә керә. Андый көйне тиз отып аласың һәм җырлыйсы килеп атлыгып торасың. Кайбер җырларның сүзләрен укыйсың-укыйсың, күңелгә керми, йөрәккә ятмый. Ятлый башласаң, тел әйләнми. Андый сүзләргә язылган җырларны мин яратмыйм, җырламыйм да. Миңа сүзләр аңлаешлы, әйтергә җайлы, җырның көенә ярашып торсын. Әлбәттә, җырның сүзләре тышкы ягы – яңгырашы белән генә түгел, эчтәлеге белән бәяләнә. Эчтәлеге сай булса, әйтергә җайлы, җырларга уңай булган сүзләр дә җырчыны кызыктырмый. Кыскасы, мин җырларның сүзләренә бик нык әһәмият бирәм. Сүзләре менә шушындый җырлап торган җырларны башкаручы артист үзе генә түгел, тыңлаучылар да ярата.

Икенче ирем – Гомәр Җәләлиев белән. 1961 ел



Син ант иттең, вәгъдә бирдең,
«Гомерлеккә яр булырмын, дип, –
Арган-талган чакларыңда,
Йөрәгеңә ял булырмын», – дип.

«Мәхәббәтем» дигән бу җырны мин бөтен йөрәгем белән генә түгел, бөтен җаным белән дулкынланып, тетрәнеп җырладым.

Сәхнәләрдә озак җырлап йөргәч, мин бу җырны радиога барып, магнитофон тасмасына яздырдым. Язманы радионың художество советы бик хуплап кабул итеп, фондка калдырган. Художество советы членнарыннан берәү, миңа бу совет утырышы булып берничә көн үткәч, болай диде:

– Әлфия, «Мәхәббәтем» җырын без бернинди каршылыксыз фондка кабул иттек. Җырлап та куйгансың инде!.. Исләребез китеп тыңладык. СССРның халык артисты, опера театрының күренекле солисты Азат Аббасов синең бу җырыңа зур бәя бирде: «Әлфиянең бу җыры – аның иҗатының югары ноктасы. Бу җырны ул шундый итеп башкара, йөрәгенең бөтен моңын, бөтен байлыгын бирә, бу җыр аның башкаруында ниндидер яңа аһәңнәр белән, ниндидер үзенчәлекләр белән яңгырый, чегән халык җырларына хас моңнар, ниндидер матур мелизмнар бар бу романста», – диде.

Мондый мактаулар көтмәгән идем, әлбәттә. Мактаганнар икән, рәхмәт. Бу турыда мактанып язуым түгел, Аббасов кебек зур җырчы биргән бәяне факт буларак язып калдырасым килгәнгә генә язуым. Зинһар, Әлфия мактана, дип уйлый күрмәгез.

Фәттах Латыйпов белән Әхмәт Ерикәй иҗат иткән бу җыр минем язмыш юлдашым булды:

Ник соң, бәгърем, биргән вәгъдәң,
Очып китте искән җил сыман?..
Тик мин калдым, ялгыз калдым,
Яфракларын койган гөл сыман...

Шушы җырымдагы кебек, мин үзем дә, яфракларын койган гөл сыман, ялгыз калдым... Бу турыда алдарак язармын...



Раил Садриев, Рәйсә Бибарсова, Нажия Минкина, кечкенә Зөлфия. 1972 ел

Таныш түгел юллар буйлап...

(Гастрольләр, гастрольләр...)

Бизмәгәндәй яшәү бәхетеннән,
Юл йөрүдән мәңге бизмәм мин.
Юллар, юллар, инде ничә еллар
Аерыла алмыйм сездән мин...

Инструменталь ансамбльне «дыңгырдыклар» дип атасалар да, авыл апалары әкренләп безнең инструментларның тавышына күнегә башладылар. Яшьләр, әлбәттә, бу яңалыкны тиз кабул итте. Яңалык дим, эстрадабызга без яңалык алып килдек, дип уйлыйм. Дөресен әйткәндә, инструменталь ансамбльгә кушылып җырлап китү җиңел генә булмады. Инструментлар белән бергәләп, җырның эчтәлеген ачарга, аны сәнгатьчә матур итеп башкарырга кирәк. Тыңлаучы аңласын да, яратсын да, күңеленә ләззәт алып, онытылып тыңласын да. Моның өчен ансамбльгә кушылып гадәти генә җырлау җитми. Ансамбль белән бербөтен булып яңгырауга ирешергә кирәк. Ансамбль артистлары белән вокалист бербөтен булып суларга, яшәргә тиеш. Һәм мин моның өчен бөтен көчемне куеп тырыштым. Озын-озак репетицияләр үткәрергә туры килә иде. Инструменталь ансамбль солистлары да коеп куйган, катып калган музыкант кына булырга тиеш түгел, эчке бер бәйләнеш белән алар минем күңелемә үрелергә тиеш. Нәтиҗәдә, күп та-



«Казан утлары» төркеменең җитәкчесе Геннадий Кляузов белән. 1972 ел



1983 ел

вышлы музыка туарга тиеш. Җырлар инструменталь ансамблгә кушылып башкарылганда яңа яңгыраш ала. Шул ук атаклы «Кәккүк» җыры инструменталь ансамблгә кушылып башкарганда инде бөтенләй яңа аһәңнәр белән байый. Кәккүк булып инде җырчы гына сайрамый, кларнет сайрый, аны башка инструментлар кабатлый. Шулай итеп, Гөлсем апа кәккүген мин инде матур тавышлы инструментларга кушылып сайрата башладым. Гөлсем ападан соң кабатлап җырласам да, үземчә җырладым, яңа аһәңнәр өстәп, яңача башкардым. Гомумән, безнең заманда, 20–30 нчы еллардагыча, Гөлсем апалар җырлаганча, сәхнәдә кулларны күкрәккә куеп, кыймылдарга да куркып җырлаудан китәргә кирәк иде. Җырның эчтәлеге таләп иткән урыннарда тиешле хәрәкәтләр ясап, сәхнәдә яшәп җырларга кирәк иде. Җырлаганда иркенлек, хөрлек, табигыйлек гадәти күренеш булып, безнең татар эстрадасына да керергә тиеш иде. Һәм мин сәхнәдә шулай үз-үземне иркен, хөр тотып җырлый башладым. Ялгышмаганмындыр, дип уйлыйм. Башка яшь җырчылар да әкренләп сәхнәдә иркен, табигый йөрешләр ясап, ирекле хәрәкәтләр белән җырлый башладылар. Һәм безнең татар эстрадасы да, башка милләт эстрадаларыннан калышмыйча, сәхнәдә яңа юнәлеш алды. «Советская эстрада и цирк» журналының 1967 елгы 8 нче санында Н. Смирнова минем турыда болай дип язып чыкты: «Актриса – бик үзенчәлекле. Аның җырлавында күп нәрсә үзенә җәлеп итә. Сәхнәдә үзен зәвыклы тоту, нәфислек, табигый кыланышлар, хәрәкәтләр аның җиңел җырлавында гына түгел, үзен грациоз тотуында, йөрешләрендә, күз карашларында да чагыла...»

Мондый бәяләр көткән кешеме мин?.. Сәхнәдә кыланыйм, хәрәкәтләр ясыйм, диеп уйлаудан түгел, җырның эчтәлеге, характеры шулай таләп иткәннән табигый хәрәкәтләр, табигый йөрешләр килеп чыга, алар үзләреннән үзләре туа, аларны ясалма рәвештә уйлап чыгарырга ярамый. Табигыйлек, табигыйлек, шул чакта гына йөрешләр, хәрәкәтләр аклана.

Инструменталь ансамбль артистлары – талантлы музыкантлар Юсыф Вәлидов, Леонид Черкасов, Геннадий Евстегнеев; соңрак килеп кушылган Рим Кәлимуллин, Игорь Иванов, Геннадий Кляузов, Рафикъ Аганов; ансамблнең җитәкчесе, җырларымны инструментларда уйнау өчен матур итеп эшкәртүче виртуоз музыкант Вадим Венедиктов – минем эстрада сәхнәсендә яңача эшләп китүемә чын күңелдән булышкан, ярдәм иткән дусларым, хезмәттәшләрем. Без алар белән бергәләп авыл клубларында, авыл сәхнәләрендә чирәм күтәргәндәй эшләдек, инструменталь ансамблгә кушылып җырлауның беренче буразналарын салдык. Шушы ансамбль составында беренче көннәрдән үк башлап, озак еллар баянчы булып, бүген инде танылган композитор Зиннур Гыйбадуллин эшләде.

Зиннур бик тырыш иде. Җаны-тәне белән музыкага, җырга бирелгән, татар музыкасын, татар җырын, бигрәк тә халык көйләрен яхшы белүче баянчы ул. Кечкенәдән гармун, баян уйнап үскән, алар әтисе җитәкчелегендә гаилә



Музыкант
Игорь Иванов белән.
1974 ел

ансамбле төзеп, бөтен гаиләләре белән Бөгелмә, Мөслим якларында авылдан-авылга концертлар биреп йөргәннәр. Алты балалы зур гаилә – һәркайсы нинди дә булса инструментта: гармунда, баянда, яки скрипкада, мандолинада уйнаган, үзенә күрә бер гаилә оркестры булган. Менә шушы музыкаль гаиләдә үскән Зиннур – халык таланты – безнең ансамбльдә аерым урын тотты. Татар көйләрен белмәгән рус музыкантларына үзенең киңәшләрен бирә, аларны татарча моңлы итеп уйнарга өйрәтә иде. Сәхнәдә ул үзен ягымлы, иркен, табигый тотып, баянында җиңел, матур уйный иде. Инструменталь ансамбль музыкантлары гастрольдә үзара бик тату, дус йөри иде. Юлда очраган авырлыкларны бергәләп җиңә-җиңә, без бик күп юллар үттек.

Кунакханәләрдә, фатирларда бер телем ипине бүлеп ашаган көннәребез дә була иде. Русы, татары, яһүде барысы бертуган кебек дус, тату йөрү белән бергә, музыкантларыбыз шаярырга, төрле кызыклар, мәзәкләр уйлап чыгарырга да ярата иде. Арада иң шугы, шаяны Зиннур Гыйбадуллин булгандыр. Нәрсәләр генә уйлап чыгармый иде ул! Рус егетләре Г. Кляузов яки Г. Евстегнеевларны көлкегә калдырырга ярата иде. Бер авылда Кляузовны, икенче авылда Евстегнеевны: «Фәлән йортта, фәлән сәгатькә килсен диеп, сине бер чибәр кыз көтә, русча белмәгәнгә күрә, миннән үтенде, чакыруымны тапшыр, диде, мине яучы итеп җибәрде, безнең татарда шулай яучы җибәрү гадәте бар», – дип, егетләрне «свидание»гә җибәрә иде. Кляузов белән Евстегнеев чын күңелләреннән ышанып, кызлар белән очрашырга йөгерә. Зиннур артларыннан: «Ничек оста алдадым», – дип көлеп кала. Кляузов белән Евстегнеев үзләренең алдануларын белгәч, җавап итеп, Зиннурның үзен төп башына утыртырга план кора. Андый



1955 ел

шаяру планнарын ул елларда минем концертларымны алып баручы конферансье Фәйзи абый Йосыпов бик оста оештыра иде. Гомумән, бөтен шуклыкны ул җитәкли иде, аның котыртуы белән егетләр төрле этлекләр уйлап чыгаралар иде. Еш кына Зиннур үзе аларның кармагына эләгеп, көлкегә кала иде. Зиннур һәрвакыт гастроль бетүгә Казанга – өенә ашыга, күзен-башын тондырып кайтып китә иде. Кайтырга билетлар алу кыен чакта да, ниндидер җаен табып, билет сатучы кызларга комплиментлар әйтеп, берүзенә генә билет сатып алып, бездән алда кайтып киткәли иде.

Шулай берүзен генә кайгыртып, кайтып китәргә җыенган чакларында, әлбәттә, безнең ачу килә. Бигрәк тә музыкант егетләр аңардан «үч алалар», әйберләрен тутырып әзерләп куйган чемоданына Зиннур үзе күрмәгәндә генә, бер-ике кирпеч тыгып куялар иде. Иңбашына баянын асып, костюмнар һәм кирпечләр салган чемоданын күтәреп, Казанга – өенә кайтып китә иде бичара Зиннур!.. Без шау-гөр килеп, көлешеп, аны кул болгап түгел, йодрык күрсәтеп озатып кала идек. Нигә соң бу чемодан авырайды икән дип, ачып карарга уена килмәде микән, әллә өенә кайту шатлыгы белән чемоданының авыраюын сизмәде микән?.. Кайчакта «Казанга өеңә кайткач, хатының белән пешереп ашарсың, менә сиңа симез тавык!» дип, егетләр язу язып, үлгән карганы әйбәтләп кәгазьгә төреп, Зиннурның юл сумкасына тыгалар иде. Сәхнә артында һәвәскәр артистлардан калган иске-москы костюмнар арасында иске модадагы берәр эшләпә аунап ятса, аны да матур итеп кәгазьгә төреп,

«хатыңа бүләк итәрсең» дип язу язып, үзе күрмәгәндә генә чемоданына тыгып куялар иде. Зиннур шулай әллә ничә тапкыр өенә каурыйлар, канатлар кыстырган иске плюш эшләпәләр алып кайтып китте. Өенә кайткач, кирпеч, карга, иске эшләпәләр күреп, Зиннурның җен ачулары чыккандыр, әмма ләкин егетләргә ул ачу тотмый иде, ачуы чыкса да, шаркылдап көлгәндер.

Зиннур белән озак гастрольләрдә бергә йөреп кайтканнан соң (озак бергә йөреп, артистлар кайчакта бер-берсеннән туеп та бетә), мин аларда еш кунак булам, күп вакыт кунып та кала идем. Гөлшат пешеренергә ярата, ул пешергән тәмле ризыклар белән сыйланып, табын янында гөрләшеп утырабыз. Гөлшат безнең егетләр шаярып Зиннур сумкасына тыгып җибәргән «күчтәнәч» каргалар өчен ачуланмый, рәхәтләнеп көлә генә. Ә искереп беткән плюш эшләпәләрне киеп, бии-бии безне көлдерә. Шулай күңелле, матур гына яшиләр иде, югыйсә. Алар да аерылышты... Чын мәхәббәт булмады микәнни соң шулай шаулап-гөрләп бергә яшәүләре?.. Әллә мәхәббәтләре сүнеп-сүрелеп киттеме?.. Мәхәббәтнең серләренә төшенеп бетеп булмый, серле шул мәхәббәт, серле... Без аларга карап соклана идек, әллә күзебез тиде микән?.. Язмышлар... Язмышлар... Шул елларда алар бергәләп язган, халык арасында популяр булып киткән матур, моңлы бер җырның сүзләре белән әйтсәк:

Юк, кайтмас яшь гомер,
Калды ул ераста,
Зәңгәр томан артында сагыш булып.
Яшьли сөйгән яр да
Ятка калды анда,
Әллә язмыш, әллә бер ялгыш булып...



1983 ел

Аларның бу җырын мин бик яратып, сәхнәләрдә озак җырладым, хәзер дә мин аны еш кына репертуарыма кертәм. Күп вакыт тамашачылар соравы буенча җырлыйм, үземнең һәм Гөлшат белән Зиннурның яшьлекләрен исемә төшереп моңаям, үзәкләрне өзә торган матур хатирәләргә бireләм.

Зиннур турында халык арасында күп мәзәкләр, анекдотлар йөри. Мәзәкләр, анекдотлар чыкмый мөмкин түгел, чөнки ул үзенең кызык, сәер яклары белән аерылып тора. Үзебезнең коллектив кына түгел, килеп төшкәч, бөтен авыл халкы рәхәтләнеп көләрлек кызыклар китереп чыгара. Төсе уңып беткән зәңгәр спорт ыштаны гына киеп, майкасыз, күлмәксез килеш ул, «чыныгам» дип, кара таңнан торып йөгерергә чыгып китә. Озын, ләкин сирәгәеп калган җирән чәчләрен җилфердәтеп йөгереп йөрүен күргән авыл халкы «кара таңнан нинди сүрәмәт йөгереп йөри» дип куркуга төшә. Зиннур урам буйлап йөгереп йөри дә урманга яки әрәмәгә китә, урманда күргән кешеләр инде аны «бу нинди качкын икән» дип шүрлиләр. Кайда нинди елга, инеш, күл очрый, саймы ул, тирәнме, Зиннур шунда коена, чума. Судан чыга да кырмыска оясына кереп утыра. Тагын торып йөгерә, тәпәнчек ата-ата гимнастика ясый, авызын ачып, кошлар сайравын тыңлап тора.

Безнең егетләр елга, күл очраса, балык тотарга ярата иде. Балыкны бик эләктерә алмыйлар, әлбәттә. Эләктерә алмасалар да, тоткан булып йөриләр, вакыт үткәрергә ярап торгандыр инде. Зиннур да балыкка йөргән була, бармак хәтле балык тотса да куана, кайтып, шул чәнти балыклардан уха пешерә. Бервакыт шулай үзенең кечкенә электр плиткәсендә кечкенә кәстрүле белән бер-ике генә чәнти балыктан уха пешергән дә ашарга утырган. Шул минутта гына биюче егетебез килеп кергән бит. Зиннур ухасын тиз генә өстәл астына яшергән. Биюче егет белән сөйләшеп торган арада, өстәл астындагы уханы мәче ашап киткән...

Авыл җирләрендә кайбер юмарт колхоз председательләре артист халкын яхшы итеп ашата, ашханәсендә булмаса, фатир хуҗасында мул итеп ашарга әзерләтә. (Хәзер, әлбәттә, андый эшләр Бакуда дигәндәй, алай сыйлаулар сирәгәйде. Артист халкы икмәк үскән җирдә – авылда кайвакыт ачлы-туклы йөри.) Кайбер колхозларда артистларга ит, тавык, бал кебек әйберләр дә биргәлиләр. (Болары да элегрәк елларда иде, әлбәттә.) Тавык бирсәләр инде, иң элек Зиннур барып ала. Кайчакта фермага ук барып, фатирына тере тавык алып кайта. Бер авылда фермада эшләүче кызларга җырлар җырлап күрсәтә-күрсәтә, иң симез тавыкны сайлап ала бу, ике аягыннан тотып, урам буйлап тавыкны мактый-мактый кайта да, суырга берәр кеше эзләп чыгып китә... Ул гомеренә пычак тотып тавык суя алмый... Суырга берәр бабай эзләп табып алып кайтканчы, өстенә чиләк каплап куйган симез тавык тыны бетеп, ишек алды уртасында җан тәслим кыла... Шулай итеп, Зиннур тавыксыз кала...

Тавык дигәннән, тавык белән бәйләнешле кызык хәлләр ул елларда күп булды инде ул. Элеккерәк елларда һәр колхозда тавык фермасы бар иде бит.



Башкортстан Республикасының Белорецк шәһәрендә Тарар әдәбияте һәм сәнгате көннәре. 1988 ел

Хәзер генә ул тавык асраудан колхозга керем юк дип, тавык фермаларын бетерделәр, бик аз авылда гына калды тавык фермасы. Артистларга хәзер тавык эләкми. Шулай бер җәйне гастрольгә чыгарга җыенабыз. Гөлшат дустым китап нәшриятында эшли иде, җәйге ялга чыгарга әзерләнә. Мин моны үзебез белән гастрольгә чыгарга күндердем. Әйдә, мин әйтәм, ялыңны безнең белән үткәр, концертларда катнашырсың, бер-ике шигырь укырсың, бергә-бергә күңелле итеп йөрербез, кояшта кызынырбыз, колхозлардан тавык алырбыз, тавык ите белән генә сыйланырсың, Казанга кайтып киткәндә тавык алып китәрсең, мин Җыракай белән балаларга да тавык җибәрермен, дим. Җыракай белән балаларга 3 тавык, күрше апаларга 1 тавык, каенанама 1 тавык, Флүрә сеңелемә 1 тавык, барысы 6 тавык биреп җибәрермен, дим. Теләсәң, үзеңә дә 6 тавык алып кайтып китәрсең, дим. Ярар, диде Гөлшат. Безгә ияреп, авылларга гастрольгә чыкты бу. Йөрибез, йөрибез авылдан-авылга, Сарман, Мөслим, Зәй районнарын әйләнеп чыгып киләбез. Үч иткәндәй, ул җәй бик яңгырлы, суык булды, туңабыз, өшибез, фатир хуҗаларыннан йон оекбашлар, йон бияләйләр сорап алып киеп йөрибез. Аякта резин галош, өстә плащ, башта шәл. Ай буена яңгыр коя. Батабыз, чумабыз, кояш күргән юк. Кояшы – кояш, тавык күргән юк. Бер генә авылда да тавык ала алмыйбыз. Йә юлда батып-чумып соң гына килеп, колхоз рәисен тота алмыйбыз, яисә колхозда Хрущев күрсәтмәсе белән, тавык асрау рентабельле түгел диеп, тавык фермасын бетергәннәр. Ай буена тавык эләкми. Гөлшат бер дә зарланмый гына йөрде. «Бу кояш чыкмаска баткандыр, кызынып булмады», – диештергәләде. «Мин китәсе көнне чыгачак ул кояш, мин Казанга кайтып

китим инде, минем белән йөргәнгә сез кояшсыз тилмерәсез», – дия башлады бу һәм кайтырга җыенды. Казанга барасы бер машинага менеп утырды, менеп дим, чөнки кузовлы машина иде, ул елларда без гел йөк машинасына төялеп йөри торган идек бит. Шулай кузовка менде бу, шул минутта ялтырап кояш чыкты. Барыбыз да көлешәбез, чынлап та, Гөлшатның китүен генә көткән икән кояш, дибез.

– Әлфия, алты тавыгың кайда? Алты тавык җибәрәсе идең бит Казанга, Җыракаеңа – 3 тавык, күрше апаларыңа – 1 тавык, каенанаңа – 1 тавык, Флүрә сеңеленә – 1 тавык... – дип санап китте Гөлшатыбыз. «Миңа да алты тавык вәгъдә иткән идең, алты түгел, ярты тавык та юк», – дип көлә үзе. «Уф!.. – димен мин, – алты түгел, ярты тавык юк!..» Артистлар көләләр: «Алты тавык, алты тавык, кая монда алты тавык, батып үлмәсәк, ярый инде», – диешәләр. Шул көннән соң безнең телгә «алты тавык» дигән сүз керде. Булмас эш, алдан сөйләнеп йөреп тә, барып чыкмас эшне «алты тавык» дия башладык. Мин берәр булмастай эшне алдан планлаштырып сөйли башласам, артистлар: «Алты тавык!..» – дип, кул селтиләр. Бу сүз безнең телгә гомерлеккә керде, ахры, һаман әле без булмас эшне «алты тавык!..» дибез. Хәтта балаларыбыз да берәр нәрсә планлаштырып сөйли башласак, «Әй, алты тавык!..» – дип көләләр.

Шундый кызыклары булмаса, гастрольләрдә йөрү бик ялыктырыр иде. Без шул төрле кызыклар, мәзәкләргә алданып, юлда бөтен авырлыкларны онытабыз.

Татарстанның атказанган артисты Фәйзи ага Йосыпов минем концертларымны озак еллар алып барды. Фәйзи ага халык арасында бик популяр иде. Афишада аның фамилиясен укуга, тамашачылар елмаешып: «О!.. Фәйзи Йосыпов килгән!» – диләр. Концертларны ул күтәренке күңел белән, бәйрәмчә итеп алып бара иде. Татар сәнгатендә озак еллар хезмәт итеп, дан казанган Фәйзиләргә (адашларына) багышлап үзе чыгарган такмазасы бар иде аның. Гармунчылар Фәйзулла Туишев, Фәйзи Биккинин, композитор Җәүдәт Фәйзи, язучы Әхмәт Фәйзи, драматург Мирхәйдәр Фәйзи, балетмейстер Фәйзи Гаскаров һәм үзе Фәйзи Йосыпов – барысы да татар халкының данлыклы Фәйзиләре. Концертны башлаганда:

Сәнгать өлкәсендә күркәм урын
Алып тора бездә Фәйзиләр, –

дип башлап җибәрә иде ул үзенең күңелле такмазасын. Соңрак елларда ул болай дип шаярып башлый иде концертыбызны:

Фәйзи агай, Фәйзи бабай,
Концерт давай!..



Фәйзи Йосыпов, Алексей Черкасов, (?) белән. 1963 ел

Фәйзи абый – Чистай районының мәшһүр язучы Гаяз Исхакый туып-үскән Яуширмә авылыннан. Мәдрәсәдә Гаяз Исхакыйдан дәресләр алган. Фәйзи абый хәзер Гаяз Исхакый турында кызыклы истәлекләр сөйли.

Фәйзи абыйның репертуары бик бай. Әнгам Атнабаевның «Унбер малай үстек авылда», Зыя Мансурның «Юл тазартам» кебек җитди шигырьләрен укый, тамашачыны уйландыра, шундук шаян шигырьләр сөйли башлый, зал рәхәтләнеп көлә. Репертуарындагы сатирик-юмористик шигырьләрен, такмазаларын, репликаларын ул гадәти итеп кенә сөйләми, уйный, кечкенә көлкеле әсәрне күңелле бер күренеш итеп, тасвирлап, төрле-төрле типларны күз алдына китереп бастырып куя иде. Сатирик такмазаларны көйләп сөйләгәндә, мин игътибар белән тыңлый идем, тавышы сыгылмалы, йомшак, музыкаль тавыш. Концертыбыз җанлы, күңелле бара иде. Конферансье буларак, ул шулкадәр халыкның мәхәббәтен яулады, аны сәхнәдән чыгармыйлар иде. Фәйзи абый ут иде, ут. Сәхнәгә ут, ялкын кабыза иде. Сәхнәгә ул гадәти атлап кына чыкмый, очып чыккандай, атылып килеп чыга. Теле-телгә йокмый, диләр бит әле, шулай теле-телгә йокмый, көлке артыннан көлке сөйли, экспромт рәвештә күңеленә тиз генә килгән мәзәкләр әйтеп куя. Бер елны Уфа шәһәрендә концерт барганда, аңа залдан мондый язу җибәрәләр:

«Әйттерәсең, чирттерәсең, төрттерәсең, әллә-лә! Фәйзи абый, телләреңә шайтан төкердеме әллә?!.»

Бу кәгазь кисәгенә Фәйзи абый бала кебек куанды, шатланып: «Менә бу минем хезмәтемә бәя дисәң дә бәя!» – дип, кабат-кабат укыды.

Яше шактый өлкәнәйгәнче ул сәхнәдән төшмәде. Кайчакларда сәхнә артында: «Балалар, минем кәеф шәп түгел, йөрәк авыртып тора», – дип зарла-



Фәйзи Йосыпов белән Башкортстанда гастрольдә. 1966 ел

нып утыра. Концерт башлар вакыт җиткәч, гадәтенчә, сәхнәгә очып чыга, без аңар: «Әй, Фәйзи абый, сәхнә артында юри генә бабайларча зарланып утырасыз ла Сез, сәхнәгә чыккач егетләр кебек биеп йөрисез!» – дибез. Ул чынлап та шулай, чын талантларга хас булганча, үз-үзен онытып, яшенең олы икәнен уйламыйча да, бар җаны-тәне белән эшли иде. Концерт барганда төрле хәлләр килеп чыга. Тамашачылар концертны алып баручыга төрле сораулар бирәләр, кайчакта юри четерекле сораулар биреп, артистларны сынап утыралар. Фәйзи абый бервакытта да югалып калмый, һәрвакыт тапкыр җаваплар биреп, тамашачыларның үзләрен кызык итә. Бер елны Сәмәрканд шәһәрендә концерт бирәбез. Залдан берәү кычкыра: «Фәйзи абый, әйт әле, безнең Сәмәрканд зурмы, Казан зурмы?» – ди. Фәйзи абый аңа болай дип җавап бирде: «Казан янында Самаркан, фил янында таракан!..» Зал рәхәтләнеп көлде.

Фәйзи абый яше белән бездән шактый олы булганга, без аны әтиебезне хөрмәт иткән кебек ихтирам итә идек. Ул безгә әти дә, абый да иде. Шул ук вакытта ул яшьләрчә дәртле булганга, без аңа үз тиңебезгә караган кебек карый идек. Ансамбль егетләре белән яшьләрчә шаяра, төрле кызыклар уйлап чыгара иде. Бервакыт виртуоз музыкант, гитарачы Геннадий Кляузов сәхнәгә чыгар алдыннан гына күреп шакката: кемдер аның гитарасының иңбашыннан асып куя торган йомшак күннән эшләнгән бик матур каеш тасмасын иске чабата киндерәсе белән алыштырып куйган. Сәхнәгә чыга алмый-

ча аптырый, бер көлә, бер ачулана. Матур тасмасын эзләп башы катты. Кем эше булгандыр, Фәйзи абыйның шаяруына охшаган иде бу. Концертларны алып барганда, Фәйзи абый кинәт Кляузовны Геннадий Кляузов дип түгел, Фәрит Фәхретдинов диеп белдерә башлады. «Кляузов фамилиясе татар тамашачысы өчен кулай түгел, гомумән, бу фамилия сәхнә өчен килешми, көлке ишетелә, мин аны татарлаштырдым», – дип аңлатты ул бу эшен. Кляузовның хәтере калмады, киресенчә, ул шат иде. Чөнки татар тамашачысы аны Фәрит дип кабул итте, яхшы музыкант буларак яратты. «Фәрит Фәхретдииов!» дип белдерүгә, Кляузов йөгереп сәхнәгә чыга, кояш кебек балкып елмая иде. «Сәхнәгә Геннадий Кляузов чыга» дип белдергәч, Геннадий сәхнәгә теләр-теләмәс кенә чыга, елмаймый да иде. Геннадий бик яшьли дөнья куйды, бик кызганыч. Ул бик талантлы, сөйкемле артист иде.

Фәйзи абый Йосыповның мәзәкләрен бригадабызда әле һаман да искә алып, көлешеп сөйлибез. Бервакыт ул концерт башланыр алдыннан болай ди: «Беләсезме, без кем шайкасында йөрибез? Без – Әлфия Авзалова шайкасы артистлары!» Без, көлешеп: «Бу әкәмәт сүз каян килеп чыкты әле?» – дибез. Фәйзи абый көлә-көлә безгә бер кызык сөйләде. Без бу вакытта мишәр авылларында йөри идек. Фатирга кергәч, Фәйзи абыйдан фатир хуҗасы – мишәр апасы болай дип сорый икән: «Бездә әле күптән түгел Гани Вәлиев шайкасы концерт бирде. Сез, Фәйзи әзи, кем шайкасында йөрисез? Рәшит Вахапов шайкасы белән килмәдегезме?» Фәйзи абый хуҗа хатынга: «Без Әлфия Авзалова шайкасында йөрибез», – дип җавап биргән.

Әле алда өзек китерелгән Ләбибә Ихсанова мәкаләсендә Фәйзи абый турында мондый юллар бар: «Республикабыз колхозларында гастрольдә йөргәндә сөйләр өчен ул «Авылым кешеләре» дигән махсус цикл әзерләде.

«Минем танышларым» дигән сатирик циклдан без кулыннан эш килмәгән бушбугаз Саттаров-Сусатаровлар, әшнәлек белән көн күрүче Малтабаровлар, эшлексез җитәкче Котбытдинов-Куркытдиновларны күреп нәфрәтләнәбез. Артист бу әсәрләрне башкарганда, бөтен эчке дөньясы белән образга кереп, сатирик персонажларны бар түбәнлекләре, булдыксызлыклары белән тамашачы алдында гәүдәләндереп бирә... Фәйзи ага туктаусыз эзләнә, өйрәнә. Бигрәк тә ул Аркадий Райкинның иҗат алымнарын күзәтеп, өйрәнеп бара...»

Бер гастроль вакытында администраторыбыз юк иде. Барлык оештыру эшләрен үзебез, артистлар башкарабыз. Транспорт табу, билет сату кебек эшләрне дә үзебез эшлибез. Клубларда концерт алдыннан тамашачыны билет тикшереп залга кертүне дә алмашлап үзебез башкарабыз. Моны артистлар телендә «ишек төбендә тору» дип йөртәләр. Программа буенча кайсы артист сәхнәгә соңрак чыга, шул ишек төбендә тора. Фәйзи абый концертны башлап җибәрүче булгач, концерт уртасындарак ишек төбенә чыга иде. Мин башлап җибәрүче булмагач, күп вакыт концерт башланыр алдыннан ишек төбендә торам. Менә бер авылда концерт башланыр вакыт җитте. Тамашачылар залга

Гитарада
Кәрим Габидуллин.
1975 ел



керде. Нигәдер бер төркем ир-егетләр ишек төбенә җыелган, залга кермиләр, әллә билетлары юк, билет аласылары килми. Күп вакыт шулай яшь-җилкенчәк егетләр концерт башланганны көтүчән була, концерт башлангач, ишек төбен яулап алып, залга бушлай кереп китә. Мин шул яшь-җилкенчәкне залга кертмәскә дип, ишек төбендә торам, менә Фәйзи абый сәхнәгә чыкты:

– Концертыбызны башлыйбыз!.. – дип белдерде. Шул сүзне әйтүе булды, ишек төбендәге бер төркем яшь егетләр, мине таптап, залга ыргылды. Мин, үзем дә сизмәстән:

– Каравыл!.. Үтерәләр!.. – дип кычкырып җибәргәнмен. Фәйзи абый сәхнәдән залга сикереп төшеп, минем янга йөгереп килде, мине идәннән күтәреп алды.

– Егетләр, сез нишлисез? Әлфия бит бу!.. – дип кычкырды.

Көлсәң – көл, җыласаң – җыла, дигәндәй, нинди генә хәлләр булмый гастрольләрдә. Бервакыт безнең бригаданың биючесе Ильяс Якупов администраторлык вазифаларын да башкарып йөрде. Концертлар әйбәт кенә бара. Бер авылда бик матур итеп концерт бирдек. Икенче көнне иртүк мәктәп директоры болай ди:

– Бөтен авыл халкы яратты концертыгызны, тик менә балалар гына мәхрүм калды. Күрше авылга киткәнче, иртәнге якта безнең мәктәп балаларына да концерт күрсәтсәгез иде, 30 тиеннән билет сатарбыз да, сезгә түләрлек акча җыярбыз.

Без риза булдык, концерт бирдек. Балалар да, укытучылар да бик канәгать калдылар. 30 тиеннән билет сатып, болар 160 сум акча җыйганнар. Безгә шул акчаны бирделәр. Уйладык-уйладык та, бу акчаны филармония кассасына алып кайтмаска, үзара да бүлмәскә булдык. Фәйзи абыйның тәкъдиме белән кибеттән төрле бүләкләр алып, авылның әбиләренә, бабайларына өләшергә булдык. Киттек кибеткә. Сатып алдык бик матур чәчәкле ситсылар, яулыклар, ирләр күлмәкләре. Авыл Советына кереп картларның исемлекләрен алдык та исемлек буенча шул әбиләргә, бабайларга өләштек. Безгә бик зур рәхмәт әйттеләр. Безнең үзебезнең дә күңелебез булды. Кайттык Казанга. Берничә көн үткәч, безне Финанс министрлыгына чакыралар. Ул елларда, хәтерем ялгышмаса, Әюпов фамилияле кеше министр иде. Без дәүләт акчасын үзләштерүдә гаепләнәбез икән... Безнең администраторыбыз Якупов филармония бухгалтериясенә отчет биргән чакта, теге авылның мәктәбеннән җыелган 160 сумны да отчетка керткән. Шулай итеп, 160 сумлык документ отчетка теркәлгән, ә акчасы филармониягә кайтмаган. Кая киткән?.. Артистлар үзләштергән килеп чыга. Безнең һәркайсыбыздан 35 әр сум акчаны тотып калырга җыеналар. Ул чакта 35 сум акча байтак акча иде. Кайсы артистның үз хезмәт хакыннан 35 сумны чыгарып бирәсе килсен? Әби-бабайларга биргән бүләгебез менә нәрсә китереп чыгара. «Бу Якуповны башка бервакытта да бригаданың җитәкчесе – администратор итеп алып чыгарга ярамый», – дидем мин. Нишләргә? Бу гаделсезлеккә риза булып, шул 35әр сумны бирергәме? Фәйзи абый шул чакта әйтте:

– Әйдәгез, балалар, түлик филармония кассасына шул 160 сум акчаны, финанс министры хатынына ыштан алып кидерсен!..

Фәйзи абый еш кына концертта кызыклы репликалар әйтә иде. Күп вакыт репликаларын үз тормышыннан уйлап чыгара иде. Шуларның берсе аерата истә калган: кесәсеннән бер язу ала да, Фәйзи абый болай дип сөйләп китә:

– Менә тамашачылар язу җибәргән: «Фәйзи абый, хатының бармы? Исеме ничек? Ничек танышкан идегез, ничек яшисез?..» – дигәннәр. – Хатыным бар, Максума исемле (Мәгъсүмә исемен шулай мишәрчәләтеп әйтә). Максума

апагыз белән яшь чакта бик матур таныштык та, шактый вакыт сердәшләр булып йөрдек. Аннары өйләнештек тә, гашыйклар булып яшәдек. 2 ел куендаш булдык. 10 ел яндаш булдык. Аннары кордашлар булып киттек. Олыгая башлагач, аркадашларга әйләндек. Арканы аркага терәп йоклыйбыз. Аннары фатирдашларга әйләндек. Бер фатирда яшибез, арка терәшүләр дә бетте, икебез ике караватта йоклыйбыз. Хәзер инде икебез ике караватта гына түгел, икебез ике бүлмәдә яши башладык. Чөнки Максума апагыз яшь чакта җырлый иде, хәзер инде хырлый...

Фәйзи абый менә шундый юморист. Юк кына мәзәк сөйләп тә тамашачыны көлдерә алу барлык артистларның да көченнән килми. Фәйзи абый – бу яктан бәхетле артист. Ул, гомумән, бәхетле кеше. Озын гомерле булуы белән дә бәхетле Фәйзи абый. Үзе дә шулай ди. Әле гөрләтеп 80 яшьлеген билгеләп үтте, зур программалы матур концерт белән тамашачыларны шатландырды. Үзенең репертуарындагы иң кызыклы әсәрләрен сөйләп, сәхнәнең түрендә булды, егетләрчә дәртләнеп чыгышлар ясады. Сәхнәдәш дуслары, замандашлары, яшь артистлар кайнар котлап, Фәйзи абыйга озын гомер, сәламәтлек, бәхет теләделәр. Әйе, бәхетле картлык кичерә Фәйзи абыебыз. Әле 1994 елның 7 маенда чыккан «Татарстан хәбәрләре» газетасында биргән интервьюсында Фәйзи абый болай ди: «Бик бәхетлемен, сеңелем. Бәхетем минем бер генә дә түгел. Беренчесе – халкым мине үз итте. Кая барсам да: «Безнең Фәйзи абый», – дип кенә йөрттеләр. Алкышлап каршы алдылар да, кул чабып озаттылар. Артист өчен моннан да зур бәхетнең булуы мөмкинме?! Икенче бәхетем – хатыннан уңдым. Мәгъсүмә апаң үзем белән канлы сугыш кырларын үткән, 51 нче армиянең баш хирургы булган кеше иде. Быел алтын туйга әзерләнгән чакта мәрхүмә булды. Ирләргә ялгыз тору бик авыр, сеңелем, шуңа күрә кабат өйләндем. Аллага шөкер, бу хатыным – Рәшидә ханым да бик ипле, бик тату торабыз». Менә күрдегезме, Фәйзи абый 80 яшен тутыргач, өйләнеп куйды, яшь кияү булды!.. Молодец, Фәйзи абый, димичә, нәрсә әйтәсең инде аңар!.. Үзе әйтмешли (сәхнәдә сүз иярә сүз чыгарып, гел шулай ди торган иде ул), бал бозылмый, артист картаймый!..

Фәйзи абый Йосыповның Фәйзиләр турындагы такмазасының бер Фәйзие – Фәйзи Биккинин турында да берничә сүз язасым килә. Фәйзи абый Биккинин инде олы яшьтә – җитмешкә җитеп килә иде, мин аны бервакыт үзем белән гастрольгә чыгарга чакырдым. «Фәйзи абый, әйдә әле, авылларда йөреп кайтыйк, бик күңелле булыр, Сез үзегезнең гармуннарыгызда уйнарсыз, авыл җирләрендә гармунны бик яраталар», – димен. Фәйзи абый ялындыра: «И, Әлфия, бик чыгар идем дә, тешләрем юк, ризык та чәйни алмыйм, ризыкны чәйнәми йоткач, ашказаным авырта», – ди бу. «И, Фәйзи абый, кайгырма, алдыңа менеп утырып, чәйнәп-чәйнәп ашатырмын!» – дим. Рәхәтләнеп көлде бу. Алай дисәң, чыгам алайса, киттек, ди бу. Чыгып киттек, авылларда йөрибез. Фәйзи абый рәхәтләнеп йөри, тешләре булмаса да, рәхәтләнеп та-

вык итләре белән сыйлана. Хәтта яшьрәк апаларга күзе дә төшкәли, тәмам үзенең җитмешкә җитеп килүен онытты бу. Гомумән, бик кызык кеше иде, мәрхүмкәем Фәйзи абый. Бервакыт берничә кеше Мәскәүгә Сара Садыйкова ижатына багышланган концертка барырга җыенганнар. Бу эшне Гөлшат Зәйнашева башлап йөргән. Фәйзи абыйны чакырырга өенә барган. Фәйзи абый, баш бармагын марля белән урап алган да, Гөлшатка болай ди икән:

– Бик барыр идем дә, менә бармагым авырта әле, гармунда уйный алмыйм...

Гөлшат Зәйнашева бик нәүмиз булып чыгып киткән Фәйзи абый яныннан. Сара апа әйтә икән:

– Фәйзинең шундый гадәте бар инде аның, концертка барасы килмәсә, бармагын марля белән урап куя да, бармагым авырта шул, гармунымда уйный алмыйм, ди. Хәйләлидер, карт төлке, ди.

Мәскәүгә барып бик матур концерт куеп кайталар болар. Казанга кайткач, Илһам Шакиров филармония коридорында Фәйзи абыйны очрата да, болай ди:

– Фәйзи абый, юкка бармадыгыз Сез Мәскәүгә. Бөтен Мәскәү татары Сезне көткән. Нигә Фәйзи Биккининны алып килмәдегез, диләр. «Фәйзи Биккинин! Фәйзи Биккинин!» – дип, аягүрә басып кул чабып, Сезне таләп итәләр. Мәскәүнең бер зур мәйданына Фәйзи Биккинин исеме бирергә, Фәйзи Биккинингa һәйкәл куярга җыенабыз, диләр. Ә Сез концертка бармадыгыз!.. Яхшы түгел!..

Беркатлы холкы белән Фәйзи абый түзмәгән, үзенең хәйләләп бармый калуын әйтеп ташлаган.

– И-и, әйтсәм-әйтим инде, авыртмый иде лә ул бармак!.. Хәйләләп кенә марля белән ураган ием... Юкка бармаганмын, каһәре!..

Бервакыт язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында концерт бирергә тиеш идек. Фәйзи абый белән бергә Бауман урамындагы Матбугат йортына килеп җиттек. Клуб бишенче катта ук. Фәйзи абый ишек төбендә туктады да:

– Бишенче катка менә алмыйм! Бигрәк биек! – ди.

– Әйдә, Фәйзи абый, гармуннарыңны үзем алып менәм, әкрен генә мен, – дим, гармуннар тутырган тартмасын күтәреп. – Минем эзгә басып менсәң, сизми дә калырсың, – дим, аңа елмаеп карап.

– Синең шулай елмаеп карап чакыруыңнан соң, синең эзләреңә басып, бишенче түгел, унбишенче катка менәм! – ди бу. – Менде!.. Йөгерә-йөгерә менде минем артымнан!..

Тәмле телле иде Фәйзи абый Биккинин. «Пылау өстендәге җимеш син!» – ди торган иде ул яшьрәк хатын-кызларга. Миңа инде: «Пылау өстендәге кара җимешем!» – ди торган иде, мәрхүмкәем.

Тагын бер танылган нәфис сүз остасы – Татарстанның атказанган артис-

ты Әзәл абый Яһудин да берничә ел буена безнең концертларыбызны алып барды. Әле Актанышта балачагымда ук: «Син, сеңелем, җырчы артистка булырга тиешсең», – дигән Әзәл абый, ниһаять, – минем җырчы артистка булып сәхнәләрдә концертларым барганда, үзе үк концертны алып баручы конферансье. Фәйзи абый кебек үк, Әзәл абый да концертларны күңелле итеп, күтәренке рухта алып бара иде. Ул да җитди әсәрләр сөйләп, тамашачыны уйландыра, шул ук вакытта күп кенә көлкеле әсәрләр сөйләп, тамашачыны көлдерә, дәртләндерә. Безнең бригада артистлары Әзәл абый Яһудин белән дә дус, тату эшләделәр. Әлбәттә, аның белән дә шаяралар иде. Ул бездән олы яшьтә дип тормыйлар, аны төрлечә көлкегә калдырырга тырышып, төрле шуклыклар уйлап чыгаралар иде.

Әзәл абый бер дә авырмый, таза, сау-сәламәт кеше. Концертларны алып барганда таләпчән, сәхнәгә соңга калып чыгучыларны бер дә яратмый. Сәхнәгә соңга калып чыккан музыкантларны ачулана. Әлбәттә, үзе бервакытта да соңга калмый, бик төгәл. Музыкант егетләр ачуланганны яратмыйлар, ачуланган Әзәл абыйга каршы берәр шуклык уйлап чыгаралар. Кайвакыт озак гастрольләрдә йөреп, барыбыз да арыйбыз. Музыкант егетләрнең аруы чиктән аша. Вакыт узсын дип, концерт барышында үзләре сәхнәгә чыкмаган арада йә карта уйныйлар, йә анекдот сөйләшәләр, үзләренчә ял итәләр.

Әзәл абый сәхнәдә үзенең номерларын башкарганда, сәхнә артында егетләрнең шулай шаулашуына кәефе китә, сәхнә артына чыгып: «Базар ясамагыз, егетләр, миңа сөйләргә бирмисез!» – дип ачулана. Егетләр, бигрәк тә җәйге эссе көннәрдә, Әзәл абый сөйләгән арада шауламас өчен, ишек алдына ук чыгып китәләр, тәмәке тарталар. Әзәл абый аларның шулай урамга ук чыгып китүләрен дә яратмый иде. Алар башкарасы номерны әйтү белән сәхнәгә чыкмасалар: «Урамга ук чыгып китмәгез, мин сезне эзләп урамга чыга алмыйм бит», – дип ачулана. Егетләр аңар: «Әзәл абый, урамга чыкмыйча булмый бит, сәхнә артында туалет юк, нишләргә кушасыз?» – ди. Әзәл абый: «Концерт вакытында нинди туалет ул!» – ди. Егетләр аптырый, чөнки Әзәл абый концерт ничә сәгать барса да, кая ул туалетка бару, сәхнә тирәсеннән беркая китми. «Ну, таза да соң бу Әзәл абый!» – диләр. Берәр этлек уйлап чыгарып шаярырга булалар һәм табалар да бит!.. Әзәл абыйның ашына үзе күрмәгән арада эчне җибәрә торган порошок салалар. Бер көнне салалар порошокны, Әзәл абый сәхнәдән беркая чыгып китмичә, икешәр сәгать концертны алып бара. Икенче көнне салалар порошокны, юк, Әзәл абый бирешми. Өченче көнне бер пакет түгел, 2-3 пакет порошок җибәрәләр моның ашына. Алай да Әзәл абый туалет эзләп, сәхнәне ташлап чыгып йөгерми, үз постын ташлап беркая китми. «И-и, бу Әзәл абыйның ашказаны, эчәкләре тимердер», – дигән нәтиҗәгә килеп, егетләр Әзәл абый белән шаяруларыннан туктыйлар. Әзәл абый менә шундый таза, сау-сәламәт кеше. Күз тимәсен, хәзер дә әле бирешми, дөбердәтеп йөри, концертларга да катнаша.



1959 ел

...60–70 нче еллар – күңелдә мәхәббәтнең шау чәчәк аткан иң дәртле еллары булгандыр. Юсыф белән үткәргән бәхетле чакларның иң матур хатирәләре искә төшеп, үзәкләр өзелеп куя. Бергәләп минем туган якларыма – Актанышка кайта идек. Агыйдел буенда су коенулар, кояшта кызынулар, Агыйдел табигатенең хозурлыгында ял итүләр... төштә күргән кебек кенә булып узганнар да киткәннәр. Актаныштагы дус-ишләр, белгән-күргәннәр барысы да безне өйләнешәчәк парлар, диеп уйлыйлар иде. Безнең Актанышта бер Сания апа бар иде. Карта ачып, язмышыңны юрый иде. Күп вакыт туры китерә торган иде бит шул Сания апа. Мәрхүмәкәемә әллә Аллаһы Тәгалә хәбәр биреп торган, хәтта югалган әйберләренә карта ачтыручылар да Сания апага рәхмәтләр әйтә иде. Чөнки югалган әйберләренең кайда икәнлеген дөп-дөрес әйтә иде бит. Берәүләрнең үсеп хәйран зураеп килгән бер оя каз бәбкәләре югала. Бер атналап эзлиләр, һич таба алмыйлар. Эзләмәгән басу, эзләмәгән су буе калмый. Санияга киләләр. Сания картасын ача да әйтә: каз бәбкәләрегез Агыйделнең аръягында бер утрауда, ди. Ул әйткән утрауга баралар, чынлап та казлар шунда... Аллаһы Тәгалә әйтә микән, әллә җеннәре өйрәтә микән моны, дип шаккаталар Санияга.

Тормышы авыр, өс-башы начар, бер күлмәкне еллар буена алыштырмыйча киеп йөри торган иде, мәрхүмәкәем. Мунчага барса, шул бер үк күлмәген киеп кайта, бер барганда уң ягы белән, икенче барганда сул ягын әйләндереп кия. Мин кайткан саен аңар берәр күчтәнәч алып кайта идем, берәр яулык-мазар, халат-фәлән алып кайтып бирсәң, шатлыктан йөгереп йөри иде, бичаракай. Куана-куана карта ача иде. Әлбәттә, Актаныш буйлап Юсыф белән бергә йөргәнне күрә, аның өенә дә Юсыф белән бергә бара идек. Безгә бик серле итеп елмаеп карый да, карталарына карап, сакау теле белән (теле, ничектер, авызына сыймыйча, сөйләгәндә бөкләнеп-бөкләнеп китә кебек иде) болай ди: «Апаем (бездә үзеңнән кечеләргә яратып шулай «апаем» диләр), бик матулл белл илл бала табасың әле... Дәп-дәңгәл күдле... ап-ак чылайлы... илл бала...» Янымда зәңгәр күзле, ап-ак чырайлы Юсыф басып торгач, шулай дими нәрсә дисен инде? И Сания апа, Сания апа, күңелең изге, теләгең матур булган да бит... зәңгәр күзле малай тумады шул бу дөньяга... Язмышлар син дигәнчә дә, мин дигәнчә дә язылмаган булып чыкты шул...

Ничәнче ел булгандыр, язгы май ае. Мин яңа җыр өйрәнәм. Тышта яшенләп килгән язгы яңгыр ява, күңелдә яшенле мәхәббәт. Дөньяда иң матур, иң сөйкемле, иң уңган кеше Юсыфка мәхәббәт!.. Җырым да яз турында.

Язгы яңгыр яуган чакта,
Тамчы буласым килә,
Тамчы булып, керфегеңә
Тамып кунасым килә!..



Наил Хәсәнов, Кәрим Габидуллин, Әлфия Авзалова, Анатолий Ведерников, Игорь Иванов. 1976 ел

Соңарып килгән чын мәхәббәтемне сүзләр белән түгел, әлеге җыр белән дә аңлата алмый идем бугай.

Язын сирень чәчәк аткач,
Сирень буласым килә.
Сирень чәчәкләрен өзеп,
Сиңа бирәсем килә.

Репертуарымдагы җырлар минем йөрәгемдәге иң газиз, иң изге, иң саф хисләремә туры килә иде.

Мәхәббәт җырлары, минемчә, тыңлаучыларның да иң саф хисләренә туры килә. Күпме мәхәббәт җырлары җырладым мин үз гомеремдә!.. Мәхәббәт җырлары минем чын мәхәббәтемнең йөрәгемнән ярсып, давыллап, ташып чыккан кайтавазы иде.

Юсыфка булган бу зур мәхәббәтем минем сәхнәдәге эшчәнлегемә дәрт өстәп торучы бер ялкынлы учак иде. Бу учак озак еллар минем күңелемне җылытты, яктыртты.

Бу ялкынлы учак турында язгач, менә шушы урында Әлфия апагыз үз язмышында булып алган тагын бер четерекле вакыйганы искә төшереп язып китмәкче. Юсыфны үлеп яраткан килеш... бары тик аны гына уйлаган башым белән мин икенче берәүне яратырга, язмышымны аның белән бәйләргә омтылып карадым. Бу инде Юсыф белән бергә була алмаячагыбызны аңлагач,

Юсыфны онытырга тырышу, ялгызлыктан котылып, гаилә корырга омтылу иде. Яратырга тырышып танышкан кешемә булган ул хисләр Юсыфка булган кебек утлы, ялкынлы, яшенле, давыллы хисләр түгел, акыл белән уйлап, алдын-артын үлчәп атлаган адым булгандыр.

Мине концертларда күреп, күзләп йөргән Монголиядә хезмәт итүче бер хәрби кеше (анысының да исемен тулысы белән язмыйм) – Г., танышыйк, дип миңа хат язган иде. Бервакыт аңардан телеграмма килеп төште: «Каршы ал, Казанга кайтам!» – дигән. Мин үзем Юсыфны яратам, аны гына уйлыйм, үзем аңардан «котылмакчы», күңелне башкага тапшырмакчы.

Дустым Гөлсинә белән киттек аэропортка. Үзем куркам, үземнең шул кеше белән күрешеп танышасым килә. И, бу адәм баласының күңеле!.. Ниләр генә кичерми?.. Туп-туры юлдан гына бармый кеше язмышы, кеше язмышының юллары бормалы-бормалы, әллә нинди чытырманнар арасына кереп китә язмыш юллары... Эчемнән генә уйлыйм: Юсыф белән барыбер бергә була алмыйбыз; бәлки, бу кеше мине аңардан «коткарыр»; бәлки, бу кеше минем язмышымдыр, бәлки, без бергә булып, бик бәхетле яшәрбез... Бәлки, яратып китәрмен, ул да мине яратыр... Менә самолеттан кулына зур чемодан тоткан озын буйлы, хәрби киемле бер кеше төште. Елмаеп безгә таба килә... Хәрби фуражка-



Юсыф Вәлитов белән.
1970 ел



Юсыф Вәлитов белән. 1969 ел

сы астыннан кара бөдрә чәчләре күренә, һушыңны алырлык чибәр, сөйкемле майор. Ул шундук мине танып, яныбызга килде. Таныштык, сөйләштек, миңа бик ошый, яратырмын шикелле. Безгә кайттык. Мин инде Юсыф белән араны өзәргә булдым. Г.га барысы турысында да дөресен сөйләп бирдем. Г. мине дөрес аңлады, киләчәктә бергә булырга вәгъдәләр биреште к. Г. ялгыз иде, хатыны белән аерылышкан. Шунысын да әйтергә кирәк: Юсыф соңгы вакытларда миңа тупасрак була башлады. Уйламаганда, миннән качып-посып башка хатын-кызлар белән дә очрашуын белдем. Ул, әлбәттә, минем белән араны өзәргә тели кебек күренми, шулай да сизенәм, күңеле уйный башлады моның. Бәйрәмнәр каршы алганда юкка чыга. Бик күп бәйрәмнәрне бергә каршы ала идек, ул эчү белән артык мавыкмый, мине дә эчүле мәҗлесләргә алып бармый иде. Соңгы вакытларда мин аны әзрәк төшергән килеш күрә башладым.

Бу көннәрдә минем Җыракай балаларны иәртеп Актанышка кайтып киткән иде. Җәйләрен алар шулай Актанышка кайтырга яраталар. Өйдә Г. белән икебез генә калырга уңайсызланып, Гөлсинәгә китмәскә кушып, үзебездә калдырдым. Сөйләшәбез, серләшәбез. Г. алып кайткан күчтәнәчләр белән сыйланабыз. Күңелле. Ләкин минем җан тыныч түгел. Ут эчендә янам, көям, менә хәзер ишектә кыңгырау шалтырар да Юсыф килеп керер кебек. Ул бит мине гел килеп ала, китереп куя торган иде. Бу хәрби кеше ул турыда уйламый да, үзен иркен тота. Мин куркам. Ахры, бер карарга килдем: Гөлсинәләргә киттек. Ул тулай тораКта аерым бүлмәдә яши иде. Өч бүлмәле зур квартирада Г. белән икәү генә калырга мөмкин түгел. Юл буе уйлап ба-

рам, үземне-үзем үгетлим, Юсыф өйләнсен, балалар үстерсен, аңа юл бирим... дим. Йөрәк бит моны аңламый, дөп-дөп тибеп, һаман Юсыфны ярата... Гөлсинәләрдән үз өемә кайтып керсәк, ишектә зур язу: «Кайда йөрисең, телефоныңны да алмыйсың. Бик озак көтеп ишек төбендә тордым. Иртәгә өйдә бул, мин машинам белән керәм, безнең дачага китәбез. Әниләр көтә...» Г. аптырап карап тора. Мин, әлбәттә, бу язуны үзем генә укып кесәмә бөгәрләп тыктым. Г.га белдермәдем. Г. мине үзләренә, Әгерҗе районының Салагыш авылына кунакка кайтырга өнди башлады. Нишләргә? Ни булса, шул булыр, Аллага тапшырдым, дидем дә, аларга кунакка кайтырга булдым.

Матур итеп киенеп, парлашып чыгып киттек Елга портына билетка. Г. белән култыклашып барабыз, мин як-якка каранам, күңелем сизә, Юсыф килеп чыгар кебек. Күңелем дөрес сизгән, Г. белән без такси тоткан чакта – каршыбызда Юсыфның машинасы. Башын машина тәрәзәсе аша чыгарган да шаккатып безгә караган. Мин аңар бармагым белән генә ымлап: «Тсс!» – дидем. Бу ымлавым Г. алдында бер сүз дә әйтмә, дигәнне аңлата иде. Юсыф, агарынып, бер сүз дә әйтә алмыйча, башын шулай тәрәзә аша сузып карап калды, әллә һушын җуйды, әллә аптыраудан сүз таба алмады. Мин Юсыф артыбыздан килмиме дип, гел артка карый-карый барам. Г. белән ашыгып портка киттек, кассирдан ялынып-ялварып ике урынлы люкска билет алдык. Кайтып әйберләрне җыйнарга да тизрәк китәргә дип өйгә кайтсак, тагын ишектә язу: «Әлфия, нинди кеше ул синең белән? Нишләдең син? Минем һушым китте, айный алмыйм. Сине бит филармониядә көтәләр, килергә куштылар...» Хәерле булсын дип, Әгерҗе якларына китеп бардык. Билетыбыз Красный Бор пристанена кадәр. Пароходта барулар шундый күңелле, Г. белән пароход палубасына чыгып, дулкыннарга карап сөйләшеп барабыз. Г. сөйләшергә ярата, сүзе мәгънәле, җитди. Шул ук вакытта шаян сүзләр дә сөйләп куя. Көлешәбез, бер кайгыбыз да юк кебек. Әмма ләкин минем башым тулы уй, кайгы... Бердән, ничек чыгып киттем соң әле, дип борчылам... Икенчедән, кая барам, кемнәр каршы алыр, ничек каршы алырлар, дип уйлыйм... Өченчедән, Юсыф нишли икән?.. Мине тагын эзләп килде микән?.. Бу хәлләрне белсә, нишләр?.. Башым тулы уй, уй... Пристаньга безне ике җиңел машина белән каршы алырга төшкәннәр иде. Каршы алучыларга Г.: «Әлфия безгә кунакка кайтты, әллә нәрсә уйламагыз, кунак кызы ул», – диде. Г.ның туганнары бик күңелле, шаяннар икән, берсе әйтеп куйды: «Кунак кызы, бәлки, безнең киленебез дә булып куяр әле, Алла боерса! Вәгъдәләшкән кыз белән егеткә охшыйсыз!..» – диде. Салагыш дөньяда иң матур авылдыр, концертлар белән дә килгәнем бар иде, бу юлы бигрәк тә матур күренде. Г.ның әти-әниләре зур, матур йортта торалар. Тормышлары нык, таза. Үзләре бик тырышлар. Йортларының ныклыгы, чисталыгы бу карт белән карчыкның чын хезмәт кешеләре икәнен күрсәтеп тора. Үзләре бик ягымлы, кунакчыл. Уенын-чынын бер итеп, миңа: «Киленебез бул, Әлфия!» – диләр. Минем артистка бу-

луыма каршы түгеллекләрен дә сиздерәләр. Без Г. белән вәгъдәләшкән кыз белән егет кебек, Салагышта унбиш көн кунак булдык. Яратышабыз да шикелле. Г. мине бик ярата кебек. Мин генә Юсыфны уйлап эчтән янам, сызам... Ник бу адымны атладым, дип үкенеп тә куям... Китәр вакыт җитте. Г. Ерак Көнчыгышка китәчәк. Казанга кайттык. Җыракай балаларны иярtеп Казанга кайткан, Г. белән безне шаккатып каршы алды. Балалар да: «Бу нинди абый?» – дип, Г.ны күзәтәләр. Җыракаем мине икенче бүлмәгә чакырып алды да:

– Бу кем? Нишләп йөрисез болай агылый-тагылый? – дип кыздыра башлады.

– Кунак... Якташ... – дим.

Апам кыздыруын дәвам итә:

– Нишләп йөрисең Юсыфны ташлап?.. Бөтен Казанны күтәрде бит! Кеше баласын харап итәрсең... Килә дә җылап утыра... Ябыгып бетте. Сине эзләп иптәш егетләре белән әллә ничә поездны каршы алганнар... Елга портына төшеп кенә белгән... Синең фотокарточкаңны күрсәтеп, кассирдан сораган, бу Әлфия Авзалова, сездән ике билет алмадымы дигән, кассир, «алды» дигәч, качып киткәндәй киткәнеңне аңлаган...

Кызым Зөлфиягә ул чакта дүрт яшьләр чамасы иде. Зөлфия урамда уйнап йөргәндә, янына Юсыф абыйсы килеп туктый.

– Зөлфия, әниең кайттымы әле? Бар, кайтса, чакырып чыгар, Юсыф абый көтә дип әйт, – ди. Кызым Зөлфия Г. ишетмәслек итеп пышылдап кына әйтте: балакаем, кечкенә булса да мондый сүзләрне кычкырып әйтергә ярамаганын аңлый иде бугай. Мин Юсыф янына чыгарга куркам. Коридор тәрәзәсен ачып карасам, күрәм, Юсыф ябыккан, куллары неп-нечкә булып машина тәрәзәсеннән салынып төшкән. Җәлләдем үзен. Йөрәгем чеметеп-чеметеп куйды. Ярты үлдем. Янына курка-курка киләм. Сөйләшәбез.

– Нишләдең син? Шул кешегә кияүгә чыктыңмы әллә? – ди бу, еларга җитеп.

– Юк, юк, – дим мин, – ике көннән китә ул, ул киткәч, барысын да сөйләшербез, аңлашырбыз, – дим.

Г. китәргә ике көн калган иде, бу ике көн ике ел кебек тоелды. Юсыф бертуктаусыз телефоннан шалтырата. Машинасын безнең өй турысына – минем тәрәзәм астына куеп, иптәш егете белән төн кундылар... Г. сизенде, ләкин бер сүз әйтми, ул да аптырагандыр инде. Шулай да киткәндә әйтте:

– Әлфия, ни генә булса да, мин сине көтәм... Чыкма берәүгә дә... Көт мине... Бергә булырбыз... – диде.

Мин дә, үз-үземне җиңеп, аңа, вәгъдәмдә торырмын, дидем. Ләкин бу вәгъдәне үтәү мөмкин түгел иде. Г. китеп бер сәгать тә үтмәде, Юсыф машинасына әнисен, әбисен утыртып, безгә килде. Мине өйдән чакырып чыгардылар, машинага утырырга куштылар. Кереп утырдым машинага. Әнисе, әбисе мине ачуланалар:

– Нәрсә эшләдең син, Әлфия?.. – диләр. – Шулай ярыймыни инде? Малайны харап итә яздың бит!

Юсыф машинасының руленә ятып елый-елый мине яратуын сөйли.

Мин үземне кулга алдым, мондый җавап бирдем:

– Юсыф соңгы вакытларда миңа тупас дәшә... Мине санга сукмый башлады. Мине яратмый икән, дип уйладым... Араны өзим, дидем, өйләнсен, гаилә корсын, дидем...

Г. белән без Салагышка киткән көнне Юсыф үзен кая куярга белми йөри, Гөлшатларга килә. Гөлшатны урамга чакырып чыгара да машинасына утыртып, бер сәгать зарлана: «Неужели Әлфия мине ташлап, шул кешегә чыга? Неужели ул мине яратмаган? Нигә сез, дуслары, аңа әйтмәдегез? Шулай итеп миннән көләргә ничек башына килгән аның?» – дип елый-елый сөйли икән. Гөлшат аңар болай дигән:

– Сез бит барыбер өйләнешеп бергә була алмыйсыз... Әлфия шуны аңлап, белеп, үз язмышын үзе хәл итәргә булгандыр... Безнең белән киңәшмәде ул, без дә белми дә калдык... Бәлки, шул хәрби кеше белән бергә булып, бәхетле яшәп китәрләр...

Юсыфның бу сүзләргә җен ачулары чыга. «Юк, юк, аның кем беләндер бәхетле булуы мөмкин түгел!..» Әйе, Юсыф дөрес әйтә, минем Юсыфтан башка кем беләндер бәхетле булуым мөмкин түгел һәм мин Г. белән арамны өздем, хат язудан да туктадым. Вәгъдә – иман диләр дә бит, бу очракта мин вәгъдәмне бозуны гөнаһка санамадым, чөнки яратырга тырышып кына яратып булмасын аңладым. Бу минем өчен сабак булды.

Юсыф белән элеккечә очрашуыбызны дәвам иттек. Мәхәббәтебез сүнмәгән, сүрелмәгән, киресенчә, зур сынау аша үткәндәй, көчәйгән генә иде. Әйе, зур сынау уздырдык. Мәхәббәтебездән ваз кичсәм, икебез ике якка китәрбез кебек иде. Юк, чын, олы мәхәббәттән ваз кичеп булмый икән.

...Минем концерт бригадамда күп кенә ир-егет җырчылар антураж сыйфатында эшләп чыктылар. Әле яшь җырчы чакларында, хәзер инде танылган җырчылар Хәнәви Шәйдуллин, Габделхак Шаһиев, Илгиз Мәҗитов, Булат Балтанов, Миңхәмәт Гыйлажев һ.б.лар белән шактый еллар бергә эшләдем. Дус, тату эшләдек, бер-беребезгә ярдәмләшеп, гастрольләрдә туганнарча йөрдек, Хәнәви матур җырлавы белән үзе дә халкыбызның яраткан җырчысы булып китте, Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исем алды. Илгиз Мәҗитов – татар сәнгатенең, танылган эшлеклесе. Ул халык арасында популярлашкан «Ак каеннар шаулый болында», «Урман юлында» кебек матур-матур җырлар язып, композитор булып китте. Мәскәүдә ГИТИС тәмамлап кайтып, режиссер буларак, опера театрында күп кенә операларны, музыкаль комедияләрне сәхнәгә куйды. Озак еллар безнең филармониядә художество җитәкчесе булып эшләде. Миңхәмәт тә сәхнәдә үз юлын табып килә. Миңхәмәт консерватория бетергән җырчы буларак, еш кына миңа



«Казан утлары» ансамбле Хәнәви Шәйдуллин белән. 1982 ел



«Казан утлары» ансамбле Миңхәмәт Гыйлажев белән. 1984 ел

ярдәм йөзеннән гаммалар җырлата иде. Клубларга килеп кергәч, әйбәтрәк көйләнгән пианино күрсә, Миңхәмәт:

– Әлфия апа, килегез әле, әзрәк гамма җырлап, тавышны ачып алыйк, – дия иде.

Хәзер минем бригадамда җырчы Рөстәм Маликов эшли. Рөстәмнең тавышы яхшы, халык аның җырлавын җылы кабул итә.

Ул Казан консерваториясен тәмамлап, берничә ел Уфада эшләп, Башкортстанның атказанган артисты дигән мактаулы исем алып, Татарстанга кайткан җырчы. Башкортстанда ул яхшы эшләп, бик нык үскән, тавышы дөрес итеп, әйбәт куелган, репертуарын баетып тора. «Салават» операсыннан Салават ариясен җырлап җибәрсә, тамашачылар сокланып тыңлыйлар. Шул ук вакытта ул татар халык көйләрен дә оста башкара.

Шулай ук минем эстрада коллективым составында күп кенә биючеләр эшләп китте. Кайберләре безнең коллективтан пенсиягә чыкты. Бик матур биюе белән халык күңелен яулаган Фәйтүнә Абдуллина, балеттан эстрадага килгән бик сөйкемле ханым Роза Смирновалар, зур хезмәт хакы алып эшләп, әйбәт итеп пенсиягә киттеләр. Яшьләрдән берничә ел безнең бригадада Гүзәл Вафина (Гаязова) биеде. Хәзер ул да – танылган биюче, Татарстанның атказанган артисткасы. Танылган артистлар Әнвәр Латыйпов белән Нәҗия Минкинаның кызы Гүзәл Латыйпова безнең коллективта беренче адымнарын атлап биеп китте.

Үзең белән бергә озак еллар эшләгән кешеләрнең сәнгатьтә үз юлларын табып, үсеп китүләрен, халыкта танылуларын күрү бик күңелле. Мин якташым Хәнәви, шулай ук Илгиз, Миңхәмәт, Гүзәлләр өчен, аларның уңышлары өчен куанам.

Сәхнәдә тар күңелле булырга ярамый. Бигрәк тә үзең белән бергә эшләүче артистларга киң күңелле, ярдәмчел булырга кирәк. Мин үзем белән бергә эшләүче артистларга кулдан килгәнчә ярдәм итәм. Тавыш кую, сәхнәдә үзүзеңне тоту, җырлаганда ачык дикция белән җырлау кебек күнекмәләр ясап, яшьләргә киңәшләремне бирәм. Минем бригадада эшләп киткән артистларның берсе дә Әлфия апа ярдәмчел түгел, дип әйтмәсләр дип уйлыйм. Күбесе миңа рәхмәтләр әйтә.

Миңа рәхмәтле кешеләрнең берсе турында язасым килә. Ул – нәфис сүз остасы Рәшит Сабиров. 1976 ел иде. Яңа гына театр училищесын тәмамлаган яшь егет Рәшит безнең бригадага сөйләүче булып килде. Ябык кына егет. Өс-башы да начар. Күренеп тора, авырлык белән укыган. Зеленодольск районында туып-үскән. Әти-әниләре олы яшьтәге кешеләр икән. Әллә ни ярдәм итеп укыта алмаганнардыр. Мин аны беренче күрүдә үк ошаттым. Бу егетнең киләчәге булыр, сәхнәдә эшләп менә дигән сөйләүче булып китәр дип, аңа сәхнәдәге беренче адымнарыннан ук ышандым. Иң элек без аның белән болай сөйләштек. Мин әйтәм, энекәш, синең тавыш бик нечкә икән, беренче



Рәшит Сабиров белән. 1980 ел

чыгышларыңнан ук тыңлап торам, мондый нечкә тенор тавышлы җырчы булсаң, ярый, ә инде сөйләүче өчен нечкә тенор тавыш уңышлы түгел. Әйдә синең тавышны күкрәккә куеп, Фәйзи абыйларныкы шикелле баритонга – калын тавышка күчерик, дим. Калын тавыш белән сөйләтеп карыйм. Калын тавыш белән дә матур гына сөйли бу. Күнегүләр ясыйбыз, тиз арада калын тавыш белән сөйләп китте егетем. Үзенә дә ошый икән калын тавыш. Шулай итеп тавышын куйдык. Аннары мин аның сәхнә костюмнары, түфлиләре турында кайгырта башладым. Бергәләп аңа әйбәт кенә костюм, түфлиләр алдык. Аннары кышкы салкыннарда бик юка гына иске пальто белән йөри иде, гастрольләребез гел авылларда, кышкы буранларда, егет туңа. Чаллыда бер складка кердем дә, мөдире белән сөйләшеп, Рәшиткә бер тун сатып алып бирдем. Милиционерлар өчен тегелгән ак кайры тун иде бу. Билле итеп тегелгән шушы тунны Рәшит бик озак еллар рәхәтләнеп киде. Миңа рәхмәтләрен әйтеп бетерә алмый иде. Шулай итеп егетем безнең бригадада әйбәт кенә эшләп китте. Берничә елдан инде ул танылган нәфис сүз остасы булып, халыкның яраткан артистына әверелде. Атказанган исемен дә, хәзер инде халык артисты дигән исемен дә алды. Кайсы гына бригада составында эшләмәсен, репертуарын гел яңартып тора, сатирик әсәрләр сөйләп, концертларны күңелле итеп

алып бара. Бенефис концертларымда катнашып, ул шулай үзенең сәхнәдәге беренче адымнарында күрсәткән яхшылыкларым турында тамашачылар алдында сөйләп, миңа рәхмәтләр әйтте. Эшләгән яхшылыкларымны онытмый ул. Әле Г. Тукай исемендәге бүләккә кандидат итик, дип тә фамилиямне филармония җыелышында иң элек Рәшит торып әйтте.

Безнең бригадада шулай сөйләүче булып та күпләр эшләп китте. Хатын-кыз нәфис сүз осталарыннан – Диләрә Ильясова, Әлифә Вәлиева, Зәйтүнә Яруллиналар безнең бригадада матур гына эшләп чыктылар. Бүген инде танылган җырчы Гөлзадә Сафиуллина берничә ел безнең коллективта нәфис сүз остасы – конферансье булып эшләде. Төскә-биткә чибәр, сәхнәдә ягымлы Гөлзадә концертларны матур, күңелле итеп алып бара иде. Ульяновск өлкәсе филармониясендә җырчы булып эшләгән, матур тавышы белән безнең бригада концертларында да җырлап китәргә була иде, үзенең дә җырларга теләге бар иде. Мин аңар туп-туры әйттем: «Сеңелем, дидем, тавышың әйбәт, яхшы җырлыйсың, мин синең җырчы булуыңа каршы түгел, әмма ләкин мин концертымда хатын-кыз җырчы җырлаганын теләмим, гадәттә, бу бригадада миннән башка гел ир-егетләр җырлый. Син ир-егет җитәкләгән бригадада җырларсың, ә бу бригадада сөйләүче кирәк», – дидем. Шуннан соң ул Илһам бригадасына китте, анда җырлады да, сөйләде дә. Аннары инде үз бригадасын төзеде һәм



Гөлзадә Сафиуллина белән. 1986 ел

чын мәгънәсендә җырчы булып китте, хәзер инде Татарстанның атказанган артисткасы, Республиканың М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты.

Ул елларда шулайрак иде бит: бер бригадада ике хатын-кыз җырчы, яки ике ир кеше җырчы бергә эшләү гадәткә кермәгән иде. Хәзер андый гадәткә кермәгән, дип караулар юк, бер бригадада ике хатын-кыз җырчы да булырга бик мөмкин, хәзер артистлар җырлый да, бии дә, булдыра алганы сөйли дә. Гөлзадәны җырлатасым калган икән, ул җырлап та, сөйләп тә концертны баетасы гына булган икән, мин ул чакта ялгышканмын. Бу минем бер хатам булган. Хәзер үкенеп-үкенеп куям.

Безнең коллективта тагын сөйләүче-конферансье булып эшләгән талантлы егет Дамир Нәбиуллин бар иде. Сатирик, юмористик әсәрләр сөйләп, тамашачыны көлдереп, концертны бик күңелле итеп алып бара иде. Бик яшьли үлде, җаныкаем, үлде дип әйтәсе дә килми, һәлак булды, әйе, әйе, һәлак булды. Илне саклап, үз постында соңгы сулышына кадәр нык торган солдат кебек, татар сәнгате постында һәлак булды. Артистлар юлда күп михнәтләр, җәфалар күрә шул. Юлдагы аварияләр, бәхетсезлекләр турында язармын әле, хәзер минем Дамирның юлда ничек һәлак булуы турында язасым килә. Мәрхүмкәем, үләм дип башына да китермәгәндер. Гастрольләрдә шундый шат күңелле йөри торган иде. Төрле анекдотлар сөйләп көлдерә торган иде. Бер кышны шулай ерак гастрольдә йөрибез. Томск шәһәреннән Кузбасска китеп барабыз. Кичке сәгатьләр. 43 градуслы салкын җилле көн. Поездлар килеп туктаган. Дистәләгән вагоннар тезелеп киткән. Платформада торабыз. Безнең поезд килә. Фараларыннан көчле утын яктыртып вокзалга якынлашты. Шул фаралар яктысында күрәм: платформадан ашыгып, туктап торган вагоннар буйлап, Дамир шул поездга каршы бара... Пальтосының итәкләре җилгә җәелеп-җәелеп китә. Уйлап алдым: Томск тамашачылары безгә юлга ризыклар пешереп, вокзалга төшәрбез, дигәннәр иде, шуларны каршы алырга барадыр бу, дим. Поезд килеп туктады, без үз вагоннарыбызны эзләп табып, урыннарыбызга утырдык. Поезд киткәнне көтәбез, Дамир килми дә килми... Кинәт поезд китте кебек булды. Кузгалып бераз алга таба барып куйды... Юк, китмәгән икән, туктады бу... Дамирны көтәбез, һаман килми. Ничәнче вагонга утырырга тиешлегебезне дә белә иде, югыйсә... Ниһаять, поезд кузгалып китте, Дамирыбыз юк... Әле генә поезд кузгалып киткән кебек иткән иде бит – ул безнең Дамирыбызның гәүдәсен поезд астыннан алу өчен генә кузгалуы булган икән... Дамирыбыз теге ризык китерергә тиешле тамашачыларны каршыларга барган чагында, аягы таеп киткән дә егылып, поезд астына төшкән икән... Аны поезд астыннан алып, платформага куялар, озатырга килүче тамашачылар Дамирны танып алалар, арадан бер ханым Дамирның үле гәүдәсен күргәч, һушын җуеп егыла. «Дамир!.. Дамир!..» – дип, тамашачылар үксеп елашалар. Без китеп барганбыз, бу фаҗигане күрмәгәнбез. Шулай да Дамирның, килеп җитмичә, шунда калганын аңлап алдык, бик каты

борчыла башладык. Үзебезнең вагонга булмаса, башка берәр вагонга утыргандыр дип, бөтен вагоннарны йөреп, эзләп арып беттек. Күңелгә бик каты шом керде. Барыбыз да кайгыга төштек. Шулай да берәр поездда безне куып җитәр, соңга гына калгандыр, дип уйлыйбыз, тапталгандыр дигән уй нигәдер башка килми, чөнки Дамир бик тәртипле кеше, эчеп-нитеп соңга кала торган гадәтләре юк, аннары ул бик шат күңелле, эленке-салынкы йөрми, менәменә безнең янга килеп керер кебек. Көтәбез, көтәбез, юк... «Тайга» дигән бер тукталышта безнең поезд 4 сәгать туктап торды. Томск ягыннан әллә ничә поезд килде. Без һәр поездның һәр вагонына кереп, Дамир килмәде микән, дип эзләп йөрдек. Инде дә килмәгәч, бер-бер хәл булган икән, дип куркуга төштек. Кузбасска барып җитеп, кунакханәгә урнаштык. Дамирыбыз юк. Ул әле бригадир да иде. Кунакханәләргә бик күңелле итеп урнаштыра торган иде. Кунакханәгә урнашуыбыз булды, Томск филармониясеннән телеграмма алабыз – Дамирыбыз тапталып үлгән. Томск моргында ята икән... Без Казанга, үзебезнең филармониягә телеграмма суктык. Ул елларда бригадабызда җырчы Рәйсә Тимофеева администратор иде, җырлый да, шул ук вакытта оештыру эшләрен дә башкара иде, аны Томскига Дамирның гәүдәсен Казанга алып кайтырга җибәрдек. Шундый авыр булды, Дамир шундый кызганыч, елашабыз, күмәргә кайтасыбыз килә. Ул чактагы филармония директоры Таҗетдинов концертларны өзмәскә кушты, безне күмәргә кайтармады.

Дамир бик талантлы егет иде. Матур җырлый да иде. Шул үләсе көнне иртәдән алып кичкә кадәр гел җырлап йөрде. Томск татарлары кунакка чакыргач, мәҗлестә дә күңелле итеп җырлап, анекдотлар сөйләп утырды. Аның сәхнәдә концерт алып барганда сөйли торган шаян монологы бар иде:

«Концертны алып баручы Дамир-р-р Нәбиуллин белән таныштырмадым бит әле... Концертны алып бара Дамир-р-р Нәбиуллин!.. Концертны алып баручы Дамир-р-р Нәбиуллин!.. Дамир-р-р Нәбиуллин!..» дип, кабат-кабат үз исем-фамилиясен «р» хәрефенә басым ясап кызык итеп әйтеп, тамашачыны көлдерә иде. Нишлисең, гомере кыска булгандыр инде, әрәм булды егет. Гаиләсе калды, гаилә җанлы, намуслы кеше иде.

Безнең бригадага эшкә килгән кеше, гадәттә, озак еллар эшли, бездә вакытлыча гына эшләп йөрүчеләр сирәк. Оркестр музыкантлары кайбер бригадаларда берничә гастрольгә чыгып кайталар да, икенче бригадага күчәләр. Безнең музыкант егетләр алай күчеп йөрергә яратмыйлар. Нәфис сүз остасы Нажия Минкина безнең бригадада озак еллар эшләп, пенсиягә китте. Безгә килгәндә Нажия инде зур тәҗрибә туплаган, танылган артистка иде. Төскә-биткә чибәр, матур буй-сынлы Нажия безнең коллективта бик тиз арада үз кеше булып китте. Тамашачылар аны белә иде инде. Беренче көннәреннән үк концертларыбызны матур итеп алып бара башлады. Репертуары бай, кирәк җирдә пафос белән, кирәк җирдә җылы лирика белән ягымлы итеп сөйли. Сатирик-юмористик әсәрләрне оста башкара. Сабантуйда, мәйданда ире көрәштә

җиңелеп калгач, ире урынына мәйдан уртасына чыгып, кулына сөлге алып ирләр белән көрәшкән һәм батыр калган Майшәкәр (Т.Миңнуллин әсәре) турында сөйләгәндә тамашачылар рәхәтләнеп көлә. Нажия белән мин бик тиз арада дуслашып киттем. Ул минем якын дустыма әйләнде. Кунакханәләрдә, фатирларда бергә торабыз. Нинди ризык алдыбызга килә, бүлешеп ашыйбыз, бер кашыктан ашап яшибез, дигәннәре шулай буладыр инде. Нажия тәрбияле, миңа ул күп яктан үрнәк булды. Чисталыгы, пөхтәлеге, кешеләр белән үзен тыныч, матур тотуы, ирен ир дип санап яшәве, интеллигентлылыгы белән аерылып тора. Нажияне мин яраттым, хәзер инде ул пенсиядә, без еш очрашабыз, сагынышып күрешәбез дә сөйләшеп туя алмыйбыз.

1969 елда безнең бригадага Кәрим Габидуллин килде. Югары белемне инженер. Инженер булып та бик шәп эшләп, күп акчалар аласы егет. Әмма ләкин күңеле тулы моң, музыкага мәхәббәт аны сәхнәгә китерә. Кулына гитарасын тотып, ул безнең музыкант егетләр арасында тиз арада матур итеп эшләп китте, нәфис тавышлы гитарасын чыңлата башлады. Озын буйлы, бөдрә чәчле яшь егет Кәрим чыгып бер елмайса, бөтен музыкантлар елмая. Инженер егет гитара чиертеп озак йөрмәс, дип уйлаган идем, ялгышканмын, Кәрим башы-аягы белән музыкага чумды, сәхнәне үзенең гомерлек иҗат мәйданы итеп сайлады. Репертуарымны баетырга ярдәм итеп, яңа җырлар табышты. Чит илләргә ялга барган җиреннән махсус минем өчен чит ил җырлары алып кайтты. Шундыйлардан Чехословакиягә барган җиреннән ул магнитофонга яздырып, миңа бик



Сания һәм Кәрим Габидуллиннар белән. 2010 ел

матур чех җырын алып кайтып өйрәтте. Татарча бу җырны «Матур хатын» дип атадык. Гөлшат дустым татарчага тәрҗемә итеп бирде. Ул җырны мин бик яратып озак еллар җырладым. Озак еллар бергә эшләү дәверендә, Кәрим минем бертуганым кебек якын дустыма әверелде. Сәхнәдә, иҗат эшендә генә түгел, Кәрим тормышта да миңа күп эшләремдә булыша.

Музыкант буларак, Кәрим үсте, инструменталь ансамбльнең җитәкчесе булып эшләү дәрәҗәсенә җитте, Татарстанның атказанган артисты исеменә лаек булды' Менә егерме елдан артык инде без бергә эшлибез, ул сәхнәдә дә, тормышта да минем якын дустым, ярдәмчем. Кәрим – гаилә җанлы, тәртипле кеше. Бик сөйкемле хатыны Сания белән матур яшиләр, Ләйсән исемле акыллы кыз үстерәләр. Соңгы елларда Сания дә безнең концертларыбызны оештыру эшләренә – администраторлык эшенә бирелеп китте, концертларыбызны оештыру эшендә булыша.

Шулай итеп, «Таныш түгел юллар буйлап» дигән бу бүлекне тәмамлаганда, тагын менә нәрсә турында язасым килә: юллар, юллар, иксез-чиксез юллар... Таныш түгел юллар буйлап күп йөри торгач, миңа бик күп юллар таныш юлларга әйләнде. Элек СССР дип аталган зур илебезнең күп төбәкләрендәге иксез-чиксез юллар минем өчен күп тапкырлар үтелгән, тапталып беткән юлларга әверелде. Артистлык хезмәтемнең беренче елларында бата-чума үткән



Биюче Гүзәл Вафина, кызым Зөлфия һәм оныгым Ләйсән белән. 1988 ел

күп кенә юллар – еллар үткәч, шома матур асфальт юлларга әйләнсә дә, бик күбесе һаман шулай мең газап белән үтә торган баткак юллар килеш сузылып ята бирә әле. Ләкин алар минем таныш юлларым инде. Шоферлар, юлны бутап, адашып, икенче якка алып киткән чакларда, мин хәзер машинадан төшеп үзем юлны өйрәтеп, шоферларны дөрес юлга борам.

Бу юлларда артист халкының мең газаплар күрүе турында матбугатта күп язалар. Ә минем юлларда күргән газапларым меңнәр белән генә исәпләрлек түгелдер. Берничә меңнәр белән исәпләсәң генә инде. Элегрәк елларда атларда, чана таккан трактордa кышкы буранда күмелеп калган юлсыз җирләрдән юл ярып үтүләр онытыла төшкән. Аларның авырлыгыннан бигрәк матур романтикасы хәтердә калган. Ап-ак буранда адаша-адаша, трактор чанасында туңа-туңа барасың, яшьлегең генә җылыта да, яныңда күңеленә ошаган кеше булса, шул гына җаныңа җылы бирә. Ул елларда җәйләрен инде яхшы ат җигелгән печән салган арбаларда үткән юллар да хәтердә матур төш кебек кенә булып калган, авырлыклары онытылган. Ул чакта яңгыр явып, юлларны сазлыкка әйләндерсә, авыл белән авыл арасын җәяү генә сыпырта торган идек. Аяк киемеңне саласың да саз ерып, көлешә-көлешә, бата-чума барасың. Яшьлек белән сизелми дә. Аннары ул чакларда барлык авылларга керә идек бит, клуб кечкенә дип, хәзерге кебек зур клублы авылларны гына сайлап йөрми идек. Авыл аралары якын иде. (Хәзер генә ул зур клублы, халык күп йөри торган, акча күп керә торган «кассовый» авылларда гына концерт кую модага керде. Бигрәк тә соңгы елларда кайбер бригадалар районны бер-ике көндә «йөреп» чыга. Районның бик күп авылларында бер концерт карарга тилмергән тамашачылар кала бирә. Әлбәттә, районның бер-ике генә авылын алсаң, авыл аралары ерак була инде. Шулай итеп яшьлектә узган юлларның авырлыклары онытылган. Ә менә соңгы елларда, 70–90 нчы елларда узган юллар хәтерләрдә уелып калган, соңгы елларда юл йөрүләр бик авырлашты шул. Чөнки машиналар күп йөри, юлларда аварияләр бик еш була, аварияләрдә фаҗигаләр булып тора. Соңгы елларда гына мин бик күп ерак төбәкләргә гастрольгә барып кайттым. Себергә, Ерак Көнчыгышка, әле 1993 елда гына да Камчаткага, Киевка барып кайттым. Ерак гастрольләргә самолет белән барасың, ә самолетларда йөрүләр дә хәзер бик куркыныч, бик еш аварияләр булып тора. Әле тегендә, әле монда самолет янып төшкән, поездлар рельстан чыккан дигән хәбәрләрне газеталардан еш укыйбыз. Ә инде автобуслар, машиналар белән йөрүе бигрәк тә куркынычка әйләнде. Алда әйткәнемчә, юл тулы машина хәзер. Юлларда тәртип сакламыйлар, исерек шоферлар да бар, алар үз гомерләрен генә түгел, пассажирларның гомерләрен дә өзә.

Соңгы елларда безнең Татарстанда күп кенә юллар, күперләр төзекләндерелде. Әгерҗе, Минзәлә, Мамадыш районнарында күп кенә яңа юллар салынды, авыл урамнарына асфальт җәелде. Республикабызның бүгенге җитәкчеләре юллар, күперләр турында кайгыртмый түгел, кайгырта, ләкин

барлык юллар да әле төзекләндерелеп бетте, дип әйтеп булмый. Бата-чума саз ерып йөрергә туры килгән авыл аралары бар әле. Юллар минем гомерем буена төшләремә кереп йөдәтә. Минем үз гомеремдә юньле, матур төш күргәнем юк. Төшемдә гел әле иске, җимерек күпер аша чыгалмыйча җәфаланам, әле менә чыктым гына дигәндә, күпер астына төшеп китәм, яки машинабыз юлдагы сазлыкка, баткаклыкка кереп чума, яисә чокырлы-чакырлы юлдан барганда машинабыз чәлпәрәмә килеп ватылып, таралып китә дә үзем берәр чокыр төбенә төшәм һәм шул чокырдан чыга алмыйча газапланам... Бөтен күргән төшләрем шундый.

Күп йөри торгач, аварияләргә дә юлыктык. Шундый аварияләрнең берсе турында язмый калдырып булмый. 1982 ел, Мари республикасында гастрольдә йөрибез. Кыш айлары. Юллар катырган. Менә концерттан соң, төнге берләр тирәсе, Йошкар-Ола юлы буйлап барабыз. Юл шоп-шома, бозлавык. Автобусның алгы өлешендә утырам, гадәтемчә, күзем алга текәлгән. Мин автобусларда һәрвакыт юлны карап барам, игътибарым гел юлда. Якякка карап, табигать белән хозурланып, төрле матур уйларга бирелеп барганым юк. Күңелем минем бер генә минутка да тыныч булмый. Тыныч, гамьсез була белмим. Бригадамдагы артистлар өчен дә үземне гел җаваплы сизәм. Әйтерсең лә, бер-бер хәл була калса, барлык артистлар да минем аркамда бәлагә юлыга. Бу төнне инде бигрәк тә җаным тыныч булмады. Тышта салкын ачы җил исә. Автобус бозлавык буйлап шуып бара. Тәгәрмәчләр тәгәрәми, шугалак буйлап шуыша. Каршыда машина килгәндә, күрәм: фаралар яктысында күзне камаштырып, юл боз катламы булып ялтырый, безгә каршы килүче машиналар да шуып киләләр. Каршы машина килгәндә мин кулларым авыртканчы каты ябышып, утыргычның аркылы тоткычына тотынам... Шулай тотынып бара-бара, кулларым ойый, әмма ләкин кулларымны ычкындырмыйм, күңелем сизенә, менә-менә нәрсәдер булыр кебек... йөрәк дөпдөп тибә... Күңел дөрес сизенгән, менә кинәт каршыда зур бер машина пәйда булды, КамАЗ... Фараларын убыр утыдай ялтыратып безгә каршы шуып килә бу... Әйе, әйе, шуып килә... Бу бозлавык юлдан башкача килү мөмкин түгел... Шундый зур тизлек белән килә, безнең автобус шоферы нишләргә белми шикелле тоелды миңа, чөнки ул да зур тизлек белән бара иде, шуып барган машинаны әкренәйтеп булмыйдыр... Безнең артистлар концертта арып йомшак машинага кереп утыргач, кайсы йоклый, кайсы изрәгән. Инструменталь ансамбль егетләре күбесе яшьләр, яшьләр бит – гамьсез халык, аны-моны уйлап бик баш ватмыйлар, алар арткы рәтләрдә кайсы көлешеп сөйләшә, кайсы сузылып яткан, кайсы утырган килеш мышный. Мин барысын да уятыйм, барысы да әзер булсыннар, болай гамьсез бара торган юл түгел бу дип, авызымны гына ачыйм дигән идем, нигәдер авызымнан сүзем чыкмады, тынсыз калдым. Әлеге «КамАЗ», аждаһа кебек фара утларын чәчеп, үкереп безгә таба шуышып якын ук килеп җитте... Безнең автобус, нишләргә белмәгәндәй, як-

якка тайпылгандай итте дә, юлга аркылы килде... Шулчак «КамАЗ» шоферы безнең автобус эчендә пассажирлар барлыгын шәйләп алды бугай, юл читенә тайпыла төшеп, безне читләтеп уза башлады, ләкин артына таккан прицебы белән безне бәрдертеп өлгерде. Минем күздән утлар чәчрәде. Нәрсәдер шартлады, ниндидер күк күкрәү, яшен яшьнәү булып алды сыман, бер секунд эчендә дөньяның асты-өскә килгәндәй булды... Автобус тәрәзәләре чәлпәрәмә килде, кемнәрдер ватык тәрәзә аша тышка, юл читенә очты. Кемнәрдер кычкырып җибәрде, ыңгырашты... Мин, Ходайның рәхмәте, утыргыч тоткасына чытырдап ябышкан килеш, күзләремне ачарга куркып, дөресрәге, күзләремне нигәдер ача алмыйча, урынымда тынсыз утырам... Күкрәгем белән алдагы утыргыч тоткасына каты гына бәрелгәнмен, бәрелгән урыным гына авырта... Бәхеткә каршы, йөрәк ягы белән бәрелмәгәнмен...

Безне узып китүче машиналардагы шоферлар хәбәр җиткездеме, бик тиз арада милиция машиналары килеп җитте, безнең артистларны юлдан җыеп алып, шул юлдан ерак түгел «Советский» поселогындагы больницага илттеләр. Күбесенең хәле авыр, миңа тоткага чытырдап ябышуым ярдәм иткәндер, тоткычны шул ябышыр өчен ясыйлар бит, ә кайберәүләр ябышырга яратмыйлар, автобус эчендә, өендә телевизор карап утыргандай, гамьсез утыралар. Шуңа күрә дә бәхетсезлекләр була. Кәрим бичаракайның алты кабыргасы сынган... Юлдан читкә куак төбенә очып барып төшкән Нәҗиябезнең иңбаш сөяге сынган... Миңхәмәтнең берничә җирдән иреннәре яргаланып, кискәләнгән... Шоферның аягы сынган... Ни хикмәттер, оркестр артистларына – артта утырган егетләребезгә берни дә булмаган, кайсы тәрәзә аша йомшак карга барып төшкән, кайсы үз урынында утырып калган. Бер-икесе хәтта салып утырган икән... Көлешкән тавышлар ишетелгән иде шул... Аракы шешәләре, стаканнары да ватылмаган... Кайберәүләр шулай салып барыр өчен артка утыралар да бит...

Больницада ятабыз. Ярый әле, үлем-китем юк. Кабырга, иңбаш сынулар гына төзәлер дип, бер-беребезне юатабыз. Нәҗия – ике айлап, Кәрим белән Миңхәмәт берничә атна ятты. Мин, дүрт-биш көн яткач, Казанга кайтып киттем. Филармониядә гөж киләләр. Безнең авариягә эләгүебез артистларны шактый куркыткан. Гастрольгә чыгып китәргә шүрләп йөриләр. Барысы да шул турыда сөйлиләр. Минем турыда төрле имеш-мимеш сүз таралган: «Әлфия күкрәге белән каты бәрелгән икән, сулыш ала алмый икән, җырлый алмаячак икән...» Кайсы сөенеп, кайсы минем хәлемне аңлап, жәлләп шулай чыш-пыш сөйләнәләр... Безнең бригада шактый озак гастрольгә чыкмый торды. Мин башка бригада артистлары белән чыктым. Сулышыма да, тавышыма да берни дә булмады, Аллага шөкер, җырлавымны дәвам иттем. Кәрим, Нәҗия, Миңхәмәтләр озак дәваландылар, шактый вакытлар сәхнәгә чыга алмадылар. Ярый, тазардылар, бригадабыз тагын бер составка җыелды. Тагын гастрольләргә йөри башладык. Мәскәү, Ленинградка барып, берничә концерт куйдык. Теге «Юллар, юллар» дигән матур җырдагыча:

Юллар, юллар, авыр булса-булсын,
Тик соңгысы гына булмасын!..

Әйе, тик соңгысы гына булмасын!.. Без әле юлда!.. «Юлда» дигән яңа җырыбыз да туды. Сүзләрен Гөлшаттан яздырдык, көен үзебез таптык:

Юллар узып, дөнья гизеп,
Кая гына бармыйбыз.
Җырлый-җырлый йөргәч, юлда
Армыйбыз без, армыйбыз!..

Менә шулай армый-талмый, юлларыбызны дәвам итәбез!.. Шулай дәвам итәргә язсын!..



Хәйдәр Сафин белән. 1983 ел

Туганнарым, балаларым, оныкларым һәм дусларым

Безнең авылның урманы
Вак кына, куак кына.
Кыз балага сүз әйтмәгез,
Кыз бала кунак кына...
(Халык җыры.)

1960 нчы еллар башында безнең филармониягә директор итеп партия эшләрендә озак еллар эшләп, җитәкчелек эшләрендә тәжрибә туплаган Хәят Әхмәдишевна Калининаны билгеләделәр. Калинина мине ярата иде, мин үзем дә аны бик нык хөрмәт иттем. Партия эшләреннән килгән булса да, ул сәнгать дөньясын яхшы белә, татар җырын аңлый, җырчыларны ихтирам итә иде. Калинина миңа бөтен уңайлыклары булган ике бүлмәле квартира алып бирде, һәрвакыттагыча ул елларда да квартира мәсьәләсе бик авыр мәсьәлә иде. Шул квартираны алуым турында языйм әле. Мин әле «сыпушка» дигән теге мунча хәтле генә квартирада торып интегә идем. Бервакыт Гөлшат килеп керде. Стеналары юеш, идәненә язларын су чыга торган, бернинди коммуналь шартлары булмаган шушы мунчада торып, мин үзем дә, балаларым да, салкын тидереп, авырып интегәбез. Минем кулда яшь бала – Зөлфия. Мин, салкын тиюдән күкрәкләрем шешеп, авырып утырам.

– Болай булмый бит инде, – диде Гөлшат. – Яңа директорыгыз Калинина бик әйбәт кеше, диләр, синең хәлне аңлар, әйдә, гариза язып шуңар кер, квартира сора!..

– Ничек язарга соң ул гариза дигәнен? – дим мин. – Син язып бирсәң генә инде...

Гөлшат утырды да Калинина исеменә гариза язды, мин кул куйдым. Икенче көнне Гөлшат филармониягә барып, шул гаризаны Калининага бирә, минем хәлне бәйнә-бәйнә сөйли. Калинина шул көннән Казан шәһәренең шул еллардагы Башкарма Комитеты председателе Тунаковка барып, миңа квартира сорый. Тунаковны тәмам күндереп, тиз арада миңа Космонавтлар урамыннан ике бүлмәле квартира бирергә булалар. Квартира алу документларын филармониябезнең администраторы Тәскирә Акчурина әзерләп, шәһәр Советына илтә. Уңган-булган хатын Тәскирә, кулына ордер алганчы, шәһәр Советы белән филармония арасында чаба, мине яңа квартирага күчерешеп үк куя. Местком председателе урынбасары булып эшләгән Тәскирә шулай күп кенә артистларның квартира шартларын яхшыртуда көчен кызганмады.

Яңа квартирага күчкәч, Җыракаем белән шатлыктан елашып куандык. Кеше почмакларында яшәү бик арыткан иде. Капчык тотып, хәер сорашып, ятим үскән авыл кызы нинди шәһәрчә квартирада тора дип, үз-үземә ышанмыйм, кайтам да ике ягыма ике кызымны утыртып, аркаларыннан сөям:



Жыракай, Светлана, кызларым Гүзәл белән Зөлфия, Таня. 1966 ел

– И балакайларым, мин күргән михнәтләрне күрмичә, шушы рәхәтләрдә исән-сау үссәгез иде, – дим.

Җыракаем балаларымны яхшы карый. Ике кызым да әбиләрен бик ярата. Әмма ләкин аның яше бик олыгайды бит инде. Актаныштагы туганыбыз кебек Вәгыйзь абыйның кызы Нәзифәне Казанга балаларымны карашырга алып килдем, кызларым Нәзифәне дә үз туган апалары кебек яраталар, «Алма апабыз» дип кенә йөртәләр, Нәзифә кызларыма дәрес әзерләшергә булыша, шулай итеп тормыш көйләнеп бара.

Кызларым әбиләре янында матур итеп татарча сөйләшеп үсәләр. Торыр квартирабыз әйбәт, тамаклары тук, өсләре бөтен, яннарында әбиләре, апалары бар дип, тыныч күңел белән гастрольләргә чыгып китәм. Чыккач, әлбәттә, җан тыныч түгел, гел балалар турында уйлыйм. Гастрольләрдән аларны бик сагынып кайтам, алар да мине бик сагыналар. Кече кызым, Зөлфиям, мин гастрольдән кайтып кергәч, кушаяклап сикереп шатлана, газизем.

Инде акча да күп алам, минем кебек хәерчелектә үскән кешегә үз көче белән тапкан хәләл акчасы бик кадерле. Акчаны бик саклап тотам. Кунакханәләрдә яшәгәндә, башка артистлар ресторанарга кереп сыйланып утыралар, ә мин тегесен-монысын пешергән булып, кипятильник дигәннәре белән чәй кайнатып, расход чыгармыйча гына яшәргә тырышам. Гастрольләргә киткәндә, балаларны ач итмә дип, Җыракайга мул итеп акча калдырам. Җыракай акчасын шулай ук юкка-барга туздырмый, чамалап кына тота,

әмма балаларны ач итми, аларны яхшы ашата. Кайвакыт саранланып та китә, әлбәттә. Кызларым мороженое, шоколад алырга акча сораса, бирми. Бервакыт мин гастрольдә чакта, 3-4 яшьлек кече кызым Зөлфияне ияртеп, Җыракай кибеткә ашамлыклар алырга китә. Сумка тутырып ашамлык алган болар. Кибеттән кайтырга чыкканда, Зөлфия Җыракайны «мороженое ал» дип, кыса башлаган. Җыракай: «Акчам юк, акчам бетте!» – ди икән. Зөлфия: «Бетмәде, синең акчаң бер капчык, ыштан төбендәге кесәңдә!» – дип акырып елый икән. Кибеттәге халык, кибетчеләр шаркылдап көлә, Зөлфия һаман бер сүзне такмаклый: «Синең акчаң ыштан төбендәге кесәңдә, үзем күрдем, асылынып тора...»

– Ай, каһәр төшкән бала!.. Гөнаһлы итәрсең, ыштан төбемдә нинди кесәм булсын минем, кеше алдында рисвай итәсең! – дип, Җыракай Зөлфияне өстерәп диярлек кибеттән алып чыгып китә. Зөлфия нык характерлы бала булып үсте, әбисенә бирешмәгән, тәки мороженое алып ашарга хәйлә тапкан. Без озак еллар танылган җырчы Сөләйман Йосыповлар белән күршеләр булып яшәдек. Кибеттән кайткач, Зөлфия Сөләйманнарга керә:

– Сөләйман абый, 20 тиен акча биреп тор әле, әни кайткач, кертермен. Җыракай мороженоега акча бирми, ыштан төбендәге кесәсе тулы акча..., – ди икән.

Зөлфия Сөләйман биргән 20 тиеннең 19 тиененә мороженое ала да калган 1 тиенен кире кертә. Кыңгырау төймәсенә буе җитми, шул 1 тиенне кертү өчен ишек төбендә шактый басып тора, үтеп баручылардан төймәгә басуларын үтенә.



Кызым Зөлфия, Якуб Билялов, Элиза Усманова. 1968 ел

Ярлылык белән гомер иткән авыл карчыгы Җыракай, чынлап та, акча кадерен белә иде, юк-барга тотмый иде. Бервакыт мин аны юри шаярттым. Озак гастрольләрдән йөреп кайткан бер көнне, берничә айлык хезмәт хакымны берьюлы алып кайттым да, ишектән килеп кергәч тә юри егылып китеп, зур төргәк акчамны идәнгә чәчеп җибәргән булдым. Янәсе, ялгыш чәчелде!.. Идән тулы кәгазь акча, иллелек, егерме бишлек, унлык акчалар чәчелеп ята. «Җыракай, бу акчалар барысы да сиңа!» – дим. И бичаракаем, акчаның өстенә үк ятты, үрмәли-үрмәли акча җыя, идән буйлап шуыша, куенына акча тутыра... Мин көләм! Миңа рәхәт! Кызык!..

Менә шулай Җыракай белән күңелле итеп яшибез, балалар үстерәбез. Зөлфия бәбкәемә, мин өйдә аз торгач, юньләп күкрәк сөте эләкмәде. Әллә шуңа бик елак булды. Тиктомалга акырып елый, һич туктатып булмый иде. Мин өйдә юк чакларда, Җыракай аңар ипи белән шикәр чәйнәп, марляга салып, имезлек бирә. Шулай ул кызларымны, элекке заман карчыклары кебек, үзенчә карап үстерде. Зөлфиясе бигрәк күп суырды андый имезлекләрне. Еламаган вакытларында Зөлфия үзе бик тере, шаян, күңелле кыз иде. Җәйләрен үзем белән гастрольгә алып чыксам, бер дә еламый, көйсезләнми, тик сәхнә артында уйнап йөри. Нинди генә уңайсыз шартларга да түзә, юл йөрүне ярата иде. Бригадада бергә эшләгән дусларым да аны бик яраталар иде. Кулдан-кулга күчереп күтәреп йөриләр иде. Бигрәк тә Юсыф абыйсы аны үз кызыдай яратып карый иде. Мин сәхнәдә җырлап торганда, аны сәхнә артында калган һәркем карый, уйната иде. Кайчакта концерт бик озынга киткән төннәрдә ул арып сәхнә артында берәр җиргә ятып йоклап та китә. Төрле киемнәр җәеп урын әмәлләп биреп, кайсы да булса берәрсе аны йокларга сала. Еш кына ул Зиннур Гыйбадуллинның баян чехолына башын куеп йоклап китә иде. Без нәрсә ашасак, шуны ашап, без ни күрсәк, шуны күреп, гастрольләрдә чыныгып үсте. Инде үзем белән алып китәргә җай булмаганда, бигрәк тә кышларын, әбисе белән өйдә калганда, әбисе чак кына ачуланса: «Гастрольгә китәм!» – дип елый икән. Безне сагынып, безнең бригадада җырлана торган популяр җыр «Юллар, юллар»ны теле дә ачылып җитмәгән Зөлфия болай дип җырлый икән:

Юллал, юллал, авыл булса-булсын...

Кайчакта мин сәхнәдә бөтен күңелем белән бирелеп җырлап торганда, минем янга чыгып баса икән дә музыка ритмына биеп, боргаланып тора икән, мин күрмим икән. Зал гөр килеп көлешеп кул чаба башлагач, сизеп алып карыйм да, түзмичә, үзем дә көлеп җибәрәм. Ул шулай җырлап-биеп, сәхнә артында тәгәрәп үсте.

Бер җәйне, өен сатып килү өчен, Җыракаем Актанышка кайтып киткән иде. Ике кызымны да Гөлшатка калдырып, бер атнага гастрольгә киттем.



Кызым Зөлфия. 1975 ел (өстә). 1987 ел (аста)



Кызларым Гөлшатның кызы Асия белән бертуганнардай уйнап, матур гына яшәгәннәр. Гөлшат аларга гади генә ситсыдан сарафаннар тегеп кигезгән. Тәмле ризыклар пешереп сыйлаган. Зөлфиясе Гөлшат апасы пешергән кабартмаларны бик яраткан. Каймакка гына басып, күпереп кабарган йомшак камырның эченә җиләк яки повидло кыстырып пешергән бу кабартмаларның исеме ничек дип сорый икән Зөлфия. Гөлшат аңар:

– Пончик дип атала мондый кабартма, – дип җавап бирә икән.

Теле ачылып җитмәгән Зөлфия «пончик» сүзен «путик» ди икән. Җыракай кызларымны үзебезгә – өйгә алып кайткач та, Зөлфия: «Путик! Путик! Путиккә барам!» – дип елый икән. Җыракай аңламый, нигә бу һаман «путик» дип аптырата соң дигәч, олы кызым Гүзәл аңлатып бирә:

– Гөлшат апаларга барыйк, дигән сүзе ул аның, ул анда бик тәмле пончиклар ашаган иде, шуны сорый ул, – ди. Шул кечкенә вакытыннан алып, кызым Зөлфия һаман Гөлшат апасын «Путик» дип йөртә. Бу «Путик» кушаматы Гөлшатка ябышып калды, хәзер аның оныклары да, Гөлшатны яратып, «Путик» диләр.

Гүзәлем тыныч, сабыр булып, ә Зөлфиям шулай чая булып үсте, характерлары белән икесе ике төрле. Кызларым кечкенә чакларында бик еш авырый иде. Җыракай аларны врачларга алып бара, үләннәр белән дәвалый иде. Бер кышны миңа Казанга кайтмыйча, кыш буена, өч айдан артык гастрольләрдә йөрергә, бөтен Урта Азияне, Казахстанны әйләнеп чыгарга туры килде. Кызларым бик нык авырган. Бер урында гына тормагач, мин алардан хат та ала алмыйм. Шундый чакларым була, балаларым өчен үзәкләрем өзелә. Бер генә көнгә яннарына очып кайтырлык булам. Концертларны өзеп, кайтып китеп булмый. Шул елны, үч иткәндәй, кышы да бик салкын булды. Кызла-



Кызым Зөлфия белән. 1981 ел



Кызым Зөлфия белән. 1987 ел



Зөлфиям. 1988 ел

рым салкын тидергән. Олы кызым Гүзәл салкын тидереп айга якын авырып яткан. Миңа хәбәр итәргә уйламаганнар, борчымыйк, тыныч кына эшләсен, дигәннәр. Хәбәр итәргә булсалар да, үзләре генә бу эшне эшли алмый бит алар: Җыракай укый-яза белми, кызлар әле бала гына, телеграмма сугуларны белмиләр. Филармония җитәкчеләренә әйтергә башлары җитми. Шул чакта кызларым янына еш килеп йөрүче Гөлшат дустым Гүзәлнең хәле бик авырайса, филармония аша мине эзләп табып, телеграмма сугарга әзерләнә, бәхеткә каршы, Гүзәлнең хәле әйбәтләнә башлый. Гөлшат аны җитәкләп врачларга алып бара, дәвалый. Гүзәлнең тамагы бик нык шешкән, эренле ангина була. Врачлар тамак төбендәге шешне ярып җибәреп, бик күп эренен агызып чыгаралар, эрен хәтта баланың борыныннан да ага. Атналар буе уколлар кадатып кына Гүзәл, тазарып, аякка баса. Мин бу турыда гастрольләремне төгәлләп кайткач кына белдем.

Җыракай үзе надан булса да, кызларымның укуына игътибарлы булды. Вакытында ашатып-эчертеп, аларны мәктәпкә озатты, мәктәптән кайтуларына кайнар аш әзерләп каршы алды. Кызларым әйбәт кенә укып урта белем алды. Аннары Гүзәлем Алабуга педагогия институтының китапханәчеләр факультетында укыды. Зөлфиям Казан театр училищесын тәмамлап, эстрада артисткасы булып китте. Сәхнә артында тәгәрәп үскән, 2–3 яшеннән сәхнәдә минем яныма чыгып биеп торган Зөлфия артистка булыр өчен туган диярсең. Мактана дип уйлый күрмәгез, җырлый да, бии дә, нәфис сүз сөйләргә дә оста. Хәзер еш кына үз бригадамда концертлар алып бара. Мәскәүдә яши, Мәскәү эстрада бригадалары чакырган чакларда, шул бригадалар составында концертларда катнаша. Кызларым үз тормышлары белән әйбәт кенә яшиләр, балалар үстерәләр.

Шушы урында бертуган сеңелем Флүрә турында язып китим әле. Флүрә алдагы бүлекләрдә язганча, балалар йортларында тәрбияләнеп үсте. Кызганычка каршы, әллә ни укый да, бер-бер һөнәр дә үзләштерә алмады. Җыештыручы, урам себерүче кебек кара эшләрдә эшләп көн күрде. Ни аяныч, язмышы шулай язылган булгандыр инде: Флүрә сеңелем берничә тапкыр иргә чыгып та уңмады. Җыен эшлексез, җыен эчкече кешеләргә тап булды. Эчкече ирләр белән торып рәхәт күрмәсә дә, бер-бер артлы алты бала тапты. Ирләре кайсы эчеп үлде, кайсы узгынчы гына булды. Безнең илдә, безнең тормыш шартларында ишек алды себереп кенә тапкан акчага ялгыз ана берүзе алты бала карый аламы соң?.. Әлбәттә, мин ярдәм иттем. Үзенең дә, балаларының да өс-башларын караштым, акчалата да бирдем, ашау якларын да кайгырттым. Әлбәттә, миңа авырга килде. Хезмәт хакым гомергә әллә ни зурдан булмады, чөнки югары музыкаль белеме юк, консерватория бетермәгән дип, миңа гомер буена югары ставкалар билгеләмәделәр, үзем кебек эстрада артистлары арасында, әйтик, Илһам Шакиров, Вафирә Гыйззәтуллиналарга караганда, минем бер концертыма түләү ставкасы

һәрвакыт түбән булды. Шулай да мин акчасыз булдым, дип әйтә алмыйм, шөкер, акчалы яшәдем; Флүрә тормышының да ярты чыгымын үз өстемә алдым. Авылда ялгызына балалар үстерү авыр булгач, мин аны Казанга алып килеп, квартира алып биреп, эшкә урнаштырган идем. Флүрәнең язмышы туган көненнән алып, гомеренең соңгы көненәчә, аянычлы булды: балаларын үзе үстереп, тормышның рәхәтен күреп яши алмады, 38 яшендә алты баласын калдырып, көтмәгәндә, кинәт кенә вафат булды. Гомере кыска булгандыр инде. Алты бала ятим калды. Әтиләре булмаса да, әниләре исән чакта, бер оя кош балалары кебек, әниләре куенында иделәр. Мин ике кулсыз калгандай булдым. Флүрәне күмү эшләрен дә башкара алмас хәлдә каушап, аптырап калдым. Ярый әле, дуслар булышты. Туганнарым юк. Флүрәне соңгы юлга әйбәтләп озату мәшәкатьләрен Юсыф үз өстенә алды. Рәхмәт инде: минем өчен иң авыр көннәрдә Юсыф шулай үзенең чын дус икәнен күрсәтте.

Флүрәнең алты баласы, алты бәхетсез җан булып, бу тормышның аяусыз, рәхимсез кочагында ятим калды. Вакытсыз дөньядан кичкән бердәнбер сеңелемне салкын гүр куенына салу бик авыр булды. Апа буларак, мин аңар тиешенчә туганлык күрсәтә алмаганмындыр, дигән уй бәгырьне телә. Биш баланы өемә алып кайттым (бер ир баласы Башкортстанда – авылда әтисенең әнисендә – әбисендә тәрбияләнә иде). Биш бала биш якта тәгәрәп елый. Берсеннән-берсе бәләкәй бу балаларны нишләтергә?.. Иң зур дигәне – ун-бер-унике яшьтә, иң кечкенәсе идән буйлап үрмәли. Балда-майда йөзмәсәләр дә, үзләре таза, нык. Уйладым-уйладым да бу балаларны берәм-берәм интернатларга, балалар йортларына урнаштырырга булдым. Иң олысын – Светланасын үземә алдым. Ул инде болай да минем кулда үсте диярлек. Кечкенәләрне интернатларга, балалар йортларына урнаштыру бик кызганыч булды. Ап-ак чырайлы, ап-ак тәнле, таза, матур Руслан исемле малай, идәндә үрмәләп әнисен эзләп, ими сорап өзгәләнеп елый, аңа карап минем күзләремнән мөлдерәп яшем ага. Елап утырып булмый, мин бит аларны карап-тәрбияләп өйдә утыра алмыйм. Эшләргә, тормышны алып барырга кирәк. Җыракайга да бу кадәр баланы кара дип әйтеп булмый, минем ике кызны карап үстергәне өчен дә рәхмәт. Мин, тәвәккәлләп, бу балаларны Хөкүмәт тәрбиясенә тапшырырга җыендым. Рәхмәт Хөкүмәтебезгә, балаларны урамда калдырмады, барысын да кабул итте. Әлбәттә, аларны тиз генә, җиңел генә урнаштырып булмады. Төрле документлар, белешмәләр юллап алып, шактый мәшәкатьләрне җиңәргә туры килде. Рәхмәт дусларыма, әлеге дә баягы шул Юсыфка рәхмәт! Гөлшатка рәхмәт! Кирәкле гаризаларны язып, анкеталар тутырып, бер учреждениедән икенчесенә чаптык. Яшь аермалары булганга күрә, барысын бер интернатка яки балалар йортына урнаштырып булмады. Учреждениеләргә йөргәндә, интернатларга, балалар йортына илткәндә, мине гел үз машиналарында йөртеп, Юсыф һәм Кәрим бик булышты. Мин бер җиргә дә җәяү йөрмәдем. Кайгымны уртаклашып, янымда киңәшчем булып,

бу дусларым бик нык ярдәм итте. Аерым-аерым урнашсалар да, ятимнәрем, бер-берсен югалтмыйча, бер-берсен белеп үстеләр. Мин алар бер-берсен онытмасын өчен кулдан килгәннең барысын эшләдем.

Гастрольләрдән кайткан араларда үз балаларыма күчтәнәчләремне бирәм дә, икенче көнне үк тәмле ризыкларымны тотып, ятимнәрем янына йөгерәм. Гастрольләрдән Казанга кайтканда, күз алдыма килә: Казанда авызларын ачып, әнкә кош алып кайтачак җимне көтеп торган кош балаларыдай, мине дистәләгән бала көтә. Хәзер инде бу ятимнәр барысы да үсеп, үз тормышларын корып, яшәп киттеләр. Кызлардан Светлана, Тәнзилә, Рамилә, Роза – барысы да кияүгә чыгып, әйбәт кенә тормыш кордылар. Кияүгә чыкканда туй бүләкләре итеп, урын-җир әйберләре, кием-салым алып бирдем, үземнән өзеп, шул ятимнәргә өлеш чыгарырга тырыштым. Яше җитеп, балалар йортларыннан кайткан балаларга квартира бирелергә тиеш дигән закон нигезендә, өч кызга квартира юллап алып бирдем.

Сеңелемне җирләп, бу ятимнәрнең язмышларын кайгыртып, әрле-бирле чабулар миңа бик авырга килде. Мин тавышсыз кала яздым. Нервлар киеренкелегеннән, күп уйлаудан, күп борчылудан тавыш җепселләрем авырый башлады. Җырлап карыйм, тавышым чыкмый. Врачлар синдә порез диделәр. Порез, ягъни тавыш җепселләре тартылып, киселеп, җәрәхәтләнеп китү җырчы өчен бик куркыныч. Врачлар миңа җырламаска куштылар. Берничә ай җырламаска туры килде. Ярый, Алланың рәхмәте, бу авыру үтте. Сәхнәдә эшемне дәвам итә башладым.

Тавыш җепселләре рәтләнсә дә, җырлау бик авыр иде, чөнки сәхнәгә чыккач, ап-ак кәфенгә төрелгән Флүрә күз алдыма килеп, бугазыма төер тыгыла иде. Моңлы җырлар җырлаганда күз яшьләремне көчкә тыеп, көчкә түзеп, җырлап бетерә идем.

Бер үлем икенчесен тарта, диләр бит. Бер еллап вакыт узуга 1976 елда башыма тагын зур кайгы килде. Балаларымны карап әйбәт кенә яшәп яткан да, Җыракаем авырып китте дә, урында озак ятмыйча гына вафат та булды. Аның каты авыруын гастрольдә йөргән җиремә телеграмма сугып хәбәр иттеләр.

Мин, гастрольләремне өзеп, Казанга кайттым. Гөлшат Җыракайны карап, врач чакырып, даруларын биреп, балаларны кайгыртып, бездә куныптөнеп ята иде. Җыракай мин кайтып кергәндә, аңында булса да, сөйләшә алмый иде инде. Шулай да мине таныды, бәгырькәем. Күзләрен мөлдерәтеп, миңа карап, нидер әйтмәкче булды, ләкин әйтә алмады, теле юк иде инде. Кулымда җан бирде, газизем. Аның ягымлы йөзендә әнкәемнең сөйкемле чалымнары бар иде. Инде мәңгегә бу чалымнарны күрмәм микәнни дип, үксеп еладым. Җыракаемны бик кадерләп, бөтен шартын китереп, хәер-дога белән җирләдек. Кабере Флүрә янында бер туфракта. Мәрхүмәкәем Җыракай бер дә үләрмен дип яшәмәде. Үлем турында, гомумән, сөйләшми иде ул. Шулай да

бервакыт, Флүрәне җирләп ярты еллап вакыт үткәч, ничектер, үлем турында сүз чыкты да, мин зиратта Флүрәнең кабере янында бер урын калдыртуым турында әйтеп ташладым. Җыракайга бу сүз бер дә ошамады. «Үлә калсам, ул урынга мине күмә күрмәгез тагын, Флүрә белән рәдем ятар хәлем юк!» – дип куйды. Мин сүзне уенга борып: «Нишләп, Җыракай, алай дисең, ир-ат заты түгел бит, үзебезнең хатын-кыз заты!» – дидем. «Юк, юк, Флүрә белән рәдем ятмыйм», – ди бу. Флүрәне яратып җитми иде шул. «Ирсез бала таба, гөнаһлы ул», – дия иде. «Рәдем ятмыйм!» – дигән иде дә, ятты шул. Флүрә янына куймыйча, ничек аны башка җиргә куйыйм? Хәер-сәдака биреп, берьюлы икесенә дә дога кылып, ике кабергә яшем түгеп, ел саен зиратка барып кайтам. Икесенең каберенә бергә бик әйбәт итеп таш куйдырдым. Флүрәнең балалары әниләренең каберенә барып йөриләр.

Җыракайның үлеме мине тагын какшатты. Еш авырый башладым. Көз җитсә, салкын тия, тамак шешә, ангина белән авырыйм. Бервакыт ангина белән авырып ятам, температурам бик югары, тәнем ут кебек яна.

Тамагымнан бер бөртек ризык үтми, хәтта төкерегемне дә йота алмыйм. Авызым ачылмый. Болай гына үтәр дип, врач та чакырмыйм, врач килсә, гастрольләремне өзәр, больничный бирер, дип куркам. Минем, гомумән, больничный алып, концертлар өзеп ятканым юк. Ангиналы килеш гастрольләргә чыгып киткән чакларым да булды. Йөри-йөри үзе бетә шунда. Бу юлысы инде үзе бетәрлек кенә түгел. Нишләргә белми аптырап ятам. Гөлшат килеп керде. Кулына чәй кашыгы тотып, авызымны ачтырды. Тамак төбем күренерлек итеп ачмаганмындыр.

– Җырлаганда авызыңны чабата хәтле итеп ача торган кеше, бөтенләй ача алмый башлагансың, чәй кашыгы да сыймый, үләсең бит, нигә врач чакырмыйсың? – дип ачулана башлады. Җавап бирә алмыйм, авызым ачылмый. Өемдә ул чакта телефон юк иде. Гөлшат ашыгып урамга телефоннан шалтыратырга, врач чакырырга чыгып китте. Бик тиз керде. Врач килгәнче тамагыңны чайкый тор дип, сода салып җылы су бирде. Көчләп диярлек авызны ачтырып, содалы су белән чайката башлады. Авызны көчләп ачтырганга, нәрсәдер тартылып китеп, тамак төбендәге шеш тишелеп, эрен агарга кереште. Врач килеп керде, бу эренне күреп шаккатты. «Бигрәк нык шешкән икән, тишелүе яхшы булган, инфекция керә күрмәсен», – дип, ниндидер дару эчәргә кушты. Ә миңа шул минутта ук җиңел, рәхәт булып китте. Даруын да эчеп тормадым, тазардым.

Бер-бер артлы ике үлем, каты авырулар тәэсир иттеме, минем башымнан мәхәббәт дигән уйлар чыгып, каядыр таралып бетте. Беркемне уйламыйм. Күңелем буш. Юсыф килгәләп йөри, ләкин элеккечә янулар, балкулар юк. Әнисе, туганнары, бик тырышып үгетләп, аны Чаллыга эшкә җибәрделәр. Ул Чаллыда филармония администраторы булып берничә ел эшләде. Әлбәттә, бу безнең араны ераклаштырырга тырышып, Юсыфны миннән читләштерергә

уйлап эшләнгән эш иде. Чынлап та, ераста яшәү – ераста яшәү инде, без бераз вакыт сагынышып, Чаллыда күрешеп, матур итеп очрашып йөрдек тә, Юсыф балалы хатынга (рус хатынына) өйләнеп куйды. Бу хәбәр башта миңа бик каты удар булды. Мин өнсез калдым. Тавышым бетте. Өйләнүен ишеткәч, сүрелә башлаган күңелем яңадан кабынып китте, яндым, көйдем, сыздым. Дуслар, хәтта кызларым да, онытырга тырыш, диләр. Элегрәк елларда бер бик матур җыр бар иде бит:

Һәркем әйтә: «Оныт, башканы сөй,
Ике килмәс безнең яшьлек», – ди.
Йөрәк җавап бирә: «Онытырга
Һичбер вакыт мөмкин түгел!» –

дигән (Ә. Ерикәй шигыре). Нәкъ шул җырда әйтелгәнчә, «Онытырга һичбер вакыт мөмкин түгел!..» Мин онытмадым. Үземне-үзем кулга алдым һәм Юсыфны уйламаска булдым.



1975 ел

Егерме елдан артык бер уйда, бер теләктә, бер сулышта яшәдек. Үкенмим дә, уфтанмыйм да, яраттым, аның мине яратуын белдем, бик күп бәхетле минутлар, сәгатьләр кичердек. Хәзер инде иптәшләр, дуслар гына булып калдык. Очрашканда эчкерсез сөйләшәбез, ләкин сүзебез мәхәббәт, сөю турында түгел, тормыш, эш, хезмәт, иҗат хакында. Аның үз гаиләсе, баласы бар, мин аңар бәхетле тормыш телим. Башка берәүне дә инде мин Юсыфны яраткан кебек ярата алмыйм, мин, гомумән, инде ярата алмыйм.

Минем инде оныкларым үсә. Оныкларымның икесе кыз бала – Иделия, Ләйсән, берсе ир бала – Әскәр. Оныкларым нәселемне дәвам итсен иде дип телим. Оныкларымны бик яратам. Бар тапканым – балаларым, оныкларым өчен. Алар да мине яраталар, «әби» дип өзелеп торалар дип язар идем дә, мин аларга миңа «әби» диеп дәшмәскә куштым шул. Баштарак, «әби» диеп дәшкән чакларында: «Әби, әнә, Баулыда!» – дия идем (Баулыда яшәгән әбисе – кодагыйны күздә тотып). Оныкларым мине «әннә, әннәкә» дип йөртәләр. Шулай иттереп, «әби» диеп әйттерәсе килмәсә дә, әби инде мин... әби... Сәхнә тутырып җырлап-биеп йөргән артисткалар да, вакыты җиткәч, әби булып куя. Бер нишләр хәл юк...

Туганнарым турында язгач, туганнарым кебек дусларым турында да берничә сүз. Минем әле алда язып киткән күпләгән иҗатташ дусларым, Гөлшат, Кәрим, Нажия кебекләрдән башка, тагын тормышта, көнкүрештә дуслашкан бик күп якын рухташларым бар. Алар иң авыр вакытларымда балаларымны карашты. Әбиләре үлгәч, җәйге каникуллары вакытында үзем



Кызым Гүзәл, оныгым Иделия. 1976 ел

Онымым Әскәр белән.
1993 ел



белән гастрольләргә алып чыксам да, кышларын уку чорында аларны өйдә калдырырга туры килә иде. Үз-үзләрен карарлык булып үсеп килсәләр дә, аларга күз-колак булу өчен олы кеше кайгыртуы кирәк. Шундый чакларда профессиясе буенча врач Рима бик ярдәм итте. Гөлсинә инде һәрвакыт минем бертуганым кебек. Мин Казанга килеп ансамбльдә эшли башлаган елларымда ук аның белән танышкан идек. Әле торыр җирем юк чакта, бик интегеп фатир эзләп йөргәндә, ул миңа бер фатир да табышып биргән иде. Шул еллардан алып без – гомер буена якын дуслар. Гөлсинә Сәлахова Буа районының Аксу авылында гади генә колхозчы гаиләсендә туып-үскән, үз тырышлыгы белән университет, аннары аспирантура тәмамлап, биология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ирешкән өлкән фәнни хезмәткәр, лаборатория мөдире. Гөлсинә – гаҗәеп дәрәҗәдә тырыш, үз өстендә күп эшләүче, үз-үзенә таләпчән шәхес. Акыллы киңәшләре белән Гөлсинә миңа тормышта дөрес юлдан барырга ярдәм итә. Сәхнәдә уңышсыз чыгышлар ясасам, халык күңеленә кермәслек җыр җырлап куйсам, таләпчән холыклы Гөлсинә мине әрләп ташлый. Сәхнәгә түше ачыграк күлмәк киеп чыга калсам да бәйләнә.

– Андый әдәпсез күлмәк киеп, халык алдына чыкма! – ди, каты гына итеп.

– Минем декольте күлмәккә бәйләнеп маташасың, хәзер сәхнәгә бөтенләй күлмәксез чыгучылар да бар, – дип, мин каршы төшеп карыйм.

– Син андый адәм актыкларыннан үрнәк алма! – ди Гөлсинә, кырт кисеп. Шунысы аяныч: мин аның киңәшләрен тыңлап ук бетермәгәнмен...

Без – Гөлшат, Гөлсинә, мин – өчебез дә бер-беребезгә тугрылыклы дус-

лар. Теге яки бу кимчелекләребезне, уңышсызлыкларыбызны бер-беребезгә туп-туры әйтеп, үзара тәнкыйтьләшкән чакларыбыз да була, әмма ләкин бер-беребезгә үпкәләшеп, рәнҗешеп йөргән чакларыбыз юк. Гөлшат һәм Гөлсинә дусларымнан мин тормышка җитди карарга өйрәндем. Алар миңа яхшылык үрнәкләрен генә күрсәтте. Язмышымаа рәхмәтлемен – әйбәт дуслар бүләк итте!..

Их дусларым, дусларым,
Дусларым, дус-ишләрем...
Сез дуслардан аерылсам,
Ялгыз башым нишләрем?! –

дип җырлавым иң якын дусларыма Гөлшат белән Гөлсинәгә махсус багышланган кебек.

Тагын бер дустым бар иде, инде вафат булды. Аның белән дуслык кызык кына иде. Дөресрәге, дуслык та түгел иде бугай ул. Ул үзе минем белән дус булырга тырыша, миңа кунакка килергә ярата иде. Алдымда әйбәт кебек иде, ә артымда гайбәтемне сата иде, мәрхүмә. Телгә бик оста иде. Уенын-чынын бер итеп, кешенең кимчелекләреннән мәзәк уйлап чыгарып, көлке итеп сөйләргә ярата иде. Шул мәзәкләрен мәҗлесләрдә, төрле очрашуларда бик оста итеп сөйли иде. Ул мәҗлесләргә күп йөри, нинди мәҗлес, банкет булса, түр башында утыра иде. Сәнгать кешеләре, артистлар, җырчылар, язучылар,



1984 ел

шагыйрьләр, композиторлар белән бик якыннан аралаша, аларга кунакка йөри иде. Китап нәшриятында директор секретаре булып эшләгәч, аңа бичара язучылар, шагыйрьләр, композиторларның йомышы төшеп тора иде, йомышы төшкән кешегә кунакка бармыйча калмый иде. Барган кешеләренең кимчелекләрен, гаепләрен табып, икенче берәүләргә баргач, шуларны мәзәк итеп сөйли иде. Аның сөйләгәннәре телдән-телгә күчеп йөри иде. Аның шул яратып кына сөйләгән шикелле итеп, төрттереп, ирония белән сөйләгәннәрен сәнгать кешеләре әле хәзер дә анекдот итеп сөйлиләр. Кем турында сүз барганын сәнгать кешеләре аңлагандыр инде: бу – Сәлимә. Ул кияүгә чыкмады, шактый олы яшькә җитеп вафат булды, төскә-биткә яшь күренә, матур иде. Минем турыда шактый анекдотлар чыгарды ул мәрхүмәкәем, урыны җәннәттә булсын инде. Минем турымда да яратып кына сөйләгәндер, мин аңа ачуланмыймын, шулай да кайчакта «Сәлимә сөйләде» дип, килеп үземә сөйләсәләр, кәеф киткәли иде. Сәлимә болай сөйли икән: имеш, Әлфия Авзалова белән Гөлшат Зәйнашеваның өчпочмаклары чабата хәтле була. Мичкә тыга торган калайларына сыймыйча, почмаклары белән берсен-берсе сөзешеп, эчләрендәге бәрәңгеләрен, итләрен актарып чыгарып пешәләр, имеш. Шулай шул, без бит Сәлимә кебек уч төбе хәтле генә табага бәләкәй генә өчдүрт өчпочмак ясап пешермибез. Без егермешәр өчпочмак ясап, килгән бер кеше туярлык, Сәлимә килеп керсә дә, минем ятим балалар килеп керсә дә, җитәрлек итеп, мич тутырып пешерәбез. Артымда гына түгел, үз алдымда да рәхәтләнеп миннән көлә иде ул. Бервакыт Мәскәүгә гастрольгә китеп барам. Гөлшат белән Гөлсинә вокзалга озата төштеләр. Вагоннарга кердек. Урнаштык. Өчәү башыбызны тыгып вагон тәрәзәсеннән перронга карап торабыз. Перрон тулы халык. Ашыгып Сәлимә килә. Мине озата төшүе икән. Безне күреп йөгереп килде дә эче катып көлә бу:

– Казанның «өч чибәре» – Әлфия, Гөлшат, Гөлсинә!.. Бөтен вокзалның күзе шушы «өч чибәрдә!...» Өчесен бергә кушып, бер кеше ясасаң, дөньяда иң ямьсез кеше килеп чыгар иде!.. Ха-ха-ха-ха!.. – ди.

Дөрес сүзгә җавап юк! Без – Гөлшат, Гөлсинә, мин – чынлап та чибәрләрдән түгел инде. Чибәрлек өләшкәндә, йөгереп килеп җитә алмаган бәндәләр. Үзе мине озата төшкән, үзе шулай миннән көлә!..

Тагын болай дип сөйли икән: имеш, Казанда күп ашаучы биш кеше – биш бирән бар. Шуларның өчесе – ир кеше: Шәүкәт Капкаев*, Мостафа Ногман, Мәхмүт Хөсәен... Икесе хатын-кыз: Әлфия Авзалова, Гөлшат Зәйнашева... «Күп ашап без нишләгән, симереп юанайганмы? Әле, Аллага шөкер, фигурабыз да ул кадәр безобразный түгел, ашасак, Сәлимәнекен ашамыйбыз бит! Шулай дип әйтегез Сәлимәгә!» – дим килеп сөйләүчеләргә. Ул Шәүкәт Капкаев, Мостафа Ногман, Мәхмүт Хөсәеннән нигә көләргә инде? Ашасалар, ир

* Шактый билгеле һәвәскәр композитор. Кырымда яши, еш кына Казанга килеп, айлар буе торып китә иде.



Эмиль Җәләлетдинов, Венера Шәрипова, Гөлшат Зәйнашева, Усман Әлмиев, мин үзем, Заһид Хәбибуллин, Ирек Галимов, (?). 1973 ел

кеше бит алар! Ашасыннар! Үткәндә аша, диләр бит! Менә хәзер болар өчесе дә вафат инде...

Ул Сәлимә композитор Сара апа Садыйковадан ничек кенә көлми иде. Сара апа үзе дә кызык кеше иде, әлбәттә. Аның турындагы көлкеләр телдән-телгә күчеп күп йөрде инде. Сара апа бизәнергә бик ярата иде бит. Битен бизәү белән бергә, түшенә, колакларына, муенына төрле бизәнү әйберләре тагарга ярата иде. Сәлимә болай сөйли икән: «Сара апаны күрдем әле, и-и-и киенеп-бизәнеп тә куя инде – эре-эре чәчәкле күлмәк кигән, күлмәгенең итәгендә бәбәй итәк өстенә бәбәй итәк, билбау өстенә билбау бәйләгән, яка өстенә яка, челтәр өстенә челтәр... Колагында озын калай алка, алка өстендә калай клипсы, башында салам эшләпә, эшләпәсенә бер яктан кып-кызыл кәгазь чәчәк, икенче яктан каурый кадаган!.. Муенында зәп-зәңгәр пыяла муенса, муенса өстендә тагын очсызлы җиз-бакырдан эшләнгән чылбыр!..» Сара апа гади генә, тыйнак кына гомер итте, чынлап та, алтын-көмешләргә күмелеп йөрмәде. Аңа акча шулай гади генә әйберләр белән бизәнеп йөрерлек кенә кергәндер шул. Аңардан нигә көләргә инде?.. Сәнгать кешеләреннән көлеп сөйләп йөрү рәхәтлек биргәндер инде, ни хәл итәсең.

Танылган шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановларга да (хәзер Рәшит үзе дә вафат инде, үзен дә сагынып сөйләргә генә калды) килеп йөргән бу. Бер елны

Рәшитләрнең бәби алып кайтканын ишеткән дә, «Бәби котларга киләм!» – дип шалтыраткан. (Шулай «Мин сезгә кунакка киләм!» дип шалтыратып килә торган иде ул.) Рәшитнең хатыны Луиза, теш врачы, бик уңганбулган хуҗабикә, тиз генә пилмән бөккән, табын әзерләгән. Якташлары Асия дә килеп кергән. Сәлимә, гадәттәгечә, нәшриятта яңа гына «табадан төшкән» бер китап тотып, бәби котларга килгән. Ашаганнар, эчкәннәр, шау-гөр килеп утырганнар. Кайтыр вакыт җиткән. Асия белән Сәлимә саубуллашып чыгып киткәннәр. Лифтта төшеп барганда, Сәлимә Асиягә әйтә икән: «Кара әле, боларның бәбиләрен җен алыштырган бит!..» Шулай бу Әхмәтҗановларның балаларын җен алыштырган, дип кеше саен сөйләп йөргән. Бу сүз Әхмәтҗановка да килеп ишетелгән. Берничә ел узгач, бала бик матур булып үсеп килгәндә, Сәлимә тагын боларга кунакка килеп чыккан. «И-и-и, балагыз бик матур булып үсеп килә икән!» – дигән бу. Рәшит аңар: «Менә син җен алыштырган дип сөйләп йөргән бала инде бу», – ди икән. Сәлимә, күзен дә йоммыйча, болай дигән: «Ул чакта җен алыштырган иде шул, җен алыштырган иде... Значит, яңадан адәм кыяфәтенә керткән!..». Бервакыт Рәшитнең үзен кунакка чакырган бу. Өстәлгә ризыклар куя-куя сөйләнә икән: «Менә бу тавык шулпасы... Кичә тавыгын Әзһәр* ашаган иде... Шулпасы калды... Сиңа насыйп икән, әйдә, аша әле...». Рәшит, шулпага карап торган да:

– Син нәрсә, мине калдык-постык шулпа ашап утырырга ач дип уйладыңмы?.. Тавыгын Әзһәр ашаган, шулпасын Рәшит чөмерсенме? Юк инде, рәхмәт! Сәлимә, бигайбә!.. – дигән.

– Утиль-сырье җыя торган оешманың гына булса да директоры бул, шул чакта сиңа да тавыгы булыр!.. Ә болай син кем? – ди икән Сәлимә, бот чабып көлә-көлә!..

Дөнья булгач, шундый дусларың да була икән.

Ә менә Зөләйха дустымның дуслыгы – йөрәккә ял бирә торган, кешене юата торган матур дуслык. Ул инде төрттереп сөйләшми, синең кимчелекләреңне күрсә дә күрми. Аның белән эчкерсез сөйләшеп, серләшеп була. Ул инде алдыңда бер төрле, артыңда икенче төрле сөйләп йөрми. Мин кайчакларда концертлардан кайтканда, төннәрен бик соңга калсам, шәһәр үзәгендә яшәүче Зөләйхаларга кереп кунып калам. Ерак гастрольләрдән кайтканда да үземнең өйгә кайтып җитә алмыйча, кара төн уртасында уятып кереп, Зөләйхаларга кайтып егылам. Ул мине, бертуганын каршылагандай, ягымлы итеп каршы ала. Йомшак тавышы, тәмле теле белән җанны назлый, аның өендә үз өеңдәге кебек ял итәсең. Озак еллар Академия театрында тавыш операторы булып эшләгән Зөләйханың өендә бик күп сәнгать кешеләре, артистлар була, ул артистларның якын дусты, һәркемне туганыдай кабул итә.

---

* Әзһәр Хөсәенов озак еллар Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры булып эшләде.



Үзбәкстаннан иптәш кызым Мөнәвәрә белән. 1972 ел

һәркемгә ачык чырайлы, ягымлы. Хәзинәсендә бары белән табынын әзерләп, чәен эчереп, кунак итә.

Дусларым турындагы бу бүлектә халкыбызның бик күркәм кешеләре – гастрольләрдә йөргәндә өендә кундырып, үзләрендә кунак иткән меңләгән фатир хуҗаларым турында язасым килә. Татар халкы кунакчыл дигән борынгыдан килгән сүзнең тирән мәгънәсен миннән дә ныграк белүче бар микән?.. Без, артистлар, гастрольләр вакытында кунакханәләрдә кунып торып эшләсәк тә, бик күп төбәкләрдә район үзәкләрендә, бигрәк тә авылларда – кешеләрдә фатирларда кунып чыгабыз. Минем шундый үзләрендә фатирда кундырып, кунак иткән меңләгән дустым бар. Бертуганы кебек якын итеп, үзләрендә кундырып, сыйлап, кунак итеп, мунча кертеп хөрмәт күрсәткән бу дусларыма мин мең рәхмәтлемен! Кайбер җирләрдә минем гастрольгә килүемне ишетеп, мине каршы алып, үзем сорамас борын мине өйләренә алып кайтып кунак иткән якын дусларым бар. Мәскәүгә барсам – Вәлидә, Уфага барсам – җырчы Флера Ногманова, Ташкентка барсам – Мөнәвәрә, Гөлстанга барсам – җырчы Разыя Гайнуллина, Ижауга барсам – Шамил, аның сөйкемле хатыны Рәзилә, Кукмарага барсам – Гөлсирә белән Нәсимә, Минзәләгә барсам – артистка Венера, китапханәче Гөлшат, Әгерҗегә барсам –

бертуган Закировлар, Исәнбайга барсам – Бания, Балык Бистәсенә барсам – Сания, Гөлшат... Фатирларда кунак иткән дусларымны санап бетергесез. Тәмле ризыкларын пешереп, кунак итүче йөзләгән, меңләгән ханымнарның нурлы йөзләре берәм-берәм күз алдыма килә. Күп кенә фатир хуҗалары әгәр бу китапны укый калсалар, минем исемемне телгә алмаган димәсеннәр, аларның барысын да санап бетерергә мөмкин түгел. Алар барысы да – хәтерем түрендә!..

Мин аларда үземне туганнарымда кебек хис иттем. Арып-талып юлдан килгәч, төннәрен концерттан кайткач, тәмле ризыкларын ашап, чиста урын-җирләрендә йоклап ял иттем. Кайбер фатир хуҗаларында концертлардан кайткач, сөйләшеп, табын янында җырлашып, таңга кадәр гөрләшеп утырган чаклар да була. Күңелле, бик күңелле халкыбызның шундый кунакчыл булуы. Әлбәттә, дөнья булгач, төрлесен күрәсең, шундыйрак фатир хуҗалары да очрый: артистлар килде дип, алар бик өзгәләнми. Тормышлары нык булса да, табыннарына ризыкларын чамалап кына куя. Бер авылда шулай бер фатирга керттеләр. Ялгыз ханым. Ферма мөдире булып эшләп, пенсиягә чыккан. Йорт-җире бик нык, өендә җиһаз чит илдән кайтартылган. Өр-яңа холодильнигы эшләп тора. Ачып карамадык-каравын, хуҗа ханым үзе ачкан арада күз төште, холодильник ризык белән шыплап тутырылган. Күренеп тора, тормышы бай. Ләкин үзе саран булса кирәк, безгә самавыр куйды, чәй кайнатты,



Уфа. 1988 ел



Кызым Гүзәл, оныкларым Иделия һәм Әскәр белән. 1993 ел

өстәленә ипи заты да куймады. Шикәр, май турында әйтмим дә инде. Бу 70 нче елларда булган хәл, ашау-эчү яклары яхшы, мул заман. Хуҗа ханымның шундыйрак икәнен сизгәч, мин үзем белән йөртә торган чәй-шикәрләремне өстәлгә куйдым, чәйнеккә чәемне салып пешердем. Башка ризык затым юк. Хуҗа ханым әйтеп куйды: «Сез үзегез белән ипи алып йөрмисезмени?» – ди. Мин: «Юк шул, урманга утын төяп бармаган шикелле, авылга ипи алып килмәгәниек», – дидем. Концерттан соң, мин бу хуҗа ханымга кайтмадым, әлбәттә. Мине бик юмарт, бик ягымлы апа үзенә алып кайтып китте.

Без артистлар саран хуҗаларга юлыксак, хуҗаларга сиздермичә генә болай сөйләнәбез: «... Сарански шәһәрендә гастрольдә йөргәндә... Сарански станцада...» һәм артист халкы бер-беребезне бик тиз аңлап алабыз, димәк, бу фатир хуҗалары сарански... башка фатир кararга кирәк... Әмма минем үземә мондый «сарански» хуҗаларда бик аз кунарга туры килде. Минем хуҗаларым юмарт, кунакчыл булды.

Фатир хуҗаларыма бәйләнешле бик күп кызык хәлләр истә калган. Бер җәйне шулай Әгерҗе районы буйлап йөрибез. Җәйге матур көннәрдә авыл һавасы суласыннар дип, Җыракай да балаларсыз торып, бераз гына тын алсын дип, ике кечкенә кызым Гүзәл белән Зөлфияне, Флүрә сеңелемнең кызы Светлананы да үзем белән алган идем. Ул елларда без – артистлар, күбрәк ачык машинада – йөк машинасында йөри идек. Менә инструменталь ансамбль егетләре, өч кечкенә кыз бала белән мин, машина кузовына төялеп, бер авылга килеп кердек. Бер йорт каршысына килеп туктадык. Мин машинадан сикереп төштем дә кызларымны күтәреп төшерергә керештем. Җәй буена авылларда йөреп, кызларым да, үзем дә кояшта янып кап-кара булганбыз. Без килеп туктаган йортның тәрәзәсе ачылды да, бер хатын аннан башын чыгарып, урамда уйнап йөргән кызына:

– Кызым, чегәннәр килде, керләрне җыеп алып кер! – дип кычкырды.

Мин көлеп җибәрдем:

– Апа, чегәннәр түгел без, артистлар! – дим.

– Артистлар булгач, бигрәк тә инде, керләрен генә түгел, бавын да алып керергә кирәк! – диде апа, әллә чынлап, әллә шаярып.



Сажидә кызы Зөлфия белән, мин үзем, Мөнәвәрә, кызым Зөлфия. 1970 ел

Шаярып әйткәндер, концерттан соң шушы апа безне үзенә фатирга алып кайтып китте. Хәзинәсендә бары белән сыйлады, чиста урын-җирен җәеп яткызды, минем кызларым аның кызлары белән бергәләп, тәгәрәшеп, идән тулып, тәмле итеп йокладылар. Бу «чегән» вакыйгасын сәнгать кешеләре артистлар тормышыннан булган бер мәзәк итеп сөйләп көлешәләр.

Ә бер елны Алексеевский районында йөрибез. Бер керәшен авылына килдек. Мине фатирга бер ялгыз хатынга – керәшен хатынына керттеләр. Өрмәгән җиргә дә утыртмый үземне. (Шушы урында әйтеп китим әле, керәшеннәр – безнең иң әйбәт тамашачыларыбыз. Алар концертларны бик яраталар. Концерт вакытында тын да алмый тыңлап, бик тәртипле утыралар). Шул керәшен хатынының чисталыгын күрсәгез: өе ялт иткән, урын-җирләре ап-ак. Мине ничек сыйларга белми бу. Йөгереп кенә йөри. Бик тиз арада самавырын кайнатып, өстәленә балын-маен куйды. Чучка борыны белән майлап, табасын шомарта да, кашык белән камырын салып, газ өстендә генә чыжлата-чыжлата коймак пешерә. Их, дип карап торам табага, чучка борыны белән майламаса, ашар идем дә бит... Күзем белән күрмәгән булсам да ашар идем әле... Шулай уйлап утырам, күземне елтыратып... Ашап булмас инде, мәйтәм... Бик ашыйсым килә юкса... Тәлинкәгә өеп кайнар коймак китерде бу. Тәмле исләр чыгарып кызыктыра, чучка борыны белән майлаган дип тормый икән, коймак – коймак икән... Бер-ике коймак ашадым шулай да... Гөнаһлы булдым инде, дип уйлыйм эчтән... Юк, үтми бит, бүтән ашап булмый... Теге чучка борыны күз алдына килә, кадалгыры... Түп-түгәрәк йомры борын... Чәй эчәм дә чәй эчәм, бик эчәсем килә, сусадым дигән булам... Коймакларың бик тәмле, мәйтәм, әле ашыйсы килми иде, дигән булам, үземнең үтереп ашыйсы килә... Рәхмәт әйтеп, өстәл яныннан кузгалдым. Йокларга яттым, күз алдымда теге чучка борыны, төшкә дә керде, каһәр. Төшемдә баянчыбыз Зиннур Гыйбадуллинны күрдем. Имеш, бер кулына шул чучка борыны, бер кулына коймак тоткан да көлә-көлә ашап утыра...

Икенче көнне башка авылга киттек. Хәтерем ялгышмаса, Тигәнә дигән авылга килдек шикелле. Бу авыл инде – мөселман авылы. Фатирга шулай ук бик сөйкемле, бик чиста бер хатынга керттеләр. Ире тракторчы икән, кырдан кайтып та керми. Бик чибәр ике кыз баласы бар. Өйдә шым гына йөриләр. Өе чиста, матур, мебельләре заманча, күренеп тора, тормышлары ныык, таза, матур яшиләр. Хуҗа хатын бик тиз генә өстәл әзерләде. Без киләсен алдан белгән, мине үзе чакырып керткән, мич тутырып өчпочмак пешергән. Табын тулы өчпочмак, бал, май, каймак... Мин – кичә бер-ике коймак кына ашаган кеше – бик ачыккан идем, бер-бер артлы өчпочмакларны сыпыртам гына. Өчпочмаклары бик тәмле, кетердәп тора... Ашыйсым килгән булуын хуҗа хатынга да сөйләп бирдем:

– Кичә кич тә, бүген иртән дә юньләп ашамадым, чөнки кичә керәшен авылында кундык, хуҗа хатын коймак пешергән иде дә, ашый алмадым. Җан

тартмады, табасын чучка борыны белән майлый, шуны күрдем дә тамактан үтмәде, керәшен – керәшен инде, – дидем, өчпочмакны ашый-ашый.

Хуҗа хатыным егылып китә язды.

– И Әлфиякәем, мин дә керәшен хатыны бит, үткән ел гына бу авылга күчеп килдек, – ди бу.

Мин дә егылып китә яздым.

– Өчпочмактан шикләнмә, сарык итеннән пешердем, ипи тотып ант итәм, кичә генә сарык суйдырдык, ышанмасаң, әнә тиресе бакчада эленеп тора, чыгып кара, – ди бу, көлә-көлә.

Өчпочмак, чынлап та, сарык итеннән пешерелгән иде, тәменнән сизәм, туйганчы ашадым. Көлешеп, рәхәтләнеп табын янында озак утырдык керәшен дускаем белән. Җырлаштык, анекдотлар сөйләштек. Мин аның күңеле булсын дип, мондый анекдот сөйләдем: «Үлеп теге дөньяга киткәч, һәркемнең оҗмахка керәсе килә бит. Менә оҗмах ишеге төбенә урыс килгән. «Кем әле бу!» – ди икән оҗмах ишеге төбендә тикшереп кертеп торучы сакчы. «Урысың», – дигән урыс. «Кер, кер әйдә, ишек төбендә сакта торырсың», – ди икән сакчы. Мари килгән. «Мин – мари!» – дигән мари. Анысына әйткән: «Мари? Бар, бар, керергә ярый!» – дигән. Чуаш килгән. «Кем син?» – ди икән сакчы. «Чуаш, мин чуашың!»... «Кер, кер, табак-савыт булса да юарсың!» – дигәннәр моңа. Керәшен килгән. «Кем әле бу?» – ди икән оҗмах сакчысы. «Керәшен мин, керәшен!» – ди икән керәшен. «Керәсең, безовсәки керәсең!» – ди икән тегесе. Татар килгән. «Кем әле бу?» – ди сакчы. «Татар мин, татармын!» – ди икән татар. «Ботыңнан тотып атармын!» – дигәннәр моңа». И ошады да соң бу



1970 ел

анекдот керәшен хатынына! «Керәшен, безовсәки ожмахка керәсең», – дигәч, соң ничек ошамасын?! Үзе ожмахка кергәндәй шатланды, бичаракаем!

Фатир хуҗаларымның берсендә ничек итеп мунча кергәндәге кызыкны языйм әле. Әгерҗе районындагы әлеге Салагыш авылында күптән түгел генә – 1989 елда гына булды бу кызык. Бригадамда хатын-кызлардан дустым Гөлшат, биюче Гүзәл Вафина бар иде. Олырак яшьтәге бер апага фатиргә кердек. Ишек алларында мунчалары күренә. Көн озын. Эссе җәйге вакыт. «Әйдәгез, мунча ягыйк!» – дидем мин. Гөлшат катгый рәвештә каршы төште: «Әле өченче көн генә мунча кердек бит!» – ди. Мин өзмим дә куймыйм: «Мунча ягабыз, мунча керәсе килә!..»

– Минем мунчага күптән яккан юк шул, анда кыш буе сарыклар яшәде, җыештырган да юк әле, мунчага мине күршеләр чакыра, шулай булгач, үзем якмагач, җыештырмыйм да, – ди хуҗа апа. – Бик мунча керәсегез килсә, әнә күршегә кереп ягыгыз, дияр идем инде, күршеләр эштә инде алар, – ди апабыз.

– Юк, юк, күршегә кереп йөрмибез, мунчаңны үзебез җыештырабыз да ягабыз, сине борчымыйбыз, апа, – дим мин.

– Җыештырсагыз, ягыгыз алайса, – ди апа. Биюче Гүзәл белән ярты көн җыештырдык та яктык мунчаны. Гүзәл көянтә-чиләк белән инештән күп итеп су ташыды. Гөлшат өйдә газеталар укып ятты, җыештырмыйм да, кермим дә ди. «Укымаган газетаңмы? Әйдә инде, әзрәк булыш», – дим мин. Юк, кузгалмый да Гөлшатыбыз. Мунча өлгерде, бик эссе иде. Ләүкәсенә каен себеркесе пешекләү өчен, зур ләгәнгә кайнап торган су салдык. Менә мунчага җыенабыз. Гөлшат кермәс өчен киреләнә: «Аяк тартмый», – ди. «Нинди аяк тартмау инде ул, урманга утын кисәргә бармыйсың бит!» – дим мин. Киттек өчәүләп мунчага. Мин ләүкәгә менеп утырдым. Гөлшат «баш пешә бит» диеп ишекне ачты. Мин җылыны әрәм итмә диеп, ишекне яптырдым. Чынлап та, баш пешәрлек эссе мунча. Чабыныйм дип, кулга себерке алуым булды, «дөберт» итеп ләүкәм җимерелеп, аска мәтәлеп төштем. Өстемә кайнар сулы зур ләгән килеп капланды. Ятам бакалар оясында! Бөтен муеннарым, күкрәгем пешеп чыкты. Акырам-бакырам!.. Гөлшат ачулана-ачулана кайнар себерке белән ләгәнне алды. «Аяк тартмый диеп юкка әйттеммени?» – дип әрли. «Гомергә мунча кермәгәндәй кыландың бит», – ди. Мине тартып торгыздылар, муеннарга, күкрәккә кагылырлык та түгел – пешкән.

– Бүген концерт өзелә инде болай булгач, – ди Гөлшат.

– Юк, өзмибез! – дим мин, батыраеп, – өзмибез!... Ләүкәгә карыйбыз, карыйбыз да шаккатабыз, ләүкә бик искергән икән, стенага беркеткәндә каккан кадаклары гына тырпаеп тора. Күгәреп беткән бу кадаклар шундый озын, егерме сантиметр бардыр. Ничек шул кадаклар миңа тимәгән? Ничек алар минем баш сөякләремне ермачламаган? Ходай саклагандыр. Пешсәм-пештем, тәки мунчага кердем. Өйгә кайткач, фатир хуҗасы:

– Ул ләүкәне ирем сугыштан кайткан елны, моннан 40 еллар элек үк ясаган иде шул, бик иске иде инде ул. Мәрхүмкәем, яңаны ясыйм, ясыйм дип йөрде, ясый алмады шул, үлеп китте, – ди.

Пешкән җирләргә каз мае сөрттек, әзрәк сызлавы басылды, концертны өзмәдек, әлбәттә.

Хуҗа апа чәй янында, көлә-көлә, болай сөйләнеп утырды:

– Әлфия, концертта ләүкәләре җимерелде диеп, минем иске мунча турысында сөйли күрмә инде син, авыл халкы көләр, җимерелеп беткән мунчасына яктырмаса, Салагышта мунча беткәнме, дияр.

– Юк апа, сөйләмәм, – дидем мин.

Концерт барышында ләүкә җимерелеп, бакалар янына мәтәлеп төшүемне кызык итеп бик сөйлисе килде. Сөйләп әллә тамашачыларны бер көлдеримме дип тә уйлап куям, хуҗа апа сөйләмәскә кушкач, сөйләмәдем. Аннары мине Гөлшат бик каты контрольдә тота, концертымда ул катнашса, мин аны-моны сөйләмәскә тырышам, бу юлы да ләүкә хикәятен концертта сөйләмәдем. Инде күптән үткән эш булгач, китапка яздым. Укучым бер елмаеп алсын, дидем.



Мөнәвәрә белән. 1970 ел

Бик күңелле, шаян фатир хуҗаларына да очрыйсың. Бер авылда шулай фатирга бер карт белән карчыкка керттеләр. Концерттан соң ашап, чәйләр эчкәч, әбекәй өенең чип-чиста итеп җыештырылган түр ягына – биек пружиналы караватка бик шәп итеп урын җәйде. Түшәк-ястыклары күпергән, тау кебек. Тышы атлас юрганнары калын, кабарып тора. Түр якта берүзем, патша хатыны кебек, мамык урын-җиргә чумдым. Өе җылы булса да, юрган астына кердем. Әбекәй әйтә:

– Әлфия, рәхәтләнеп ял ит, берүзеңә бер өй, беркем мишәйтләмәс!..

– Үзең кайда ятасың, картың кайда? – дим.

– Үзем әнә кече якта, кухнәдә, карт каравылда ул, фермада куна, – дип әбекәй, утны сүндереп, кече якка чыгып китте, калын ишекне шыгырдатып япты.

Бик арылган, ятам изрәп, шул минутта ук йокымсырап киттем. Инде йоклыйм гына дигәндә, юрганымны кемдер тарта бит!.. Бер тартты бу, ике тартты, тарта да тарта... Йоклап булмый. Кем булыр бу?.. Курка башладым. Йокы качты. Юрганнан тарталар!.. Караваттан сикереп төштем дә, ишеккә йөгердем. Атылып кече бүлмәгә чыктым!

– Әби, берүзең генә ял ит рәхәтләнеп дигән идең, анда кемдер бар! Юрганны тарта!.. Әллә картың кайтып, шаярамы? – дим.

– Юк, юк, картымның алай юрган тартып шаярырлык рәте юк инде..., – ди әбекәй.

– Ә кем тарта соң? – дим.

Әби торып ут кабызды, икәүләп түр якка кердек. Анда да ут кабыздык. Беркем юк.

– Ә-ә-ә-ә, – ди әбекәй, көлеп, – карават астында каз оясы... Каз утыра... Курыкма, ана каз ул, ата каз түгел... Берни эшләтмәс!..

Кайбер авылларда халык авылы-авылы белән шаян, шук була. Бер авылга килеп төштек. Клуб яны тулы халык. Араларында бер дивана бар. Җәйге челләдә башына бүрек, өстенә шинель кигән. Гомеренә солдат булмаса да, сугыш күрмәсә дә, авылда шулай кайбер диваналар шинель, гимнастерка киеп йөри бит. Күкрәге тулы медаль моның. Нинди генә медальләр такмаган?!. Сугыш медальләре, хезмәт ветераны медальләре, этләргә тага торган медальләр... консерв банкасыннан түгәрәкләп ясалган калайлар... Чылтырап тора. Халык шуны сөйләндереп көлешә. Бер чая хатын әйтә моңа:

– Әй чибәр артисткалар килде... Берәрсенә өйлән инде... Кырыкка җиттең, һаман ялгыз йөрисең селкенеп...

– Кайсына өйләним соң? – ди дивана бичара, гөнаһсыз җан иясе.

– Соң кайсына телисең, любоен сайла!.. – ди чая хатын. – Хатының артистка булса, бәхет инде, Казанга алып китә, трамвайда гына йөрерсең...

Без инде боларны тыңлап озак юанмадык. Әйберләребезне күтәреп клубка кереп киттек.

Фатирларга урнаштык. Мин Камәр исемле ялгыз апага кердем. Мунча якты бу. Киттем мунчага. Чишенеп юына гына башлаган идем, кемдер кереп килә. Ишекне бикләп тормаган идем, авылда мунчада кем ишек бикләп тора инде? Ишекне киң ачып, медальләрен чылтыратып, теге дивана килеп керде бит!

– Уф, Алла!.. Нишләп йөрисең? – дим.

– Өйләнергә килдем! – ди бу. – Камәр апа үзем димлим, Әлфия Авзаловага өйлән, әнә мунча керә, янына бар диде, – дип, ишек төбендә басып тора, диванакаем!

– Мин Әлфия Авзалова түгел, мин – мунча пәрие, җен бит!.. – дидем тегеңә.

Куркып чыгып йөгерде. Мунчадан кайтуыма, Камәр апа:

– Кияү егетеңнең котын алгансың!.. Абына-сөртенә өенә йөгерде!.. – дип, бот чабып, көлеп каршы алды үземне.

Дусларым турында язганнарыма йомгак ясап, шуны язам, мин дуслыкка хыянәт итмим, бер дуслашкан кешеләрем белән гомер буе дус булып калырга тырышам. Арада, әлбәттә, Гөлшат белән дуслык – иң ышанычлы дуслык. Гөлшат белән кайчан, кайда, ничек танышып, дуслашып киткәнемне хәтерләмим. Әллә кайчан, Казанга килгәч тә дуслашканбыз... Гөлшат, Сарман якларында туып, Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында



Башкортстанның халык җырчысы Флүрә Ногманова белән. Уфа, 1975 ел

үскән. Балачагы минем шикелле ата-ана тәрбиясе күрмичә, ятимлектә үткән, тормышның ачысын-төчесен күп күргән, иҗат эшләрендә дә төрле киртәләрне җимереп, авырлык белән, сабырлык белән уңышларга ирешкән кеше булганга, безнең язмышлар охшаш, шуңа күрәдер без һәрвакыт уртак тел табабыз. Гөлшат кеше хәленә керә белә, мин нинди генә хәлдә калсам да, аңа мөрәҗәгать итәм, ул үзенең акыллы киңәшләре белән миңа һәрвакыт ярдәм итә. Сәхнә эшемдә ярдәмчем, киңәшчем булган кебек, ул – тормышымда да, көнкүрешемдә дә иң якын таянычым, ярдәмчем. Ул миңа иҗатта, тормышта дөрес юлдан барырга юл күрсәтүчем. Ялгыш адымнар ясамыйча яшәвемдә, сәхнәдәге уңышларымда Гөлшатның тәэсире зур булды. Безнең балаларыбыз, оныкларыбыз да – дуслар. Дөнья хәлләрен белеп булмый, дөньяда үлемкитем бар, кайсыбыз алдан үлсәк тә, балаларыбызны ташламаска, аларга әни урынында киңәшләр биреп, ярдәм итәргә диеп, Гөлшат белән антлар бирештек.

Минем кырык елдан артык сәхнәдә эшләү дәверемдә, Хөкүмәтебез җитәкчеләренең, культура, сәнгать өлкәсендәге, филармониядәге җитәкчеләрнең төрлесен күргән, төрлесе белән эш итәргә туры килде. Үзебезнең Татарстан хөкүмәте җитәкчеләренә минем бернинди үпкәм, рәнҗешем юк. «Миңа юл куймадылар, мине кактылар, суктылар», – дип зарлана алмыйм. Бик тиз арада булмаса да, миңа квартирасын да, мактаулы исемнәрен дә бирделәр. Башка артистлар арасында бу мәсьәләләрдә ким-хур булмадым. Татар артисткасының хәле шул инде, әллә кая сикерә алмыйсың, әлбәттә, русларның минем пландагы артисткалары Людмила Зыкина, яшьрәкләрдән Валентина Толкунова, София Ротарулар чит илләрдә гастрольләрдә йөреп, бөтен дөньяны әйләнделәр. Мин туристлар составында гына үз акчама чит илләргә барып кайттым-кайтуын, гастрольгә мине бер генә чит илгә дә җибәрмәделәр. Бу инде безнең татар артистларын ничек тә дөнья аренасына чыгармаска тырышудыр һәм бу безнең Татарстан җитәкчеләреннән генә торган эш булмагандыр.

Хәер, эш үзебезнең җитәкчеләрдән генә торган чаклар да булды. 60 нчы еллар ахырында безнең Татарстаннан бер төркем сәнгать кешеләрен Финляндия татарлары чакырган иде. Илһам белән мине күргә теләүләрен әйтеп, икебезне чакырып хат язганнар иде. Төркемне шул еллардагы культура министры Булат Миңнуллович Гыйззәтуллин җитәкләде. Булат Миңнуллович минем урынга Опера солисткасы Р.ны алып китте. Минем белән борчагы пешмәс иде шул. Ә Р. ханым белән аңар Финляндиядә сәяхәт бик күңелле булгандыр... Артистлар кайткач, сөйләделәр, Булат Миңнуллович ялгыз гына ямансулап йөрмәгән... Үз илемдә миңа, әлбәттә, кая гына гастрольгә барсам да юл ачык булды, шунысы да шатлык. Республикабызны Ф.Табеев, Г.Усмановлар җитәкләгән елларда да миңа начар караш булмады. Мин рәхәтләнеп чын иҗат атмосферасында эшләдем. Алар җитәкчелек иткән елларга хәзер башкача бәя бирәләр, аларның эшләреннән бик күп гаеп табалар. Кайбер артистлар: «Иҗат

кешеләренә юл бирмәделәр, фәлән-төгән», – дип, аларны нык тәнкыйтьлиләр. Бездә бит шундый гадәт: власть башында утырган чагында бик дус булып, бергә әвәрә килешеп йөргән кешеләр, җитәкче абзый урыныннан төшкәч, аны хурлап, мыскыллап сөйләргә яраталар. Мин үзем ул елларда миңа Хөкүмәт җитәкчеләре яхшы карады, миңа үсәргә мөмкинлекләрне тудырды дип уйлыйм һәм Фикрәт Табеевка, Гомәр Усмановка да, шулай ук озак еллар идеология эшен җитәкләгән Рәис Беляевка, Мансур Хәсәновка да күңелемдә ихтирам саклыйм. Дөрес, олы җитәкчеләрнең ярдәмчеләре бар бит әле, алар арасында юкка-барга бәйләнеп, гаеп табып, обкомга чакырып кыздыручылар булгалый иде. М. Вәлиев шундыйларның берсе иде, мәрхүм. Бу дөньядан күптән түгел генә китеп барды, урыны җәннәттә булсын, мине берничә рәт обкомга чакырып: «Нигә теге җырны җырлыйсың, нигә бу җырны җырламыйсың?» – дип, һәм башка гаепләр табып, ачуланган иде. Бервакыт, мәрхүмкәй, мине обкомга чакыртып китертте. Бик ягымлы, елмаеп кына сөйләшә үзе. «Нигә чакыртты икән?» – дип, куркып кына утырам. Хәл-әхвәл сорашты бу матур гына итеп. Аннары җайлап кына болай ди:

– Әлфия ханым, Сез инде – безнең күз өстендәге кашыбыз. Сәхнәбезнең йолдызы! Сезнең турыда кайгыртып кына яшибез...

(Мин шатланып куйдым, әллә, мәйтәм, мактаулы исем бирәп, дәрәҗәмне күтәрергә җыеналармы? Әллә берәр бик шәп, үзләре яши торган йортлардан, Мәскәү, Ленинград планировкалы квартира бирәләрме, «хрущевка»да гына яшәтмик әле, рәхәтләнсен «туалеты аерым» квартирада диеп, минем турыда кайгыртамы әллә диеп, елмаеп утырам...)

Вәлиев агаем сүзен дәвам итә:

– Сез бер дә үзегезне сакламыйсыз икән... Тавышыгызны саклыйсы урынга, Сез, киресенчә, тавышыгызны бетерергә...

Мин түзмәдем, аның сүзен бүлдем:

– Нәрсә әйтергә җыенасыз? Тавышымны бетерер өчен эчәм, шулай диярга уйлыйсызмы?

Минем бу сүзләремнән бик уңайсызланган кыяфәткә кереп, ык-мык итте дә, Вәлиев сүзен болай дәвам итте:

– Юк инде, Әлфия ханым, алай ук дип әйтергә не смею, потому что минем сезне исерек килеш күргәнем юк... Кайбер кешеләр шундыйрак сүзләр әйтәләр... Сезгә тавышны сакларга кирәк... Әнә безнең Фәхри агай Насретдинов... Менә, ичмасам, җырчы!.. Менә ул инде үзен саклый белә!.. Аның кебек тавышын саклаучы артист бүтән бездә юктыр... Ул эчми, тартмый... режим белән генә ашый, режим саклап кына яши... Тамагын кадерләп, саклап кына йөри, ул инде сентябрь аенда ук авызын йон шарфы белән каплап, тавышын җил-яңгырдан саклый. Шуңа күрә аның тавышы бервакытта да бетми... Ул безнең классик тенор!.. 70 яшьтән узды, ә ничек яхшы җырлый!.. Үзен ничек егетләрчә тота!..

Минем ачуым килде:

– Дөресен генә әйтимме? – дидем. – И-и, җитмештән узгач, чалбар төбең тез астыңа асылынып төшкәч, җырласаң ни дә, җырламасаң ни!.. – дидем.

Вәлиев тәрәзә янына китте, кет-кет көлә, көлүен миннән яшермәкче, урамга карап тора. Олы җитәкчеләрнең ярдәмчеләре бит алар ул елларда, шулай безне кыздырырга яраталар иде. Ә үзләре шыпырт кына яшь артистларга гашыйк булып йөриләр...

Ә хәзер, соңгы еллардагы Хөкүмәт җитәкчеләре – бөтенләй башка кешеләр. Аларның күңелендә артисткалар белән буталу кайгысы түгел. Алар халык тормышы турында кайгырталар. Иң югары дәрәҗәдәге җитәкчеләр дә, аларның ярдәмчеләре дә, артистларга вак-төяк бәйләнеп, вакытларын әрәм итмиләр. Бигрәк тә безнең Президентыбыз Минтимер Шәймиев, чын мәгънәсендә, олы җитәкче. Ул республиканы мөстәкыйль дәүләт итү өчен көрәшә, халыкның тормышын яхшырту турында кайгырта. Хәзер, гомумән, обкомга чакырып кыздыру кебек гадәтләр бетте. Мин үзем Хөкүмәтебезнең бүгенге җитәкчеләреннән бик канәгать. Шәймиев, Мөхәммәтшин (Сабировы да шулай булды) – барысы бергәләп бер теләктә эшлиләр, берсе дә миңа начар карашта түгел.

Бигрәк тә Шәймиев миңа яхшы мөнәсәбәттә. Нинди үтенеч белән мөрәҗәгать итсәм дә, үтенечемне аяк астына салмый, һәрвакыт ярдәм итә. Миңа гына түгел, башка артистларга да, гомумән, бар халыкка яхшы, уңай булсын өчен тырыша безнең Шәймиевебез. Замана болганчык, авыр булса да Шәймиев, халык өчен зур эшләр башкара. Совет власте чорында манаралары киселгән, җимерелеп беткән күпме мәчетләр торгызылды, күпме яңа мәчетләр салынды. Шәймиевнең турыдан-туры фәрманы белән, гомер буена сасып яткан, чүп чокырына әйләнгән Болакка тиз вакыт эчендә реконструкция ясалды, Казан урамнары төзекләндерелде, башкалабызга ямь керде. Хан заманыннан бирле җимерелеп яткан ипподром яңадан төзелде. Шәймиевнең мондый эшләрен санап чыгу минем вазифам түгел, сүз иярә сүз чыккач кына әйтүем. Хәзерге җитәкчеләр ижат кешеләре арасында, бигрәк тә артистлар арасында төрле интригалар тудыруларга юл куймый торган, чын эш белән мәшгуль кешеләр. Их, минем яшь чакларымда бүгенге җитәкчеләр кебек җитәкчеләр булса иде!.. Моннан бер ун ел элек кенә шундый җитәкчеләр булган булса да, минем ижатым тагын да ныграк үскән булыр иде дип уйлаган чакларым бар. Моннан ун ел элеккеге җитәкчеләр үзләренең ярдәмчеләренә бөтен ижат кешеләренең язмышын тапшырып, читтәрәк калырга ярата иде. Моннан ун еллар чамасы элек мондый хәл булды. Татарстанның бик күп сәнгать эшлеклеләре, шул исәптән, бик күп җырчылар Кара-Калпак автономияле республикасына әдәбият-сәнгать декадасына барды. Кайбер җырчылар аннан «Кара-Калпакның атказанган артисты» дигән мактаулы исемнәр алып кайтты. Шул көннәрдә мин дә, йөз көн йөреп, озакка сузылган авыр гастрольдән кайткан идем. Филармония кассасына зур керем алып кайт-

кан көннәрем иде. Концертларымны алып баручы нәфис сүз остасы Нәҗия Минкина белән, уңышлы гастролебездән соң, Кара-Калпакка барырбыз дип бик өметләнгән идек. Ләкин безне анда алып бармадылар. Нәҗия белән бик гарьләндек, бик рәнҗедек. Безне шундый зур, матур тантанага барудан мәхрүм иттеләр. Мәңге онытасым юк шул рәнҗетүләрен. Моны, әлбәттә, обкомның беренче секретаре түгел, аның ярдәмчеләре шулай эшләде.

Минем озакка сузылган сәхнә гомеремдә филармониядә дә биш-алты директор эшләп алды. Филармония җитәкчеләре арасында да элегрәк елларда юкка-барга бәйләнеп, төрлечә аптыратырга сәбәпләр табып, җанга тиюче директорлар, художество җитәкчеләре булып алды. Арада эшлекле булулары белән бергә, кешелекле булган җитәкчеләр дә бар иде. Милләте белән рус булса да, татар сәнгатен яратучы Михаил Федорович Боголюбов, сәнгатькә гашыйк, җырчыларның барысына да тигез карарга тырышучы Хәят Әхмәдишевна Калинина, үзе дә шигырьләр, җырлар язучы, сәнгатьне яхшы аңлаучы Марат Абдрахманович Тажетдиновлар директор булган елларда мин рәхәтләнеп эшләдем. Алар миңа тиешле шартлар тудырды, ижатыма ярдәм итте. Бүген филармонияне җитәкләгән Әсгать Сафин да миңа әйбәт карашта. Үзе озак еллар сәхнәдә биегән артист булгач, ул артистларның хәлен аңлый, ә инде шәхсән минем үземә һәр эшемдә ярдәм итә. Әсгать Сафин артистлык хезмәтенең соңгы елларында минем бригадада эшләде. Яхшы биюче булуы өстенә, административ эшләрне яхшы белүче, оста оештыручы да иде. Минем бригададан пенсиягә китте. Оста оештыручы булгач, озак кына директор урынбасары булып эшләде, шуңа күрә аның филармония директоры булып китүе очраклы хәл түгел.

Татар сәнгатен белмәгән, аңламаган, яратмаган директорлар, художество җитәкчеләре дә эшләп китте безнең филармониядә. Ул вакытта обком кемне кирәк тапса, шуны җитәкче итеп билгели иде бит. Андый җитәкчеләр белән эшләү авыр иде. Алар синең ижатыңа ярдәм итәсе урында, төрлечә синнән гаеп, табып, кимсетәләр, иркенләп эшләргә ирек бирмиләр. 60 нчы елларда күбрәк халык көйләрен җырлаучы җырчылар Зифа Басыйрова, Габдулла Рәхимкулов кебек артистларга кайбер музыка белгечләре (бигрәк тә бик күпне белә торган Зәйнәб Хәйруллина) кимсетеп карыйлар, төрлечә бәйләнәләр иде. Зифа апаны «Өй артында шомыртым»нан артык җыр җырламый, дип хурлыйлар, профессиональ яктан югары түгел, дип аптыраталар иде. Фәйзи Биккинин, Зифа Басыйрова, Габдулла Рәхимкулов кебек танылган артистларга «профнегодный» дигән бер ярлык тагарга, аларны художество советлары утырышларында хурлап сөйләп, сәхнәдән төшерергә тырыштылар. Бигрәк тә партиясез артистларга бәйләнәләр иде. Бу җил миңа да кагылды, миңа да «профнегодный» дигән бәя бирергә, кимсетергә омтылдылар. Ләкин мин бирешмәдем. Яңадан-яңа җырлар өйрәнеп, репертуарымны тагын да баетып, үз өстемдә эшләп, үземә андый бәя бирүләренә юл куймадым.

Зифа апа кебек халыкчан планда җырлап, халык күңелен яулаучылар, халык мәхәббәтен казанучыларга ул елларда бик авыр булды. Меңләгән тыңлаучылар моны белми, ә без – җырчылар, бу хәлгә аптырый идек. Мәрхүмә Зифа апа халыкның зур мәхәббәтен казанса да, «Татарстанның атказанган артисткасы» дигән исем белән генә якты дөньядан китеп барды. Ә ул халык артисткасы дигән зур исемгә бик лаек иде.

Күптән булып үткән бу хәлләр турында мин искә дә алып тормас идем, китапны укучыларга шуны әйтәсем килә: артистлык хезмәте бик авыр хезмәт. Артист ул үзе куйган максатка хәтфә палас җәелгән шома юлдан җиңел генә атлап, кәеф-сафа корып кына бармый, күп авырлыкларны җиңеп, күп михнәтләр чигеп, күп гайбәтләр ишетеп, тырыш хезмәте белән бара, зур уңышларга зур кыенлыклар җиңеп ирешә. Мине дә җиңел генә ирешкән икән бу дәрәҗәләргә, дип уйламагыз.

60 һәм 70 нче елларда аноним хатлар язу, шул хатларга ышанып, кеше язмышларын хәл итү бик киң җәелгән иде бит. Безнең филармониядә дә аноним хатлар язучылар бар иде. Аноним хат язучылар алар, минемчә, көнчел кешеләр. Үзләре ирешмәгән уңышларга син ирешәсең икән, синең өстән аноним хат язарга керешәләр.

Азмыни көнчел кешеләр?! Җырчылар арасында да бар андыйлар. Бер җырчы популярлашып, халык алдында танылып китсә, үзе популярлаша алмаган җырчының ачуы килә, көнләшә башлый, популяр җырчыдан үч алырга, аноним хатлар язып, сәхнәдән төшерергә тырыша. Мине хурлап, миннән төрлечә гаеп табып, филармониягә, Культура министрлыгына, КПСС өлкә



1990 ел

комитетына аноним хатлар яздылар. Эчтәлегеннән, ничек язылуыннан мин ул хатларның кайберләрен кем язганын сизенә идем. Үзе сәхнәдән төшеп баручы, кызганыч бәндәләр (исемнәрен язып тормыйм инде, үзләре белә алар), шулай ялган хатлар язып, мине хур итәргә тырышалар иде. Шушы турыда Илһам Шакиров белән сөйләшә идек тә, Илһам болай дия иде:

– Иҗатың гөрләп торганга язалар, әнә фәлән апа сәхнәдән төште, бүгенге көндә беркемгә дә кирәге калмады. Аның турысында бер дә сөйләмиләр. Сөйләсеннәр, сөйләмәсәләр начар ул...

Аноним-ялган хатлар гына түгел, ул елларда телефоннан ялган шалтыратулар да була иде. Кайвакыт төн уртасында, тәмле йокымны бүлеп, телефон шалтырый. Алып тыңлый башласаң, кәгазьгә язарга җирәнгеч кабахәт сүзләр әйтәләр. «Тамагыңа шеш чыккыры, кадалып кит!» – дип кычкыралар. Кайчакта болай дип тә шалтыраталар: «Шимпанзе, ни хәлләрең бар?» – диләр. Андыйларга: «Хәлләрем әйбәт, орангутан, үзең ни хәлләрдә?» – дип җавап бирәм. Мин дә бит төшеп калганнардан түгел, җавапка кесәгә кермим. Мондый мыскыллауны кем уйлап тапканын да, кем шалтыратканын да беләм. Бу китапны укый калса, үзе аңлар, хәзер ул шагыйрә булып китте, шигырьләр яза. Мин бит кешенең сөйләшүен тавышыннан таныйм, белгечләр «абсолют слух»лы артистка дип бәялиләр мине.

Мине маймылга охшатуларына ачуым килми лә анысы. Үземнең маймылга охшаганымны беләм, маймылга охшыйм, әмма ләкин матур маймылга охшыйм. Маймылга охшый дип тормадылар, яшьлегемдә гашыйк булучылар да, яратам сине, дип өзгәләнүчеләр дә булганын язган идем бит инде. Маймыл дип әйтүләренә исем дә китми. Александр Ключарев яраткан хатын-кызларына гел «маймулка» ди торган иде әле. Бер елны мин Кисловодскига дәваланырга барган идем. Курорт – курорт бит инде ул. Дәваланып кына калмыйсың, ял да итәсең. Кичләрен танцыга да барган буласың. Мин танцыларга йөрергә бик яратмыйм да. Кичләрен вакыт үтсен дип, барган булам. Бер көнне танцыга бардым. Зал тулы хатын-кыз, ир заты бер дә юк. Булганнары да – карт-коры. Утырам. Беркем дә чакырмый бит танцыга. Бер ир адәм чакырды шулай да. Зур гәүдәле юан бер абзый, корсагы «КамАЗ» машинасының тәгәрмәче хәтле. Килде дә бу минем янга:

– Какая хорошенькая обезьяночка! – ди. – Пошли танцевать! – ди.

– Пошли! – мин әйтәм, – хорошенький медведь!.. Рәхәтләнеп көлде бу. «КамАЗ» тәгәрмәче хәтле корсагы селкенми дә. Киттек танцевать итеп.

– Вы – чукча? – ди бу миңа.

– Нет! – дим мин.

– Тогда Вы – якутка! – ди бу миңа.

– Нет! – дим мин.

– Тогда кто Вы? Казачка? – ди.

– Нет! – дим мин.

– Калмычка? – ди.

– Нет! – дим мин.

– Кто же Вы, скажите, пожалуйста! – ди.

– Японка я! – дим мин.

– О, японка!.. Какая хорошенькая японка! – ди бу миңа, «КамАЗ» тәгәрмәче хәтле корсагын терәп. – Скажите что-нибудь по японски? – ди.

– И-и, карт алаша!.. – дим моңар.

– О!.. Какие красивые слова по-японски! – ди бу, шатланып.

Шулай итеп, «японский маймыл» булып йөрдем курортта!..

70 нче елларда республикабызның югары органнарына минем өстән язылган аноним хатлар явып кына торды. Нинди генә пычраклар атмадылар миңа. Эчеп-исереп егылып, концертны өзде дип, Батыевка язганнар иде. Бер көнне филармониягә килсәм, Батыев чакыра, бик тиз Кремльгә – Батыевка бар, диләр. Киттем. Килсәм, Батыевка керергә бик зур чират, сәгатьләр буена көтеп арыган кешеләр утыра. Мине чиратсыз гына кертеп җибәрделәр. Ник чакырды икән дип, куркып кына кердем. Куркырлык та шул, Батыев бит ул!.. Патша кебек. Югары Совет Президиумы Председателе генә түгел, чынлап та, патша шикелле утыра. Бик ачулы. Елмаю дигәннең әсәре дә юк йөзендә.

– Син нишләп эчеп-исереп концертларыңны өзеп йөрисең гастрольләрдә? – ди бу. – Синең өстән бик күп жалоба язалар.

– Минем үз гомеремдә концертны өзгәнем юк. Хәтта авырып, температурам күтәрелеп тә, минем концерт куймый калганым юк, – дим. – Ә эчү турында мине сәхнәдән төшерергә теләгән, миңа каршы кешеләр уйлап чыгара. Жалоба түгел алар, аноним хатлар. Сез шул аноним хатларга ышанып утырасыз, – дим. – Тикшермисез. Менә мин иртәгә үк үземнең бригада артистларын алып киләм сезгә. Сөйләшегез, сорашыгыз: кайчан мин эчеп-исереп концерт өзгәнмен, әйтсеннәр.

Икенче көнне филармония автобусына төядем дә, бригадамдагы бөтен артистларны Батыевка алып килдем. Инструменталь ансамбль солистлары – музыкант егетләр берәм-берәм күз алдымда минем бервакытта да эчеп-исереп йөрмәвем турында сөйләделәр. Мәрхүм Геннадий Кляузов болай диде:

– Әлфия аракы эчү түгел, концерт алдыннан барыбызны да, авызны ачтырып, иснәп тикшереп чыга. Минем эчкәләү гадәтем бар, яшермим, минем хәтта чәчемнән өстерәп, башымны төя-төя кыйнаганы да бар аның... Менә Кәрим Габидуллин безнең бригадага килгәч, Кәрим белән икәүләп, алар шундый тәртип керттеләр, эчеп килсәң, концертка катнаштырмыйлар, бер атналык хезмәт хакын тотып калдырып, эчмәгән артистлар арасында бүләләр...

Бу аноним хатлар буенча кеше язмышларын хәл итүләр безнең илдә озак дәвам итте. Хәзер дә әле аноним хатлар язучылар, шуңа ышанучылар бар. 1980 ел иде булса кирәк, мине Культура министрлыгына чакыралар. Культура министры урынбасары Ренат Харис янына барырга кушалар. Үзем генә

барырга йөрәк җитмәде. Гөлшат дустымнан, бергә барыйк әле, дип үтендем. Татар халкының танылган шагыйре, бик культуралы, интеллигент кыяфәтле, сүзен үлчәп кенә сөйли торган, сабыр холыклы Ренат безне бик яхшы каршы алды.

– Әлфия ханым, нишләтергә инде бу аноним хатларны, сезне пычратырга теләп, министрлыкка да, филармониягә дә язалар... – ди бу.

– Эчә, алкаш ул, сәхнәгә эчеп-исереп чыгып егылды, диләрме? – дим мин.

– Шулайрак язалар шул, – ди Ренат, уңайсызланып кына.

– Сез ышанасызмы шуңа? – дим.

– Эчеп исереп чыгып, сәхнәдә егылгач, концертларны өзү булыр иде бит, концертларны өзгән фактларны язалармы соң? – дип, Гөлшат та сүзгә кушылды.

Ренат Харис катгый итеп:

– Юк, андый фактлар язмыйлар. Мин үзем андый хатларга ышанмыйм. Шулай да кем язганын, ни өчен язганнарын беләсем килә, – ди. – Аноним хатны язучы кеше үз кулы белән язмый, әлбәттә. Кемнәндер яздырта. Шуңа күрә ул хатларның иясен табу кыен. Шулай да сиземләвегез белән кем язганын беләсездер, кемнәрдән шикләнәсез соң? – дип сорый Ренат, безгә карап.

Мин кем язганын, ни өчен язганын, чынлап та, сиземләвемне, кемнән шикләнүемне сөйләп бирдем. Ренат бик игътибар белән тыңлады да, болай диде:

– Чын талантларга дошманнар һәрвакыт булып тора. Алар шушылай итеп талантларны пычратырга тырышалар. Әйдәгез, болай эшлик: сез, нервларыгызны бетереп, бу хатлар турында уйлап йөрмәгез, сәхнәгезне, иҗатыгызны белегез. Ә без бу хатларны ертып, корзинкага ташлыйбыз, – диде дә, әлеге хатларны ертып, өстәл астындагы корзинга ташлады.

Шулай итеп, эт өрер, бүре йөрер дигәндәй, аноним хатлар килә торды, мин үз эшемне белдем, җырымны дәвам иттем. Бер-ике елдан Хөкүмәтебез дә, аноним хатларга карап, кеше язмышларын хәл итмәскә дигән бик кешелекле закон кабул итте. Бу бик вакытлы закон булды, аноним хатларга карап, җитәкчеләребез кеше язмышларын хәл итмидер инде. Шулай да аноним хат язучы дөнья болгаткычлар әле һаман яман эшләрен дәвам итәләр. Хәзер инде алар бу пычрак эшләрен ныграк яшереп эшлиләр, кемнәрнедер сатып алалар, үз якларына аударалар, шул кешеләрнең исем-фамилияләре белән ялган хатлар язуларын дәвам итәләр. Бөкрене кабер генә төзәтә, диләр бит, андыйларны төзәтеп булмый.

Безнең илдә кеше турында яман хәбәр таратыйм, дигән уй белән йөргән бәндәгә бик җиңел: тота да үзе күралмаган кеше турында «эчә» дигән хәбәр тарата. Эчү бездә иң таралган яман гадәт, «эчә» дигәнгә бик тиз ышаналар. «Эчеп егылган» дигән сүздән дә җайлысы юк. 80 нче елларда да бу гайбәтне

миңа ябыштырырга бик тырыштылар, югары органнарга «Әлфия сәхнәгә эчеп исереп чыкты» дип язган хатлар яудырдылар. 70 нче елларда ук сәхнәгә эчеп исереп чыга торган булсам (кайбер хатларда исереп чыгып, сәхнәдә егылды, дигән сүзләр язалар иде), бүген җырлап йөрү түгел, таякка таянган бетәшкән кортка (карчык) булыр идем инде, яки әллә кайчан теге дөньяга киткән булыр идем. Эчкечеләр сәхнәдән бик тиз төшеп кала. Күпме бик шәп тавышлы артистлар бүген сәхнәдән төшеп калдылар. Хатын-кыз бигрәк тә эчү кебек яман гадәткә тиз бирелә һәм кешелеген тиз югалта. Мин, Аллага шөкер, менә шушы яшемә җитеп әле гөрләтеп концерт бирәм, концертларыма тамашачылар теләп килә. Минем эчеп исереп сәхнәдә егыла торган кеше түгеллегемне вакыт бик яхшы күрсәтте, мин үземнең андый гайбәттән өстен икәнлегемне эшем белән исбатладым. Тамашачылар концертларыма теләп килә дигәннән, тамашачыны аны бер килмәсә, концертыңа көчләп тә китертә алмыйсың. Бушлай куйсаң да, килми концертыңа!.. Урамга чыгып кычкырып елап чакырсаң да, килмәскә мөмкин. Бик зур мактаулы исемнәре булган, зур даннары булган популяр җырчыларның да концертларына килмәсә-килми ул тамашачы дигән гажәп кеше. Бүген инде бигрәк тә, билет бәяләре кыйммәт, дөнья көтүләре авыр, тамашачыда концерт кайгысы түгел, аны һич гаепләп булмый, иң яраткан җырчысына гына бара ул.

Кая барыйм, кичен нишлим икән, дигән кайгысы юк аның, кичен рәхәтләнеп өендә, телевизор карап утыра ала ул. Миңа еш кына 40 елдан артык җырлыйсың, арымадыңмы, туймадыңмы, диючеләр бар. Арысам да арымадым... Туйсам да туймадым. Арыдым дип туктап калырга уйлаган чакларымда күз алдыма залны тутырып кул чабып утырган тыңлаучылар килә. Нигә туйыйм, сәхнә бит – минем тормышым, ә тормыштан кем туя? Аннары мине күрергә теләгән тамашачыларым бар бит әле. Алар бит минем концертларыма килә. Менә килми башласалар инде, ул чакта мин туктармын. Әле концертларыма йөриләр икән, димәк, мин аларга әле кирәк. «Кайчан туктыйсың?» – диючеләргә: «Тамашачыга кирәгем беткәч», – дип җавап бирәм.

Шунысы кызык, артист халкы турында сөйләргә яраталар. Чынын да, чын түгелен дә сөйлиләр. Белгәне дә сөйли, белмәгәне дә сөйли. Мәҗлесләрдә артистлар турында сөйләү үзе бер гадәткә әйләнгән инде ул. Артистлар турында тегесен-монысын сөйләп утырсаң, табын ямьләнеп китә бугай, табындагы ризыклар да тәмле тоеладыр. Минем хакта күп сөйләүләрен мин беләм. Бу яктан мин – бәхетле! Яшьрәк чакта ир-егетләр белән йөри дип, сөйлиләр иде. Яшь чагында кем йөрми?.. Артисткаларның язмышы шулай бит инде, озак вакытлар гастрольләрдә йөреп, өендә аз торгач, гаиләсенең рәте булмый, бик сабыр иргә туры килсә генә артистканың гаиләтормышы көйле була. Кайсы ир айлар буена гастрольдә йөргән хатынына тугры булып, өендә шым гына яшәр?.. Мин дә гаилә корып яшәргә тырышып карадым. Барып чыкмады бит. Зөлфиямнең этисе мин озак гастрольдә йөргәндә, бервакыт өйләнеп

1970 ел



йөри икән, кайтып керсәм, вокзалда, каршы алырга төшкән дусларым шушы хәбәрне әйткәч, егылып китә яздым. Шуннан соң инде «күп йөри» дигән сүзнең чыгуы гажәп түгелдер. Йөрмәдем дисәм, барыбер ышанмаслар, йөрдем, әмма ләкин мин беркемнең дә гаиләсен бозмадым. Шушы «күп йөри» дигәннәре югары органнарга да барып җитә иде бит. Аноним хатларда да язалар, «күп йөри» дип Хөкүмәт җитәкчеләренә, министрларга барып сөйлиләр.

Бер елны шулай, 70 нче елларда бугай, мәрхүм Булат Миңнуллович Гыйззәтуллин министр чакта, мине Культура министрлыгына чакырталар. Бик тиз килсен, бик важный мәсьәлә, диләр. Киттем. Матур киендем инде, әлбәттә. Киенергә яратам. Модадан калышмыйм. Монысын үзегез дә беләсез инде, артистка башым белән нигә әле мин ямьсез киенеп йөрим?.. Яшь чак,



1966 ел

дәрт ташып тора. Булат абый миннән олы инде, олы кеше булса да, министр кеше, мәйтәм, яшь, чибәр, матур киенгән артисткаларны яратадыр, күңелендә матур тәэсир калдырыйм әле, дим. (Валлаһи, чын күңелемнән әйтәм, гашыйк итим дигән уем юк, абый итеп, сеңелесе буларак, ошыйсым килә, артистка итеп мине ошатып калсын дип уйлыйм, бәлки, мәйтәм, берәр чит илгә баручы артистлар группасына кушарга уйлыйдыр мине дип тә исәплим. Ул елларда Финляндиягә берничә бригада артистлар барып кайтты, минем дә бик барасым килә иде, җибәрмәделәр.) Килеп кердем Булат Миңнуллович янына, чырае шундый караңгы, йөзенә сукыр лампа яндырып куйганнармыни?.. Матур киенеп, елмаеп килеп кергән артистка басып тормый каршысында, әйтерсең, урамнан кергән бер әшәке хатынны каршылый бу. Шундук җаным сизенде, юньлегә чакырмаган министр. Утыр дип урын да күрсәтми, әкрен генә, ипләп кенә (җырда әйткәндәй), сүз башлады:

– Син нәрсә анда, бик йөри диләр сине, нишләп алай, ирең юкмыни соң синең?.. – ди.

Коелдым да төштем, нәрсә дип җавап биргәнемне дә хәтерләмим.

Минем хакта, уенын-чынын, барын-югын бергә кушып болгатып, гайбәт итеп, аннары анекдот-мәзәк итеп сөйләргә яратучы артистлар мондый уйдырма чыгарганнар. Мәҗлесләрдә һаман әле сөйләп көлешәләр. Имеш, мин Булат Миңнулловичка болай дип җавап биргәнмен:

– И-и, агаем, нишләргә кушасыз соң? Печән ашатып булмый бит...

Бусын арттырып сөйлиләр, андый сүз әйтмәдем. Ул чакларда министр кебек министрга андый сүзне шаярып та әйтә алмыйсың, ул бит шаярганны

аңлый торган кеше түгел иде, мәрхүмкәем, урыны җәннәттә булсын инде, гомергә елмайганы да булмагандыр аның. Елмаймаса да чын булгандырмы, гайбәттерме: чибәр-чибәр артисткалар белән йөри икән, дип сөйлиләр иде үзе турында.

Ниһаять, инде Финляндиягә җибәрергә чакырадыр, дип канатланып барган идем, канатларымны шәлперәйтеп кайттым министрлыктан. Шул «гаебем»не әйтер өчен генә чакырган икән Булат агаем.

Йөрсәм, югары органнарда эшләүчеләр, җитәкчеләр белән йөрмәдем, җитәкчеләр белән йөрде, мактаулы исемнәрен фәлән-фәлән агай белән йөреп алды, дип сөйләмәделәр. Аллага шөкер, мактаулы исемнәремне үз хезмәтем белән эшләп, лаеклы рәвештә алдым, шуңа күрә андый гайбәтләр чыкмады да, алай итеп сөйләмәделәр дә. Утсыз төтен йөрми дигәндәй, бер чыкмаса, бер чыгар иде андый сүзләр, чыкмады, димәк, уты булмаган, шулай булгач, төтене дә булмады. Ә бит, яшерен-батырын түгел, андый хәлләр бар безнең сәнгать дөньясында, кайбер артисткалар мактаулы исемнәрен кайбер җитәкче агайларның куенына кереп тә алгалыйлар. Шуңа күрә кайбер артисткаларыбыз турында шактый тозлы-борычлы сүзләр йөри. Гаепләп тә булмый, мактаулы исемнәрне алулары бик авыр. Соңгы елларда гына кайберәүләр җиңел генә мактаулы исемнәр ала. Бик тиз генә конкурсларда җиңеп чыгып, лауреат булалар, кыйммәтле бүләкләр алалар, кайсы җиңел машина, кайсы бик шәп тун, кайсы япон магнитофоны ала. Безнең заманда, элегрәк диюем инде, конкурста җиңсәң, грамота дигән кәгазь бирәләр иде дә, вәссәлам!.. Миндә ул грамоталар өелеп ята. Ленин башы сурәте төшкән кәгазь белән нишлисең, бүләкмени инде ул?.. Үз гомеремдә сәхнәгә чыгып бер генә җитәкче кеше дә бер генә бүләк тә биргәне булмады. Тун түгел, бүрек тә эләкмәде.

Барысын сатып алдым. Ә менә үз акчама сатып алсам да, сатып алырга да юк әйберләрне табып бирүчеләр, нәрсәдер алырга ярдәм итүчеләр күп булды. Бигрәк тә район җирендәге җитәкчеләр нәрсә сорасам да, кире какмады. Күп кенә район җирендәге элеккеге райком секретарьлары, хәзерге администрация башлыклары тормышымда күп ярдәм иттеләр. Минзәлә, Әгерҗе, Алабуга, Кукмара, Чүпрәле, Чаллы, Сарман кебек районнарның җитәкчеләре миңа бик ярдәмчел булды. Бу районнардагы колхоз рәисләре үзләренең район башлыклары шикелле үк ярдәмчел. Район һәм авыл җитәкчеләре яхшы булган җирләрдә тамашачылар да яхшы күңелле, кунакчыл. Мин бу районнарның җитәкчеләренә, колхоз рәисләренә, тамашачыларына мең рәхмәтлемен! Соңгы елларда бик күп урыннарда яшь җитәкчеләр эшли, яшь җитәкчеләрдән безнең халкыбызның кешелекле, артистларны хөрмәт итүче гаҗәеп мәрхәмәтле уллары бар. Шундыйлардан берничә районның администрация башлыкларына аерым рәхмәт әйтәсем килә. Минзәлә районының элеккеге җитәкчесе Рәшит Хәмәдиев бертуганым шикелле булды. Кайчан барып чыкмыйм, бертуган апасын каршы алган кебек каршы алды, кунакханәсеннән иң яхшы номерын

бирeп, хөрмәт күрсәтте. Нәрсә сорасам, шуны табып бирде. Бервакыт Актанышка кайтышлый гына туктаган идем:

– Әлфия апа, Актанышка кайтырга өлгерерсең әле, Минзәләдә кунак бул, – дип, бер атна кунак итте. Минзәләдә нинди яхшы кием-салым бар, барысын сатып алырга шартлар тудырып, мине баштанаяк киендерде. Йорт кирәк-яраклары сатып алырга ярдәм итте. Сатып алган әйберләрне Казанга алып кайту өчен машинасын бирде. Бертуганың да шулай яхшылыклар эшләмәс. Хәзерге заманда бер риясыз шулай ярдәм итүчеләр бик сирәк. Мин бит аңар бернинди дә яхшылык эшли алмыйм. Яхшылыкка – яхшылык көтеп эшләми, болай күңеле яхшы булган өчен эшли бит ул. Мин аңар гомерем буе рәхмәтлемен. Хәзер инде ул Зәй районын җитәкли. Артыннан Зәйгә дә барырмын инде, дип уйлыйм. Яхшы кешене югалтасы килми икән ул. Рәшит Хәмәдиев сәнгатькә гашыйк кеше. Бигрәк тә җырга гашыйк. Бер очрашуда шулай:

– Әлфия апа, сез яшь чакта бер җыр җырлый идегез, бик матур җыр иде ул. Радиода язмагыз да бар, тик нигәдер сезнең ул җырыгызның язмасын бик сирәк тапшыралар. Гомумән, радио аша бер үк җырларыгызның язмаларын тапшыралар. Менә шул җырны җырласагыз иде, – ди Рәшитем.

– Нинди җыр соң ул? – дим мин. – Исеме ничек?..

– Исемен хәтерләмим, менә мондыйрак сүзләре бар иде аның:

«Кил син, бәгърем, кил син, бәхет кошым...» –

ди Рәшит, җырны әзрәк көйләп.

– Ә-ә, «Бәхет кошым» дигән җыр ул, – дим мин, исемә төшереп. – Зиннур Гыйбадуллин музыкасы, Гөлшат Зәйнашева сүзләре. Әйе шул, бик яратып җырлый идем. Хәзер инде онытыла төшкән, җырлап булмас, дим.

Рәшит, әкияттәге батыр сыман, гәүдәсен турайтты да, үзе җырлап җибәрде:

«Яңгыр көткән иген кыры сыман,
Сагынып көтәм сине зар булып.
Кил син, бәгърем, кил син, бәхет кошым,
Гомерлеккә миңа яр булып...»

Матур тавыш белән, моңлы итеп җырлады, минем күзләремә яшь килеп тыгылды. Менә шундый дустым ул Рәшит Хәмәдиев. Әгерҗе районы администрация башлыгы чагында Нурулла Баһрамов та миңа бик күп яхшылыклар эшләде, күп кенә кирәкле әйберләрне сатып алырга ярдәм итте. Әгерҗе районында җитәкче урыннарда эшләүче бертуган Ренат, Рәсим, Рөстәм Закировлар минем тормышыма, көнкүрешемә кирәкле әйберләр сатып алуда бик күп ярдәм иткән дусларым. Иж-Буби колхозы рәисе Рәсим Закировның,

әйтерсең, мин бертуган апасы: «Әлфия апа, ни зарың бар, нәрсә кирәк?» – дип кенә тора. Чаллыга барсам, КамАЗ җитәкчеләре артистка итеп, кеше буларак хөрмәт итеп, миңа гел яхшылык эшлиләр. «Бөреле» совхозы директоры Азат Җаббаров, Саба урман хуҗалыгы директоры Рәис Миңнеханов, баш инженеры Василлар миңа тормыш-көнкүрешемдә бик күп эшләрне башкарып чыгарга ярдәм иттеләр. Азат Җаббаровның әтисе мәрхүм Галимҗан абый да бик яхшы күңелле кеше иде. Чистайда җитәкче эшләрдә эшләде. Артистларны бик яхшы каршы ала иде. Мин аларны чын дусларым саныйм.

Дусларым күп, барысын да санап бетерү мөмкин түгел. Дусларым күп булганга күрә, сәхнә гомерем дә кырык елдан артып китеп, эстрадада озак эшләгәнмендер. Дусларың булмаса, концерт белән килеп төшкән җирдә кырын күз белән карап каршы алсалар, ничек итеп җырламак кирәк. Дусларның җылы карашын тойсаң гына, рәхәтләнеп җырлап була. Ә мин ул җылы карашны һәрвакыт тоеп җырладым. Зал тулып утырган тамашачылар барысы да дусларым булды. Залдагы тамашачы белән ике арада дуслык булганда, сәхнәдә бәйрәмчә күтәренкелек була. Җыр, музыка яңгырый, тирә-якка моң агыла, күңелләрдә сүз белән аңлатып булмый торган ниндидер бер күркәмлек тантана итә. Җырчының иң бәхетле минутлары барлыкка килә!.. Залда утырган меңләгән кеше күңелен җыр, моң гүзәллегенә, биеклеккә күтәргән тылсымлы минутлар!.. Менә шулай тамашачы белән якын бер бәйләнеш, бербөтен бәхет кичерү өчен артист җанын да бирергә әзер.

Җыр ничек туа? Репертуар ничек барлыкка килә?..

Су буенда берәү җырлый,
үзәкне өзә,
Моңлы җырлар бер могҗиза,
бер могҗиза!

Моңлы җырлар бер могҗиза ул, чынлап та, бер могҗиза!..

Моңлы, чын мәгънәсендә матур җырлар сирәк туа. Еш кына җырның өч авторы була, диләр. Композиторы, шагыйре һәм башкаручысы. Башкаручы турында арттырыбрак әйтәләр, минемчә. Башкаручы автор ук түгел инде ул, шулай да, җыр тугач та аны беренче булып башкарган җырчы җырның язмышында хәлиткеч роль уйный. Нотага композитор тарафыннан язылган җыр әле ул яңа туган бала шикелле. Аның җаны әле уч төбендә генә торган кебек.

Беренче булып аны җырлаган җырчы, чынлап та, аңа җан кертә. Беренче булып җырлаган кеше аның иң кыйммәтле сыйфатларын таба алса, үз йөрәгеннән моңнар кушып җырласа, ул җыр тыңлаучы йөрәгенә барып җитә, озын гомерле була. Күп кенә җырларны беренче булып башкарып, мин аларга җан бирүче ролен үтәдем дисәм, укучыларым мактана бу димәсен, җырчылар барысы да – шулай кайсыдыр җырларга җан кертүче. Үземнең репертуарымдагы дистәләгән җырларны саный алам: «Яшь наратлар», «Ватанымның гади бер кызы мин», «Актаныш таңнары», «Кайтам инде», «Йөрәк сере», «Ник соңладың?», «Тугайларым», «Күл буена килсәң иде», «Яшь гомер», «Сәяхәтче җыры», «Гармунчыга», «Күңелле ял итегез», «Кукмара», «Башкаемны кемгә салыйм таңнарда», «Туй күлмәге», (соңгы елларда чыккан «Туй күлмәге» түгел, М.Имашев музыкасы, М.Шиһапов сүзләренә 80нче елларда язылган җыр), «Бик сагындым, авылым», «Һаман да көтәсең», «Эзләдем, бәгърем, сине», «Сөясеңме дип, ник сорыйсың?», «Безнең күңелләр», «Тамчылар», «Ялгыз җилкән», «Җилләр-җилләр», «Сагыну җыры» (Р. Хәсәнов әсәре), «Тамчы гөл», «Кил, иркәм, кил инде», «Гөлләр иле», «Урамнарда йөрим дә мин» һәм башка шундый җырларга минем ярты җаным кушылган. Бу җырларның күбесенең дөньяга ничек килүе, ничек тууы күз алдымда булды. Музыка авторы да, сүз авторы да, кайбер җырларының каралама вариантын миңа күрсәтеп: «Менә бу урыны ничек яңгырый, болай итеп үзгәртсәк, ничек карыйсың? – дип, минем белән киңәшеп, миннән җырлатып карый-карый эшләде. Бигрәк тә З.Гыйбадуллин, Г.Зәйнашева җырлары шулай туды. Композитор, шагыйрь, мин өчәүләп җырлап карый-карый, бер җыр өстендә атналар буе, айлар буе эшли идек. Кайбер җырларны мин үзем җырлап карый-карый үзгәртеп, соңыннан авторлары белән киңәшә идем, барыбыз бер фикергә килгәнче, җырны әле ашыгып халык алдында җырламый идем. Шулай үзем җырлап карый-карый

бер формага китергән күп җырлар бар репертуарымда. Шундыйлардан бик җитди темага язылган киеренке, ярсулы «Һаман да көтәсең», җылы, ягымлы, лирик җыр «Гөлләр иле», матур ритмик төзелешле, шатлыклы «Тамчылар» һәм башка җырларны мин кабат-кабат җырлый-җырлый, шул җырларга хас төсмерләр эзләп, озак эшләдем. «Гөлләр иле» дигән җырны эшләп йөргән көннәрем бүгенгедәй хәтеремдә. Музыка авторы мәрхүмә Сәлимә апа Шәмсина һәвәскәр композитор иде, грамотасы да бик җиткән булмагандыр инде. Бу җырының нотасын миңа бирде дә, үзе пианинода уйнап, җырлап күрсәтте. Тавышы да бик хөрти иде, мәрхүмәкәемнең. Җыр бер дә күңелгә кермәде инде. Ноталар җыелмасы кебек бик гади генә бер көй. Сүзләрен бик яраттым, җырны җырлыйсы килә. Шуннан Сәлимә апага әйттем:

– Апа, бу җырны җырлыйм мин, әмма ләкин мин аны үземчә, үзем ишеткәнчә үзгәртәм, – дидем.

Җырны алып Гөлшатның бакчасына киттек. Мин бакчаның телефон будкасы кебек кенә кухнясына кереп утырам да, сәгатьләр буе шушы җырны җырлыйм. Матур бормалар кертәм, атна буе шулай җырладым. Кырмыска эшли, чикерткә сайрап утыра, дигәндәй!.. Гөлшат бакча эшләре белән



Өстәге рәттә (уңнан-сулга): Әхмәт Гадел, Фәннүр Сафин, Мөдәррис Әгъләмов, Илгизәр Фазлуллин, Кирам Сатиев хатыны Гөлшат белән. Астагы рәттә: мин үзем, Риф Гатауллин, Гөлзадә Сафиуллина



Рафаэль Ильясов белән. 1970 ел

мәшгуль, мин җырлап утырам. Кайчакта Гөлшатны чакырып, җырны тыңлатам. Ул тыңлый да: «Менә бу төшенә мондыйрак борма керт», – ди. «Юк, – мин әйтәм, – анда андый борма кертсәм, көйгә сыймый, көй бик гади, артык бормаларны кабул итми. Бормаларны чама белән генә кертергә кирәк. Кайбер җырларга күп бормалар кертсәң, көе бетә», – дим. Мин бит бу мәсьәләне теория ягыннан аңлата алмыйм (теоретиклар аңлатыр анысын), мин бу хикмәтләрне күңелем белән тоеп кына әйтәм. Күңелем көйгә кайда нинди борма, нинди бизәк кирәген сизә, тоя. Кирәк түгел бизәкне күңел көйгә көчләп такмый. Шулай эзләнә, кабат-кабат җырлый торгач, «Гөлләр иле» менә бүген радиодан яңгырый торган бер формага, кыяфәткә керде. Минем уйлавымча, гади генә булса да, бу – матур җыр. Мин аны бик яратып башкардым. Гади генә, халыкчан, халык көйләренә тартым. Халык көйләре дигәннән, күп кенә халык көйләрен җырлаганда да, онытылып барган җырларны кабаттан җырлаганда да җырчылар көйгә яңа бизәкләр өсти, яңа бормалар таба. Мин үзем дә күп кенә халык көйләрен кабат җырлаганда, миңа кадәр җырлаган җырчылар керткән бормаларны кабатлап кына калмаска, үзем яңа бормалар кертергә, үз моңнарымны кушып җырларга тырышам. «Сагынам, дускай, илкәйне», «Их, җаныем, суларда», «Актаныш басмалары», «Күбәләгем» «Шахта», «Минзәлә», «Сарман», халкыбызның борынгы җырлары – «Гөлҗамал», «Сәгать чылбыры», «Салкын чишмә», Г. Тукай сүзләренә җырлана торган көйләр – «Әллүки»,

«Зиләйлүк», «Тәфтиләү», башкорт халык көйләре – «Элмәлек», «Гөлнәзирә». Бу җырларны бик күп җырчылар җырлаган булса да, мин аларны кабаттан башкарганда, үзем генә тапкан, үз күңелем генә «әйтеп торган» бормабизәкләр белән җырларга омтылдым. Ничек килеп чыккандыр, тыңлаучылар бирә инде бәяне.

Мин үзем һәр җырчының үз тавышы булырга тиеш, аны беркем белән дә бутарга мөмкин булмаска тиеш, дип саныйм. Үз тавышы, үз моңнары белән җырлаган җырчыларны яратам. Бер-берсенә охшаган тавышлы җырчылар, бер-берсен кабатлаган тавышлар кыйммәтле хәзинә түгел, һәр кошның үз тавышы булган шикелле, һәр җырчының үз тавышы булсын. Бу елларда җыр сөючеләр яраткан бик матур тавышлы ике Зөһрәбез бар безнең. Зөһрә Сәхәбиева һәм Зөһрә Шәрифуллина. Шактый еллар инде бу ике җырчы – халык мәхәббәтен казанган, популяр җырчылар. Ике Зөһрә – ике тавыш. Икесе дә моңлы җырлыйлар. Ләкин һич кенә дә бер-берсенә охшаган тавышлы җырчылар түгел. Икесе дә үзенчәлекле, үз тавышлары белән җырлыйлар. Бер-берсен кабатламыйлар. Бу җырчыларны җыр сөючеләр бер-берсе белән һич тә бутамыйлар. Мин аларның икесен дә яратам, һәр икесе дә көйләрнең бормаларын матур итеп алалар, иң кирәкле җирендә, иң кирәкле төсмер, моңлы бизәк таба беләләр. Алар мине дә, башка берәр җырчыны да кабатламыйлар, аларның үз моңнары бар. Беркемне дә кабатламыйча үз моңнары белән җырлап, халыкның зур мәхәббәтен казанган Хәмдүнә Тимергалиева турында берничә сүз әйтәсем килә. Хәмдүнә киң күкрәктән чыккан көчле тавыш белән халык көйләрен дә, композитор җырларын да үзенә генә хас моң белән башкара. Җырларда аның моңлы бормалары сырлы-мырлы түгел, ясалма бормалар боргалап җырламый ул, аның моңы табигый, үзеннән-үзе килеп чыга.

Соңгы берничә ел эчендә эстрадада Мәскәүдә оешкан «Бәйрәм» ансамбле бик тиз халык арасында популяр булып китте. Аны җырчы Хәния Фәрхи җитәкли. Драма артисткасы буларак (Хәния үзе режиссер) концертларын кызыклы итеп сәхнәгә куя, үзе көйләр, шигырьләр яза. Бу талантлы артистканың йомшак, халыкчан тавыш белән җырлавын тамашачылар бик тиз яратып өлгерде. Хәниянең дә җырларында – үз моңнары, үз йөзе.

Бу артисткаларның халык күңелен яулап алуларына мин шатланам. Безнең эстрада буш түгел, сәхнәгә эстраданы бездән соң дәвам итәчәк талантлы җырчылар килде. Алар мине кабатламыйлар, минем эздән килсәләр дә, һәркайсының үз юлы бар. Алар Гөлсем апа, Зифа апалардан башланган халыкчан башкару традициясен дәвам итәләр. Традиция туктап калмасын, киләчәккә барсын. Шулай киләчәккә барыр, дип ышанам. Бүген эстрадага тагын да яшьрәк буын килә. Арада Зәйнәб Фәрхетдинова үзенең матур тавышы белән аерылып тора. Мин халыкчан планда җырлаучы җырчыларга һәм хатын-кыз башкаручыларга гына тукталдым. Безнең опера җырчыларыбыз ара-

сында да бик шәп тавышлы артисткаларыбыз бар. Алар сәнгатьтә үзләренә аерым бер урын тота.

Ике Зөһрә, Хәмдүнә, Хәния – болар татар дөньясына халыкчан планда язылган күп кенә яңа җырлар тууына үзләреннән зур өлеш керткән җырчылар. З.Сәхәбиеваның «Җидегән чишмә»се, З.Шәрифуллинаның «Су буенда учак яна»сы, онытылып барганнан соң, Х.Тимергалиеваның татар эстрадасына, бик матур аһәңнәр белән баетылып, яңадан кайткан халык көе – «Җомга»сы, Х. Фәрхинең заманча яңгырашлы матур җыры – «Питрәч»е – йөрәк җылысы белән эстрадага килгән матур җырлар. Җыр тууда җырчының роле турында күп язалар, күп сөйлиләр. Безнең татар җырлары өчен генә хас күренеш түгел бу. Башка милләтләрдә дә шулай. Русларның халыкчан җырлау остасы Людмила Зыкина үзе турында язган китабында болай ди: «Яхшы җыр әзер килеш кулга бик сирәк килеп керә...». Дөньяга туган кайбер бик матур рус җырлары Людмила Зыкина исеменә бәйле.

Әйе, яңа матур җырлар сирәк туа һәм яңа җыр тууы җырчы исеменә бәйле. Кайчакларда минем шундый җыр җырлыйсым килә – көе дә, сүзе дә әле язылмаган, ниндидер бик матур, дөньяда юк җырны ишетеп, әкрен генә көйләп йөри башлыйм... Колагыма ишетелә, шул җырны җырлап сәхнәдә басып торуымны тоям, шул юк җырны, язылмаган җырны җырлыйм шикелле... Бу саташу дип уйлый күрмәгез! Юк, бу саташу түгел. Бу – матур яңа җыр җырлыйсы килү... матур җырга сусау... Мондый халәтемне күреп, миңа аптырап карап торганнары бар... Филармониянең художество җитәкчесе композитор Илгиз Мәҗитовка мин бервакыт шулай дөньяда юк җырны рояль янына басып җырлап күрсәттем. Ниндидер көе дә, сүзләре дә бар шикелле... Шуны башкарганда ничек итеп басып торып, нинди хисләр кичереп җырлавымны тасвирладым... Илгиз аптырап карап торды да, рәхәтләнеп көлде. «Бик матур җыр җырлаган образга кердең, бу җырны мин дә ишеттем, сәхнәдә синең шул җырны башкаруыңны мин дә күрдем, – ди. – Син миңа бу кыланышың белән бик матур бер тема бирдең, яңа җыр язачакмын!..» – ди.

Кулыңа яңа матур җыр эләксә, шатлык инде. Ул җырның тууында үзеңнең дә катнашың барлыгын тою – тагын да зур шатлык.

Җырчы кайбер җырларның тууына төп сәбәпче була, яки кайбер җыр туганда, турыдан-туры үзе катнаша. «Кукмара» җырының тууына мин сәбәпче булдым. Кукмара районына концертлар белән еш йөрим. Барган саен тамашачыларның чын мәгънәсендә җыр сөючеләр икәнен күрәм. Концертларыма зал тулып киләләр. Тамашачы яратамы, юкмы икәнен бик тиз сизәсең бит. Кукмарадагы тамашачының үземне яратканын бик нык сизәм. Шулай ук район җитәкчеләре дә, колхоз җитәкчеләре дә хөрмәт иткәннәрен тоям. Аннары Кукмарада Актаныштан ук дуслашкан Нәсимә, Гөлсирә кебек якын дусларым бар. Кыскасы, Кукмараны мин бик яратам. Табигате, ямьле авыллары күңелемә бик якын. Актанышны яраткан шикелле яратам шул Кукмара-

ны. Гел уйлап йөрим, Актаныш турында җырладым, шушы Кукмара турында да берәр матур җыр җырлар идем, дим. Дустым Гөлшат Зәйнашевага бу уемны әйттем: «Кукмара турында бер шигырь яз әле, көен үзем яздыртам. Кукмара турында җырлыйсым килә», – дидем. Гөлшат: «Кукмара турында кемнәрдер җыр язганнар бит, шуны алып җырла», – ди. «Юк, мин әйтәм, кемдер җырлаган җырны җырлыйсым килми, үз җырым булсын иде, минем өчен генә язылган», – дим. Гөлшат озакка сузмады, «Кукмара» дигән шигырь язып, «музыкасын үзең яздыр» дип, минем кулыма тоттырды. Шигырьне укып чыктым да шундый шатландым, шундый шатландым, нәкъ менә мин әйтергә теләгән сүзләр:

Каршы ала, озатып кала
Поездларны Кукмара.
Поездлар ерак китсә дә,
Ерагаймасын ара.
Әй, Кукмара, Кукмара,
Ерагаймасын ара.
Сагынырсың, саргаерсың,
Читләргә китеп кара!..



1975 ел

«Музыкасын үзең яздырырсың» дисә дә, бу эшкә үзем генә алынмадым, Гөлшатны ризалаштырдым, без икәү бергәләп, җырның музыкасын яздыру турында кайгырта башладык: композитор Мәсгут Имашевтан яздыртырга булдык. Мәсгут Казан театр училищесында директор булып эшли. Шалтыратабыз моңар: «Менә шулай, шулай, «Кукмара» дигән җыр язсаң иде, минем шул Кукмара турында җырлыйсым килә», – димен мин, телефон трубкасын кысып тотып. Дулкынланам, мине шул туып килә торган җыр «кысыклый», җаныма тынгы бирми, минем кайнар сулышым белән телефон трубкасы тирләп чыкты. Мәсгут бик тиз ризалашты. Гөлшат белән училищега йөгердек. Мәсгут шигырьне укып чыкты, йөзе балкый, күзләре нурлы, елмаюдан яшәреп китте бу!..

Мин Мәсгуткә: «Менә шулайрак булсын, шундыйрак көй кирәк», – дип, әкрен генә көйли башлаган идем, Мәсгут мине шып туктатты. «Кирәкми, көйләмә, үзем... үзем...», – диде. Бер-ике көннән шалтыратырга кушты. Без Гөлшат белән, кош тоткандай куанып, кайтып киттек. Ике көн үтте микән, Мәсгуткә шалтыратабыз. «Бер көй чыкты, ничек булгандыр, килегез, уйнап-җырлап карыйк», – диде Мәсгутебез, тыйнак кына. Училищега килдек, Мәсгут уйный пианинода, мин шундук җырлый барам, көй күңелгә үзеннән-үзе керә, шундук хәтердә кала – нәкъ мин теләгәнчә, нәкъ мин ишеткәнчә, артык катлаулы да түгел, шулай ук бик гади генә дә түгел, халыкчан, матур, моңлы көй. Тукай сүзләре белән әйтсәк, «нәкъ безнеңчә, милли матур көй...». Гөлшат белән бу музыканы, бу көйне без бик яраттык. Озак җырлап утырдык. Мин инде җырны яттан беләм. Икенче көнне үк концертымда җырладым моны. Шулай итеп «Кукмара» җырының дөньяга килүендә мин турыдантуры катнаштым, шуңа күрә бу җырым үз балам кебек күңелемә бик якын.

Бу – минем үз җырым. Ул җырны бозып җырласалар, рәнҗим кебек, көен дә, сүзләрен дә бер генә дә бозып җырлатасым килми. Үз җырым дигәннән, әлбәттә, үзе беренче башлап җырлап, аңа юл ачкан, җырны дөньяга тудырышкан җырчының теге яки бу җырга «бу минем җырым» дип әйтергә хакы бар. Әмма ләкин җыр инде ул, бер җырлагач, халыкка барып җиткәч, синеке генә түгел. Ул инде очып киткән кош кебек. Шуңа күрә соңгы елларда кайбер җырчыларның «бу минем җырым, син аны нигә җырлыйсың», дип дәгъвалашып йөрүләре миңа ошамый. Әле газеталарда «фәлән җырчы фәлән җырчының фәлән җырын урлаган» дип, бик ямьсез итеп язып та чыгалар. Җырга алай хуҗа булу, минемчә, ярый торган эш түгел. Җырласыннар! Бәлки, синнән дә матуррак итеп җырларлар?.. Матуррак җырлый алмасалар – бигайбә инде, үзләренә үпкәләсеннәр. Мин үз гомеремдә: «Бу – минем җырым, башкалар җырламасын!» – дип йөрмәдем. Мин беренче башлап җырлаган җырларны бик күп җырчылар кабатлап җырлый, җырлый бирсеннәр. Яхшырак җырлыйлармы, начаррак җырлыйлармы – анысы инде миңа кагылмый. Минем анда эшем юк. Мин үзем дә күп еллык сәхнә эшемдә

гел «үземнең җырларны» гына җырлап яшәмәдем. Башкалар беренче булып җырлаган, алар дөньяга чыгарган җырларны да җырладым. Кайвакыт репертуар төзегәндә тематик яктан кирәк була, яки халык нәкъ менә шул җырны башкаруыңны көтеп утыра, хәтта сәхнәгә кош теледәй хат җибәреп, шул җырны сорый, андый чакта минем җырым түгел дип, сәхнәдә үзсүзләнеп торып булмый, һәрвакыт елның иң популяр җыры була. Ул популяр җырны бу аныкы, минеке түгел дип, тормаска туры килә, тотасың да, Аллага тапшырып җырлыйсың. Мин, мәсәлән, Зөһрә Сәхәбиеваның «Җидегән чишмөсе»н сәхнәләрдә бик еш җырлыйм. Чөнки халык сорый. Бигрәк тә чит өлкәләрдә яшәүче тамашачылар «бу җыр аныкы, бу җыр тегенеке» дип уйлап утырмыйлар, шул җырны тыңларга телиләр, акча түләп килгән концертында үзе яраткан, үзе тыңларга теләгән җырны башкаруыңны сорый икән, җырламый хәлең юк.

«Ирне ир иткән дә – хатын, юк иткән дә – хатын» дигәндәй, җырчыны җырчы иткән дә – җыр, юк иткән дә – җыр... Пүчтәк сүзләргә язылган ике-өч нотадан гына торган примитив көйләр җырлап күп йөрсәң, ерак бара алмыйсың. Җырчының матур тавышлы булуы өстенә, җырлаган репертуарының да матур булуы кирәк. Репертуар – җырчының иң-иң зур проблемасы. Яхшы репертуар – ярты уңыш. Ярлы репертуар җырчыны ярлыландыра. Музыкаль яктан профессиональ югарылыкта язылган, яңа интонацияләргә нигезләнгән



Баянчылар Ганс Сәйфуллин һәм Хәйдәр Сафин белән. 1976 ел

җырларны башкару җырчыга профессиональ яктан үсәргә ярдәм итә. Мин, профессиональ яктан үсәргә омтылганга күрә, композитор Рөстәм Яхин әсәрләрен бик еш репертуарыма кертәм: «Күзләрем тик сине эзлиләр» (М. Ногман сүзләре), «Кил, чибәрем» (Ә. Ерикәй сүзләре), «Туган ягым» (Р. Байтимеров сүзләре). Мондый җырлар тавышны баета, диапазонны киңәйтә, һаман-һаман такмак сыман җырлар гына җырлау җырчыны бик очсызландыра, ваклый.

Үткән ел мин радио аша бер тапшыру тыңладым. Француз халкының бөек җырчысы Эдит Пиаф турында иде бу тапшыру. И, сөйләп тә куйдылар инде ул Пиаф турында!.. Аның күкрәк түреннән чыккан куе, калынчарак, әллә нинди матур төсмерләргә бай меццо-сопрано тавышы... Аның төз, зифа буй-сыннары, аның кыйммәтле бәрхеттән тегелгән, билләрен кысып торган матур күлмәкләре, әллә ничә шәһәрдәге бай җиһазлы, җәннәттәй матур итеп төзелгән коттеджлары, шәхси машиналары, шәхси шоферлары... Барысы турында да тыңлап, исләрем, акылларым китеп, уйланып утырдым. Без түгел инде... Талантлы да, байлыгы да бар. Акылы-фигыле дә күркәм булган ул Пиаф дигән мәшһүр җырчының. Җыр, репертуар турында сүз чыккач, ул мондыйрак сүз әйтте: «Җыр җырчыны шәхес итә...» Менә шулай җырчыны шәхес итәрлек җырлар сирәк туа шул. Соңгы елларда бигрәк тә композиторлар нигәдер пассивлашты. Шуңа күрә кайчакта элекке елларда, яшь чакларда җырлаган җырларымны кабат алып репертуарыма керткән вакытларым да була. Шулай соңгы елларда М. Мозаффаровның «Син кайтмадың», «Кайда да йөрәктә» кебек мәңге искермәс җырларын кабат җырлыйм. Әлбәттә, репертуарымда һәрвакыт башкорт композиторлары, башкорт халык көйләре зур урын алып тора. Башкорт җырлары безнең үз җырларыбыз кебек. Көй агылышы, моңнар бер үк. Шуңа күрә гомерем буена башкорт җырларын яратып җырлыйм. Башкортстанга гастрольгә барсам, һичшиксез, яңа җырлар өйрәнеп кайтам. Анда минем композиторлардан Рим Хәсәнов, Тәлгать Шәрипов кебек чын дусларым бар. Тәлгать Шәриповның «Көмеш балдак» дигән җырының язылуы бик кызык кына булды: Уфада концерт бирәбез. Бригадам составында Гөлшат Зәйнашева да бар иде. Концерт беткәч, безнең икебезне композитор Тәлгать Шәрипов өенә кунакка чакырды. Бик тәмле ризыклар белән сыйлангач, кулына баянын алып, Тәлгать безне музыка белән сыйлады. Тәлгатьнең яңа җырларын тыңладык. Әле яза башлаган гына көйләрен дә уйнады. Кайбер көйләренең сүзләре юк икән. Шунда миңа бер көй бик ошады. Борынгы көйләргә тартымрак, киң диапазонлы, матур төзелешле, монлы көй. Кабат-кабат уйнаттым бу көйне. Көй чыккан, сүзе юк. Тәлгать ул көен берничә шагыйрьгә уйнап күрсәткән, шагыйрьләр шигырь язарга вәгъдә дә биргәннәр, әмма ләкин язмаганнар. Әзер көйгә, әзер калыпка шигырь язу авыр шул. Бик сирәк шагыйрь генә бу эшкә алына. Мин үзем матур көйләр отсам, сүз табалмаганда, шагыйрьләрдән сүз язуларын үтенәм, күбесе язмый. Андый чакта

Гөлшат «выручать итә». «Тәлгатьнең бу көенә дә сүз яз!» – дип, Гөлшатка мөрәҗәгать итәм. Ул да көйне яратты һәм «язам» дип вәгъдә бирде. Без Тәлгатьләрдә таң атканчы шул көйләр белән җенләнеп утырдык. Күршеләргә ишетелмәсен өчен, Тәлгать баянын әкрен генә уйный... Мин дә ярты тавышка гына җырлыйм... Таң аткач кына таралдык. Гөлшат кунакханәгә кайткач, бер минут йокламыйча, бөтен дөньясын онытып «Көмеш балдак» дигән шигырь язды, Тәлгатьнең исемсез һәм сүзсез көе – «Көмеш балдак» дигән җырга әверелде. Шулай итеп бер төн эчендә яңа җыр туды. Мин аны бик яратып җырлыйм. Узган яшьлегемә, үземнең тормышыма багышланган шикелле ул җыр. Кызганыч, ул җырны мин, ничектер, радиога барып, магнитофон тасмасына яздыра алмый йөрим. Шуңа күрә, ул җыр күп тыңлаучыларга таныш түгелдер. Сүзләре мондый юллар белән башлана:

Алтын түгел, көмеш балдак кидем,
Борынгыдан калган саф көмеш.
Саф көмештәй гүзәл яшьлек үтте,
Синсез үтте, нинди үкенеч!..

Репертуарымда дөнья халыклары җырлары һәрвакыт зур урын ала. Алар минем репертуарымның матур бер сәхифәсе кебек.

Мин аларны бик яратам. Тамашачылар да яратадыр дип уйлыйм. Шуңа күрә, мин аларның кайберләрен репертуарымнан төшерсәм дә, кайберләрен репертуарымда даими тотам.



1974 ел

Репертуар турында сүз чыкса, кайбер кызыксынучан кешеләр:

– Репертуарыңда ничә җыр бар? – дип сорыйлар. Кем санаган инде аны? Җырлар бит алар җырланалар да, еллар үткәч, репертуардан төшәләр. Элегрәк җырлаганнарын оныта барасың. Репертуар бит ул яңарып тора. Кырык елдан артык сәхнәдә җырлаган җырларның санын исәпләп чыгарыйм дисәң, белмим, ничә йөз җыр җырланган булып килеп чыгар иде икән?.. Меңгә җитәргә мөмкин!.. Нинди генә җырлар җырламаганмындыр инде мин үз гомеремдә?.. Шулай да әле иң матур җыр җырланмагандыр кебек. Алда, киләсе көннәрдә әллә нинди матур җырлар туар, әллә нинди матур җырлар җырлармын кебек булып күңел ашкынып тора, колакка әллә нинди матур аһәңнәр килеп ишетелә. Бу инде матур җырларга туймас күңелнең бер җилкенүедер. Әлбәттә, мин сәхнә кояшымның баеп килүен беләм, әллә нинди яңа матур җырлар җырлап тамашачыны шаккатыралмам инде. Шулай да, өметсез – шайтан гына, диләр бит. Иң матур җырымны җырлыйсы көнем алдадыр шикелле...

Үземнең иҗат гомеремдә җырлаган җырларымны хәзер тыңлыйм да әллә нинди кичерешләргә биреләм. Узган яшьлек елларым, яраткан, газиз кешеләрем, сәхнәдәш дусларым күз алдыма килеп, үзәкләрем өзелеп куя.



Ленинградта. 1980 ел

Күптән түгел генә радио аша үзем яратып җырлаган «Мәхәббәтем» җырын тапшырдылар. Тын да алмый тыңладым, күземә мөлдерәп яшь тулды. Күкрәп үскән агачны тамыры белән куптарып ташладылармыни?

Йөрәгемнән нәрсәнедер тамыры белән актарып куйгандай, әллә нинди хисләр, әллә нинди тойгылар дулкынында калдым. Шул җыр минем бөтен язмышымны тасвирлый шикелле, шул җырда минем узган яшьлегем, мәхәббәтем, мәхәббәтемнән аерылуым, сагышым – барысы, барысы... Шул җырда мин эреп беткәнмен, кеше түгел, җырга әверелгәнмендер кебек тоелды... Шатлыклы да, хәсрәтле дә, сагышлы да бер халәттә калдым, бу халәт көне буена барды, шул җыр мине көне буе эзәрлекләде... Их, дип куйдым, миннән соң килгән җырчылар шул «Мәхәббәтем» кебек җырларны җырласыннар иде, ул җырлар үлмәсен иде, килер көннәргә барсын иде, халкыбыз күңелендә яшәсен иде, дип уйладым. Теләсәләр, яшь җырчыларга шул җырларны өйрәтер идем, яшь җырчылар белән бергәләп шул җырлардагы моңнарны саклап җырлау серләрен ачарга иде. Мәсәлән, Хәмдүнә Тимергалиева ул җырны җырласа, ышанам: ул аның бөтен матурлыгын бирә алыр иде. Бәлки, әле мин ачып җиткермәгән гүзәллекләрен Хәмдүнә ачар иде.

Җырлар, җырлар... Алар да кеше язмышлары кебек, төрле-төрле, катлаулы. Җырлаган җырларым – алар минем язмышларым...

Уңышлардан башым әйләнмәде

Уңышларга ирешмәдем түгел, Аллага шөкер, зур уңышларга ирештем. Татарстанның атказанган артисткасы дигән исемем өстенә тагын 1970 елда – Татарстанның халык, 1983 елда Россиянең атказанган артисткасы дигән мактаулы исемнәр бирделәр. Ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләндем. Инде җиткән иде, тагын да зур дәрәҗәле исемнәр көтми идем, булганына шөкер итә идем. 1992 елны тагын зур дәрәҗәле исем бирделәр – Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге премиясе лауреаты булдым. Халкым да, Хөкүмәтебез дә бик зурлады. Уңышларга ирештем дип, мактанырга һич җыенмыйм. Уңышлардан башым әйләнмәде, гомумән, баш әйләнсә, әйләнерлек чаклар булмады түгел, булды. Әмма ләкин уңышлардан баш әйләнү миңа хас сыйфат түгел. Башлары әйләнүчеләр бар ул. Хәзер эстрадада уңышларга ирешә башласалар, кайберәүләрнең башы әйләнә башлый. Данны күтәрә белергә дә кирәк. Күтәрә белмәсәң, дан кешене киregә, артка таба өстери, яки бер урында таптанып торырга мәҗбүр итә. Мактау сүзләре ишетә башласа, газета-журналларда мактап мәкаләләр язып чыксалар, җырчыларның кайберләре борыннарын чөя, эреләнеп китә. Юк, мин борын чөеп, эреләнеп йөрергә яратмыйм, элек нинди Әлфия булсам, хәзер дә шундый. Шулай булу рәхәт тә...



70 яшем тулганда. 2003 ел

Газета-журналларда минем эстрадада озак еллар эшләвем турында күп яздылар. Үзебезнең республика газета-журналларында, чит өлкәләрнең газета-журналларында, гастрольгә барып чыккан һәр төбәктә мәкаләләр чыгып торды. Кырык елдан артык хезмәт юлымда язылган мәкаләләрне җыйсаң, тау кадәр кәгазь өеме булыр иде. Мин аларның барысын да җыя алмадым, аларны җыеп бару минем өчен мөмкин дә түгел иде. Гастрольләргә китеп барам, газета-журнал чыкканны каравыллап ятып булмый бит. Ә инде чит төбәкләрдә чыкканнарын ничек җыясың? Шулай да кайбер мәкаләләр бар миндә. Менә Тукай премиясенә кандидат итеп күрсәткәч, үземдә булган кайбер газета-журналлардагы мәкаләләрне бер папкага туплап, бүләк билгеләүче комитетка тапшырган идем. Анда кайларда гына чыккан газеталар юк?!. Татарча, русча, башкортча, казахча, үзбәкчә язылган мәкаләләр... Кемнәр генә язмаган аларны?.. Музыка, сәнгать белгечләре, тәнкыйтьчеләр, журналистлар, язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, артистлар... Эшчеләр, колхозчылар, гади хезмәт кешеләре, студентлар... Шул мәкаләләрдән кайбер өзекләрне, болай кызык өчен генә, бергәләп укыйк әле... Менә бер саргаеп беткән тарих бите... 1961 елда башкорт язучысы Сәгыйть Агишев (күптән вафат инде ул язучы абый) «Кызыл таң» газетасының 24 декабрь санында Уфада Илһам Шакиров белән минем концертым турында язган мәкаләсендә мондый фикерләр әйтә: «... Халык телендә «берсеннән-берсе шәп» дигән бик матур сүз бар. Бу ике җырчыда да һәрберсен үзенчә яраттыра торган һәм уртак сыйфатлар бар. Уртаклык шул: алар икесе дә халык җырларын, композиторлар әсәрләрен бер генә тон, ярты тонда да ясалмалык күрсәтмичә, табигыйлек белән башкаралар...» Илһам белән бергә эшләгән концертларыбыз турында күп яздылар. Менә Чүпрәле районының «Коммунар» газетасында (1962 ел, 14 февраль саны) А. Алязов язган мәкаләдән өзекләр: «...Сәхнәдә, ниһаять, Илһам Шакиров! Халыкның иң яраткан җырчыларыннан берсе булып киткән бу яшь сәхнә йолдызын бизи торган беренче сыйфат – ул гадилек. Сабыр хәрәкәтле, уйчан карашлы Илһам тавышында моң белән куәт бергә кушыла... Тыңлаучыларның күңелләрен Илһам бөтенләй яулап алганнан соң, башка кешегә урын калмагандыр да кебек тоелды. Ләкин болай уйлаган күзәтүче шундук үзенең артык ашыгып нәтиҗә ясавын аңлады. Күңелләргә яңа яу белән киләсе каһарман сәхнә артында гына булган. Менә ул тынычлык күгәрченедәй, үзенең җиңел ак киеменә төренеп, балкып та чыкты! Бу Әлфия Авзалова иде... Әлфиянең уңышын билгеләгән төп сыйфат нәрсәдә соң? Тирән лиризмга да, уйнак йөгереклеккә дә бай булган тавыш белән башкару осталыгының, чын мәгънәсендә артистлыкның бергә кушылуында. Әлфия башкару сәнгатенең иң соңгы казанышларын үзләштергән. Ул һәр җырны саф үз тавышы белән, үзенчә аңлап, үзенчә баетып җырлый. «Кәккүк», «Төймә-төймә» һәм башка җырлар турында шуны әйтергә мөмкин...»

Илһам данына ияреп йөреп кенә булмый бит инде, үзем аерым бригада

булып эшләп киткәч, үземә генә атап язылган мактау сүзләре китте, дисәм, мактауларны бик ярата икән бу, үзен мактаган газеталарны җыеп барган дия күрмәгез, бу очраклы рәвештә генә сакланган газеталар, мин аларны җыеп бармаганлыгым турында алда әйткән идем инде. (Мактау ярата икән дигәннән, мактауны кем яратмый?.. Кайсыгызның үзегезне хурлап газетага яздырып чыгарасыгыз килә?..)

Менә Лениногорск районының «Ильич васыятьләре» исемендәге газетадан (1965 ел, 10 июнь саны) И.Егоров, Х.Гумеров язган мәкаләдән кайбер юллар: «...Зал тып-тын, әйтерсең, беркем дә юк. Җырчы тамашачыларны әсир иткән. Ә җыр тәмамлануга, зал тактлы кул чабуга күчә, «бис» тавышлары ишетелә. Җыр чишмәсеннән чыккан төсле җырларның моңлысы да, шаяны да бер-бер артлы агыла...»

Менә Башкортстанда чыга торган татар газетасы «Кызыл таң»ның (1965 ел, 31 август саны) Г. Рамазанов мәкаләсеннән өзекләр: «...Бригада составында Әлфия Авзалованың да килүе җыр-моң яратучылар өчен аеруча зур шатлык булды. Концерт башланасы көн җиткәнче үк инде кассаларда билет алырга мөмкинлек калмады! Бу үзе үк тамашачыларыбызның кунакларны күрергә ашкынып торуы турында сөйли. Әлфия Авзалованың тавышын җыр-моң сөючеләр еш ишетеп торалар. Аның көмештәй саф, көчле җырлавы әледән-



әле радио, «зәңгәр экраннар» аша ишетелә һәм без ул яратып башкарган җырларны яттан беләбез. Кабатланмас осталык белән башкарылган «Кәккүк», «Нәфисә», «Салкын чишмә», «Кайтам инде» җырларын аңардан башка берәү җырласа, ул кадәр үк матур да булмас төсле тоела безгә... Концерт барышында ул утызга якын җыр башкарды... Әлфия Авзалованың бу концертта башкарган җырларының күбесен безнең ишеткәнебез юк иде әле. Алар арасында башкорт халык көйләре, безнең композиторларыбызның җырлары да байтак. Бәхти Гайсинның «Нигә генә икән», Тәлгать Шәриповның «Туган авылым», башкорт халкының борынгы көйләре «Кылый кантон», «Элмәлүк» һәм башка җырлар аның башкаруында матур һәм яңача яңгырады... Әлфия Авзалова башкарган бер җыр турында гына да әллә күпме язып булыр иде. Ләкин моның кирәге юк һәм аның башкару осталыгы «күкләргә чөйгән» сүзләргә мохтаҗ да түгел...»

Шулай «күкләргә чөйгән»гә Әлфия апагызның борыны күкләргә чөелмәде. Андый язмалар күп. Менә Кыргызстанның Ош шәһәрендә чыккан «Ленинский путь» газетасының 1973 ел, 17 апрель саны. Анда В. Камалова, А. Волчин язган мәкаләдә мондый сүзләр бар: «...Зрителям хорошо знаком старый репертуар солистки. А сегодня она выступает с новым. Впервые звучит, например, песня «Маки». За инструментом – автор, молодой композитор Марс Макаров. Слушаешь, а перед глазами – алые долины. Замечательной певице благодарные зрители также преподносят пламенеющие цветы – дар киргизских гор...»

Чәчәкләрне күп бирделәр, үз гомеремдә кочак-кочак чәчәкләр алдым. Ташкент тамашачылары бер җәйне үзем буе булып үскән гладиолуслар белән сәхнәне тутырдылар. Яңа гына өзелгән озын-озын гладиолусларны кая куярга белми идем. Җырчы Минхәмәт Гыйлажев шаяртып: «Бу кадәр чәчәкне нишләтергә, әллә, Әлфия апа, урам чатына алып чыгып сатыйк микән, бигрәк күп, бигрәк жәл, кунакханәгә алып кайткач, икенче шәһәргә чыгып китәбез, номерда әрәм булып кала», – диде.

Магнитогорск шәһәрендә чыккан «Магнитогорский рабочий» газетасында Магнитогорскида яшәүче композитор Рафаэль Бакиров үзенең мәкаләсендә (1974 ел, 20 декабрь саны) мондый сүзләр язган: «...Наряду с известными популярными песнями Альфия исполняла новые, написанные специально для нее. Трогательно, с драматизмом прозвучала песня «Һаман да көтәсең». И зримо предстает образ поседевшей старушки – матери, которая ждет своего любимого сына, так и не вернувшегося с фронта... И снова звучали бурные аплодисменты, когда А. Авзалова исполнила современную песню «Күзләрем тик сине эзлиләр», «Туган авылым», башкирскую шуточную – «Шәл бәйләдем...»

Үзебезнең Татарстан газеталары концертым булган саен мәкалә бастырып тордылар. Республика газеталары, район газеталарында бик күп мәкаләләр

чыгып килде. Менә 1981 елның 18 август санында «Социалистик Татарстан» газетасы Кукмара кирпеч заводы директоры Наил Хәсәнов мәкаләсен бастырып чыгарды. «Татарстанның халык артисткасы Әлфия Авзалова концертларын бер-бер артлы ике тапкыр кабарга туры килде. Күңелдә тирән эз калдырырлык шатлыклы минутлар булды алар минем өчен. Дөрес, аның башкаруындагы җырларны моңарчы да яратып, ниндидер бер канәгатьләнү хисе белән тыңлый идем. Бу концертларда булу шул хисләремне тагын да көчәйтте. Алай гына да түгел, шул хисләремә горурлык хисе дә өстәлде. Менә ничәмә-ничә еллар инде сәхнәбезне бизәп торучы йолдызыбыз Әлфия Авзалованың шәхси уңышлары өчен шатландым. Аннан килеп, татар эстрада сәнгатенең үсеше өчен чиксез горурлык хисе тойдым. Аның концертларының соңгысын мин КамАЗда – даны бөтен дөньяга таралган машина төзүчеләр белән бергә караган идем. Залда бик күп милләт вәкилләренең дә булуы аеруча шатлыклы иде. Димәк, җырчыбыз башка милләт халыкларының да йөрәгенә үтеп керә алган, ул аларның да көтеп алган кунагы икән. Төрле милләт халыклары белән бергә, гарәп халык җырын, үзбәк көйләрен тыңлау аеруча истә калырлык булды. Программа берникадәр яңарып та өлгергән. Г. Ахуновның «Хәзинә» романы буенча эшләнгән спектакльдәге җырны тамашачылар Ә. Авзалова башкаруында җылы кабул иттеләр. Ә. Авзалованың менә шулай иң беренче булып халыкка җиткергән җырлары күпме?.. Әлфия Авзалова иҗатына баш игән хәлдә, ел дәвамында ул башкарган хезмәтне күз алдына китерергә дә тырыштым. Монда инде кайбер саннар ярдәмгә килде. Җырчыбыз ел саен 250ләп концерт бирә һәм аны һәр көнне 500–600 тамашачы карый. Егерме биш елга якын *(бу сүзләр 1981 елда язылган, хәзер инде кырык елдан артык. – Ә. А.)* менә шулай армый-талмый иҗат итә, яңа уңышлары белән сөендерә... Концертлар Б. Гайсинның Ә. Атнабаев сүзләренә язылган «Саубуллашу» җыры белән тәмамлана. Анда «...очрашырбыз әле җыр аша» дигән юллар бар. Әйе, һичшиксез, очрашырбыз, Әлфиянең иҗат уңышларына тагын кат-кат шатланырбыз әле. Моннан кеше туямыни?..»

Туеп китүчеләр дә бардыр инде... Күп ашасаң, майлы ботка да туйдыра, һәр нәрсәнең ахыры була, минем эстрадада эшләү дәверемнең ахыры якынлашты. Туктарга туры килер. Әлбәттә, үзем туймадым, эштән туйгаННан түгел, вакыты җитте, дип туктармын.

Кызык өчен тагын берничә газета битеннән өзекләр укыйк әле: Үзбәкстанда чыккан «Сельская правда» газетасының 1983 ел, 19 март санында К.Гайдинов язган мәкаләдән юллар: «...Альфия Авзалова завоевала признание слушателей мастерским исполнением старинных и современных песен, народных мелодий, частушек, татарских лирических и песен народов других республик. Своими истоками современная татарская песня исходит из народного творчества. И исполняя ее, Альфия Авзалова подчеркивает глубоко национальные, народные интонации...».

Башкортстан, Үзбәкстан газеталары минем турыда күп яздылар. Гастрольләрем дә бу республикаларда күп булды инде, әлбәттә. Ә үзебезнең республикада тагын да күп язылды. Үзем туып-үскән Актаныш районы газетасы аерата мине якын күреп, концертларым турында даими язып торды. Менә – Актанышта чыга торган «Игенче даны» газетасының 1984 ел, 30 июнь саны. Анда Әхтәм Сатыев язган мәкаләдә мондый юллар бар: «...Һәр җырдагы образлылык, үзенә хас хәрәкәтләр, мимика, югары актерлык сыйфаты тамашачы белән элемтә күпере булып торалар. Концертта бертөрлелеккә урын юк, тамашачы белән башкаручы бер организм кебек. Бигрәк тә Сибгат ага Хәкимнең композитор Сара ханым Садыйкова белән бергәләп язган «Язмыш» җыры девиз булып яңгырый. Ул җырның эчтәлегенә Авзалова чит илләрдә йөреп гыйбрәтләр күреп кайткач, ныграк төшенде. *(Чит илләргә үз акчама туристлык путевкасы сатып алып барып кайтуым турында бу сүз, Культура министрлыгы оештырып, мине чит илләргә җибәрмәве турында алда язган идем инде. Аларны көтеп ятып булмый бит, үз акчама барып кайттым. – Ә. А.)* Шуңа күрә:

Аерма мине кара икмәгем,
Сөтле чәемнән, –

дигәндә, бу җырның сүзләрен шагыйрь язганын бер мизгелгә онытасың. Әлфия Авзалова якташыбыз, Тат.Ямалы егете, баянчысы Кирам Сатиев турында болай сөйли: «Аның белән 5 ел бергә эшлибез. Консерватория тәмамлаган оста баянчы. Бригаданың шулай оешкан төстә эш алып баруында Кирамның роле зур. Тон алыштыру кирәк булса, яки берәр көтелмәгән үзгәреш килеп чыкса, ярты сүз, күз карашы белән аңлашабыз. Ут булмаган чакларда да концертны өзмибез, ансамбль эше баянчыга йөкләтелә. Сәгать ярым, ике сәгать буена сузылган киеренке хезмәттән Кирамның җиде кат тире чыга...»

Баянчыларымны мин һәрвакыт ихтирам иттем. Бер генә баянчы да: «Әлфия апа белән эшләү авыр, ул юкка-барга бәйләнеп җанга тиде», – дип әйтмәс, дип уйлыйм. Баянчыларымны һәрвакыт кешегә мактап сөйләдем, аларны хурларга теләгәннәргә дә каршы чыктым. Хәер, хурларлык баянчылар белән эшләмәдем дә. Минем бәхетемә талантлы, әйбәт баянчылар туры килде: шушы урында үзем белән бергә эшләгән баянчыларны рәхмәт хисләре белән телгә алып китим әле. Иң беренче елларда мин халкыбызның яраткан баянчысы, сәхнәләрдә беренче профессиональ баянчы булган Рокыя апа Ибраһимова белән Мөхтәр Әхмәдиев, Гали Җәмлиханов, Гани Вәлиев, Мостафа Сәләхетдиновлар кебек өлкән буын баянчылары белән эшләдем. Алар гаҗәп дәрәҗәдә халыкчан башкару осталары иде. Аннары яшьләр китте: Рифкать Гомәров, Рифкать Лотфуллин, Зиннур Гыйбадуллин, Фәнис Гыйльмет-

динов, Хәйдәр Сафин, Ринат Сибгатуллин, Марс Макаров, Кирам Сатиев – болар барысы да халык алдында танылып, күбесе хәзер мактаулы исемнәр алган музыкантлар. Хәзер минем бригадада яшь музыкант Равил Закиров баянчы. Баянны яхшы уйнавы белән бергә, матур гына җырлый да. Талантлы баянчыга үсәргә һәрвакыт ярдәм итәргә кирәк. Мин кулдан килгәнчә, баянчыларыма ярдәм итәргә тырыштым. Менә Равил дә, тавышы булгач, җырласын. Хәзер эстрадада шулай – җырла да, бие дә, сәхнәдә барлык сәләтеңне күрсәт. Баянчыларым белән дус эшләдем. Дөнья булгач, табак-савыт шылтырамыйча тормый, диләр бит. Озак эшләгән баянчыларым белән төрле вакытлар булгандыр. Ләкин беркем белән дә дошманлашып аерылышмадык, безнең бригададан киткән сурәттә дә алар белән дуслар булып калдым.

1992 елда Г. Тукай исемендәге премиягә кандидат итеп күрсәтелгәч, минем хакта газеталарның барысында да диярлек язып чыктылар. Шуларның икесе белән генә танышып китик әле. Журналист Мирхәт Хөснимәрдәнов – минем якташым. Актаныш районында туып-үскән журналист (күптән түгел кинәт кенә үлеп китте, мәрхүмкәем) мине бик күтәреп язган. («Ватаным Татарстан», 10 апрель, 1992 ел.) Үзенең мәкаләсен Мирхәт болай башлый:

Булдым инде моңлы кошкай,
Сайрамыйм чыгып кына...

Сабый чакта елак балага кайчак: «Әйдә, җыласын, үскәч, җырчы булыр», – дип әйткәлиләр. Бу ике сүз арасында тирән бер мәгънәви бәйләнеш бар кебек. Башта «елау» сүзе алдан йөри. Аннан соң инде үсә төшкәч, җыр сүзе төпкә җигелә һәм ул я елатырга, я елмайтырга тиеш. Шулай булмаганда, җырлауның мәгънәсе юктыр. Безнең Әлфиябез дә, әлбәттә, башта һәр сабый кебек үксеп-үксеп елагандыр... Гомер агышында очрап торган мәрхәмәтсезлекне, җәберләүләрне, кимсетүләрне татып та күңеленнән әрнегән, тавышсыз гына сыкрангандыр Актаныш кызы, Агыйдел сылуы Әлфия. «Моңлы бала түгел идем, моңнар төште башыма», – дип бик иртә җырлый башлаган ул. Мәктәпкә кергәнче үк... җырчы турында язу бик авыр. Аның иҗат биографиясе, җыр башкару сәләте сөйләү өчен катлаулы. Аны тулысынча ачу өчен үзеңә олы музыка белгече, яки җыр остасы булу кирәктер. Әлфиягә минем үз мөнәсәбәтем бар, мөмкинлек чыгудан файдаланып, үз сүземне кабат әйтәсем килә. Моңа минем хакым бардыр сыман. «Кабат» дип тикмәгә генә белдермәдем.

Без – бер чор кешеләре. Икебез дә Агыйдел якларыннан. Икебез дә ятим. Зур иҗат юлына басарга икебезгә дә шушы якның – Актанышның мәрхәмәтле кешеләре булышты. Бусын сүз уңаеннан гына хәтергә төшерәм. Әлфия турында иң беренче итеп, республика яшьләр газетасында мин кайчандыр, иҗатымның башлангыч чорында, «Яңа язмыш» дигән очерк язып,

яшь талантлар конкурсында катнаштым һәм призлы урын алдым. Әмма без Әлфия белән иртәрәк, очерк басылганчы ук очрашкан идек. 1947–1949 елларның җәй айларында. Аңа кадәр дә Актанышның бәләкәй җырчы кызы турында ишеткәнем бар иде. Күрергә дә насыйп булган. Казанда татар театр училищесының беренче курсын тәмамлап каникулга кайткач, мине райкомолга чакырып алдылар һәм агитбригадага кушылырга өндәделәр. Риза булдым. Анда Әлфия дигән кызчык та бар иде. Бер гармунчы, тагын бер биюче кыз һәм мин. Без нәни генә программа төзеп, айдан артык авылларда «концерт» куеп йөрдек. Авыр заман иде. Сугыштан соңгы чор. Әмма халык сәнгатькә шулкадәр сусаган, гади генә бер агитбригада чыгышы да сугыш еллары михнәтен җилкәсеннән коя башлаган авыл халкы өчен бәйрәм төсен ала иде. Кулыбызда районның зур җитәкчеләре кул куеп биргән «юллама» бар. Анда «һәрьяклап булышлык күрсәтергә» дигән җөмлә дә өстәлгән. Авылга килгәч иң беренче эш итеп, Әлфия колхоз идарәсендәге җитәкче кешегә шул кәгазьне тоттыра. Ул инде бөтенесен рәтләп, тиешле ризыкка язу алып кайта. Беләбез, авыллар шулкадәр хәерчеләнгән иде. Кайберләрендә шушы биш-алты кешелек агитбригаданың тамагын туендырырлык та ашамлык табуы авыл башлыгын читен хәлгә куя иде. Әлфия «аяк терәп», каты сөйләшә. «Җырчының тамагына бал да, май да, йомырка да кирәк. Югыйсә, җырлап булмый», – дип кенә җиппәрә бу. Табалар. Тамакны туйдыралар. Ә кичен берничә терәүле авыл клубы шыгрым тулы була. Әлфияне юри азакка калдырабыз. Концертның бүтән номерлары – бию, гармунда уйнау, нәфис сүздән соң гына сәхнәдә ул пәйда була. Кул чабулардан клуб стенасының тузаннары оча иде. Һаман, һаман аның җырлавын сорыйлар. Әлфия исә карышмый, җырлый. Җырлый гына түгел, моң суза:

«Бакчаларда гөлләр чәчәк атты,
Тормышыбыз кебек ямьләнеп.
Урман суларына аккош кайтты,
Сандугачлар килде әйләнеп.
Сандугачлар килде, аккош кайтты,
Син кайтмадың киткән җиреңнән...»

Зал сулкылдап елый... Ирләре, сөйгәннәре, уллары сугыштан кайтмый калган хатыннар, кызлар, аналар үкси. Таң атканчы, яктырганчы җырлаган чаклары да була иде Әлфиянең. Чөнки халык сорый, ялвара, «җырла, балакаем, җырла, хәсрәтебез дәрья булып аксын», диләр иде... Колхоз рәисе торып: «Җитәр инде, иртән эшкә барасы бар», – дип тә карый. Ләкин җыр белән әсәрләнгән халык кузгалырга да уйламый...»

Радиокомитетта эшләгәндә, миңа Әлфия турында радиоочерк язарга туры килде. Монда очеркның үзенчәлеге шунда: андагы сөйләм җыр белән бергә



1984 ел

үрелеп бара. Әлфия башкаруында халык бик яратып тыңлый торган җырлар сайлаган идем. Шушы концерт-очеркка карата бихисап хат килде. Тулы бер папка. Моннан 30 ел элек язылган хатларны тагын бер кат актарып, укып чыктым. Нинди генә рәхмәт хисләре юк инде, нинди генә мактау сүзләре тезелмәгән хәзер инде ул саргаеп беткән кәгазь битләрендә. «Халкыбызның моңлы кошы ул, Әлфия, – дигәннәр. – Ходай Тәгалә озын гомер бирсен, тавышы тутыкмасын...» Әйе, тутыкмаган. Тау астыннан чыккан, ургылып аккан чишмәләрнең агышы тукталмаган кебек, Әлфиянең моң чишмәсе һаман сүрелми. Шушы юлларны язарга әзерләнгәндә очрашкач та әле: «Иртәгә тагын чыгып китәбез», – дип ашыктырды ул мине... Ул һаман юлда, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйровалар эстафетасын үз кулына кыю алып, аны үзенчәлекле төсмерләргә баетып дәвам итә-итә, үз эстафетасын булдырган. Аны хәзер бик тырышып яшьләргә тапшырырга омтылган җырчы бүген дә халыкның үз җырчысы, үз сөйкемлесе... Тагын бер очрашуны хәтерлим. Бусы аның фатирында булды. Гөлшат Зәйнашева да килгән иде. Кич буе сөйләшеп утырдык. Җыр башкару осталыгы турында сүз барганда, Әлфия чәй янынан тиз генә кузгалды да, түр башындагы пианино янына утырып, аклы-каралы эшкәртмәаләренә бармакларын җиңел генә тигезеп алды һәм русчалатып: «Я люблю свою землю» дип җырлап та җибәрде. Бу җырны рус артистлары баш-

каруында да ишеткәнем бар иде. Әмма Әлфия аны үзенчә, татарча аһәң белән башкарды. Көй бозылмаган, әмма яңгырашы башкача. Әлеге дә баягы, моң үзенчәлеге өстенлек итә. Моны, бәлки, Әлфия генә булдыра ала торгандыр. «Һәр халыкның үз моңы: җыр башкаручы моны күңеленнән тоярга тиеш», – дип кабатлады Әлфия. Ләкин мине иң гажәпләндергәне аның уйнавы иде. Нәрсәдә бит әле?! Пианинода! Минем өчен бу чын-чынлап яңалык иде. Ә соңгы очрашуда, әле менә кичә-бүген генә дигәндәй: «Малайкаем («малайкаем» дип безнең якта иң якын кешеңә генә эндәшәләр), мин бит хромкада да уйныйм, яшьләр кебек эстрадада бии-бии җырлыйм. Төшеп каласың килмәсә, өйрәнәсең аны!» – дип көлдерде. Тик монда хикмәт коры теләктә генә түгел, сәләттә. Кайбер иҗат кешеләренең таланты олыгая барган саен сүрелә төшә. Ә аныкы – юк. Ул үзендә замана белән атлап барырлык көч таба. Мин гомерем буе гармунчыга, биючегә, җырчыга гашыйк: сокландым да, көнләштем дә, кызыктым да. Әлфиягә бигрәк тә гашыйк идем. Хәер, мин генә түгел... Ничәмә-ничә еллар ул сәхнәдән төшми, бик төшәр иде, ял вакыты да җиткән, әмма аның моңлы җырын сорап һаман-һаман хатлар килә. Халык бит бик сизгер күңелле, яратмаган җырчысын сорамый, күңел кылларын тибрәтмәгән җырны кабул итми...»

Якташым Мирхәт Хөснимәрдәнов мине бик күтәреп язган. Шушы Тукай премиясенә кандидат итеп билгеләнгәч, мине Мирхәттән дә ныграк күтәреп язучылар булды. Мин аларның кайберләреннән өзек китерергә хәтта оялам, уңайсызланам. Илһам Шакиров барысыннан да уздырып җибәргән. Җырчы турында шулай мактап язуы белән Илһам мәкаләсе кызыклы да шул. Илһам тикмәгә мактамый, тикмәгә күтәрмидер инде. Илһам бит ул!.. Аның мәкаләсеннән кайбер фикерләрне укыйк әле:

«...Иң якты йолдызлардан яралган, үзе дә сәхнә йолдызына әверелгән Әлфия Авзалова бар. Әлфия үз талантын ил-халык язмышына бәйләде. Хәзер инде татар тарихын Әлфия Авзаловадан башка күз алдына китерүе дә кыен. Аның турында уйланганда, шагыйрь Равил Фәйзуллин сүзләре искә төшә:

Холкыбызмы шундый: без, эш узгач,
Әй үксибез, тәүбә иткәндәй.
Ә эчебез поша исән чакта,
Берәребез гөрләп үскәнгә...

Шагыйрь хаклы. Хөрмәтле композиторыбыз Сара апа Садыйкованы, үзе вафат булгач кына, Г. Тукай бүләгенә тәкъдим иттеләр. Шул чакта мин болайрак язган идем: татар акылы – төштән соң, үзе исән чакта кадерен белеп бетермәдек, инде гөнаһыбызны юыйк, аның якты рухы алдында акланыйк һәм пакьләник, дигән идем. Үзе исән чакта иҗатына тиешле бәясен ала алмаучылар арасында Сара Садыйкова ялгыз түгел. Татар дәүләт филармониясенең гомуми җыелышында Әлфия Авзалованы Г. Тукай бүләгенә кандидат итеп

күрсәтергә дигән тәкъдим булгач, бөтен зал бердәм «ah» итеп куйды, бераз өнсез торганнан соң, тыела алмый дәррәү кул чаба башладылар. Нигә бу шулай яшен суккандай тәэсир итте соң әле? Сәбәбе ачык: һәркемнең башыннан бер уй йөгереп узгандыр: «Ни өчен соң әле без бу хакта моңарчы уйламаганбыз, әллә кайчан булырга тиешле ич бу!..»

Шагыйрь хаклы, мең мәртәбә хаклы, адәм баласының үзе исән чакта ук иҗатына тиешле бәя бирелмәүне безнең сукырлыкка, яки чукраклыкка гына сылтау дөрес түгелдер... Моның төбендә көнчелек дигән әшәке гадәт ятмыймы икән? Мөгаен... Әлфиянең иҗаты хакында кайта-кайта уйланам.

Аның язмышы да Тукайныкы кебек диярлек бит әле. Сабый чакта ук әнкәсеннән, аннары әткәсеннән ятим калып, йә ерак туганнарына елыша, йә балалар йортына эләгә, яки ятлар почмагына сыена, яки бөтенләй урамда кала.

Сәнгать дөньясына шулай урау юллардан килсә дә, Әлфия җыр сәнгатенә ятимлек тойгысы алып килмәде. Киресенчә, аның җырларын тыңлаганнан соң, кешенең дәрт-дәрманы арта, яшәүгә ышанычы ныгый, иманы камилләшә. Бары тик кешене уйландыра торган, әйбәт фикер уята торган җырларны гына халыкка җиткерергә тырышты ул. Үзеңнең башымнан кичкән хәлләр: кайчакта янасың-көясең, төннәр йокысыз үтә, күңелдә ачу, үпкә, рәнҗү, аерым кешеләргә генә түгел, хәтта халыкка рәнҗисең... Әмма ул үпкә-рәнҗүләрне башкаларга да таратып йөрергә безнең хакыбыз юк! Сәхнәгә – тамашачы каршына якты йөз, пакь күңел белән чыгарга кирәк. Безгә Ходай шулай язган. Әлфия дә сәнгать дөньясына шундый иман белән килде, шул иманына тугры булып калды. Бүләккә тәкъдим иткәндә «ниндидер аерым хезмәт өчен булырга тиеш» дигән фикер йөри. Әлфия Авзаловаңың хезмәте ни дәрәҗәдә? Әйе, ул меңләгән җыр башкарды, ул башкарган җырларны миллионлаган кешеләр отып алды, күңеленнән кабатлады. Җырлый башлап, карыны белән кар ярып, нинди газаплар белән һәр төбәккә моңыбызны, милли сәнгатебезне илткәне өчен генә дә без аңа рәхмәтле булырга тиешлебез. Әлфиянең хезмәте аның белән генә тәмамланмый әле. Үзеннән соң килгән уннарча җырчыга юл күрсәтүе дә – зур каһарманлык, олы хезмәт, дияр идем мин. Бу хезмәтне күрмәү – наданлык; күрергә теләмәү – гөнаһ.

Әлфия белән без җыр сәнгатенә бер чорда килдек, бергә иҗат иттек. Җырларны ул үзе тапты (шагыйренә әйтеп яздырды, композиторына көйләп күрсәтте), үзенчә, бары тик үзенчә генә башкарды, һәр җыры халык күңеленә барып җитте. Әлфия туган халкын яратты, үзен дә яраттыра алды. Әлфия фәкать кул чаптыру уе белән мәгънәсез җырлар башкармады. Кырык елга якын иҗатын тикшереп карагыз: табарсызмы икән сез анда мәгънәсез, шырдый-бырдый берәр җыру?

Әлфия Авзаловаңың иҗатына тиешле бәя бирелмәде, ул бөтенләй читтә калып барды, дисәк тә хата булыр.

Әйе, ул – Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган артисты, ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек булды. Димәк, күрми калмаганнар... Әле, моннан кала, аның бер сандык урак-чүкечле, йолдызлы, кызылга буялган Мактау кәгазьләре дә бар... Әлфия Авзалованың татар милләте каршында йөзе ак, күңеле пакь. Әлфия – тумышы белән моң!.. Ул – милләт кызы. Тукай кызы. Әлфия кебекләр дөньяга сирәк килә. Килгәннәренең кадерен белик, хезмәтләренә тиешле бәяне бирергә соңармыйк. «Әлфия» гарәпчәдән «мең яшәр» дип тәрҗемә ителә. Әйдәгез, без дә Әлфия Авзаловага «Мең яшәсен!» дигән теләктә булыйк. Татар эстрада җыр сәнгатенә нигез салучыларның берсе – Әлфия Авзалованың иҗатын-хезмәтен дөрес бәялик».

И, Аллам!.. Бигрәк зурлап, күтәреп язган инде бу Илһам минем иҗатым турында!.. Бу зурлауларны мин һич тә мактанудан бу китапка күчермим, факт итеп кенә күчереп язам. Илһамның чын дусларча минем иҗатыма-хезмәтемә булган бәясе бу. Илһам булып, Илһамнан шундый мактау сүзләре ишетү – минем өчен зур бәхет. Бәхет дигәннән, миннән еш кына: «Бәхетлеме син?» – дип сорыйлар. Ничек мин бәхетсез булыйм?.. Шулкадәр озын-озак сәхнәдә җырлап яшәү бәхет түгелмени?!. Мин бәхетнең иң кечкенәсенә дә куанырга күнеккән. Ә монда инде кечкенә бәхет түгел. Минем өлешемә бәхетнең иң зуры тигән. Мин бәхет тавының иң югары биеклегендә итеп тоям үземне. Рәхмәт мине бәхетле иткән туган халкыма! Рәхмәт республикабызның җитәкчеләренә! Рәхмәт минем якын иҗат дусларыма – артистларга, композиторларга, шагыйрьләргә!.. Нинаять, миңа 1992 елны Республикабызның иң зур бүләген – Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирделәр, мин Тукай премиясе лауреаты булдым!..

Эстрадада озак эшләү дәверемдә бик күп хатлар алдым. Газеталарны җыеп бара алмаган шикелле, хатларны да җыеп бара алмадым, бу эшкә игътибарым җитмәде, гастрольләрдә үткән тормыш мәшәкатьләре моңа мөмкинлек бирмәде. Аннары чын күңелләреннән хөрмәт итеп, миңа хат язган җыр сөюче дусларым алдында гафу үтенәм, мин ул хатларның күбесенә җавап та яза алмадым. Җыеп бармасам да, очраклы рәвештә генә сакланган кайбер хатлар бар миндә. Ул хатларда безнең халкыбызның үз җырчысына зур мәхәббәте, хөрмәте чагыла. Шундый бер-ике хаттан кайбер юлларны бергәләп укыйк әле:

«...Әлфия апа минем әнкәем белән бер яшьтә. Аның кебек үк минем әнием дә яшьли ятимлек күреп, тормыш авырлыгын күреп яшәгән, һәр татар җырымоңына гашыйк кеше. Сабый чагымнан радиодан ишетеп һәм әнкәй башкаруында Әлфия апа җырларын тыңлап, илһамланып үстем. Безнең гаиләдә аны яратмаган кеше юк иде. Дәү әни дә, әнкәй дә һәм без өч ятим кыз (әтиле килеш әтисез үскән ятимнәр) радиодан бер генә концертны да калдырмый тыңлый идек. Әлфия апаның яшь чагы... Яңадан-яңа җырларын җырлап безгә бүләк

итә. Без аларны шундук отып алабыз һәм җырлап йөрибез... Мәктәптә укыганда минем бер хыялым бар иде: Казанга барырга, ВУЗга керергә һәм Әлфия апаның концертына эләгергә, аның үзен тыңлау бәхетенә ирешергә. Ә студент елларымда шундый бер кызык хәл булды. Институттан кайтып барабыз (70 нче еллар), Ленин бакчасы тукталышында 5 нче трамвайга бер сөйкемле генә, уртача буйлы, татарга да, башкортка да охшаганрак апа менде. Кеше күп, урын юк иде. Мин торып аңар урынымны бирдем. «Рәхмәт, сеңелем, бик арыган идем», – диде ул. Мин аның тавышы гаҗәп тә таныш икәнлеген ишетеп хәйран калдым. Атна-ун көн үткәч, концертка барсам, танып алдым, трамвайда урын биргән апам – Әлфия апа булып чыкты. Мин инде үзем 2 бала анасы, олыгаеп киләм. Музыканың төрле жанр һәм стильләреннән хәбәрдармын. Чит ил музыкасын, классик әсәрләрне дә яратып тыңлыйм. Тик шулай да татар җыр-моңын йөрәгемә сеңдереп яшим. Мине куандырган Әлфия апа Авзалова һәм Илһам абый Шакиров кебек гаҗәеп шәхесләргә сокланам. Әлфия апа да, Илһам абый да миңа саф сулы авылым чишмәсен хәтерләтә. Гомер үтә, бары да үзгәрә, тик аларның сафлыгы, садәлеге генә мәңгелек, яшәүнең үзе кебек озын гомерле. Ә бу шигъри юлларым – Әлфия апага бүләгем:

Әлфия апа!..
Сезнең ижат челтер чишмәгә тиң,
Суын эчеп һәркем сафлана.
Йөрәгендә җаны булган татар,
Сезне сөя, сагына, соклана.
Ничә еллар Сезнең серле аһәң
Күңелләрдә давыл кузгата.
Кайгылыга – дәва, гашыйкка – дәрт,
Шатлык өсти, назлый, юата.
Сихерләнәм Сезне тыңлаганда,
Моң дәрьясы ургып акканда.
Сихәт табам керсез күңелемә,
Тормыш җиле ярдан какканда.
Табигатьнең гүзәл чәчкәсе Сез,
Сокланырлык ижат юлыгыз.
Килер буыннарга мирас булсын
Исемегез, дәртле җырыгыз!..

Сәлам юллап, иң изге теләкләр белән – Гарипова-Әкрамова Хәмидә Лотфулловна. Югары Ослан районы, Мәмәтхуҗа мәктәбе директоры».

Казан телевидениесе аша минем концертымны карагач, Казанда яшәүче пенсионер Садыйков Салих (һөнәре буенча инженер-электрик) мондый хат язган:

1983 ел



«...Әлфия Авзалова концертын карагач, аның иҗаты миңа көчле тәэсир итте, горурлык уятты. Бар икән бездә чын милли талантлы музыкаль шәхес. Ул – җырчы Әлфия Авзалова!.. Миңа аның җырлавы, ансамбленең уйнавы бик ошый. Бу концертта ул үзенең осталыгын, милли көйләрнең нечкәлекләрен тирәнтен үзләштерүен, ансамбленең яңгырашын тагын да камилләштерүен кабат күрсәтте. Картаймый да соң безнең Әлфия!..»

Башкортстанның халык артисткасы Флүрә Ногманова «Совет Башкортостаны» газетасының 1985 елгы 13 декабрь санында үзенең зур күләмле мәкаләсендә мондый юллар яза: «Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы Әлфия Авзалова Башкортстан эргәсендә туып-үскән. Шуңадырмы аны, сагындырып килгән кунак кебек, зал тулы тамашачы алкышлап каршы ала. Бу алкышларда халыкның җыр-моң сәнгатен сөюе, ә Авзалова иҗатына ихтирамы чагыла.

Менә 30 елдан артык Әлфия Авзалова үзенең эстрада сандугачы дигән данын югары тотып килә. Еллар үткән саен, аның башкару осталыгы камилләшә, күңелгә ятышлы моң-бизәкләргә байый бара. Ул һәр әсәрнең – халык көе дисеңме, композитор язган җыр булсынмы – мелодик үзенчәлеген, идея куәтен хис үткерлеге белән халыкка җиткерергә өйрәнгән. Тамашачы аның һәр җырында тәмамланган, тулы образ күрә, һәр җырыннан олы илһам, эстетик зәвык ала. Ә җырлары ифрат күп аның. Артистканың кабатланмас тавышына, сандугачтай назлы моңына гашыйклар санап бетергесез. Бу юлы да Әлфия Авзалова Өфе халкын сагынулы бай концерт программасы белән кинәндерә. Р.Яхинның Р.Байтимеров сүзләренә «Туган ягым» җыры Ватан-

га мәхәббәт гимны булып кабул ителсә, Р. Сафиуллинның М.Латыйфуллин сүзләренә «Сагындым, авылым» җыры әнә шул илгә мәхәббәт хисен тагын да куәтләп җибәрә. Күп кенә җырлар яшьлек дәрте, нечкә юмор белән өртелгән. Гарәп халык җыры «Сәлам алдык», болгар җыры «Чибәр хатын» гарәп, болгар һәм татар телләрендә башкарыла. Ә залдагыларга бар да тансык. Өлкән буын тамашачылары «Шахта»ны, «Җомга» көен сорап җырлата. Әйе, артисткa бер җырны да үз репертуарына очраклы гына сайлап алып кертмәгән...»

Флүрә Ногманова – үзе дә җырчы-артистка. Башкортстанның күренекле җырчысы, менә озак еллар ул яшь җырчылар тәрбияләп, яшьләргә вокаль белем бирә, педагог, укытучы, танылган музыка эшлеклесе. Шундый сәнгать әһеле, җырчы дустым Флүрәнең бу мәкаләсе мине бик дулкынландырды. Җырчы – җырчы турында шулай ихластан яза, минем иҗатыма югары бәя бирә. Рәхмәт аңар! Хатын-кыз җырчы – хатын-кыз җырчы турында шулай зур бәя биреп язу – сирәк күренеш ул. Күп җырчыларда көнчелек хисе була. Ә Флүрәдә көнчелек, хөсетлек юк.

Әле соңгы елларда гына (1993 елгы 18 сентябрь санында) «Шәһри Казан» газетасында басылып чыккан тагын бер мәкаләдән өзекләр китерәсем килә. «Яшьлегемә кире кайтыр идем» дип аталган бу мәкаләне журналист Рәйсә Яхина язган.

«Татар халкында исемнәре мәңгегә тарих битләренә кереп калган шәхесләр бар. Исән чакта без аларның күбесен аңлап та бетермибез. Җиңел кулдан гына төрле имеш-мимешләр дә таратабыз, тиешле кадер-хөрмәтебезне дә күрсәтә алмыйбыз. Барысы да соңыннан, еллар үткәч кенә искә төшә.

Әле шушы көннәрдә Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисткасы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әлфия Авзалова белән сөйләшеп утырганда да мин шул фикергә килдем. Ни өчен икәнен һәркем үзенчә аңлар, үзенчә нәтиҗә ясар. Мин фәкать үземнең сорауларымны һәм аның җавапларын гына тәкъдим итәм.

– Әлфия апа, Сезнең балачагыгыз һәм яшьлек елларыгыз турында шактый язылды инде. Шулай да бераз искә төшереп узыйк әле. Сез ничек җырчы булып киттегез?

– Әйе, җаным, ятим бала моңлы була, диләр бит. Мин 5 яшемнән әниемнән калып, бик авыр тормышта, ятимлектә үскән кеше. Яза башласаң, бер дә Габдулла Тукайның балачагыннан ким түгел. Беренче класстан ук җырлый башладым мин.

Һаваларда очкан карлыгачлар
Болытларга кереп югала.
Кыз булганчы, булсам канатлы кош –
Тоткын булмас идем дөньяда!

Шушы җырым белән кешене җылата идем... Инде менә 41 ел буена сәхнәдән төшкәнем юк.

– 41 ел үзе бер кеше гомере бит. Арытмадымы?

– Юк, арымадым. Яшем шактый олы булса да, тавышым бар әле. Кая гына барсам да, алкышлап каршы алалар, сәхнәдән төшермиләр. Мин шулай эшләп кенә яшим. Әле менә быел апрель аенда Камчаткада булып кайттык. Шунда яшәүче татар, башкорт халкы «Әлфия Авзалова килсен иде» дип, махсус чакыру кәгазе язып җибәргәннәр. Бөтен бригадабыз белән бардык, ун көн буена балыкчылар янында яшәп кайттык. Аэропорттан чыгуга, «Волга»лар белән каршы алдылар. Күз ачып йоммаслык кар явып торуга, салкын булуга карамастан, кулларыбызга чәчәк бәйләмнәре китереп тоттырдылар. Остабикәләр кебек, өйдән-өйгә кунакка йөрттеләр. Бару-кайту өчен самолетка билет хакларын да үзләре түләделәр. Ташкентка да ел саен барам, көтеп кенә торалар. Шулай булгач, мин үземне халкыма кирәк кеше дип саныйм, өйдә генә утырырга җыенмыйм.

– Ә репертуарыгызда нинди яңа җырларыгыз бар?

– Әгерҗедә яшәүче Әнвәр Закировның Гөлшат Зәйнашева сүзләренә язган «Соңлап килгән мәхәббәт» җырын башкарырга уйлыйм. Минем бик яраткан артисткам бар, матур тавышлы Хәния Фәрхи. Без аның белән икебез дә түбән тавышлылар. Аның репертуарыннан «Үпкәләмә» дигән җырын яратам. Хәниядән рөхсәт алып, шуны өйрәндем. Ә элекке җырларыма килгәндә...

Әлфия апа үзенең сихри тавышы белән җырлап та җибәрде:

«Син ант иттең, вәгъдә бирдең...»

Җыр өзелде. Әлфия апа телефон трубкасын алды.

– Кәримулла, ни хәл, җаным? Әзерләнәсеңме? Җылырак киен, яме, көннәр салкынайды. Йон оекбашларыңның барысын да алып бар. Сүтәбез дә яңартабыз аны. Старье түгел бер дә, ал, ал. Оекбаш искерми ул, табаны гына туза. Биш энә бар... Песок, чәй, май, варенье алырга кирәк. Обязательно, фатирларда яшәячәкбез. Хәзер халык бәрәңге ала. Синең турыда уйларга вакыты юк. Бу сиңа Әгерҗе районы түгел!..

Бу аның Кәрим Габидуллин белән сөйләшүе булды.

– Иртәгә телевидениегә төшерәләр. Урманда. Салкын тидермәсәм генә ярар иде. Өем дә бик салкын...

Бөтен республикабыз буйлап командировкаларда йөргән кеше буларак, үземнең дә бар нәрсәмне сумкама төяп, юлга җыенган чакларым исемә төште. Әлфия апа бит гомере буе шул юлларда йөргән. Ләкин ул әле күренекле артистыбыз – татар эстрадасының мәңге сүнмәс йолдызы гына түгел, ә балалары турында кайгыртучы Ана да, ятим туганнары өчен иң изге күңелле Апа да, хезмәттәшләре өчен акыллы киңәшче дә. Ходай түземлек, илһам, саулык-сәламәтлек бирсен аңа!..»

Бенефис

Хатын-кызлар яшьләрен яшерергә ярата бит алар. Артисткалар бигрәк тә. Яшьләрен өч-дүрт яшькә кечерәйтеп әйтәләр. Мин үзем дә берничә ел гел кырык яшьтә йөрдем. Илле тулып килгәндә дә: «Ничә яшь сиңа?» – дисәләр, «Кырык яшь!..» – дия торган идем. Картаясы килми шул!.. Менә шулай, пенсия яшенә дә җиттек! Ходайның рәхмәте, пенсия яшен дә узып киттек һәм... түгәрәк 60 дигән яшькә дә килеп җиттек бит, әй!.. Нишлисең, гомер уза, агым су кебек... 60 яшем якынлашып килгән айларда филармониябез җитәкчеләре, дус-ишләрем: «Әлфия, әйдә юбилееңны ясыйбыз!..» – дия башладылар. Әй шул юбилей дигәннәрен бер дә яратмыйм. Озын итеп доклад сөйлиләр, юбилярга кызыл тышлы папкалар бирәләр, ул папкалар шулкадәр күп була, президиум өстәле артында утырган юбилярның папкалар өеме артыннан башы гына күренә. Тамашачы арып бетә, берәм-берәм, залдан чыгып, кайтып китә... Кызыксыз, күңелсез үтә. Моннан биш-алты-ун еллар элек юбилейлар бик күп була иде һәм шулай эчпошыргыч уза иде. Соңгы елларда, әлбәттә, алай түгел. Артистлар, сәнгать кешеләре юбилей даталарын коры юбилей итеп түгел, бенефис итеп уздыра башладылар. Бенефисны күңелле итеп уздырып була. Революциягә кадәрге чорда бенефислар бик модада булган. Революциядән соң да әле шаулатып бенефислар уздырганнар, 20 нче елларда мәшһүр артистка Фатыйма Ильская бик матур итеп үзенең бенефисын ясаган. Атаклы артист, режиссер Габдулла Кариев Ильскаяга, үзенең кулыннан салып, бриллиант кашлы алтын балдагын бүләк иткән. Бенефис ул иҗат бәйрәме, иҗат кешесен зурлау, хөрмәтләү. Зурлау, хөрмәтләү, әлбәттә, кызыл тышлы папкалар бирү генә түгел, бүләкләр дә бирәләр... Җитәкчеләрем, дус-ишләрем: «Юбилей гына итеп түгел, бенефис итеп үткәрик!» – дигәч, уйладым-уйладым да, Аллага тапшырып, риза булдым. Бенефис үткәрү – бик мәшәкатьле эш. Филармониябез директоры Әсгать Сафин бу мәшәкатьләрдән курыкмады, бик ныклап әзерләнә башлады һәм бик яхшы итеп оештырды. Филармониянең җитәкче эшендә эшләүче башка иптәшләр дә, Айрат Арсланов, Илһам Шакиров һәм башкалар да бу эшне оештыруда көчләрен кызганмадылар һәм, 1994 елның 24 гыйнварында минем бенефисым, чын мәгънәсендә иҗат бәйрәмем булып, шаулап-гөрләп узды. Минем иҗат бәйрәмем генә булмады ул, гомумән, сәнгать сөюче, эстрада яратучы тамашачыларыбыз бәйрәме булды, халкыбыз бәйрәменә әверелде. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы ул көнне тамашачылар белән шыплап тулды, бик күп дусларым килгән иде. Артистлар, язучылар, композиторлар һәм башка хезмәт кешеләре җыелган иде. Шунысы мине бик куандырды, Хөкүмәтебез җитәкчеләреннән Мөхәммәт Галләмович Сабиров (республиканың ул чактагы премьер-министры), Фәрит Хәйруллович Мөхәммәтшин да сөйкемле хатыннары белән минем бенефисыма килгән иде. Шулай ук башка шәһәр, районнардан да, авыллардан да, Казан

завод-фабрикаларыннан да җитәкче эшләрдә эшләүче, мине үз иткән кешеләр килеп, бенефисымда катнаштылар, мине бәхетле иттеләр. Хәтта Төркиядән, Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан телеграммалар җибәреп, мине зурладылар. Мине котларга сәхнәгә йөздән артык кеше күтәрелде. Алда язганымча, мактаулардан башым әйләнмәде анысы, әмма ләкин дулкынланудан башым әйләнеп китте, сәхнәне яктырткан прожекторлардан күзләрем чагылып, күз алларымда утлар биеште. Бик зурладылар, 40 елдан артык сәхнәдә үткән гомеремдә минем мондый зурлауны, мондый хөрмәтне күргәнем юк иде. Зур-зур бүләкләр бирделәр... Бенефис концертымнан кергән барлык акчаны филармониябез директоры тамашачылар алдына чыгып, миңа бүләк итәчәген әйтте. Әлбәттә, иң зур бүләкләр Хөкүмәтебез бүләкләре булды. Республикабыз Президенты Минтимер Шәрипович Шәймиев Президент фондыннан 1 миллион сум акчалата премия бирде. Республикабызның премьер-министры туган җирем Актанышта миңа бер йорт салып бирергә вәгъдә итте. Әлбәттә, дөресен әйткәндә, мин, шундый йортны салып бирегез дип, тамашачылар алдында үзем сорадым. Кайберәүләр миңа: «Ничек итеп, син уңайсызланмыйча, миңа йорт салып бирегез, дип әйттең», – диләр. Уңайсызланмадым, мин хәер сорашып үскән кеше, сорап алуның ни гаебе бар, дип уйладым. Премьер-министр вәгъдә биргәч, залдагы тамашачылар гөрләтеп кул чапты. Димәк, минем үтенечемне алар дөрес аңладылар, хупладылар. «КамАЗ» акционерлык җәмгыяте коллективы «Ока» җиңел машинасы, Актаныш районы хезмәт ияләре исеменнән, районның администрация башлыгы Таһир Ахмаев – бер сыер, Тукай районы хезмәт ияләре исеменнән, районның администрация башлыгы Васил Хажиев бер тай бүләк иттеләр. Ат бит ул!.. Аны ничек карарга кирәк?! Зәй совхозы бер бия-тай бүләк итте тагын. Ләкин аларны балконда асрап булмас бит! Ат хуҗалары: «Бүген килеп ал, Әлфия апа», – дип әйтәләр дә әйтүен... Ә ул сыерны, инде сәхнәдә эшләми башлагач, гомер булып яши алсам, асрармын, Алла боерса. Карармын, савармын, сабый чакларда сыер күрми, сөт күрми үскәнне кайтарырмын, исән булсам. Актанышта йорт салып бирсәләр, җәйләрен балаларым, оныкларым белән шунда яшәргә исәп. «Ока» машинасын, бәлки, үзем йөртермен!.. Нигә, әнә, чит илләрдә әбичәбиләр чалбар, куртка киеп, яшьләрчә әтәчләнеп машина йөртәләр бит әле, без кемнән ким?! Шаярам гына, бусы булмас, әлбәттә!..

Мине шулай зурлаганнары өчен, Хөкүмәтебез җитәкчеләренә бик зур рәхмәтләр әйтәм. Шулай ук мине олылаган барлык район, предприятие хуҗаларына рәхмәтемнең чиге юк. Актаныш, Тукай районы администрация җитәкчеләре Таһир Ахмаевка, Васил Хажиевкә миңа шундый зур бүләкләр бирүләре өчен зур рәхмәт! Аннары тагын Зәй районы администрациясе башлыгы Рәшит Хәмәдиев район тамашачылары исеменнән бенефисымны котлап, миңа зур бүләкләр бирде. Алабуга районы администрация башлыгы Илдар Ишков, Түбән Кама районы администрация башлыгы Әхтәс Галиәхмәтовлар

да бенефисым уңае белән кыйммәтле бүләкләр биреп, мине бик зурладылар. Завод-фабрикалар, күп кенә колхоз, совхозлар, акционерлык җәмгыятьләре, аерым предприятиеләр дә мине бик хөрмәтләделәр. Казанның компрессорлар заводы, «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсе, Татпотребсоюз, Минзәлә һәм Мамадыш спирт заводлары, Зәй автоагрегат заводы (директорын аерым басым ясап әйтеп китим әле, Вадим Георгиевич Мишин – милләте белән урыс, үзе татар артистларын ярата, татарча матур итеп җырлый), Питрәч кошчылык фабрикасы, Салмачы совхозы, Казан ит комбинаты, Кокушкино кошчылык фабрикасы, Казан киез итек сәүдә базасы, «Алтын руно» хезмәт коллективлары исеменнән зур бүләкләр биреп кенә калмадылар, бенефис-концертымны уздыру өчен матди ярдәм күрсәттеләр, спонсорлык иттеләр. Шул урында менә нәрсә турында әйтәсем килә: хәзер район, авыл җирләрендәге җитәкчеләр, завод-фабрикаларның директорлары барысы да диярлек яшьләр – заман егетләре. Алар укымышлылар, культуралылар, сәнгатьне аңлыйлар, яраталар. Артистларны ихтирам итәләр. Игътибарлылар. Мин инде кайберләреңә мөрәҗәгать итәргә җыенгач, мине бу яшьләр белеп тә җиткермиләрдер инде, танымыйлардыр, дип уйлыйм, кабинетларына уңайсызланып кына керәм. Таныйлар, беләләр бит! «Әлфия апа, әйдә, уз, уз, нинди җилләр ташлады? Ни үтенечегез бар?» – дип, урыннарыннан торып, каршы алалар. Үтенечемне үтәргә әзер торуларын әйтәләр. Элекке еллардагы җитәкчеләр белән чагыштырам да, исем китә. Элекке еллардагы райком секретарьларының күбесенең кабинетына кереп, сүз әйтергә куркып тора идек. Алар хан кебек утыралар иде. Эш урыннарында аларны тотып булмый торган иде. Заман үзгәрде, кешеләр дә, җитәкчеләр дә үзгәрде.

Бенефисымда тагын сәнгать сөюче бертуган Рафис һәм Нәфис Кашаповлар, җырчы-композитор Фирзәр Мортазин, җырчылар Хәмдүнә Тимергалиева, Зөһрә Шәрифуллина, яшь җырчылар Салават Фәтхетдинов, Айдар Галимовлар да мине кыйммәтле бүләкләр белән олыладылар. Мин аларның барысына да зур рәхмәтләр әйтәм. Бенефисымда мине бүләкләгән, зурлаган барлык иптәшләргә, дусларга рәхмәт. Исем-фамилияләп барысын да санап чыгу мөмкин түгел, ул исемлек бик озынга китәр иде. Кемнедер исем-фамилиясе белән искә алып китә алмасам, зинһар, үпкәли күрмәгез. Бенефисымда катнашкан һәркайсыгызга гомерем буе рәхмәтле булырмын.

Шулай зурлап, бенефисымны үткәрүне оештырган филармониябез җитәкчеләре Әсгать Сафинга, Илһам Шакиров, Айрат Арслановка, сәхнәдәш дусларым Кәрим Габидуллин белән Сания Габидуллинага, Алмаз Хәмзингә, бенефис-концертымда җырлаган, биегән артист дусларыма, мине котларга килгән композиторларга, язучыларга, шагыйрьләргә барысына зур рәхмәт!

Шагыйрә Лена Шагыйрьҗан ул кичне миңа багышлап язган шигырен укыды:

1980 ел



Әлфия апа үзенә бер!
Күпне күргән Апам бу, дим,
Карыймын да йөзенә бер:
Җырчылар күп бездә, шөкер,
Әлфия апа – үзенә бер!..

Хөрмәтемне көйгә салып,
Әйтим әле үзенә бер...
Тыңлаган саен сокланам,
Әлфия апа – үзенә бер!..

Язмышының гыйбрәтеннән
Үзәкләрем өзеләдер...
һәрбер җыры күкрәгеннән
Энҗе булып тезеләдер...

Йолдызлар арасында да
Унга түгел – йөзенә бер...
Йөз дә түгел, мең дә түгел –
Әлфия апа – үзенә бер!..

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов бенефис-концертымда миңа багышлап укыган шигырендә мине тагын да ныграк мактап, сандугачка тиңләде:

Әлфиягә мәдхия

Бармы соң безнең татарның
Хәсрәтсез торган чагы?! –
Хәсрәтне оныттыра кайчак
Моңлы Актаныш ягы.

Күк капусын гомергә бер
Безгә дә Тәңре ачты –
Иңдерде Актанышка ул
Иң моңлы сандугачны!

Беләбез, бүген дөньяның
Моңнары кемдә генә –
Сыя да бетә икән ул
Сандугач йөрәгенә.

Сүнгән күңелгә сөюне
Ул гына сала икән.
Халыкны бер сандугач та
Юата ала икән!..

Иртә-кич сайрый да сайрый –
Юана татар җаны.
Шулай ярата икән ич
Сандугач кына аны!..

Ул сандугач дигәнебез –
Әлбәттә, Әлфиябез.
Мең яшә, безнең бәхеткә
Тәңредән иңгәнебез!..

Сайрый күр! Җиде... юк, җитмеш
Миллион татар тыңлар!..
Синең җырың җыр гынамы? –
Сандугач сузган моңнар!..

1987 ел



Бенефисым тантаналы, матур узды. Театр бинасы тамашачылардан, артистлардан торган зур бер гаилә кебек булды. Әйтерсең, меңләгән кешедән торган зур бер гаилә үзенең гаилә бәйрәменә җыелган!..

Тантаналы, шатлыклы узса да, вакыт-вакыт тамашачы тынып калып, тирән уйларга да бирелде. Бенефисны алып баручы Алмаз Хәмзин минем балачагымда күргән михнәтләрне сөйләгән чакта, залда күзеннән яшьләрен сөртеп утыручылар да булды. Аларга кушылып минем күземнән дә яшьләрем тамды. Бенефис шатландырды да, елатты да, көлдерде дә. Бенефис барышында кызык кына мәзәкләр дә килеп чыкты. Берәм-берәм сәхнәгә менеп котлаучылар арасында мин танып җитмәгән кешеләр дә булгалады. Минем танып җитмәвемне сизгән берәү болай ди: «Әлфия ханым, исеңдәме? Без синең белән ниткән идек...» Түзеп торып булмады, көләсе килә башлады. Мин:

«Ниткән идек соң?..» – дидем. Ул һаман: «Ниткән идек... ниткән идек...», – ди. Мин: «Кайда, кайчан ниткән идек соң?» – дим. Үзе дә көлә башлады бу. Тәки нишләгәнебезне ачыклый алмыйча, икәүләп бик мәзәк хәлдә калдык. Бенефис барышында мондый кызыклар шактый булды.

Әнә шулай шаулап-гөрләп, зур сәнгать бәйрәме булып, бенефисым узып та китте. Бу – минем үз гомеремдә иң зур, иң матур вакыйга! Мин Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясен алуымны – Бәхет тавының иң югары ноктасына ирешү бу дип, шатланган идем. Бу бенефис та тагын бер кат шулай Бәхет тавының иң югары ноктасына ирешү булды. Ятимлек белән үсеп, үз көчем, тырышлыгым белән эстрада сәхнәсе түреннән урын алу – бу инде, чынлап та, зур бәхетләргә ирешү.

1994 ел дәвамында концертлар бирдем. Бу концертларны бенефис концертлары дип атадык һәм һәркайда тамашачылар бик җылы каршы алдылар. Бу бенефиска багышланган концертларым Чаллы, Кукмара, Питрәч, Актаныш, Түбән Кама, Теләче, Зәй һ.б. районнарда булып узды. Район үзәгендә булсынмы, авылларында булсынмы – һәркайда концертларыбыз шаулап-гөрләп үтте, тамашачылар безне чәчәкләргә күмделәр. «Бенефисыңда катнаша алмадык, соңга калып булса да котлыйбыз», – диеп, миңа күп кенә бүләкләр бирделәр, һәркайда табын әзерләп, безне кунак иттеләр, сыйладылар. Район, авыл җирләрендә халыкның, җитәкчеләрнең шулай зурлавы бик күңелгә тиде, елап җибәргән чакларым да булды. Инде болай шаулатып-гөрләтеп концертлар биреп эшләп йөри алмам, гастрольләргә чыга алмам дип, кайбер сәхнәләрдә тамашачы белән саубуллашып, хушлашып киттем. «Бу килүем соңгы килүем булыр инде, дуслар», – диеп сәхнәдән чыгып барганда, күзгә яшь тыгыла, сәхнә артында үксеп елыйсы килә, көчкә тыелам. Кайбер тамашачылар сәхнәгә менеп, минем кулны кысып, рәхмәтләр әйтәләр дә: «И Әлфия апа, бәгырькәем, картаймагыз әле, җырлагыз әле, алай хушлашып китмәгез әле, тагын килегез!» – диләр. Җырлыйсы килә, әлбәттә, бер дә туктыйсы килми. Тамашачының, халыкның мәхәббәтен тою картаюыңны да сиздерми, йөрәк һаман яшьләрчә. Картаямыни соң йөрәк?..

Картаямыни соң йөрәк?..

Картаямыни соң йөрәк?..
Маңгайлар сырланса да...

Шаулап-гөрләп үткән бенефисымнан соң уйланам-уйланам да: картая, әйе, йөрәк тә картая икән; тик күңел генә яшь кала, дип куям. Нигә соң алайса, картаямыни соң йөрәк, дип жырлыйсың дип әйтерсез?.. Жыр бит ул!.. Жырның ертыгы юк, диләр. Жыр бит ул – теләк, хыял, омтылыш!

Кеше жырда теләген, омтылышын әйтә. Жыр һәрвакыт шулай. Кеше жырда күңелендә йөргән теләген әйтә. Мәхәббәт жырлары да шулай. Мәхәббәт жырларында кеше яратасы килүен, яратыласы килүен, мәхәббәттә бәхетле булырга теләвен жырлый. Менә мин дә картаясы килмәвем турында жырлыйм. Соңгы елларда репертуарыма керткән бу жырым минем күңел халәтемне тасвирлый – картаясы килми шул!.. Ә картлык килә. Синнән сорап тормыйча килә. Кайберәүләр шулай: «Юк, йөрәк картаймый ул», – диләр. Нишләп инде кешенең бөтен организмы картайганда, йөрәк кенә яшь калсын, ди. Йөрәк тә картая. Ләкин картаясы килмәү – кешене яшь тота. Яшьләрчә күренгән кеше – картаерга тырышмаучы кеше ул. Мин дә менә картаерга тырышмыйм. Картаерга тырышмыйча картаю насыйп булсын. Картлыкның да үз күркәмлеге бар. Шуны тоеп яшәргә кирәк икән. Мин аны тоям. Матур картлык килсен иде. Балаларымның, балаларымның балалары матур, таза, сау-сәламәт булып үскәнне күрү картлыгы – бәхетле картлык ул. Мин әнә шундый бәхетле картлык көтәм. Көтәм дип әйтү дөрес түгел, картлык көттерми, үзе килә ул.

Тавыш та картая. Нигә картаймасын? Тавыш жепселләре корычтан ясалмаган бит. Корыч та еллар узгач туза. Мин дә, тавышым картаймады дип, мактана алмыйм.

Картлык килгәч, узган гомерләрең турында уйлыйсың икән. Ничек узган гомерең, яшьлегең матур узганмы, картлыгың матур киләме?.. Мин үз гомеремнең ничек узганы турында уйласам да, начар узмаган икән дип, шөкерана кылам. Яшьлегем матур узды. Үзем теләгән эш белән узды, жырлап, сәхнәдә яшьнәп узды.

Сәхнә гомеремдә мин бик күп жырлар жырладым, яшьлек турында, мәхәббәт турында жырладым. Шуны төшендем: мәхәббәт – яшьлек юлдашы икән! Менә хәзер миндә мәхәббәт яшьлек хатирәсе генә булып калды. Нигә соң алайса:

Мәхәббәт яшьләрдә, диләр,
Була ул һәркемдә дә.
Мәхәббәтсез яшәп булмый
Олыгайган көннәрдә дә, –

дип җырлыйсың диярсез. Тагын шул сүз: җыр бит ул – җырның ертыгы юк! Тагын теләк, омтылыш. Теләгем, омтылышымны җырлыйм. Мәхәббәт һәрвакыт булсын иде дә бит. Юк, килеп җитә бервакыт – мәхәббәт синнән китә, хыялда гына кала. Җырның сүзләрен язган артист Гата Нуруллинның, бәлки, мәхәббәте китмәгәндер, инде пенсия яшендә дә, бәлки, ул гашыйк булып яшидер, анысы турында мин белмим, әмма минем күңелдән мәхәббәт китте, җырымда гына мин мәхәббәт дөньясына кереп чыгам, ә тормышта мәхәббәт миннән ерак йөри. Минем мәхәббәтем оныкларыма күчте. Оныкларымнан да яраткан кешем юк бу дөньяда.

Бәлки, шундый кешеләр бардыр: картайгач та гашыйк булып йөриләрдер. Яки «мин гашыйк» дип сөйләнәләрдер генә. Мөгаен, сөйләнәләрдер генә. Ә алай юкны сөйләнеп йөрү – кылану гына бит ул. Кыланырга яратмыйм. Менә шулай, дусларым, яшьлегендә мәхәббәт утларында янган артистканың тыныч кына картлыкка кереп баруы турында укып гажәпләнерсез, бәлки. Һәр нәрсәнең үз вакыты бар дигән сүзләр артисткага да карый, артистка да – адәм баласы бит!

Әлфия сүнгән икән, димәгез тагын, хыялларым, теләкләрем сүнмәде. Хыялым белән мин мәхәббәтнең серле тауларында йөрим, мәхәббәт йолдызлыгында гизәм – хыял яшәсен!.. Әлләни дә бер яшьләре белән минем чамадагы бик сөйкемле кешеләр очрап куя. Яки телевизордан күреп каласың. «Ah!» дип куясың. Менә шундый кеше: «Әйдә, Әлфия, картлык көнебезне бергә үткәрик!» – дисә, каршы килмәс идем, дип уйлаган чакларым булгалый. Күңел бит!.. Хыялый күңел!.. Күңел картаймау шулдыр инде ул!..

Ә шулай да яшәү матур!.. Дөньяда җыр булганга матурдыр ул! Җырлаган җырларым узган юлларыма сибелеп калган чәчәкләр кебек! Ул чәчәкләр шиңмәгәндер, орлыкларын сипкәндер, дөнья тулы чәчәкләр – җырлардан яралгандыр алар!.. Бәлки, киресенчә, җырлар чәчәкләрдән яралгандыр!..

Җыр!.. «Җырланмаган әле безнең җыр» дигән матур җырның сүзләре белән әйтсәм, җырланмаган әле минем җыр, диясе килә. Әйе, җырлар җырланып бетмәгән кебек, һаман яңа җырга сусап тибә бу йөрәк!.. Яңа җырлар җырларга теләп яшәү яшәтәдер җырчыны!.. Җырлыйсы килә!.. Җырга багышланган тормыш юлым туктап калмас төсле!.. Бөек Тукай әйтмешли:

Еллар үтеп бара торгач картайсам да,
Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да, –
Күңелем минем япь-яшь калыр, һич картаймас,
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.
Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә.
«Без китәбез, сез каласыз!» – дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак белән күмгәндә дә...



2008 ел

Иң бәхетле артист – сәхнәдә үлгән артист, диләр. Мин ничек үләрмен, анысын белмим. Гомумән, мин үләрмен төсле түгел. Яшик әле!.. Җырлый-җырлый яшик!.. Җырдан мәңге аерылмыйк!.. Рәхмәт, сиңа, Җыр!.. Кешене яшәтүче көч – Җыр, мәңге яшә!.. Татар җыры яшәсә, татар халкы үлмәс!..

Мөфти Тәлгать Таҗетдин үзенең бер вәгазь-чыгышында болай дип әйткән икән: «Халкыбыз динен, гореф-гадәтләрен, телен югалтырлык төрле кысуларга дучар булган елларда, җыр тирәсенә тупланды. Җыр аны югалудан саклап калды...» Әйе, мин республикабыздан чит өлкәләрдә концертлар биргәндә, моңа шаһит булдым – татарча белмәгән татарлар да концертларыбызга килә, татар җырын тыңлый, сүзләрен аңлап җитмәсә дә, моңын аңлый, үзенең татар милләтеннән икәнлеген тоеп, концерттан үз асылына кайтуын аңлап китә. Кайберләре сәхнә артына кереп, оялып кына, үзенең инде ана телен белмәвен әйтә, шулай да концертны яратканын, татар моңнары күңелен сафландырганын әйтә, рәхмәтләр укый. «Мин үземнең татар булуымнан ояла идем, хәзер оялмаячакмын. Бу концерттан мин үземнең татар булуым белән горурланып китәм. Татар җыры матур, моңлы. Шундый җыры булган милләт баласы булу хурлык түгел!..» – диючеләр бар. Әйе, җырыбыз яшәсә, милләтебез яшәр!..

Җырчы тикмәгә генә җырлап йөрми, халкы өчен, милләте өчен җырлый. Минем дә сәхнәдә кырык елдан артык җырлап йөрүем тикмәгә генә булмагандыр, шәт?.. Шул турыда уйлыйм да, сәхнәгә киләчәк яшь җырчыларга бөек Тукаебызның тагын бер шигъри юлларын исләрендә тотарга киңәш бирәм:

Файдасыз җырлар җырламасын иде яшьләр!.. Җырчы файдалы җырлар җырласа, халкы күңелендә мәңге калыр!.. Җырларында калыр!..

Безнең сөекле җырчыларыбыз Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Вәһапов, Зифа Басыйрова, Сара Садыйкова җырларында калдылар, алар халкыбыз белән бергә җырларында яшиләр. Мин дә җырларымда калсам иде – Ходай миңа шундый язмыш бирсен иде!..*

Казан. 1995 ел



2008 ел

* Әлфия Авзалованың истәлекләре тәүге мәртәбә Гөлшат Зәйнашева эшкәртүендәге «Үзем турында» китабында 1995 елда нәшер ителде. – *Редакция искәрмәсе.*



ӘЛФИЯ АВЗАЛОВА ТУРЫНДА

Минтимер Шәрип улы ШӘЙМИЕВ,
Татарстан Республикасының Беренче Президенты,
Дәүләт Киңәшчесе

Халкыбызның газиз баласы

Әлфия Авзалова – халкыбызның сөекле җырчысы, олугъ моң иясе, мәдәниятебездә тирән тарихи эз калдырган лаеклы кызы. Аның халкыбыз алдындагы хезмәте шулкадәр олы, шулкадәр көчле һәм тәэсирле – без аның җырларынтыңлаган саен соклана-соклана искә алабыз. Мин аңа гел якын итеп Әлфия дип эндәшә идем, чөнки ул – халкыбызның газиз баласы, тормыш авырлыкларын халык белән бергә кичергән, аның кайгысын, шатлыгын үз йөрәгенә моң итеп җыеп үскән. Биш яшеннән ятим калган кызчыкны халкыбыз үз кочагына алган. Аның тормыш юлын күзаллаганда, ирексездән Тукай юллары искә төшә:





«Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңгаемнан милләтем».

Безнең киң күңелле милләтебезнең олы җанлы кешеләре үз вакытында аңа белем алырга, үсәргә ярдәм иткән. Зур рәхмәт аларга. Иң мөһиме, әлбәттә – Әлфиянең үз таланты, тырышлыгы, кыюлыгы, чаялыгы, барлык каршылыкларны җиңеп баручы иҗади омтылышы.

Әлфия үзе бөтен дөньяны урап чыкты дисәк тә ялгыш булмас, үзе барып җитә алмаган җиргә – моңы, җырлары барып иреште. Ул үзенең дәртле, мәгънәле, моңлы җырлары белән җир йөзенә сибелеп яшәүче милләттәшләребезне берләштереп, рухларын ныгытып торды. Төрле-төрле телләрдә җырлар өйрәнеп, күп халыклар йөрәгенә сукмак салды, татарны дөньяга танытты.

Әлфия җырны җырлап бирә белә иде, бу, әйтергә кирәк, сирәк талант һәм аны сүз белән генә аңлатып та булмас. Җырны аның кебек башкару – тәмен, кадерен белеп, моңы түгелмәслек итеп йөрәк аша җиткерү һәр җырчыга да бирелмидер, мөгаен. Әлфиянең гомере – җырлап узган гомер ул.

Шәхсән мин үзем, Әлфия җырларының тәэсирен, якташы буларак, аеруча сизә идем. Җыр сүзләренең актанышчарак яңгырашы җанга якын, әткәй-әнкәйне, авылны сагынган күңелне юата шикелле. Безнең якларның гүзәллеге Әлфия җырларында тагын да матуррак чагыла кебек тоела.

«Ямансулап болыннарны буйлама, онытканды инде диеп уйлама...
«Кайтам инде кайтам туган ягыма, кырларыма, тугайларыма», –

дип җырлавын ишеткәч, чыннан да күз алдына туганҗир килә, аның басулары өстеннән сызылып, бөтенебезгә таныш – «Актаныш таңнары» ата...

Тиңсез сандугачыбыз Әлфия Авзалова иҗатына багышлап үткәрелүче мәшһүр җыр бәйрәменең – Әлфия Авзалова исемендәге конкурс-фестивальнең күп еллар элек Актаныш җирендә, Актаныш районы хакимияте ярдәмендә барлыка килүе дә табигый хәл. Анда Әлфиянең үзенең дә катнашуы нур өстенә нур була иде. Бу конкурсның елдан-ел колачлырак һәм әһәмиятлерәк була баруы, кунакларның һәм катнашучыларның арта торуы мәгълүм. Быел исә аның халыкара фестиваль-бәйге дәрәҗәсенә күтәрелеп, Татарстан хөкүмәте, Казан шәһәре мэриясе, Бөтендөнья татар конгрессы һәм башка абруйлы оешмалар булышлыгында беренче тапкыр зурлап Казанда үткәрелүе – аның исемен мәңгеләштерү юнәлешендә лаеклы гамәл дияр идем. Олы иҗат юлына Әлфия Авзалова исеменнән фатыйха алу – яшь җырчылар өчен зур дәрәҗә. Әлфия үзе яшь талантларга һәрчак игелекле булды, шөкер, яшьрәк буын җырчылары да аңа исән чагында булдыра алганча кадер-хөрмәт күрсәттеләр.

Татар халкы Әлфиягә мәңге рәхмәтле булачак. Ул – безнең чорның бизәге, гасырларга каласы милли мирасыбызның бәһасез хәзинәсе. Моң патшабикәсе. Еллар үтәр, гасырлар узар, заманалар үзгәрер, буыннар алмашыныр, ләкин Әлфия Авзалова җырлары, татар рухының иҗади өлгесе булып, милләтебез сагында торыр – без моңа ышанабыз.



Илсур МЕТШИН,
Казан шәһәре мэры



Җыр кызы

Чын мәгънәсендә халык артисты Әлфия Авзалова феномены – кешелек өчен зур могҗиза. Бу серне ачу максатыннан, әлеге бөек җырчы турында киләчәктә күп китаплар язылыр, кинофильмнар төшерелер әле. Ул әлеге югарылыгына халыктан аерылгысызлыгы белән иреште дип уйлыйм. Шуңа күрә дә ул – газиз халкын, халкы бөек җырчысын аңлады, алар бербөтен һәм аерылгысыз. Аның холкындагы туры сүзлелек, эчкерсезлек, юмор, үз дәрәҗәсен белү, башкаларга хөрмәт белән карау, авырлыклар алдында югалып калмау кебек асыл сыйфатлар бер-берсен тулыландырып тора. Менә шулар могҗизалы шәхесне тудыра да инде. Ул соңгы көннәренә кадәр милләтенә, тамашачысына, халкына тугры, игелекле булды. Әлфия апаның табигатендә ясалмалык юк иде.

Аның җыр-моңнары күңел түреннән агылды. Концертларына бернинди реклама кирәк түгел иде, искитмәле чыгышлары халык белән шыгрым тулы залларда узды, һәрчак көчле алкышларга лаек булды. Моңа карап ул беркайчан да масаймады, гади Җир кызы – Җыр кызы булып кала белде. Ул җырлаган һәрбер җыр халык теленә күчте, күңел түрендә яшәде. Халык

Әлфия ханымның концертларыннан тормыш ямен тоеп, күңеле күтәрелеп, яшәренә көч алып кайтып китте. Ул туган җиргә самими мәхәббәт хисләрен, кеше язмышларына бәйле уй-фикерләрен, тылсымлы җырлары аша, күңел кылларын тибрәтерлек итеп, үзенә генә хас аһәң белән, җиренә җиткереп башкарды. Тамашачы белән җырчы арасында нәфис, зәвыклы, өзелмәс җепләр бар иде. Үзенең тирән, нечкә тоемлавы белән Әлфия ханым халкыбызның күңелен аңлый алды, бер дулкында тибрәлде. Көнгә биш-алты концерт биреп тә, ару-талуның ни икәнен белмәгән артистка яраткан тамашачылары илһам бирде. Аңа меңләгән тамашачыдан торган тулы зал да, кечкенә авыл клубы да бер үк дәрәҗәдә якын булды. Ул һәр җирдә дә тулы программа күрсәтеп, бер генә номерны да кыскартуга юл куймый иде.

Әлфия ханым һәрвакыт максатчан һәм гадел булды, шушы күркәм сыйфатлары аны биеклеккә күтәрде, абруйлы итте, кабатланмас шәхес итеп формалаштырды. Үз-үзенә һәм башкаларга карата таләпчәнлеге белән ул бик күпләргә үрнәк булды.

Миңа искитәрлек бер вакыйганы сөйләгәннәр иде. Бер концерт вакытында Әлфия ханым бик каты авырып китә, сәхнә ябыла. Артистның кан басымы 240ка җиткән икән! «Ашыгыч ярдәм» машинасын чакыралар, әмма ул хастаханәгә барудан баш тарта. Табиблар, чарасызлыктан, «Дәваланудан үз теләгем белән баш тартам» дигән язуга кул куярга кушалар. Көчле рухлы артист бирешми: «Миңа хәзер үк кан басымын төшерә торган укол кадагыз, сәхнәгә чыгачакмын», – ди. Ул дәваланудан баш тарту белешмәсе астына: «Үлсәм, сәхнәдә үләм!» – дип язып та куя. Концерт дәвам итә, бөек җырчы тамашачылар алдындагы бурычын тулысынча үти.

Башкала мэры булганнан соң, мин Әлфия апабызны халкыбызның иң зур, дәрәҗәле бәйрәменә – Сабан туена чакырдым. Сабан туе ул чагында Казан ипподромында була торган иде. Аннары башка елларда, Аккош күле Сабан туенда да, ул халкыбызга сокландыргыч җыр-моңнарын бүләк итте. Аңа булган кайнар алкышлар – тамашачыларның олуг, эчкерсез мәхәббәте бүген дә күз алдымда тора.

Әлфия ханым соңгы көнгәчә сынауларга баш бирмәде – күңеле һәрчак күтәренке, йөзе елмаюлы иде. Ул тамашачысын һәрвакыт, тәүге күргәндәй, ихластан сәламләде, соңгы күргәндәй хушлашты. Әлфия Авзаловаңы искә алу концертына без – хатыным, иң кече улыбыз белән бергә бардык. Улым, тын да алмыйча, бөек җырчының беркемне дә кабатламый торган искитмәле җырлавын бик тәэсирләнеп тыңлап утырды. Ни кызганыч, без Әлфия апабызның тере тавышын башка ишетмәбез инде, әмма безнең балаларыбызга, киләчәк буын вәкилләренә ул матур, кабатланмас җыр-моңнарын калдырып китте.



Гүзәл АВЗАЛОВА,
Әлфия Авзалованың олы кызы

Безнең өчен әниебез – иң кадерле, иң газиз, иң зирәк, иң гадел кеше. Мин аңа безгә яхшы тәрбия биргәне, тормыш серләренә өйрәткәне, дөрес юлны күрсәткәне, гомер буе җил-яңгырдан ышыклаганы, биргән алтын киңәшләре өчен мең рәхмәтле! Тормыш юлымда очраган кешеләр арасыннан дусларны сайлап алганда да миңа әнием киңәшләре ярдәмгә килә. Безнең җаннарыбыз аерылгысыз. Сурәтендәге карашыннан да мин аны ишетәм, аңлыйм, нәрсә әйтәсен сизәм. Аның күңеле кебек ачык, киң күңел, белмим, башка бармы икән? Ул күңел без-якыннарына гына түгел, меңләгән тамашачысы өчен дә киртәсез, чикләүсез булды.

Бүгенге тормышта ирешкән уңышларым, тоткан урыным, яулаган биеклекләрем белән мин әниемә бурычлы! Ул беркайчан да үз-үзен аямады, үзенә карата да, башкаларга карата да бик таләпчән булды. Югары иҗади сәләт, күңеленә дөнья зары, җиһан моңы сеңгән гүзәллек аны меңнәр арасыннан аерып тотты. Сәхнәдән алып баручы әнием исемен әйтеп бетерүгә үк, тамашачы гына түгел, ә бәлки, ул чыгыш ясаячак диварлар да хәрәкәткә килә кебек иде миңа. Алкышлар... чәчәкләр... бүләкләр... тамашачы мәхәббәте...



Бу кадәр дан-шөһрәткә ия булган, халкы кулында күтәреп йөрер дәрәҗәдә яраткан бөек шәхес, безнең өчен гап-гади, тормыш йөген зарланмыйча нәфис иңнәрендә сөйрәп барган әни була белде. Бездә дә ул шул гадилекне, кешелеклелекне тәрбияләде. Аның иҗаты бик тә күпкырлы иде. Күңелле мәхәббәт җырларыннан алып, җан түренә үтеп керә, елата, юата торган югары сәнгать әсәрләренә кадәр үтемле итеп башкара алды ул. Башкару осталыгыннан кала, ул әле оста юморист та, дипломат та, әллә нинди кызыклы яңалыклар уйлап табучы фантазер да, бөтен залны үз моңына әсир иттерә алган шәп дирижер да иде. Аның һәрбер сәхнә әсәре – тормыштан алынган чынбарлык. Халык аны матур тавышы өчен генә түгел, шул матур моңга уралган эчкерсез күңеле, милләте өчен җанын ярып бирергә әзер булган тәвәккәллеге, кыюлыгы өчен дә яратты. Аның өчен иле, Ватаны, халкы, тамашачысы аеруча кадерле, якын иде. Сәхнәдә басып торганда, яшәү көчен үзенә ышаныч белән карап, балкып утырган күзләрдән алды. «Көчле алкышлардан милләтнең бердәмлеген, көчен тоям», – ди торган иде ул.

Тыңлаучы җырны җаны белән тоя, шуңа да өлкән буын кешеләре, хәзерге җырларга караганда, элеккеге җырларга өстенлек бирә. Чыннан да, элеккеге җырларда җанга үтәр тирән хис яшеренгән. Әнием репертуарын сайлаганда нәкъ менә кеше күңелен укый ала торган сүзләргә өстенлек бирде.

Күп җырларын алар бергә, икенче әниебездәй якын, кадерле Гөлшат апа Зәйнашева белән уртага салып иҗат иттеләр. Ул җырлар мәңгелек! Аның



тулы репертуары 600ләп җырдан тора. Бу җырлар барысы диярлек радио-телевидение фондларында саклана. Алар халыкка үз вакытында меңләгән тираж белән пластинкалар булып таралды. Әле күптән түгел генә әниемнең 100 җыры яздырылган диск дөнья күрде.

Халык белән шыгрым тулы заллар, кочак-кочак чәчәк бәйләмнәре, бөек җырчы турындагы легендалар, риваятьләр, ачы теллеләрнең гайбәт сүзе – болар барысы да үткәндә калды. Әнием тормышта алтын урталыкны тапты: дәрәҗәм бар дип, югарыга сикермәде, кимсетәләр дип, упкынга төшмәде. Тирән моң, кайнар йөрәк, аек акыл белән бөтен киртәләрне узып, халык күңеленә мәңгелеккә якты моң булып кереп урнашты. Ул гомер-гомергә илем, Ватаным, халкым, дип яшәде. Бүген халкыбыз әниебезне зурлый, хөрмәтли, онытмый икән, димәк, аның тырышлыгы бушка китмәгән, аның юлы дөрес булган! Бүгенге сәнгатебез аның эзеннән атласа, милли моңнарыбыз югалмас, халкыбыз, милләтебез яшәр, дөньяны матурлык, моң саклап калыр!

Их, борасы иде тормыш тәгәрмәчен
Үткәннәргә, әниле чакка...
Әйтми калган бөтен назлы сүзне,
Тезәр идем сарылып кочакка...

Кулларыннан үбеп алыр идем,
Сыйпар идем дулкын чәчләрен...
Шушы матур уйларга төренеп,
Йоклап китәм һәркөн кичләрен.

Чынбарлыкта каберенә киләм:
Ташы суык – җанны өшетә.
Нигә икән без матур сүзләрне
Әйтәлмибез исән кешегә?..
...Үксез бала кебек елап торам,
Сулык-сулык кабер читендә...

Зөлфия НИГЪМӘТҖАНОВА-АВЗАЛОВА,
җырчының кече кызы



Мин – бу дөньяда иң бәхетле кешеләрнең берсе. Чөнки мине күңеленнән дәрьядай моң ургылып торган, миллионнарның кумиры, бөек шәхес, мәрхәмәтле, изге Ана тапкан, баккан! Балаларыма да, оныкларыма да, иремә дә язган бу чиксез зур бәхет!

Сүземне әле үзем дә хәтерләмәгән иң кечкенә чагымнан башлыйм. Әни белән яраткан Гөлшат апам, икесе бергә очрашканда, гел бер кызык вакыйганы искә алып сөйли торганнар иде. Мин бик кечкенә чагымда ук, әни мине үзе белән гастрольгә алып киткән. Бу сәфәрдә сәхнәдәшләре, гаилә дусларыбыз – Гөлшат апа белән гармунчы Зиннур Гыйбадуллин да булган. Концерт вакытында йоклап киткәнмен һәм мине уңайлы куяр урын булмагач, аптырап торманаганнар – Зиннур абыйның гармун чемоданына салганнар. Авызымда – кара икмәкне марляга ураган имезлек, ә үзем йоклаган килеш, музыка тактына туры китереп, чемоданның кырыена тибепме-тибеп ятам икән, ә үзем йоклыйм... Шуңа да алар миңа, үсә төшкәч тә, синең моңың бар, синең тавышың матур, син артист булырга тиеш, дип гел әйтә килделәр. Без әнинең әнисенең бертуган апасы – Закирә әби белән бергә яшәдек. Ул безнең өчен иң кадерле, иң якын әбиебез булды. Без аны, яратып, Җыракай дип йөрттек. Әни гастрольгә киткәндә гел әбекәй белән кала идек. Җыракай әби безнең өчен бик тә кадерле. Ул – безгә беренче тормыш дәресләре биргән акыллы, сабыр канатлы, изге җан. Ул безне генә түгел, әнине дә йорт эшләренә, пешеренергә өйрәтте. Янәшәбездә яраткан әбиебез булса да, әнине бик тә сагына идек. Ул безгә һәрвакыт җитмәде. Ничәшәр ай буе әнисез тору бик тә ямансу иде. Мин еш авырый башладым. Әни авыру баланы юлга алып чыгып китәргә куркып, теләсә-теләмәсә дә, мине өйдә калдырырга мәҗбүр. Гүзәл апам белән әбекәй гел янәшәмдә. Безгә әти назы күреп үсәргә дә язмады, әти белән әни без кечкенә чакта ук аерылышкан. Бу да, нәни күңелне тырнап, гомер буе бер әрнү булып торды. Йортыбыз гел хатын-кызлар патшалыгы кебек иде. Әни безнең өчен әти дә, әни дә булды. Ул күп вакытын гастрольләрдә үткәрсә дә, гаҗәеп бала җанлы, мәрхәмәтле Ана булды, бер генә минутка да безнең турыда онытып тормады. Ул кайткан көн зур бәйрәм була иде. Нинди генә күчтәнәчләр төяп кайтмый иде ул. Кылган изгелекләре өчен без аңа чиксез рәхмәтле! Хәзер үзебез әни булгач кына аңа

ничек авыр булганлыгын чамалыйбыз. Кечкенә чакта аны гел сорау биреп бимазалый идек бит.

– Әни, нигә син гел каядыр китәсең? Башка әниләр өйләрендә тора бит, көн дә тәмле әйберләр пешерә, җыелышларга бара, – дигән сүзләргә аның җаны ничек әрнегәнен хәзер генә аңлыйм. Аның җавабы һаман бертөрле булыр иде: «Балакайларым, мин дә көне-төне өйдә утырсам, безне кем ашатыр, кем киендерер? Яшәү өчен, тәмле әйберләр, матур киемнәр алырга акча кирәк», – ди торган иде.

Әнием турындагы истәлекләр дигәч, өйдә алъяпкыч ябып, башына яулык чөеп йөргән әни түгел, илнең төрле төбәкләрендә булган концертлар, халык белән тулы тамаша залы, гастрольләр, сәхнәдә балкып, матур киенеп, елмаеп, җырлап торган әни күз алдыма килеп баса. Үсә төшкәч, балачак, яшьлек елларыбыз гел тәгәрмәч өстендә узды. Гадәттә, уку елында өйдә торабыз, укыйбыз. Җәй көне безнең өчен бәйрәм, ирек: үзе белән эшкә алып йөри. Ул гастрольләр маршрутын да, безгә күз-колак булыр өчен, уку вакытында янәшә шәһәрләрдә генә оештыра килде, җәй көне, безне алып, ерак сәфәрләргә китә иде. Мин әнине шулкадәр нык яраттым, хәтта тамашачылардан да көнли идем. Әни нигәдер тамашачыларны миңа караганда ныграк яратадыр кебек тоела иде.

Әни безгә карата коры, таләпчән булды. Гастрольләрдә без уйнап-шаярып кына йөрмәскә, нинди булса да файдалы эш эшләргә тиеш. Ул һәрчак безне кул арасына кертергә тырышты. Ишек төбендә билетлар тикшереп торучы контролер да булдык, костюмер һөнәрен дә үзләштердек, киемнәрне ничек дөрес итеп юарга, үтүкләргә өйрәтте. Әлбәттә, ул чордагы артистлар тормышы белән бүгенге сәхнә кешеләренең тормышы – җир белән күк аермасы. Юллар юк, ат арбаларында, төбенә печән, борчак саламы түшәлгән иске машина әрҗәләрендә сикерә-сикерә барып, эчләр авырта башлый иде. Кыш булса, авыл клублары суык, җәй көне халык белән шыгрым клубларда сулар һава юк. Гадәттә, авылларга барганда безне алырга йөк машинасы җибәрәләр иде. Шунда бөтен



«Казан утлары» ансамбленең инструментларын тутырабыз да, үзебез дә әрҗәгә төялеп, тиешле авылга юл тотабыз. Әнигә урынны гел машина кабинасыннан бирәләр иде, чөнки аңа салкын тисә, бөтен гастрольләр графигы өзелә. Ул, гадәттә, кабинага утыра да, алдына баянны куйдырта, ә мин – башка артистлар белән машина әрҗәсендә. Яңгыр коя башласа, брезент каплыйбыз. Ул юлларның начарлыгын мәңге онытырлык түгел. Миңа ул чакларда 11 яшьләр тирәсе булгандыр. Бик нык яңгыр коя башласа, әни мине үз янына кабинага алдыра. Бер тезендә – баян, икенчесендә – мин. Ул баянны җаны кебек саклады, баян – иң төп инструмент, дия торган иде. Халык җырларын баянга кушылып җырларга бик яратты.

Берсендә автобусыбыз юлда батып калды. Көн шулкадәр суык, әни мине чирләмәсен дип, үзенең матур итеп үтүкләп әзерләп куйган концерт күлмәкләренә минем аякларымны, гәүдәләремне төрде. Аннары Кәрим белән бер музыкант, өч км ераклыктагы авылга барып, трактор алып килде. Ул көч-хәл белән автобусны тартып чыгарды. Менә шундый шартларда да әни төшенкелеккә бирелмәде. Башка артистлар әнинең көр күңелле булуын күреп, үзләре дә шаярыша-көлешә башлыйлар иде, авыр дип, берсе дә кул селтәмәде. Шулай итеп алар, бергә-бергә юл газапларын, тормыш нужаларын җиңә-җиңә, халкыбыз күңеленә җыр-моң өләште. Төп максат җыр-моң аша телебезне, милләтебезне яшәтү, милли җәүһәрләрне саклау иде. Аның ихлас күңелдән башкарган җырлары туп-туры халык күңеленә барып иреште. Әниебез моның өчен бөтен талантын, тырышлыгын, үҗәтлеген җикте. Ул татар эстрадасында беренче булып инструменталь ансамблгә кушылып җырлаучы, бу яңалыкны кертүче тәүге карлыгач та бит әле!



Апам Гүзәл белән

Ерак гастрольләр вакытында да әни, безгә атнасына берничә тапкыр телефоннан шалтыратып хәлне белә. Ул вакытларда телефоннар район үзәкләрендә генә, сөйләшер өчен ерак араларны үтәсе, озак

вакытлар номерыңны тоташтырганнарын көтеп утырасы. «Ерак чакрымнар үтеп, көтеп-көтеп тә тавышыгызны ишетә алмыйча, үзәкләрем өзелеп кайтып киткән чакларым да күп булды», – дип сөйли торган иде әни. Әмма ул бирешмәгән, яраткан эшен дә җиренә җиткергән, без – балаларын тәрбияләргә вакытын, җаен тапкан. Шуңа күрә шимбә, якшәмбе көннәре безнең өчен зур бәйрәм иде, чөнки безгә телефоннан әниебезнең тавышын ишетү бәхете тия. Ягымлы бер-ике сүзеннән үк, аның безне ничек нык сагынганлыгын аңлап була иде. «Бәбекәчкәйләрем, мин сезне шундый нык сагындым, ничек хәлләрегез, әбиегез ни хәлдә?» Аннары ул телефонны әбигә бирергә куша: «Җыракай, хәлләрең ничек? Балалар ничек укый, көндәлекләрен караганың бармы?» – дип сорый. Ә Җыракай: «Ничек карыйм, мин бит күрмим», – ди. Әни анда да аптырап калмый. Беркавым үткәч, безнең өйгә күршедә яшәүче Эмма Мәхмүтовна килеп керә. «Әниегез көндәлекләрегезне тикшерергә кушты», – дип, дәресләрне әзерләтеп чыгып китә.

Бер караганда, танылган кешенең баласы булу рәхәт, икенче караганда, артистлар турында нинди генә имеш-мимешләр сөйләмиләр... Бер бик тә күңелсез, күңелне сызлаткан вакыйга онытылмый. Бервакыт, Гүзәл апа белән Совет урамындагы 5 нче трамвайга утырып, шәһәр үзәгенә юл тоттык. Ершов тукталышында трамвайга бер хатын килеп керде. Килеп тә керде, берәү янына басып, кычкырып сөйләп тә җибәрде: «Беләсезме, кичә бит больницага Әлфия Авзалованы китергәннәр. Күзенә әллә ниләр күренә икән, бәйләп атканнар», – ди. Апа белән безгә бик тә гажәп тоелды бу хатынның сүзләре, чөнки безнең әни инде өченче аен Урта Азиядә гастрольдә иде.



Минем Гүзәл апа холкы буенча сабыр, ә мин түзмәдем, теге апага: «Без – менә Әлфия Авзалованың кызлары. Әниебез турында шундый сүзләр сөйләргә ничек оялмыйсыз, без әнине инде өч ай күргән юк. Ул бит ерак-та, гастрольдә», – дип, ярсып кычкырдым. Теге апа кинәт шомыраеп калды. «Белмим алайса, миңа кеше сөйләде», – диде. Менә шундый гаделсезлекләрне җиңә-җиңә яшәргә туры килде безгә. Әнине, бер гаепсезгә, кешеләрнең ялган сүзе, имзасыз хат язулар нәтиҗәсендә, партия райкомнарына, обкомнарга чакыртып сорау алулар – берсе дә калмады. Шулай да, өстәге түрәләр, әнинең тырышлыгын күреп-белеп торалар, хезмәтен бәялиләр иде.

Әни өчен үлемгә тиң тагын бер авыр хәл: һич уйламаганда, 37 яшендә, алты баласын калдырып, сеңлесе Флүрә үлеп китте. Бу хәсрәттән әнинең тавышы бөтенләй бетте, ул җырлый алмас дәрәҗәгә килде. Флүрә апаның иң олы кызы Светага – 18 яшь, иң кечкенәсе Русланга – 9 ай. Флүрә апа үлгәч, ул аларның иң кечкенә өчесен үзебезгә алып кайтты, алар бездә ничәдер ай торгач, әни бу кадәр балаларны берүзе үстерә алмаячагын аңлап, аларның иң кечесен – балалар йортына, олыракларын интернат-мәктәпкә урнаштырды. Әни ул ятимәләргә үсеп җиткәнче булышты. Шимбә, ял көннәре саен, алар безгә кунакка килеп, сыйланып китәләр иде. Әни ул көнне күп итеп тәмле камыр әйберләре пешерә, барыбызны кыстый-кыстый ашата. Без шулай бергә-бергә зур, тату гаилә булып үстек. Үсеп буйга җиткәч, әни аларның һәрберсен, үзләренә закон буенча тиешле, ятимнәргә бирелә торган фатирлары артыннан йөреп, кирәкле кәгазьләрне җыеп, дәгъвалап, йорт-җирле итте.

9 нчы классны тәмамлаганнан соң, мин Казан театр училищесына укырга кердем. Ул вакытта әни Актаныш якларында гастрольдә иде. Үзе монда булса, ул минем документларымны анда бирдертмәгән булыр иде, дип



уйлыйм, чөнки ул безнең артист булуны теләмәде. «Артист эше бик авыр. Сезне һәрвакыт минем белән чагыштырырлар», – ди торган иде. Ул минем җырлавыма каршы булмады, синең тавышың матур, әмма мелизмың юк, син ничектер яңача җырлыйсың, ди торган иде. «Яки җиренә җиткереп бик матур итеп җырларга, яки буталып йөрмәскә кирәк сәхнәдә», – дип, кырт кисте. Башта театр училищесына керүемә дә бик каршы төшсә дә, тора-бара күнде. Төрле сәбәпләр аркасында беренче курстан соң мин рус актерлык бүлегенә – Дамир Сиражиевка күчтем, театрның рус бүлеген тәмамлап, кулга диплом алдым. Озакламый Равил исемле егеткә кияүгә чыктым. Ул – обком больницасының физиотерапия бүлеген җитәкләүче яшь табиб. Равилне моңарчы ук белгәнгә, әни аны бик яратты. Аңа кияүгә чыгуымны бик хуплады, якын итеп – Равил кияү, кайчагында улым, дип йөртте. Аның өчен иң шатлыклысы, мөгаен, балаларыбыз, оныклары туу булгандыр. 1983 елда беренче сабыем – кызым, Ләйсәнем туды. Ул туганнан соң әнигә Россиянең атказанган артисты дигән зур исем бирелде. «Ләйсән кызымның аягы җиңел булды, менә бит ничек зурладылар әбисен, – дип сөйләнде ул, шатлыгыннан чиксез куанып. – Әйе, тырышуын да тырышам бит, мин бу исемгә үземне лаек дип саныйм», – дип тә куанычын яшермәде.

Алда әле безне тагын бер зур сынау көткән икән. Равилне эш сәфәренә Әфганстанның Кабул шәһәренә, госпитальдәге солдатларны тернәкләндерү бүлеге башлыгы итеп җибәрделәр. Әлбәттә инде, без аның исәнлеге өчен ут йотып тордык. Шөкер, Равилебез исән-сау әйләнеп кайтты. Мине күп җирләргә эшкә чакырдылар. Ләйсәнебез кечкенә булса да, әни миңа өйдә утыр, димәде. Ул минем эшсез тора алмаганымны белә иде. Бервакыт ул мине, әйдә, кызым, гастрольгә, дип алып чыгып китте. Бу 1987 ел. Ул вакытта конферансьелар бик почетта иде. Безнең әни үзе дә юморга бик оста, ул сәхнәдән



сәгатьләр буе сөйләп, көлдереп торырга мөмкин. Тик шулай да һәрбер бригадада сүз остасы булу мәҗбүри иде, алып баручысыз гастрольгә чыгарып җибәрмәделәр. Әйбәт конферансье табуы авыр, концертның уңышы еш кына аның артистлык осталыгына бәйле. Мин шулай итеп әни бригадасында конферансье булып эшли башладым. Кечкенәдән сәхнә артында үскәнгәме, бу эш миңа бик тә якын, таныш иде. Әмма да ныгытып, җаваплылык сизеп, беренче концертта чыгыш ясавым, дулкынлануым әле дә истә. Әни һәрвакыт сәхнәдәшләренең нәрсә сөйләгәнен тыңлап, анализлап тора иде. Мин беренче тапкыр сәхнәгә чыкканда, ниндидер бер каушау сизеп, сөйли торган җирдән тукталып тордым. Әни моның өчен мине, әлбәттә инде, җәзасыз калдырмады. Бөтен кеше алдында миңа: «Әгәр дә мондый хәл тагын кабатлана икән, мин сине кайтарып җибәреп, урыныңа икенче кеше алачакмын!» – диде. Минем, читенсенүдән, битләрем кызарып чыкты, әмма әни баштан килеп сыйпамады. Тора-бара эшкә күнектем, сәхнәдә үземне иркен тота башладым.

1988 ел. Без җылы якта – Үзбәкстанның Сәмәрканд шәһәрендә гастрольдә идек. Үзем дә, кызым да авырый башладык, икебездә дә – көчле температура. Бу ял йортында – безнең янәшәдә генә, танылган «Ялла» ансамбле дә концертлар бирә. Без дә концерт куярга тиеш. Әмма әни мине, авыруыма карамастан, ачуланып: «Нинди авырып яту ул, синдә температура дип, тамашачылар концерт карамыйча китсенмени, давай, дәвалан?!» – дип, әмер бирде. Ул вакытта нинди дәвалану инде, шул бер аспирин эчеп куясың да тереләсең... Без дә бу концертны әйбәт кенә эшләп чыктык. Әле әни безне кызганып торса, бернәрсә дә килеп чыкмаган булыр иде. Менә шундый – эш өчен җанын бирә торган артист иде ул. Төнгә каршы безнең температура тагын күтәрелде. Без бу ял йортында врач эзли башладык. Аның администраторы Валентин исемле кореялы иде. Врачны аның аркылы белештек. Берзаман администратор: «Менә мин сезгә Әфганстаннан врач алып килдем», – ди. Әни: «Нинди Әфганстан, нинди врач ул тагын?» – ди. Шулчак ишек ачылып китте дә Равил килеп керде. Һай, шатлык булган иде бу көтелмәгән очрашу! Хәтта, әни бу сөенечтән аңын югалта язды. Равил Ташкентка яралы солдатлар алып кайткан булган, Сәмәркандта икәнне белеп, безне күреп китәр өчен яныбызга килгән. Күңеле сизгән диярсең, ул безне чыннан да дәвалап, терелтеп китте.

Төмән шәһәрендә булган гастрольләрдәге тыгыз графикларны уйлыйм да исем китә. Иртәнге 10 да – беренче концерт, соңгысы – төнге 12 дә. Берәүгә дә чирләргә рөхсәт юк! Эшлибез дә эшлибез, халык көткәндә, без эшләргә тиеш! Үзенә карата да, башкаларга карата да әни бик таләпчән булды. Күп вакыт сәхнәгә югары температура белән чыгып, берни булмагандай, ду китереп җырлап керер иде. Елмая-көлә, шаярта, халык берни сизми кала. Менә шулай яратты ул сәхнәне, тамашачылары өчен үзен дә, башкаларны да жәлләмәде.

Әни гаилә бәйрәмнәрен аеруча ярата иде. Яңа ел бәйрәме безнең өчен иң күңелле бәйрәмнәрнең берсе булды. Барыбыз да өйдә, бергә, әни йөгерә-

йөгерә камыр баса, беребез иттарткычтан ит чыгара, аннан бергәләп пилмән ясыйбыз. Пилмән янына һәр елны өстәлебездә тәмле каз ите булыр иде. Әни өйдә баштанаяк эшкә чумып йөрсә дә, анда ниндидер затлылык өстенлек итте. Күңелендә нинди уйлар барлыгын да белеп булмый, чөнки ул һәрвакыт шат күңелле, ачык йөзле, кунакчыл, эчкерсез булып кала белде. Бу күңелле мәшәкатьләр, җылылык, бергә чаклар мәңге дә онытылмаячак! Әнинең тәмле токмачлы ашлары, күпереп пешкән пәрәмәчләре, уңган камыр ашлары, мәтрүшкәләп ясалган чәйләре әле дә онытылмый. Егермегә якын үләнне салып ясаган чәйләре телеңне йотарлык була иде. Ул аларны җәй саен җыеп киптерә, аннары кыш буе чәен эчертә. Тагын бер искитмәле хәл: сөтле чәйгә бер чеметем генә әче әрем сала, шулай үзенчәлекле хуш исле чәй килеп чыга. Яңа елларны ул чын мәгънәсендә могҗизалы итә белә иде. Ничек булса да Яңа елга чыршы, яисә нарат юнәтү дә матур гадәт булды. Бер елны ишектә кыңгырау чыңлый, без әни кайтты дип, сөенешеп йөгерешәбез. Ул да булмады, ишек ачылып китте дә, башта ак чыршы, аннары зур-зур пакетларга салынган күчтәнәчләр, аннары гына әни үзе күренде. Беркайчан арыганлыгын күрсәтми.

– Балалар, әйдәгез әле, бәйрәмгә әзерлекне башлыйбыз, – дип, шул мизгелдә үк чишенеп, чыршыны бизи башлый торган иде. Ул бәйрәмнәрдә беркайчан да ресторанга барырга яратмады. Иске Яңа елда һәр елны Актерлар йортына бара торган иде.

Иҗатташлык, дуслыкка килгәндә, әнинең иң тугры, якын дуслары, җан дуслары – Гөлшат Зәйнашева, Зиннур Гыйбадуллин булды. Алар, өчәүләп, халык күңеленә кереп калырлык искиткеч матур әсәрләр иҗат итте. Бик күп кенә хитларының туу тарихы белән мин дә таныш. Шундый халыкчан, матур җырларының берсе – «Яшь гомер»не дә алар, бер кич утырып, Гөлшат апа белән икесе язды. Әни, Гөлшат апага: «Гөлшат, әйдә әле шундый җыр языйк, гомер узса да, күңел бит ул барыбер яшь кала, картаймый. Менә шундый сүзләр кертеп җыр тудырырга иде», – дип әйтүгә, Гөлшат апаның матур җөмләләре әзер иде инде. Алар бер-берсен ярты сүздән аңлый, шуңа да җырлары да алар теләгәнчә, халык уйлаганча килеп чыга иде. Шундый ук халык яраткан җырларның берсе – «Аерылмагыз» җыры да тик торганнан гына тумады. Равил Әфганстаннан кайтканнан соң, икебез арасындагы аңлашылмаучанлыкны күреп, ике яшь йөрәкне ялгышлардан саклап калу теләге белән, каләмне җан ачысына манчып язган җыр бу. Чөнки Гөлшат апаны без ничек якын күрсәк, ул да безне үз балаларыдай якын итте. Ул безнең өчен аналарча борчыла, безне ярата иде. Әлбәттә, бу җырның безгә тәэсире зур булды, дисәк, һич арттыру булмас. Бу җырда күпме нәсихәт-үгет, җан җылысы, әманәт! Соңыннан бу җыр табын җыры булып китте, аерылышу алдында торганнарның гимнына әверелде. Миңа калса, бу җыр беркайчан да халык күңеленнән китмәс!

Без Гөлшат апаны яратып, оныкларына иярeп, аны «Гөләни» дип йөртә идек. Әни һәрвакыт безне Гөлшат апаның кызы Асия белән дус булуны теләде. Шөкер, без мәңгелек дуслар булып яшибез. Шулай итеп ике татар кызы тудырган җырлар әле дә булса яши, аларны бүген дә яратып тыңлыйлар. Әни чит ил җырларын тәрҗемә итүне дә бары тик Гөлшат апага гына ышанып тапшырды. Алар, музыка яңгырашыннан ук, бу җырда сүз нәрсә турында барганлыгын аңлыйлар иде. «Юл җыры» язу уе да шундый чит җырларның берсен тыңлаганнан соң килде. Без Равил белән инглизчә җырны тәрҗемә итеп күрсәттек, нәтиҗәдә, искиткеч матур җыр туды. Әниемнең җырларын яратучыларга бер олы серне ачасым килә. Ахирәте Гөлшат Зәйнашева белән бервакыт аларның яңа җыр турында серләшеп утырганнарын ишеттем. «Әйдә әле, Гөлшат, бөтен хатын-кызларга да кагылышлы «Бер апа җыры» языйк», – диде әни аңа. Гөлшат апа әни әйткән фикерне бервакытта да гамәлгә ашырмый калмады. Бу очракта да нәкъ шул исемдәге матур җыр сүзләре язылып, композитор Рафик Аганов, шушы сүзләргә туры китереп, искиткеч матур көй язды. Әмма, ниндидер сәбәпләр аркасында, тамашачыларга бу җыр барып ирешмәде. Киләчәктә бу җырны да халыкка ишеттерербез, дип уйлыйм. «Бер апа җыры» ул, әни әйтмешли, бөтен апаларга да кагыла. Гөлшат апа белән әни утырып, серләшеп ижат иткән башка җырларны халык барысын да диярлек яттан белә. Алар татар сәнгатенә искиткеч бай мирас калдырдылар. Ахирәте, җан дусты, ижатташы Гөлшат Зәйнашеваның дөньялыктан китүе әни өчен зур югалту булды. «Аның белән минем ярты җаным китте», – диде ул.

Әйткәнемчә, әниебез сәхнәне, тамашачыларны шулкадәр нык яратса да, аның күңел җылысы без-балаларына, оныкларына да җитте. Оныклары тугач, ничек куанганын күрсәгез! Ул алар туган саен яшәрә бара иде. Безгә – үз кызларына үтә дә кырыс, таләпчән булса да, оныкларына «их» дип тә әйтмәде. Шуңа да аны оныклары бүгенгәчә телләреннән төшермиләр, бик еш сагынып искә алалар. Әни үзе дә алар өчен җанын кызганмады. Аның бик тә яратып кия торган – Салават Фәтхетдинов бүләге – ярым айлы алтын муен чылбыры бар иде. Шулай бер көнне әни үз янына төпчек кызым Ренатаны чакырды да: «Кызым, менә бу кадерле бүләгемне сиңа бирәм, сакла, яме! Минем төсем итеп ки!» – дип, муеныннан салып, Ренатамның муенына элде. Күзгә яшьләр килде. Әле кайчан гына төпчегем тугач: «Кызым, нинди исем куярга уйладыгыз соң? – ди. – Рената, – дим. – Әй, кызым ирләр исеме түгелме соң ул?» – дип көлдергән иде. Әни бик тә җор кеше иде бит. Ул сәхнәдә дә үзен гаҗәеп иркен тотты. Халык аны шуның өчен дә яратты, үз итте. Әни аягөстендә йөргәндә, кәефе яхшы булганда Салават Фәтхетдинов аны үзе белән концертларына алып йөрде. Әниебезнең бу чыгышлары халкы белән саубуллашуы булган икән. Шуның өчен дә ул Салаватка бик тә рәхмәтле калды. Тамашачылары алдына чыгуны соңгы көнгәчә зур сынау итеп кабул итте, аларны бөек көч итеп, таянычы итеп күрде.

Әнием белән Илһам абыйның мөнәсәбәтләре турында аерым әйтәсем килә. Сәхнәдә кемнең кем икәнен белә-аңлый башлагач та, аларның бик ачык, ихлас сөйләшкәннәрен, аралашканнарын күреп, атаклы җырчыбызны бер туганыбыздыр, туганнан туган абыемдыр, дип уйлап йөри идем. «Син – минем кызым», – дип торган кешене ничек инде якын итмисең?! Билгеле, үз әтием дә килеп, хәл белешеп китә. Шуңа күрә нишләп ике әтием бар икән, алай булмый бит инде, дип уйлый идем. Тора-бара әниемне якын иткән кешеләрнең шулай дәшүен табигый кабул итә башладым. Әйтик, Юсыф Вәлитов та бик якын итә, миңа «кызым» дип дәшә иде.

Илһам абый бик игътибарлы, өебезгә бүләксез килми. Апам Гүзәлдән дә, миннән дә, якын итеп: «Ничегрәк укыйсыз, фәннәрне үзләштерүе бик кыен түгелме?» – дип сораштыра. Мин театр училищесына керергә имтихан биргәндә әниемнең Актанышта гастрольдә булуын, артистлыкка укырга җыенуымны белмәвен алдарак искә алган идем инде. Илһам абыйга бәйле, язмышымда бик әһәмиятле сынау булганга, әлеге вакыйгага тагын бер кат тукталам. Имтиханга барганда, очраклы рәвештә, Илһам абый белән күрештем. Ул филармония бинасы янында басып тора. Янәшәдә генә диярлек училище бинасы. Аңа күренмәс өчен, юлның икенче ягына йөгереп чыктым. Күзенә чалынмый гына узып китәргә исәп. Ул күреп алды да: «Әй, Зөлфия, кил әле монда», – дип чакырып алды. Ашыксам да, килдем инде. Кабул итү имтиханнарының икенче туры бит. «Кая ашыгасың?» – дип кызыксына. «Дус кызым имтихан бирә. Шуның янына ашыгам», – дип хәйләләдем. «Ярый, ярый», – дип калды бу. Икенче турда этюд башкарасы иде. Җырлап, биеп алырга, кыскасы, нәрсәгә сәләтле икәнеңне күрсәтергә кирәк. Миңа гына чират җиткән иде, ишек ачыла да Илһам абый килеп керә. Мәшһүр кеше бит инде: аңа барча ишекләр ачык. Беркем аны туктатырга базмагандыр. Билгеле, мин бераз каушап калдым. Бу турны узасы, ничек тә сынатмаска иде бит. Шулай да, бөтен көчемне җыеп, үземне тынычландырдым, тиешлене ерып чыктым кебек. Башка имтихан бирүчеләр сыман, ишек төбенә чыгып басып, бушанып, җылап алдым. Мөгаен, алмаслардыр, үтә алмадым, ахры, дип борчылдым. Илһам абый әкрен генә чыгып китте. Мин аны күрмәмешкә салыштым. Бераз басып торгач, кабул ителгәнлегемне әйттеләр. Кемдер, Илһам абый аркасында алганнардыр инде, дип ычкындырды. Әмма Илһам абый булдыксыз, сәләтсез кешеләр өчен сорап йөри торган кеше түгел. Ул – бик гадел, бигрәк тә иҗат кешеләренә зур игътибарлы кеше. Кабат күрешкәч, ул: «Беләсеңме... ярый, ярый. Син артист булачаксың», – дип сүз катты. Беркайчан да мактарга яратмады. Хәер, әнием дә мактауга саран иде. Әйбәт кенә дип әйтүе – мактау иде инде. Туй вакытында әнием Әстерханда гастрольдә иде. Без туйны өйдә тыйнак кына уздырдык. Апамның гаиләсе, Равилләр ягы. Нибары ун кеше. Әнием шалтыратып, Илһам абыең киләчәк, дип әйтте. Ул килде. Әйтерсең, әтием фатихасын бирде. Озак утырмадык, чәйләр эчтек тә таралыштык.

Әнием белән мөнәсәбәтләре шактый кызык, үзенчәлекле иде. Кайбер вакытта якага-яка килеп дигәндәй бәхәсләшәләр. Гүя моннан соң башка аралашмаячаклар, сөйләшмәячәкләр. Әмма алар бик тиз татулаша иде. Әнием, гомумән, ачу саклый торган кеше түгел. Әле генә орышкан кеше белән биш минуттан, берни булмагандай, сөйләшә башларга мөмкин. Илһам абый белән дә биш-ун минуттан елмаеп сөйләшә, мәзәк сөйләп, көлешә башлыйлар иде. Әнием аның иҗатын бик хөрмәт итте. Кай чакларда аралары суынып алса да, аның хакында һәрвакыт югары фикердә булды. Аларның үзара мөнәсәбәте хакында төрле имеш-мимеш күп йөрде. Шуңа күрә әнием гайбәтләргә ышанмаска, йөрәккә якын алмаска кушты.

Әнием һәрвакыт аның хәленә керергә тырышты. Әйтик, бергәләп гастрольләргә чыгып китәләр. Илһам абый салкын тидерә. Бервакыт Башкортстанның Октябрь районына баргач, бөек җырчыбызның температурасы бик каты күтәрелеп, ул хастаханәгә кереп ятар хәлгә җитә. Шуңа карамастан, сәхнәгә, халык каршына чыга. Ул да – әнием кебек үҗәт, үзсүзле кеше. Шушы халәтен сизеп, әнием сәхнәгә чыга, кушылып җырлый. Шушылай әкрен генә бер җырчыны икенчесе алыштыра. Тамашачылар моны табигый кабул итә. Дөрес, икенче көнне имеш-мимеш китә: янәсе, Илһам белән Әлфия кичә исерек килеш сәхнәгә чыккан. Кеше белсә дә, белмәсә дә сөйли инде... Югыйсә, аларның беркайчан да исерек килеш сәхнәгә чыкканнары булмаган. Һәрхәлдә әнием хакында тәгаен әйтә алам. Илһам абыйның да салмыш килеш сәхнәгә чыгуын күз алдына китерә алмыйм. Усал кешеләр бар инде, алар нәрсә сөйләмәс?! Әнием аларга игътибар итмәскә, алга карап яшәргә, иҗади үсүне кайгыртырга чакырды. Ул беркайчан да элгәре гастрольләрендәге репертуарын кабатламый, гел үзгәрешләр кертеп тора, кимендә биш-алты яңа җыр өйрәнә иде.

Әниебез, картаюдан, үлемнән качып котылып булмый, дип гел әйтә килде. Соңгы инсульт булганда дәваханәгә өметен җуймады. Бу көрәш – 40 көн буена барды. Табиблар безгә: «Әниегезнең баш миенең дүрттән өч өлеше зарарланган», – дисә дә, соңгы көнгә кадәр без дә өметебезне өзмәдек. Ниндидер бер могҗиза булыр да, әниебез аягына басар дип көттек. Әмма бу юлы могҗиза булмады. Җырлап үлде дип, нәкъ менә безнең әниебездәй көчле рухлы кешеләргә әйтәләрдер инде! Чөнки әниебез шул хәлендә дә җырлады, моңын туры китереп, телен әйләндерерлек көче булмаса да, җырларга тырышты. Кул-аяклары, тәннәре язылсын дип, төрле җиңел хәрәкәтләр ясату да, сөйләмен кире кайтарыр өчен авазлап сүзләр кабатлату да – берсе дә калмады. 40 көн буе, чиратлашып яныннан бер генә минутка да китмәдек, беребез – көндез килсә, икенчебез төнгә кунарга калдык. Мин киткәндә күзләре моңсулана, карашы түбән төшә, ә инде шул минутта икенче кызын күрүгә, кабат йолдыздай балкый. Аның янына хәл белергә килүчеләрнең исәбе-хисабы булмады, рәхмәт барысына да! Җырчы Салават Фәтхетдинов килгәч,

әйтерсең лә, әнинең соңгы өмете терелде. Ул аның кулларын озак җибәрмичә, күзләренә мөлдерәтеп: «Бәлки, берәр нәрсә эшләп буладыр, улым?» – дигән сыман карап торды.

Туганнан туган сеңлебез Розага һәм Әлифә Вәлиевага нинди генә рәхмәтләр әйтсәк тә, аз булыр. Алар безгә күпмедер ял бирде, хәлебезгә керде.

Әниебез әүлия кеше булган, күрәсең. Ул изге Рамазан аенда ахирәткә күчте. Өчесе һәм җидесе көннәре дә Рамазан аена туры килеп, укыган хәердогаларыбыз изге көннәрдә барып ирешкәндер, дип уйлыйм.

Әниебез үләсен алдан белеп, бөтен күмү йолаларына алдан әзерләде. Барыбызны бергә җыеп, янәшәгә тугры дусларыбыз – Сания белән Кәримне дәшеп, авыр булса да васыятьләрен җиткерде. Каберенең кайсы урында буласын, нинди күлмәктән күмеләсен, каберлек өстендә нинди таштан, нинди сын буласын – барысын да бәйнә-бәйнә аңлатып китте. Барысы да ул уйлаганча, ул теләгәнчә булды. Каберлеге халык йөри торган юл өстендә, үзе теләгәнчә – бәрхет кызыл күлмәктән китте әниебез. Сәхнәдәге кебек матур булып, күркәм булып, үзе булып китте.

Хушлашу, яраткан тамашачылары белән саубуллашу да, үзе якын иткән Татар дәүләт филармониясендә үтте. Скульптурада булачак сынга кайсы фотография барачагы да аның теләге белән тормышка ашачак, Алла боерса. Менә шундый бөек Ана, бөек җырчы, бөек Артист безнең әниебез!

Ул һәрвакыт: «Халкым мине беркайчан да онытмас, чөнки яшьтән үк гомеремне халыкка багышладым», – ди торган иде. Без әниебезне бер генә көн дә онытмыйбыз. Әниебезнең рухы шат булсын дип, догалар укытабыз, Коръән ашлары уздырабыз. Әниебез безне күктән күзәтеп, без кылган гамәлләребезгә сөенеп, куанып торадыр төсле. Бик тә сагынабыз, юксынабыз! Аның якты истәлеген киләчәк буыннар да хәтерләсен, аның моңлы җырлары телләрдән төшмәсен иде!

Әниебезне хөрмәтләп соңгы юлга озаткан барлык татар халкына, аның исемен, җыр-моңнарын хөрмәт иткән башка милләт халыкларына, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә, Казан шәһәре мэриясы хезмәткәрләренә, Мәдәният министрлыгына, күрсәткән ярдәмнәре өчен, чиксез рәхмәтләребезне җиткерәбез!

Гади генә татар кызының Казанга килеп шулкадәр уңышларга ирешүе, биеклеккә күтәрелүендә, әлбәттә, аның үзенең тырышлыгы, максатчанлыгы ята. Ул – үзенә Ходайдан биргән табигый талантын үстереп, җыр-моңнары аша милләтебезне яшәтүгә күп көч куйган бөек шәхес. Әни белән бөтен татар халкы горурлана, аны барлык милләттәшләр, хәтта, чит илләрдә дә беләләр, яраталар, аның җырлары мәңгелек! Без – балалары, ике кызы, кияүләре, оныклары – шундый әниебез, әбиебез булуга икеләтә горурлык кичерәбез! Буыннар чылбыры өзелми, дәвам итә. Аның бүгенгесе көндә балалары, оны-

клары Казанда, хәтта Америка Кушма Штатларында да яши. Әмма кайда гына яшәсәк тә, горурлыгыбыз, чишмә башыбыз матур, озын, җырлы юл узган әниебез – Әлфия Авзалова буласына иманым камил. Чынлап та, әниебез бәхетле, озын, җырлы юл узды. Үзе яраткан хезмәттә зур уңыш казанды, безне – ике кызын матур тәрбия биреп үстерде, балдан татлы оныкларын сөйде, хәтта оныкларын, онык чыкларын да күрү бәхетенә иреште. 85 яшенә ярты ел гына җитми калды. Аның мәңге үлмәс җырлары калды. Гади булып туды, гади булып китте, әмма аның исеме, аның җырлары күңелләрдә мәңге тынмас! Ул җырлары аша безгә һаман да: «Туган илне, туган җирне сөегез, аннан да газиз урын юк!» – дип эндәшә кебек...

Сүз уңаеннан әниемә якын кешеләрдән берничәсен телгә алмасам, дөрес булмастыр. Тәгаен алганда, Чаллыда яшәүче Гөлчирә исемле ахирәте белән соңгы 25 елда якын дус, сердәш булдылар. Аллага шөкер, ул исән-сау: әниемне соңгы юлга озатырга да, җидесенә дә килде. Үз вакытында, Гөлчирә янына барып кайтыйм әле дип, автобуска утыра да китә, йә кемдер Чаллыдан килеп ала... Аңа зур рәхмәтемне җиткерәсем килә. Рабит абый Батулла гаиләсе белән дә тыгыз аралашып яшәде әнием. Рузия апа, уллары да якын итте. Актанышта вакытта, балалар йортыннан кайткач, әниемне үзләренә сыендырган Сажидә апа белән Вагыйз абыйларның кызы Нәзифә апа (без аны Алма апа дип йөртә идек) белән дә дус яшәдек. Композитор Сөембикә Вәлиева шигырьләр дә яза иде. «Төнбоек» дигән җырның авторы ул. Әнием ул язган бик күп җырны башкарды. Зөләйха һәм Альберт Йосыповлар әнием өчен дә, Илһам абый өчен дә якын дуслар иде. Разыя Тимерханова белән Сабир абыйны да еш искә алды. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры директоры Рәүфәл әфәнде белән очрашканда, без ул көннәрне сагынып искә төшерәбез. Әниемнең ялтыравыклы концерт күлмәкләрен бик матур дип әйтәләр иде. Тукымаларын кайдан алганлыгын да әйтергә кирәктер. Әниемә ул тукымаларны Америкадан, Нью-Йорк шәһәрендәге татар мәдәни оешмасын җитәкләүче Оркыя апа җибәреп торды. Хәзер дә ачык зиһенле, яхшы хәтерле апа ул, күптән түгел аңа туксан яшь тулды. Алар бервакыт Абдулла абый белән икәүләшеп Казанга да килеп китте.

Кызганыч, аның бик күп җырлары радио-телевидениедә яздырылмады, фонотекага алынмады. Бәлкем, кемдер видеога төшергән, магнитофонга яздырып алгандыр. Дөрес, әле алар шактый соң кулланышка керде. Камерага төшереп алу мөмкинлеге, күп дигәндә, утыз ел элек кенә барлыкка килде бит. Ул тасмаларны җыеп алып, бәлкем, бер концерт, документаль фильм итеп оештырып, дөньяга чыгарып булыр иде. Тамашачыларга кызык булачак бу!

Әлфия Авзаловаңы зурлаганнары өчен аның якташларына, шәхсән Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә, һәм, гомумән, барлык милләттәшләремә чиксез рәхмәтемне җиткерәм.

Равил
НИГЪМӘТҖАНОВ



Татарстандагы ерак авылларның берсендә, район үзәгенең агач клубында Казаннан артистлар килүен көтәләр иде. Узган гасырның илленче еллары иде бу, тормыш кызыклы һәм мавыктыргыч иде ул чакта. Башкала артистлары килү – кайсы авыл өчен дә зур вакыйга. Барысы да түземсезлек белән концерт башлануын көтә.

Балалар, һәрвакыттагыча, сәхнәгә якынрак урнашырга тырыша, кемгәдер бәхет елмая, алар сәхнәгә алып менә торган шыгырдавык баскычка утыра. Зал могҗиза көтеп тынып калган – Казанның чын сәнгать осталары башкарган татар җырлары һәм биюләре барысы өчен дә гадәти булмаган сихри төстә яңгырый һәм матур күренә; сәхнәдәге ачык чибәр йөзләр, киемнәр, музыка инструментларының ялтыравык төймәләре һәм башка өлешләре – авыл балаларына болар барысы да ниндидер башка, әкияти дөньядан булып тоела. Алар артистлар алып килгән әкиятнең беркайчан да бетмәвен тели. Анда иң зур могҗиза – җырчылар арасында Әлфия Авзалова да бар. Ул җырлаганны зал сулыш та алмыйча тыңлый, бал исе аңкыган чәчәкле болын, елга һәм урман, ягымлы Кояш күз алдына килә; концерт тыңлаучылар үзләрен, әле бик яшь башкаручы булса да, үзенең таланты һәм кабатланмас тавышы белән бөтен Татарстанга танылган Әлфиянең җырларыннан бөркелгән шул матур, бәхетле тормышның бер өлеше итеп тоя. Китәр алдыннан, артистлар инструментларын җыя башлагач, малайларга тылсымлы булып тоелган баян төймәләренә кагылу, хушбуй исе белән сугарылган, музыка авазлары белән тулган ниндидер гажәеп һава сулышын тою насыйп була. Алар һәрвакыт ачык йөзле, күңелле, елмаеп сөйләшүче кунаклар янында бөтерелә; артистлар исә, балаларның күңелләрен күтәреп, яңа концерт программасы белән килергә вәгъдә итә.

Аннары әкият белән яңа очрашуга өметләнгән малайлар һәм кызлар, артистларны озатып, тузанлы авыл урамы буйлап йөгерә.

Әлфия Авзалова актив ижади тормыш алып барды. Концертлар искиткеч күп иде, ул айлар буе гастрольләрдә йөри, зур Ватаныбызның бик күп шәһәрләрендә, авылларында була, бер тур вакытында Уралны да, Үзбәкстанны да урап кайта ала иде. Кем генә тулы аншлаг белән йөзәр концерт бирә алыр иде икән?! Әлфия моны булдыра иде. Кайчакларда бераз тукталырга,

ял итәргә, көч җыярга кирәклеген аңласа да, ул чын халык хезмәтчесе булып калды, чөнки белә иде: аны көтәләр, җырлавын тагын-тагын тыңларга телиләр. Кайвакыт, ихлас күңелдән сөйләшкәндә, ул үзенең халык өчен, тамашачысы өчен яшәвен әйтә иде, бу тормышының иң югары фәлсәфәсе булды. Аның дуслары артык күп булмады, гәрчә аның талантына сокланучыларга бүтәнчәрәк тоелгандыр.

Тормышында аерым урын алып торучы Илһам Шакиров – танылган татар халык җырчысы иҗаты нигезенә табигый талант, онытылмас тавыш тембры салынган олуг эстрада йолдызы, иҗатка багышланган тормыш кешесе, легендар шәхес. Илһам Шакиров Әлфия Авзалова иҗатын нык хөрмәт итте, аның уникальлеген, кабатланмас талантын тоя иде ул. Бер караганда, ике йолдыз кушылсын да, «йолдызлы пар» төзесен генә бит инде – Илһам белән Әлфия өчен мондый мөмкинлек булмаган түгел – мөнәсәбәтләре дуслык белән генә чикләнмәгән, тик без инде ике бөек артист арасындагы хисләрнең барлык нечкәлекләрен белә алмабыз. Күрәсең, алар өчен шәхси мөнәсәбәтләргә караганда, сәнгатькә хезмәт итү өстенрәк булгандыр.

Әлфия Авзалованы барлык атаклы композиторлар да, музыка язучы яшьләр дә белә һәм әсәрләрен беренче тапкыр башкару өчен аңа бирергә тырыша, чөнки гаҗәеп талант иясе булган бу эстрада йолдызы шундый итеп җырлый: ул җырлар шул көннән халык яраткан популяр җырга әйләнә. Композиторлар – Сара Садыйкова, Александр Ключарёв, Рөстәм Яхин, Заһид Хәбибуллин, Зиннур Гыйбадуллин, Әнвәр Бакиров, Мәсгуть Имашев, Риф Гатауллин, Сафьян Ибраһимов, Фасил Әхмәтов, Резеда Ахиярова җырларының уңышын Әлфия Авзалова башкаруына да бәйлиләр. Нигездә, Әлфия татар халык җырларын җырлады, болар халык хәтерендә озак еллар аның башкаруында саклана, бүген дә аерым соклану хисе белән тыңлана.

Җырчылар арасыннан Әлфия апа Винера Ганиеваны югары бәяләде, ул аның иҗатына аерым мәгънә бирә, бик еш үзе белән гастрольләргә – Мәскәү, Санкт-Петербург һәм ул чактагы союздаш республика башкалаларындагы зур концертларда чыгыш ясарга чакыра иде.

Талантлы опера җырчысы, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының примасы Зилә Сөнгатуллина татар халык җырларын да бик яратып башкара – Әлфия аның иҗатына зур хөрмәт белән карады. Популяр татар җырчылары – Хәмдүнә Тимергалиева, Зөһрә Сәхәбиева, Зөһрә Шәрифуллина, Римма Ибраһимова, Зәйнәб Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билаловны Татарстанда да, Башкортстанда да, чиксез Ватаныбызның татарлар яши торган башка төбәкләрендә дә яхшы беләләр.

Безнең көннәрдә популярлык казанган, аның репертуарындагы җырларны да оста башкарган, ләкин вакытсыз дөньядан киткән Хәния Фәрхинең татар халык җырларын башкаруын бик ошата иде Әлфия ханым.

Россиядә генә түгел, барча дөньяда танылган опера җырчысы, Татар-

станның халык, Россиянең атказанган артисты Альбина Шаһиморатова Әлфия Авзалова иҗатын милли татар сәнгатенең нигезе, дөнья сәнгатенең аерылгысыз өлеше дип саный.

Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ренат Ибраһимов татар җырларын оста башкаруы белән дә популярлык яулады. Әлфия Ренатны яхшы белә һәм аның иҗатына соклана иде.

Илебезнең популяр җырчысы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Алсу Сафина Казанда татар халык җырларыннан торган альбомын тәкъдим итү кичәсенә Әлфия Авзалованы чакырды, атаклы җырчының фикере аның алдагы иҗат юлы өчен бик әһәмиятле иде.

Россиянең атказанган, Татарстан һәм Башкортстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов, татар халык җырларын оста башкаручы, чын милли нигезләрне саклаучы буларак, Әлфия Авзаловага аерым зур ихтирам хисе белән карый, аны татар эстрада сәнгатенә нигез салучы дип саный иде. Бөек җырчының соңгы елларында Салават, Әлфия Авзалованы үз концертларында сәхнәгә чыгарып, халыкка яраткан җырчыларын яңадан күрү мөмкинлеге бүләк итте. Ул яңадан сәхнә мохитендә булу, артистлар белән аралашу, үзен аягүрә басып алкышлаган тамашачыларның сокланулы карашларын күрү белән бәхетле иде.

Хәйдәр Бигичев, Айдар Фәйзрахманов, Фердинанд Сәлахов, Нәфкать Нигъмәтуллин – үз иҗатларында татар халык сәнгате һәм эстрадасы нигезләрен саклаган төрле стиль җырчылары. Әлфия аларның иҗади үзенчәлекләрен һәм алга таба үсү юлларын билгеләде.

Төрле елларда Әлфия Авзалова төркемендә танылган биючеләр – Розалия Мостафина, Гүзәл Вафина, Гүзәл Галиева, Ирина Сабитова эшләде. Айрат Хәмитов тора-бара Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе, аның хатыны Ләйсән ансамбльнең солисткасы булды, икесе дә Татарстанның халык артисты исемен алды, бер үк вакытта Казан мәдәният университетында мөгаллимлек итә башлады, халык биюләре кафедрасын – югары һөнәри артистлар әзерли торган әйдәп баручы мәктәпне җитәкләде.

Концерт программасын алып баручылар арасында, һичшиксез, Фәйзи Йосыпов, Дамир Нәбиуллин, Нажия Минкина, Зәйтүнә Яруллина, Әлифә Вәлиева, Диләрә Ильясова, соңрак Татарстанның халык артисты исеменә лаек булган Рәшит Сабиров; шулай ук баянчылар – Рәфкать Гомәров, Марс Макаров, Рәшит Мостафин, Зиннур Гыйбадуллин, Равил Закиров, Ринат Сибгатуллин, Фәнис Гыйльметдинов, Кирам Сатиев, Рөстәм Вәлиев, Хәйдәр Сафин игътибарга һәм хөрмәткә лаек.

Алар, Әлфия Авзалова иҗат юлының төрле елларында төркем составында эшләп, үз вазифаларын югары һөнәри дәрәҗәдә башкардылар. Төркемне 40 елдан артык Татарстанның атказанган артисты Кәрим Габидуллин җитәкләде.

Әлфия төркеменең башка әгъзалары кебек үк, ул һәм аның хатыны Сания дә артистлар гына түгел, беренче чиратта, фикердәш дуслар булдылар, бер гаилә кебек, ял сәгатьләрен, көннәрен дә бергә үткәрделәр. Музыкант һәм композитор Рафик Аганов Әлфиянең концерт эшчәнлегенә саллы гына ижади өлеш кертте. Әлфиянең гаилә дусларына әйләнгән Ирина Сабитова һәм аның ире Рәфкать Сабитов һәрвакыт аның янәшәсендә булды.

Әлфиянең фатир күршесе Миләүшә Тәминдарова, Казан Дәүләт консерваториясен тәмамлап, күңелле, шук, шаян кыздан Татарстан Республикасы Дәүләт камера хоры җитәкчесенә әверелде. Бүген инде Миләүшә Тәминдарова – күренекле артист, татар җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, күп кенә дәрәҗәле халыкара конкурслар лауреаты; ул бөек җырчының кызы Зөлфия белән яңа ижади планнар кора.

Татар җәмәгать эшлеклесе, театр режиссёры, мөгаллим, язучы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан тарихының олуг сакчысы, республикабызда булган вакыйгалар турында уникаль материал җыеп, күптомлы басмага туплаган Рабит Батулла, шулай ук, шактый еллар Әлфия Авзалова белән күрше булып яшәде. Алар гаилә дуслары иде. Рабит ага хатыны Рузия белән менә дигән ике талантлы егет – Нурбәк һәм Байбулатны үстерде. Алар бергәләшеп, табын янында җыелышып, бал белән чәй эчә-эчә, тормыш, сәнгать турында гәп кора иде. Рабит белән Әлфиянең әңгәмәләре, уникаль материал буларак, Әлфия Авзалова турындагы документаль фильмга нигез булды. Аның сәнгатьне тою интуициясе шаккаттыра иде, ул концерт программаларын үзе төзи, төрле илләрдәге авторларның җырларын сайлый, аларның талантын ниндидер, үзе генә сизгән билгеләр аша бәяли белә иде. Үзебезчә, яки чит телдә башкарылган теге яки бу җырны бер тапкыр ишетү дә җитә – Әлфия шундук башкаручының талантына, җырның әһәмиятенә, музыкаль бизәлешенә бәя бирә иде. Бервакыт ул Род Стюарт башкаруында «Seiling» җырын ишетә һәм шунда ук якын дусты, атаклы татар шагыйрәсе Гөлшат Зәйнашевага шалтыратып, әлеге җырның сүзләрен татарчага тәрҗемә итүен сорый. Кемгәдер бу гаҗәп тоелырга мөмкин, ләкин без, аны яхшы белүчеләр, аңлыйбыз: аның башында фикер туып килә һәм ул тиздән аны тормышка да ашыра: җырны татарча башкара, репертуарына кертә. Ул чорның теләсә кайсы шагыйре, яки композиторы өчен үз әсәрен Әлфия Авзаловага тәкъдим итү зур дәрәҗә булды, алар тиз арада танылып китә, табигый, Әлфия ханым өчен бу эш формаль түгел иде. Ул үзе яңа авторлар эзли, хәтта бөтенләй билгесез, яки аз билгеле авторлардан да баш тартмый.

Әлфия Авзалова өчен ижат шундый чиксез мәйдан иде: ул анда үзен ихлас һәм ирекле хис итә, аның дөньяны тою тирәнлеге, зурлыгы башкарган җырларына күчә, җыр нигезенә салынган вакыйга поэмага әйләнә. Ул табигать турында җырласа, очсыз-кырыйсыз басулар, урманнар күз алдына килә,

яңгыр тавышы ишетелә, йомшак җил аша чәчәкләр хуш исен тоясың; сугыштан кайтмый калган солдатлар турындамы, патриотик эчтәлекле җырмы, Ватан турындамы – Әлфия башкаруында барысы да аңлаешлы, тыңлаучыларга якын.

Күп кенә популяр җырларның авторлары билгесез булып чыга, андый чакта сәхнәдә «халык көе һәм сүзләре» дип игълан итәләр. Әлфия Авзалова иҗаты турында да шуны ук әйтергә мөмкин: ул халык артисты иде, иҗатында үз халкының образларын, үзе яшәгән табигатьне гәүдәләндерде; әти-әнигә, балаларга булган изге хисләр бигрәк тә якын иде аңа. Кечкенәдән ятим калса да, үзе тоя алмаган хисләрне җыр аша тасвирлый алды, чын кешелек сыйфатларын, ихлас тойгыларны, мөнәсәбәтләрне бәяли белә иде ул.

Әти-әнисеннән бүләк булган табигый сәләте сирәк очрый торган талант иде. Ул тормыш, кешеләр турында фикерләрен җырларында тудырган образлар аша башкалар белән бүлеште. Дан һәм хөрмәткә, бүләк һәм мактауларга ирешкәннән соң, Әлфия озак еллар шушы уңышлардан файдаланып та яши алыр иде бәлкем, ләкин ул һаман хәрәкәттә, эзләнүдә булды, әйтерсең, кемдер аңа тукталмаска өнди, ул бит рок, джаз элементлары булган татар эстрадасы нигезләрен булдырды. Дөнья халкы җырларын Әлфия, көе, ритмы, образларына карап, үзе сайлый, башкарганда аларны саклый, тугры дусты Гөлшат Зәйнашева, аның соравы буенча, җырның кайбер өлешләрен татарчага тәрҗемә итә. Һинд, кытай, гарәп һәм башка халык җырлары Әлфия башкаруында үзенчәлекле яңгыраш ала, татарча тәрҗемәдә яңа тормыш белән яши башлый. Берчак шулай, чит илләргә гастрольләре вакытында ачык күңелле, шаян, эчкерсез Әлфия юлдашлары белән Венгриянең Будапешт каласында бер традицион кафега керә, биредә «тере музыка» яңгырый. Атмосфера шактый төксе, һәркем үз уйлары белән мәшгуль, бернәрсә дә ачык эмоцияләргә тартмый кебек. Әлфия музыкантларның талантына битараф кала алмый, кинәт кенә урыныннан торып, музыкантлар янына килә, микрофон сорап ала да «Зәңгәр иртәдә» дип аталган венгр романсын рус телендә җырларга теләвен әйтә. Гомерендә беренче тапкыр бу җиргә аяк баскан Әлфия башкаруында романс шундый гажәп яңгырый ки, барлык игътибарны үзенә тарта – гөрләп торган кафе шундук тынып кала. Аннары инде овацияләр, «Браво!» кычкырулар, кабат җырлавын сораулар... Сөекле җырчыбыз тагын алты тапкыр шул җырны башкара һәм әкрен генә сәхнәдән төшеп китә; тагын кул чабулар, венгрлар һәм башка ил кешеләренең сокланулы авазлары – әнә шундый иде Әлфия, дан-мактауларга омтылмый, ләкин күңел халәтен җырында тасвирлап бирә ала. Күпләргә бик үк аңлашылып җитмәсә дә, үзен һәр җирдә иркен, ирекле итеп хис итә иде ул.

Әлфия Авзалова уңышларын һәм җиңүләрен исәпләп утырмады, иҗаты белән яшәде, бик күпне эшлисе, өлгерәсе килде, бөтенесе үк барып та чыкмагандыр, ләкин тормыш аны якты, кабатланмас тәэсирләр белән сөендерде.

60 нчы елларда Әлфия Авзалова «Дөнья халыклары җырлары» дип аталган программа әзерли, ул чор өчен бу ниндидер гадәттән тыш хәл, бөек опера җырчыларыбыз гына булдыра ала торган эш булып тоела, ләкин нәтиҗә шаккатмалы була. Әлфия чит ил җырларын татарча, нәкъ оригиналдагыча, ышандырырлык һәм дөрес итеп җырлый ала. Халык җырчысы Әлфия Авзалованың иҗаты, аның татар эстрада сәнгатенә керткән өлеше безнең көннәр өчен дә мөһим. 21 нче гасырга Россия «милли идея» үсеше программасы белән аяк басты, бу бигрәк тә безнең дәүләтнең гасырларны кичкән фольклор нигезендә формалашкан күпмилләтле халкы сәнгатендә чагылыш таба. Үзенчәлекле сәнгатен, йола һәм гореф-гадәтләрен саклап калган татар халкы – дәүләт төзүче буларак мәгълүм, ул рус мәдәнияте белән дә бердәм булып кала. Республика, федераль һәм халыкара дәрәҗәдә танылу алган җырчы Әлфия Авзалованың иҗади тормышы этаплары – ерак татар авылында ятим үскән гади авыл кызының үз илендә, үз иҗаты аркасында, халыкның яраткан, сөекле җырчысы, татар эстрадасына нигез салучы була алуының ачык мисалы. Әлфия Авзалованың иҗат юлы юнәлешен сайлауда профессор Ирма Яунзем – бөтен тормышын халык җырына багышлаган академик белемле җырчы зур роль уйный. Рус телендәге җырлардан тыш, ул илебез буйлап фольклор экспедицияләрендә бөртекләп җыйган җырлардан искиткеч зур репертуар төзи алган, ул халык җырларын аутентик хәлдә башкарган. Кайчандыр Ирма Яунзем җырлаган җырларның саны шаккатыра: 5000 җыр! Шуларның 500дән артыгы – дөньяның 64 телендә. Шул исәптән, ул татар һәм башкорт телләрендә дә җырлый. Ирма Яунзем фикеренчә, «Берәр милләтнең җырын башкару өчен сүзләрен һәм көен белү генә җитми. Халык җырлары шундый нюансларга ия була ки, аларның күбесен нота билгеләре белән генә күрсәтеп бетерү һәрвакыт мөмкин дә түгел. Шуңа күрә милли төбәкләрдә мин тырышып телне, һәр халыкка хас булган тавыш чыгару үзлекләрен өйрәнәм. Шулай ук тембр характерына, көйне бирү манерасына игътибар итәм. Мин үзем ишетмәгән халык җырын җырламыйм». Ирма Яунзем иҗатына Сергей Лемешев, Юрий Завадский, Ромен Роллан, Максим Горький сокланган; Сергей Прокофьев аны үз җырларын иң яхшы башкаручы дип атаган. И. Яунзем, беренчеләрдән булып, халык җырларын башкаруда эстрада тенденцияләренә игътибар итә, бу юнәлешне хуплый һәм илебезнең талантлы яшь артистларына ярдәм күрсәтә. Әлфия Авзалова татар җырларын җырлауга табигый сәләте булган һәм инде яңа юнәлеш – татар эстрада сәнгате төзергә омтылган якты талантларның берсе була, бу Ирма Яунзем тарафыннан аңлау һәм яклау таба. Ул талантлы яшь җырчы кызны күп нәрсәгә өйрәтә, Әлфия Авзалова исә бу вакытта «Казан утлары» ижади төркемен оештыра, «Дөнья халыклары җырлары» программасын төзи, аны илебезнең төрле төбәгендәге шәһәр-авыллар хуплап каршы алалар.

Әлфия Авзалованың элеккеге еллардагы җырларына музыкаль бизәлеш ясаган Валерий Коротковка – халыкара дәрәҗәле уңышлы музыка продюсерына аерым рәхмәт! Аларның 2018 нче елның 11 нче июнендә футбол буенча Дөнья чемпионаты кунаклары алдында яңгыравын Казан, чит ил җанатарлары кызыксынып тыңлады, борынгы җырларны заманча, яңача башкару барысына да ошады. Әлфия Авзалова ижатының яңа буын тыңлаучыларына да зарур булуын аңлау бик мөһим иде, бигрәк тә Валерий Коротков тәкъдим иткән яңа музыкаль укылышта. Әкренләп Әлфия Авзалованың ижади мирасына тугры булган талантлы һәм югары һөнәри артистлардан яңа ижади төркем оеша, аларны бер хис, бер теләк берләштерә: Әлфия Авзалова дәрәҗәсендә иң яхшыны һәм гадәти булмаганны булдыру.

Яшь башкаручылар һәм ижади төркемнәрнең Әлфия Авзалова исемендәге беренче халыкара фестиваль-конкурсы Татарстан Республикасы Актаныш районының Актаныш авылында 2018 нче елның 1 нче июлендә үткәрелде. Анда төрле жанрда, төрле яшьтәге группаларда 300дән артык кеше катнашты, яшь артистлар Татарстаннан гына түгел, Башкортстаннан да килгән иде, Э. Фәттахов һәм Актаныш районы администрациясе коллективы ярдәмендә менә дигән бәйрәм – татар халык ижаты бәйрәме барлыкка килде. Жюри рәисе – Россиянең атказанган, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов, жюрида тагын Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Винера Ганиева, бөек җырчының кызы Зөлфия Авзалова-Нигъмәтҗанова, Рабит Батулла, Татарстанның күренекле артистлары һәм сәнгать эшлеклеләре булу күп нәрсә турында сөйли: бу – бик җитди ярыш, ул яңа исемнәр ачты. Сүз уңаеннан, конкурс шартлары буенча, лауреатлар 2018 нче елның 21 нче октябрендә, икенче турда катнашу өчен, Казанда җыелырга тиеш. Әлфия Авзалова туып-үскән һәм белем алган Актанышта халык традицияләре саклана, район яшьләренең һәм бөтен Татарстан кешеләренең ижади үсешенә ярдәм итә.

2018 нче елның августында Мәскәүдә Әсәдуллаев йортында Әлфия Авзалова истәлегенә багышланган кичә узды. Аны, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Россия Федерациясендәге Татарстан Республикасы вәкиллеге ярдәмендә, Әлфия Авзалова фонды оештырды; кичәгә башкалада яшәүчеләр һәм кунаклар җыелды. Яраткан җырчыларының җырларын яңадан ишетергә теләүчеләрнең барысын да зал сыйдыра алмады. Беренче видеокадрлар – Әлфия Авзалова җырлавын зал, аягүрә басып, көчле алкышлар белән каршы алды; талантлы яшь җырчыларның Әлфия Авзалова репертуарындагы җырларны башкаруын да тамашачылар көчле алкышларга күмде. Соңрак, концерт тәмамлангач, кичәне оештыручылар тамашачылар белән очрашты, Әлфия Авзаловага нисбәтле ижади планнары турында фикерләре белән уртаклашты, бөек җырчының ижади мирасына мөкиббән булган, сәнгатькә бирелгән кешеләр белән аралашты.



Мәскәүдә Әсәдуллаев йортында Әлфия Авзалова истәлегенә багышланган кичә. 2018

Бер үк вакытта Әлфия Авзалова фонды президенты Зөлфия Авзалова җитәкчелегендә 2018 нче елның 20-22 нче октябрендә уздырылачак Әлфия Авзалова исемендәге беренче Халыкара фестиваль-конкурска актив әзерлек барды. Татарстан Хөкүмәте, Мәдәният министрлыгы, Казан мэрияседе һәм ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерү фонды тарафыннан күрсәтелгән ярдәмнең әһәмияте, һичшиксез, зур булды. Конкурс 20-21 нче октябрь көннәрендә Казан дәүләт мәдәният институтында өч номинациядә – вокал, бию, нәфис сүз буенча үткәрелде. Анда Татарстан Республикасыннан, Россия төбәкләреннән – биш йөздән артык, шул исәптән, АКШ, Кытай, Һиндстан, Мисыр, Үзбәкстан, Израиль кебек чит илләрдән кырыктан артык кеше катнашты.

Фестивальнең үзенчәлеге шунда: конкурста катнашучылар бөтенесе дә Әлфия Авзалова репертуарындагы җырларны татарча башкарды. 22 нче октябрь көнне «Пирамида» комплексының мәдәният-күңел ачу залында зур концерт оештырылды. Анда конкурс лауреатлары, Татарстан, Россия һәм чит илләрнең күренекле артистлары чыгыш ясады. Әлфия Авзалова фондына изге ниятләрен тормышка ашыруда зур уңышлар телим! Бу чаралар, һичшиксез, бөек татар җырчысының һичбер вакыт искермәс иҗатын саклау һәм үстерүгә ярдәм итәчәк.

Азат ХАМАЕВ,
Татарстан Республикасының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры



Әлфия Авзалова белән беренче очрашуым 1960 нчы елның урталарында булды. Алар бригадасы безнең авылга концерт белән килгән иде. Тагын күпмедер вакыттан соң, аны сәхнәдә тагын күрергә, кабат моңлы тавышын ишетергә насыйп булды. Бер концертына ул кызын да алып килгән иде. Кайсы районга, кайсы авылга барса да, Әлфия апаны колач җәеп каршы алдылар, туган ягы Актанышта ул һәрвакыт көтелгән, кадерле кунак булды. Чираттагы очрашуыбыз нәкъ менә Актаныш районы, «Чишмә» колхозында булды. Әлфия апа бу колхоз рәисе белән бик дус булган. Ел да рәис аларны берәр атналап үзендә ял иттергән. Бу юлы ул үзе белән танылган композитор Сара Садыйкованы да алып килгән. Безнең студент еллар, мин шул колхозга эшкә килдем. Бер көнне безне – биш-алты студентны, колхозчылар йортында әзерләнгән мул, сыйлы өстәл янына дәшеп алдылар, ашап бетереп килгәндә, Сара апа белән Әлфия апа килеп керде. Ул табын алар хөрмәтенә әзерләнгән булып чыкты. Шулай итеп сөйләшеп, аралашып киттек, аралар якынайды.

2000 нче елларда безгә Әлфия апа белән Ямашев урамындагы бер йортта, бер подъездда яшәргә туры килде. Ике еллап бергә яшәлгәндер. Әлфия апа бик тә җор кеше, сөйләшергә, аралашырга ярата торган ханым иде. Кызы Зөлфия гаиләсе белән Америкага киткәндә, этләрен Әлфия апага калдырганнар. Әлфия апа шул эт артыннан йөгереп йөри торган иде. «Ничек котылырга инде моннан?» – дип көлдерә иде. Гомер буе артист хезмәтендәге кешеләрнең холкы төрлечә буладыр инде. Миңа Әлфия апа бик тә аралашучан, киң күңелле, кыю, максатчан булып исемдә калган. Концерт саен 15-20 каз алып кайтам, дип көлеп сөйли торган иде ул безгә.

Аннары мин Әлфия апаны тагын Тукай районы Сабантуенда очраттым. Актаныш Сабантуеннан соң, район башлыгы Энгель Фәттахов мәҗлес оештырды. Шул мәҗлестә дә безгә бергә булырга туры килде. Очрашканда һәрчак тормыш, балалар турында сөйләшә идек. Хәзер дә аның кызлары белән аралашканда, үземә карата ниндидер җылы мөгамәлә сизәм. Алар әниләрен сагынып, гел яхшы яктан гына искә ала. Минем күңелемдә дә Әлфия апа йомшак күңелле, кешелекле, ярдәмчел булып калды. Ул һәрчак миңа ягымлы булды. Сирәк күрешсәк тә, очрашканда сөйләшеп сүзләр бетмәде. Күңелем белән Әлфия апаның мине хөрмәт иткәнен тоя торган идем. Тормыш юлымда шундый зирәк, зур талант иясе, моңлы җырчы белән очраштырганы өчен, Аллаһы Тәгаләгә мең рәхмәтлемен!

Азат ХӨСӘЕНОВ,
композитор-музыкант



Әлфия Авзаловага кагылышлы хатирәләрем күп түгел. Шулай да кайберләре әледән-әле күңелдә яңарып тора. Әтием байтак еллар Актаныш районының Әтәс авылында мәктәп директоры булып эшләде. Безнең өй клубка терәлеп үк диярлек тора...

Бервакыт Әлфия апа авылыбызга концерт куярга килә. Бу – 1961 ел. Артистларны кемгә фатирга кертергә? Безгә кертергә булалар. Ул чакта без – җиде бала, әткәй-әнкәй, мин – иң кечесе, ул вакытта әле сеңлем тумаган. Шул вакытта ук безнең фотоаппарат булган. Әткәй безне – җиде баланы, әнкәйне тезеп бастырып, уртага Әлфия апаны алып, фотога төшерә. Ул чакта әниемнең – сеңлемне, Әлфия апаның Зөлфияне көткән, ягъни икесенең дә көмәнле чаклары. Әлеге фотосурәт әле дә бездә саклана.

Тагын бер якты хатирә. Мөслим районының Усы авылы. Консерваториядә укыган чак. Җәйге ял көннәрендә генә мин анда клуб мөдире булып эшли идем. Шунда бер көнне Әлфия апаның концерты булды. Әлбәттә инде, клуб шыгрым тулы. Сыймаганнар урамда утыра. Үзен көтәбез. Берзаман Әлфия апа килеп төште. Кайсыдыр колхоз рәисе китерде. Рәхәтләнеп мунча керткәннәр.



«Менә юеш чәч белән килдем. Мунча чабындым әле. Көттерде бу, дип ачуланмагыз!» – дип сәхнә артына кереп китте. Клуб мөдире булгач, мин инде концертны басып кына карыйм. Тәртип ягын да күздән ычкындырмаска, барысына күз-колак булырга кирәк бит!



Әлфия апа сәхнәдән бер баянчысы турында, менә без кабат дуслаштык, бер-беребезне хөрмәт итәбез, дип сөйләп китте (хәтерем ялгышмаса, ул вакытта Кәрим офыкта юк иде әле). «Баянчым шәп бит, яшь баянчы әйбәт инде ул! Аның исеме – Ринат Сибгатуллин. Ул консерваториядә укый», – ди. Мин бит инде барча баянчыларны беләм. Консерваториядә Ринат дигән кеше укымый. Менә концерт бетте. Андый тамашалардан соң, мин, кулыма гармун алып, халыкны биетмичә калмыйм. Татарча бию көйләре, вальс та яңгырый. Менә уйный башладым. Кулына гармун алып, Ринат та килеп кушылды. Әлфия апа да рәхәтләнеп халык белән биеде.



Биюләр тәмамлангач, мин Ринаттан: «Син консерваториядә укыйсыңмыни?» – дип сорап куйдым. «Юк инде, Әлфия апа арттырырга ярата, мин музыка училищесын гына тәмамладым әле», – дип җаваплады ул. Без шунда, Әлфия апа концертында таныштык һәм күп еллар аның белән дус булдык. Бергәләп Зәйнәб ансамблендә дә эшләдек. Дөрес, соңрак та Әлфия апа белән очраштыргаладык. Тик мондый җылы истәлекләр башка юк бугай.

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА,
язучы



Җыр дәвам итә...

Меңъяшәр дигән исем йөрткәннәр дә мәңгелек түгел шул... Чәчелгән-сибелгән татар халкының горурлыгы – Әлфия апабызның бакыйлыкка күчүенә инде бер ел узып китте. Шунысы сөенечле: аның җырлары, ул җырларны, моңнарны дәвам итүчеләр калды.

2000 елда ук Актанышта районкүләм җыр бәйгесе рәвешендә башланган конкурсның быел инде Әлфия Авзалова исемендәге I Халыкара фестиваль-бәйге югарылыгына үсеп җитүе моңа үзе үк бер дәлил булып тора. 30 июнь – 1 июль көннәрендә фестивальнең төбәкара туры нәкъ менә Актанышта узуга һич кенә гажәпләнергә кирәкми. Әлфия апаның теленнән, җырыннан төшмәгән туган ягы, туган туфрагы, лабаса.

Аның милләтебез алдында куйган хезмәтен сүзләр белән бәяләү мөмкинме соң?!. Үзе кызыл, төче сүзләрне яратмас иде, «кит әле, исәр сатып торма әле», дип, кул гына селтәр иде дә, ятимлектә үткән балачагын, Җыракаеның тау башыннан озатып калуын, артист хезмәтенең, юл гизүнең газапларын берчә көлеп, берчә күз яшьләрен сөртә-сөртә, кыйсса-кыйсса итеп сөйләп алыр иде...

Әлфия Авзалованы халык ничек бар – шулай: ачык йөзе, туры сүзе, гадилеге, чаялыгы, бар булмышы белән үз кызы итеп кабул итте. Урта һәм өлкән буын хәтерендә аның ут янып торган шомырт күзләре, җор теле, пластинка тәлинкәләреннән, сәхнәдән агылган дәртле-моңлы җырлары бик озак сакланыр әле. Халыкның ихлас мәхәббәтен яулау һәр җырчыга да тәтеми. Эчкерсезлеге, күңел түреннән ургылып чыккан моңы белән үзенә тартамы ул? Аның җырларында – тулы бер милләтнең сагышы, шатлыгы, фаҗигасе, үткәне, бүгенгесе чагыламы?

Әлфия апа белән бергә Салават концертында утырганым истә. Салават сәхнәдән: «Бүген залда минем икенче әнием дә бар әле», – диюгә, урта рәткә түгәрәк ут яктысы төште. Яраткан җырчысын танып алгач, зал, урынныннан кубарылып, кул чабарга тотынды. Чын йөрәктән чыккан рәхмәт һәм сагыну хисләре шушы шашкын алкышларга сыйган кебек иде. Әлфия апа тыйнак кына баш иде дә: «Салават, әни димә инде, картайтасың бит. Сеңелкәшем генә дичәле», – дип, гадәтенчә шаярып алды. Чаллы Сабантуенда да халыкның нәкъ шундый ихлас мөнәсәбәтенә тап булган идем. Рәт-рәт тезелгән эскәмияләр арасыннан Әлфия апа атлап менә. Тирә-юньдәгеләр, мәйдандагы тамашаны онытып, йотлыгып-йотлыгып легендар җырчыга төбәлделәр. Кемдер терсәге

белән күршесенә төртә: «Әнә, Әлфия Авзалова!» Кемдер җырчының кулына кагылып ала, берәү аркасыннан сөеп өлгерә, берәү исәнләшә, кемдер елмаеп баш кага...

«Һи-и, әле син Петербург Сабантуендагы хикмәтне күрсәң! – диде Әлфия апа, бу хакта соңыннан сүз кузгаткач. – Уратып алдылар, мин сиңа әйтим. Барысы да автограф сорый. Кайсы паспортын, кайсы правасын, кайсы тәмәке кабы суза. Җитмәсә, һәрберсе, атымны яз, атымны яз, дип, исемен дә язарга куша. Арыдым дип, ничекләр борылып китәсең инде...»

Ятим балачагында абзарда казлар белән бер табактан ризык бүлешкән мәлләрен, өстәл клеенкасыннан тегелгән букча тотып, берүзе детдомга юнәлүен, Актаныш урамындагы түгәрәк «тәлинкәдән» яңгыраган бөтен җырларны ятлап бетерүен, шулар канатында Казанга, Җыр һәм бию ансамбленә килүен, «консерватория бетермәгәнсең, югары белемең юк», дип, үзәккә үтүләрен, күз яшьләре аша, көлә-көлә сөйли иде ул. Композитор Александр Ключаревның: «Әлфия – Актаныш туфрагыннан табылган самородок ул», – диюен, горурланып, яратып искә төшерә иде.

«Эстрада концертында беренче тапкыр ялгызым гына җырлаганда сүзләрен оныттым бит!

«Безнең илнең егетләре
Сугышларда дан алды шул... –

дидем дә, шуның белән шул. Күз чите белән генә баянчы Рокыя Ибраһимовага карыйм, янәсе, әйтеп җибәрмәсме... Аннан өмет булмагач, телемә килгән беренче сүзләрне куштым да җырлап бетердем:

Кояш килеп чыкты да
Җир тишегенә кереп югалды-ы-ы...»

Әлфия апа үзе турында ачылып сөйләүдән читенсенми иде. Халык алдында кәгазьдән карап җырлаудан да оялмады. Иң мөһиме – бүгенге эстрада җырчыларының бик күбесе шикелле, фонограммага авыз ачып-ябып, тамашачысы алдында кәмит куймады, халыкны алдамады. «Аннан да кыен эш юк бит ул. Бүтәннәр ничек ялгышмый икән, дим. Себердә салкын тидереп, нык кына ютәлли башлагач, бер-ике җирдә фонограммага кушылып караган идем. Җыр китә – авызым йомык кала. Авызым ачыла – җыр туктаган...», – дип, үзе дә гаҗәпләнеп телгә ала иде.

Өенә кунакка барсаң, ни ашыксаң да, тиз генә чыгып китәрмен димә. Берсе икенчесенә ялганган хатирәләр үзенә бәйли дә, Әлфия апаның авызына карап, дөньяңны онытканны сизми дә каласың. «Башына парик кигән, авызында хөкүмәт теше, диләр. Андыйларга чәчемне дә, тешемне дә йолкып-йол-

кып күрсәтәм, – дип көлеп ала да, шкафны ачып, тезелеп торган даруларына ымлый. – Теге чир белән чирләгәндә, бөтен чәчем коелып беткән иде, яңадан үсте бит, бөдрәләнеп, матур булып үсте! Нык чирләдем бит, менә шушылар белән торам, җаныкаем!» Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, тормышка һәм җырга мәхәббәт, табибларның алтын кулы үзен яман шеш авыруыннан алып калгач, дөньяга кабаттан тугандай хис итә иде ул үзен.

...Хушлашам кошлар белән.
Алар минем хәлне белми,
Мин аларныкын беләм...

Бу җырны, нәкъ менә шундый авыр мәлләрендә, Свердловск шәһәрендә яшәүче дуслары иҗат итеп җибәрә Әлфия апага.

Шулай да гомер чикле, менъяшәрләр дә беркөн китеп бара. Онытылмас, үзәк өзгеч моң булып, истәлекләр, җырлар, дәвамчылар кала...

Аңа багышланган җыр бәйрәме дә – үзе шикелле ихлас, ачык йөзле, гади һәм... гали иде. Залда урындыкларга гына сыймаган, рәт-рәт булып басып караган тамашачы, сәхнәдә, экранда Әлфия апаның сурәте пәйда булганда да, аның тавышы ишетелгәндә дә, «Кәккүк», «Гөлҗамал», «Сакмар су» кебек җырлары талантлы яшьләр тарафыннан яңгыраганда да, «ah» итеп, сулышсыз булып тыңлады. Югары дәрәҗәдә, затлы һәм зыялы итеп оештырылган бәйрәм барышында вакыт исәбе онытылгандай иде.

Жюрида Салават Фәтхетдинов, Винера Ганиева, Риф Гатауллин, Рабит Батулла, Илфак Ибраһимов, Гаптерәүф Нуриев, Әлфия Авзалованың кызы Зөлфия Нигъмәтҗанова һәм башкалар булып, алар ике көн дәвамында яшьләрнең җыр, нәфис сүз, бию буенча осталыкларына бәя биргәннәр. Сүз дә юк, 23ләп кеше арасыннан җиңүчеләр санаулы гына була ала. Нәкъ менә алар Гала-концертта сәхнә тотты да инде. Башкортстан һәм Татарстанның төрле районнарыннан килгән яшь талантлар диплом һәм бүләкләргә генә түгел, көз көне халыкара бәйгедә катнашу хокукына да ия булдылар.

2014 елда Әлфия Авзалова исемендәге фестивальнең 2007 ел Гран-при иясе Алсу Нургалиева истәлегенә махсус приз булдырылган иде. Алсуның әнисе – «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова – ул бүләкне, гаилә исеменнән, Актанышның тагын бер моң иясенә таппшырды.

Ә менә быелгы бәйгедә төп бүләкне яулаучы табылмады. «Гран-при иясенең җыр башкару осталыгы жюрида утыручыларны гына түгел, тамашачыны да «ah» иттерергә тиеш. Әлфия Авзалова беренче тапкыр сәхнәгә чыккач, халык «ah» иткән һәм аны илле ел буе шулай тыңладылар», – диде Салават Фәтхетдинов, бу күренешкә кыска гына аңлатма биреп. Шулай, Тукайларны, Әлфияләрне, Илһамнарны гасыр үзе берәмләп кенә тудырадыр шул!

Район башлыгы Энгель Фәттахов, җиңүчеләргә тәбрик сүзе җиткергәндә, Актанышның йөзек кашы булган Әлфия апабыз белән горурлануын да, аңа бәйле хатирәләрне дә искә төшерде: «Әлфия апаның рухы алдында күңелем чиста, соңгы көненә кадәр аралашып яшәдек, гомере өзелергә санаулы минутлар калганда да больницада, аның янында булдым».

...Үз җырларының яшьләр телендә тибрәлүен, фестивальнең нәкъ менә Актанышта узуын Әлфия апа үзе дә, шаян гына елмаеп, бакыйлыктан күрепкүзәтеп торадыр шикелле. «Җырым тагын халкыма кайтты. Җыр исән, моң исән», – дип, рухы сөенәдер...

Айгөл НУРИСЛАМОВА,
«Ай белән кояш» үзәге җитәкчесе,
гаилә дуслары



Җыр-моң дөньясы белән мине кечкенәдән бабам таныштырды, чөнки ул гармунчы, оста баянчы иде. Авыр сугыш елларында ачлык-ялангачлыкта гомер сөрсә дә, аның күңеленең бер почмагында җыр-моңга мәхәббәт, егетләргә генә хас күңел көрлеге яшеренеп калган. Ни кызганыч, бабайдан башка нәселебездә гармун тартучы да, җыр-моң белән мавыгучы да юк. Бер очраклы вакыйга күңелемне тетрәндермәсә, мин дә җыр-моңнан ерак торыр идем, мөгаен. Карап торышка бик тә зәвыклы, энәдән-җептән киенгән, күркәм ханым белән очраклы гына танышып, сөйләшеп киттек. Гадәттә, һәркемдә яңа танышыңның нәрсә белән кызыксынганын белү теләге туа. Аның да, сүз арты сүз китеп, минем Әлфия Авзалова җырларына карата булган фикерләремне беләсе килде. Мин: «Әлфия Авзалова җырларын тыңлаганым юк», – дигән идем. «Әгәр дә сез, безнең Әлфия Авзалованы тыңламыйсыз икән, минем сезнең белән башка сөйләшер сүзем юк!» – диде ул. Шушы күңелсез әңгәмәдән соң, мин җыр дөньясына кереп чумдым, хәтта ки Әлфия апаның җырларыннан башка яши алмый башладым.

Инде ул көннәрдән соң әллә ничә дистә ел вакыт узды. Язмыш диген, бүгенгесе көндә мин легендар җырчы Әлфия Авзалованың балалары белән тыгыз элемтәдә торам, якын дуслыкта яшим. Бу бәхет миңа күкләрдән иңгәндәй тоела. Миңа Әлфия апаның кызлары белән аралашу, алай гына да түгел, ярдәмләшеп яшәү бетмәс-төкәнмәс күңел җылылыгы, зур шатлык бирә. Мине кызларының, легендар җырчы Әлфия Авзалова исемендәге фонд-

ны тернәкләндереп, аның истәлеген саклау йөзеннән башкарган хезмәтләре сокландыра. Әлеге фестивальдә, Әлфия Авзалова исеме белән бергә, аның җырлары, моңнары терелде. Аларга яшь башкаручылар яңа сулыш өреп, киләчәк буыннарга илтүне үзләренә бурыч итеп алды. Җыр-моңнарыбыз аша танылып килгән, бүгенгә кадәр сакланган телебез, моннан соң да бөек җырчыбыз Әлфия Авзалова сызган җырлы-моңлы юлдан барыр дип ышанам.

Айсылу НАСЫЙБУЛЛИНА,
гаилә дусты



Җыр башлана... Нәкъ менә Аның башкаруында Җыр җырлана һәм Сине тулысынча биләп ала. Татар җыры. Татар моңы. Шундый тирән, чиксез, моңлы... Бу вакытта дөньяда нибары Син үзең, Аның тавышы һәм Җыр кала.

Онытыласың. Бу мизгелдә онытыласың, тулысынча Җыр-моң дәрьясына чумасың. Үз-үзеңә, асылыңа кайтасың... Никадәр көч бу кабатланмас тавышта. Әлфия апа тавышында!

Бу шәхеснең иҗатына хөрмәтебез һәм мәхәббәтебез чиксез. Зур гаиләбезнең һәр буын вәкиле аны үзенчә ярата, үзенчә кабул итә. Әлфия апаның татар сәнгатен үстерүгә багышланган фидакарь хезмәте бәхәссез. Тамашачы күңелен яулаган талантлы моң иясе, чын милли татар җырчысы әле озак еллар дәвамында татар халкының рухы һәм моңы сагында торыр!

Айдар ГАЛИМОВ,
җырчы, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты



«Моң алиһәсе» Әлфия Авзалованың мәңгелеккә күчүе турындагы хәбәр бөтен Башкортстан һәм Татарстан халкын кара кайгыга салды. Әлеге бөек, легендар җырчы белән иҗат юлларыбыз гел кисешеп торды. Искиткеч талантлы, гасырга бер туа торган мондый мәшһүр җырчы белән бер чорда яшәү – үзе зур бәхет! Күңелендә Галәм киңлеге кадәр моң йөрткән җырчының якты дөньяда бер гасырга якынлык тормыш юлы, салган эзе бар. Аның татар җыр сәнгате һәм мәдәнияте үсешенә керткән өлеше әйтеп бетергесез зур. Ул үзеннән соң киләчәк буыннарга зур мирас калдырып китте. Аның үз юлы, үз агымы, беркемне дә кабатламаган үз моңы, үз стиле бар иде. Аның яшәү мохите сәхнә иде.

Минем артист булу теләгем дә аның җырларын тыңлаганнан соң бөреләнде. Мин әле ул вакытта 3нче класста гына укый идем. Кулымны сындырып, урамга да чыкмыйча өйдә ятам. Шулчак, безнең авыл клубына концерт белән Әлфия Авзалова килә икән, дигән хәбәр таралды. Үз-үземне белештермичә, муенга сынган кулымны бинт белән асып, клубка атладым. Иң алдагы рәттә бер урын буш иде, шунда барып утырдым. Күңелемә, мин дә җырчы булам, дигән хыял шунда кереп оялады, чөнки мин кечкенәдән җырларга ярата идем. Концерттан, сынган кулым турында да онытып, бик хисләнеп кайттым.

Уфада техникумда укыган студент елларымда Әлфия Авзалованың гастроль концертларының берсеннән дә калмадым. Хәтта бер үк программалы концертка берничә тапкыр бару бәхете дә тиде. Ул вакытта ике кассеталы магнитофоннарның чыккан чагы гына иде әле. Без – яшь егет-кызлар, аның җырларын яздырып, кат-кат рәхәтләнеп тыңлый идек. Минем күңелдәге бу кабатланмас халәт, аның моңнарына әсир булу ул чорда яшәгән һәрбер кешедә дә булгандыр дип уйлыйм.


Тора-бара балачак хыялым тормышка ашкач, без бу буй җитмәс бөек шәхес белән бер сәхнәләрдә чыгыш ясый башладык. Мин аның үземә карата бик тә җылы, әниләрчә мөгамәләсен сизә идем. Ул читтән караганда кырыс, таләпчән күренсә дә, якыннан аралашканда искиткеч гади, кешелекле, аралашучан ханым иде. Холкындагы бу капма-каршылык аның кечкенәдән ятимә

калып үсүе нәтиҗәсендә саклану чарасы булып формалашкан бер сыйфаттыр дип уйлыйм. Анда йолдызлык чире беркайчан да булмады. Ул сәхнәдәшләренә гаҗәеп тирән хөрмәт белән, үзен яңа гына җырлый башлаган җырчы кебек карады. Аның янында һәрвакыт төркем-төркем кешеләр булыр иде, чөнки аның кебек җор, тапкыр телле җырчы әле тумаган! Минем күңелдә ул тормыш сөючән, батыр йөрәкле, беркайчан да төшенкелеккә бирелмәс, һәрвакыт кешеләргә ярдәм кулы сузучан изге фәрештәдәй булып истә калды.

Әлфия апа беркайчан да үз-үзен аямады, бөтен барлыгы белән халкына, милләтенә хезмәт итте. Ул вакытларда бит хәзерге кебек яшәү шартлары юк иде. Айлар буе, юлсыз юлларда авыллар буйлап бушка концерт куеп йөрсәләр дә, аларның күңеле һәрвакыт көр, күтәренке булды. Шушы күңел матурлыгын, ата-бабаларыбыздан килгән моңнарны, гореф-гадәтләрне буыннан-буынга тапшыру бурычын үтәп киткән легендар җырчы ул безнең Әлфия Авзалова!

Тормыш дәвам итә. Инде бүгенге көндә бу камытны без кидек. Йөгерәбез, чабабыз, каядыр ашыгабыз, бер генә бирелгән гомерне аның кебек лаеклы итеп үтәсе килә. Әлфия апабызның урыны, һичшиксез, ожмах түрендәдер, чөнки ул бакыйлыкка изге Рамазан аенда күчте. Инде аңа булган рәхмәтләребез изге догаларыбызда чагылыр. Тыныч йокла, Әлфия апа!

Александр ЧУГУНОВ,
Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, профессор



Мине язмыш Әлфия Авзалованың кияве Равил белән очраштырды. Әлеге дуслыгыбыз инде 40 елдан артык дәвам итә. Ул хәзер дуслыктан туганлыкка әверелде, чөнки кызым дустым Равилнең улы Искәндәргә кияүгә чыкты. Алай гына да түгел, инде безнең берсеннән-берсе матур оныкларыбыз – Али, Мостафа һәм Әминәбез үсеп килә. Мине бу күркәм гаилә үзенә генә тартып калмады, алар миндә татар милләтенә карата ихтирам, хөрмәт тудырды, Әлфия апаның җыр-моңнары татар сәнгатенә зур мәхәббәт уятты.

Мин еш кына Әлфия апаларда кунакта була идем. Әлфия апа мине яратып, үз итеп – Сашка яки, бик тә күңеле көр булганда, «Чугун» дип кенә эндәшә иде. Ул чыгыш ясаган концертларда да бик еш булырга туры килде. Мин аны татар эстрадасының иң талантлы,

бөек җырчысы дип таныйм. Элеккеге татар моңнарын аның кебек җиренә җиткереп башкаручы башка артистларны белмим. Минем кече кызым тормышка чыкканда, «Казан» милли-мәдәни үзәге ашханәсендә узган кызыл туй мәҗлесендә дә ул матур милли моңнарны үзәк өзгеч итеп башкарды. Туйга килгән барча кунаклар аның үзенә генә хас көчле тембрлы, киң диапазонлы, үзенчәлекле тавышына гашыйк булды. Бу матур чыгыш мизгелләре күңелләрдә мәңгелеккә уелып калды. Аның өчен иң якын кешеләр – дуслар, туганнар иде. Ул бервакытта да матди ягын кайгыртмады, дуслар хакын хаклап, һәрчак халык мәнфәгатен кайгыртып яшәде.

Ул, татар җырлары белән беррәттән, башка милләт җырларын да бик оста башкара иде. Минем күңелгә Әлфия Авзалова яхшы күңелле ханым, бөек моң иясе булып кереп калды. Соңгы елларда, авыруы көчәйгәч, ул миңа еш мөрәҗәгать итә иде. Куркыныч диагнозын ишеткәч тә, күңелен төшермәде – көчле рухлы, батыр ханым иде ул. Без – кияве Равил белән, кулдан килгәннең барысын да эшләдек, барча таныш табибларны аякка бастырдык. Әлфия апа тиешле дәвалану курсы узып, әле аннан соң да 20 ел яшәде. Бу инде аның батырлыгы, әҗәлне җиңүе, үлемгә баш бирмәве иде. Әлфия апа – туганнары, балалары күңелендә генә түгел, татар җыр-сәнгатен бәяләгән һәрбер татар җанлы, милли рухлы кеше йөрәгендә тирән эз калдырган, бөек шәхес! Аның татар җыр сәнгатенә керткән өлеше әйтеп бетергесез зур.

Алсу НӘБИЕВА,
Казан кооперация институты
ректоры, профессор



Татарның илчесе

Олуг җырчы турында фикер тупланганда, аның җырлары күз алдына килә. Безнең буын Әлфия Авзалова моңнары аша тәрбияләнде. Дөньяның кайсы почмагына барып чыксаң да, Әлфия Авзалова турындагы китапларны, аның башкарган җырлар тупланмасын кадерләп саклаганнарын күрергә була. Очраклы рәвештә генә Моң алиһәсен «Татарның илчесе!» диеп атамаганнардыр. Еллар үткән саен, фән белгечләре Әлфия Авзалова моңының үзенчәлеге турындагы сорауларга җавап эзләр. Чөнки ул башкарган җырлар татар халкы язмышына бәйләнгән. Күренекле драматург Туфан ага Миңнуллин, заманында: «Бөекләрнең исемнәрен мәңгеләштерү – бакыйлыкка күчкәннәр өчен түгел, фани дөньяда яшәүчеләр өчен әһәмиятле», –

дигән иде. Чыннан да, Әлфия Авзаловага багышлап оештырылган чаралар телебезне, моңыбызны яшәтә. Күңелемдә аның белән булган очрашулар якты хатирә буларак саклана. Без Әлфия ханымның кызы Зөлфия Нигъмәтҗанова белән мәшһүр җырчы исән чагында танышкан идек. Бүгенге көндә Әлфия Авзалованың кызлары легендар җырчының мирасын киләчәк буыннарга җиткерү өчен зур хезмәт күрсәтә. Ана өчен зур бәхет – балаларың сызган юлыңны дәвам итеп, эшеңне киләчәк буыннарга җиткерә алса. Бүгенге көндә Әлфия Авзалова исемендәге фондның эшли башлавы шуның бер матур башлангычы булып тора. Мин үзем фондның химаячеләр советында катнаша алуым белән горурланам. Без Әлфия Авзалова истәлегенә уздырылган һәр чарага теләктәшлек белдерәбез. Быел узган Әлфия Авзалова исемендәге Халыкара иҗат фестивалендә уку йортыбызның педагоглары, студентлары һәм волонтерларыннан торган төркем иң актив катнашучылардан саналды. Киләчәктә бөек җырчы истәлегенә багышланган кичәләрне Казан кооперация институтында оештырырга телибез. Минем уемча, Әлфия Авзалованың үлемсез җырлары безнең күңелләрдә мәңге җуелмас!

Минем Әлфия апаның балаларын билгеләп узасым килә. Әниләренең исемен мәңгеләштерүдә аларның өлеше бик зур, һәр эшне балалары башлап йөри. Мин аларга зур рәхмәт сүзләремне җиткерәм. Әлфия Авзалова исемендәге фонд оештырып, төрле идеяләрне чынга ашырып яшиләр. Легендар җырчының мирасын киләчәк буыннарга җиткерү өчен алар зур хезмәт күрсәтә. Әлфия апаның җырлары сакланса, безнең телебез, милләтебез, мәдәниятебез яшиячәк. Фондның эшчәнлеге алга таба да файда китерсен. Халыкара бәйге дә тиз арада үз йөзен, башкаручысын, тамашачысын табачак. Яшьләргә мәшһүр җырчының ижатын җиткерергә кирәк, ул мәңге яшәргә тиеш!

Алсу ХӘКИМОВА,
Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе музее мөдире



Аның җырларында – халкыбыз моңы...

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әлфия Авзалованың филармония музеенда сакланучы шәхси кенәгәләрен, фотоларын күздән кичерәм. Легендар җырчы турында чыккан бихисап күп мәкаләләр, истәлек-язмалар белән янәшә, аның турында чыккан култамгалы китаплар да саклана...

Татар дәүләт филармониясе элек-электән, концерт сезоны ачылу алдыннан, сәхнә ветераннарын чакыра, Халыкара өлкәннәр көне, яки башка бәйрәмнәр уңаеннан табын янында котлау мәҗлесләре оештыра. Әлфия апаның ул очрашуларга килгәнен мин сирәк хәтерлим. Чөнки бу вакытта ул, гадәттә, гастрольләргә чыгып китә иде. Ә менә 1998 елдагы очрашу, ул да катнашкангамы, матур булып истә калган. Филармониянең сәнгать җитәкчесе, бөек җырчы Илһам ага Шакиров та катнашты ул очрашу мәҗлесендә. Филармониянең администрация бинасы әле ул вакытта Гоголь урамында иде. Шунда беренче катта урнашкан репетиция бүлмәсендә сәхнә осталары чәй өстәле янында чыгыш ясады, аралашты, истәлекләрен уртаклашты – җыр-моңга күмелде ул көнне филармония бинасы. Әлфия апа соңыннан, китапханәгә кереп, җыр җыентыклары да яздырып алды әле һәм үзе турында Г.Зәйнашева төзегән «Үзем турында» дигән китабын бүләк итте. Аның култамгасы төшерелгән әлеге китапта шундый юллар бар: «Үзебезнең газиз филармониябезгә мәңгелек истәлек булып калсын әле. Кадерле филармониямә унҗиде яшемдә килдем. Белмим, күпме гомерем бардыр, тәнемдә җаным бар чакта шушы йортта эшләргә язсын иде. Сезнең Әлфия апагыз. 1998 ел».

Әйе, Әлфия апа Авзалова – бөтен гомере буе Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә хезмәт куйган олуг җырчы. Аның сәнгатебезгә күрсәткән эчкерсез иҗаты фидакарьлек, татар сәнгатенә тулысынча бирелгәнлек үрнәге булып тора.

Ул бигрәк тә алтмышынчы-сиксәненче елларда филармониянең әйдәп баручы җырчысы була. Бөтенсоюз эстрада студиясен тәмамлагач, ул дөнья халыклары җырларыннан торган концерт программасын әзерләп, ил буйлап гастрольләрдә йөри.

Күпкырлы җырчы татар халык җырлары «Зөләйха», «Гөлҗамал», «Шахта» һәм башка борынгы моңлы көйләрне; Солтан Габәшинең «Кәккүк» романсын үзенә хас моң белән җырлаучы була. Татар классик композиторлары әсәрләрен югары зәвык белән башкара, мәшһүр композиторлар – Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев, Рөстәм Яхин, Җәүдәт Фәйзи, Алмаз Монасыйпов һәм башкаларның әсәрләре аның башкаруында Татарстан радио-телевидениесенең алтын фондында саклана. Зур талант иясе, былбыл тавышлы җырчының җырларында зур тарихлы халкыбыз моңнары чагыла. Халыкчан җырчының моңы бүген дә күңелләрдә яңгырый.

Әлфия апа белән соңгы елларда да очрашып торырга насыйп булды. Ел саен туган көненә, юбилеена багышлап филармониядә үтүче концертлары вакытында, җырчының иҗатына һәм тормышына багышланган күргәзмәләр оештыру өчен, ул безгә бик күп афишалар, фотолар тапшырды. Инде олыгаеп, үзе генә йөри алмый башлагач, филармония администрациясе белән без аның янына хәл белергә кереп чыга идек. Ул шул чакта сабый балалар кебек шатлана иде. Вафатына берничә атна гына калгач, аның хәлен белергә хастаханәгә

баргач, ул мине танымаса да, елмайды. Җып-җылы куллары белән кулны каты кысып, җибәрми торды. Көчле рухлы, батыр йөрәкле, кече күңелле иде Әлфия апа! Аллаһы Тәгалә аның рухын шат итсен, җаны оҗмах түрләрендә булсын иде.



Алсу ШӘЙБӘКОВА,
гаилә дусты

Тормыш үзенчәлекле, кызыклы һәм көтелмәгән вакыйгаларга бай. Кечкенәдән татар сәнгатенә, мәдәниятенә, әдәбиятына гашыйк булган кызчыкның хыялы үсә төшкәч тормышка аша. Язның ямьле бер көнендә яратып тыңлаган, кушылып башкарган, репертуарының һәр җырын яттан белгән иң кадерле жырчысы белән танышырга насыйп була. Һич көтелмәгәндә, мәшһүр Әлфия Авзалова үзенең тату гаиләсе белән минем иң якын кешеләремә әйләнәләр. Бүгенге көндә – Равил абый һәм Зөлфия апа гаиләсе белән без якын дуслар. Барлык шатлык-борчуларны бергә кичерәбез, мәшәкатьләрне бүләбез, алар – минем олуг киңәшчеләрем. Аларның киң күңеллелеге, тормышка, кешеләргә булган карашлары, хөрмәтләре, тормыш байлыклары таң калдыра, үрнәк булып тора.



Альбина НАСЫЙРОВА,
«Бала-Сити» халыкара полилингваль балалар бакчалары мөдире

Әлфия Авзалова жырлары минем балачак хатирәләре белән бәйле. Дәүләтиемнең яраткан жырчысы иде бит ул! «Татар моңын тоеп, татар җырларына мәхәббәт уятып үстерергә кирәк балаларны», – дигән сүзләренә үзем хәзер әни булгач кына төшенә башладым. Балачактан тыңлап үскән җырлар бик тирән эз калдыра.

Әлфия апа жырлаган җырлар да, аның тавышы да йөрәккә үтеп кереп, иң нечкә хисләрне уята. Уйландыра, дәртләндерә, яшәүнең мәгънәсен аңларга ярдәм итә!

Эшем киләчәк буын балаларын тәрбияләү белән бәйле булгач, сыйфатлы җырлар тыңлау баланың тормышында әһәмиятле роль уйный, дип уйлыйм. Без Әлфия апа Авзалова иҗатын буыннан-буынга тапшырып, аның белән горурланып үсәргә тиешбез!



Альбина ШАҺИМОРАТОВА,
опера җырчысы, Татарстанның халык,
Россиянең атказанган артисты

Җыр сәнгатенең патшабикәсе

Әлфия Авзалова халкыбызның иң күренекле шәхесләренең берсе булды һәм булачак! Ул – җыр сәнгатенең патшабикәсе! Үзенең кабатланмас көчле тембрлы матур тавышы белән һәрбер җырны ул үзенә генә хас зур профессиональ осталык белән башкарды. Аның репертуары бик тә бай. Борынгы татар җырларыннан алып заманча көйләрне беренче тапкыр инструменталь ансамбльгә кушылып җырлаучы да ул!

Татар җыр сәнгатен искиткеч бөек үрләргә күтәргән җырчыны дөньяга сибелгән бөтен татар милләте йотлыгып тыңлады. Җырны югары дәрәҗәдә, үзенчәлекле итеп, күп телләрдә башкарган, тамашачысына мәңге тугры калган җырчыны, татар халкы гына түгел, башка милләт кешеләре дә үз итте, яратты. Татар эстрада җыр сәнгатен ул зур географик киңлекләрдә танытты, зур көч куйды, тәүге нигезен төзеде. Аның башкаруындагы дәртле, иланһи матур, моңлы җырларны халык – 20, 50, хәтта 100 ел узса да – яратып тыңлар!

Әлфия Авзалова сәхнәдә патшабикә булса, гади тормышта олы җанлы Ана, чын кеше иде! Шәхсән үзем татар халык җырларын җиренә җиткереп, тирән хис, мәгънә салып җырлау осталыгына Әлфия ападан өйрәндем. Ул иҗатташ дусларын бик тә хөрмәт итә торган иде. Кешеләргә изгелекләр кылырга атлыгып торган, киң күңелле, ярдәмчел, көчле рухлы Әлфия апабызны сагынмаган, юксынмаган көнебез юк. Ул беркайчан да «йолдыз чире» белән авырмады. Безнең күңелләрдә чорыбызның легендар бөек җырчысы Әлфия Авзалова, исән чагындагы кебек үк, киң күңелле, ачык йөзле, курку белмәс батыр йөрәкле, гадел, шаян, чая булып яшәр. Әйтерсең, аны күкләр җиргә вакытлыча гына җибәргән: моңнарын сибеп, дөньяны кояштай нурландырырга, кешеләргә илһам өләшергә дип...

Әгъзам ГОБӘЙДУЛЛИН,
Татарстан Республикасының
Муниципаль берәмлекләре
Советы ассоциациясе рәисе



Моң алиһәсе

Татар халкының моңлы сандугачы һәм күренекле җырчысы Әлфия Авзалованың якты дөньядан китеп баруына тиздән бер ел була. Әмма бу легендар шәхесне онытып булмый. Хәер, аны онытырга ярамый да. Әлфия Авзалова тавышы әле дә колакта яңгырый, аның җырлары күңелне иркәли һәм йөрәк сагышын баса. Аның саф тавышы таш бәгырьләрне дә эретерлек иде.

«Шахта», «Сарман», «Нурия»... Бу җырлар кеше җанына шатлык өсти, аны үсендереп, канатландырып җибәрә. Ходай Әлфия апага чиксез зур бүләк – моң биргән.

Әлфия Авзалова – Актаныш районы кызы. Бик яшьли ятим калган. Шуңадыр, бәлки, аның тавышы, аның моңнары күңелнең иң нечкә кылларын да тибрәтергә сәләтле.

Мин Әлфия апаның үзе һәм иҗаты белән бик яхшы таныш. Тормыш аны ятимлек белән дә, ачлык белән дә сынаган. Әмма ни генә булса да, авырлыкларга бирешмичә, гаҗәеп гади, ачык йөзле, җор телле иде ул. Эчендәге борчу-хәсрәтләрне тышка чыгармыйча, үзен тулысынча тамашачыга багышлаган мәшһүр шәхес.

Кышкы зәмһәрир салкыннарда ат арбасына, трактор чанасына утырып, республика район-авыллары буенча концерт белән йөрүен бүгенгедәй хәтерлим. Салкын, ягылмаган авыл клубларында чыгыш ясаудан да тартынып тормады ул. Төн дими, көн дими, халык өчен, милләт өчен үзен аямыйча хезмәт итте Әлфия апа. Күпчелек җырчыларның остазы, сәнгать дөньясына юл күрсәтүче маяк иде ул.

Бүген аның безнең арабызда юклыгы белән күңел һаман да килешергә теләми. «Картаямыни соң йөрәк?» – дип, әле дә сәхнәгә чыгар төсле. Дөрес, Әлфия апаның җырларын тыңлаган, аның моңы белән сугарылган йөрәк картаймый!

Әлифә ВӘЛИЕВА,
нәфис сүз остасы



Күңеле бик киң иде

Мине Әлфия апа белән язмыш 1975 елда очраштырды. Аңа кадәр үк, Әлфия апа минем әтинең бертуганы Рәзилә апа белән таныш иде. Ул Әгерҗе районының Биектау авылына концерт белән килгәч, Рәзилә апаларга фатирга кергән һәм менә шушы очрашу гомерлек дуслыкка әверелгән. Рәзилә апа Әлфия апаны беренче күргәнен бик тә кызык итеп искә ала.

– Көз көне, бәрәңге алган чак иде, без барыбыз да җыелышып бакчага бәрәңге алырга чыгып киттек. Күп тә үтмәде, чып-чын авыл хатыннары сыман, яулыкларын чөеп, җиңнәрен сызганып, аягына кәлүшләр киеп, кунак Әлфия апабыз бакчага чыгып килә. Ул көнне Әлфия апа булышмаса, бәрәңге алынып бетми иде, – ди ул, көлеп. Алар шул чакта ук Әлфия апаның гадилегенә, тырышлыгына, уңганлыгына исләре китеп калган. Аннары алар Удмуртиягә күченгәч тә, араларын өзмәделәр, Ижевск шәһәренә гастрольләргә килсә, Әлфия апа иң беренче Шамил абый белән Рәзилә апаларга туктала торган иде. Аның килүен алдан белсә, әниләре Хәмдениса апа әй тотыныр иде әзерләнергә, безнең Әлфиябез килә дип, пилмән, бәлеш, чәкчәк, төш – барысы да табын түренә тезелер иде.

Әлфия апа килгәндә, алар аны беркайчан да кунакханәгә җибәрмәделәр, бер атна концерт булса, бер атна кунак иттеләр. Минем яраткан җырчым белән танышуым Ижевск шәһәрендә булды. Ул үзенең төркеме белән «Тимеръюлчылар» мәдәният йортына чираттагы концертын куярга килгән иде. Ул көнге тәэсирләр бүген дә күңелне җылыта. Ул үзенә генә хас тирән моңы, матур тавышы белән бөтен тамашачыларны әсир итте, аны алкышларга күмделәр. Концерт тәмамлангач та без өйгә кайтырга ашыкмадык, Әлфия апа автобуска утырып күздән югалганчы озатып калдык. Аның шулкадәр яшь, чибәр, матур итеп киенгән, шук, чая, ут янып торган чагы иде ул. Рәзилә апа миңа: «Әлфия Авзалова концерт куярга килсә, гел бездә туктала, ул булганда, безгә берәр килеп утыр әле», – дип чакырган иде. Икенче көнне гармунымны тоттым, матур чәчәкләр алдым да җизни белән Рәзилә апаларга киттем. Үзем бик тә дулкынланам, Әлфия апа ничек кабул итәр дип куркам.

Куркуым тиккә генә булган. Ул шулкадәр ачык йөзле, киң күңелле, шаян сүзле булып чыкты. Рәзилә апа Шамил җизнигә катырак эндәшкәндерме, ул шаяртып: «Рәзилә, Шамилне болай каксаң, үзем белән Казанга алып китәм дә, 18 яшьлек кыз белән таныштырам», – ди. Күңелле итеп кич утырдык. Мин, утыра торгач, гармунымны алып җырлап җибәрдем. Ул тыңлап-тыңлап утырды да: «Әйдә, бәгърем, Казанга кил җәй көне, мин сине үзем эшкә урнаштырырмын», – ди. Миңа Казандагы адресын да тиз генә язып бирде. Җәй җиткәч тә, Казанга юл тоттым. Әлфия апалар ул чакта Галиев урамындагы 8 нче йортның 10 нчы фатирында яши иде. Аларга кергәнче иң элек чәчтарашта чәчемне бөдрәләттем, химик составын дөрес кушмыйчамы, вакытын дөрес чамаламаганмы – минем чәчне көйдереп бетерделәр, кәеф кырылды. Җитмәсә, Әлфия апалар йорты турына килеп җиткәч, Җыракай: «Бу нинди бүрек кигән кыз, кая бара бу?» – дип көлеп калды. Мин 10нчы фатирның төймәсенә бастым, ишекне Әлфия апаның кызлары – Гүзәл белән Зөлфия ачты. Минем арттан ук, бастырып, Җыракай килеп керде. Әлфия апа эштә иде. Без бергә утырып чәйләр эчтек, тиздән Әлфия апа да кайтып җитте. Без, беркавым торганнан соң, Әлфия апа белән бергә музыка училищесына киттек. Анда шагыйрә Гөлшат Зәйнашева белән очраштык, укытучыларга минем музыкаль сәләтемне тыңлатты. Баян классында урын беткән иде, миңа флейта бүлегенә керергә тәкъдим ясадылар. Әмма минем башка уен коралына күчәсем килмәде, без театр училищесына юл тоттык. Әлфия апа белән ни өчен килгәнебезне белгәч, гармунда уйнап күрсәткәч, студентларны кабул итүче Асия апа Хәйруллина, мин сезне алам дип, башка имтиханнар бирдереп тә тормады. Мин шул уку йортында, бик тә талантлы артист, остазым Габдулла Шамуков кулы астында белем ала башладым.

1 нче курсны тәмамлагач, Әлфия апа миңа акча да эшләрсең, укуыңа акча булыр дип, үзе белән гастрольләргә алып чыгып китте. Шунда беренче тапкыр гастрольгә чыктым. Дүрт көн өчен, 180 сум акча түләде миңа, бу ул заман өчен бик күп акча иде. Ә бөтен керем 720 сум булды. Бу акчага сөенүләрем, хикмәт баедым бит. Мин шул акчага өстемә кыйммәтле нутри яка белән ут янып торган кызыл төстәге пәлтә тектердем, шапка алдым, рәхәтләнеп баштанаяк киендем. Минем өс-башыма бөтен кызлар кызыга иде. Үзем Әлфия апада эшләвем белән чиксез бәхетле идем. Безнең студентларның айлык пособиесе ул чакта 30 гына сум иде. Мине Әлфия апа, фатирга акча түләп ятма, дип, үзләрендә яшәтте. Без – аның кызы Зөлфия белән бергә, театр училищесында укыдык. Әлфия апаның күңеле бик киң иде. Җәй җитеп каникуллар башланса, балалар йортында тәрбияләнүче ятим туганнарының балалары да аларда торыр иде. Ятимнәр йортыннан аларга бет ияреп кайтып, барыбыз бетләп тә беттек, аны дуст белән, керосин белән агулап, ничек чәчсез калмаганбыз. Күрде инде башлар, ә Әлфия апа ничек чыдады икән бу хәлләргә? Ничә баш кешене туйдырырга да кирәк, ижат белән дә шөгыльләнәсе. Хәзер шуны уйлыйм да исем китә, без бит ул ва-

кытта – яшь, акыл кермәгән кыз балалар. Үзләреннән башка, өч бүлмәле фатирда тагын 8 кеше мәш килдек. Ул беребезгә дә караңгы чырай күрсәтмәде. Өйдә торганда Әлфия апа гел безгә пәрәмәчләр пешерә торган иде, олы табакка өеп куя да, безне өстәл янына утыртып, кыстый-кыстый ашата. Әй, тәмле дә була торган иде ул пешергән ризыклар. Берсендә Актаныштан боты белән ит алып кайткан иде, аны үзе чапты. Тагын өч литрлы карабодай балы алып кайтканы исемдә. Банкасын 1 сум 20 тиенгә алдым дигән иде ул миңа, бик тә исемдә калган шул сүзе. Аның юмартлыгына ис-акыл китәрлек иде. Тагын ул ит белән балдан әле сеңелләренә, туганнарына өлеш чыгара торган иде. Ул гынамы: он, шикәр комы, ярма, ак май һәм тагын башка үзендә булган нигъмәтләрне туганнарыннан һич кызганмады. Ул эш эшләгәндә йөгерә-йөгерә, җырлый-җырлый эшли иде, бик күңелле яшәдек. Яңа ел җитә башласа, бөтен эшне куеп, иттарткычтан ит чыгарып, күп итеп пилмән ясап куя торган идек. Шулай итеп театр училищесын әйбәт кенә тәмамладым, мине филармониягә эшкә билгеләделәр. Иң элек – Илһам Шакиров төркемендә, аннары Зиннур Нурмөхәммәтов белән эшләргә туры килде. Соңыннан Зөһрә Сәхәбиева килде һәм мине аның төркеменә күчерделәр. Аннары инде Әлфия апа мине үз төркеменә алды. Ул безнең һәрберебезне шулкадәр якын күрде. Авылларга концертлар белән барсак, колхоз рәисләре белән сөйләшеп, безгә тана ите кирәк дип, итен, онын, ярмаларын дисеңме, барысын да яздырып, сатып ала да, алтыбызга да тигез итеп бүлеп бирә. Әле бүлгәндә миңа, сеңелкәш, бас артың белән, бу кисәге кемгә, менә бусы кемгә, дип әйттерә дә, нәкъ мин әйткән кешегә итне тоттыра. Әле шул вакытта Әлфия апа биргән карабодай ярмасын һаман да ашыйбыз, бозылмый икән ул. Шөкер, оннарыбыз капчык белән торды, тамак тук булгач, күңелләр дә күтәренке иде. Шулай бервакыт Азнакайдан кайтып барабыз, һәрберебездә капчык белән 45әр килограмм яңа суйган тана ите, башка колхоз председателе белән дә сөйләшкән булган, безгә ит сатып алырга дип. Берзаман җырчы Рөстәм Маликов миңа: «Әй, Әлифә, син ялгыз башың бала үстерәсең, бәлки, синең теләкләрең кабул булыр. Бу бүген без барасы колхоз рәисе урынында булмаса гына ярар иде, ул да ит бирсә, аны кайларга куярбыз», – дип көлә. Бәхетебезгә, ул көнне колхоз председателе, чыннан да, урынында булмады. Безнең автобус тәгәрмәчләре болай да шартларлык булып кайта бит инде: алтыбызга – алты капчык югары сортлы ак он, яртышар капчык арыш оны, 45 килограмм ит! Берсендә Азнакайга концерт куярга барабыз, автобус бирделәр, ә бензин юк. «Ярар, борчылмагыз, үзем сөйләшермен заправкадагы кешеләр белән», – ди Әлфия апа. Хактан да, очраган бер заправкага кереп тәмле теле белән сөйләшкәннән соң, Әлфия апаны танып, һушлары китеп, бер генә җыр җырла дип, һәрбер очраган заправкада 20шәр литр бензин салдылар. Ул бензин безгә кире Казанга кайтып җитәргә дә җитте. Ә берсендә берничә кәттә егет Әлфия апаны танып, килеп эндәште дә: «Әлфия ханым, без Петровский спиртзаводында эшлибез, хәзер Сезгә менә дигән чиста аракы алып киләбез», –

дип, ике тартма аракы китереп бирде. Әлфия апа бер дә аптырап калмады, аны да, һәммәбезгә тигез итеп, бәйрәмнәрдә кирәге чыгар әле, дип, таратты да бетерде.

Үзгәртеп кору еллары, 90 нчы еллар филармония тормышына да күп үзгәрешләр кертте. Мәдәният министрлыгында эшләүчеләрнең 30 процентын кыскартырга, дигән карар тоттыралар. Әлбәттә инде, бу кыскартуларга артистлар да эләгә. Эшсез калудан курыккан артистлар, җырчылар, музыкантлар арасында кемне кыскартырлар дип күңел төшенкелеге башланды. Әлфия апа шул чагында да үзенең төркемендәге бер кешене дә кыскартуга эләктермәде. Әгәр дә минем төркемдәге берәр кеше эшсез кала икән, мин дә китәм, дип министрлыкка кергән. Менә шулай һәрвакыт безнең өчен үзен аямый, гел яклап, әниебез кебек кайгыртып яшәде ул.

1994 елның сентябрь ахырында көтмәгәндә ирем Фәрит Бәдретдинов мәңгелеккә күзләрен йомды. Ул Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә баянчы иде. Шул авыр көннәремдә дә Әлфия апа, аның кызлары гел янәшәмдә булдылар. Күпме теләсәк тә, безнең балабыз булмады. Ирем үлеп берничә ай узуга, мин үземнең организмда ниндидер гажәеп үзгәрешләр сизә башладым. Эчем дә зурайган сыман, мин әйтәм, берәр суалчан йөри микән әллә соң эчемдә, дим. Бу сәер хәл турында Әлфия апага да, аның кызларына да әйттем. Алар миңа хатын-кыз табибына күренергә куштылар. Барсам, ни гажәп: мин иремнән авырга узып калган булганмын. Күпме бәби көтеп, эти буласын да белми үлеп киткән мәрхүмкәем-иремне кызганырга да, үземне жәлләргә дә, бала турында уйларга да белмим. Сөенеч булырга тиешле вакыйга, көенечкә әйләнде. Ходайдан күпме ялварып көткән баланы да юк итәсе килми, тапкан очракта берьялгызым ничекләр үстерермен, дип кайгырам. Әлфия апаның кызы Зөлфиянең Мәскәүдә яшәгән вакыты. Ул мине профессорга күрсәтәм дип, Мәскәүгә чакырды. Әлфия апаның Кипрга – балаларына барасы бар иде, ул мине Мәскәүдә калдырып, Кипрга китте. Профессор тикшерде, йөклелек әйбәт уза, дип юатты һәм бары тик кесарево белән генә табарга киңәш итте. Бик тә кайгырдым, борчылдым, еладым. Миңа кушылып, Әлфия апа белән кызы Зөлфия дә елыйлар. Шунда миңа Әлфия апа: «Әлифә, кайгырма, үзем булышырмын, һәр бала үз бәхете белән туа», – дип, мине юатып, җылы кочагына алды. Улым Аязның бер яше тулгач, 20 концертлы гастрольгә чыгып киттем. Өч яше тулгач, без инде Аязым белән 90шар концертлы озын юлларга чыгып китә торган идек. Кайда булсак та, Әлфия апа Аязымны гел карашты, тамагына ашатты, үстереште.

Кызыклы вакыйгалар искә төшеп кенә тора. Бервакыт Башкортстанга баргач, фатирга кердек. Минем кесәдән 200 сум акча югалды. Әлфия апага әйтергә куркам. Әмма бу сер барыбер аңа килеп ирешкән һәм ул акча югалганлыгы турында милициягә гариза язган. Шул минутта бер малайны тотып алып килделәр, ул урлаган акчасын сарыф итеп бетергән булып чыкты. Икенче көнне авыл Советы аша миңа ул малайның әбисеннән алып,

200 сумны кулыма тоттырдылар. Теге карак малайга Әлфия апа берне менеп тә төште. Әлфия апа бер дә караклыкны, урлашуны сөймми торган иде. Ул һәрвакыт, карак димәсеннәр, дөреслек белән яшәргә кирәк, кеше хакына кермәгез, ди торган иде.

Әлфия апа гомер-гомергә мине үз кызы кебек кайгыртып яшәде. Мин тулай тораКта яшәгәнлектән, аның моңа бик тә эче пошa иде. Ул мине фатирлы итәр өчен филармония җитәкчелегенә кереп, тулай тораКтан бер бүлмә алып бирде. Анда хәйран гына яшәгәч, «Әлифә, син гомер буе тулай тораКта яши алмыйсың бит инде?» – дип, тагын җитәкчеләр тупсасын таптый башлады. Җайлы торак булмаганлыктан, ялгыз Мәрхәбә әбигә: «Менә бу бала сине карар соңгы көнеңәчә, син аңа васыять яз», – дип, үзе минем урында антлар итеп, шул көннән мин Мәрхәбә әбиләрдә тора башладым. Әбиеңне дә, бәбиеңне дә карыйсың бар, акча кирәк, әйдә гастрольгә дип, минем арттан өйгә автобус китертеп, үзе белән юлга алып чыгып китәр иде. Элек телефоннар сирәк кешедә, мин ераКта чаКта әбиемнең хәлен дә, улымның хәлен дә сораша алмыйм. Бу очраКта да Әлфия апам ярдәм итте. Ул чаКта телефон кертер өчен алтышар ел чират торалар иде. Әлфия апа «Таттелеком» җитәкчесенә барып шушы гозерне әйтүгә, икенче көнне үк килеп безгә телефон керттеләр. Сүзебездә тордык, Мәрхәбә әбине карап, тәрбияләп, соңгы юлга зурлап озаттык. Гомумән, Әлфия апа да, кызлары да мине бик тә якын күрде. 2007 елда әниемне соңгы юлга озатканда да алар, бөтен эшне ерып, авыр минутымда зур терәк, таяныч булдылар.

Үзе кебек, кызлары да бик тә юмарт, кешелекле булып үстеләр. Кызлары Зөлфия Мәскәүдә яшәгәндә, без Мәскәү аша кайда гына барсак та, аларда тукталдык. Килеп керүгә, берәр камыр ризыгы пешерә башларлар иде. Әлфия апа, һәрвакыттагыча, камырны үзе ясый. «Кайчан камыр кулыгызга ябышмый башлый, шунда гына ризыгыгыз уңар», – ди торган иде ул безгә. Камыр пешергәндә эчлегенә салган ризыкны мулдан тондырыр, шуңа аның пәрәмәчләре телне йотардай тәмле булыр иде. Аның синеке, минеке, дигәне беркайчан да булмады. Аның юмартлыгына, күңеленең киңлегенә соклана торган идек. Ул шушы юмартлыгы белән дә оҗмах түрләренә керер дип уйлыйм.

Мин – бик тә бәхетле ханым, чөнки минем бөтен тормыш юлым, хезмәт эшчәнлегемнең күп еллары аңа бәйле. Шушы данлыклы төркемдә хезмәт куюымны хөкүмәтебез дә югары бәяләде. Мин – бүгенгесе көндә «Хезмәт ветераны» медале иясе. Моңа кадәр күкрәгемә «Казан шәһәренең 1000 еллыгы истәлегенә» медален тактылар.

Җырдагыча, «бергә чаклар бик күңелле, әмма аерылулар бик яман...» «Чыннан да, Әлфия апабыз соңгы инсультыннан соң аякка баса алмады. Кызлары, яныннан бер минут китмичә, аны чиратлап карадылар. Мин дә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырыштым. Аның ихтыяр көченә, авырлыкларга, сызлануларга түзүенә исләрем китә торган иде. Алай гына да түгел, хәле булмаса да, безне күрүгә елмая, «Картаямыни соң йөрәк?»не җырлый башлый. Куллар-

дан тотса, җибәрми, анысы инде мине үз кызыдай якын күрүе иде... Башкаларга җырчы Әлфия апа булса, минем өчен ул әни дә, дус та, сердәш тә, хезмәттәш тә, кирәк чакта, әрләп атучы «Туры Тукаем» да булды. Мине шундый бөек шәхес белән бер юлдан йөрткәненә язмышыма мең рәхмәтлемен! Инде хәзер Әлфия апабызның каберенә барып чәчәкләр куеп, аның белән серләшергә генә калды. Иманым камил: күкләрдән дә безгә ярдәм итеп торадыр ул.

Әскәр АВЗАЛОВ,
Әлфия Авзалованың оныгы



Әбием турындагы хатирәләр – минем күңелдәге иң якты, иң кадерле истәлек. Ул – минем өчен яшәү үрнәге. Аның күңел матурлыгы, ихтыяр көче минем өчен тормыш маягы. Ул башкарган җырлар бүген дә актуаль, аларда бетмәс-төкәнмәс моң, үлемсез сөю, мәхәббәт яшерелгән. Безне әбием белән бик күп кызыклы вакыйгалар, тормыш мизгелләре бәйли. Бүген шуларның кайберләре турында сөйләп китәм:

– Иң истә калган, күңелле хәлләр, әлбәттә инде, туган җире Актанышка бәйле. Ул аны, яратып, «Татар Швейцариясе» дип атый, мине җәйге каникуллар вакытында еш кына үзе белән Актанышка алып китә иде. Бернинди дә җиңел машинада йөрү юк, һәрвакыт халык күп йөри торган пассажир автобусларында барабыз. Ул бик тә аралашучан, кызык, җор сүзле кеше иде. Әбием юл буе янәшәдә утырган юлчылар белән гәп кора, мин автобус тәрәзәсеннән табигать матурлыгына сокланып барам. Чыннан да, бик тә матур ул якның табигате. Табигате генә түгел, кешеләре дә ачык, киң күңелле, зыялы, гади, кунакчыл, эчкерсез. Нәкъ менә әбием кебекләр! Без анда үзебезнең гаилә дусларыбызда туктала идек. Барып кереп, коймак белән мәтрүшкәле хуш исле чәй эчүгә, табигать кочагына – болынга чыгып китәбез. Һәрбер агачка эндәшеп, кошлар белән серләшеп йөргәннән соң, әбием җыр сузып җибәрә. Бу минутта кошлар да тынып калгандай була. Ул бигрәк тә туган ягында – «Туган авылым» дигән җырны җырларга яратты. Аның тавышында сабый күңеленә дә үтәрлек сагыну, сагыш сизелә иде. Шулай, өйгә кайтып кергәнче, җырлап кайтабыз. Аның моңын ишетеп, капка төбенә күрше-күлән җыела, күңелле очрашу урам бәйрәменә әверелә.

Әбием белән барча темага да иркенләп сөйләшеп була иде. Ул спортны да үз итте. 2002 нче елда без аның белән футбол буенча Дөнья Чемпионатының

бөтен матчларын карап бардык. Гади тамашачы гына түгел, Россия җыелма командасының җанатары идек.

Актанышның данлыклы Сабантуйларының берсе дә әбиемнең матур җырларыннан башка узмады. Әлбәттә инде, бу мизгел-балкыштан халык туймый кала иде. Сабантуйдагы бар халык кубарылып кул чаба, һәркемнең әбием белән фотога төшәсе, сөйләшәсе-аралашасы килә. Бу минутларда мин: «Ярый әле, бу бәхет безгә мәңгелеккә», – дип уйлый идем.

Әйткәнемчә, әбиемнең дус-ишләре ил буйлап таралган. Шуларның берсе – Яр Чаллы каласында гомер кичерүче Гөлчирә апа. Алар бик озак еллар чып-чын ахирәтләр булып аралашып яшәде. Шулай бервакыт, кичен Гөлчирә апаларда без шахмат уйнаганда, телевизордан «Йолдызлар фабрикасы-2» башланды. Әбием кызыклы уеныбыздан бүленеп, бирелеп-бирелеп яшь талантларны, рус эстрада җырларын тыңларга кереште. Алай гына да түгел, ул әле чит ил эстрада җырларын тыңларга да вакыт тапты, чөнки аның җыр дөньясы, сәнгать дөньясы белән кызыксынуы көчле иде.

2015 нче елның 12 нче сентябрендә сөеклем Эльза Илдаровна белән кызыл туебыз булды. Ни кызганыч, әбиебез туйга килә алмады. Үзебез аның янына бардык. Аның күзләрендәге сөенечне әйтеп-аңлатып бетерерлек түгел иде. Ул безнең белән фотосурәтләргә төште, туй киемнәребезгә сокланды, мин сайлаган парны – Эльзамны мактап туялмады. Үзе дә сизмәстән, матур яшьлегенә кайтып, анда булган матур истәлекләрне хәтеренә алды, кызып-кызып безгә сөйләде. Минемчә, яраткан әби генә балаларын, хәле булмаса да көлеп, колач җәеп шулай каршы ала.

Әбием үзе уен-көлкене ярата, аңлый торган кеше булгач, миңа икеләтә рәхәт иде.

Мин еш кына телефоннан тавышымны үзгәртеп, Мәдәният министрлыгыннан, яки «Продюсерлык үзәге»ннән дип таныштырып, аны төрле фестивальләргә чыгыш ясарга чакыра идем. Баштарак әбием танымыйча, ышанып сөйләшсә, соңга таба минем күңел булсын дип, шаяртып, белмәмешкә сабышып сөйләшә башлады. Соңыннан без икебез дә рәхәтләнеп көлешә торган идек.

Бервакыт без йөк машинасына утырып, иртәнге өчтән әбием белән бик ерак бер авылга мунча бурасы алырга бардык. Юл буена әбием шофер йоклап китмәсен дип, сөйләшә дә сөйләшә. Ничек барып җиткәнебезне сизми дә калдык. Уен-көлке, шаян сүз белән юл газабын сиздермәде безгә җор телле әбием.

Шәһәр читендәге бакча йортын җиткергәнче, без анда баргач, мунчада яши идек. Төнлә коп-коры агач идәнгә ятабыз. Әбием: «Каты агач сәкедән дә рәхәт урын юк», – ди торган иде. Йоклар алдыннан колакларга мамык шарлары тыктыра, анысы колакка төрле бөҗәкләр кермәсен өчен дип аңлата иде.

Колледжны тәмамлап диплом алган көнне әбиемнең килүе – минем өчен өстәп тагын бер алтын медаль алуга тиң булды. Мәңге исемдә калды.

Мин аңа барысы өчен дә мең рәхмәтле!

Әсхәт САФИН,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре,
2003-2007 елларда Татар дәүләт
филармониясенең җитәкчесе



Моң алиһәсе иде

Мин Татар дәүләт филармониясендә озак елдар эшләдем. Минем төп һөнәрем – биюче. Бәхетемә, хезмәт юлымның соңгы биш елында миңа Әлфия Авзалова төркемендә эшләргә туры килде. Бу минем күптәнге хыялым иде. Әлфия апа мине үз бригадасына биюче итеп эшкә чакырды, мин шатланып риза булдым. Шул ук вакытта ул миңа ышанып администраторлык эшен дә тапшырды. Бу биш елда без кайда гына булмадык, бик күп гастрольләрдә булып, исәпсез-хисапсыз күп концертлар бирдек. Безнең уңышларның барысы да Әлфия апаның оештыру сәләте, үҗәтлеге, максатчанлыгы, тырышлыгы нәтиҗәсе иде. Татарстанда гына түгел, Рәсәйнең төрле төбәкләрендә, алай гына да түгел, бөтен союздаш республикаларда аның иҗатын беләләр, таныйлар, яраталар, бөтен җиргә чакыралар иде.

Гастрольләрне без алдан ук планлаштыра торган идек: Татарстан һәм тугандаш Башкортстан Республикаларында – ямьле җәй айларында, чөнки авыл юлларында җәй көне йөрү күпкә уңайлы, Рәсәй шәһәрләренә – беренче кварталда, союздаш республикаларга өченче кварталда чыгып китәбез. Без ел да май урталарында китеп, өчәр ай дәвамында, үзебезнең Татарстан һәм күрше Башкортстан төбәкләрен аркылы-торкылы йөрдек. Рәсәй һәм союздаш республикалардагы гастрольләрне без, алдан телеграмма сугу юлы белән, «Росконцерт» һәм «Союзконцерт» дигән оешмалар аша эшли идек. Шул оешмаларга: «Без – фәлән кешелек җырчы Әлфия Авзалова төркеме артистлары – Сезгә фәлән числода концерт белән килергә уйлыйбыз. Билет бәясе – фәлән сум» дигән эчтәлектәге телеграмма сугып, алардан җавап көтәбез. Сезнең килүегезне хуплыйбыз дигән телеграмма алгач, бер ун заявка җыелгач кына юлга кузгалабыз. Шулай алдан хәбәрләшеп эшләү бик тә нәтиҗәле була торган иде. Без килгәндә инде кассада билетлар сатылып бетә, зал тулы тамашачы була. Әмма филармониядә эшләүче бөтен артистларга да чират торып билет алмыйлар, күп артистлар концертлар кую планын үти алмый. Филармониянең җитәкчелеге үзенә бирелгән гомуми планны үтәтер өчен, безнең бригадага тагын өстәмә концертлар куярга дигән тәкъдим белән чыга. Әйтик, без елына план буенча 187 концерт бирергә тиеш булсак, без аны 260-270 итеп, һәр елны арттырып үти торган идек.

Күп вакытта, сораулар буенча, өстәмә концертлар куярга да туры килә. Ул көнне бер чыгыш – көндез, икенчесе кич була. Иртәгесе көнгә безне та-

гын башка урында көтәләр. Менә шундый тыгыз график белән эшләдек. Әлфия Авзалова концертын һәркайда бишкуллап каршы алалар. Аның җырларын яратмаган, белмәгән төбәк юк иде. Ерак Тыва Республикасының Кызыл дигән шәһәрендә булган очрашу күңелләрдә тирән уелып калган. Безне анда бик тә җылы каршы алдылар, зурлап кунак иттеләр. Без инде бу төбәктә татарлар юктыр, дип уйлаган идек, бик күп булмаса да, бар икән. Әмма монда яши торган башка милләт халкы да Әлфия апаның җырларын бик яратып тыңлады, чиксез рәхмәтләрен яудырды. Союздаш республикаларга гастрольләргә чыкканда да алдан маршрут таныклыгы төзеп, һәрвакыт алар белән хәбәрләшеп эшләдек. Урта Азия илләренә – Үзбәкстан, Таҗикстан, Казахстанга, әйткәнемчә, без өченче кварталда – һәрберсендә айлап-айлап йөреп кайта торган идек. План буенча без башта айга 19 концерт бирергә тиеш булсак, соңыннан аны унҗидегә калдырдылар.

Әлфия апаның ижатына килсәк, ул тамашачысын бик яратты, чыгышларына, репертуарына бик җаваплы карады, һәрвакыт программага нинди булса да яңалык кертергә тырышты. Концерт башланыр алдыннан бик озак ымлап, тавышын көйләп йөри, аякларын тыпырдатып төрле бию хәрәкәтләре ясый. Ул сәхнәгә чыккач, бөтенләй башка кешегә – моң алиһәсенә әверелә, хәтта күз алдында үсеп тә киткән кебек тоела. Ул сәхнә өчен туган кеше иде. Аның өчен сәхнә – тормыш мәгънәсе, яшәү кыйбласы. Әлфия апа тормышта да бик шаян кеше: кызык-кызык анекдотлар сөйләп көлдертә, күңелне күтәрә. Аның сөйләм осталыгына таң калып тыңлый торган идек.

Элек артистларның репертуарларын махсус комиссия тикшерде. Һәр биш ел саен тарификация үткәрде. Аның «отделение», «красная строка» дигән төшенчәле хезмәт хакын арттыру төрләре исемдә. Әлфия апа тарификациясен һәрвакыт уңышлы үтте, заманына күрә, хезмәт хакын азмы-күпме арттырып тордылар. Әмма хәзерге заман артистлары белән чагыштырганда, аларның акчасы тиен генә иде. Эш шартлары – җир белән күк аермасы. Юлсыз авылларга, юк машиналарны табып, аны ягулык белән тәэмин итү өчен акча юнәтергә, баруыңа салкын, ягылмаган клублар, куныр өчен фатирлар эзләү – барысы да төп җырчы – бригада җитәкчесе иңенә төшә иде. Нинди генә авырлыклар булмасын, Әлфия апа беркайчан да төшенкелеккә бирелмәде. Беркайчан да зарлануны белмәде ул, әйтелгән сәгатьтә тамашачысы каршына елмаеп-көлеп чыгып басар иде.

Безнең коллективтагы мохит һәрвакыт дуслыкка, бердәмлеккә, бер-беребезгә карата ярдәмчеллеккә юнәлтелде. Болар барысы да – җитәкчебез Әлфия апаның тәрбия нәтиҗәсе, без аннан бик күп яхшы сыйфатларга өйрәндек. Үзе белән җырлаучы артистларга һәрвакыт ярдәмчел булуы белән дә аерылып торды ул. Кемдер мине үтеп китмәсен, мин генә дигән масаю анда бөтенләй булмады. Аның бригадасында эшләгән баянчылар чын ижат мәктәбен уздылар. Һәрвакыт үзгәреп торган репертуарга ияреп бару җиңел булмаса да, алар тырыштылар, үзләре дә сизмәстән, дәрәҗәле, оста баянчыларга әверелделәр. Әлфия

апаны һәрвакыт татар җыр сәнгатенең киләчәге борчыды. Ул соңгы вакытта яшь җырчыларның фонограммага җырлауларын кабул итмәде. Бу хәл аның өчен бик тә сәер тоелды. Ике-өч сәгать буе тере тавышка җырлап, көненә әллә ничәшәр концерт биргән Әлфия апалары кебек җырласалар, алар нәрсә эшләр иде икән? Филармониядә җитәкчелек иткән ижат кешесе буларак, мин үзем дә бу турыда бик еш уйланам, борчылам. Әле дә ярый безнең яшь талантлар арасында оркестрга кушылып җырлаучы артистларыбыз бар. Оркестрга бит бары тик тере тавыш белән генә кушылырга мөмкин, менә бит хикмәт нәрсәдә?..

Элеккеге һәм хәзерге аппаратураларны чагыштырсаң да, исең китәрлек. Аларның яңгыраш сыйфаты, компактлылыгы хәзер бик күпкә яхшырак һәм сыйфатлырак. Элеккеге аппаратураларның чыбыклары бөтен сәхнәне биләп торыр иде, без бии башласак, ул чыбыкларны кая куярга белмичә аптырап бетә идек. Әлфия апа да җырлаганда бер кулы белән микрофон чыбыгын тотар, икенче кулы белән хисләнер иде. Хәзерге кебек ижат иркенлеге булмаса да, табигый таланты белән бөтен дөньяны әсир итте, моңнары белән дәвалады, татар җырын ерак-еракларга илтте ул. Үзенең хезмәт хакы акчасына аппаратуралар сатып алып, микрофоннарны кесәсендә генә кадерләп саклап йөртә торган иде. Чөнки шулай итмәгәндә, филармония бүлеп биргән акчага гына ижади үсеп, башкалардан аерылып ижат итеп булмаячагын бик яхшы аңлады ул.

Тагын Әлфия апаның бик тә яхшы сыйфатын – башкалар турында кайгыртуын бер дә оныта алмыйм. Элек кием-салым да, ашау-эчү дә дефицит булды. Артист халкына сәхнәгә матур өс киеме дә, аяк киеме дә кирәк булып тора. Әлфия апа барыбыз турында кайгыртып, складлардан безгә кием-салым, ашау-эчү юнәтте. Мин бик тә рәхмәтле аңа! Концертлардан соң бөтен бригада белән сыйлану матур бер гадәт иде, беркайчан да Әлфия апа, мин дәрәҗәле, зур артист дип, бездән башка гына, аерылып, кәеф-сафа корып йөрмәде. Бу кешелеклелек сыйфаты өчен без аны тагын да хөрмәт итә торган идек. Шуңа да безгә эш карышмады, тамак тук, өс бөтен, җитәкчебез ышыгында рәхәт итеп ижат иттек. Ул яхшылыгын кемгәдер ярар өчен түгел, күңел халәте кушуы буенча башкарды, без аның шулай икәнен сизә идек. Кемгәдер ниндидер яхшылык эшләсә, аның шундук кәефе күтәрелеп китә торган иде. Алар озак еллар сүз остасы Нажия Минкина белән бергә йөрделәр. Кайда булса да җәен су буена барсак, алар узыша-узыша кояшта кызына иде. Бик тә ахирәтләр иде алар икесе. Көннәр буе кояшта кызынып, җылы яктагы кебек тән каралтып, шаярышып, көлешеп йөрүләре әле дә истә. Анда кемдер балык тота, кемдер табигатькә карап хозурлана. Әлфия апаның кызлары да күп вакыт үзе белән бергә булды. Шулай итеп эш белән ялны күңелле итеп бәйләп алып барды Әлфия апабыз, барыбызны ял да иттерде, эшләтте дә, үкенечтә калдырмады. Аның белән эшләгән елларым – хезмәт юлымның иң матур, иң күңелле еллары. Язмышыма мең рәхмәтлемен, мине шундый бөек тә, гади дә Әлфия апа белән очраштырганы өчен!

Винера ГАНИЕВА,
җырчы, Татарстанның һәм
Россиянең халык артисты



Әлфия апа турында истәлекләр

Синдәй Әлфия апабыз
Юктыр ул җир йөзендә,
Сандугачлы чишмәләрең
Мәңге булыр күңелдә!
(Рамил Чурагулов)

Әлфия апаны, яшәде дип, элекке заманда сөйләү һич тә мөмкин түгел. Без аның китүен көтмәдек, ул мәңге безнең янда сайрап торыр кебек иде, шуңа күрә кабул да итә алмыйбыз. Мондый ихлас күңелле, тормышны яраткан моң чишмәләре мәңге дә кипмидер ул, киресенчә, аның агымы тагын да көчәеп, моңлырак, сагышлырак аһәңгә күчә, җир тамыры – чишмәләр аша киләчәккә юл аладыр. Бу милли моңнарда әле әллә ничә буын үсәр, киләчәк буын аның исемен йолдызларга кушар, диеп уйлыйм мин! Әлфия апа күңелдә искиткеч гади, халыкчан, кешелекле булып калды. Кечкенәдән күп авырлыклар күргән ятим кыз бала башыннан ниләр генә үтмәгән?! Шул тормыш авырлыклары аның күңеленә моң булып кереп урнашкандыр, кайгы-сагышларын җырлап үткәргәндер кебек, аның моң дөньясына чумсаң... Ятимлектә, артык кашык булып үссә дә гажәеп киң күңелле, кешелекле, ипле, тыйнак иде Әлфия апа. Аның тагын бер искиткеч сыйфаты булды – ул үзенең иҗатына галәмдәге миллионлаган кешене гашыйк итте. Аның тавышын тамашачы җырының беренче сүзеннән үк таный иде, чөнки табигате белән андый үзенчәлекле тембрлы, абертоннарга бай, түбән регистрлы җырчылар бик сирәк очрый, өстәвенә, сәхнәдә чын артистларга гына хас мөлаемлек, җылылык, шаянлык, актерлык осталыгына ия булды ул. Әлфия апа – минем тормышымда, иҗат юлымда зур урын алган бөек, онытылмас шәхесләрнең берсе. Аның белән булган матур истәлекләр күңелдән мәңге дә китмәс. Шуларның берсен, минем тормышымда бик тә борылыш ясаган бер вакыйга турында сөйләп үтәсем килә. Бервакыт ул мине – яңа гына консерватория тәмамлаган, сәхнәгә тәүге адымын ясаган, әле беркемгә дә билгеле булмаган яшь опера җырчысын – Мәскәүгә юбилей концертында чыгыш ясарга алып китте. Ул минем өчен көтелмәгән вакыйга, тормышымда иң зур сынауларның берсе булды, дисәм, һич тә арттыру булмас. Ул чактагы дулкынлануымны, баштан узган кичерешләремне бүген искә алсам да, гажәпкә


калам. Мәскәүдәге «Россия» концертлар залында алма төшәр урын да юк, халык Әлфия апаны аягүрә басып каршы алды, чәчәкләргә, мактауларга, алкышларга күмде. Бу кадәр тамашачы мәхәббәтен яулаган, югары биеклектәге артист белән бер сәхнәдә басып тору минем өчен әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык бәхет иде. Шул вакытта мин халык мәхәббәтен яулау өчен никадәр ихтыяр көче, тырышлык, үз эшеңә бирелгәнлек кирәклеген аңладым. Иҗатымның башында Әлфия апа минем сәхнәдәге һәрбер хәрәкәтемне, кичерешләремне күзәтеп, барлап, нәтиҗә ясый торган булды. Ул еш кына кулларын өскә күтәреп, күзләрен күккә төбәп, куллары белән кош канат кагынган хәрәкәтләр ясап, мин булып күрсәтә, бирелеп, җырны күңел аша үткәреп җырлавымны мактый иде. Ул бигрәк тә минем репертуарымдагы «Киек казлар» җырын мөкиббән китеп тыңлый торган иде. Күрәсең, мин шул концерттан соң Әлфия апаның ышанычын аклаганмын, мине юбилейларга, төрле кичәләргә, концертларга, Сабантуйларга, республикакүләм һәм районара чараларга еш чакыра башладылар. Без остазым Әлфия апа белән озын җырлы юллар урадык, күп чакрымнар уздык, шатлыгы да, сагыш-борчулары да бергә булды.

Мин, Әлфия апаны уникаль җырчы дип атар идем, чөнки аның иҗат диапозоны бик тә киң һәм гаҗәеп үзенчәлекле. Ул тирән мәгънәле, озын халык җырларын да, эстрада, һәвәскәр композиторларның әсәрләрен дә, чит ил җырларын да югары дәрәҗәдә башкара алучы бердәнбер һәм беренче артистка! Ул татар җыр сәнгатенә тәүге үзгәреш җиле алып килгән бөек җырчы, беренче карлыгач! Эстрада җырларына килгәндә, ул беренче булып җыр сөючеләргә татар җырларын яңа стильдә, өр-яңа форматта тәкъдим итте, татар эстрадасы тарихында беренче адымнар ясаган шәхес. Шуңа да ул өлкән яшьтәгеләрне дә, үсмерләрне дә, урта яшьтәгеләрне дә үзенең кызыклы моң дөньясында яшәтә алды. Җырчы булды, дип әйтергә тел әйләнми, ул сәхнәдә яшәде, аның бөтен тормыш, яшәеш мәгънәсе шул җырларда иде. Сәхнәгә чыгуга, аның йөзе кояшка әверелә, ул яшәреп китә, җанлана, моң дәрьясенә кереп чума. Үз тамашачысының сулышын тоя, аңлый, ярата, аның уйларын укый белү сәләте бар иде Әлфия апабызда. Заманына карап, репертуарын да дөрес, кызыклы, көнкадак темаларга бай итеп сайлый белә иде ул. Әлфия апа татар сәнгатен, татар телен җырлары белән, хезмәте белән мәңгеләштерде, татар җыр сәнгатенә нигез салучыларның берсе булды. Ул – безнең барыбызга да иҗат үрнәге, яшәү өлгесе булып тора!

Минем өчен тагын бер якын ягы бар Әлфия апаның. Алар – минем каенанам белән якташлар – Актаныш ягыннан, ямьле Ык буйларында бергә үскәннәр, сәхнәгә тәүге адымнарын ясаганнар, бергә уйнаганнар, бергә җырлап йөргәннәр. Ул, кайвакытта ачылып китеп, теләр-теләмәс кенә шул балачак, сугыш чоры, авыр еллары турында сөйли торган иде. Ул чакта аның йөзләре кинәт моңсулана, күзләрен сагыш-моң баса, бу теманың аның өчен йөрәк ярасы икәнлеген аңлап, мин сүзне башка якка таба бора торган идем.

Җырларының шулкадәр моңлы, тирән, ихлас яңгыравы, халык күңелен айкавы да аның тормышының борылмалы, сикәлтәле булуы турында сөйлидер кебек. Гади тормышта да искиткеч соклангыч, үзенә тартып тора торган, шат күңелле, шаян, ачык йөзле ханым иде ул – Әлфия апа. Тормышны, кешеләрне, милләтен, халкын яратты! Алыштыргысыз моң иясе, сайрар сандугачы – Әлфия Авзалованы халык яратты, ә ул соңгы көненә хәтле яраткан халкына хезмәт итте. Бер кеше гомере кадәр сәхнәдә торып та, сәнгатьтән, җыр-моңнан туймады ул. Өлкән яшьтә дә, сәхнәгә менсә, аның күзләрендә очкын кабынып китә торган иде. Мәңге картаюны белмәс яшь күңелле Әлфия апаның «Картаямыни соң йөрәк?» дигән җыры инде күптән өлкән буыннар гимнына әверелде. Элек бит, хәзерге кебек, җылы машиналарда йөрү булмаган, кышкы суыкларда, ат арбаларына утырып барып, авылдан-авылга концерт куйганнар ул чор артистлары. Әле дә чыдам булганнар инде! Соңгы көнгә кадәр диярлек сәхнәгә чыгып, яраткан тамашачысына моңлы җырларын бүләк итте бөек талант иясе. Кызлары белән дә гел аралашып яшим, Әлфия апаны еш сагынып искә алабыз. Зөлфиясе бигрәкләр дә әнисенә охшаган, карап торам да, гел Әлфия апа белән сөйләшкән кебек булам. Әлфия апаның бер генә җыры да халык күңеленнән сызыла, онытыла торган түгел, алар – мәңгелек! Аның җырларын, Әлфия апаның үзе кебек дәртләнеп, халык күңелен уятырлык итеп берәү дә башкара алмый. Милләтебезнең җәүһәре, йөзек кашы, кабатланмас моң иясе Әлфия апабызның җырлары, моңнары әле безне кабат-кабат үзләренә гашыйк итәр, ул, җырлары белән, безнең арабызда мәңге яшәр!

Вәсим ВАХИТОВ,
Казандагы Актаныш якташлар
җәмгыяте рәисе



1994 елның 10 июле көнне Актаныш районы Сабантуена без – якташлар, төрле яклардан кайттык. Башта безне Ык елгасы буенда (администрация башлыгы Таһир Әхмәев иде) зурлап каршыладылар. Кунаклар шактый күп иде, яр буенда матур концерт булды. Әлфия апаның матур җырлаганын барыбыз да яхшы белә, ә менә аның шундый затлы итеп, күлмәк итәген биленә кыстырып биюе бик тә истә калган. Ул бар якка да оста иде: сүз сөйләргә дә, биергә дә, бигрәк тә матур итеп, моңлы итеп җырларга аңа тиңнәр юк иде. Ул чорда, моннан 25 елга якын элек, видеокамералар да юк әле, шулай да бер өйрәнчек малай шул Ык буенда булган очрашуда азмаз төшергән язма сакланган. Гомумән, без аны якташлар очрашуына чакыра идек, ул аларда бик теләп катнашты.

Икенче бер вакыйга. 2000 еллар башы. Актаныш якташлар җәмгыяте Кәрим Тинчурин театрында зур очрашу оештырды, концерт булды. Әлфия апаны квартирасыннан барып алдык. Билгеле, аның җырлавын халык бик тә көтеп тора, зал шыгрым тулы. Программада Актаныш районыннан чыккан талантлы җырчылар барысы да бар иде. «Сәхнәдә Әлфия Авзалова җырлый», – дип игълан итүгә, халык басып, кул чабып каршы алды. Шунысы кызык: җырлары арасында ул кайларда гастрольләрдә булганын, андагы әкәмәтләрне сөйләп, халыкны бик тә рәхәтләнеп көлдергән иде. Концерт беткәч, аны квартирына озатып кую насыйп булды. Машинада барган чакта, авылдан авылга концерт куеп йөргәндә булган мәзәкләрне сөйләп көлдергән иде.

– Шулай бер авылда, концерттан соң кунарга калгач, бер әбигә фатирга керттеләр. Чиста, пөхтә өй, бер бүлмәле. Чәй эчеп йокларга яткач, инде йокыга киткән идем, аягымны кемдер тешләп алды, куркудан кычкырып җибәрдем. «Кем бар анда, нишлисез? – дип, әби дә сикереп торды. – И, Әлфия кызым, әйтергә онытканмын: синең карават астында ана каз йомыркага утырган иде, бәбкә чыгарырга. Күрәсең, аягың азрак читкә төшкәндер, ул бит синең атказанган җырчы икәнеңне белми», – дип көлде. Инде яңадан курка-курка гына яттым, урамда йоклап булмый бит инде, – дип сөйләгәне әле кичә генә булган кебек.

Менә шундый шартларда: авылдан авылга – ат арбасында, кышын чанада, ягылмаган салкын клубларда микрофонсыз җырлауларын сөйләгән иде ул.

Владимир ЛАПШИН,
тавыш режиссеры



Олы йөрәкле артист

1968 елларда Казанның М. Горький исемендәге Үзәк паркында җәйге бию мәйданчыклары эшли иде. Мин шунда үземнең «Меломаны» дип аталган инструменталь ансамблемне оештырып җибәрдем. Бу яраткан эшемне башлар өчен бөтен инструментларны үземнең акчама Мәскәүнең «барахолка» базарыннан алып кайттым. 3-4 сезон шулай яшьләрне биетеп, күңел ачтырганнан соң, 1972 елда минем яныма танылган җырчы, Татар дәүләт филармониясе солисты Әлфия Авзалова төркемендә гитарада уйнаучы музыкант Кәрим Габидуллин килде. Без – Казан музыкантлары, бер-беребезне күреп, ишетеп белә идек инде. Ул миңа: «Туймадыңмы әле урамда кеше биетеп, әйдә, безнең төркемгә, мин бик талантлы җырчы Әлфия Авзалова белән эшлим», – дигән тәкъдим ясады.

Ул вакытта инструментларга кытлык вакыт, мин төркемгә бөтен инструментларым белән килеп кердем һәм җиң сызганып эшкә алындым. Бөтен колонкаларымны, аппаратурамны филармониягә күчереп, ныклап эшли башладык. Беренче гастрольләребез күрше Башкортстан Республикасында булды. Аннары Әлфия ханым безгә: «Дусларым, безне гомеребездә беренче тапкыр Урта Азия илләре буйлап дүрт айлык гастрольләр көтә, зур әзерлек белән, февраль аенда юлга кузгалабыз, – диде. Без, чыннан да, ул елны февраль аеннан – июнь аена кадәр, җылы якта гастрольләрдә йөреп кайттык. Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Казахстан авыл һәм калаларында көнгә әллә ничәшәр тапкыр күпсанлы концертлар бирдек, һәркайда Әлфия Авзалованың чыгышын алкышларга күмделәр. Алма-Ата, Дүшәнбе, Ташкент, Бохара, Сәмәрканд, Астана кебек зур шәһәрләрдә, халык соравы буенча, өстәмә концертлар куйдык.

Минем өчен бу шулкадәр көтелмәгән хәл булды, мин гомеремдә беренче тапкыр дөнья күреп, төрле җирләр гизеп кайттым. Ижат юлымның болай кискен борылышы минем өчен зур бәхет иде. Әлфия ханымның кешелеклелеге, гадилеге хакына безнең музыкантлар ихлас күңелдән эшләделәр. Бер генә кеше дә коллективтан аерылмады. Мин бу яраткан хезмәтемә барлыгы 32 ел гомеремне багышладым, шуның якынча биш елы – Әлфия ханым төркемендә. Аның белән эшләгән елларны гел сагынып искә алам. Элек бит чит җирләр белән аралашу бик җиңелдән булмады. Әлфия ханым исә, эшне шулкадәр оешкан төстә алып барды: без Урта Азиянең кайсы гына почмагына бармыйк – аншлаг; афишалар куелган, билетлар сатылып беткән, зал тулы халык иде. Ташкентта гына 30 мәртәбә булырга туры

килгәндер, эш графигыбыз шулай бик тыгыз булды. Командировкадан эшләп кайткач, безгә 10 көн ял бирәләр иде. Әмма филармониягә килеп керер хәл юк, берәр төркем тагын сиңа эш тәкъдим итә, каршы килә алмыйча, тагын чыгып китәсең. Артист тормышы – чегән тормышы белән бер, дип тикмәгә әйтмиләр инде. Миңа татар эстрадасының данлыклы җырчылары – Зиннур Нурмөхәммәтов, Габдулла Рәхимкулов, Вафирә Гыйззәтуллина кебек зур шәхесләр белән дә эшләү бәхете тиде. Безгә илнең бөтен географик картасын йөреп чыгарга туры килде, дисәк тә ялган булмас. Санкт-Петербург, Мәскәү, Балтыйк буе илләре дә татар кызы Әлфия Авзалованы бишкуллап көтеп тора иде. Балтыйк буе илләрендә үзебезнең татар диаспораларының да татар җыр-моң сәнгатенә игътибары зур булды. Андагы тамашачыларның Әлфия апаны ничек алкышларга, чәчәкләргә күмгәне әле дә истә. Алар концерт тәмамлангач та, таралмыйча, аягүрә торып басып, Әлфия ханымны алкышлый, хөрмәтли иде. Шулай итеп артистның бөтен тормышы тәгәрмәч өстендә үтә, әмма бер кешенең дә зарланганын ишетмәдем. Әлфия Авзалова үзенә дә, кешеләргә дә бик таләпчән иде. Шул ук вакытта әниләрчә юмарт, ул пешергән пәрәмәчләрне ашап туеп булмый иде.

Бервакыт без Ижевскида гастрольләрдә чакта Михаил Боярский белән очраштык. Аның белән бер кунакханәдә яшәдек, бер мәйданчыкта чыгыш ясадык. Ул бик тә аралашырга ярата торган кеше булып чыкты. Без яши торган кунакханә янында көнкүреш әйберләре сата торган кибет бар иде. Кайтыр көн килеп җиткәч, өйгә берәр нәрсә алырга дип, кибеткә кердем. Михаил Боярский да шунда, әллә олысын, әллә кечерәген алырга икеләнеп, төчеләнә-төчеләнә сатучы белән киңәшә-киңәшә, ашау пешерә торган плитка сайлый. Мине күрүгә, ачык итеп: «Әй, беләсең бит инде артист тормышын, әнә кичә плитка булмагач, раковинаны содалап юып, шунда борщ пешереп ашадык әле», – ди бу. – «Ничек инде, пычрак раковинадамы?» – дим. «Без бит аны чистартып юдык, әйбәтләп сода белән, савытың булмаса, унитазда да пешереп ашарсың, тамагың ачса, – ди, көлеп. – Без гастрольләрдә шашлыкка кадәр пешерәбез», – дип шаккатырды. «Ничек?» – дим. «Итне вак итеп турап маринадта тотасың да, пергамент кәгазенә, аннары шоколадның ялтыравыклы кәгазенә төреп, кызган үтүк белән пешкән ит исе чыкканчы, алмаш-тилмәш ике ягын да бастырып торасың, 10 минуттан шашлык әзер», – дип, тормыш серләрен өйрәтте Михаил.

Гастрольләрдә йөргәндә танылган артистлар белән юлыбыз гел кисешеп торды. Телевизорлардан карап мөкиббән китеп утырган Эдита Пьеха белән дә очрашкан булды Санкт-Петербургта. Шул чакта ук, татар артистлары рус артистлары белән бер сәхнәдә чыгыш ясап, татар җырларын, татар моңнарын таратып йөрделәр. Алар инструменталь ансамбльгә кушылып җырлаучы беренче карлыгачлар иде. Уйнарга сыйфатлы инструментлар булмаганлыктан, күп аппаратураны кулдан сатып алдык. Рус артистлары чит илгә күбрәк чык-

канлыктан, алар аннан аппаратуралар алып кайталар, таможнядан үткәндә контрафактлы товар дип бәйләнмәсеннәр өчен, сатып алган яңа аппаратураларын тартмаларыннан чыгарып, тышкы кыяфәтләренә иске төсмер кертеп алып чыга торган булганнар. Ә элегрәк алганнарын башкаларга саталар иде. Без Эдита Пьеха музыкантларыннан шундый бер тотылган аппаратура сатып алдык. Ул чакта ул безнең өчен әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык бәхет иде. Аппаратураларны гына түгел, өс киемнәрен дә чит ил кешеләреннән сатып алдык. Күп вакыт без тукталган кунакханәләрдә финнәр күп булыр иде. Аларда аракы бик кыйммәт булганлыктан, алар безнең илгә аракыга чыга торган булганнар. Ул чакта бер шешә аракыга аларда менә дигән кроссовка тигән. Әле дә хәтеремдә: без концертны тәмамлап кичен кунакханәгә кайткач, финнәрнең кәеф-сафа корып, аракыга киемнәр алмашып йөргәннәрен күрдем. Мин үзем дә Санкт-Петербургтагы кунакханәгә тукталгач, алардан өстемә джинсы костюм белән джинсы чалбар алган идем. Ә Илһам Шакиров төркемендәге Володя Абышев дигән музыкант алардан ике шешә аракыга ике пар менә дигән чын тиредән теккән хатын-кызлар аяк киеме алды.

Шулай ук «Белоруссия» теплоходындагы гастрольләр круизы да хәтердә тирән уелып калган. Анда без Мәскәү артистлары – Георгий Вицын, Анатолий Моргунов, аның улы Антонны, кино артисты Кирилл Лавровны, Писаренко фамилияле концерт алып баручы конферансьены, «Веселые ребята» ансамбле солистлары белән банкетларда бергә утырып, ял итеп, эшләп йөрдек. Күп вакыт Әлфия ханымның кызлары Зөлфия белән Гүзәл дә безнең белән гастрольләргә чыга иде. Зөлфиясе бигрәк тә, бер тамчы су кебек, үзенә охшаган чибәр, чая кыз иде. Тора-бара ул концертлар алып бара башлады, әнисенә кушылып җырлый, матур итеп бии дә иде. Ул теплоходта җырчы Римма Ибраһимова да бар иде. Ул инде кияүдә, беренче сабые – улы белән көмәнле вакыты иде.

Ни кызганыч, сәфәрләребезнең барысы да уңышлы гына тәмамланмады, күңелсез хәлләргә дә тарыдык. Себердә концерт тәмамлангач, бөтен төркемебез белән тимер юл вокзалына Омскига барырга чыктык. Вокзалга килеп җиткәч, төркемебездә конферансье, сүз остасы булып йөрүче Дамир Нәбиуллин: «Инде тамакларыгыз ачкандыр, поезд кузгалганчы мин сезгә ашау юнәтеп киләм», – дип, тайгак кышкы юлда, поездлар йөри торган рельслардан сикереп, күздән югалды. Караңгы төн, көчле, якты фаралар яктыртып торган тимер юл шып-шыр бозлавык. Ә Дамир абый ничек концерттан чыккан, шул аяк киеме белән иде. Әй, көтәбез, әй, көтәбез, юк бит Дамир абыебыз. Поезд китәргә санаулы минутлар калды. Ниһаять, поезд кузгалып китте, без инде Дамир абый, шәт, соңгы перронга йөгереп менеп утырыр, дип өмет итәбез, әмма күпме генә көтсәк тә, ул күренмәде. Икенче көнне Омскидан Әлфия апа Себергә телефоннан шалтыратып сораса, егылып китә торган кайгылы хәбәр алдык. Аны безнең яннан киткәч тә, күрмичә, поезд таптаган булып чыкты. Мәрхүмне моргта без куйган концертта булган бер ханым

танып алган. Шулай итеп, бу сәфәребездән без зур югалту белән кайттык. Әлфия апаның ул чактагы кайгырулары, елаулары...

Тагын Илһам Шакиров төркемендә эшләгәндәге бер вакыйга бер дә баштан чыкмый. Без Ташкент аэропортыннан Алма-Атага очарга тиеш идек. Тиешле вакыт җитүгә, безнең самолетка сатылган билетлар кеше саныннан артык булганга күрә, аңлашылмаучылык килеп чыкты. Безнең белән бер самолетка билетларны «Пахтакор» футбол командасы әгъзаләренә дә сатканнар. Ярышка соңга калу сәбәпле, без аларга үзебезнең билетларыбызны биреп, алдан очырттык. Аэропорт җитәкчесе үзебезнең татар кешесе иде, ул безне бу яхшылыгыбыз өчен табын әзерләп сыйлады. Ике сәгатьтән соң безгә өстәмә самолет бирделәр. Без Алма-Атага килеп төшкәч, бик күңелсез хәбәр җиткерделәр. Без үзебезнең урынга утыртып җибәргән футбол командасы әгъзалары барысы да самолет белән һәлакәткә юлыккан. Язмыш безне менә шулай итеп үлемнән алып калды, әмма без сөенә алмадык, яшь егетләр кызганыч иде.

Гомумән, самолетта очу безнең өчен гадәти күренеш иде. Әллә самолетта очабыз, әллә автобуста, безнең максат тизрәк концерт буласы урынга барып җитеп урнашу иде. Саратов өстеннән очып барганда, самолет ниндидер гадәти булмаган тавышлар чыгарып, башка аэропортка төшәргә рөхсәт сорады. Самолетыбыз җиргә утыргач, барыбыз да җиңел сулап куйдык. Безгә: «Башка самолетны көтәсезме, юлыгызны шушы самолетта дәвам итәсезме?» – дип мөрәҗәгать иттеләр. Шунда Әлфия апаның тәвәккәллегенә таң калдык. «Юк, курыкмыйбыз, утырабыз, очабыз, бер генә үләсе!» – диде. Без кабат шул самолетта Алма-Атага вакытында барып җитеп, чыгыш ясадык. Әлфия апа тамашачы алдында үзен бик тә җаваплы сизә иде. Тамашачы белән аның арасында ниндидер күренмәс җепләр бар иде кебек. Ул тамашачыны елатты да, көлдерде дә, югыйсә бит, җырлап кына басып тора. Җырның тәэсире, башкаручының осталыгына карый шул. Ул «Күбәләгем» җырын җырлаганда кешеләр утырган җиреннән очар дәрәҗәдә булып утыралар, күзләре яна, хис дулкынына чумалар.

Әлфия апа беркайчан да үз алдына акча эшләү максатын куймады. Алар дүртәр ай йөреп, эшләп кайтсалар да, гади музыканттан аз гына артык хезмәт хакы алыр иде. Әлфия апа кебек чит ил артистлары ил гизеп йөрсәме, алар 60 яшьтә миллионер булыр иде инде. Шулай ук Илһам абый да үзен-үзе аямады, гастрольләрдән кайтып кермәде.

Көннәрдән бер көнне Илһам абый үз төркеме белән гастрольгә барып кайтырга тәкъдим ясады. Мин ни эшләргә белмичә аптырап калдым һәм аңа бу турыда Әлфия апа белән сөйләшергә кирәклеген әйттем. Филармониягә килеп Илһам абый белән очрашканнан соң, Әлфия апа миңа: «Володя, син Илһам төркеме белән бер барсаң, кире миңа кайтмассың инде, күңелем шулай сизә. Син миңа үзең кебек оста бер тавыш режиссеры табып бир, яме», – диде. Мин шулай итеп Илһам ага Шакиров белән эшли башладым. Минем урынга Коля Маршалов дигән музыкант килде, ул киткәч, аны Володя Наумов алмаштырды.

1980 елда Каракалпакстан Республикасында уздырылган Татарстан сәнгате көннәре аеруча күңелле, истә калырлык булды. Бу вакыйгага алар ике ел әзерләнгән. Махсус зур аэропортлар, бездәге «Татарстан» кунакханәсе кебек күпкатлы йортлар төзетеп каршы алды алар безне. Хәтта ашханәләрдә азык әзерләгәндә артист халкын сыйларга тауларда махсус сөт эчертеп кенә асраган сарыклар файдаланылган. Анда филармониянең бөтен төркеме дә барган иде. Андагы кадер-хөрмәтне, сыйны аңлатып бетерерлек түгел. Өстәлләр тулы нигъмәт: кавын, карбыз, җылы як җимешләре, шәрабләр – барысы да җаның теләгәнчә! Урамда җыр-моң, бию, пионерлар сәламләве, ике мең урынга әзерләнгән сый-хөрмәттән сыгылып тора торган табыннар. Мондый оҗмахка өйрәнмәгән кайбер музыкантлар өстәлдән шешә алып чыгып барганда хуҗа, официантларга: «Тиз генә кунакларга бер тартма коньяк алып чык!» – дип, безгә юлга тартмасы белән коньяк тыгып җибәрде. Алай гына да түгел, бу чарада катнашкан һәрбер җырчыга, музыкантка эченә бүләкләр салып, дипломатлар тапшырдылар. Көндез диңгез буенда ял итеп, концерт куеп, кич кәеф-сафа корып бәйрәм иттек. Бу дуслык бәйрәме – оҗмах – ун көн буе дәвам итте. Озак та үтми, каракалпакстанлылар безгә килде. Бездә дә алар килүенә зур әзерлек алып барылды, аларны зур кунак итеп озаттык.

Шунысы куанычлы: гомер үтте, әмма заяга үтмәде, халыкка хезмәт иттек, «БАМ» төзелешенә кадәр барып җиттек. Элекке артистларның тормышы белән хәзерге артистларның тормышы – җир белән күк арасы. Менә шулай гаиләсен, балаларын күрмичә ничәшәр ай гастрольләрдә йөреп алган мактаулы исемнәр бик кыйммәткә төште аларга. Ачык машиналарда, суык клубларда чыгыш ясап, сәламәтлекләрен бетергән олы йөрәкле артистларыбызның һәрберсенә һәйкәл куярлык! Хәзерге артистларның күбесе исем алганнарын да халык белми, бу бик тә аяныч, халык җырчысы буласың килә икән, Әлфия апалары кебек халык арасында булырга кирәк! Кешеләргә иҗат канатлары бирүне зур хезмәт, дип беләм, татар җыр-моң сәнгатенең үсешенә азмы-күпме өлеш кертүем Әлфия апа, Илһам абый кебек бөек затлар хөрмәтенә булды. Уйлап карасаң, концертта күп нәрсә тавыш режиссерыннан тора. Шуңа да чыгышы башланыр алдыннан Әлфия ханым, Лапшин фамилиясен кыскартып, үзенчә яратып, «Лапша кая, Лапша» дип, мине таптырыр иде. Әлфия ханым минем иҗат юлымда зур роль уйнады.

Мин шушы төркемгә, үз янына дәшкән Кәримгә дә бик тә рәхмәтлемен. Дөнья гиздек, галәм урадык, үкенечкә калдырмадык! Кемнәр белән генә эшләргә туры килмәде миңа филармониядә, төптән уйласаң, алар бөтенесе татар эстрадасының легендасына әверелде. Таһир Якупов, Вафирә Гыйззәтуллина, Венера Шәрипова, Гали Ильясов, минем белән бергә эшләгән музыкантларның күбесе инде бу якты дөньядан узды. Инде бүген матур истәлекләрне барлап яшәп ятам, хәтерләрдә чакта кеше үлми, мондый истәлек китаплары мәңгелек!

Гамирә ГАДЕЛШИНА,
журналист



Ул ирек ярата һәм сәхнәдә үләргә тели иде

Зәй шәһәрендәге «Октябрь» Культура сараеның грим бүлмәсе ишеге бикле түгел иде. Әкрен генә ишек шакуыма җавап бирүче булмады. Мин керергә тәвәккәлләдем. Таныш булмаган йөзләр. Биюче ябык кына беләгенә беләзек киеп маташа. Өстәл кырында күңелсез генә аксыл чәчле гармунчы кыз утыра. Менә «ул» үзе – арыган кыяфәтле, тыныч ханым. Бераз буялган авыр күз кабаклары астыннан дөньядан ваз кичкән кебек караучы күзләр. Сәхнәгә чыгарга берничә минут бар әле. Мин аңардан, концерттан соң очрашып, сөйләшеп утырып булмасмы, дип сорыйм. Ул ризалык бирә һәм мин тамаша залына юнәләм.

Менә конферансье аның чыгышын игълан итә. Зал кул чабулардан шартлый яза. Сәхнәдә – Әлфия Авзалова. Күз камаштыргыч ап-ак киемнән. Әле генә аның бөтен барлыгын урап алган кебек тоелган арыганлык һәм битарафлык кая киткән?! Аңардан хәзер шулкадәр шатлык бөркелә, әйтерсең, ул гомер буе биредә утыручы тамашачыларны гына көтеп яшәгән.

Беренче җыр, икенче... Аннары «бис»ка тагын берничә җыр яңгырый. Концерт тәмамлануын игълан иттеләр. Тик тамашачылар китәргә ашыкмый, сәхнә кырына җыела. Кемдер кулын суза, кемдер – чәчәк, кемдер – язу...

Зәй районында берничә концерт булудан файдаланып, мин Әлфия Авзалованы үз өемә кунакка чакырырга тәвәккәлләдем. Безнең әңгәмә озак һәм ачыктан-ачык булып чыкты; кайчак шундый «ачык» ки, кайбер өзекләр диктофон тасмасында гына калды. Бәлки, өй мохите дә ачылырга булышкандыр. Ә, бәлки, бу тормышта юлларыбызның берничә тапкыр кисешүедер. Ике дистә еллап элек ул, шул чакта ук яхшы танылган җырчы, Үзбәкстанда гастрольләрдә йөргән иде. Бу чорда мин яшәгән Нәваи шәһәрендә дә берничә концерт булды. Урта Азиядә Авзалованың популярлыгы искиткеч зур иде. Концертларга эләгү мөмкин түгел, кассаларга якын килеп булмый. Аның тамашасына билетны әниемнең дус хатыны табып бирде, ул – тумышы белән Актанышстан, шуның өстенә, җырчының гаилә танышы да булган икән. Шуннан соң, ун ел узгач, без Актаныш районының Чугана дигән авылында очраштык, ул анда үз төркеме белән килгән иде.

Тагын берничә очрашу булды әле. Һәр очракта безне яңадан таныштыралар, без озаклап, ачылып сөйләшәбез. Ул һәрвакыт мине җиңел генә оныта да... Безнең озакка сузылган әңгәмәбез әнә шул очрашуларны искә алудан башланды. Менә нәрсәләр ишетү насыйп булды миңа...

Тормыш турында

Минем сәхнә тормышыма тиздән илле ел була инде. Күпме вакыйга, шәһәрләр, илләр, кешеләр, исемнәр! Минем янына яхшы ниятле кешеләр килә, ә мин күп вакыт аның кем булуын, кайда очрашуыбызны искә төшерә алмыйм. Барысын истә калдыру мөмкин дә түгел. Менә син, сәхнәгә ник кәгазь белән чыгасыз, дип сорыйсың. Башкара торган җырымның сүзләрен онытудан куркам. Дүрт ел элек бик катлаулы операция кичердем бит. Минем зобны кисеп алдылар. Шундый стресс! Бер терапия курсы гына ни тора! Сиксән нурланыш сеансы алдым. Билгеле, бер моментта чәчләрем коточкыч коела башлады. Артист өчен моның нәрсә булуын күз алдыңа китерәсеңме? Мин бит сәхнәдән башка тормышны белмим. Шушы гастрольләрдән, шушы тузанлы сәхнә артыннан, рампа яктысыннан башка яшәүне күз алдына да китерә алмыйм. Инде көчле нурланыш алу үзен сиздерә башлады. Җырларымның сүзләрен бөтенләй оныта башладым. Ләкин тавышым исән бит! Шуңа күрә җырладым да җырладым. Авыртуларны оныту өчен, үземнең Әлфия Авзалова икәнемне, халкыма һаман да кирәк булуымны онытмас өчен.

Тора-бара бик куркыныч хәл булды: мин кинәт тавышсыз калдым. Коточкыч курыктым. Аллаһы Тәгалә миңа артык авыр зур сынау бирмәскә булды, ахры. Менә үзең күрәсең: чәчләрем чыкты, тавышым кире кайтты. Мин яңадан тамашачым белән очрашуга чаптым.

Балачак турында

Гаҗәп: еллар үткән саен, күптән үткәннәрне ачыграк искә төшерәм. Кинәт кенә балачак елларының кайбер мизгелләре хәтердә кабынып китә. Истә калмаган да кебек мизгелләр.

Мин Актанышта туганмын, ләкин алты яшемә кадәр Яңа Кабан авылында яшәдем. Бу – Башкортстанның Нефтекамск районында. Агыйдел елгасы аша әнием туган Актаныш – кул сузымы гына.

Әтием көтүче булган. Ярлы һәм башсыз. Борынгыча эчкән, күңел ачкан. Ә менә әнием йомшак табигатьле, тыныч, бик яхшы кеше иде. Бәлки, шуңа да әтинең кыланмышларын гафу иткәндер. Ә инде, бер дә түзәр чамасы калмаганда, елга аша туганнарына качкан. Әтинең, безнең арттан килеп, әнине кире кайтырга үгетләгәнен хәтерлим. Кайттык. Флүрә сеңлем туды. Бераздан Гөлсирин. Әниебез, көтмәгәндә, тиф белән авырып киткәндә, ул нибары ике атналык кына иде. Күз алдымда әнинең кызарган йөзе, газап тулы күзләре. Әти аны, кулына күтәреп, больницага алып китте. Башка мин әниемне күрмәдем. Бераз соңрак, ялкынсынудан, кечкенә сеңлем дә үлеп китте.

Коточкыч ярлылыкта яшәдек. Әниемнең кыз туганы (үземне үстергән апамны – әниемнең сеңлесен мин гомерем буе әби дип йөрттем) әтиемнән сеңлем белән икебезне үзенә бирүен сорагач, хәтерлим, безне чанага утырттылар. Кыш көне иде. Актанышка килеп җиттек, безне күргәч, әби аздан гына һушын җуймады. Каты салкын, ә без ярымялангач, саламга төренгән,

зәңгәрләнеп калтырыйбыз. Җитмәсә, бетләр... Бу хәшәрәтләрне гомердә дә онытмам. Бөтен балачак шулар белән үткән. Алар инде, мөгаен, ярлыларның мәңгелек юлдашыдыр!

Ачлыкны да хәтерлим. Һәрвакыт ашыйсы килә иде. Йортлар буенча кул сузып, хәер сорап йөрдем. Сеңлемне ул арада Такталачык балалар йортына җибәрделәр, әбием икебезне дә карый алмас иде. Аннары мин алтынчы класста укыганда, әбине утырттылар.

Колхоз басуыннан алган берничә уч бодай өчен биш ел бирделәр. Мине исә балалар йортына озаттылар. Әбиемне вакытыннан алда азат иткәнчегә кадәр, мин шунда укыдым.

Җырлар турында

Йөзләгән, меңләгән җыр беләм. Беркайчан санаганым булмады. Үземнең беренче җырымны яхшы хәтерлим. Бик кечкенә вакытымда җырлаганмындырмы, белмим. Икенче класста инде, чынлап, тамашачылар алдында җырладым. Ул җырда мондый сүзләр бар иде:

Түгәрәк күл – күл булалмас,
Су белән тулмаса.
Кыз бала туып тормасын,
Бәхет өчен тумаса.

Мин ул чакта тормышымның авыр, бәхетсез булуын аңлый башлаган идем инде. Ләкин һәрвакыт үҗәт һәм кире булдым.

Тавышым ачылгач, җырладым да җырладым мин, әйтерсең, шушы Аллаһ биргән сәләттә котылу бәхетем икәнен төшенгәнмен. Бераздан мине күреп алдылар. Концертларга чакыра башладылар. Аннары инде мәктәпне дә тәмамладым, Казанга ыргылдым. Монда укый башладым, Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләдем. Шул чорда мин тавышсыз кала яздым. Күрәсең, минем тавыш аппараты шундый итеп яратылган: көчләп тагылган муштраны күтәрә алмый. Сигез ай буе дәвам иткән күнегүләр мине аздан гына тавышсыз калдырмады. Мин җиңел җырлыйм, беркайчан да арымыйм, ләкин бугаз белән түгел, күкрәк белән җырлыйм. Хатын-кызларда сирәк очрый торган икенче альт миндә. Тагын бер нәрсә әйтәсем килә: тавышны саклау, иркәләү кирәкми. Күбрәк җырлаган саен ул ныгый, байый гына бара!

Көнчелек турында

Ай, нинди көнче мин! Берәр җырчыны тыңлыйм да газаплана башлыйм: «Ah, ничек матур җырлады, минем алай булдыра аласым юк! Ah, нинди җан җылыткыч сүзләр, ник мин җырламыйм бу җырны!» Менә минем репертуардагы җырны берәрсе җырласа, тынычланам, юк инде, мин аны яхшырак җырладым, дип уйлыйм! Көнләшүдән куркырга кирәкми. Иҗат кешесенә менә дигән стимул ул. Тагын да яхшырак эшләргә, тагын да кызыклырак, яктырак...

Көнчелекне яла ягу, хөсетлек белән бутарга да кирәкми. Мин болар-

дан гомерем буе иза чиктем. Артымда минем турыда нинди генә гайбәтләр сөйләмәделәр, ничек кенә каралтырга тырышмадылар. Популярлыгымнан, җанатарларым күп булуыннан көнләштеләр. Күп йөрүемнән көнләштеләр. Мин бит Италиядә, Испаниядә, Венгриядә, Төркиядә, Грециядә, Финляндиядә, Германиядә булдым, барысын да санап та бетерә алмыйм. Һәм болар «тимер пәрдә» елларында бит! Мине хурлыйлар, ә мин елап тормыйм, җавап итеп, яңа телдә яңа җырлар өйрәнәм. Алман телендә дә, гарәп, үзбәк, һинд телендә дә җырладым...

Сәясәт турында

Артистларга сәясәткә кысылырга кирәк түгел. Бу – башка тормыш. Андагы кеше дә бөтенләй башка булырга тиештер. Көчлерәк рухлы, катырак бәгырьле. Билгеле бер чорда, флаглар тотып, Казан мәйданында «баррикада»ларда йөргән кайбер җырчыларыбыз чынлап ачуымны китерә. Нинди азатлык сорыйлар алар? Кемнән? Нәрсәдән? Артистлар өчен хәзерге мөмкинлекләр, перспективалар элек беркайчан булмады. Аллаһ җырчыга бөек бүләк – тавыш бирә, шулай булгач, халыкка хезмәт иттер аны. Җырың белән аерым берәүгә булыш. Аның газапларын кимет, кәефен күтәр, юат һәм тынычландыр. Тик аның болай да катлаулы тормышына буталчыклык өстәмә.

Сәясәткә кысылмау фил сөягеннән ясалган манарага менеп бикләнү дигән сүз түгел. Юк, әлбәттә! Мин халкымның ничек яшәвен бик яхшы беләм. Мәрмәр түшәлгән бай залларда йөрмим бит концертлар белән, авыллар, бистәләр буйлап йөрим. Төн кунарга да кунакханәләргә түгел, гади авыл өйләренә керәм. Трибуналарга басып түгел, самавыр янына утырып сөйләшәм. Татарлар менә дигән итеп яши хәзер! Мин нәрсә белән чагыштырасын беләм бит!.. Артистның сәясәте әнә шул инде: тамашачың белән янәшә булу, аның мәнфәгатьләренә хезмәт итү.

Шәймиев турында

Аның турында начар сүзләрне күтәрә алмыйм. Беренчедән, безнең Беренче Президентыбызны хөрмәт итегез. Икенчедән, ул үзенә карата начар мөнәсәбәткә лаек түгел.

Без бүген һәм хәзер шуны аңларга тиеш: тормыш безне бөек сәясәтче белән очраштырды. Үз Ватаны өчен, Татарстан өчен ул эшләгән кадәр берәү дә эшләмәде. Узган елның декабрендә без концертлар белән бөтен Россия буйлап йөреп чыктык. Ханты-Мансийск, Свердловск, Чиләбе һәм бик күп башка өлкәләр, шәһәрләр... Аларда нәрсә булганын күз алдыгызга китерә алсагыз иде сез! Меңәрләгән гектарда ташландык җирләр, уңышы җыелмаган чиксез басулар, ташландык авыллар. Урманда агач кисеп җәфаланучы картлар, газ мичләрен анда ишеткәннәре дә юк, үз гомерләрендә күрмәсләр дә инде. Шулай булгач, булган бәрәкәттән тагын нинди бәрәкәт эзлибез соң без? Безнең алдан күрә белүче акыллы җитәкчебез бар, әйдәгез, аны хөрмәт итә белик тә, аңа булышыйк.

Үземнең хушлашу турым турында

Минем зур сәхнәгә аяк басуыма киләсе елда ярты гасыр була. Һәм хәзер ниндидер чик сызыгы үткәреп, иҗат тормышыма йомгак ясыйсым килә. Әнә афишаларга шулай дип яздырдым да: «Сөйгән халкым белән хушлашам». Һәм шигырь: «Мин китәмен, сез каласыз. Сезнең өчен җырлаган җырларым кала». Сәхнә – минем чын тормышым, мин үз ятагымда түгел, сәхнәдә үләргә теләр идем. Тик сер итеп кенә әйтәм: мин әле бик озаклап хушлашачакмын. Минем республикамда күпме шәһәрләр, бистәләр! Ә авыллар! Сүз уңаеннан, апрель аенда Казанда соңгы унбиш елда беренче тапкыр минем сольный концертларым булачак. Шуңа күрә Әлфия Авзалова тынычланыр да мич башында гына утырыр, дип уйламагыз да...

Аның көчле кеше дигән даны бар. Ул иронияле, комплиментлардан кача гына, үз бәясен белә. Әңгәмәдәшенә дә бәяне тиз бирә. Аның алдында боргаланудан файда юк. Кара күзләренең җитез, үтәли күрүче карашыннан үзүзеңне кая куярга белмисең Ул кичергән югалтуларны, ул күргән авырлыкларны әле көчле ир-атларга да күтәрү җиңел түгел. Ул кичергән шушындый тылсымлы уңыш, шундый шаккаткыч популярлыкны теләсә кайсы артист күтәрә алмый. Әлфия Авзалова – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, өч мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән. Аның бөек казанышы – исеме. Бу исемдә татар халкының ничә буыны тәрбияләнде, тарихи ватаннан читтә яшәүче татарлар өчен ул халкының иң лаеклы вәкиле булып калды. Әлфия Авзалова һәм Илһам Шакиров – ике легенда, ике йолдыз, якын киләчәктә аларга тиң булырдайлар күренми.

Безнең озын әңгәмәбез вакытында Әлфия апаның ике тапкыр күзләре яшьләнде. Беренче тапкыр – аның белән хушлашмыйча китеп барган әнисен искә алганда, икенчесе – кече ватанында аның өчен төзелә башлаган йорт турында сүз чыккач. Инде фундамент салынгач, төзелеш туктап кала, шул арада аңа «ушлы» якташларның күзе төшә. Иренмиләр, фундамент блокларын кискәләп ташып бетерәләр. Әлфия Авзалованың авыл өе турындагы хыялын җимерәләр. Дөрес, хәзер өе бар аның, атаклы Әлдермеш авылында сатып алган, бирегә килеп шәһәр шау-шуыннан ял итә ул. Үз ватанында пәйгамбәр булмый, диләр. Без әлегә янәшәбездә булган бөек замандашларыбызны бәяли белмибез шул. Гаҗәп: бүгенге көнгә кадәр Әлфия Авзалова турында документаль фильм да төшерелмәгән. Ул әле исән, ул ярты гасыр буе безнең өчен җырлый, ләкин вакыт шундый мәрхәмәтсез...

Гүзәл ВАФИНА,
биюче, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре



Былбыл кебек сайрап торды

Мин үзем – биюче, хезмәтемне Татарстан Республикасының данлыклы җыр һәм бию ансамблендә башлап җибәрдем, миңа ул чакта бары тик 17 генә яшь иде әле. Әнием укытучы булып эшләгәнлектән, ул мине бик тә тәртипле, әдәпле итеп үстерде.

Гадәттә, артист кеше шаян, җор телле, кыю була, мин холкым белән бик тә тыныч, тыйнак, оялчан гына авыл кызы идем. Беркөнне кемдер авыр сүз әйткәндерме, читтә берүзем елап торганда, Әлфия апаның гитаристы Кәрим килде дә: «Елама, мондый елак булсаң, рәт булмас, бирешмә!» – дип юатып торганда, Әлфия апа килеп чыкты да: «Әйдә, Гүзәл, миңа эшкә кил!» – ди. Мин бернәрсә аңламыйм, кайда, кемгә эшкә киләсен, аптырап, югалып калдым. Ул чакта аның төркемендә биюче булып Гүзәл Галиева эшли иде. Ул кияүгә чыгарга йөри, Әлфия апаның төркеме зур, ерак гастрольгә җыена. Гүзәл: «Мин бер генә тапкыр кияүгә чыгам!» – дип, гастрольгә барудан баш тарткан. Әлфия апа шулчак, мине исенә төшереп, үз төркеме белән гастрольгә алып чыгып китте.

Бик күп юллар узып, гастрольләр планын үтәп кайттык. Күрәсең, шул вакыт ул мине ошаткан. Ул миңа: «Син моннан соң үземдә генә эшлисең, сине беркемгә дә бирмим, булды, бетте, минем сүзем закон!» – диде. Шул гомердән ул мине үз төркеменә алып, без бергә эшли башладык. Бу минем өчен әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык бәхет иде. Башка төркемнәрдә артистлар гел алмашынып торды, ә безнең төркемнән беркем дә беркая да китмәде.

Ул кешеләрдә гаделлек, кешелеклелек, тугрылык сыйфатларын өстен күрә иде. Ул бөек талант иясе булуы белән генә түгел, кешеләргә һәрчак ярдәм кулы суза белүе, гадилеге белән дә халыкны таң калдырды. Ерак сәфәрләрдә булып, зур-зур сәхнәләрдә чыгыш ясадык, илнең кайсы почмагында гына булмадык: Себер яклары дисеңме, Ленинград, Мәскәү, нефть төбәкләрен әллә ничә урадык, ул гастрольләр вакытында нинди генә кызык хәлләр, вакыйгаларга тарымый идек. Бервакыт без Әгерҗегә юл тоттык. Әлфия апа белән Хәмдүнә Тимергалиева алданрак киттеләр, без шагыйрә Гөлшат апа Зәйнашева белән, поездга утырып, икенче көнне киттек. Алдан белгәндәй, проводникка, йоклап калсак, безне уятырсыз, дигән идек, ул да оныткан,

без төшәсе станцияне үтеп киткәнбез. Берзаман уяндык та, ап-ак оекбашлар кигән килеш, поезддан сикердек. Пычрак, саз, яңгыр. Әгерҗегә җәяүләп калтыр-колтыр, туңып-өшеп килеп җиттек.

Ул чакта Гөлшат Зәйнашева – шигырьләрен сөйләп, концертны алып баручы конферансье. Әй, Әлфия апа безне туздырырга тотынды: «Кайда йөрисез сез, концертны өзә идегез бит!» – ди. Безне берьялгызы гына яшәүче апага урнаштырдылар. Мине яшь килен, дип кенә атап йөрттеләр төркемдәгеләр, чөнки мин иң яше идем бригадабызда, ә Әлфия апа, яратып, «сестра» дип йөри торган иде. Берзаманны хуҗабикә тавык суйган. Мин тотындым тавык чистартырга. Мунча да ягарга кирәк, ди Әлфия апа. Бу апа ялгыз булганлыктан, үз мунчасын якмыйча, гел кешеләрдә генә юынып йөри икән. Мунчага керсәм, шаккаттым: ләүкәләре, идәннәре гөмбәләп беткән. Тотындым чистартырга, ялт итеп юып чыгардым мунчаны, ягып җибәрдек. Суык та тимәс, без әйтәбез, юлда бик тә туңган идек бит. Концертка кадәр җитешәбез, дип, кереп киттек мунчага, өчәүләп: Әлфия апа, мин, Гөлшат апа. Чишендек, ләүкәгә менеп утырдык, Гөлшат апа белән Әлфия апа мине тормыш көтәргә өйрәтеп, көлешә-көлешә юынып утырганда, ләүкәбез ишелеп, барып төштек. Еларга да, көләргә дә белмибез, бөтен җиребез авырта. Әлфия апа чыккач, теге хуҗа хатынны кыздырды гына: «Нигә дип үзең кермәгән мунчага безне керттең, нигә әйтмәдең ләүкәңнең тузганын», – ди.

– Зинһар дим, мине гафу итегез, берүк авылдашларга бу турыда сәхнәдән сөйли күрмәгез, – дип, әй ялвара теге апа. Ул көнне тамашачыларның эче катып бетте – Әлфия апаның мунча мажарасын тыңлап. «Бәхетегез бар икән, мине башка күрмәгән булыр идегез, ярый ләүкәдән егылып исән калдым», – дип көлдерде ул халыкны. Шулай итеп төркемне таркатмыйча, аның эчендә булган хәлләрне күпертмичә, һәр кеше күңеленә юл табып, үз төркеме белән ахыргача дус, тату мөгамәләдә эшләде Әлфия апабыз. Безнең турыда әниләрчә кайгыртып, бөтенебезнең хәленә керә белде, бик тә олы йөрәкле кеше иде! Миңа бөтен Татарстанның горурлыгы булган легендар җырчы Әлфия Авзалова белән бер төркемдә эшләү – Ходайдан әйтеп бетермәслек зур бүләк ул!

Икенче бер кызык вакыйга: мин Хәйдәр Бигичев һәм Зөһрә Сәхәбиева белән бервакытны Түбән Новгород, Сергач якларына гастрольгә чыгып кайттым. Анда зур-зур авыллар, авылда өчәр мәчет, тамаша залы халык белән шыгрым тулы. Безне ул вакытта шунда яшәүче Рифат дигән бер ир-ат каршы алды һәм без шул тапкан фатирда кундык, ә болай ул як кешеләре фатирга беркайчан да кеше кертмиләр икән. Мин кайттым да, үзебезнең төркем белән барырга кыстый башладым шул якка. Бу турыда Әлфия апага да әйттем. Озак уйлап тормадык, җыенып, Сергач мишәрләре янына юл тоттык. Әйткәнемчә, залда алма төшәр урын юк, ишектән дә, тишектән дә керәләр. Чыгышларыбызны да, үзебезне дә бик яраталар, әмма кунарга кертүче адәм юк. Безгә тагын иртәнгә икенче авылга барырга кирәк. Без – хатын-кызлар, бөтен кон-

церт күлмәкләребезне күтәреп, ир-атлар аппаратураны иңнәренә салып, юлга чыктык, төнлә басудагы печән эскертенә оя ясап, шунда йоклап, иртән торып су буенда учак ягып, Әлфия апа безгә ашарга пешереп, юлыбызны дәвам иттек. Ул чакта гармунчы Рөстәм Вәлиевның әле эшли генә башлаган еллары. Аның белән гыйшык-мыйшык уйнап йөргән чагыбыз. Мин соңыннан гына белдем, Әлфия апа махсус, без бергә булсын дип, оста итеп уйнаучы Кирам абыйны калдырып, аны алган булып чыкты. Киләсе Кочка-Пожарка дигән авылда безне тагын да зуррак сынау көткән булып чыкты. Бу – баянчы Рамил Курамшин авылы. Ул көндез килеп: «Мин ялга кайттым, мине дә катнаштырыгыз әле бу концертка», – диде. Әмма инде безнең бит музыкантлар бар иде, аны кире кактык. Халык әйбәт кенә җыелып, концерт башланган иде, шап итеп ут сүнде. Авылда бар, клубта юк ут! Соңыннан бу этлекне Рамил эшләмәгән микән, дип көлештек. Шул чакта да Әлфия апа чыгышын туктатмады, лампа яктысында дүрт сәгать ярым концерт бирде: ул сандугачтай сайрап, җырлап торды, мин очып-очып биедем. Микрофонсыз булгач, бөтен авырлык баянчыга төште, ул Рөстәм Вәлиевка бик зур сынау булды. Соңыннан Әлфия апа Рөстәм белән минем янга килеп: «Сестра», син – молодец, ә син «брат», пока не «брат», – диде. Тора-бара еллар үтте, үз өстендә эшли-эшли, Рөстәм атаклы баянчы Рөстәм Вәлиевкә әйләнде!

Концертларны соңыннан Әлфия апаның кызы Зөлфия алып бара башлады. Зөлфия бик тә чибәр, акыллы, нәкъ Әлфия апага охшаган. Алар белән бергә Үзбәкстанга барып, икешәр-өчәр ай концертлар куеп йөрибез. Туганнарыбызга, дусларыбызга җылы яктан посылка белән җиләк-җимешләр җибәрәбез. Администраторыбыз милләте буенча Корея кешесе иде. Безнең автобуста гел аның «Баллончик» дигән эте йөрде. Аны бөтенебез ашата, бик тә ярата идек. Көннәрдән беркөнне шул администратор безнең барыбызны шашлыкка дачасына кунакка чакырды. Без Әлфия апа белән никтер бармадык. Шуннан кайткач, ул безнекеләргә: «Ә сез беләсезме, мин бит сезгә шашлыкны «Баллончик»тан пешердем», – дигән. Андагы хәлне сөйләп бетererлек түгел, кайберләре укшый башлады. Соңыннан Әлфия апа ул администратордан баш тартты, икенче кешене куйдырды. Бервакыт без шул Үзбәкстанда, Шәһрисабыз дигән җирдә вакытта, башка милләт кешеләренә рәт бетте. «Русские – в Рязань, татары – в Казань» дигән плакатлар күтәргән, чылбырлар тоткан үзбәкләр безнең концерт куясы площадканы әйләндереп алдылар. Безгә концертны кыскартырга кушылды. Халык залда шыгрым тулы иде, Әлфия апа: «Ничек инде, халыкны алдау була бит бу?!» – дигәч, барыбер ике сәгать чыгыш ясадык. Киткәндә, автобусларга ташлар ыргытып, атып калдылар, шөкер, без аппаратура тулган автобус идәненә ятып, исән-сау калдык. Ул чакта Әлфия апа да бик курыкты, чөнки кызы Зөлфия, оныгы Ләйсән дә шунда иде.

Нинди генә хәлләр булмады инде. Чын тормыш мәктәбе уздык без Әлфия апа белән. Тормыш кыйнады да, яратты да, бәреп тә екты, тартып та тор-

гызды. Бүгенгедәй исемдә: Ижевскида концерт вакытында Әлфия апага бик начар булды, кинәт кан басымы күтәрелеп, «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырттык. Табиблар укол ясап хәле арулануга, аларның сүзенә колак салмыйча, кабат сәхнәгә чыгып китте. Килгән табиблар аның чыгышлары беткәнче кизү тордылар, тамашага килгән халык берни дә белмәде. Ул алар белән, гадәттәгечә, шаярды, көлде, яшь аралаш елмайды. Менә шундый бөтен яктан да камил, кыю, ил бөркете белән бер юлда йөртте мине язмыш! Бергә дөньяларны гиздек, бер савыттан ашадык, коры идәннәрдә, эскерт куышларында бергә йокладык. Күпме авырлыклар күрсә дә, икенче көнне кояштай балкып, кызык, туры сүзләре белән халыкның күңелен күтәрде, былбыл кебек сайрап торды Әлфия апа. Мин генә түгел, аның белән бөтен милләт горурлана, мин икеләтә бәхетле булдым!



Гүзәл ЛАТЫЙПОВА,
Әлфия Авзалова бригадасында эшләгән Татарстанның атказанган артисты Әнвәр Латыйпов һәм Татарстанның атказанган артисты, конферансье Нәҗия Минкиналар династиясен дәвам итүче кызлары – халык бию ансамбле солисты, биюче

Зур җаваплылык иде

Безнең династиянең иҗат юлы да, тормыш юлы да бөек җырчыбыз Әлфия Авзаловага бик тыгыз бәйле. Әнием Нәҗия Минкина белән Әлфия апа – сәхнәдә генә түгел, тормышта да ахирәтләр, якын дуслар иде. Әниемне – иң яхшы алып баручы дип атавы, әлбәттә, ул биргән иң дәрәҗәле, зур бәя. Әтием Әлфия апа бригадасына җыр һәм бию ансамбленнән килә. Без Әлфия апа кызлары белән һәрвакыт гастрольләрдә йөрдек, балачак гел тәгәрмәчтә узды, дисәк тә, ялгыш булмас. Мин үзем сәхнә артындагы урындыкларда бик тиз генә йоклап китә алмый интегә идем, бүгенгедәй күз алдымда нәни Зөлфиянең бөтерелеп урындыкта тәмләп йоклап ятуы. Шулай итеп, без сәхнә тормышын кечкенәдән күреп, өйрәнеп үстек. Бу, минемчә, үзенә күрә зур батырлык – Әниләр батырлыгы! Алар бит иҗат белән дә шөгыльләнгән, безне дә кочакларында йоклаткан, вакытында ашаткан, эчерткән, беркемгә дә ташлап китмәгән. Әти-әниләр, Әлфия апа биргадасы белән бөтен Рәсәйне аркылы-торкылы урап чыкты.

Берничә айлык гастрольләрдән кайткач, гаиләләребез белән Әлфия апаның дачасында ял итүләр бүген дә иң кадерле ядкарьләрнең берсе. Әйткәнемчә, Әлфия апаның кызлары Зөлфия һәм Гүзәл белән без туганнардай якын булып үстек. Зөлфия белән бергә театр училищесының хореография бүлегендә укыдык. Аннары, үсеп буйга җиткәч, ул минем туемда шаһит булды. Ул кияүгә чыкканда, без табын түрендә утырдык. Бу гаиләдән мин күп тәрбия дәресләре алдым. Алар белән аралашу шулкадәр рәхәт, җиңел иде. Үз-үзләрен гаҗәеп гади тотулары, кешелекле, ярдәмчел булулары белән үзләренә тартып тордылар. Мин Әлфия апа бригадасына 1984 елда килдем. Халык бию ансамблендә җыйган тәжрибәм, ялгыз биюләрем белән халык күңеленә, тамашачы арасына кереп киттем. Әлфия апаның мине – яшь белгечне, тәвәккәлләп, үз бригадасына алуы зур шатлык булса, бу – бик зур җаваплылык та иде. Бүгенгедәй хәтердә: мин эшкә кергәч тә, Галиәсгар Камал театрында зур концерт булды. Мин бик тә дулкынландым, әмма Әлфия апаның сәхнә артындагы мөлаем йөзен, миңа сокланып карап торуын күргәч, бөтен борчылуларым кинәт юкка чыкты, үз-үземә ышанычым артты, әйтерсең лә, иңнәремә канат үсте. Аның янына эшкә барырга атлыгып тора идем, ул вакытта әле әнием дә безнең белән бергә эшләп йөри, әтием инде лаеклы ялда иде. Бүген дә Әлфия апаның кызлары – ышанычлы терәгем, гаилә дусларыбыз! Күпме юллар бергә үтелгән, күпме якты хатирәләр уелып калган күңелләрдә. Авыр булса да, без бу җырлы юлларны «их» тә дими, кабат узар идек, менә нинди бәхетле язмыш бүләк иткән безгә Аллаһы Тәгалә!



Диләрә ИЛЬЯСОВА,
нәфис сүз остасы

Бик матур яулыгын бүләк итте

Әлфия белән тәүге тапкыр күрешүебез алар төркеме безнең Башкортстанның Яңавыл районына концерт белән килгәч булды. Минем Яңавыл район үзәгендә мәктәптә укып йөргән вакыт, ул чакта анда апаларым яши иде. Матур җырлары белән танылып килүче яшь артист Әлфия Авзалова килә дигәч, без апа белән шулкадәр нык әзерләндек: мунчалар яктык, бәлешләр пешердек. Бүгенгедәй хәтеремдә: әлеге концерттан

алган тәэсирләр шулкадәр күңел түрендә уелып калды. Әлфиянең матур, моңлы итеп җырлауларына, талантына, сәхнәдә үз-үзен тотышына таң калдым. Ул чакта концертны Фәйзи ага Йосыпов алып барды. Алар, кызганычка каршы, концерттан соң кунып тора алмадылар, ашыктылар, китәргә туры килде. Шул чакта Әлфия миңа адресын биреп калдырды.

Мин аларга кунакка килеп йөри башладым. Ул вакытта инде ул кияүдә иде, кызларының бик кечкенә чаклары. Аннары мин Казанга күчеп килдем, укыдым. Нәфис сүз остасы булып филармониядә эшли башлагач, без концертларга бергә, бер төркемдә йөри башладык. Без аның белән бик тә дуслаштык, җан дусларга әйләндек. Мин конферансье гына түгел, Әлфиянең бөтен концерт күлмәкләрен үтүкләп, әзерләп биреп, киендерешеп, костюмерша ролен дә үтәп йөрдем һәм мин моны ихлас күңелемнән башкара идем. Әлфия беркайчан да күңелсезләнеп, төшенкелеккә бирелеп утырмый иде, 5-6 концерт биреп хәлдән тайса да, тамашачы аның арыганлыгын сизмәде. Ул һәрвакыт яшь, матур, сөйкемле, бизәнгән, чибәр булыр иде. Безгә – барыбызга да аның белән гаҗәеп рәхәт, күңелле иде.

Без гастрольләрдә кайларда гына булмадык, нинди кызык хәлләргә тарымадык, нинди генә авырлыклар күрмәдек. Казахстан, Ташкент, Мәскәү, Ош, Баку, Ленинград кебек зур шәһәрләрдә бер генә түгел, икешәр-өчәр мәртәбә булырга туры килде. Безнең белән бер төркемдә шулай ук Шамил Хисмәтуллин, Рәшит Сабиров һәм бер төркем музыкантлар йөри иде. Бервакыт, Рәшит Сабиров укуга киткәч, Әлфия Авзалова төркеме белән ашыгыч гастрольгә китәргә кирәк, дип, миңа дәштеләр. Кайсы төркемгә дәшсәләр дә, каршы килеп тормый идем, «пожарник» кебек, һәммәсен тыңлап, барысының хәленә кереп йөрдем. Әмма бу юлы апам фаҗигале төстә үлеп, апамның өчесе дә узмаган килеш, чыгып китәргә туры килде.



Шамил Хисмәтуллинны сизенеп йөрим, ул мине күзләп, бәйләнеп, кызыгып йөри, ә миңа

ул ошамый иде. Мин аның мәхәббәтен кире каккач, ул гастрольгә баргач, минем киемнәр тутырылган чемоданымны машинада калдырып кергән. Минем апаны сагынып елап йөргән чагым, шул чагында Әлфия апа, Шамилнең шул кыланмышын белеп алып, аның яңагына китереп суккан иде. «Диләрәнең шундый кайгылы чагы, гел елап йөри, безнең хәлне аңлап кына эшкә чыкты бит, нинди шаяру, нинди хәл бу, ничек сиңа оят түгел», – дип, аны ачынып-ачынып ачуланганы бүгенгедәй хәтеремдә. Менә шундый гадел, куркып тормый торган сыйфаты бар иде аның, ир-аттан да курыкмас, тимер холыклы иде ул. Ә бервакыт, Казахстанга баргач, без «Казахстан» дигән гаҗәеп күп катлы, бик тә зәвыклы интуристлар кунакханәсенә тукталдык. Шамил Хисмәтуллин, мәрхүм, бик тә мут, кәеф-сафа корырга ярата торган кеше иде. Берзаманны кунакханәдә зур тавыш чыкты, сезнең музыкант безнең эшчегә ташланган, ул тән җәрәхәтләре алган, дип, безнең барыбызны да администратор үз янына җыйды. Моның өчен Шамил Хисмәтуллинны нәрсә эшләтәбез дип, ул Әлфия апага мөрәҗәгать итте. Шунда Әлфия: «Төрмә! Кешегә кул күтәргән адәмне бөтен катылыгы белән җинаять җаваплылыгына тартырга кирәк!» – дип әйтеп салмасынмы?!

Берәү булса, и, иртәгә безнең концерт куясы бар, җибәрегез, дип ялыныр иде. Менә шундый гадел дә, курку белмәс тә Әлфия безне яклап та, саклап та йөрде, әмма дөреслек безнең якта булса гына яклады, фәрештәдәй канатын җәйде. Мине яратып йөргән Шамилне 15 тәүлеккә утырттылар ул вакытта. Чыгышлар уртасында сәхнәдәшләрең белән шундый хәлләр булсын әле, ә ул менә халык алдында елмаеп торыр иде, аннан соң бөтен мәшәкать, бөтен авырлык аның нәфис иңнәренә төшәр иде. Киңәш-табышка да бик рәхәт кеше иде Әлфия. Кешене яратсаң гына өметләндер, кеше хисләре белән уйнап йөрергә ярамый, арада мәхәббәт булмаса, булмый инде, ди торган иде ул һәрвакытта да янәшәдәге дус-ишләренә. Аның юмартлыгына аерым тукталырлык. Сәхнәдә аның иңнәренә матур яулыклар, шәлләр салырлар иде. Шундый бүләкләрнең берсе булдымы икән, миңа да бер бик матур яулыгын бүләк итте. Әле дә аның төсе итеп башымнан төшермим. Ул гынамы, сәхнә күлмәкләренә кадәр бүләк итте. Бер матур ачык яшел төстәге плюш күлмәген рәхәтләнеп сәхнәләрдә киеп йөрдем. Әле бертуган апамның кызы – диктор, аңа да биреп тордым.

– Белеп ки, апаем, легендар җырчы Әлфия апаң үзе кигән күлмәк, берүк саклап ки, дип искәртеп бирдем. Инде менә миңа да 83 яшь тулды! Әлфияне уйламаган, сагынмаган, юксынмаган көнем юк. Әле дә үлемсез җырлары бар, шул җырларын тыңлап, бергә узган күңелле яшьлек елларын искә алып утырам, елап та алам. Нишлисең бит, без бу дөньяда кунак кына. Бер сәхнәдә йөрсәк тә, безне онытырлар, Әлфиябез онытылмас; аның моңнары, тырышлыгы, максатчанлыгы җырларында калды. Ул җырларга, әйтерсең лә, Әлфиянең күңел моңы сеңгән. Алар, кояш баешында алсуланып аткан таң кебек, йөрәкләргә өмет, нур, көч өсти.

Дүсинә ӘХМӘДУЛЛИНА,
Россия Федерацияседең һәм Татарстан Республикасының атказанган табибы, гаилә дусты



Үзебезнең Әлфия апа

Әлфия Авзалова исеме мин кечкенә чакта ук безнең күңелебезгә, гаиләбезгә килеп керде. Әти-әнием гомер буе Актанышның МТСында эшләде. Әтием 1927 елгы иде. Яше җитмәү сәбәпле, әтием сугышка алынмаган. Ул бик тә матур җырлый иде. Әлфия апаныкы кебек, тавышы көчле, моңлы иде. Бу 1950 еллар. Әлфия апа шул МТС клубында эшләгән. Без – гаиләдә өч бала. Без һәрвакыт өебездә җырчы Әлфия дигән сүзне ишетеп үстек. «Әлфия бик сәләтле, бу кадәр күп чит телләрдә җырлаучы татар хатын-кыз артисты бүтән юк!» – дип сөйләде иләр иде безнең әти-әниләр соңрак, бу сәләткә шулкадәр сокланып. Хәтта Әлфия апа минем сеңлем Зөлфияне, әти белән әни репетицияләргә баргач, сөеп, яратып, күтәреп тә йөрткән әле. Тирә-якта аның турында газета битләрендә очерклар, зур мәкаләләр статьялар, зәңгәр экраннардан тапшырулар чыга башлады. Ул үзенең чыгышын карамаган халык арасында да тиз танылу тапты, чөнки аның җырлары радиолар аша гел яңгырап торды. Аның моңлы, аңәһле тавышын халык меңнәр арасыннан танып ала иде. Әлфия апабыз телдән төшәрлек җырчы түгел иде бит. Хатын-кыз җырчылар арасында андый биеклеккә күтәрелгән, үзенә, татар җырына болай юл салган бүтән җырчы юк иде! Аның турында сөйләгәндә еш кына аны гел Актанышта туып-үскән, дип сөйлиләр иде. Әтием моңа гел гажәпләнеп: «Әлфия Авзалова Башкортстандагы Калтасы районының бер авылында туган. Әйе, ул Актанышта, бездә эшләде, ул монда туганнарында Тау асты урамы, икенче төрле әйтсәк, Мәктәп асты урамында яшәде», – дип, гел дикторларның, хәбәрчеләрнең төгәлсезлекләренә ризасызлыгын белдереп, үз алдына сөйләнеп утыра торган иде. Безнең класста талантлы укучылар бик күп иде. Без җырларга ярата идек. Үземнең дә кечкенәдән үк сәхнәгә менү теләгем зур булды. МТС клубында без дә гел бәйрәмнәрдә катнашып, җырлап йөрдек. Әлфия апа бәйрәмнәрне искиткеч матур оештыра иде. Ул елларда һәркем аның янына – иҗатка тартылды. Без шулай итеп МТС сәхнәсендә чирканчык алып үстек. Җиңү яуласак, безне Актаныш район культура йортына алып баралар иде. Без күп фестивальләрдә катнашып, урыннар яуладык. Хәтта пионер вакытта республикакүләм фестивальгә дә барганыбыз булды.

Үсеп буйга җиткәч, мин Казанга юл тоттым, шунда укырга кердем. Бер очраганда, мин аңа чәчәк бәйләме суздым да: «Әлфия апа, хәтерлисезме: мин менә Актаныш МТСында эшләүче, җырчы Шамил кызы булам», – дидем. Ул мине, туганын күргәндәй якын итеп, шатланып кочып алды. Ул шулкадәр гади, эчкерсез ханым иде бит. Аның сөйләүләре, һәрбер әйткән сүзе күңелгә май булып ятты торган иде. Мин аның өчен шуннан бирле Шамил кызы булып калдым.

2000 елларда Татарстанның барлык төбәкләрендә якташлар җәмгыятьләре оешты. Безнең Актаныш якташлар җәмгыяте дә киң колач җәеп эшли башлады. Әлеге оешмаларның төп максаты – туган җир кешеләрен бергә туплау, дустанә, тату яшәү булды. Шушы уңайдан зур-зур мөһим чаралар, бәйрәмнәр, кичәләр оештырылды. Җәйге Сабантуйлары, кышын авыл хуҗалыгы алдынгылары бәйрәме, икенче төрле без аны – Кышкы сабантуй, дип тә йөртә идек. Әлбәттә инде, бу бәйрәмнәрнең һәрберсенең түрендә безнең яраткан җырчыбыз Әлфия Авзалова булды. Безнең беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев безнең Актаныш ягы Әнәк авылыннан булганлыктан, бу бәйрәмнәр якташларның гына түгел, бәлки, бөтен республика халкының игътибарын җәлеп итте. Бу бәйрәмнәрнең һәрберсенә без зур чакырулы кунак идек. Бервакыт шундый матур кичәләрнең берсендә ул мине үзе биергә чакырды. Безнең актанышлылар искиткеч матур биилəр бит алар! Ә мин биергә чыкмаска тартышып ятам, янәсе, матур бии алмыйм... Шулчак иптәшем: «Җаным, ничек инде син, Әлфия апа сине үзе биергә чакырганда, каршы килә аласың, бар, бар, бие!» – дип, мине биергә чыгарды.

Тагын бер шундый бәйрәмнәрнең берсендә – урман аланлыгында махсус ясалган түгәрәк өстәл янында, дугасыман ясалган озын утыргычта утырабыз. Шулчак Минтимер Шәрипович: «Әйдә әле, Әлфия, җырла әле, сип әле моңнарыңны!» – диде. Әлфия апа безнең арада, уртадарак утыра иде. Башкаларны кузгатудан читенсенеп, ул матур, озын итәкләрен кулына җыйды да, өстәл астыннан үрмәләп, горур гына сәхнәгә менеп басты. «Президентыбыз әйткәч, үрмәләп булса да чыгам, җырлыйм!» – диде ул, шаяртып, гадилеге, чаялыгы, үткенлеге белән шаккатырып. Бу бәйрәмгә килгән халык, барысы басып, аңа дәррәү кул чапты. Шушы бер гамәле белән дә ул үзенең күңел матурлыгын башкаларга җиткерә алды. Шул минутта без аның бу җирдә берәү генә, кабатланмас шәхес икәнлеген аңладык!

Безне, гадәттә, якташлар җәмгыяте оештырган бәйрәмнәргә, зур чараларга Казаннан дәү автобуслар белән алып киләләр иде. Ул чакта безнең төбәккә чит ил автобусларының яңа кайткан вакыты. Безнең һәрберебездә диярлек Әлфия апа автобусына утырып бару теләге иде. Ниһаять, безгә дә бу бәхет тәтеде. Әлфия апа өчен алдагы бер урын билгеләп куелган иде. Без Әлфия апалар яши торган йорт янына барып җиттек, аның чыкканын хәйран гына көтеп утырдык. Бөек җырчыны көтеп утыру үзе бер рәхәт тойгы бирә,

ниндидер бер могҗиза алдында торган кебек. Ниһаять, дүрткүзләп, зарыгып көткән Әлфия апабыз күренде. Автобуска менеп үз урынына утырды да шофер көзгесенә карап чәчләрен рәтли башлады. Шулчак кемдер: «Әлфия апа, бигрәк матур инде сез», – дип, аңа комплимент әйтте. Әлфия апа: «Әйе шул, мине бит япункага охшагансың дип әйтәләр», – дип елмайды. Автобус кузгалып китте. Тып-тып гына барабыз. Әлфия апа янында берәү дә җыр сузарга жөрьәт итми. Күпмедер баргач, бер батыры табылды, аңа башкалар кушылды. Казанга барып җиткәнче, җыр-моң, уен-көлке тынмады. Якынаеп китеп, Әлфия апага сораулар яудырдык: «Әлфия апа, сез бүген җырлыйсызмы?», «Әлфия апа, сез бүген теге матур ялтыравыклы күлмәгегезне киясезме?..» Ул безнең белән үзен бертигез күреп, рәхәт итеп сөйләшеп, аралашып барды. Бу сәфәр күңелләрдә мәңге онытылмаслык тирән эз калдырды. Без аның талантына, җырларына һәм дә моңлы тавышына гына түгел, бәлки, аның сөйләменә дә, үз-үзен тотышына да, зәвыклы киемнәренә дә, бизәнүенә дә, хәтта ки елмаюына, көлүенә дә гашыйк идек. Андый горур, шул ук вакытта гажәеп гади, тылсымлы тавышлы, киң күңелле, мировой кеше башка булмас! Ул – берәү һәм кабатланмас шәхес. Ул – милләтебезнең йөзек кашы, сәхнә патшабикәсе! Ул сәхнәдән нәрсә генә сөйләсә дә, халык аны аңлады, шуңа да якын итте, яратты!

Минем тормыш иптәшем, үзе профессор булса да, җыр-моңга гашыйк җан иде. Ул үзе дә бик матур җырлый иде. Аның репертуарында романслар өстенлек итте. Ял иткән чакларда, бәйрәм табыннарында дуслар аның җырлавын еш сорый, ул каршы килеп тормый, рәхәтләнеп башкара. Бездә, хәтта, аның җырларының фонотекасы бар. Бервакыт шулай өйгә кайтып керсәм, пластинкадан бер хатын-кыз «Журавли» дигән венгр романсын башкара. Искиткеч матур моң күңелләрне айкый... «Дүсинә, әйт әле, бу романсны кем башкара, беләсеңме, җаным?» – ди иптәшем. Мин кемнәрне генә әйтеп, атап бетермәдем, әмма белә алмадым. Шунда ул: «Әй, шуны да белмисең, бу бит үзебезнең Әлфия апабыз!» – диде ул, горурлыгын яшерә алмыйча. Миңа оят булып китте. Әлфия апаның шул көнне урыс җырын шулкадәр дәрәҗәдә оста итеп башкаруына таң калган идем. Минем өчен бу зур ачыш булды.

Җырчыбызга булган кайнар мәхәббәтебезнең, рәхмәтләрнең зур бер чагылышы – беренче кызыбызга бөек җырчы Әлфия Авзалованың исемен куштык! Әлфиябез дә – бөек җырчыбыз кебек үк, максатчан, тырыш бала. Ул үзенең бу матур исеме белән бик горурлана.



Зәлинә ХӘЙРУЛЛИНА

Мәңге сүнмәс йолдыз

(Әлфия Авзаловага багышлана)

Нинди моң һәм тавыш иясе Сез –
Татар күңелен яулап алырлык!
Шундый матур җырлар җырладыгыз,
Тарихларда уелып калырлык...

Сәхнә түрләре – күк йөзе,
Ә Сез – Кояш идегез! –
Үзегезнең яктылыкны
Жәлләмичә бирдегез....

«Картаямыни соң йөрәк?»
Сезнеке – картаймады:
Тормыш йөге астында да
Былбыл кебек сайрады!

Язмышыгыз бигрәк авыр иде –
Биш яшьтән үк ятим калдыгыз...
Тик, соңгы сулышка кадәр,
Яшәү дәрте белән яндыгыз!

Утлар, сулар аша кичтегез Сез,
Уфтанмыйча алга бардыгыз –
Үз тырышлыгыгыз белән
Зур сәхнәгә юллар салдыгыз!

Сыгылмыйча, галибанә барып,
Сәхнә түрен яулап аласыз...
Әлфия апа, Сез бит – безнең өчен,
Актанышның бөек баласы!

Зәйнәб ФӘРХЕТДИНОВА *һәм*
Зөфәр БИЛАЛОВ,
җырчылар, Татарстанның халык артистлары



Сокланып, яратып яшәдек

Без Зөфәр белән Әлфия апабыз турында бары тик матур-матур сүзләр генә әйтә алабыз. Без аны яратабыз, яраттык һәм мәңге яратачакбыз. Аның белән һәрбер очрашу бер татлы мизгел, күңелле бәйрәм төсмере ала торган иде. Аның барыбызны яратып, балакайларым, җанкайларым, дип эндәшүе мәңге күңелдән китмәс. Аның белән беренче танышу, очрашу Зөфәр белән тормыш корган чагыбызга туры килә.

Без әле яңа гына сәхнәгә аяк баскан яшь җырчылар бит инде. Бервакыт бик күп артистлар катнашында, «Яшьлегемә кире кайтыр идем» дип аталган концерт оештырдылар. Анда танылган өлкән буын җырчылардан: Таһир Якупов, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Флюра Сөләйманова һәм башка бөек сәнгать әһелләре катнашында бик матур программа әзерләнде. Әйткәнемчә, бу концертта Зөфәр белән мин дә катнаштым. Безне өлкән буын җырчыларындагы әдәплелек, бер-беренә карата хөрмәт сокландырды. Олыны – олы, кечене кече итә белә торган, безгә үрнәк, тормыш өлгесе, бөек шәхесләр алар! Аларның ничек итеп тамашачы мәхәббәтен яулаулары, алкышларда коенулары безне дә ижат үренә менәргә канатландырды диясем килә. Әлфия апа белән Илһам абыйның сәхнәдә генә түгел, сәхнә артында да бер-берсенә булган җылы мөгамәләсе күп вакыт без-яшьләрне таң калдыра иде. Шаяртып сөйләшүләре һәрчак күңелләребезне күтәрде. Сәхнәгә тәүге адымнарыбызны атлаганда шундый остазларыбыз булганга, бик тә бәхетле идек без. Аның белән очрашканда ул беркайчан да гамьсез генә, үз уйларын уйлап узып китмәс. Яратып эндәшер, аркадан сыйпар иде. «Битең алма кебек матур!», «Әй, аякларыңа кадәр миңа охшаган инде, бигрәк матур җырлыйсың!» – дип, канатландырып җибәрүләре генә дә ни тора. 15 еллап элек ул миңа бик тә кирәкле киңәш бирде. Безнең татар кызлары тормышта да, сәхнәдә дә артык тыйнак. Тормышта ярар инде, ә менә сәхнәдә артык тыйнаклык кирәк түгел, үзеңне иркен тотарга өйрән, диде ул миңа. Аллага шөкер, аның бу киңәшләрен тотып, үз-үземне тәрбияләдем, мин инде хәзер үземне сәхнәдә иркен хис итәм. Әлбәттә, каушамагач, җыр да матуррак чыга, бу инде алкышларда сизелә.

Шулай берчакны без Әлфия апа бригадасы белән Уфа якларына гастрольгә киттек. Анда «Шәрыкъ» радиосы көннәре иде. Безне, зурлап, «Президент»

отеленә урнаштырдылар. Бер кичне, концерттан соң, без – Зөфәр белән, ресторанга төшеп, тамак ялгарга уйладык. Үзебез белән Әлфия апаны да чакырмакчы булып, аның номерына шакыйбыз. Әлфия апа ишеген ачты да: «Әле кайда җыендыгыз болай матур итеп киенеп?» – ди. Менә, Әлфия апа, ресторанга сине дә алырга килдек әле, әйдә безнең белән, дибез. Әлфия апа: «Юк, балалар, минем бер күкәй белән бер сосискам бар, шуларны ашыйм да, аякларымны күтәреп, рәхәтләнеп урыныма менеп ятам, сез – яшьләр, үзегез парлап кына утырыгыз инде, ачуланмагыз, яме», – дип, бүлмәсендә калды. Башка көннәрдә Әлфия апага иртән хәерле иртәләр теләргә кереп, кич аның белән серләшеп утыра торган идем. Аның битләренең чисталыгына, матурлыгына сокланып утырганда, ул миңа аның серләрен дә әйтте. Мин бүгенге көнгә кадәр бу файдалы киңәшен тотам, әлбәттә инде, нәтиҗәсен дә күрәм. Ул иртән битләрен, билгә кадәр гәүдәләрен сап-салкын су белән юам, ди торган иде, анысының да файдалы икәнлеге көн кебек ачык. Башка җырчылар кебек әллә нинди чит ил кремнары сөртмәсә дә, аның чибәрлегенә таң кала торган идем. Сокланып, яратып яшәдем. Минем өчен ул нурлы, якты бер чәчкә иде! Менә шундый соклангыч, алтын киңәшләрен биргән Әлфия апам. Ул шаяртып сөйләшергә бик тә ярата иде. Хәзер уйлыйм: шаярту артында сагыш-кайгыларын яшергән, күрәсең. Ул беркайчан гайбәт сөйләмәде, гайбәт сөйләгән җирдә тормады. Син ишеттеңме, дисәләр, күрмәдем, ишетмәдем, дип кенә җавап бирә торган иде. Авылда туып-үсеп, балалар йортында тәрбия алган кызда кайдан шулкадәр интеллигентлылык, зәвык, кешелеклелек булганлыгы олы табышмак! Гасырларга бер генә туа торган бөек моң иясе белән очрашып, бер юлда йөргәнемә, бер сәхнәне бүлешкәнебезгә язмышыбызга чиксез рәхмәтлебез! Без – Әлфия апаның җырларында тәрбияләнгән буын, аның эшен дәвам итүчеләр. Татар моңнары яшәгәндә, әлбәттә инде, милләтебез дә, шушы милләтнең яшәешенә күп көч керткән бөек кешеләрнең исемнәре дә яшәр!



Земфира һәм Тәлгать
САНАТУЛЛОВЛАР,
күршеләре



Июль урталары, бик кызу көн иде. Гадәттәгечә, эштән кайтып барабыз. Ишегалдында, агачлар астындагы утыргычта Әлфия апа утыра. Әз генә моңсурак та. Исәнләштек тә өйгә кереп киттек. Авыл тавыгы белән токмачлы аш пешереп алдым. Тәрәзәдән карыйм. Әлфия апа һаман да ишек алдында утыра. Йөгереп чыктым да: «Әлфия апа, әйдә, керик әле. Әзрәк авыл сыйлары да бар», – дим.

– Якташ (шулай эндәшә иде ул миңа), ике сәгать вакытың бармы? Булса гына керәм, – ди. «Табарбыз, Әлфия апа», – дим. Аш салдым, авылдан килгән кызыл эремчек, каймак, ипи бар иде. Ашны бер-ике генә капты да, торып, әкрен генә бүлмә буйлап йөреп, тормыш юлларын, гастрольләрне, балаларын сөйләргә тотынды. Чәчне карэ рәвешендә кистергән, карадан әз генә сыеграк төскә, тырнаклар исә кызылга буялган (аягы кечкенә иде).

– Аяк тырнакларыңны да буягансың, Әлфия апа, – дим. «Миңа башкача килешми, мин артист кеше бит», – ди. Ул арада нидер исенә төште дә, кәгазьгә кызу-кызу хатирәләрен, ниндидер исемнәр язып куйды. «Китап чыгарабыз бит», – ди. Тагын йөри-йөри сөйли. Тормышының кызык хәлләрен дә, әче җирләрен дә исенә төшерә. Елатып та алды, күздән яшьләр чыкканчы көлдек тә. Өстендә бик килешле күлмәк. «Зөлфиям алып кайтты», – ди. Үзе һаман йөри. Ирем дә өйдә иде. Бераздан, эшләрем бар, дип ул чыгып китте. Шулай итеп, күршем Әлфия апа берүземә ике сәгать тормыш спектакленнән өзек күрсәтте. Соңыннан гына аңладым: ул аның бер концерт куярлык вакыты икән. Чәй дә эчелеп бетмәде, ярты чынаягы шулай утырып калды.

Ишегалдында Әлфия апа белән еш очраша идек. Төенчекләрен күтәреп чыга да, Кәримне көтәм әле, концерт белән районга бара идек, ул килеп алырга тиеш, дип утыра иде. Ул арада берәр кызык та сөйләп ала. Күңелләр күтәрелеп китә. Һәрвакыт шат күңелле, тормыштан бервакытта да зарланмас. Бар нәрсәдән тәм табып, яшисе килеп яшәде.

Бервакыт яз көне тәрәзә юып ятам. Ишектән кәккүк кычкыра кебек. Туктап тагын тыңлыйм: тагын кәккүк тавышы. Игътибар белән карасам, беренче каттагы кызлар белән тәрәзәдән сөйләшә, аларга кәккүк булып кычкырып күрсәтә икән Әлфия апа. Искитәрлек, чып-чын кәккүк тавышы...

Аякларыма физкультура булсын дип, көн саен ишек алдында йөреп керә иде. Соңгы юлга озатканда, барча күршеләр чыгып, ризалыгыңны биреп кит,

Әлфия апа; искитәрлек тулы тормыш белән яшәп, балаларыңның хөрмәтен, тәрбиясен күреп китеп барасың, дип калдык. Фаҗигале балачак та, авырлыкларга, данга да күмелгән, вакыты-вакыты белән кытыршы да, шома да барган чаклары күп булган «Әлфия Авзалова» дигән тормыш спектакленең. Кайчакта Әлфия апа яшәгән фатирның тәрәзәсендә ут күренсә, тагын күңелле булып китә. Хәзер инде аның моңы, җырлары сагындырып, күңелләребездә яши.

Зилә ВӘЛИЕВА,
«Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» директоры, «Татарстан хатын-кызлары» республика иҗтимагый оешмасы җитәкчесе



Үзенчәлекле, кабатланмас шәхес

Безнең татар сәнгате дөньясында халык күңелен яулаган даһи язучыларыбыз, олы шәхесләребез янында Әлфия апаның үз тоткан урыны бар. Бу якты йолдыз Татарстан күген мәңге балкытып торыр! Ул җыр-моңнары белән милләтебезне, татарлыгыбызны уятты. Аны җырчы-көрәшче, җырчы-сәясәтче, җырчы-илче, җырчы-дипломант, җырчы-агитатор һәм тагын әллә кемнәр дип тә атарга була. Ул бернинди сөйләм телен кулланмыйча, җыр аша оста итеп күңелләрне сугарды, тәрбияләде, үз артыннан әйдәде. Аның җырларын тыңлап, без бер милли сафка тезелә бардык.

Мин Әлфия Авзалованың «Яратам, дисең син» дигән җырын тәүге мәртәбә, кечкенә чакта ук, Уфада укыганда ишеттем. «Казан утлары» исемле инструменталь ансамбльгә кушылып җырлаган, тавышыннан, йөзеннән сихри нур сибелгән кыска итәкле яшь җырчы кызга кем генә игътибар итмәде икән ул заманда?! Ул – күзне дә алып булмаслык зәвыклы, башкалардан аерылып торучы җырчы иде. РТИ заводының «Юбилейный» дигән заманча культура бинасы төзелгәч, җырчылар читтән гастрольләр белән килә башлады. Әлфия Авзалова концертлары афишасын күргәч, әтием кассадан ике билет алып кайтты. Ул үзе дә гармунда өздереп, матур итеп уйный иде. Безнең шул чакта әтием белән концертка барганыбыз бүгенгедәй истә. Мин әле ул вакытта

мәктәптә генә укый идем. Ул чакта ук, бу җырчыны күрү, ишетү һәркемнең зур хыялы иде. Инде берәр кайчан аның белән аралашу бәхете дә тәтер, дип кем уйлаган? Инде Казанга килеп, газеталарда эшли башлагач, депутат булып сайланып, Парламентка күчкәч, концертларга даими йөри башладым. Ә инде хезмәт вазыйфам тулаем иҗат өлкәсенә кагылгач, Әлфия апа белән якыннан таныштым. Ул көнне мин аңа: «Әлфия апа, мин сезне кечкенәдән үк беләм, сез һаман да шул килеш матур!» – дип, эчке соклану белән, мактау сүзләре яудырган идем. Мин үз каршымда искиткеч гади, кеше яратучан, бай сөйләм телле, шаян, җор ханымны күрдем. Ул шулкадәр зур осталык белән, кирәк урында юмор куллана белә иде. Әгәр дә ул сатира-юмор сәнгатен сайлаган булса, бу өлкәдә дә аңа тиңнәр булмас. Кайберәүләр киң бәдәнле, олы гәүдәле була, ә Әлфия апа җаны белән зур кеше иде. Янәшәсендә утырсаң, үзеңне аның канаты астында хис итәсең. Аннан шулкадәр көчле энергетика бәреп тора иде. Аның белән сөйләшә башласаң, ихтыярсыздан аның күңел колына әвереләсең. Ул – хезмәтен җан кушуы буенча, бөтен талантын, бөтен көчен, күңел җылысын биреп башкарган шәхес. Алар эшләгән чорда бернинди шартлар да булмаган, әмма да алар, барыннан да риза булып, күтәренке рух белән, күңел биреп эшләгәннәр. Салкын клубларда, юк юллардан, мең газаплар аша вакытында барып җитеп, башкаларга күңел җылылыгын өләшкән бөек затлар алар.

Әлфия апа сөйләшкәндә, еш кына үткәннәргә кайтып килә торган иде. Әмма ул сүзләрдә бер зарлану, кемгәдер үпкәләү ише нәрсәләр булмады. Ул элек башыннан үткәннәрне кызык итеп, гыйбрәт булсын, дип кенә сөйли торган иде. Хәтта тыңлаучыда: «Күр әле, ул чорда нинди рәхәт булган!» – дигән фикер туа иде.

Җырчы буларак, Әлфия апа дәрәҗәсенә җитәрлек шәхес, бәлки, туарга, бәлки, үсәргә тиеш! Үткән гасырда эшләгән, бу гасырда якты эз калдырган кешеләр арасында бу бөеклеккә Әлфия ападан башка берәүне дә куясым килми. Бердән, ул – бик үзенчәлекле, икенчедән – кабатланмас шәхес. Кайтып, ул башкарган җырлар исемлеген карасаң, нинди генә бөек композиторлар әсәрләре юк аның репертуарында. Халык җырларын да югары профессиональ дәрәҗәгә җиткереп эшләргә тырышкан ул. Һәрбер әсәренең үзенчәлеген саклап, тамашачыны елата да, көлдерә дә алды. Мин аны танылган инглиз җырчысы – Эллафи Джеррари белән тиңләр идем. Аларның моңы каяндыр тирәннән чыга, шуңа күрә аның җырларын бөтен халык аңлый. Ул иҗаты аша моңның ни дәрәҗәдә көчле хис икәнлеген аңлата алды. Ул бик бай күңелле кеше иде, башкарган җырларында да шул тирәнлек сизелә. Ул – табигый талант иясе, табылдык хәзинә, асылташ! Чишмә үз юлын тапкандай, Әлфия апа үз тырышлыгы, таланты белән үзен-үзе тудырган, үзенә юл салган шәхес! Кешелеклелеге белән дә, ижади таланты белән дә аерылып тора. Минем өчен югарылык ул – ижади бәхәстә туган моң әсәрен башкалар-

га җиткерә алу. Гөлшат Зәйнашева һәм Әлфия Авзалованың иҗат җимешләре нәкъ шундый шартларда туып, халык күңелен яулады. Без бу зыялы ханымнарга мәңге рәхмәтле! Алар үз эшләренең чын осталары иделәр. Мин, шулай ук, бу ханымнарның кешелеклелек сыйфатларын ассызыклыйсым килә. Алар биек оча торган кошлар иде. Алар беркайчан да түбән төшмәделәр, вакланып йөрмәделәр. Аларның юк-бар белән мавыгырга вакытлары да, теләкләре дә булмады. Җирдә яшәгәндә һәр минутларының кадерен белеп, янәшәдәгеләргә җан җылысы өләште алар. Һәрбер иҗат иткән җырлары канатланып илләр гизде, күңелләргә оя корды. Аларны халык мәхәббәте тудырды, халык мәхәббәте яшәтте, үлемсез итте! Ә бит халык мәхәббәтен сатып алып булмый! Алар бит, хәзерге эстрада йолдызлары кебек, үзләре турында төрле юк-бар сөйләп, мактанып йөрмәделәр. Халык аларны җырлары, моңнары аша таныды. Безнең сәнгатебез менә шушы югарылыктан төшмәскә тиеш! Әгәр дә милли кыйммәтләребез сакланмый икән, ул чакта инде сәхнәләрне төрле төсләр белән бизәүдән, балкытудан мәгънә булмаячак. Тагын бер мөһим шарт: халык күңелен уку, ишетү сәләте булырга тиеш! Менә бу сыйфат та Әлфия апада көчле иде. Ул репертуарын һәрвакыт халык күңеленә ятышлы җырлардан гына төзеде. Икенче көнне үк ул җырларны халык отып алып җырлый торган иде. Аның бер генә җыры да онытылмый, ә чит ил җырларын башкару да ул заман өчен зур яңалык, зур алга китеш иде. Нинди генә телләрдә җырласа да, бер куплетын, халык аңласын өчен, татарчага тәрҗемә иттерде. Бу эшне дә алар ахирәте, иҗатташ дусты Гөлшат апа Зәйнашева белән башкардылар. Талант ул – аерым кешеләргә Аллаһы Тәгаләдән бирелә торган сәләт. Җирдәге кешелек өчен алар зур бүләк! Ә талант иясенә бу әйтеп бетергесез зур бурыч, йөк. Ул бу исемне гомере буе лаеклы йөртергә, халык алдында да, Ходай алдында да акларга тиеш. Бу – бик зур вазыйфа. Һәркем абынып егылырга мөмкин, тик менә менгән биеклектән төшмичә канат кагыну бик тырыш, үҗәтләргә генә бирелә. Өстәвенә, ул бит әле хатын-кыз, Ана да! Ул йортында да өлгерергә тиеш, сәхнәдә дә кешеләргә бәйрәм ясап елмаеп торырга тиеш. Сәхнәдәге кешенең бөтен ягы да халык күз алдында. Халыкның күзләре үткен, колаклары – сак! Ул сине шул минутта бәяли. Сәхнә ул – тормыш көзгесе. Ул сине ничек бар, шулай күрсәтә. Сәхнә һәм тормыш кануннарының барысын да аңлап, үзенә тиешле миссияне җиренә җиткереп үтәп киткән кеше ул Әлфия апа! Күпме генә буыннар алмашса да, Әлфия апаның җырлары үз дәрәҗәсен югалтмаячак, моң аның үлчәме белән үлчәнәчәк! Ул җырлар заман белән бергә атлаячак! Аның репертуарындагы җырларга кабат-кабат кайтырга, яшь буынга моң, тәрбия дәресләре итеп бирергә кирәк. Безнең бурыч – бу җырларны, бу исемне онытмау, киләчәктә безне – Тукай, Сәйдәш, Әлфия, Илһам моңнары аша танысыннар иде!

Зилә СӨНГАТУЛЛИНА,
җырчы, Татарстанның,
Каракалпакстанның һәм Россиянең
халык артисты



Һәр җыры тамаша иде

Мин әниләр янында авылда яшәгәндә, йортыбызда радиодан гел татар җырлары яңгырап торды, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалованың кабатланмас моңнары кечкенәдән күңел түрендә уелып калды. Авылыбыз – 3 мең йортлык татар авылы, танылган язучы Нәкый Исәнбәт туган авыл. Күңелем кечкенәдән гел татарлар арасына, Казанга омтылды. Әлфия апаны тәүге тапкыр күрүем 1964 елда Уфада булды. Мин әле яшүсмер кыз гына, бары 14 яшь, Уфада яшәүче апаларыма килеп, музыка училищесына укырга кереп йөргән чагым. Апа мине Әлфия Авзалова концертына алып барды. Ул чакларда бөтен халык, исе китеп, елап-елап, һинд киноларын карый. Әлфия апа халык күңелен бик нык тоемлаучы җырчы буларак, үз репертуарына һинд җырын керткән. Һинд музыкасы башлануга, халык әллә нишләп китте, ул музыкага Әлфия апа моңы да кушылгач, күзләргә яшь килеп тыгылды. Ул, шулай итеп, тамашачысының күңеленә май салды. Мин шулчак, бу җырчыны ишетү генә аз, үзен дә күрергә кирәк икәнлеген аңладым. Аның сәхнәдә үз-үзен табигый тотышы, зәвыклы киенүе, андагы энергия, темперамент бер генә тамашачыны да битараф калдырмый. Ул – татар җыр сәнгатен орлыгыннан алып җимешләренә кадәр үз тырышлыгы белән булдырган асыл зат. Элек-электән Башкортстан да, Татарстан да моңлы җырчылары белән дан тотты. Ул заманнарда бу бөек җырчылар исемлегенең башында: Башкортстанда – Фәридә Кудашева булса, Татарстанда – Әлфия Авзалова иде. Әмма бу ике җырчының талантын берничек тә бер үлчәмгә куеп үлчәп булмый. Фәридә апаның моңы салмак кына, тыныч кына, тын гына агылса, Әлфия апаның моңы кайнап торган диңгез шавына тиң иде! Ул – чын халык артисты! Шуңа да халык моңлы кызын шулай үз итте, зурлады, хөрмәтләде, яратты, иҗатына табынды. Мондый бөек җырчылар гасырга бер генә туа дыр. Аның бөеклегенә әле беркемнең дә күтәрелгәне юк, чөнки мондый табигый талант ияләре бик сирәк туадыр! Әлфия Авзалова ул – татар иле, татар җыры, моңлы Татарстан! Әле бу аңнарыбызга барыбер сеңеп бетми. Аңласын иде җитәкчеләр, сәнгать әһелләре: бөтен татар җырчыларының моң кыйбласы – Әлфия Авзалова. Бары да менә шушы биеклеккә омтылсын иде.

1968 елда мин Казанга күченеп килдем. Инде Казанда яшәвемә дә – ярты гасыр. Язмышыма бик тә рәхмәтлемен! Мин Әлфия апа белән бергә бик күп гастрольләрдә булдым, бергә бик күп чыгышлар ясадык. 2008 елда бөтен нефть чыгучы шәһәрләрне гиздек. Аның белән кичергән рәхәтлекләр, кызыклар, үзе бер зур китаплык. Без-өлкәннәрне үзләренең санаторийләрендә ашату-эчертү, дәвалау дисеңме, берсе дә калмады. Әлфия апа кечкенә генә яхшылык эшләгән бәндәне дә мәңге онытмый. Ул аны, сәхнәгә менеп, биш-алты тапкыр арттырып мактап, күңелен күрмәсә, ул инде Әлфия апа түгел. Әлбәттә, мондый рәхмәтләр ишеткән кешенең яхшылыкны тагын да кыласы килә. Менә бит аның тәмле теле – җан азыгы иде! Хәзер генә кайберәүләр сәхнәгә менеп бер-ике җыр башкарса, үзләрен йолдыз дип саный... Әлфия апа кебек бөек җырчылар – гади, әмма үз бәясен белә торган шәхесләр. Ул да талантлы икәнен, үз урынын белде, әмма аңа карап шапырынмады, тыйнак иде. Кирәк чакта, гаделлекне эзли дә, таба да иде. Ул үз-үзен хөрмәт итмәсә, аны халык та санга сукмас иде. Ул кайсы биеклектә, кайсы пьедесталда торасын бик яхшы аңлап эш итте. Бик көчле әйдаман булды, аның артыннан меңнәр иярде, ул салган юл беркайчан да тайгак булмады.

Җырчы гына түгел, җырчының тавыш мөмкинчелекләре дә төрле баскычларны уза, ул иң элек – бөредә генә булса, аннан, чәчәк тажларына әверелә, соңрак шау чәчәккә күмелә. Әлфия апаның да тавышы иң элек челтерәп аккан чишмәдәй иде, ә менә соңгы елларда ул шаулап чәчәк атты! Шундый кеше күңелен уята торган көр тавышка әверелде, гомумән, ул – төрле тембрлы тавыш белән җырлый алучы алтын тавыш, күпкырлы талант иясе! Без аны романслар башкаручы, бөтен татар классикларының әсәрләрен җырлап чыккан илаһи моң иясе буларак та беләбез. Татар музыкасына джазны да бит Әлфия апа керткән. Үз репертуарына төрле халык җырларын файдалану да иң беренче аннан башланды. Башкалар борын астыннан мырылдап хромкага җырлап торганда, авылдан килгән бер гади татар кызының шулкадәр көч-кодрәтенә ничек сокланмыйсың да, ничек горурланмыйсың! Алай гынамы, Әлфия апа җырлаган һәрбер җыр – бер спектакль, тамаша була барды. Тамашачы онытылып җырга кереп китә, ул җыр белән яши, җырчы кичергәнне ул да кичерә. Аның сәхнәдә халык белән аралашу осталыгы да берәүгә дә бирелмәгән байлык. Тамашачы белән җырчы арасында бушлык юк, күңелләр – күңелгә, җаннар – җанга тәңгәл. Хәзер уйлыйм да, бу минем иң матур ижат елларым булган икән, дим. Егылып-егылып көлә идек, күңел шат, дәртле, безгә боларның барысын да бетмәс энергия чыганагыбыз – Әлфия апа өләшкән! Аның концертларга әзерләнүе дә үзенчәлекле иде, әмма ул бик тә дөрес булган. Безнең тавыш резонаторлары бар, сәхнәгә туп-туры чыгып җырлаганда әле алар уянмаган булырга мөмкин. Әлфия апа аларны, ымлап, алдан уятып, әзерләп куя торган иде. Аның җырны тоемлавы бик тә көчле иде, ул – үз эшенең чын профессионалы! Без, студентларыбыз белән,

нәкъ шуның өстендә эшлибез дә бит, сулышны дөрес итеп куйсаң гына матур талгын, өзлексез моң агыла... Әлфия апага бу талант тумыштан бирелгән! Шунысы гаҗәп: кешедә талант йә була, йә юк!

Ә Әлфия апаның кешелеклелек сыйфатларына килгәндә, аның өчен – идән юучы да бер, министр да бертигез булды. Аңа урамда бер чит кеше «Әлфия апа», дип эндәшсә, ул хәлләре бетеп, вакыты бармы-юкмы, тукталып аның белән сөйләшә торган иде. Менә шушы чамадан тыш гадилек, минемчә, даһилекнең беренче күрсәткече! Мин аны хәтта бөек музыкант Растропович белән чагыштырыр идем. Ул да бит – гаҗәеп гади, кешелекле, үзе буй җитмәслек бөек!

Аннары ул, әйткәнемчә, бик тә зәвыклы иде, аның бу зәвыклылыгын бизәнүендә дә күрергә мөмкин. Чама белән, килешле төсләрне генә алып, табигый матурлыгына хилафлык китермичә генә бизәнә иде. Бу сыйфатына да соклануымны яшермим. Дулкын-дулкын чәчләре, хәтерләгез әле, ничек матур булып, берсе өстендә берсе, дулкыннар кебек, уйнаклаша иде. Ул беркайчан да сәхнәгә тузган килеш-килбәт белән чыкмады. Юлларда ат арбасында тәүлекләр буе килгән, арыган, йончыган ханым дип, аны беркем дә, беркайчан да әйтмәс. Бер генә җырга да концерт номерларын киметмичә, киресенчә, тамашачы сораган һәр җырны башкарып, тамашачының күңеле булганчы чыгыш ясый торган иде. Инәдән-җептән киенә, дип, нәкъ менә Әлфия апага әйтелгәндер төсле. Аның һәрбер хәрәкәте табигый, үзенә тартып тора, караган саен карыйсы килеп, тамашачыны үзенә җәлеп итә. Әйтерсең, ул аларны сихерли, күзгә күренмәс сөйкемле сөяге бар! Рәхәтләнеп, Әлфия апа кебек, ихлас көлгән кеше генә менә шундый яраттыра һәм ярата ала торган кеше була, минемчә. Ул, ичмасам, көлсә, рәхәтләнеп, чын күңеленнән көлә иде. Ул шулай тормышын җиңеләйткән, күңелендәге авыр уйлардан арынгандыр инде, күрәсең... Ул беркайчан да үзе өчен генә җавап бирмәде, тулы бер бригада өчен җавап тотты. Үз гаиләсе өчен генә тырышмады, аларның барысының гаиләсе тук булсын дип, башын иде, кирәксә – елмайды, кирәксә – елады...

Республика җитәкчелеге Әлфия апаны һәрвакыт хөрмәт итте, зурлады. Чиксез зур рәхмәт беренче Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиевка! Аның юбилей кичәләрендә Минтимер Шәрипович Әлфия апаны якташы итеп кенә түгел, милли җәүһәр буларак бәяләп, аңа карата матур, тәмле сүзләрен беркайчан да кызганмады, аңлады, кадерен белде. Ул аны, син – бөтен халык байлыгы, дип зурлады. Чыннан да, аны бөтен халык ярата, ә башка җырчыларның, хәтта танылганнарының да үз җанатарлары, үз мохите генә. Шул ук исәптән, минем дә үз даирәм. Бөтен халык кабул иткән, чын талантлар күп булмый, бармак белән генә санарлык. Язучылар арасында – Габдулла Тукай, җырчылар арасында – Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова. Сәхнә – ул кешенең көзгесе, анда менеп бер җыр башкаруга, халык сиңа үз бәясен бирә. Әлфия апаның җыры һәркемгә аңлаешлы булды, кешеләр

күңелен – сандугачтай моңы, җанга ятышлы аңәһе белән яулады. Әлбәттә, аның язмышы, тормыш юлы сикәлтәсез генә булмады, ул аларны көчле рухы, максатчанлыгы, сабырлыгы белән җиңә килде. Юлында көнчелләр, усаллар да күп очрагандыр, әмма аның иң тугры юлдашчысы – моң булды. Ул матурлыкны яратты, аның күңел күзе гел яхшылыкта гына иде. Башкаларга матур хуплау сүзләрен кызганмады. Миңа карап та: «Әй матур да инде син, Зилә, күрче ул билләреңне, королева, тавышың нинди матур!» – дип әйтүләрен ярымшаярту дип, рәхәтләнеп кабул итеп, шаркылдашып көлә идек. «Иң яхшы гадәтең: син дә, минем кебек, кеше сөйләп йөрмисең, гайбәт сөйләргә яратмыйсың. Менә шул ягыңны яратам», – ди торган иде. Юктан да кызык табып, кеше күңелен күтәрү – бер талант бит. Нинди авыр балачагы узып, ялгызы ике бала үстергән ананың безне яратып, киң күңелле булып, беркемгә тавыш күтәрмичә, бөек зат булып яшәве безнең һәрберебезгә үрнәк! Ул һәркемгә дә ихтирамлы, игътибарлы булды. Ниндидер бер концертта мин, гадәттәгечә, Илһам абый белән Әлфия ападан алданрак чыгыш ясадым. Ул пәрдә кырыеннан мине күзәтеп тора. Тиздән аның чыгышы булуына да карамастан, чәчләрендә бигудиларны да салмыйча тын калып мине тыңлавы, баш бармагын күрсәтеп, шәп җырлыйсың, дип бәя биреп торуы бүгенгедәй күз алдымда. Аннары мин чыгыш ясап бетергәч, тын да алмый, биек үкчәләремне дә салмыйча, Әлфия апа белән Илһам абыйның чыгышын күзәтә торган идем. Аларның сәхнәгә чыгышын да халык бит аягүрә басып алкышлады, җыр тәмамлангач, алкышлар бик озак тынмый иде. Мин алардан күп тәрбия алдым. Язмышымда Әлфия апаның очравы – минем өчен зур горурлык! Җырчы булырга хыялланган һәрбер кешенең репертуарында Әлфия апаның җыры яңгырарга тиеш. Аның берәр җырын матур итеп башкара алмаса, ул җырчы түгел. Аллаһы Тәгалә биргән сәләтен дөрес кулланып, халкына тугры хезмәт иткән, телен, милләтебезне саклауда зур тырышлык куйган әлеге бөек җырчыбызга без генә түгел, әле бик күп буыннар табыныр. Минем иҗатымда да Әлфия апаның роле зур, чөнки 14 яшемнән – аны беренче мәртәбә күргәннән бирле, максатыма туры атладым. Аның иҗаты белән юлларыбыз очрашкач, остазымның тырышлыгын, максатчанлыгын үземә өлге итеп алдым. Милли моңны яшәткән олы җанлы бөек татар җырчысы Әлфия Авзалованың җырлары әле дә ватанпәрвәрлек тәрбияли, уйлата, юата, уята. Милләтебез йокламасын, телебез яшәсен, дисәк, Әлфия апаның җырларын үзебезгә корал итеп алыйк!

Зөлфия *һәм* ***Җәвит ШАКИРОВЛАР,***
җырчылар,
Татарстанның
һәм Башкортстанның
халык артистлары



Филармониябез кояшы

Артистларыбызның кайсысына гына тукталсаң да, күз алдына аларның тормыш юлы, иҗаты килеп баса.

Юллар аша, еллар аша, җырлар аша халык күңеленә сукмак салган, татар җыр сәнгатенә зур, бәяләп бетергесез мирас калдырган шәхесләр бик күп. Аларның һәрберсе мактауга, хөрмәткә лаек.

Һәр чорның үз геройлары – халык яраткан, һәр адымын күзәтеп барган, иҗат биографиясенең өтерен, ноктасын да яттан белгән сәнгатькәрләр бар. Халык телендә андый шәхесләр турында, күз өстендәге каш, дип әйтәләр.

Бу сүзләр нәкъ безнең өчен, татар-мөселман дөньясы өчен яратылган бөек җырчыбыз Әлфия апа Авзаловага шулкадәр туры килә. Ничә еллар кабатланмас моңлы тавышы, бик күп телләрдә җырлавы, кайда гына чыгыш ясаса да, татар кызы булуы белән горурланды, гадилеге, шаянлыгы белән таң калдырды ул.

Әллә инде җырларында халык язмышы өчен борчылып, шатланып яшәгәнгә микән, Әлфия апага хөрмәт беркайчан да кимемәде.

Без – Зөлфия белән икәүләп, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә килгәндә, Әлфия апа, Илһам абыйлар турында, аларның җырлары аша, газеталарда басылып чыккан мәкаләләр аша барысын да белә идек кебек.

Әмма без белгәннәр – күлдәге тамчы гына булган икән. Инде бер оешмада эшли башлагач, гастрольләр арасында филармониядә очрашканда, бу шәхесләрне үзебез өчен яңадан ачтык.

Әлфия апа филармониянең кояшы иде. Ул эстрада бүлегенә килеп кергәндә, кояш чыккан кебек була.

Башка артистлар гастрольдәге авырлыклар турында сөйләшеп, бер-берсенең гайбәтен сөйләп, зарланып, яхшы эшләгән коллективларның уңышларыннан көнләшеп авызларын турсайтып утырганда – Әлфия апа ки-

леп керер иде дә, гастроль вакытында булган бер-ике мәзәк сөйләп, шундагы мохитне бөтенләй яхшы якка үзгәртеп чыгып китәр иде.

Без – яшьләр, аның кыланмышына, сөйләгәненә таң калып карап тора идек. Аңардагы дәрт, шаянлык, оптимизм безне шаккатыра.

Артистлар гастрольдан кайткач, бер-ике көн филармониягә килми иде. Айлар буе концертлар куеп йөргәннән соң, өйдә дә торасы килгәндер инде. Әлфия апа гастрольдән кайчан кайтса да, иртән филармониягә килә. Аның филармония капкасыннан килеп кергәнен күрүгә, урамда торган артистлар хөрмәт күрсәтеп, сәлам бирергә ашыкты.

Үзеннән-үзе, аңа ияреп, эстрада бүлегенә керә идек. Чөнки хәзер нәрсәдер була: я берәр кызык хәл, я яңалык көтә идек Әлфия ападан.

Аннары ул үзенә генә хас шундый шаяру белән: «Илһаметдин мондамы?» – дип сорап куя. Үзара сөйләшкәндә дә Әлфия апа Илһам абыйга Илһаметдин дип дәшә.

Минем Әлфия апа белән очрашуым бик күп еллар алдарак булды. 1986 елда үзебезнең Чакмагыш районындагы Тайняш авылында мәдәният йорты директоры булып эшләгән чак. Район мәдәният бүлегеннән миңа шалтыратып, районга Әлфия Авзалова гастрольгә килә, афиша, билетларны килеп алырга кирәк, фәлән-фәлән көнне концерт була, диделәр.

Барып алдым. Ул вакытта артистларның төсле портреты белән эшләнгән афишалар бик сирәк була иде. Аны клубларга бер-ике данә генә бирделәр. Мин Әлфия апаның шул төсле афишасын үзебезнең директор бүлмәсенә элеп куйганым әле дә истә.

Ул вакытта Әлфия апа бригадасында Минхәмәт Гыйләҗев, Кирам Сатиев, Кәрим Габидуллин һ.б. эшли, концертны Нәҗия апа Минкина алып бара иде. Концерттан соң, сәхнәгә чыгып, рәхмәт сүзләрен әйткәнем бүгенгедәй хәтеремдә.

Зөлфиянең Әлфия апаны беренче тапкыр күрүе тагын да иртәрәк булган икән. «Миңа 7-8 яшьләр тирәсендә Әлфия апа Югары Аташ авылына концерт белән килгәч булды, – ди Зөлфия. – Әти-әниләр концертта, халык шыгрым тулы, урын булмаганлыктан, балаларны залга кертмиләр. Без урамнан, тәрәзә аша концерт карадык», – дип искә ала Зөлфия. Чөнки эссе җәй көннәрендә концерт булган вакытта тәрәзәләрне алып куялар иде.

Яраталар иде Әлфия апаны. Безнең Чакмагыш районы тамашачылары бигрәк тә. Район Сабантуена килеп чыгыш ясаганнарын да хәтерлим. Башкортстанда гастрольдә булганда, безнең районга кермичә калмый иде Әлфия апа.

Ә инде соңгы елларда, Әлфия апаның юбилейларын әзерләгәндә, сценарий авторы буларак, легендар җырчыбызны икенче яктан ачарга туры килде.

Сценарийны язгач, беренче булып филармония директоры Кадим Ну-

руллинга күрсәтә идем. Ул киңәшләрен бирә: «Әлфия апа болай әйткәнне бик яратмый, болайрак итик, бу тирәсендә шаяртып алырга кирәк, монда җитдирәк булсын», – дип, төзәтмәләр кертә, аннан инде сәхнәдән халыкка тәкъдим иттек.

Күңеле яхшы кешенең эше дә күңелле уза. Әлфия апаның юбилей кичәләре шундый җай гына үтә – бернинди авырлык, аңлашылмаучанлык булмый. Чөнки ул хата эзләми, берәр сорау туса – Шакир (ул миңа шулай дәшә), үзең беләсең, энекәш, ничек кирәк – шулай эшлә, ди торган иде.

Филармониядә тагын бик матур бер традиция бар. 90нчы елларда, көзге айларда – филармониянең концерт сезонын ачу. Бөтен артистлар катнашында концерт белән Татарстан, Башкортстан, Удмуртия шәһәрләрендә гастрольләр оештырабыз. Без инде аны көтеп ала идек, чөнки автобус тулы артистлар. Җәйге яллардан соң сагындырылган. Хәл-әхвәлләр, яңалыклар сөйләшә-сөйләшә, өлкән артистларның сүзләрен тыңлап, күпме юл үткәне дә сизелми кала.

Әлфия апа белән Илһам абый гел янәшә утырып баралар. Берсеннән-берсе кызык хәлләрне сөйләп, көлешерләр иде. Безгә бик тә кызык, күңелле.

Еллар үткәч кенә шушы мизгелләрнең никадәр кадерле, кыйммәтле икәнен аңлыйсың икән. Их, шул чаклар!

Гастрольләрне ярата иде Әлфия апа. Чөнки халык белән очрашу, аралашу аңарга яшәр өчен көч, дәрт биргәндер. Сәхнәгә чыгып җырлау гына түгел: шул изге сәхнәгә барып җиткәнче, күпме газаплы, авыр юллар, йокысыз төннәр үтәсе барлыгын үз җилкәсендә татыган артист кына белә.

Юллар дигәннән, миңа Салават дустымның Мәскәүдә үткән концертларында катнашырга туры килде. Бару-кайту – автобуста. Бөтен уңайлыклары бар: ятсаң – ятарга, утырсаң утырырга була. Юл бит ул – ничә сәгать барасы, барган көнне концерт. Барлык артистлар да йоклый. Тик машина йөртүче һәм Әлфия апа гына, керфек тә какмый, юлны күзәтә.

– Әлфия апа, ник йокламыйсыз? – дип соравыбызга, ул:

– Бу рәхәт тормышны йоклап уздырасым килми, – дияр иде.

Бәлки, шул вакытларда яшь буынга, үзенә алмашка килгән, үзен, ижатын хөрмәт иткән, үзенә әниләрчә игътибарлы булган Салаватка, Ходайга рәхмәт әйтеп, эченнән генә дога кылып, хатирәләрен яңартып, үткәннәрен барлый-барлый, юлга карап уйланып баргандыр.

Әйе, уйларның, юлларның чиге юк.

Әлфия апаның җырлары – уйландыра.

Әлфия апаның моңнары – сокландыра.

Әлфия апаның ижаты – таң калдыра!

Зөһрә СӘХӘБИЕВА,
җырчы,
Татарстанның халык артисты



Чорыбызның мәшһүр кызы

Әлфия Авзалова – чорыбызның легендар шәхесе. Ул – үзеннән алда килгән затлы җырчылар – Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Мәрьям Рахманкулова, Галия Гафиятуллина, Зөләйха Хисмәтуллина, Разыя Тимерханова һәм башка мәшһүрләрнең татар классик җырларын башкару традицияләрен дәвам итүче, татар җыр сәнгате үсешенә үзеннән зур өлеш керткән җырчы. Казан Дәүләт консерваториясендә укыганда ук минем вокал буенча укытучым, опера театры солисткасы Зөләйха Хисмәтуллина: «Әлфия Авзалова – халкыбызның җәүһәре, энҗе бөртеге!» – дигән иде. Дөньядагы иң сирәк тавыш иясе, опера җырчысы, остазыбыз Зөләйха Хисмәтуллина аны татар халык җырларының мәгънәсен, бөтен нечкәлекләрен тирәнтен аңлап, үзенчәлекле итеп башкаргаы өчен хөрмәт итте.

Ишетеп белүемчә, Әлфия Авзалова үзенең иҗат юлын Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә башлап җибәргән. Аның табигый таланты, матур тембрлы тавыш мөмкинлекләре зур булганлыктан, ул тиз арада ансамбльнең башлап җырлаучы солисткасына әверелә. Мин тәүге мәртәбә бу матур тавышлы җырчыны үсмер чагымда, авылыбызның кечкенә генә радиосы аша ишеттем. Шул чордагы аның данлыклы ансамбльгә кушылып башкарган «Кәккүк»ге, «Болын»ы һәм башка җырлары мине әсир итте. Мин аның һәрбер җырын, һәрбер чыгышын зур түземсезлек белән көтеп ала торган идем, ул җырлаган һәрбер әсәрне өйрәнә бардым. Халык арасында бик тиз популярлык казанган җырчыга Габдулла Тукай исемендәге филармония җитәкчелеге үз бригадасын оештыра. Эстрада бүлеге артистларына бервакытта да дәүләтебез тарафыннан дотация бүлеп бирелмәде.

Артистлар еллар әйләнәсендә гастрольләрдә йөрде. Бөтен чыгымнарны күтәрү, шуның өстенә, дәүләт казнасына акча алып кайту да труппаның төп җырчысы җилкәсендә иде. Җырчыга халык ургылып йөрсә генә, хөкүмәт куйган планны үти алса гына, ул үз бригадасын тота ала. Әгәр бу таләпләргә җавап бирә алмаса, бу бригаданы таркаталар. Казан Дәүләт консерваториясенең вокал факультетын тәмамлаганнан соң, мин дә филармониягә чакырылдым. Озак еллар Әлфия ханым белән бөек Тукай исе-

мен йөрткән филармониядә бергә эшләү насыйп булды. Сагынып сөйләрлек, истә калырлык матур хатирәләр бик күп. Төрле бригадаларда йөрсәк тә, безне бер максат – халкыбыз җырларына олы мәхәббәт, җыр-моңнарыбызны халыкка тарату, милли моңыбызны саклау, киләсе буыннарга илтү теләге берләштерде. Бу бурычын Әлфия ханым тулысы белән үтәде, үз халкы алдында йөзе ак аның. Гастрольләрдә инструменталь ансамблгә кушылып җырлаучылар арасында да ул беренчеләрдән булды. Дөнья буйлап таралган халкыбызның Әлфия Авзаловага карата булган мәхәббәте бинихая көчле иде.

Яшьли ятимә калган кызны туган ягы Актаныш та үз итте, якын итте. Ул үзе дә якташлары янына, җылы яктан кайткан сандугач кебек, канатланып, сагынып кайта торган иде. Әлфия ханым бригадасы һәрвакыт тату, дус булды, бервакытта да музыкантлар алмашынып, китеп йөрмәделәр. Без, күчмә кошлар кебек, иртә яздан – көзгәчә, кыштан – язгача, гастрольләрдән кайтып кермәдек. Хәзерге җырчылар тормышы белән элеккеге җырчы тормышы – җир белән күк аермасы. Ат чанасында да, җәяүләп тә, ватык-җимерек машина әрҗәләрендә дә йөрде ул заман җырчылары. Ягылмаган салкын авыл клубларында юка күлмәктән генә елмаеп җырлап торган Әлфия ханым – соңгы көненә кадәр сәхнәгә гашыйк бер мәҗнүн җан булып кала бирде. Уфтанмады, авыр димәде, зарланууны, гомумән, белмәде. Иҗнәребезгә күтәрә алмаслык авыр кайгы килгәндә, алар ижатташ дусты Гөлшат Зәйнашева белән өебезгә килеп, Хәйдәр белән мине юатуларын мәңге дә онытасым юк. Әлфия ханымны Хәйдәр дә бик хөрмәт итте, бик яратты.

Әлфия ханымга төрле яклап сокланырлык! Ул – бөтен тормыш авырлыгын нәфис иҗнәрендә тартып барган батыр йөрәкле хатын-кыз, олы җанлы Ана да бит әле! Һәрвакыт игътибар үзәгендә булып, тормышының караңгы якларын тамашачыга күрсәтмичә, халыкны әйдәп, җырлары белән көч биреп, татар дөньясын яңгыратып яшәгән бөек җырчы ул! Мин моны хезмәт кенә дип түгел, ә геройлык дип атар идем! Мин аның зирәклегенә, хәйлә-акылына, тәвәккәллегенә һәрвакыт сокландым. Тормыш мәктәбен халыкның үзеннән чумырып алган гажәеп шәхес. Үзе кебек матур, үҗәт ике кызны ялгыз башкае ничек үстергәнен ул үзе генә белгәндер?! Бервакытта да зарланмады, күңел төшенкелегенә бирелмәде. Киресенчә, безнең хәлгә кереп, күңелне күтәреп, кулыннан килгәнчә изгелекләр кылып яшәде яраткан җырчыбыз, кабатланмас тавыш иясе Әлфия ханым. Ике күз нуры – кызларын гел канаты астында үстерде. Олы кешегә дә авыр булган сәфәрләрдә, чемодан өстендә йоклап үскән кызлар – бүген инде үзләре әниләр. Әйе, ул гасырларга бер туа торган талант иясе, әмма мондый талантың булып та, тормышта югалып калырга да бик мөмкин. Әлфия ханым, үтмәстәй упкын-киртәләрне узып, үзен-үзе тудырган шәхес. Аның турында язганда Җырчы сүзен дә, Ана сүзен дә зур хәрефләр, алтын хәрефләр белән язарга кирәк! Зур хөрмәткә, олылауга лаек ул Әлфия Авзалова!

Бер вакыйга исемнән чыкмый. Матур язларның бер иртәсендә филармониягә килдем. Безнең, төркем-төркем булып, очар кошлар кебек, ерак юлларга чыгып китәргә әзерләнгән чагыбыз иде. Күрәм: филармония каршысында – автобус, автобус тирәсендә – Әлфия Авзалова төркеме артистлары. Аларның гастрольгә чыгып китә торган көне икән, бар да дүрткүзләп Әлфия ханымны көтәләр. Берзаманны бер кулы белән бала утырткан арба тартып, икенче кулы белән әз генә зуррак бала җитәкләп, Әлфия Авзалова килеп җитте. Бу юлы аның гастрольгә оныкларын иярткән алып баруы икән. Менә шулай итеп җир тырмашып яшәде, эшләде ул.

Туган телебез, җырыбыз, моңыбыз яшәсә, милләт яшәр! Әлфия Авзалова – халкыбызны нәкъ менә туган телебез, милли моңыбыз тирәсендә туплаучы, милләтебез сагында торучы шәхесләребезнең мәшһүрләреннән. Сәнгатьне иңнәрендә күтәреп барган эстрада җырчысы тормышы читтән генә ал да гөл булып тоела. Бу бик авыр юл. Аны сирәк кеше генә күтәрә ала. Әлфия ханым бөтен гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлады, соңгы көненә кадәр сәхнәдә булды, яраткан тамашачысы белән аралашып яшәде. Ул сәхнәгә чыгуга, халык дәррәү килеп кул чаба башлый торган иде. Аның һәрбер җыры татар җыр-сәнгатенең, мәдәниятенең алтын фондын тәшкил итә. Кеше китә – җыры кала! Әлфия Авзалова җырлары әле тагын бик күп килер буыннарны сөендерер һәм тәрбияләр, Иншаллаһ!

Зөһрә ШӘРИФУЛЛИНА,
җырчы, Татарстанның халык артисты,
Азат ХӘЛИМОВ,
музыкант, композитор, Татарстанның атказанган артисты



Аккош йөзгән кебек...

Хыялым тормышка ашты. Кечкенәдән җырларга яраткангамы, мин артистларга үлеп гашыйк идем. Бигрәк тә Әлфия Авзалова минем өчен илаһи тылсым, бер могҗиза иде. Иртән уянып күзләремне ачуга, бер генә теләк: Әлфия апа бүген радиодан җырлар микән, нинди икән ул Әлфия апа, бер генә күрәсе иде үзен, дигән уй биләп ала торган иде күңелемне. 7 нче сыйныфта укыганда, Сарманга Әлфия Авзалова килә, дигән хәбәр таралды. Чатнама

суык кыш иде. Концертына эләгеп булмасмы дип, мин дә клубка юл тоттым. Ул вакытларда мәктәп укучыларын концертларга бик кертмиләр иде. Мин, клуб тәрәзәсендәге бозны тыным белән эретеп, Әлфия апаның концертын башыннан ахырына кадәр урамда басып карадым. Шулкадәр бирелеп карагамын ки: битемнең өшегәнен кайткач кына сиздем. Әлфия апаны беренче күрү шатлыгым шунда булды.

Еллар узды. Әлфия апаның җырларын, моңнарын тыңлап, аңарга охшарга тырышып, без дә үсеп җиттек. Музыка училищесының вокал бүлегенә укырга кердем, аны 1980 елда тәмамлап, Җыр һәм бию ансамбленә юллама алдым. Ул вакытта Җыр һәм бию ансамбле филармония составына керә иде. Айга ике тапкыр, хезмәт хакы алырга дип, филармониягә барабыз. Мин Әлфия апа белән Илһам абый килеп кермәсләрме икән дип, озак итеп филармония коридорында арлы-бирле йөрим. Шул тере артистларны күрсәм, күңелләрем булып кайтып китә идем. Дөньяда алардан да бәхетле кеше юктыр кебек тоела иде миңа. Әле дә хәтеремдә: Әлфия апаның бик матур, зәңгәр-ак борчаклы костюмы бар иде. Ул аңа шулкадәр килешә, гәүдәләре бик тә матур, аккош йөзгән кебек кенә узып китә...

1981 елда мине филармониянең эстрада бүлегенә кабул иттеләр. Илһам абый Шакиров төркемендә эшли башладым. Гомерем буе бер күргә хыялланган легендар шәхесләр белән бер түбә астында эшләү – минем өчен әйтеп бетерә алмаслык зур бәхет иде!

Тагын бер бәхетле мизгел: миңа Әлфия апаның Казанда гөрләп узган 50 яшьлек юбилей концертында булырга туры килде. Мин шунда, сәхнә артына кереп, Әлфия апаның өстендәге, Америкадан алып кайткан күлмәген тотып карадым. Ул аны Америкадан алып кайтканлыгы турында сәхнәдән дә әйтте. Ялык-йолык бу ап-ак күлмәккә ул вакытта сокланмаган тамашачы кал-





магандыр, ул аңа шулкадәр нык килешә. Сәхнәдә үзен гаҗәеп иркен тотуы, андагы энергия беркемне дә битараф калдырмый. Тора-бара Әлфия апа белән Урта Азия илләрендә, Рәсәй шәһәрләре буйлап гастрольләрдә йөргәндә очраштык, аның белән бер кунакханәдә тордык. Алар – Илһам абый белән дуслар, сөйләшеп сүзләре бетми. Аралашып, бергә чәйләр эчеп, бик дуслашып киттек. Әлфия апа – бик тә ачык, аралашучан, безне төрле кызык мәзәкләр сөйләп көлдереп бетерә, үзенең киңәшләрен бирә. «Җырның бормаларын эчтән каерып алып җырларга кирәк, өстән-өстән генә җырлаган халык күңеленә барып җитми ул», – ди торган иде. «Халык синең җырың белән яшәргә тиеш!» – дигән алтын киңәшләре әле дә хәтеремдә.

Әлфия Авзалова белән бик күп гастрольләрдә бергә йөрергә туры килде. Советлар Союзын аркылы-торкылы йөрдек, дисәк тә, ялган булмас. Кешенең кем икәнлеген беләсең килсә, аның белән юлга чык, диләр. Кайда гына булсак та, Әлфия апа безне үз канаты астына сыендырды. Ул кешелеклелеге, ярдәмчеллеге белән башкалардан аерылып тора иде. Аның белән бервакытта да ач та, ялангач та булмыйсың. Аңа һәрвакыт сокландык, аның белән горурландык. Әкрен генә без Әлфия ападан сәхнә серләренә өйрәндек, аңа охшарга тырыштык. Аллага шөкер, балачак хыялларым тормышка ашты. Халкыбызның сөекле кызы, легендар җырчысы белән бергә, бер сәхнәләрдә иҗат итәргә насыйп булды. Соңыннан инде без якын дусларга әверелдек. Бер тапкыр Уфа кунакханәсендә Әлфия апа белән икебез бер бүлмәгә урнаштык. Ул вакытта паспорт режимы иде. Бер көнне, төн уртасында кереп, паспортларны тикшерә башладылар. Әлфия апаның паспорты юк иде. Тиз генә йөгереп Кәримне алып мендем. Тикшерүче кешенең берсе татар булып чыкты. Төн уртасында безнең кем икәнлекне танымыйлар гына бит. Аңлата торгач: «Әй, Әлфия апа, бу Сезмени, гафу итегез!» – дип, чыгып киттеләр. Менә шундый кызык хәлләргә дә тарыдык. Нинди генә хәлдә дә Әлфия апа судан коры чыгар иде, тапкыр сүзле булды, сүзен куркып сөйләшмәде. Ул күп вакыт үзе өчен түгел, бригададагы кешеләр өчен баш иде. Кибетләрдә азык-төлек, киемнәрнең юк вакытында да ул аларның үзләрен генә түгел, гаиләләрен дә киендерде, туендырды. Әлфия апаның бөеклеге, мөгаен, аның гадилегендә, чиста, моңлы күңелендәдер. Әлфия апа, Илһам абыйлар чорында яшәвебез белән бәхетле без! Әлфия апаның җырлары мәңгелек, димәк, Әлфия апа да безнең белән, ул һәрвакыт исән! Татар җыр сәнгатен үстерүгә зур көч куйган, бөтен гомерен багышлаган шәхес – Әлфия Авзалованың исемен, иҗатын мәңгеләштерү – безнең бурыч! Аның иҗаты, тормыш юлы мәктәп дәреслекләренә дә кертелергә тиеш. Ә Әлфия Авзалова исемендәге Халыкара җыр фестивале – Әлфия апаның иҗаты кебек киң колачлы татар моңын гасырларга илтәчәк, ышанычлы эстафета булыр, дип ышанасы килә...

Зөфәр ГАЯЗОВ,
«Татинтер Ресторантс»
ресторанлар холдингы иясе



Балаларыбыз күңелендә яшәсен

Әлфия апа белән очрашуыбыз Мәскәүдә булды. Без 1990 ел башында Мәскәүдә «Татарстан» дип аталган беренче татар халык ашлары ресторанын ачтык. Минем Эчке сәүдә академиясен тәмамлаган елларым. Ул вакытта Мәскәүдә яшәүче якташларыбыз: Фикрәт Әхмәтҗан улы Табиев, татар эшкуарлары – Валерий Владимирович Кузьмин, чыгышы белән Чистай якларыннан булган, СССРның сәүдә министры урынбасары Анатолий Иванович Козлов миңа шушы фикерне әйтеп, татар ресторанын ачу бурычын йөкләде.

Ул чакта ук инде татар җанлы якташлар тарафыннан Мәскәүдә яшәүче татарлар өчен «Клуб-16» дигән оешма эшли башлаган иде. Бөтен якташларыбыз көтеп алган ресторанны ачу тантанасына без барча татар халкы яратып тыңлый торган, татар җырларын инструменталь уен коралларына кушылып иң стильле башкаручы җырчы Әлфия Авзалованы чакырдык. Бу тарихи вакыйгага бик күп кунаклар, якташлар, татар зыялылары килде. Әлфия апа килеп керүгә, бинага ниндидер сихри нур, яктылык иңгәндәй булды. Бу очрашу минем күңелемдә тирән, дулкынландыргыч мизгелләр белән уелып калды. Килгән кунаклар яраткан җырчыбызны алкышларга, чәчәкләргә күмде. Бу тантананың үзәгендә, әлбәттә инде, тормыш иптәше Динә ханым, яраткан оныклары белән Фикрәт Әхмәтҗан улы Табиев та булды. Алар Әлфия апа белән бик тә җылы, дустанә мөнәсәбәттә аралашты, ул җырлап бетергәч, аңа зур чәчәк гөлләмәсе тапшырды.

Әлбәттә, мин Әлфия апа исемен кечкенәдән ишетеп, аның җырларын тыңлап үстем. Без әниләр белән кайда гына булсак та – бакчадамы, өйдәме – радиоалгычлар, җыр пластинкалары аша гел Әлфия апа, Илһам абый моңнарын яңгыраттык. Минем әти-әнием аларның җырларын һәрвакыт күңел биреп, мөкиббән китеп тыңлый иде. Йөз җырчы арасыннан аның тавыш тембрын бер кеше белән дә бутап булмый. Әлбәттә, Әлфия апа турында мондый истәлекләр, аны белгән замандашларының фикерләре, хатирәләре бик тә урынлы. Бүгенге яшьләр өчен тормыш китабы, энциклопедия бу. Татар милләтенең электән килгән матур йолаларын, гореф-гадәтләрен, җырмоңнарын киләчәккә илтүче милләтебез өчен янып-көеп хезмәт иткән мондый шәхесләрне онытырга ярамый. Милләтебезнең дәһи кыз-уллары күп.

Әдәбият өлкәсендә – бөек шагыйребез Габдулла Тукай, җыр-моң өлкәсендә – Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров! Алар туган телебез, яраткан халкыбыз, якты киләчәгебез, милләтебезнең яшәеше, мәдәниятебезнең үсеше өчен әйтеп бетергесез зур эш башкарган, йөз елга бер генә туа торган бөек шәхесләр.

Тора-бара тормыш юллары тагын да кисеште, без гаилә дусларына әверелдек. Моңа, әлбәттә, Әлфия апаның кияве Равил белән бергә академиядә уку да этәргеч булгандыр. Безнең балалар бергә аралаша башлады. Шул чакта мин Әлфия апаның оныгы Ләйсәннең артистлык сәләтен күреп, исләрем киткән иде. Ул минем кызымны курчаклар ярдәмендә концерт куйдырып, артистлык осталыкларына өйрәтә башлады. Без бу сәләтле кызны бөтен гаиләбез белән яраттык. Әлбәттә, безгә бар яктан да камил булган әлеге кешеләр белән аралашу бик рәхәт иде.

Әлфия апа белән төшкән фотосурәтләребезгә карасаң да, безнең арадагы җылылыкны тоясың. Ул Мәскәү хәтле Мәскәүдә, җинаятьчелек чәчәк аткан тотрыксызлык чорында татар ресторанын ача алуыбызга сокланыйм, хөрмәтен яшермәде. Безнең барыбызны бер максат – татарларны җыйнау, миллилекне югалтмау, телебезне, иманыбызны саклау берләштерде. Бер үк вакытта безнең «Татарстан» ресторан төрле милләт вәкилләренең дуслык учагы да булып торды. Без аш-су өлкәсендә мондый югарылыкка күтәрелүче беренче карлыгачлардан идек. Хәзерге көндә бу ресторан инде ябылды, башка татар милли аш-су ресторан әлегә кадәр күренми. Әлбәттә, мондый ният белән янган татар яшьләрен белсәм, мин ике дә уйламый аларга бу эштә зур этәргеч булыр идем. Мондый очрашу урыннары гади ашау-эчүгә генә кайтып калмый, аның сәяси ягы да гаять әһәмиятле. Милли җанлы, эшлекле кешеләрне бер йодрыкка туплау, аларның милли, сәяси мәсьәләләрне турыдан-туры чишү урыны да бу. Вакытында Мәскәү татарлары оештырган «Клуб-16» нәкъ менә шул юнәлештә эш алып баручы милли учак булып торды. Анда татар җырчылары, бигрәк тә Әлфия апа кебек бөек җырчылар чыгыш ясаганда, тамашачыларның күзләре яшьләнә иде. Бу, әлбәттә инде, җырның ни дәрәҗәдә кеше күңелен кузгатуы, туган ил, туган җирне сагынуын аңлата. Әлфия апаның җыр-моңнары киләчәктә дә халкыбызны миллилеккә рухландырып, киләчәк буыннарда – балаларыбызның күңелендә яшәсен, дигән теләктә калам.

Иделия ИСХАКОВА,
Әлфия Авзалованың оныгы



Иң сөйкемле, иң мөлаем, иң сабыр...

Без әбиебезне, барыбыз да яратып, «әннәке» дип йөрттек. Гаиләбездә әннәке – иң төп урын алып торучы, иң хөрмәтле, яраткан кешебез булды. Безнең араны ныклы, аерылгысыз җепләр бәйләде. Ул ижатта гына түгел, хатын-кыз буларак, өй эшләрендә дә бик булдыклы, уңган хуҗабикә иде. Йортта нинди генә эш эшләсә дә, кулы ятып торды. Ул пешергән телне йотарлык, уңган камыр ашларының тәмен мәңге дә онытырлык түгел! Бигрәк тә пәрәмәч, өчпочмак, мантый ризыкларын теләп, яратып пешерде, шуңа да бездән күрше-күлән, кунаклар өзелмәде. Әннәке тыштан каты холыклы булып күренсә дә, бик нечкә күңелле иде. Тормыш юлы, ижаты дәверендә ул аралашкан кешеләр безнең тәрбиядә дә зур роль уйнады. Аннан ниндидер җылылык, якты нур бөркелеп тора иде. Минем бөтен балачагым аның белән узды. Әннәке еш кына мине үзе белән гастрольләргә алды. Аның белән узган һәрбер көн могҗизалы, кызыклы һәм мавыктыргыч булды. Ул бик тә бай фантазияле, эзләнүчән кеше иде. Безнең белән балаларча бөтен күңелен биреп уйный, бергә телевизор, кинолар карый, шаяра, көлә.

Үсә төшкәч тә, ул безгә могҗизалар тудырудан туктамады. Аның гастрольдән кайтканын дүрткүзләп көтеп ала идек. Кайткан көнне үк, юлдан алҗып кайтуына да карамастан, зур табын әзерләп, бөтенебезне шул мул, сыйлы табынга җыя. Барыбызны да тигез күреп, кайткан саен һәрберебезгә бүләкләр алып кайтып сөендерүдән туя алмады. Әннәкебез һәрчак сабыр гына, һәрнәрсәне төшендереп сөйләшә торган иде. Безнең белән аралашудан, безне шатландырудан тәм тапты. Һәрчак безгә дәресләр кararга булышты, хәтта мәхәббәт өлкәсендә дә беренче киңәшләрне әннәкебез бирде.

Аның белән икәү тапкырлау таблицасын ятлаганым бүгенгедәй истә. 7х8 ничә икәнлеген беркайчан да онытма дип искәртә-искәртә, миңа тирән арифметика белемен сеңдерүче дә ул.

Инде буйга җитеп, читтән үзем Казанга кайтканда, мин иң беренче әннәке янына кагыла идем. Туйганчы сөйләшеп хушлашыр вакыт җиткәч, ул мине һәрвакыт: «Аллаһыга тапшырдык, кызым, исән-сау йөр!» – дип озатып калды. Шул сүзләрдән соң минем күңелемә ниндидер тынычлык, рәхәтлек иңә.

Әннәкәдә күзгә күренмәс, әмма күңелне тартып торган ниндидер бөек көч бар. Шуңа күрәдер аңа һәркем тартылды, чөнки ул кешеләрне, тормыш-

ны яратты. Ул беркайчан да күңел төшенкелеген кешеләргә сиздермәде, киресенчә, үзенең күңел нурын һәркемгә өләште, әйтерсең, ул җиргә бәхет өләшергә җибәрелгән бер фәрештә иде.

Ул – искиткеч киң күңелле, гаҗәеп үзенчәлекле кеше. Безнең гаиләнең бәхетен ул үзенең нәфис иңнәрендә тотты. Ирләр тартмас авыр йөкне тартты, сер бирмәде, сынмады-сыгылмады, беркайчан да кешеләргә күз яшен күрсәтмәде.

Ул мәңге җырларында яшәячәк. Ул – минем өчен дөньядагы иң матур, иң сөйкемле, иң изге, иң мөлаем, иң сабыр, иң яраткан, бердәнбер Әннәкем. Аны яратуым җырларын тыңлаган саен, фотосурәтләрен караган саен, көчәя генә бара. Мин шундый әннәкем булуы белән чиксез бәхетлемен!

Өйрәткән иде әби...

«Таш астына су, юк, үтми...
Һәм ут кабызмассың мичтә –
Утын булмаганда һич тә.
Көтмә Ходайның рәхмәтен,
Татлы йоклыйм, дисәң әгәр.
Салам җәю кирәк мәгәр,
Тигезлеген карап, рәтен.
Кешенекен алма, тыел,
Үзеңнекен яхшы сакла!
Яшьләрең сөрт, булыр кыен,
Көчсезләтә жәлләү, яклау.
Күпне сорама Ходайдан,
Ярдәм кирәк калса, килер Ул.
Кahәр әйтә күрмә, саклан,
Язмышка зарланма, тимер бул.
Кемдер китергәнне көтмә,
Аягың бар, үзең барып ал.
Бәла килсә – коткарырлармы?
Син беренче үзең сукмак сал.
Башкалар булдырса – синең дә
Мөмкинлек бар, тырыш, курыкма.
Куркуның зур, ди, күзләре дә.
Бар да яхшы булыр, бирешмә.
Барлык үпкәләрне оныт –
Гафу ит... Эх, алдан белсәмме?»
...Әби өйрәтте, ә тормыш
Раслап торды һәрбер әйткәнне.

Анна ОПАРИНА

Илдар КЫЯМОВ,
тележурналист



Артист бәхете

Әлфия апа Авзалованың «Үзем турында» дип исемләнгән китабын (ТКН, 1995 ел. Әдәби эшкәртүчесе – Г.Зәйнашева) студент елларымда йотлыгып укып чыккан идем. Фикеремне белдереп, хәтта кечерәк кенә рецензия дә язган идем әле. Бу китапны авылга алып кайткач, гаиләдәгеләр, истәлекләрне бер-берсеннән качыра-качыра укып чыктылар. Аннан ул кадерле басма авыл буйлап «сәяхәткә китте». Берәр ел йөргәч кенә, тузып-таушалып кулыма кайтып керде. Әнә шул дәрәҗәдә Әлфия апабыз халыкка кызыклы һәм газиз бер зат ул!

Безнең Чирмешән районындагы Кара Чишмә авылы халкы өчен Әлфия апа икеләтә тансык, кадерле артист бит әле. Ни өчен дигәндә, данлыклы баянчы, М.Җәлил премиясе лауреаты Рифкать Гомәров аның эстрададагы беренче баянчысы булган, дип беләбез. Бу хакта Р. Гомәров турындагы истәлекләр китабына биргән интервьюсында Әлфия апа миңа үзе сөйләгән иде. Аның язмасы бик урынлы гына әлеге китапның 50-52нче битләрендә урнаштырылды («Моңлы «Саз», моңлы гомер». Казан, «Матбугат йорты» нәшрияты, 2003 ел. Автор-төзүчесе – Илдар Кыямов).

Әлфия апаны якыннан беренче күрүем 1990 еллар азагында булды. Татарстанның халык артисты Асаф Вәлиевнең машинасында ни йомыш беләндер Казан буйлап барабыз. Данлыклы якташын урамда күреп алып, Асаф аны машинага чакырды.

– Инәгезне!

Машинага кереп утыргач та, Әлфия апаның «исәнләшү»е шулайрак яңгырады. «Нихәл, энекәш, Әлфия апаңны утыртып кайтыйм, дидеңме?» Татар эстрадасы примасының шул дәрәҗәдә гади, кешелекле булуы гажәпләндерде.

Инде 1997 елдан бирле эстрадада, банкетларда алып баручы булып эшләгәч, мөхтәрәм артистны игълан итеп сәхнәгә чыгарырга да туры килгәләде. Ләкин бөек җырчы белән якыннан аралашу Себер гастролендә булды. Сәфәрдә чакта артистлар бер-берсен ныграк өйрәнә, хәтта туган дәрәҗәсендә якынаеп бетә бит инде. 2000 елның 11-24 декабрь көннәрендә продюсер Марсель Иванов чакыруы буенча, Себер якларында йөрдек. Максатыбыз – хәзерге Мәскәү мэры Сергей Семенович Собянинны Төмән өлкәсе губернаторы итеп сайлау барышында агитация концертларында катнашу.

Делегация бик зур – Илһам ага Шакиров, аның баянчысы Рөстәм Вәлиев, Әлфия Авзалова, Сания һәм Кәрим Габидуллиннар, Газинур Фарукшин, җырчы Светлана Сабирова, Рафаэль Сафин – кыскасы, 14 кеше. Мин шул концертларны алып барам, әле өстәвенә, ике җыр башкару хокукы да бирелде. Күкнең җиденче катында идем. Шундый легендалар белән аралашу, алар белән бер автобуста йөрү, тамашачы алкышларын тоемлап бер сәхнәдә янәшә басып тору – сәхнә дип шашкан егет өчен моннан да зур нинди сөенеч була ала?! Бик бәхетле, онытылмас бер гастроль булды ул минем өчен.

Әлфия апа белән Илһам абый – тамашачы һәм оештыручыларның күз уңында. Без дә алардан күзне алмыйбыз – һәр сүзләрен сеңдереп, отып барабыз. Казан вокзалында Әлфия апаның Илһам абый белән күрешүеннән үк без «спектакль» көтә башладык. Һәм шулай булды да. Кочаклашып күрешкәч, Илһам абый:

– Гастрольгә барасыңмыни? Җырлап күрсәт баштан! – дип шаяртты.

Көлешә-көлешә поездга утырдык. Бу эчкерсез, риясыз, халык рухиятен үстерү өчен яратылган ике зат сәхнә артында тәмам үз кешегә әйләнеп китә иде. Ике сәгатьтән артык барган концерт вакытында грим бүлмәсендә җыелып, мәзәк сүзләр сөйләшергә дә, рәхәтләнеп аралашырга да өлгерә идек. Алар рәсми статус сакларга туры килгән мизгелләрдә дә үзләрен гади һәм күркәм тота, әлбәттә. Ләкин сәхнә артында, без – бер төркем яшь-җилкенчәк арасында, алар үзләрен бөтенләй табигый стихиягә эләккәндәй хис итә иде сымак – безнең белән бер дулкында сөйләшәләр, көлешәләр, шаяралар иде. Аларның бу сыйфаты безгә аеруча кадерле.



Лянтор шәһәрендә булса кирәк, иртәнге ашны безгә бер татар кызы әзерләде. Якыннан танышып киттек. Сорауларны Әлфия апа бирә. Безне сыйлаучы ханымның ире урыс икәнлеге ачыкланды. Әлфия апа болай диде:

– Ярар, бик әйбәт. Урысыңны ярат, сакла, бәхетле яшәгез. Минем дәү әни остабикә иде. Ул болай дияргә ярата иде: «Кызым, татар барда – хәтәр бар. Урыс барда – мәрхәмәт бар». Татар урынлы-урынсыз кыйнауны гына белә. Урыс – ярдәмчел, йомшак күңелле. Менә шул: урысыңны кадерләп тор!»

Себер ягының зур-зур авылларында да чыгыш ясадык. Яши торган кунакханәбез Төмәндә. Шуннан чыгып-чыгып, концертларга барып кайтабыз. Эске дигән авылда чыгыш ясаганыбыз истә. 180 чакрымдагы Шатан исемле авылга баргач, агач күпергә юлыктык. 13 тонналы автобусны күтәрмәс дип, безгә төшеп торырга туры килде. Барып керсәк, 50 нче елларда салынган агач клуб. Концерт буласын белмиләр дә икән. Әлфия апа, чын аналарча, безне кайгырта, Мәһди исемле клуб мөдирен чаптыра башлады – артистларга чәй генә дә куелмаган икән. Без берничә сәгать юлда килгән бит. Әле ике сәгать эшләгәч, тагын шуның кадәр кайтасы бар! Әлфия апаның үҗәтлегенә күрә, без ул көнне дә тук булдык: Мәһди абзый клубтагы радиоузелдан авыл халкына белдерү ясады. Бер сәгатьтән зал шыгрым тулы иде. Әле шатанлылар легендар артистларыбызны кунак итәргә дип, тәм-томнар да кыстырып килгән булып чыкты. Без дә рәхәтләнеп сыйландык...

Журналист булуым сәбәпле, миңа һәр нәрсә кызык. Шунлыктан, мин Әлфия ападан бер адым калмыйча, аңа тагылып дигәндәй йөрим. Табынга да үз янына утырта. Бәлки, шаяруларына кушылып рәхәтләнеп көлгәнгә, шукланулары дөрес аңлаганга, каршы килмәгәндер. Ул, гадәттә, түргә утыра, мин писарь сымак, аның янынарак чүмәшәм дә, бөтен вакыйгаларны мыекка чорнап барам. Сургут шәһәрендә матур гына банкет оештырылды. Бер ханым сүз алды да, русчалатып сөйли башлады. Бу көннең нинди бәхетле көн икәнен, Илһам ага, Әлфия апаларның Сургутта булуы тарихи вакыйга булуын һәм башка шундый рухтарак. «Әйтер сүзем күп, әйдәгез, сезгә җырлап бирим әле!..» – дип, сузып та җибәрде. Әмма дулкынлануданмы-ничекме, дөрес алмыйча, терциягә өстәрәк җырлый башлады. Бара торгач, бик кыен хәлдә калып, көчәнә инде. Бу апаны кызгануым кыяфәтемә үк чыккан булган, ахры. Әлфия апа, миңа иелебрәк, болай дип куйды:

– Акырсын, күтәне чыксын!

Беренче карашка кырысрак яңгыраса да, дөнья күргән зирәк артист ханымның: «Кулыңнан килмәсә, алынма!» – дигән сүзе иде бу.

Берничә ел аралашу дәверендә мин Әлфия ападан шактый һөнәри хикмәтләр, профессиональ эш күнекмәләре алып калганмын икән бит. Казан милли-мәдәни үзәгендә эшләгән елларда Солтангалиев мәйданында Республика көненә әзерләнәбез. Репетициядә Әлфия апа Авзалова да кат-

наша. Мин режиссерның күрсәтмәләрен төгәл үтәп барсам да, дулкынланам. Кирәклесен үз урынында әйтеп җитешмәм шикелле. Әлфия апа, минем халәтне күреп:

– Борчылма, энекәш. Нәрсә кайгырасың? Урам бит бу! Урамда җырлыйбыз бит, – дип тынычландырды.

Концерт барганда утырып торырга ярамый, озак күченүләр булганда, ял итеп барырга кирәк. Сәхнәдә эшләгәндә тәртип бик көчле булырга тиеш – болар һәммәсе дә Әлфия апа сабаклары. Тәртип, димәктән, ул «салган» кешеләрне яратмый иде. Егетләрнең арттырып җибәргәнен күрсә, икенче көнне «тәрбия сәгате» ясап ала. Аларга төртеп күрсәтә дә: «Кому – война, кому – файда!» – дип куя. Файда күрүчесе – азрак капканы була инде...

Аш-су тирәсендә дә талымсыз иде ул. Әлбәттә, үзенең зәвыгы, үзе яраткан ризыклары, һичшиксез, булгандыр. Ләкин үз статусына туры китереп берни дә дауламый, нәрсә бар – шуңа риза. Берсендә бәрәңге салыйм дип сузылгач, ялгыш өстәлгә чәчтем, аның кулына да эләкте әле. Берни булмаган кебек, Әлфия апа, чәчелгән ризыкны алып ашап куйды. Буза да куптармады, кисәтү ясап, акыл да өйрәтеп маташмады. Бу хәл аның ризыкка хөрмәте зур икәнне генә күрсәтте. Шул Себер гастроленнән Казанга кайтып барыш. Әлфия апа поездда чәйләп алырга уйлаган.

– Энекәш, мин инде сумкаларымны җыеп куйдым, өстән тартып төшерәсем килми. Юкмы берәр шикәр кебек нәрсәң? – ди.

– Бар, Әлфия апа, миндә конфетлар бар. Тик алар шактый йөри торгач, бераз катып киткән, ярыймы соң?

– И, ярамый, димени? Шунысы үтергән инде аның!

Шул чәйдән соң, Әлфия ападан бер бит чиста кәгазьгә автограф алдым. «Миңа беркем ышанмас, Әлфия апа, үз кулыгыз белән язып бирегез инде», – дигәч, бик шәп, матур сүзләр язып бирде. Ул язу да архивымда кадерләп саклана.

Бу сәфәрдән кайткач, берничә елдан соң, Әлфия апа белән Ульяновск өлкәсенең Атлаш авылына концерт куярга барган идек. Автобуста, башлыча, биючеләр. Алар – артта, без – алда. Барганда да, кайтканда да рәхәтләнеп сөйләштек, аралаштык. Үземне кызыксындырган сорауларга Әлфия апа тулы җаваплар бирде. Бөтен автобус кызыксынып безнең янга җыелгач, кайбер вакыйгаларны махсус сорап та сөйләттек әле (берсе гармунчы Гани Вәлиевкә бәйле). Әлфия апа юморны бик оста бирә, үзе бер театр бит инде ул. Көлә-көлә эчләр катып бетә иде.

Автобуста утырган җирдән кул баглауларымны, дога кылуларымны күреп, ул:

– Син кайчаннан абыстайга әйләндең соң әле?.. – дип куйды. («Абыстай» дип, белә торып шаяртуы, кызык ясавы инде).

– Син алай бик тиз әүлиягә әйләнмә әле! «Тегендә баргач», сине дә кыса-

чаклар, белеп тор, син дә безнең кеше бит! – дип, Әлфия апа, авызы каршында бармакларын селкетеп алды. Янәсе, син дә – сүз сөйләүче, сәхнә кешесе.

– Үзегез укыйсызмы соң, Әлфия апа? – дим.

– Юк, намаз укыганым юк, мин өйгә кайткач, тәһарәт алып, теләкләр телим, Алла бирсә! Балаларыма тыныч, игелекле тормыш, үземә саулык сорыйм. Безгә бит дин бик эләкмәде. Шуңа күрә, белгәнемне кабул кыл, белмәгәнемне гафу кыл, дим дә, Аллага тапшырам. Ул – Белүче, мәрхәмәтеннән ташламас!

Шул сәфәрдә Ульяновск шәһәрендә кунакханәдә кундык. Төнлә бик яман яшенләп яңгыр яуды, күк күкрәде. Иртән юлга кузгалганда Әлфия апа инде, гадәттәгечә, яшьләрне көлдереп тора иде: «Төне буе күз дә йоммадым, балалар! Шартлап-шартлап яңгыр ява, малай! Тәрәзәдән карарга да куркыта. Мендәремне кочаклап, торып ук утырдым. Күк күкри дә:

– Мине генә ата күрмә! – дип укынып куям.

Әлфия апа Авзалова – гаять киң диапазонлы җырчы-артист. Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбленә килгәндә үк, С. Габәшинең «Кәккүген» башкарган икән, димәк, ул – өлгергән җырчы, халыкчан башкару остасы булган инде. Шул ук Себер гастролендә, русча да кирәк, дигәч, «Человек с рюкзаком» дигән җырны, баянга кушылып, гөлт иттереп башкаруы белән дә шаккатырды. Эстрада җырларын утлы тавыш белән, яндырып җырлавы – барыбызның да хәтерендә, күңел түрендә. Болардан тыш, камера әсәрләрен дә җиренә җиткереп башкарган икән Әлфия апабыз. Резидә Әхиярованың Ринат Харис сүзләренә язылган «Сагындыра» дигән җырын күз яшьләрсез тыңлау бөтенләй мөмкин түгел. Җырчы-артист анда шул чаклы моң, сагыш салган. Һәм шуны күкрәктән чыккан бер өзгәләнү белән тасвирлый алган:

Сагындыра кар сулары гөрләп аккан,
Сине тапкан, сине тапкан...
Һәм югалткан
Моңлы язым сагындыра...

Әлфия апа сәхнәдә – әверелеш остасы, чын актер. Ул анда тамашачы хозурында тәмам «эреп бетә» (Илһам абый Шакиров кызык кына итеп «тиресеннән чыга» дип әйтә иде). Чыннан да, Әлфия апа йөз процент бирелеп эшли. Сәхнәдә чакта аңардан күзеңне аерып алышлы түгел. Ничаклы җылы, ихлас, саф, риясыз энергетика! Ни дәрәҗәдә үз эшеңне ярату, тамашачыга тирән хөрмәт, бөтен бер залны бер сулышта тота белү. Башкарыла торган җырыңның образын түкми-чәчми залдагыларның йөрәгенә салу куәте. Болар шаккатыргыч иде. Мин сәхнә артыннан примабызны күзәтеп, сокланып тора идем. Себер шәһәрләрендә йөргәндә, Әлфия апа әле үз көчендә, олы яшьтә булса да, кирәк чакта, хәтта, биеп тә җибәрә. Чыгышын төгәлләп сәхнә артына керә. Зал котырып кул чаба, яңадан чыгуын сорый. Әлфия апа



С. Собянинның портреты төшерелгән афишаны тотып, тыпырдап бии-бии, кабат тамашачы каршына чыга. Афишаны карап, үбеп тә ала әле. Шул ишарәсе дә менә дигән реклама булган бит инде. «Мин бу кешене сайлар идем, сез дә гафил булмагыз!» – диюе. Чыгышы бөтенләй тәмамлангач, ул кулларын өскә чөеп, көчле тавыш белән, тамашачыга болай ди:

– Рәхмәт, дуслар! Беләм, яратасыз, рәхмәт! Онытмагыз, Әлфия апагызны!!!

Бу вакытта үзенең сөекле баласын кадерләгән татар тамашачысы, аягүрә басып, аның иркендә кала. Әлфия Авзалова дигән бөек шәхеснең хозурында үзен әсир итеп тоя, алкышлар көчәя бара. Берничә минут шулай дәвам итә. Минем исә, чын артистның хакыйкый бәхетен, чын сәнгатькәр сөенечен күреп, аркаларым чымырдый, күзләрем яшьләнә иде...



Илзирә ВӘЛИУЛЛИНА,
шагыйрә, журналист



Масаймады, кылтаймады

Милләтебезнең якты йолдызы. Моң алиһәсе. Җыр патшабикәсе. Татар эстрадасына нигез салучыларның берсе. Татар җырының әнкәсе. Татар халкының горурлыгы. Кабатланмас, уникаль шәхес, остаз. Халкыбызның моңлы сандугачы Әлфия апа Авзалованың җырларын тыңлап үскән төрле кавем кешеләре, халык, яраткан җырчысына тугры калып, җырчыга бәйле истәлекләрен хәтерендә яңартып яши. Әлфия апа бакыйлыкка күчкәннән бирле, һәркемнең күңелендә моң катыш сагыш уты, югалту ачысы дөрли.

«Масаймады, кылтаймады. Кеше белән гади итеп аралашты. Авылыбызга концерт белән килгәч, атыма утыртып күрше авылга илтеп куйганым булды үзен. Аның белән төшкән сурәтем истәлеккә калды. Әлфия ападан автограф алганым булды. Заманында бер табын артына утырып чәй эчкәнем бар иде»... Халык арасында әнә шундый сүзләр еш ишетелә.

Шәхсән үземнең күңелдә дә халык җырчысына бәйле күркәм истәлек яши. Дөрес, ул вакытта истәлеккә сурәтләргә төшелмәгән. Көз аеның ямьле бер көне иде. Авылыбызга – Түбән Кама районының Тоба авылына – Казан каласыннан мәшһүр җырчылар килә, дигән хәбәр килеп иреште. Ул вакыттагы колхоз рәисе, үзе дә гармунда оста уйнаучы Риян Мотыйгуллин: «Рәхимә апа, син артистларга табын әзерлә инде, концерт тәмам булгач, җыелышып өегезгә кайтылыр», – диде. Гомер буе авылда терлекче, сыер савучы булып эшләгән, җитәкчеләр алдында тырышлыгы белән хөрмәт казанган әнием үзе дә Әлфия апаның җырлавын яратып тыңлаучы, һаман саен көйләп-җырлап йөрүче булараk (әниемнең тавышы калын, бик тә моңлы иде), бик дулкынланса да, каршы килмәде, ризалык бирде. Ә минем шул вакыттагы сөенүләремне белсәгез икән! Чөнки ул вакытта бик тә популяр булган, халык теленнән төшмәгән Әлфия Авзалова үзе безнең өйгә килә! Шулай итеп әни белән түр яктагы бүлмәдә табын хәстәрли башладык. Мәрхүм әнием өйдә чиста-пөхтә, аш-суга бик оста, бәлешләре ашап туймаслык, шулпалы, итен күп салып пешерә торган иде. Клубта концерт кararга мин дә бардым, концерт беткәч тә йөгереп өйгә кайтып киттем, ник дигәндә, әнигә: «Концерт бетте, ашка токмач сала торсак та ярый», – дип әйтергә тиеш идем. Ә токмачны мин яшьли үзем кисәргә яраттым. Көткән кунаклар килеп җитте, авылыбыздагы ямьле кичә безнең өйдә, аш-су табыны артында дәвам итте. Әнием, мин бит концертта була алмадым, дип кунаклардан җырлауларын үтенде. Әлфия апа баштарак авырып торам дисә дә, чордашына каршы килмәде (әнидән ике яшькә генә кече Әлфия апа), моңлы итеп

җыр сузды. Табын артында да кызык сүзләр сөйләп, гадилеге белән җәлеп итте ул. «Эчемдәге – тышымда минем», – диюләре хәтердә. Кунаклар арасында – Әлфия апаның музыканты Кәрим абый Габидуллин, гармунчы Кирам Сатиев, җырчы Рөстәм Маликов, бүгенге көндә «Яңа Гасыр» телеканалында урынбасар булып эшләүче Данил Гыйниятов бар иде. Алар кунарга калмады, шул төнне, бераз ял итеп алгач, үзләренең автобусына утырып, кайтыр юлга кузгалды. Без – өйдәгеләр, җыелышып, аларны озатырга чыктык. Әлфия апаның өстендә кара төстәге юка плащ иде. Кочаклашып аерылышулар бүген дә истә.

Ни кызганыч, әлеге очрашудан соң ике дистәдән артык ел узгач, җырчы белән 40 ел гомерен сәхнәдә бергә уздырган иҗатташы Кәрим Габидуллин, Әлфия апага җырлаганда кушылып җырлап торучы солистка Сания Габидуллина белән Әлфия апаны соңгы юлга озату мәрәсимендә очрашырга туры килде.

– Әлфия апа белән эшләү бик рәхәт иде, әмма җиңелләрдән бирелмәде, ул бик таләпчән кеше булды, көненә икешәр-өчәр концерт куйды. Гастрольләр белән авылларда йөрергә бигрәк тә яратты. Авыл җиренә баргач, берәр чакрым җәяүләп йөреп килә иде, – дип искә алды танылган музыкант.

Әйе, ул бит – җаны-тәне белән авыл кызы, биш яшендә әнисе тиф авыруыннан үлгәч, кечкенәдән күп михнәтләр күреп үскән Актаныш кызы. Әнисе үлгәч, төпчек сеңлесен, әле яше дә тулмаган имчәк баланы – Гөлсиринне тыштан салкын сөт алып кереп эчертеп, гомерен чикләргә дигән кararга киләләр. Әй, җылый да соң шул чагында үзе дә сабый Әлфия, сеңлесен кызганып. Аннан сеңлесе Флүрәне балалар йортына алып китәләр. Әлфия әнисенең туганы – Закирә тәрбиясенә кала. Кызның күңеленә яхшы хатирәләр белән кереп калмаган әтиләре үзе дә кыска гомерле булган. Әлфия апаның кечкенәдән җырга һәвәслеге мәгълүм. Әле беренче класста укыганда ук, укытучысы Нәфисә Акмалованың: «Әлфиянең тавышы матур, җырны матур итеп җырлый, хәтере дә яхшы, булдырасың, Әлфия, күз тимәсен!» – дип, үсендереп торуы да җыр сәнгатенә беренче адымнар ясаганда гаҗәеп этәргеч булгандыр, дип саныйм.

Әлфия апа истәлекләрендә: «Иске-москыдан, алама киенсәм дә җырлыйм да җырлыйм, өйдә ялгыз гына калсам, әйтерсең, патефон борып куялар, нинди җыр ишеткәнмен, барысын да отканмын, «концерт бирәм»... Нәфисә апа өйрәткән «Шахта», «Ал Мәрфуга, гөл Мәрфуга», «Нурияләр»не сибәм генә... Җыр күңелемә юаныч бирә, ятимлегемне, ач-ялангачлыгымны онытыргандай була, ниндидер якты өметләр белән киләчәккә ымсындыра, дәртләндерә. Беренче класста укыганда әнисен сагынуын моң белән басарга теләгән Әлфия, моңлы көйгә җырлана торган:

«Түгәрәк күл матур була
Су белән тулса гына.
Тусын анадан кыз бала
Бәхетле булса гына» –

дигән башкорт җырын яратып җырлый торган була...

Нәтиҗәдә, сугыш башланып, ачлык газаплары кичереп, күп михнәтләр үтә-үтә, киртәләрне җимерүче Әлфия Авзалова танылган халык җырчысына әйләнә, кешеләрнең мәңгелек мәхәббәтен яулый, 17 телдә җырлап, милләтебезне дөньяга танытып, 500гә якын җырны мирас итеп калдыра, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов әйтмешли: «Халкыбызның сайрар сандугачы, тормышта авыр сынаулар аша, 84 яшендә мәңгелеккә китеп бара. Аның җырлары мәктәпләрдә укыган һәр баланың, Донбасс шахталарында күмер чапкан егетләрнең, кырларда иген иккән агайларның, сугыштан кулаякларын югалтып кайткан каһарманнарның күңелләрен елатты, җырлатты, шул ук вакытта юатты».

– Ул беркайчан да кеше сөйләмәде, зарланмады, кеше хурламады, – дип фикере белән уртаклашкан иде, бөек җырчыбызны соңгы юлга озату мәрәсимендә филармония җитәкчесе Кадим әфәнде Нуруллин. Әйе, Коръәндә кеше сөйләү, гайбәт таратуны зур гөнаһлардан саналганын искәртим. Әлфия апабыз аннан азат булуы белән бәхетле. Чөнки ул – күпләрнең, Рамазан аенда үлсәм ярар иде, дигән теләген тормышка ашырып, изге айда изге эшләр калдырып китә алган бөек шәхес, татар сәнгате легендасы!

Инсия ЗАРИПОВА,
Әлфия Авзалованың туганнан туганы



Кечкенә вакытта Җыракай тутабыз янына авылга кайта идем. Әлфия апаны беренче тапкыр шунда күрдем. Ул мине РТС клубына алып барды. Анда гармун уйнады, җырлады. Биедек, күңел ачтык. Соңрак аның шунда клуб мөдире булып эшләгәнен белдем.

Хәтерләвемчә, Әлфия апа Казанга беренче мәртәбә 1951 елда килде, филармониягә эшкә керде. Мине һәрвакыт үзе белән концертларга йөртә иде. Сул Болак урамында шәхси йортта торды. Анда яшәгәндә беренче ире Зиннур абый белән таныштым. Без әни белән икәү генә тордык. Әни һаман чирләде, тормышыбыз авыр булды.

Әлфия апа мине карады, булышты, киендерде. Икенче әни шикелле булды. Аннан да якынрак туганым юк. Ул мине эшкә урнаштырды. Шатлыкны да, кайгыны да аның белән бүлешә идем. Нинди генә гозер белән барсам да, вакыт табып, киңәшен бирде. Килгән саен, ачык йөз белән каршы алып, сыйлап җибәрә иде. Аннан күргән яхшылыкларны сөйләп, язып бетererлек түгел...

Илдар һәм Айрат БИККИННАР,
Әлфия Авзалованың беренче
ире Зиннур Биккинның
икенче гаиләсеннән туган уллары



Илдар сөйләгәннәрдән

Минем күңелдә дә Әлфия апа иң якын кешем – туганым булып калды. Еш кына кешеләр: «Сезгә җырчы Әлфия апа кем була?» – дип сорый иде. «Безнең әтинең беренче хатыны», – диюгә, аларның йөзендә аптырашлы караш укый идек. Аптырарлык та бит! Шундый бөек җырчы безнең гаиләне дус итеп, якын итеп яшәсен дә, кем аптырамасын ди, бу хәзерге акыл белән үзебезгә дә аптыраш.

Әлфия апа белән булган күңелле вакыйгалар бик күп. Аның белән бергә Әлдермеш авылыннан агач үсентеләре алып кайту бер генә дә онытылмый. Юлда очраган машинадан машинага үсентеләрне күчереп, автобусларда кешеләр янына агачлар сөйрәп керү, аны башта көч-хәл белән өйгә алып кайтып, аннары шул ук могҗизалы юллар аша бакчага илтеп утырту үзе бер онытылмас тарих бите булып калды.

Әлфия апабызның арабыздан китүе күңелдә күңелсезлек, бушлык калдырды. Әлфия апа зәңгәр экраннардан җырлый башласа, йөгереп килеп, тавышын бар көченә ачабыз, аның белән булган күңелле очрашулар искә төшеп, ирексездән күздән яшь чыга. Тормыш иптәшем Светлана да, кызым Алинә дә әннәкене бик якын итәләр, юксыналар. Әйе, без барыбыз да Әлфия апаны апа дип түгел, ә әннәке дип йөрттек. Ул безне үзен әннәке дип йөргәнне бик тә ярата торган иде. Кызыбыз Алинә тугач, кечкенә чакларында, бигрәкләр дә матур безнең курчагыбыз, дип сөя, ярата, кочаклый, үбә торган иде. Тормыш иптәшем Светаның да, абыем Айратның хатыны Маргаританың да балалар йортында тәрбияләнеп үскәнлекләрен белгәч, аларга карашы тагын да җылынды. «Ашагыз, ашагыз», – дип, өстәлдә булган бар нигъмәтләрне аларның алларына куя-куя кыстый торган иде. Соңыннан без моның хикмәтен белдек, баксаң, Әлфия апа үзе дә балалар йортында үскән ятимә икән... Күрәсең, тормышның ачысын-төчесен татыганга, ул балаларын әтисез калдырырга теләмәгәннән, бар авырлыкны йотып, елмаеп йөргән. Нинди бөек Ана!!!

Үз әниебезгә дә без бик тә рәхмәтле, чөнки әни олы җанлы булмаса, Әлфия апа бәргәләнсә дә, берни эшли алмас иде. Бу – ике татар хатын-кызының сабырлык үрнәге, ачы язмышы, яшәеш тарихы була инде. Ул соңгы минутларына кадәр кешеләргә ачык, мөлаем булып кала белде, яшь аша көлде, авыруын яшереп, һаман да сүзне кызыкка борды. Без шундый апабыз, шундый матур,

әниләрдәй ягымлы апаларыбыз булу белән горурланып яшибез. Сагынганда җырларын тыңлыйбыз, апаларыбыз белән тугандай йөрешәбез, димәк, әти-әни, Әлфия апаның дуслыклары газиз балаларында дәвам итә. Бу бик күпләр өчен бик тә гаҗәеп, сәер күренештер, әмма киң күңеллелек дигән сыйфат бүген дә әһәмиятле. Әлфия апаның җырлары да бит, берсе – «кояшлы», берсе – «болытлы» иде... Тормышта да ак белән кара чиратлашып бара. Әлфия апа белән әни шул кара юлдан җитәкләшеп ак юлга чыгарга ашкынганнардыр, күрәсең...



Айрат сөйләгәннәрдән

Безнең әни бик тә аралашучан, ягымлы, кешелекле иде. Әлфия апа да бик ачык күңелле булгангамы, алар икесе бик тә дус булды. Без әни белән бик еш аларга кунакка бара идек. Тора-бара бәйрәмнәрне дә бергә-бергә үткәрә башладык. Мин бик кечкенә идем әле, иң беренче төсле телевизорны да мин Әлфия апаларда күрдем. Мин бу ягымлы апаны кечкенәдән безнең тугандыр, дип белдем. Бераз үсә төшкәч кенә аның әтинең беренче хатыны, ә кызы Гүзәл әтинең кызы икәнлеген аңладым. Тагын да үсә төшкәч, мондый дуслык булуына тагын да исем китте. Чөнки безне Әлфия апа гел ачык чырай, мул, сыйлы табын белән каршы алды. Ул вакытта кибеттә бөтен азык-төлеккә кытлык, алырга берни дә юк. Әлфия апаларда бөтен тәмле әйбер бар. Шуңа күрә дә, әни Әлфия апаларга барыйк, дисә, мин атлыгып тордым. Ул бик тә тәмле пешерә. Ул пешергән тәмле пәрәмәчләр тәме авызда әле дә саклана. Аның гастрольләрдән кайтуын без түземсезлек белән көтеп тора идек, чөнки ул үз балаларына гына түгел, энем Илдар белән миңа да матур киемнәр, уку әсбаплары ташыды. Соңгы көненә кадәр безнең белән аралашып, хәлебезне белешеп, безне әниләрчә кайгыртып, кечкенә генә уңышыбызга да сөенеп яшәде.

Без Әлфия апаны, сәхнә кешесе дип түгел, якын гаилә дустыбыз буларак беләбез, кечкенәдән шулай кабул иттек. Ир балаларның холкы үзгәрәк була, күп вакыт улларын эти-әни дә аңлап бетерми. Әлфия апа безнең белән бик тә җиңел аралаша, безнең хәлгә керә иде. Кайчагында малайлар белән аларга керсәк, аның мине аерып якын итүе, хәтта, иптәшләрем алдында оялдыра да иде. Ул безгә карата һәрчак ачык йөзле, киң күңелле булды. Ул безгә еш килеп йөрде. Монда да үзен, үз өендәге кебек, гаҗәеп иркен тота иде. Минем әнием дә аш-суга бик оста булды. Ул әнием пешергән ризыкларны мактый-мактый ашый торган иде. Бергә бакчаларга йөрдек: Әлфия апа, ике кызы, эти,

әни, энем белән мин. Бергә эшлибез, бергә ял итәбез, бу мизгелләр күңелемдә бик тә рәхәт булып истә калган. Әти Зөлфия белән Гүзәлне дә бик яратты. Бервакыт, алар бакчасына агач утыртып соңга калгач, әти аларны соңгы электричкага утыртып төнлә безгә алып кайтты. Вакытның инде соң булуына да карамастан, әни аларны елмаеп каршы алды, тиз генә коймак пешерде, урыннар җәеп бирде, иртән хөрмәтләп озатты. Әни белән Әлфия апаның эчкерсезлеге, олы җанлылыгы аркасында без бер-беребезне белеп, якыннан аралашып үстек. Хәтта Әлфия апа тормыш иптәшем Маргарита белән дә җылы мөгамәләдә булды. Рәхәтләнеп табын янында Әлфия апаның җырлап утырулары, аның кызык сүзләреннән шаркылдашып көлүләр – барысы да бүгенгедәй хәтеремдә.

Ирек ШӘРИПОВ,
«Татарстан халыкларының Дуслык йорты» директоры, Удмуртия Республикасының атказанган журналисты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре



Кояштай елмаеп

Безнең буын кешеләре кебек үк, мин Әлфия апа белән туганнан бирле таныш, чөнки аның моңнары бертуктаусыз радиодан агылып торды, ул җырлаган җырлар һәрчак кеше күңелендә, кеше телендә булды.

Без бик тә бәхетле халык, чөнки элеккедән сакланып килгән үз моңыбыз – Әлфиябез, Илһамыбыз бар! Авылга Әлфия апаның концерт белән килүе, елга бер була торган күңелле Сабантуена тиң олы бәйрәм була торган иде. Мин моны бик тә бәхетле чорым, дип кабул итәм. Әлфия Авзалованың озын иҗат юлы татар дөньясы белән аерылгысыз. Хәзер дә ул сызган юл дәвам итә, нигездә, татар җыры, татар сәнгате аның кыйбласына таба атлый. Еш кына Салават Фәтхетдинов феномены, диләр, ә бит уйласаң, Салават та – Әлфия Авзалова нигез салган феноменның дәвамы! Без Әлфия Авзалованы бөтен авыл халкы белән ни өчен соң шулай нык сагынып, өзелеп көтә идек? Чөнки ул халыкның күңеленә үтә белә: сәхнә белән халык арасында бернинди чикләр дә юк иде. Ул бер ел эчендә үз тормышында нәрсә булганын яшерми сөйли, бездә нинди яңалыклар булганын тыңлый. Халыктан, әйтегез, нинди җыр җырлыйм, дип сорый да, шуны җырлый. Менә шундый тере аралашу иде халык белән җырчы



арасында. Без, Әлфия апа белән тудык, үстек, хәзер дә аның иҗади рухы белән яшибез!

Мин еш кына, тормышымда, хезмәт юлымда милли хәрәкәтләр белән эшләүче, халыклар дуслыгы өчен җан атучы, аларның рухи халәтен, кичерешләрен аңлап яшәүче кеше буларак, Әлфия апа, ул заманның башка җырчылары бу өлкәдә нинди роль уйнады икән, дигән сорауга җавап эзлим. Нәтиҗә ясап, яраткан җырчыбыз Әлфия Авзалова – күпмилләтле халыклар арасында дуслык күпере төзүче, җыр-моң аша һәрбер халыкның күңеленә үтеп кергән милли җәүһәр, гомер буе милләтара вәкиллек хезмәтен башкаручы бөек зат, дип әйтер идем. Шуның өчен дә без аларның ижатына зур игътибар бирәбез, аларны хөрмәтлибез, зурлыйбыз. Ул заман җырчылары, берьяклап – җырчы булсалар, икенче яктан – сәясәтче, бөтен дөнья буйлап чәчелгән татар милләтен бергә җыйнаучы, берләштерүче дөрләп янган, кайнар, очкынлы учак иде. Ул вакытта чит җирләрдә яшәүче милләттәшләрнең милли оешмалары да юк иде бит, менә нинди киң эш, җавапчыл, олы бурычны үтәп барган алар үз җилкәсендә. Алар булган җирдә татар халкы үзен горур тотып, барлыгын белеп, үз мәдәниятен онытмыйча, киләчәккә ышаныч белән янып яшәгән. Менә шушы миссияне гомер буе күңел биреп алып барган, үз кыйбласына ахыргача тугры калган изге шәхесебез ул – Әлфия апабыз!

Җырчы гына түгел, Татарстан башкаласында яшәүче аерым бер татар вәкилләре буларак, җырчыларның ерак төбәкләрдә һәрберсенең фикердәшләре, дуслары бар иде. Мин шундый киң күңелле милләттәшләр арасында Әлфия апаның дуслары, үзебезнең төбәк кешеләре, Әгерҗедә яшәүче – Ринат Гайфи улы Закировлар нәселен, Ижаудан – Ишмәтовлар гаиләсен әйтеп үтәр идем. Әлфия апа алар белән һәрвакыт дус, тату мөгамәләдә булды, һәрчак аралашып яшәде. Татар милли матбугаты, милли оешмалар булмаган чорда бу шулай ук татарларны берләштереп торучы бер тотка иде. Бу фикердәшләр, замандашлар арасындагы ярдәмләшү, яраткан җырчыларының концертларын оештыру, гастроль чыгымнарын күтәрүгә генә кайтып калмыйча, татар милләтен яшәтү юлында чын дуслык булгандыр, дип уйлыйм. Дөнья булгач, төрле мәзәк хәлләр була. Әлфия апа тормышта да, сәхнәдәге кебек, гади иде бит. Шулай бервакыт без Әгерҗегә баргач, Ринат Закировларга кагылып чыкмакчы булдык. Безне кунакчыл татар гореф-гадәте белән, килеп керүгә үк, табын янына дәштеләр. Мич ягылган, кемдер табаларны чаж-чож майлап, мич алдында коймак пешерә. Тәмле коймак кайчан чыгар инде, дип көтеп утырганда, аралыктан башына ак яулык чөйгән, тәлинкәсе белән өеп коймак күтәргән Әлфия апабыз килеп чыкты. Бишмәтләр киеп абзардан Илһам абый да чыкмаса ярый инде, дип эчләр катып көлешкән идек шулчак. Менә шундый гаҗәеп гадилеге белән үзенә тарта белде Әлфия апа. Ул чакта йолдыз дигән сүз юк иде бит. Кеше бит – җирдә, ә йолдызлар күктә балкыйлар, алар зур, бөек шәхесләр булсалар да, халык белән тигез, бергә булдылар, беркайчан да арага киртә куймадылар. Татар сәхнәсендә Әлфия Авзалова стиле, образы бүген дә саклана. Бүгенге татар эстрадасы җырчыларының күбесе Әлфия апа беренчеләрдән булып керткән бу алымны бик теләп куллана. Чөнки, сәхнәгә чыккач, бер гаилә әгъзаларыдай эчкерсез сөйләшү, җылы аралашу тамашачы белән җырчыны күренмәс җепләр белән бәйли, якынайта. Әлфия Авзалова концертлары шуның белән дә онытылмас, кабатланмас, җылы, якты, нурлы иде, өстәвенә, кабатланмас моң! Менә монысын инде кабатлап булмый, кешедә бу бар, яисә юк!

Әлфия апа турында тагын бер якты истәлек! Әлфия апа, әйтүемчә, бик милләтпәрвәр җан иде, татарлар кайда – ул шунда! Бервакыт без Удмуртиянең «Яңарыш» редакциясендә булганда, ялт иттереп, кояштай елмаеп, Әлфия Авзалова килеп керде. Аны колач җәеп каршы алдык, татарлар тормышы турында, милләт киләчәге турында фикер алыштык, барыбыз бергә истәлеккә фотога төштек. Бу фотосурәт бүген дә шул көннәрнең якты истәлеге булып тора. Мин Әлфия апаны җырчы гына түгел, милләтне яшәтүче ватанпәрвәр зат буларак та хөрмәт итәм. Ул эшләгән эшләрне бернинди бизмәннәр дә үлчи алмас, чөнки аның җырларында күңелләргә сыймас мәңгелек моң яшеренгән!

Исламия МӘХМҮТОВА,
театр актрисасы,
Татарстанның халык, Россиянең
атказанган артисты



Мин Әлфия ападан үрнәк алдым!

Әлфия апа белән без 1963 елны Түбән Әлки авылы елгасы буенда очраштык. Элек бит артистлар, авылдан авылга ат чаналарында, трактор чанасы, машина өсләрендә утырып йөриләр иде, концерт, спектакльләр куеп, авылда кунып калалар, чөнки юллар юк иде.

Әлфия Авзалова Әлки районы авылларында концерт куеп йөри икән, дигән хәбәр бик тиз таралды. Без аны шатланып көтеп алдык. Клубтан ерак түгел, Кәримә апаларга квартирага кергән икән, диделәр. Аның белән бик тә очрашасым, аны күрәсем килә бит. Түземсезлек белән мин аны эзләп киттем. «Ул өйдә юк, су буена китте», – диделәр.

Су буенда Әлфия апа керләр чайкап ята, кечкенә кызы коляскада йоклый (ул Зөлфиясе булган икән). Мин кыюсыз гына Әлфия апа белән исәнләштем, ул елмаеп: «Менә, балаларның керләрен юган идем әле», – диде. Шуннан аның белән сөйләшеп, танышып киттек. «Әлфия апа, минем бик тә артистка буласым килә», – дидем. «Бик яхшы, әгәр сәләтең бар икән, әнә, филармония ансамбльгә кызлар җыя, барып кара!» – диде. Мин, шатланып, рәхмәтләр әйтеп, кичке концертны көтә башладым. Сәхнәгә Әлфия апа озын матур күлмәктән килеп чыкты, нәкъ курчак инде. Халык кул чаба, ул җырлый. Мин сихри дөньяда утырам кебек. Аның тавышы, аның моңнары әле дә колагымда чыңлый. Берничә көннән соң, мин Казанга киттем. Казанда минем Талия исемле дус кызым бар. Мине Казан белән таныштырып йөргәндә, Кремльдә Спас башнясына ябыштырылган «Татарстан Республикасы күчмә театры» дип язылган тактаны укыгач, минем аның эченә керәсем килде. Чөнки безнең авылга күчмә театр артистлары килгәне бар иде. Икенче катка күтәрелдек. Кечкенә генә бүлмә икән, артистлар отпускыда, диделәр. Директор М. Хәмзин, режиссер Р. Тумашев иделәр. Мин, бер дә оялып тормыйча: «Абый, мине ар-

тистлыкка алыгыз әле?» – дидем. Алар мине җырлатып, биетеп, шигырьләр сөйләтеп карадылар да кабул иттеләр.

Менә шулай мин артист булып киттем. Филармониягә барып җитә алмадым. Әлфия апалар белән гастрольләрдә бик еш очраша идек. Өйгә кайт кач, хәлләр сорашабыз, туган көннәребезгә чакыра идек. Хәлилгә 50 яшь тулган көнне Әлфия апа Германиядән кайтып төште. Ял да итмичә, безнең К.Тинчурин театрына килеп, сәхнәдән: «Мәхмүт энем! Синең юбилейга кайттым. Билетлар беткән. Ләкин билетсыз булса да менә кайтып җиттем», – дип, көлдереп, җырлап, безнең бәйрәмебезгә якты нурын өстәде (Хәлилгә Мәхмүт диеп эндәшә иде ул). Әлфия апа бик тә кызык кеше. Аның сөйләгәннәрен тыңлагач, тагын да яшисе килә, аның кебек буласы килә, ул үзенең кешеләргә яхшы энергиясен бирә иде.

Еллар уза, гастрольләр, гастрольләр... Миңа 1987 елның 11 августында «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирделәр. Мине Татарстанның Югары Советы Президиумы җитәкчелегенә чакырдылар. Анда язучылар да, төрле вәкиллек хезмәткәрләре дә, Әлфия апа, Лима Кустабаева да бар иде. Безне бик матур итеп котладылар. Әлфия апа, гел гастрольләрдә булу сәбәпле, чакырган вакытларына туры килмәгәндер инде, ул бөтен бүләкләрен берьюлы алды. Күкрәге орден-медальләр белән тулды. Бик матур мизгел булды бу. Без, шатланып, рәхмәтләр әйтеп, таралыша башладык.

Коридорга чыккач, Әлфия апа:

– Кызлар, бу байлыкны «юарга» кирәк бит. Әйдәгез, Азык-төлек министрлыгына керәбез. Буш чыгармас әле, бик әйбәт егет ул! – дип, безне үгетли башлады.

Ул заманнарда бар әйбер дә талонга гына иде. «Юк, Әлфия апа, мин кермим, оялам», – дидем. Лима да, әллә ничек, дип тора. Безне ачуланып ташлады. «Их, сез жүләрләр, мин сездән сорамыйм, үзем әйтәм, сез бик матур, чибәр кызлар, миңа иптәш кенә булып керегез», – дигәч, без ризалаштык. Ишекне шакып, керергә ярыймы, дип, иң беренче безне этеп кертеп җибәрде. «Исәнмесез, менә нинди чибәр кызлар белән хәлегезне белергә кердек әле, үзләре бик тә сәләтле, халкыбыз ярата торган артистлар, дип, сайрый да, сайрый. Менә, энем, безнең күкрәкләргә генә кара, күкрәк тулы орден-медальләр, боларны «юмыйча» булмый бит инде... Карала, диләр!» Министр урыныннан торып, көлә-көлә, урыннар тәкъдим итте, күреште. «Ярар, аңладым, Әлфия апа, бары да булыр дип, секретарен чакырып алды да, аңа әмер бирде. Озак та үтмәде, без сөйләшеп утырган арада, өч кәгазь тартма керттеләр. Без аңа рәхмәтләр әйтеп, чыгып киттек. «Кызлар, боларны күтәреп кайтып булмый бит инде, әйдәгез, транспорт министрына кереп, машина сорыйбыз», – диде. Инде без дә ялындырып тормадык. Өченче бүлмәгә кереп тә киттек. Әлфия апа һаман бер үк сүзләрне кабатлап, сөйли дә сөйли. Менә бүләкләр бирделәр, безне озаттырып куегыз инде, дигәч, «Әй, Әлфия апа, сезне җәяү йөртмәбез

инде, дип, ул да секретарена әмерен бирде. Рәхмәтләр әйтеп, чыктык. «Кызлар, килгән-килгән, әйдәгез, Мансур Хәсәновичка да кереп чыгыйк», – ди бу.


Ярар, аңа да кереп киттек. Безне Мансур Хәсәнович бик матур каршы алды. «Әйдәгез, кызлар, түрдән узыгыз», – дип, урыннар тәкъдим итте. «Бигрәк матур җирдә утырасыз инде, бүлмәләрегез зур, якты, Казансу елгасы күренеп тора. Без сезнең хәлне белергә кердек әле, менә бу чибәр кызлар белән. Менә күкрәккә кара син, Мансур Хәсәнович, бүген безне бик зурладылар. Күкрәк тулы орден-медальләр...» Мансур Хәсәнович безне барыбызны да кул биреп котлады. «Мансур Хәсәнович! Бу Тукай премиясен алмаган кеше калмагандыр, чират миңа җиткәндер инде. Минем телем Тукай теле белән ачылды, аның җырларын җырлап, бөтен дөнья буйлап йөрим», – дип шаярган була.

Мансур Хәсәнович: «Әйе, Әлфия ханым, дөрес әйтәсең, син аңа, чыннан да, лаексың. Уйлашырга, сөйләшергә кирәк. Булыр!» – дип вәгъдә бирде.

Без рәхмәтләр әйтеп, саубуллашып урамга чыктык. Анда безне машина көтеп тора, тартмалар, күчтәнәчләр куелган. Көлешә-көлешә, бер-беребезне озатышып йөрибез. Әмма аерыласы килми бит! Күчтәнәч шактый саллы күренә. «Әйдәгез, Исламия, сезгә барыйк. Мәхмүткә хәзер шалтыратыйк, мичкә бәрәңге ыргыта торсын, идәнгә ашъяулык җәеп, бер рәхәтләнеп сөйләшеп утырыйк әле», – диеп, Хәлилгә шалтыратты. Без өйгә килеп кергәндә, мич бәрәңгесенең тәмле исе борынга килеп бәрелде. Идәнгә утырып, бүген булган хәлләрне искә алып, көлешә-көлешә ашадык.

Бу мәңге онытылмаслык мизгел булды. Әнә шундый батыр йөрәкле, үзе гади, үзе шаян, үзе горур, халкыбызның бик яраткан якты йолдызы иде. Мин һәрвакыт аңардан үрнәк алып яшәдем һәм яшим! Халыкның мәхәббәтен яулау бик җиңел түгел. Юллар... Гастрольләр... Гаилә кору, балалар үстерү, аларны аякка бастыру, кеше итү артистка җиңел түгел. Иң мөһиме: яраткан халкыңа хезмәт итү – үзе бер батырлык! Рәхмәт, Әлфия апа! Урының җәннәттә булсын...

Искәндәр БИКТАҺИРОВ,
җырчы, Татарстанның халык артисты



Мин Әлфия апаның җырларын бүген дә җылый-җылый тыңлыйм. Бер ләззәт кичерү өчен генә түгел, эшем, сәхнә өчен дә кирәк бөек җырчыбызны истә тоту. Әй рәхәт булып китә шул чакларда...

Аның белән бергә гастрольләрдә йөрергә туры килсә дә, Әлфия апаның бригадасында эшләү насыйп булмады. Соңгы елларда «Урал-Себер» фестивальләрендә еш очраштык. Чиләбе, Ырымбурларда булганыбыз әле дә истә. Ырымбурдан кайтышлый, Абдуллино районында туктап, табигать кочагында хозурланып йөрүебез бүген дә күз алдымда. Көз ае иде.

– Табигать бигрәк матур инде! Каеннарны кочаклап аласым килә! – дип тәэсирләнде Әлфия апа. – Ул үзе дә – табигать баласы иде бит. Аның бөтен гомере сәхнәдә узды, бөтен яшәеше сәхнә иде. Әле хәзер дә уйлап куям: балаларын ничек үстергән икән?! Сәхнәдә, халык алдында җырлаганда үсеп-буй җиткереп килгән кызлары күңеленнән китмәгәндер. Ашаганнармы, юкмы, шапшак йөрмиләрме, кырын юлга кереп китмәгәйләре, дип тә борчылмый калмагандыр. Никадәр зур талант, никадәр зур ихтыяр көче булган анда. Дөрес, хәрәкәт ике яклы булды: халык бик яратты аны, халык мәхәббәте, алкышлары яшәтте. Үзе дә халкым, тамашачыларым, татарларым дип өзелеп торды. Олы яшьтә дә җырлап йөрүе, шуңа көч табуы – сәхнәнең бер зур сере ул.

«Күл буена килсәң иде», «Кил, иркәм, кил инде» кебек җырларын кемнәр генә отып алып җырламагандыр?! Бер ишетүдә истә кала, күңел түренә кереп урнаша ич. Аның пластинкалары чыгу үзе бер зур вакыйга була иде. Аны бөтен җирдә җыелып тыңлыйлар. Һәрбер тәрәзәдән, һәр клубта аның җыры яңгырый. Без яшь артистлар булып сәхнәгә чыга башлаган вакытта да клубларда Әлфия апаның җырлары яңгырап торды. Бөтен җирдә Әлфия апа, Илһам абый пластинкасы! Милләтнең иң кирәкле җырларын тыңлап үстек без. Милли җырларыбызны җырлап, ничәмә буынны тәрбияләп үстерде алар! Шуларны тыңлап үскән җырчылар бүген дә сәхнә тота. Салаватлар да шул исәптә. Ул вакытларда радиода кабат язылу өчен бер ай узгач кына килергә мөмкин иде. Әлфия апа, вакыты булганда, гастрольләрдән бушап торганда килеп язылгандыр инде. Анда килеп язылу өчен яхшы хәлдә булуың да кирәк бит әле.

Мин мактанып та, сөенеп тә сөйлим: соңгы елларда аның белән еш аралаштым. Хәл белергә бара идем, үзе дә, вакытың булганда килгәләп тор, дип чакырып торды. Әй, теләгем бар иде, тик Әлфия апа бригадасында эшләп булмады. Шул гына үкенечкә калды. Аның репертуарыннан «Төнбоеклар», «Актаныш басмалары»н җырладым. Кайсы гына җырын алып җырласаң да, аның җырлары затлы, матур. Ул җырларны тыңлап, җырлап, мин үзем дә үсеп китәм. Җырларны шундый югарылыкка күтәрүе – зур казаныш бу!



Кадим НУРУЛЛИН,
Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры

Миңа җитәкчегә караган кебек карый иде

(Зимфира Гыйльметдинова әңгәмәсе)

Әлфия Авзалова... Халкыбызның тугры, моңлы, кабатланмас җырчысы. Дөньяның ачысын җитәрлек татыганнан соң, бер генә бизмән белән дә үлчәп бетереп булмаслык шөһрәткә ирешкән ИЛ КЫЗЫ. Бизәкләрсез, купшы мактауларсыз, исемен әйтүгә үк, һәр татарның йөрәгендә ялкын кабызган, күкрәкләрне киереп атларга, башны горур тотарга мәҗбүр иткән шәхесебез иде ул... Хәер, нигә – «иде». Гасырларга күчәр җырлары аша бүген дә халкыбызны кыю, зирәк, көчле булырга чакыра лабаса ул.

Гомере буе диярлек Татар дәүләт филармониясендә эшләгән Әлфия апа. 1951 елда ул чакта филармониядә булган Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә җырчы булып килгән дә вафатына кадәр диярлек биредә эшләгән. Әлфия апа белән гастрольләргә йөргән артистлар, чын мәгънәсендә, бәхетле булганнар. Чөнки аның белән гел эш бар, эш булгач – аш бар. Аның төркемендә эшләгән бер халык артистының гажәеп авыр, илдәге ике кешенең берсе эшсез калган 90нчы еллар уртасында әйткән сүзләре истә: «Әлфия апа гына сау булсын. Аның белән булганда, ачка үлмәбез».

Филармониядә әллә ничә җитәкче белән эшләгән Әлфия апа, җырчының ижат гомерендә шактый алмашынган алар. Холкы белән чая булса да, җитәкчеләр белән сак булгандыр, дип уйлыйм мин аны. Хәзергечә әйтсәк – һәрчак субординация саклаган, җыр патшабикәсе икәнлеген аңлаган хәлдә – хөкүмәт тарафыннан җитәкче итеп куелганнарга беркайчан да каршы сүз әйтмәгән, каршы бармаган. Бу да – сыйфат, җырчыга хас булганча – аның көчен, җегәрен кирәкмәс юлга җибәрмичә, фәкать җыр өчен генә тотар өчен кирәк ул.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясен 30 яшь тә тулмаган килеш директор буларак кабул итеп алган, уникаль традиция – Илһам ага Шакировның, Әлфия апа Авзалованың туган көннәрен ел саен зур сәхнәдә купшы концертлар белән уздыруны керткән, 13 ел дәвамында аны берничек тә туктатмаган Кадим Нуруллин белән Әлфия апа хакында сөйләшкәндә дә, җырчының җитәкчеләргә гаять зур хөрмәт белән каравы хакында сүз булды.

– Сез соңгы елларда Әлфия апа белән тыгыз аралашкан кеше, истәлекләрегез күптер. Аның белән ничек аралаша идегез: бөек җырчы белән яшь җитәкче аралашуы идеме ул, шаян, акыл өйрәтү, киңәш бирүләр белән сугарылган сөйләшүләрме?

– Әлфия апа белән аралашканда мин үземә ниндидер «скидка» белән сөйләшүен, яшь дип ышанмыйчарак аралашуын беркайчан да сизмәдем. Миңа ул җитәкчегә караган кебек карый иде. Күрәсең, ул элеккеге – коммунистлар заманыннан калган җитәкчеләргә хөрмәт белән карау гадәте булгандыр. Әлфия апа үзенең гадилеге белән даһи иде. Зур белемнәре, әллә ничә дипломы да юк иде аның. Ләкин әйткән сүзләре гениаль, фикерләре зирәк иде. Шуңа да сүзләре, җөмләләре халык арасында мәкаль булып таралган да. Беркайчан кеше сөйләмәс иде, беркайчан. Минем өчен шуның белән дә аерым хөрмәткә ия иде.

– Әлфия апаның акчага аерым бер, хәтта мәзәкләргә кергән мөнәсәбәте бар иде. Сезнең арада, шактый уртак концертлар авторы булганлыктан, акча мөнәсәбәтләре дә булгандыр.

– Әлфия апа матди якка бик игътибарлы иде, анысы хак. Ул аның ятим, юклык белән үскәнлегеннән килеп чыккандыр. Хәтеремдә бер хәл саклана –



Әлфия апаның туган көненә багышланган бер концерттан соң, икенче көнне аны гонорарын алып китәргә чакырдык. Ул шактый саллы иде. Өенә машина белән кайтарырга куштым. Аны озатып бер сәгать вакыт уздымы икән – Әлфия апа кабат килеп керде. Куркып калдым – подъездда талаганнар, ахры, дим. Юк икән. Филармония янындагы бер кибет директоры аңа күчтәнәчкә азык-төлек вәгъдә иткән дә, шуларны алырга барышы икән. Үзенә әйтмәсәм дә, саллы гонорар алгач, бушлай ризыкка ник кызыгуын аңламадым ул чакта. Миңа ваклану булып тоелды бу. Берничә көннән мин аның әлеге гадәте – килгән бер генә нигъмәттән дә баш тартмавы, күчтәнәчне, байлыкны, башкасын беркайчан кире какмавы – балачакта кимсенүләрне, ачлыкны, ялангачлыкны оныта алмаудан, бернәрсәне дә исраф итәргә өйрәнмәгәнлектән икәнлеген аңладым. Без бит ул күргәннәрнең йөздән берен дә күргән буын түгел. Аның тойгылары да, гадәтләре дә – аның гомер агышы нәтиҗәсе, безгәме аны хөкем итәргә?..

– Ул бит беркайчан да үзе өчен генә сорамаган. Туганнары, төркемдәге артистлары, мохтаҗлар өчен сораган, һәркем белән бүлешкән. Бу хакта Әлфия апа белән аралашканнар яхшы белә.

– Әйе, үз популярлыгыннан үзе генә кулланмаган ул. Акчасызлык заманында азык-төлеккә дә эшләп йөргәннәр бит, артистларына яшәр өчен ризык тапкан. Әлфия апа турында төшереләчәк кинода да, китапларда да җырчының гаделлеге, миһербанлылыгы чагылыр дип ышанам. Без башка, күпкә битараф заманда яшибез, кеше проблемасы белән бик кызыксынмыйбыз, һәркем үзе өчен күбрәк кайгыра. Әлфия апалар заманы үрнәге, рухы хакында, әлбәттә, сөйләргә, язарга, яшьләргә әйтеп калдырырга кирәк.

Кадрия ИДРИСОВА,
«Ак калфак» татар хатын-кызларының республика иҗтимагый оешмасы рәисе



Шулай бервакыт Әлфия апа белән аскы Актанышның ике юл чатында басып торабыз. «Әле мин кечкенә чакта бу таллар тәбәнәгрәк иде, – дип, җырчыбыз үз истәлекләрен барлый башлады. – Бәлки шуңадыр, егылып төшкән чаклар истә түгел. Ләкин менә шушы тирәкләрнең ботакларына басып җырлауларым һаман да истә. Белмим... Бәлки, башкалар да ишетсен, дип тырышканмындыр инде. Тирә-юньдә кеше-мазар күренсә, тагын да кычкырыбрак җырлый идем. Бу өянкеләр минем беренче сәхнәм булгандыр, апаем». Әлфия апаның миңа «Апаем» дип эндәшүен

кайберәүләр, бәлкем, аңлап та бетермәгәндер. Безнең якларда өлкәннәрнең яшьрәкләргә яратып әйтә торган сүзе ул.

Элек-электән үк тормышым сәнгать өлкәсе белән үрелеп барса да, 90нчы еллар уртасында эш урынымны алыштыргач, әлеге даирә әһелләре белән аралашуым тагын да артты. Шул шәхесләрнең иң-иңнәре булган Әлфия апа Авзалованы шалтыратып кунакка чакырырга туры килде. Җырчыбыз берсүзсез ризалыгын бирде, ләкин шунда ук бер шарт куйды: «Сеңлем, миңа җиргә тия язып барган машина җибәрмәгез, мин биек машинада йөрергә яратам», – диде ул.

Әлфия апа кайтып җиткәч, өстәл янында кабат шушы әңгәмәне дәвам иттек. «Өйрәнгәнсез сез, Әлфия апа, гел биектә, сәхнәләрдә генә чыгыш ясап», – дидем, шаяртып. «Әйе, өйрәнгән шул! – диде Әлфия апа. – Күпме гомер грузовик-сәхнәләрдә җырлап йөреп кара әле син, сеңлем...». Бу безнең күренекле якташым белән якыннан беренче аралашуыбыз, сөйләшүебез иде. Нәкъ менә шул мизгелләрдән башланып киткәндер инде моң алиһәсе – Әлфия апа белән ике дистә елга якын сузылган дустанә аралашуыбыз.

Кабатланмас мизгелләр бик күп булды. Бүләк урманының тау башына басып, аскы Актаныш табигатенә сокланып кычкырып җырлап җибәрүләре, чишмәләргә карап, су агышлары да икенче бит безнең чишмәләрнең, дип сокланулары, яшүсмер чорындагы кызыклы вакыйгаларны искә төшереп сөйләүләре, халык белән аралашуга атлыгып торуы... Кайда гына булсак та, кара инде безнең Актанышыбызны дип, кабат-кабат әйтә иде.

Кендек каны тамган җире башка якларда булса да, Әлфия апабызга Актанышыбыз нигәдер бик якын иде. Сәбәбе аның сүзләрендә ачык чагыла: «Бетле бер Әлфия идем бит инде мин...», – дип әйтә иде бөек җырчыбыз, балачагын искә төшергәндә. «Шушы халык булмаса... Җиде классны бетерүгә, клуб ачкычы тапшырдылар. Әллә бик оста эшли белгәнгә, дип уйлыйсыңмы? Без-ятимнәргә игътибарлы иде шул халык. Җырлавымны күреп, юнәлеш бирүләре булгандыр инде».



Җәйнең бер кичендә: «Әлфия апа, иртәгә

сезнең көнегез иркенрәк. Такталачык авылындагы шифаханәдә дәваланучыларга җырлап кайтмыйсызмы?» – дип сорадым (анда Минзәлә, Мөслим, Әгерҗе, Актаныштан җыелган халык дәвалана иде).

– Ә аппаратура бармы соң?

– Профессиональ аппаратура юк инде анда.

– Ярар алайса, энекәш ял иттерсә, барам.


Кунагыбызның әлеге сүзләре аның чыгышлары арасында ирем Азат Нургалиевның җырлап ял иттерүе турында иде. Гаҗәеп матур, кояшлы көн иде ул. Халык бик күп җыелган. Капкадан килеп керүгә, көчле кул чабулар белән каршы алдылар. Яшел үлән-сәхнәдә Әлфия апа үз моңнарын суза. Өч-дүрт җыр... Аннан аны Азат алыштыра, кабат Әлфия апабыз дәвам итә. Тамашачылар арасында урыс халкы булуын белгәч, ул телдә дә җырлар башкарды якташыбыз. Һәр кешенең күңелен күрде, тамашачының бер генә соравын да җавапсыз калдырмады. Аны бик яратып, булса да булыр икән тавыш, дип озатып калдылар.

Икенче көн дә очрашуларга бай булды. Көндез Байсар, Пучы, Киров авыллары Сабантуйларында мәйдан тотса Әлфия апа, кичен инде без Актаныш үзәге стадионында идек. Нәкъ шушы кичтә җырчыбызның тагын бер гаҗәеп ягын ачтым: стадион сәхнәсендә, ике җырын җырлап бетергәч, кызыкларын сөйлисөйли, сәхнә артына кереп даруын эчте дә, берни булмагандай, халык алдында җырлавын дәвам итте. Чыгышын тәмамлагач: «Әлфия апа, дарулар эчә-эчә, бу яшькә җиткәч, җырлап йөрү кирәкме икән?» – дип сорадым. «Әлфия беткән, димәсеннәр, җырлыйбыз әле, сеңлем!» – диде, ул вакытта җитмеш биш яшен түгәрәкләп килгән җырчыбыз. Бәлки, аның үз Актаныш халкына рәхмәтен белдерүе, әле дә бирешмәвен күрсәтүе булгандыр.

Чыннан да, халыкка рәхмәте зур иде җырчыбызның. Шушы егерме ел эчендә Әлфия ападан якташларыбыз турында күпме истәлекләр ишетергә туры килде. Бигрәк тә Актаныш халкының аны Казанга озатуы турында хатирәләрне яңартырга ярата иде. «Берәү – яулык, икенчесе – кофта, өченчесе шарф бирде. Шулай җыеп, төйнәп җибәрделәр», – дип көлеп җибәрә иде Әлфия апа. «Менә шулай бернәрсәсез чыгып киттем мин, апаем», – дип, җитди сөйләшүгә күчә иде.

Вакыт һаман да алга атлый. Көн – төнне, төн көнне алыштырган кебек үк, бер буын икенче буынны алыштыра. Табигатьнең әлеге кагыйдәләре ничек кенә кырыс тоелмасын, без – кешеләр, аларга буйсынып яшәргә мәҗбүр. Мәңгелек булып тоелган Әлфия апа да инде арабызда юк. Хатирәләремне барлап әлеге язмамны язганда, «татар» исемен, татар телен дөньяга таныткан җырчыбызның һәрбер әйткән сүзен, кылган гамәлен искә төшерергә тырыштым. Әлфия апа, чыннан да, бөек иде һәм бөек булып кала бирә. Авырлыкларны, ятимлекне шаян сүзләре астына яшереп яши белгән якташыбызның гаҗәеп көчле ихтыярлы шәхес, үз максатына ирешүчән, үҗәт, түземле, сабыр хатын-кыз икәнен күреп, аңлап, аның алдында баш иям!

Кәрим ГАБИДУЛЛИН,
музыкант, Татарстанның
атказанган артисты,
Сания ГАБИДУЛЛИНА,
аның тормыш иптәше



Ярты гасыр бергә булдык

1965 елда Казанда КХТИны тәмамлаганнан соң, мин бу профессиянең өнәмичә, үземне тулысынча музыкага багышларга булдым. Шул теләк белән музыка училищесының баян классына укырга кердем. Аны уңышлы гына тәмамласам да, баянга түгел, гитарада уйнарга тартылдым. Башта иске гитараларда уйнадым, чөнки, яңалары кыйммәт булуга карамастан, аларны табуы, алуы бик кыен иде. Тора-бара Казандагы башка музыкантлар белән таныштым. Алар белән Горький паркында чыгышлар ясый башладым. Берсендә, хәтта, безне Мөслим Могамаев концертында уйнарга чакырдылар. Әлбәттә инде, хезмәт хакы даими түгел, без үзебезнең эш өчен тиешле акчаны да сорап ала алмый идек. Иң мөһиме: безнең өчен яраткан уен коралында уйнау, үзебезнең күңелебезне үзебез күрү. Эдик Литвинский дигән музыкант, барабанчы Гена Ефстегнеевлар белән бергә уйнап йөри торгач, куллар хәйран ук шомарды, уйнаганым үземә дә ошый башлады. Бервакыт София Ротару гастрольләр белән килгәч, безне аның төркемендә уйнарга чакырдылар. Эдикны үзләре белән Болгарияга алып киттеләр, ул «Червона рута» төркемендә эшли башлады. Көннәрдән бер көнне мин Юсыф атлы музыкант белән очраштым. Ул үзенең танылган татар җырчысы Әлфия Авзалова бригадасында эшләве турында әйтте, мине дә шул төркемгә эшкә чакырды. Гена Ефстегнеев та алар төркемендә эшли икән, ул да мине ныгытып үзләре белән эшләргә кыстады. Мин ризалаштым. Бу 1969 ел иде. Әлфия апа төркеменә килгәч, җырчының үзе белән очраштым. Беренче күрүдә үк, ул миңа бик таләпчән, кырыс булып тоелды. Ул үзенә музыкантларны энә күзеннән чыгарып сайлагандай алды. Алда мине зур сынау көтәчәге көн кебек ачык иде. Тора-бара ул Юсыф белән мине аеруча нык хөрмәт итә башлады. Үзенең киләчәк иҗат юлын бездән башка күз алдына китермәгәнлеген әйтте. Шул көннән без бер-беребезгә тулы ышаныч белән карый башладык, гомер буе авыр да, рәхәт тә артист тормышы белән кайнадык. Әйтергә генә ансат – безнең Әлфия апа белән иҗат юлыбыз – 50 ел! Бу ярты гасырлык иҗат юлында нинди генә авырлыклар, мажаралар, киртәләр, упкыннар аша

узмаганбыздыр?! Әлфия апа безне, ана кош сыман, үз канаты астында саклап йөртте дисәм, бер дә ялган булмас. Ул гадел, туры сүзле, кырыс, әмма кешелекле иде. Бервакыт Казахстанга гастрольләр белән бардык, инде билетлар алынып, кайтыр вакыт җитте дигәндә, кунакханәдә бер күңелсез хәл булды. Берзаман Әлфия апа: «Тәмләп помидор белән чәй эчәрмен дигән идем, теге кабахәт Шамил кеше суйган, – дип, башларын тотып, үзен-үзе кая куярга белмичә, такмаклап утыра. Биюче Шамил гостиницада эшләүче портьер белән низагка кереп, ялгыш аның кан тамырын җәрәхәтләгән икән. Шунда ук кунакханәгә хокук сакчылары килеп җитте. Алар бригада җитәкчесе Әлфия Авзалованы чакырып төшерделәр. Әлфия апа килеп тә керде, Шамилнең яңагына берне ямады да, ныграк элэктергән, күрәсең, хәтта ул тәгәрәп китте. Бу хәлне көтмәгән хокук сакчылары бер мәлгә аптырап калдылар. Әлфия апага: «Сез нәрсә, самосуд ясыйсыз монда, алай ярамый бит», – диюләренә, Әлфия апа: «Нигә ярамасын, аңа чит кешене суярга кем кушкан?» – дип, аларга дорфа гына җавап кайтарды. Бәхетебезгә, ул кеше исән булып чыкты. Хокук сакчылары: «Әлфия апа, йә, биючегезне ни эшләтик, җибәрикме, утыртыйкмы?» – диюенә, Әлфия апабыз, ике дә уйламыйча: «Төрмә!» – дип кычкырып җибәрде. Шамилгә кайтыр юлга самолетка кыйммәт бәягә билетлар алынса да, безнең ай-вайга карамыйча, Шамилне калдырып кайтып киттек. 15 тәүлек утырып, гаебен танып, башка алай кыланмаска тәүбә итеп, Шамил кайтып җитте. Бу гамәле белән Әлфия апа: «Әгәр тәртип бозсагыз, барыгызга да шул булачак, дип аңлатканы көн кебек ачык иде. Эшкә киләсез икән, эшләгез, бик иркенлисегез килсә, эштән соң күңел ачарсыз!» – ди торган иде ул. «Үзе кылган һәр нәрсәгә кеше үзе җавап бирергә тиеш!» – дигән сүзләре әле дә колагымда яңгырап тора. Башбаштаклыкны, гаделсезлекне, тәртипсезлекне бер дә өнәмәде ул. Безнең бригадада һәрвакыт каты режим, тәртип хөкем сөрде. Әлфия апа, әйткәнемчә, бик кырыс, таләпчән кеше. Аңа ошарлык, күңеленә тәңгәл килерлек музыкант табуы бик авыр иде. Әлфия апа кул астында йөзгә якын музыкант эшләп киткәндер, бездә эшләп киткән музыкантлар берсе дә тормыш юлларында югалып калмадылар. Без эш дәверендә 25 программа әзерләдек. Әле программаларны яңарткан арада, гастрольләрдән дә бушап булмый бит, бер чыгып киткәч, ике-өч ай эчендә 108әр концерт биреп кайта торган идек. Елына 4-5 тапкыр Мәскәү, Ленинград якларын урап кайтабыз, өчәр айга Урта Азия якларына китәбез. Кайчакларда төрле шәһәрләрдә концерт куяр өчен көненә 3-4 самолетта очарга туры килгәләде. Бервакыт шундый вакытлар булды, бөтен җирдә гел урысча гына сөйләшәләр, Казанда да татар мәктәбе бары берәү генә иде. Ә без төркемебез белән Җир шарының кайсы гына почмагына барсак та, Әлфия апа татарча җырлады, татарча сөйләште. Телебезне саклап калуда аның куйган хезмәте әйтеп бетергесез зур. Ул гастрольләр вакытында нәрсәләр генә күрмәдек.

Бервакыт Башкортстанның Мостай Кәрим туган авылында концерт

бирәбез. Алгы рәттә Мостай Кәримнең туганнары тезелеп утырган. Әлфия апа, берничә җыр җырлаганнан соң халыкка мөрәҗәгать итеп: «Сез татар авылымы, башкорт авылымы?» – ди. Халык беравыздан: «Татар!» – дип кычкыра. «Ә соң нишләп, сез татарлар арасында бер Мостай Кәрим генә башкортмыни?» – дип куймасынмы?! Халык дәррәү кул чабарга тотынды. Икенче көнне Әлфия апага обкомнан шалтыраттылар. Күрәсең, ул вакытта милләт мәсьәләсе сәяси, каршылыклы тема булган. Бер биш-алты елдан Мостай Кәрим Әлфия апага хат язды. Ул хатта: «Әлфия ханым, ул вакытта Сезнең бер гаебегез дә юк иде, гафу итегез», – дип язылган иде.

Сәхнә арты – сәхнә арты инде, ә менә – сәхнә, тамашачы күз алды тагын да җаваплырак. Мәскәүнең эстрада концертлар залы халык белән тулы иде, кинәт мине уйнап торган җирдән ток сукты, мин сәхнәдә үк аудым. Мин үләргә ятам, Әлфия апа минем якка борылып кына карады да: «Кәрим катты бугай», – дип, җырлавын дәвам итте. Мине «Ашыгыч ярдәм» күрсәтү табиблары сәхнәдән алып чыгып китеп, уколлар кадап, көчкә исән калдырдылар. Нәкъ шундый ук хәл Әлфия апаның үзе белән дә булды. Ул үзе үлем хәлендә булганда да, чыгышын бетермичә, тамашачыны таратмады. Аның өчен тамашачыдан да изге, кадерле кеше юк иде. Шуңа да халык күңелендә мәңге яши Әлфия апа!

Күптән түгел Казанда базарга чыктым, зур джип машинасыннан гәүдәле генә бер ир-ат, минем янга килеп: «Кәрим абый, бу Сез бит, ничек хәлләрегез, әле кичә генә Әлфия апа белән Сезне искә төшереп утырган идек», – дип, хәлләре бетеп, минем хәлне белеште. Әлбәттә, ул инде мине түгел, Әлфия



апаны сагынып минем янга килгән. Бөтен гомер юлы бергә узды бит, онытырлык түгел Әлфия апабызны, аның белән узган озын юлларны, җырлы-моңлы елларны. Әлфия апаны искә алу концертында да Сания белән икебез дә булдык. Әлфия апа аркылы халык безне хөрмәт итә. Алар безнең өчебезне гел бергә күреп өйрәнгән инде. Мәскәү тамашачысына кадәр якын итеп, урын бирепәллә кайдан исәнләшеп, күрешеп, ачык йөз белән каршы алды. Искиткеч матур искә алу кичәсе булды, зал халык белән, гадәттәгечә, шыгрым тулы, Әлфия апабыз гына юк... Сагындыра, бик тә сагындыра Әлфия апа!

Сания ГАБИДУЛЛИНА



Әлфия апа белән озак еллар бергә эшләргә туры килде. Аның якты йөзе, кәефне күтәрә торган кызык сүзләре күңелләрдән мәңге дә китмәс инде. Без аның белән бер гаилә кешеләре сыман яшәдек. Төнлә берничә сәгатькә генә аерылып тора идек тә, көндез – репетиция, кич – концерт, ә гастрольләр вакытында гел бергә. Нинди матур чор булган бит бу, бөтен Җир шары үз иткән татар кызы белән бер юлда йөрү – бәхетнең дә бәхете булган ич! Аннан без бик күп матур гадәтләргә өйрәндек. Ул беркайчан да төшенкелеккә бирелми иде. Бервакыт поездда барабыз, безне монда, кешеләрне үтерәләр, тагын әллә нәрсәләр, дип куркыталар. Мин ышанып, котым очып, йоклый алмас дәрәҗәгә җиттем, Әлфия апа уйлап та бирми, кызык хәлләрне сөйли дә сөйли. Менә шундый булып кара әле син, эчендә ут янса да, белдерми, башкаларга, сер дә бирми, горур татар кызы иде ул! Бервакыт, без өйләнешкәч, көзге каршында басып торганда, Әлфия апа миңа: «Карале, Сания, синең кыз фамилияң нинди иде», – ди. Мин әйтәм: «Шәрәфетдинова». «Әй, менә минеке – Авзалова! Күрче, ничек яңгыравыклы!» – ди.

Берсендә Октябрскидан самолетта кайтабыз. Самолет куркыныч тавышлар чыгарып, шундый нык улый, башкалар паникага бирелә башлады, без – артистлар, кычкырып-кычкырып җырлыйбыз, җырлый торгач, ничек җиргә төшкәнебезне дә сизми калдык. Кызык вакыйгалар бер дә онытылмый, минем Кәримгә кияүгә чыккан гына вакыт. Без – Әлфия апа, Илһам абый, Кәрим – дүртәү, Чаллыда узган концерттан соң, «Татарстан» гостиницасына кайтып барабыз. Миндә ул вакытка кешедә юк, күпләрнең хыялында гына булган ма-

тур джинсы чалбар. Шулчак, Илһам абый: «Сеңлем, монда бандитлар бәйләнә башласа, каршы килмә, сразу ят!» – ди. Мин ышандым инде, көлмичә сөйли бит. « Мин әйтәм, сез нишлисез?» – дим. Ул әйтә: «Без качабыз!» – ди. Шулвакыт барысы да көлеп җибәрделәр, шаяртулары икән. Бүлмәгә кергәч, Кәрим: «Минем хатын матур җырлый, тыңлап карагыз әле, диюгә, алар мине уртага бастырып куйдылар да: «Әйдә, сеңлем, җырла, нинди җыр җырлыйсың?» – диләр. Мин шунда иң яраткан җырым – «Рәйхан»ны җырладым. Башка чакта да гастрольләргә бергә барсак, Илһам абый миңа гел: «Әйдә, сеңлем, «Рәйхан»ны җырла әле!» – ди торган иде. Янымда гомер буе ике бөек шәхес, ике илһамчым булды. Әлбәттә, Кәрим белән бергә эшләү миңа рәхәт иде. Ирем өйдә калып, гаиләле булып, гел гастрольләрдә йөри алыр идемме икән? Күп вакыт миңа: «Сез Әлфия апаның кызымы әллә, бик охшагансыз», – дип тә әйтәләр иде. Хәтта тавышларыбызны да охшата иде кайбер тамашачы халкы. Әлфия апаның дөньядан китүе, балаларыннан кала, безгә иң кыены, иң авыры булгандыр, мөгаен. Без һәрвакыт, кайда гына йөрсәк тә, кайда гына булсак та – өчәү идек, ул кемгәдер охшагандыр, кемнеңдер ачуын чыгаргандыр. Әмма ул безнең булу белән бик тә бәхетле иде. «Без, кешеләр сыман, парлы гына түгел – өчәү, арага берсен дә кертмәгез! – дия торган иде ул безгә. – Әй, гел канатларыңны җәеп кенә торасың инде», – дип, минем барлыгыма сөенә торган иде. Үзе дә безнең өчен җанын да бирергә әзер иде Әлфия апа. Без аның яратканын сизә, тоя идек. Без аны бөек артист буларак түгел, анысын барыбыз да белә, икенче яктан – кешелекле, эчкерсез, гади, тугры дус буларак ачарга телибез. Тирә-яктагы кешеләр дә аны бик яратты, аның иҗатын яраттылар, ул үзе халкын, тамашачыларны яратты. Баш әйләнгеч уңышлары белән дә шундый гади булып калуы сокландыра Әлфия апаның. Безнең арада бернинди дә сер юк иде, ул безгә бөтен эч серләрен бушата, киңәшләшә, безгә кирәктә үзе киңәшләрен бирә. Әлбәттә, бар да җырлап кына барды, диеп булмый. Әлфия апаның үзенә генә хас сыйфатлары бар, аларны белеп, холкын аңлагач, бер-беребезгә үпкә тотмый идек. Халык һәрвакыт Кәримне – Әлфия Кәриме дип йөртте. Өйләнергә уйлагач та, Кәрим мине иң беренче Әлфия апага күрсәтте. Әлфия апа ризалык биргәч кенә, без кавыштык. Торабара без гаилә дусларына әверелдек. Бөтен бәйрәмнәрне бергә үткәрдек, бөтен мәшәкатьләрне бергә ердык. Әгәр дә берәр көн күрешмәсәк, ул көнне бер ун мәртәбә телефон аша сөйләшә торган идек. Соңыннан гына телефон аша сөйләшүләр кимеде, ул авырый, телефон номерларын исендә тота алмый башлады. Яшь вакытта аның хәтере бик тә яхшы булды. Ул җыр сүзләрен бик тиз ота, көненә дистәләп анекдотлар сөйли, үзе белән булган вакыйгаларны гел исендә тота торган иде. Карта уеннары уйнаганда, кемдә нинди карта икәнлеген алдан ук белеп, чутлап чыгара торган иде. Ул бик тә матурлыкны ярата, күрә белә. Берсендә мин стенага матур сувенир-тарелка алып куйдым. Ул йорт-җир җиһазларына бик игътибар итмәсә дә, бу матур тарелканы шун-

дук күреп алды. «Нинди искиткеч матур тарелка, каян алдың әле?» – ди. Без, Әлфия апа белән икебез, аның концерт күлмәкләренә матур ялтыравыклар тегә торган идек. Ул вакытта бит матур муенсалар, алкалар, төймәләр берсе дә кибеттә юк, барысын да юллап, кайсын кайдан аласы, табасы, юнәтәсе. Әлфия апаны бөтен җирдә белгәч, аңа беркайда да бернәрсә дә кызганмадылар, кибетчеләр, алыпсатарлар юк җирдән табып бирерләр иде. Аларны алу өчен акчасы да кирәк бит. Соңыннан кызлары Америкадан, Кипрдан иң яхшы материалларны, бизәнү әйберләрен ташып кына тордылар. Бернигә карамыйча, ул үз заманында иң матур, зәвыклы киенүче артистка булды. Аның очып торган иңнәренә нәрсә кисә дә килешә. Аның дәртлелеге, тамашачыга күчеп, аны да канатландыра, урынында биетә. Ул һәрвакыт өч сәгать концерт куйды, беркайчан да, бернинди сәбәп табып та кыскартмады. Авыл һавасын, авыл кешеләрен ярата иде. Гастрольләргә башта кызларын, аннары оныкларын алып йөри башлады, без дә Ләйсәнебезне алдык. Рәхәтләнеп авыл һавасы суласыннар, ди торган иде ул. Эш булгач, һава гына сулап йөрмәдек, бигрәк тә бригаданың бөтен кешесе өчен Әлфия апабыз борчыла торган иде. Берәр нәрсә ул теләгәнчә булмаса, шундук гаеплегә эләгә, алай итмәс иде, бригадага план бирелгән, план үтәмәсәң, акчасыз каласың. Бөтен эшләгән акчаны филармониягә кайтарып тапшыра торган идек, ике план үтәгәндә дә акчаны санап кына түлиләр, менә шундый замана иде.

Бервакыт Болгар шәһәренә баргач, без җырчы Венера Шәрипова белән очраштык. Концерт куйгач, ул безне озата чыкты, без кузгалып киттек. Шулчак Әлфия апа: «Аягы җиңел булса гына ярар иде инде Венераның», – ди. Ул көнне кайда гына адашып йөрмәдек, ахырда, юлыбызны сарык көтүе бүлде. Ул көнне билгеләнгән урында концерт куя алмадык, төнге 11дә генә барып җиттек. Әлфия апа, гадәттә, авылларга килеп җиткәндә берәр километр кала алдан туктатып, басулардан чәчәк җыя-җыя, табигатькә, кошлар сайравына хозурланып, җырлый-җырлый, тавышын көйләп, әзерләнеп бара торган иде. Нинди генә заманнарны кичермәдек! Үзгәртеп кору чорлары бигрәк тә үзәккә үтеп калган вакытлар. Ул чорда бик күп артистлар чыкты, алар барысы да диярлек фонограммага җырлыйлар. Әлфия апаның беркайчан да фонограммага җырлаганы булмады. Үзгәртеп кору чорында Мәскәү артистлары да картотекада, ягъни бурычта утырган вакытта да, Әлфия апаның концертларында тулы зал тамашачы булыр иде. Зур-зур урыс артистларына халык йөрмәгәндә, Әлфия Авзалова Мәскәүнең атаклы «Москонцерт»ында, тулы зал татар тамашачысы белән 24 концерт биреп, бурычтан чыгарган беренче данлыклы җырчы! Ул елларда күп артистлар, хәтта, акчалары булмау сәбәпле, Мәскәү кадәр Мәскәүдә дә җәяү йөрибез, дип сөйли торган иделәр. Менә шундый авыр елларда да, искиткеч зур популярлык казанган, Мәскәүләрне гөрләткән җырчы ул безнең Әлфия апабыз! Моннан соң безне бөтен Мәскәүдәге кон-

церт заллары колач җәеп каршы алды, Әлфия Авзалова өчен монда бөтен ишекләр дә ачык иде.

Ә бит җырлый башлаганда аңа каршылыклар, киртәләр күп булды. Әле минем исемдә: без икәү, эстрада концертлар залында чыгыш ясар өчен, алдан сөйләшенүгә бару. Бу бинага килеп җитүгә, беренче очраган кеше тәрәзә юучы хатын иде. Әлфия апа, аны күрүгә үк: «Без концерт кую буенча сөйләшергә килдек», – ди. Теге хатын аптырап калды. Мин әйтәм: «Әлфия апа, директоры белән сөйләшергә кирәк, бу бит тәрәзә юучы гына», – дим. Менә шулай итеп йөри-йөри шомара кеше. Гади татар кызы, ятимлектә үскән кыз бала, тормышның төбеннән күтәрелеп, йолдызларга юл ала!

Күрмәгәне калмады, түзде, үзе өчен генә түгел, безнең өчен дә тырышты. Кайда гына барсак та, ул бөтен бригада өчен ризык юнәтә торган иде, бервакытта да миңа бирделәр дип, итнең калҗасын үзенә алмады, сөягенсөяккә, итен-иткә тигез итеп бүлдерде. Гажәеп тормыш җанлы, мәрхәмәтле, олы йөрәкле Ана иде. Ничек булса да акча юнәтү, балалар үстерү өчен Польшага бару да, анда барганда, сату өчен, төрле вак тимер-томырлар алып бару да калмады. Бездән әйбер сатучы чыгамы соң, анда да безне танып алдылар, көлделәр үзебездән. Әмма бернәрсәне – горурлыкны югалтмадык, тырыштык, таптык, булдырдык!

Сагындыра... Әлфия апабызга эндәшмәгән, киңәшмәгән көнебез юк, мәңге дә истән чыкмый.. Концерттан соң төннәр буе шул чыгыш, тамашачылар турында сөйләшеп таң аттырулар, хаталарны булдырмау өстендә эшләү... – болар барысы да инде тарих. Әлфия апабызны сагынсак, бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган Зөлфия исемле кызына карыйбыз, гел яшь вакыты инде... Гүзәлебез дә – искиткеч мөлаем, акыллы, уңган-булган әни. Оныклары әйтәсе дә юк! Хәзер инде без аның кызлары-йолдызлары, сөекле оныклары белән дуслыкта яшибез.

Кирам САТИЕВ,
музыкант, Татарстанның халык артисты

Якташым, иҗатташым

Якташым Әлфия Авзалова турында озак, мәгънәле итеп язарга, сөйләргә була һәм кирәктер дә. Аның белән гастрольләрдә булган вакыйгаларга аңлатма-комментарийлар бирмичә, ничек бар, шулай язам.

Әлфия апаның чираттагы юбилей концерты Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында булды. Аның сценарие болай төзелгән иде: Әлфия Авзалова Америка кешесенә кияүгә чыга. Кияү – Равил Шәрәфи. Тамада – Хәлим Җәләй. Баянчы – Кирам Сатиев. Равил абый инглиз телендә генә сөйләшә. Американ, ләбаса. Соңрак татарчага күчә, чөнки кәләш аның телен бик үк аңлап бетерми...

Өстәл тулы тәмле ризык. Кияү белән кәләшне котларга Татарстан сәнгать әһелләре, чит ил кунаклары килгән. Иң гаҗәбе өстәлдә, нәкъ чын туйдагыча, натураль эчемлекләр: чын хәмер, чын шәрабләр... Тагын шунысы кызык булды: тамашачы да, артистлар да бер үк сүзне, бер үк фикерне кабатлый. Гомеремдә сәхнәгә чыгып бер кәлимә сүз әйтмәгән миңа да: «Нәрсә, Әлфия апа, тагын кияүгә чыгасыңмыни?» – дигән реплика әйтергә туры килде. Монысы инде туй-концертның сценарий авторы, режиссеры Алмаз Хәмзинның фантазиясе иде.



Бер атуда – өч куян

Хөкүмәт планын үтәр өчен көндез дә концертлар куя идек. Авылда уттай кызу эш өсте.

– Энекәш, Сатый, булмас ахры бу концерт, халык җыелмас, – дип әйтеп куйды борчылып, Әлфия апа.

– Борчылма, Әлфия апа, безгә язганы булыр. Кайчан әле концертның куелмый калганы бар? Моңа кадәр гел тулы заллар булды.

Шулай диюгә, зал күз ачып йомганчы халык белән шыгрым тулды. Сыймаганнар урамда басып торды. Уттай кызу эш өсте булуга карамастан, авыл җитәкчеләре безне җылы каршы алды. Сүз уңаеннан әйтеп китим: концерт саны, акча планы үтәлмәсә, безнең баштан сыйпамыйлар иде.

Шулчак мин Әлфия апага: «Әлфия апа, авылда халык ике генә очракта җыела, диләр: берсе – суд булганда, икенчесе – председатель алмашынганда. Безнеке – өченче очрак, кыскасы, берьюлы – ике куян гына түгел, өченче куянны да атачакбыз!» – дидем.



Шашлык

Шашлык ясар өчен, иң беренче чиратта ит кирәк. Җәйге гастрольләр тәмам. Колхоз рәисе безне озата барды. «Әлфия апа, сезне шашлык белән сыйлыйсым килә. Урыны – су буенда, яр башында, Казан белән ике арада», – диде ул. Шулай диде дә, Әлфия апаны үзенең вездеходы – «УАЗ»игының алгы урынына утыртты, мин артка кереп постым.

...Килеп җиттек. И бушата, и бушата персидәтел тәмле ризыкларны. Җаның ни тели – шул бар! Кинәт җитәкче тынсыз-өнсез калды. «Әлфия апа, шашлык онытылган...», – ди. Аланда авыр тынлык урнашты...

– Борчылма, энекәш, иртәгә килербез, – дип шаярттым җырчы апабыз, киеренкелекне бераз йомшартып.

Чокыр-чакырлы басу юлларында байтак тузан йотып арыган идек. Кире кайтып шашлык итен алып килүне коллектив кирәк санамады. Булган ризыклар белән сыйланып, ашап-эчеп, рәискә зур рәхмәтләребезне әйтеп, кайтыр юлга кузгалдык. Юл буе шашлык турында сөйләп, үзен бу эшнең остасы дип игълан иткән җитәкченең, шул исәптән, безнең дә хыял тормышка ашмады.

«ПАЗ»икның ишеге ябылганда, Әлфия апа әллә чынлап, әллә көлеп: «Шашлыкка иртәгә, иртәгә...», – дип, кат-кат кабатлады. Ул арада безнең аппаратура төялгән автобусыбыз басуның тузанлы юлына кереп күмелде. Кыскасы, итсез шашлык тәмле булды...



«Сатый, уйна!»

Урта Азия республикаларында – Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстанда гастрольләрдә йөрибез. Тамашачы, һәрвакыттагыча, яраткан җырчысын сагынып көткән. Шыгрым тулы заллар, алкышлар, чәчәкләр... Кайсыдыр шәһәрдә, концертның икенче бүлеген башлаганда, сәхнәнең пәрдәсе күтәрелми генә бит. Пәрдә дигәне, тимер бетоннан эшләнгән дивар. Шушы калын стена электр ярдәмендә генә күтәрелергә тиеш икән. Ут та бар, югыйсә, әмма да барыбер күтәрелми. Җитәкчеләр, сәхнә эшчеләре тыз-быз килә. Акыл сатучылар артканнан-арта, белгечләр – күп, белүчеләр – юк!

Әлфия Авзалова сүзен кистереп әйтте: «Халыкны биздермибез, концертны дәвам итәбез!» – диде дә, алга – оркестр чокыры янына чыгып җырлый башлады. Без – сәхнәдә, аны күрми генә уйныйбыз.

– Сатый, миңа хат-язу бирделәр. «Шахта»ны уйна, җаныем!

– «Сарман»ны сорыйлар! Башкарабыз.

– «Сагынам, дуслар, илкәйне»!

Бер-беребезне күрмичә, тавыш көчәйткечләр аша гына аңлашабыз. Сүз уңаеннан әйтим: ул чакта «хат-язулар» буенча җырлау мәҗбүри түгел, ул худсовет тарафыннан тыела иде. Монысы – вәҗдан эше. Без законны бозмадык, урап кына уздык. «Сәер концерт тамашачыларга аеруча ошады, кем әйтмешли, «На ура!» узды. Ә пәрдә... ачылмады.

Кадерле укучым! Мин сезгә сәхнә арты тормышын сөйләдем. Бу истәлекязмам сөекле җырчыбыз Әлфия апа рухына дога булып барып ирешсен. Урыны җәннәт түрләрендә булсын!



Ләйсән һәм Рената
НИГЪМӘТҖАНОВАЛАР,
Әлфия Авзалованың оныклары

Безгә миллионлаган татар халкы яраткан бөек җырчы Әлфия Авзалова гаиләсендә туу һәм яшәү бәхете тиде. Ул безгә үзен әби дип түгел, ә бәлки, әни сүзеннән алынган «әннәке» дип эндәшергә кушты. Безне тормышта күп нәрсәгә өйрәтте. Хәзер дә аның зирәк киңәшләрен тотып, мәңге сүрелмәс күңел яктылыгына сыенып яшибез. Ул бөтен барлыгы белән җыр

сәнгатенә табынып яшәсә дә, аның өчен гаилә барча байлыктан кыйммәт иде. Ул безне туган җиребезне, телебезне, милләтебезне сөяргә, милли йолаларны, гореф-гадәтләрне тотарга өйрәтте. Хатын-кыз өчен тормышта иң кирәкле шөгыль – аш-су пешерү осталыгына да без әннәкедән өйрәндек.

Ләйсән:

– Минем балачагым бик тә бәхетле булды. Күңелемдә уелып калган бер вакыйганы бик еш искә алам. Миңа 5 яшь иде. Без Казан тимер юл вокзалына әннәкебезне Ленинградка гастрольгә озатырга килдек. Ул, минем читтә ямансулап торганымны күреп: «Әйдә, балакаем, минем белән гастрольгә», – димәсенме?! Бу минутта миннән дә бәхетле кеше булмагандыр. Сөенечемнән аның муенына сарылдым. Әлеге сәфәрдә узган бәхетле көннәремне мәңге дә онытасым юк. Кечкенә чакта рәсем ясарга бик тә ярата идем. Нигәдер минем рәсемнәрдә тату, бәхетле гаилә, күп балалар чагылыш таба иде. Бервакыт әннәке, рәсемнәремне алып карап утырды да: «Ләйсән, кызым, синең, Алла боерса, балаларың күп булыр», – диде.

Бу сүзләрне, әйтерсең лә, ул минем киләчәкне күреп әйткән. Бүгенгесе көндә мин – берсеннән-берсе матур дүрт сабыйның әнкәсе. Газизләремә тәрбияви киңәшләр биргәндә, гел әннәкедән ишетеп белгән тормышчан, күңелемә уелып калган сүзләрне файдаланам. Иманым камил: аның сөекле оныкчыклары беркайчан да әбиләре – бөек җырчы Әлфия Авзалова исеменә тап төшермәсләр.

Рената:

– Мин – әннәкемнең иң кечкенә оныгы, шуңа да ул минем белән иң күп вакытын үткәрде. Хәзерге акылым белән уйлыйм да ис-акылым китә: «Ничекләр гастрольгә безне ияртеп барырга җөрьәт иткән, ничекләр безне тәрбияләргә җай, вакыт тапкан икән?» – дим. Хәзер аңлыйм: ул – искиткеч олы йөрәкле Ана; шул ук вакытта мәхәббәтен сөйгән халкына җыр-моң аша таратучы илаһи моң Алиһәсе булган икән!

Кечкенәдән аның җырларын йотлыгып-йотлыгып тыңлый идем. Минем яраткан әннәкемне халык шулай алкышларга, чәчәкләргә күмүе миндә чиксез горурлык хисе уятты.

Бер сокланып, сәхнәдәге – Әлфия Авзаловага карасам, мең аптырап, күз яшьләренә манчылып, бирелеп моң дәрьясына чумган тамашачыларны күзәттем. Хәзер аңлыйм: туып-үскән туфрагыңны әннәке кебек яратыр өчен, Аллаһы Тәгаләдән бирелгән моң, сәләт, упкын-киртәләрне узарлык көч, тырышлык кирәк икән. Әннәкебезнең бөеклеге – аның гадилегендә, эчкерсезлегендә, дип уйлыйм.

Арабыздан китәргә берничә ел кала, ул мине янына дәшеп китерде дә муенындагы алтын чылбырлы матур кулонын салып миңа кидерде, берсеннән-

берсе матур, изге теләкләр теләде. Нәселебезнең әлеге реликвиясен мин дә киләчәктә, әлеге изге теләкләрне әйтеп, кызым Майяга кидерермен, дип уйлыйм. Минем өчен әлеге муенса-чылбыр – иң кадерле бүләк, бәхет талисманы. Ул мине, әннәкем урынына, җил-яңгырлардан, ялгыш адымнардан, яман күзләрдән, ялган сүзләрдән саклый!

Ләйсән ХӘМИТОВА-МОСТАФИНА,
хореограф, Татарстанның халык артисты



Йолдызлы токмачлар пешерә иде

Әтием Рәшит, әнием Рузалия озак еллар Әлфия апа белән сәхнәдә бергә эшләде. Әнием – оста биюче, әти музыкант иде. Әлфия апа белән әнием хезмәттәшләр генә түгел, җан дуслар да булды. Алар бер-берләренә рәхәтләнеп бөтен эч серләрен сөйли, бергә яңа җырлар өйрәнеп утыра иде. Минем әнием дә бик матур тавышлы, моңлы. Синең бит очыңдагы чокырлар, елмаюың бигрәк матур, гел сәхнә өчен генә тугансың инде дип, хуплау сүзләре әйтеп, әниемнең күңелен күтәрә иде ул.

Минем күңелгә биюче булу теләге кече яшьтән үк кереп оялады, чөнки гел сәхнәдә үстем. Теләгемне тормышка ашырырга теләп, хореография училищесына укырга кердем. Миңа әни эшләп ашарга кирәклеген гел кабатлап торды. Бию теләгем зур булганлыктан, әни мине Әлфия апа төркемендә биергә сөйләште. Әниемнең: «Ул мин башкарган барлык биюләрне дә бии, хәтта миннән дә матуррак бии», – дип мактаганы әле дә исемдә. Каникул вакытында әниемнең әнисе – дәү әнием авырып китте. Әлфия апа мине, әнием урынына, биюче итеп Минзәләгә концерт куярга алып китте. Ике концерт бирдек. Әлфия апа, мин биегәндә сокланuын яшермичә, исләре китеп карап тора торган иде.

Әлфия апаның, менә бит алма агачыннан ерак китми, киләчәге зур булачак бу кызның, дип сокланып карап торуларын сәхнәдәшләрем миңа җиткерә иде. Катлаулы элементлар ясаганда, кызым, берүк аягың имгәнә күрмәсен, дип аналарча кайгырта, борчыла торган иде. Шулай итеп әни мине олы сәхнәгә алып менде. Биюче кызы булгач, миндә җаваплылык икеләтә иде. Ул вакытта Әлфия апаның кызы – Зөлфиясе концертлар алып бара башлады, кирәк булса, җырлый да, үзе матур итеп бии дә. «Минем кызым» диеп, аңа бернинди дә яклау эләкмәде, киресенчә, аннан сорау күбрәк тә иде әле. Ул

кызларын менә шулай үзе янында, үз мисалында авырлыктан курыкмыйча яшәргә, сынмаска, сыгылмаска өйрәтте. Ул вакытларда авыл клублары салкын, бернинди шартлар юк. Клубка керә торган бер ишек, концерт башлангач, сәхнә киемнәреннән беркая да барып булмый. Безгә шул юк шартларны да Әлфия апа тудырып, безнең өчен борчылып, җаен өйрәтеп йөри торган иде.

«Ярый әле, тамашачыларга сәхнәнең матур ягы гына күренә», – дип көлешкән чаклар күп булды. Барыбер дә рәхәт, күңелле иде безгә. Әни белән Әлфия апа үзләре белән һәрчак электрга тоташтыра торган спиральле плитә алып йөрделәр. Алар анда күп вакыт йолдызлы токмачлар пешерә иде. Янгын куркынычсызлыгы буенча гостиницаларда мондый плитәләр белән файдаланырга ярамаганлыктан, аны ят күзләрдән яшереп куярлар иде. Концерт куеп кайтканнан соң, шушы плитәдә тиз генә ашарга пешереп, бөтенебезнең тамагын туйдырыр иде Әлфия апабыз. Хәтта, камыр куеп, пәрәмәчләр пешереп яткан инде безнең әниләр гастрольдә чакта. Әнием һәрвакыт, Әлфия апа төркемендә эшләү күңелемә ял бирә, дип әйтә торган иде. Ул һәркемгә әни була белде, аның күңелендәге яхшылык, изгелек һәркемгә дә җитәрлек иде. Үзенә булмаса-булмады, ул башкаларга яхшы булсын, дип тырышты. Гастрольләрдә чакта да ул күбесенчә башкаларга җылы урынлы караватларны биреп, үзе идәнгә ятты. Мин – танылган артист, дип, борын чөюне бөтенләй дә белмәде, киемнәрен дә, сумкаларын да иңрәеп үзе ташыр иде.

Менә шундый гади, халыкчан шәхес белән очраштырды безне язмыш. Мондый язмышыма мең рәхмәтле! Минем биюче булып китүемдә әниемнең дә, Әлфия апаның да өлеше бик зур, рәхмәт аларга! Бу төркемдә эшләгәндә мин кешелеклелек, ярдәмчеллек, изгелек, әдәплелек кебек кешеләргә кирәкле иң кыйммәтле сыйфатларга өйрәндем, чөнки Әлфия апа төркемендә һәркем бер-берсенә карата ягымлы, дустанә, тату булды. Күп төркемнәрдә җырчылар белән музыкантлар бер дә уртак тел таба алмый иде, аның төркемендәге бер кеше дә беркая китми, музыкантлары белән гомер буе дус, тату эшләве, әлбәттә инде, Әлфия апаның киң күңеллелеге, гадилеге белән аңлатыла. Аның янында бар кешегә дә рәхәт, җайлы, уңайлы, чөнки анда мин-минлек юк иде, ул үзе турында түгел, гел башкаларны кайгыртты.

Без гастрольләрдә чакта юлларда автобуслар белән дә, поездлар белән дә, аппаратураны сөйрәп җәяү дә күп йөрергә туры килде. Поездларга утырганда вакыт кысан, ике минутта тонналы аппаратураны да төяп, чемоданнарны да алып, үзең дә сикереп менеп утырырга кирәк. Әллә нинди кызыкларга очрап бетә идек юлда. Берсендә поездда чакта ялгыш бер музыкантыбыз «стоп кран»га баскан, аның өчен машинистларга бик күп штраф каралган икән. Көчхәл белән, безнекеләр түгел, дип котылды Әлфия апа. Печән җәелгән ачык машиналарда тавыклар белән бергә йөргән чакларны бер дә онытып булмый.

Берсендә борчак басуына тукталдык, минем бер теш коронкасы төшә торган иде. Мин аны кулыма тотып, борчак ашауга шулкадәр бирелеп киткәнмен, коронкам кулымнан төшеп калган. Соңыннан бөтен төркем белән ул коронканы басудан күпме генә эзләсәк тә, таба алмадык.

Музыка аппаратурасының авыр кейсын Әлфия апа гел үзе белән йөртте, ул аны берәүгә дә ышанып тапшырмады, чөнки ул заман өчен музыка аппаратлары бик тә кадерле, кыйммәтле нәрсә иде. Аның бер комплектын безнең төркемгә Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев үзе бирде.

Мин үзем Татарстан Республикасының җыр һәм бию ансамблендә бик күп еллар эшлим. Ул ансамбль быел үзенең 80 еллык юбилеен билгеләп үтте. Мәшһүр Әлфия апабыз, танылган җырчыларыбыз – Хәмдүнә Тимергалиева, Зөһрә Шәрифуллиналар да иҗат юлын нәкъ менә шушы данлыклы иҗат коллективында башлап җибәргән. Һәрбер иҗат кешесе өчен зур сынау, тормыш тәҗрибәсе туплау мәктәбе бу. Иҗат юлымда шундый олы йөрәкле иҗат кешесе белән бер сәхнәдә эшләвемә чиксез бәхетлемен. Ул һәрвакыт минем күңелдә икенче әнием кебек якын, кадерле булып исемдә калыр.

Лилия һәм Әхмәт
ДӘҮЛӘТЪЯРОВЛАР



Ут күршеләр идек

Без инде бүген күршеләр генә түгел, чын дуслар, бер-беребезне туганнан да якын күреп яшибез. Безнең өчен Әлфия апаны югалту кояшыбыз сүнүгә тиң. Аны искә алмаган, сагынмаган бер генә көнебез дә юк. Ул безгә икенче әниебез кебек якын булды.

Мин бу йортка башка шәһәрдән килен булып төштем. Ул чакта бөтен кешедә көне-төне радиолар эшләп тора иде. Аннан искиткеч моңлы, матур җырлар яңгырый. Күңел кылларын тибрәтерлек бер моң башкаларыннан нык аерылып тора. Мин татарчаны бик яхшы белмәсәм дә, үзем музыка кешесе буларак, бу моңның бик тә табигый, җан түреннән чыккан җыр икәнен тоям, тора-бара бу җырчының Әлфия Авзалова икәнлеген белдем. Көннәрдән бер көнне безгә шундый ягымлы, сөйкемле йөзле апа килеп керде. Әнием Лера белән ул инде күптәннән таныш икән. Әнием мине: «Бу безнең иң якын күршебез – Әлфия апаң булыр», – дип таныштырды.

Әлфия апа тавышын ишетүгә мин, профессионал музыкант буларак, аның сөйләвендә ниндидер җанга якын таныш моң, үзенчәлекле таныш авазны сизеп алдым. Үзем дә сизмәстән: «Әлфия апа, сез җырчы түгелме?» – дип сораганымны абайламый да калдым. Ул, бөтен фатирны нурга күмеп: «Әй, каян беләсең? Җырлыйм, әйе, җырлыйм», – дип, сүзне бик тиз икенчегә борды. Минем шул чакта ук аның гадилегенә, тыйнаклыгына исем киткән иде. Тора-бара аралар тагын да якынайды, әни белән Әлфия апаның бөтен эч серләре уртак иде. Хәтерлим әле: Әлфия апа сәхнә өчен нинди күлмәклек алса да, аны безгә күтәреп керә, иң беренче әни белән, безнең белән киңәшләшә торган иде. Күп вакытын Әлфия апа гастрольләрдә үткәрде, шуңа да кызлары Зөлфия белән Гүзәл балачактан ук мөстәкыйльлеккә өйрәнеп, тормыш көтәргә яраклашып үстеләр. Без бөтен бәйрәмнәрне дә бергә, кызык итеп, бер табын түрендә уздыра торган идек. Яңа ел бәйрәме бигрәк тә күңелле иде инде. Без – бер мәйданчыкта биш гаилә, иртәнгә кадәр бер-беребезгә кереп сыйланып йөреп, таң атканын да сизми кала идек, бөтен кешедә – ачык йөз, сый-хөрмәт! Әлфия апа хәл белергә генә кергәндә дә бер генә тапкыр да буш



кул белән керми иде. Аның кулында һәрчак ул гына пешерә ала, авыз сularын китерә торган тәмле, күпереп уңган бөккәннәр, вак бәлешләр булыр. Әни белән озаклап чәйләп, дөнья хәлләрен сөйләшеп, балачаклары узган туган якларын – ямьле Ык буйларын, Актаныш якларын искә алырлар иде. Бәйрәм табыннары күңелле җыр-моңнан башка узмас иде. Әлфия апа торып басып матур җырын сузса, табынга ямь керә, аны башка «артистлар» күтәреп ала. Беркайчан төшенкелеккә бирелеп, кеше гаепләп сөйләп утыра торган гадәте булмады. Кемдер яки ниндидер вакыйга турында сөйләсә, төгәл, кыска итеп, менә шулай булган бит әле, дип әйтеп куюдан узмый.

Мин Әлфия апаны бик тә уникаль шәхес, уникаль җырчы, дип саныйм. Ул татар эстрада сәнгатен тамырдан үзгәрткән беренче юл яручы, тәүге җырчы. Тумыштан ук моңлы бала булган, аңа сәләтне Ходай үзе биргән. Ул чакта аның «Казан утлары» инструменталь ансамбленә кушылып җырлаган беренче җырларын халык дәррәү күтәрелеп, көчле алкышларга күмеп, яратып кабул итте. Озын халык көйләрен җырлаган артистның тамашачылары яшәрде, меңәрләп артты. Иптәшем Әхмәт тә нәкъ шул «Казан утлары» инструменталь ансамбленең музыканты буларак, Әлфия апаның табигыйлегенә, кешеләргә карата булган олы хөрмәтенә, ихтыяр көченә шакката торган иде.

Берара безне язмыш аерып торды, безгә әлеге йорттан күченергә туры килде. Ул чакта да араларны суытмадык, гел хәлләр белешеп, хәбәрләшеп яшәдек. Әмма ни гажәп: без бүген тагын бер йортта күршеләр булып яшибез. Бу безгә Ходайның олы бүләгедер инде! Бүген инде безнең бала балалары – оныкларыбыз бик тә дус, аралашалар, тугандай якын итешәләр. Без әле дә – бик якын күршеләр, Әлфия апаның дәвамы – үзе кебек киң күңелле кызлары белән араны өзмибез. Ул безгә дә, кызларына да тормыш тәҗрибәсен биреп, дөрес юлдан атларга, авырлыкларга бирешмәскә, тормыш юлында сынмаска-сыгылмаска өйрәтеп китте. Аның киң күңеллелеге, тормыш яратучанлыгы сеңгән җырлары бүген дә безне – бар татар халкына матур киләчәк туасына өметен сүндерми. Бу дөньяда тирән эз салып китте, бүген дә якты маяк, тормыш өлгесе ул безгә Әлфия апабыз! Без аның бөеклеген гадилегендә, халыкчанлыгында, милләтпәрвәрлегендә күрәбез.

Мансур ХӘСӘНОВ,
музыкант



Искиткеч шәхес

1981 елның октябрь аенда, Татар дәүләт филармониясенең Вафирә Гыйззәтуллина бригадасында эшләгәндә, мине эстрада бүлеге җитәкчесе Габделхак Гыйләлович, үзенә чакыртып алды да:

– Мансур, Вафирә Гыйззәтуллина авырып китте, сиңа, эшсез утырмас өчен, вакытлыча Әлфия Авзалова бригадасында эшләп торырга туры килер. Аларга клавишник кирәк, әле генә алар бригадасы Уфага гастрольгә китте, диде.

Мин алар артыннан Уфага очтым. Әйберләремне кунакханәдә калдырып, концертка киттем. Аңа кадәр мин Әлфия Авзалова бригадасының музыкаль җитәкчесе Кәрим белән таныш идем. Мин килгәндә, инде зал шыгрым тулы, концертның икенче өлеше бара иде.

Сәхнә ачылды. Алып баручы Нажия Минкина Әлфия Авзалованың чыгышын игълан итте. Сәхнәдә купшы, матур күлмәктән җырчы үзе пәйда булды. Музыка башланды, зал моң әсирлегенә чумды. Җыр тәмамлануга, артист үзенчә гади, җылы итеп тамашачылар белән аралаша башлады. Залдагы меңнән артык кеше, әйтерсең лә, аның әсирлегенә бирелде. Соңгы җырдан соң аны бөтен залдагы тамашачы бик озак, аягүрә басып алкышлады. Мин дә алар рәтендә ике сәгать ярым барган концерттан алган тәэсирләремне тыярлык көчтә түгел идем. Концерт тәмамланып, Әлфия ханым чыгып барганда, аңа тамашачыларның булган хөрмәтенә тагын бер ис-акылым китте. Киткәндә, болай итеп зур түрәләрне дә озатмыйлар. Тамашачылар, ике якка тезелеп, җырчыга рәхмәт сүзләрен әйтеп, бүләкләрен сузып саубуллашулары мине таң калдырды. Җырчы да, үз чиратында, якын туганнарыннан аерылгандай, алар белән искиткеч җылы хушлашты. Минем бу бөек җырчы белән танышуым менә шундый тирән хисләр белән бәйле булды. Аннары без – Кәрим белән бергә, репертуарны өйрәнү өстендә эшләдек. Мин тиз арада коллективка кереп киттем, инде икенче концертта ук, мин сәхнәгә ансамбльнең тулы хокуклы музыканты булып чыктым. Тора-бара без Әлфия Авзалова өйрәнәчәк яңа җырлар өстендә эшләдек. Җырчы җырларын гел яңартып торырга омтыла иде. Аның репертуарында, татар җырлары белән беррәттән,

чит ил җырлары да күп урын алып торды. Ул җырларын сәхнәдә генә түгел, репетицияләр вакытында да бөтен күңелен, җанын биреп башкара иде.


Җәй көне – авыл хуҗалыгы эшләре вакытында, басуда авыл хезмәтчәннәре алдында чыгыш ясау безнең гадәти эшебезгә әйләнде. Администраторыбыз Әсгать Сафин тырышлыгы белән, республиканың бөтен игенчеләре, терлекчеләре көндезге аш вакытында да җыр-моң тыңлап ял итте. Әлфия апа, үзе авыл кызы буларак, авыл кешеләре белән бик иркен аралаша, аларга аерым бер хөрмәт белән карый иде.

Әлфия апаның күңел көрлегенә аптырап, «Әллә сәхнәгә исерткеч эчемлек кабып чыга микән?» – дип уйлаучылар да булгандыр. Әмма мин аның янәшәсендә күпме генә йөрсәм дә, хәтта бәйрәм табыннарында да чәркәгә үрелгәнен күргәнем булмады. Ул тамашачылары белән очрашу бәхетеннән «исергән», күрәсең. Әмма Әлфия апа үзенең көндәшләреннән дә өстен була белде. Ул үзе турыда яман, ялган сүзләр ишетсә дә, җөпләп йөрмәде. Күрәсең, бөек кешеләр, күркәм шәхесләр шундый буладыр.

1982 елның җәендәге бер кызык вакыйганы искә алып үтәсем килә. Футбол буенча Дөнья чемпионаты барган мөһим матч көне безнең концерт белән тәңгәл килде. Ул көнне Бразилия белән Италия командаларының финал уены иде. Без – футбол җене кагылган музыкантлар, Кәримгә: «Әлфия апа белән сөйләш әле, һава торышы бозыла, диген, концертны бераз кыскартмас микән, футбол карар идек», – дидек. Концерт бара, без футбол кararга өметләнәбез. Билгеләнгән 2 сәгать 30 минут вакыт узып та китте. Шулчак Әлфия апа, тамашачыларга: «Минем егетләр каядыр ашыга, әйдәгез әле, мин сезгә тагын бер өч җыр җырлыйм», – димәсенме?! Тамашачыларның сөенүләрен күрсәгез, безнең күңел төште, шулай итеп, Әлфия апаны алдап булмады.

Шул ук елны безнең Башкортстан, Татарстан төбәкләре буйлап озакка сузылган гастрольләр булды. Бу ерак сәфәрнең ахыры Казан шәһәрендәге «Химиклар» мәдәният сараендагы зур концерт-тамаша белән төгәлләнде. Әлеге концерт яздырылып, әле дә телевидение архивында саклана. Бөек җырчы Әлфия Авзалова белән бергә эшләгән күңелле елларым шуның белән тәмамланды. Аның тормышымда булуына мин Ходаема мең шөкерле! Шундый гади, эчкерсез, киң күңелле Әлфия апаны туйганчы күрү-ишетү, тыңлау бәхете кайчан эләгер иде миңа?!

Мәсгуть ИМАШЕВ,
җырчы, композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре



Әлфия Авзалова концертын беренче мәртәбә 1957 елда Пермьдә карадым, концерттан соң артистларны чәйгә дәштек, танышып киттек. Мин Казанга укырга килгәч тә, укып бетергәч тә, Әлфия белән дуслыгыбыз дәвам итте.

Танылган җырчы Әлфия минем байтак җырларымны репертуарына алып, концертларында, радиодан, телевизордан җырлап, мине күп мәртәбәләр сөендерде («Гүзәлия җыры», «Сок буйлары», «Мәхәббәт романсы», «Туй күлмәге» һ.б.).

Ә бер көнне телефоннан шалтырата:

– Имаш, бүген кич өйдә буласыңмы?

– Өйдә!

– Гөлшат Зәйнашева белән сиңа кунакка киләбез.

– Килегез, көтәм!

Килделәр.

Әлфия: «Менә, Мәсгут, мин Кукмарадан гастрольдән кайттым, заказ алып кайттым. Концертым тәмамлангач, Кукмараның «первые» (1970–1980 елларда партия райкомының беренче секретаре район башлыгы булып



санала иде), минем янга килде дә: «Әлфия, син безнең якны яратасың, гастрольгә икенче килүеңдә Кукмара турында берәр яңа җыр алып кил әле», – диде. Менә Гөлшат сүзләрен язып та куйды. Гомерең буе син Кукмара аша Казан–Пермь юлын таптыйсың, көйне дә син язарга тиеш. Сүзләрен укып кара әле».

Укыдым. Күңелемә ятты. Өч-дүрт көн эчендә көй туды. Шалтыраттым. Килделәр. Җырны җырлап бетерүемә, Гөлшат: «Мондый көй буламыни?» – диде. Әлфия: «Җырлыйм мин моны, яңа көй бит бу», – диде.

Ноталарны мин баянчы Кирам Сатиевка бирдем, «Әлфия белән өйрәнегез!» – дидем. Җырны өйрәнеп бетергәч, Әлфия Кукмараның первыена шалтыраткан. «Килегез, халыкны җыярбыз», – дигән кукмаралылар.

Киттек Кукмарага, җырны тапшырырга: Әлфия, Кирам, Гөлшат һәм мин. «Первый» заказы булгач, поезддан төшүгә, аның кабинетына юл алдык. КПССның Кукмара райкомы беренче секретаре, Социалистик Хезмәт Герое Рим Зарипов безне ишектән үк каршы алды. Исәнләшеп, хәл-әхвәл белешкәч, җырны тыңлагач: «Булган бу», – диде Зарипов, – урамда сезне автобус, Олы Сәрдек авылында клуб тулы халык көтә».

Олы Сәрдектә Әлфия Авзалова концерты булды бу. «Кукмара» дигән яңа җырны кул чаба-чаба, өч-дүрт мәртәбә җырлаттылар.

«Кукмара» дигән җырның тарихы шулай башланды. Календарьда 1982 ел иде бугай.

Әлфиягә рәхмәт, урыны җәннәттә булсын!



Мирсәет СӨНГАТУЛЛИН,
җырчы, Татарстанның халык,
Россиянең атказанган артисты

Сагынабыз, юксынабыз!

Мин Әлфия апа Авзалова белән үземне белә башлаганнан бирле таныш, дип әйтергә җөрьәт итәм. Җырчы булуымда аның моңнарының өлеше хәтсез зур. Әлфия апаны, Илһам абыйны тыңлау мине дә сәхнәгә алып менде, җырчы итте.

Хәтерлим, үткән гасырның алтмышынчы еллар башында Әлфия апа безнең авылга да концерт белән килгән иде. Әмма: «Сез әле кечкенә, шаулашып кына утырасыз», – дип, безне – мәктәп балаларын, концертка кертмәделәр. Мин шунда сәхнә артындагы Әлфия апа янына килеп, гозеремне

җиткердем. Әлфия апаның: «Тыныч кына тыңлап утырачаксыңмы?» – дип сораганы хәтердә. Мин клубта идәнгә чүгәләдем, башка малайлар-кызлар концертны ишек ярыкларыннан, тәрәзәдән карадылар. Бераз үсә төшкәч, мин радиодан ул башкарган җырларның исемнәрен дә отып кала башладым, үзем дә көйләп йөри идем, басу киңлекләрендә кычкырып җырлап да җибәрдем. «Шахта», «Кәккүк», «Актаныш таңнары» иң яраткан җырларым иде.

Мәктәпне тәмамлагач Казанга килдем, консерваториядә белем алдым, шунда җырчы белән якыннан танышу мөмкинлеге туды, бергәләп сәхнәдә чыгыш ясаган вакытлар да бик еш булды. Киңәшләрен дә бирде: «Тавышың матур, буй-сының килешле, син коеп куйган сәхнә кешесе, әмма берүк масая күрмә, үзеңне әллә кемгә санама», – дигән сүзләрен әле һаман да күңелемдә йөртәм. Заманында ул тәкъдим иткән «Сибелә чәчем», «Сагынам, дуслар», «Кичке авыл көе» һ.б. репертуарымнан төшми.

Әлфия апа мине гаиләле иткән җырчы да. 1985 елның октябрь ае иде. Мәскәүдә, Мулланур Вахитовның 100 еллык юбилее уңаеннан концерт-тамаша булды. Менә шунда Әлфия апа мине Кадрия исемле кыз белән таныштырды. Без уртак тел таптык, гаилә корып җибәрдек. Шушы шатлыгыбызны Әлфия апа өебезгә килеп тә уртаклашты, чәй өстәле янында төрле кызык-мызыклар сөйләп елмайта да, уйландыра да иде. Аларның байтагы Гөлшат апа Зәйнашева, Зиннур абый Гыйбадуллин турында була инде. Көненә өчәр концерт бирүе, һәр концертта утызар җыр башкаруы турында сөйләве дә хәтердә калган.

Кызларын ничек укырга-язарга, математикадан санарга өйрәтүе турында сөйләгәннәре дә бер караганда кызык та, вакыт-вакыт гыйбрәтле дә иде. Сөйләме белән дә үзенә карата белде Әлфия апабыз. Гастрольләрдә дә ул гел игътибар үзәгендә иде, авызыннан берәр кызык сүз чыгасын көт тә тор! Шулай итеп ул гастрольдән артистларның кәефен күтәрә, сөйләме белән вакыт-вакыт борынын күтәрүчеләргә җиргә төшәргә кирәклегенә ишарә ясый иде.

Илле яшь тулу уңаеннан Камал театрында оештырылган концертымда Әлфия апа бик мәртәбәле кунак булды, тамашачы алдында чыгыш та ясады: «Энекәш, син халык җырларын, композиторыбыз әсәрләрен башкарып бик дөрес эшлисең, шушы юлдан берүк тайпылма», – дип киңәшен бирде, шөкер, иҗат гомеремдә мин шуңа тугрылыклы.

Әлфия апа гомере буе туры сүзле, игелекле, ярдәмчел булды. Үзеннән халкыбызга бай мирас калдырды. Үсеп килүче яшь буын шул байлыкның кадерен белеп, халыкка хезмәт итәргә бурычлы. Аның моңы мәңгелек. Аны сагынабыз, бик юксынабыз!

Мөнәвәрә, Данил *һәм уллары*
Ранил НУРИЕВ,
якын күршеләре



Әлфия апа белән беренче очрашуым төзелештә, үзебез фатир алачак йортта эшләгән вакытта булды. Әлфия Авзалованы күргәч, хезмәттәшләремнең: «Әй, карагыз әле җырчы Әлфия Авзалова бит бу!» – дип шаккатканнары истә. Мин ул чакта өченче балам белән йөкле идем. Ул авырлы килеш төзелештә эшләп йөрүемә аптырады, минем хәлемне җиңеләйтергә теләгәндәй, эчләремне сыпырып, авыр түгелме соң болай биектә эшләве, дип сорады. Безгә буласы фатирны кереп карады, үзенең дә бу йорттан фатир алырга теләвен әйтте.

Икенче очраганда инде без әллә кайчан аралашкан дуслар кебек сөенештек. Сез кайсы каттан фатир алсагыз, мин дә шуннан алачакмын, диде. Тиздән без күршеләр булып яши башладык. Тиздән төпчек кызым Ләйсәнне алып кайттым. Бервакыт сабыем авырып китте, тән температурасы күтәрелде. Куркып кына Әлфия апаларның ишеген шакыдым. «Парацетомолыгыз юкмы, Әлфия апа», – дим. «Юк шул, менә корвалолым бар, бәлки шуны эчертербез», – дип өзгәләнә. «Юк, Әлфия апа миңа температура төшерә торган дару кирәк», – дим. Ул сабыемны кулына алып, кочагына кысуы булды, балам шым булып, изрәп йокыга китте. Шуннан соң ул, балаларга: «Мин сезнең әннәкегез булырмын, миңа шулай дип эндәшегез!» – диде. Шул көннән балалар да аны яратып, «әннәке» дип йөри башлады. Әлфия апа безне якын итеп, гел «улым», «кызым», дип йөрде. Бервакыт консерватория залында узган бенефисыннан соң ул безне бәйрәм табынына чакырып алды да: «Улым, кызым, әйдәгез табын янынарак утырыгыз», – дип эндәште. Арадан кемдер: «Әлфия апа, синең улың юк бит, бу кияваңме әллә; алай дисәң, бу Равил түгел, алар бит читтә», – диде. Әлфия апа бик тә кызык сүзле иде, бервакытта да җавапсыз калмады. Ул аңа: «Этнең баласы бит чат саен», – диде дә, көлде.

Әйткәнемчә, без бер гаилә булып яшәдек. Ул – безне, без аны бик тә яраттык. Балалары үсеп читкә киткәч, гел кан басымы уйнаклап, сәламәтлеге какшый башлагач, без аны үзебездә яшәргә ризалаттык. Безнең балаларга ул үзен әннәке, дип әйтегез дип өйрәтте. Үзебез дә якын итеп, соңгы көнгә кадәр әннәке, дип йөрдек. Ул безгә балалар үстергәндә зур терәк-таяныч булды. Ул булган

җирдә сагыш-моңга урын юк, гел бәйрәм төсле. Кичләрен Данил гармунын алыр иде дә, гел җырлашып утыра торган идек. Берсендә өстәге күршем: «Әй, Мөнәвәрә, төннәр буе идәнгә банка куеп, Әлфия апаның җырлаганын тыңлый-тыңлый елыйм. Бүген дә җырлашып утырыгыз әле», – диде.

Ул беркайчан да зарланмады, сәхнәдә дә, тормышта да гадилеге, ярдәмчеллеге белән үзенә тартып тора иде. Аның өчен урам себерүче дә, профессор да бер үк, беркемне дә сортларга аермады. Шуның өчен дә тамашачы да, без – якыннары да, аның өчен өзелеп тордык. Бөтен серләребез уртак иде.

«Бервакыт сәхнәгә очып чыгып барам, кинәт кан басымы күтәрелде дә, башым әйләнеп китте, сәхнә кырыендагы декорациягә чак кына тотынып калдым, әмма концертымны өзмәдем, шул халәтемдә җырымны җырлап чыктым», – дип сөйләгәне исемдә. Аның сәхнә киемнәре гади булса да, искиткеч килешле, зәвыклы, матур иде. Ул вакытта бездә булмаган матур материалларны чит илдә яшәүче кызы Зөлфия алып кайтып торды. Ул бүләк иткән ак күлмәген озак еллар бик яратып киде. Шушы елларда аңа коточкыч диагноз куйдылар. Аны кияве Равил белән Зөлфия чит илгә алып чыгып дәвалады. «Алар булмаса, үлгән булыр идем инде мин», – ди торган иде. Химия терапияләре алып чәчләре коелгач та, Зөлфия аңа матур париклар алып кайтып бирде. Кабат кара чәчләре чыккач, сөенүләребез бүгенгедәй хәтеремдә. Балалары читтә яшәгәндә туган оныклары шатлыгын да бергә бәйрәм иттек, бергә сөенештек.

Улым Ранилымның артистлык сәләтен, артист булу теләген белгәч, ул аңа: «Артист булырга җитешерсең, иң элек берәр һөнәр ал, аннары да сәхнәгә менеп була», – дип киңәш бирде. Ранил, чыннан да, әннәкесенең киңәшен тотып институтның юридик факультетын тәмамлап, ТР Эчке эшләр министрлыгы аппаратында эшләде. Ранил, чынлап та, сәхнәгә кайтты, ул иң зур кунак итеп Әлфия апаны чакырды. Ул чакта Әлфия апа нык авырый иде инде. Ранилның сәхнәдә үз-үзен тотышына, җырлавына зур бәя биргән иде шулчак Әлфия апа. «Нәрсә, Ранил улым, әллә син миңа әйтмичә генә культура институтын да тәмамладыңмы?» – дигән иде ул, Ранилның искиткеч матур җырлавына сокланып. Концерттан соң тамашачы булып килгән Әлфия апабызны бөтен халык сырып алды, аны халкыбыз шулкадәр нык хөрмәт итә, ярата иде шул. Ранилның бер зур хыялы тормышка ашмый калды. Аның бик тә Әлфия апа белән дуэт җырлыйсы килгән иде. Хәзер телевизорлардан Әлфия апаның чыгышын күрсәтә башласалар, тизрәк фотоаппарат алып истәлеккә төшерәбез, ә күзләрдәге яшьне тыеп булмый. Ул һәрвакыт үзенә, 85 яшькә җитсәм, миңа шул җитә, дип юрады. Ни кызганыч, юраганы юш килде. Соңгы вакытта кан басымы белән интекте, әмма да беркайчан да авыруйм, дип гастрольләргә бармый калмады. Кайчагында соңгы көчен җыеп кайтып егылыр иде, икенче көнне берни булмагандай тагын репетициягә чыгып китә. Хәтта куркуымнан кесәсенә исемнәрен, адресны язып тыккан чакларым булды, кан басымы күтәрелеп егылып ятса, ни эшләр, дип борчылдым. Шатлыгыбыз да, кайгыбыз да уртак булды. Бер-беребездән яшерен серебез булмады, бер гаиләдәй тату-дус яшәдек. Безнең балаларны үз оныкла-

рыдай якын күрде. Аның гадилегенә, тәмле итеп пешергән ризыкларына күңел сусый. Үзем дә ул кайтуга тәмле итеп өчпочмаклар пешереп куя торган идем. Кая барса да төянеп, сумкасын тутырып күчтәнәнәчләр алып кайтты. Хәтта берсендә аңа өч литрлы банка белән ширбәт биреп җибәргәннәр. Аны да урамда чирлим, дип йөргән бер исерекне жәлләп, банкасы белән аңа чыгарып тоттырды. Үлә күрмәсен, ул да адәм баласы бит, ди. Менә шундый гажәеп олы җанлы, кешелекле, ярдәмчел, юмарт, уңган-булган кеше иде ул бөек җырчы Әлфия апабыз. Аны югалту безнең гаилә өчен әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык зур фаҗига булды. Ул безнең күңелләрдән мәңге китмәс!

Нәфкать НИГЪМӘТУЛЛИН,
җырчы, Татарстанның халык артисты һәм
Рәмзия СӘЛАХОВА,
җырчының гаилә дуслары



Нәфкать

Әлфия апа белән ун елдан артык бер йортта күршеләр булып яшәдек. Тормышымның бу бәхетле мизгелләре мәңге истән чыкмас.

Әлфия апа гомере буе халык арасында, аралашып яшәргә күнеккән, шуңа күрә ялгызлыкны яратмады. Без гастрольдән кайтканны ул тәрәзәдә ут яктысыннан күреп белде (аның ишегалды тәрәзәсе безнең тәрәзәгә карый). «Бу юлы бигрәк озак булдыгыз!» – дип, сагынып керә иде.



Әйтеп бетергесез нур, мәңге сүнмәс дәрт – Әлфия апа эчке халәте белән илле яшьтән олырак түгел иде. Аның киңәшләре, шаян мәзәкләре... Җырлар тыңлый идек, караоке җырлый идек.


Их, сөйләшеп туеп булмады... Никадәр эчкерсез, гади, тыйнак, тәртипле кеше иде. Никадәр бөек, гасырга бер генә туа торган шәхес иде ул. Шул «иде»сен бер дә әйтәсе килми. Күңелләрдә мәңге яшәр ул!

Рәмзия

Әлфия апа кеше арасында йөрергә бик ярата иде. «Казанны әйләнеп чыга торган трамвайга утырып, дөньяны күреп кайтам», – диде.

Базарга барырга яратты. Сатучылар, андагы кешеләр белән аралашып, күңеле булып кайта иде. Әлфия апабызның затлылыгыннан күпләребез үрнәк алырлык. Биек үкчәле түфли кимичә, ул чүп түгәргә дә чыкмады. «Әйдә, менә уңайлы түфли ки әле», – дисәң, юк, буем юк, моны кисәм, бөтенләй күренмим, дип җавап кайтарыр иде. Аның беркайчан да халат кигәнен күрмәдем. Хәер, аның халаты юк иде дә бугай. Һәрвакыт чәче-башы таралган, матур киенгән булды.

Әйе, Әлфия апаны өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле. Җырчыларга, музыка белгечләренә бу җәһәттән эшләр күп. Казанда Әлфия Авзалова үзәге булдырыйк, дәреслекләргә аның турында мәгълүмат кертик, башкалабызның бер урамына исемен бирик – киләчәк буыннарыбыз горурланып искә алсын! Аллага шөкер, бүгенге көндә аның мирасын барлап, саклап зур эшләр башкаручы кызлары – Гүзәл, Зөлфия һәм яраткан кияве Равил бар. Тәртипле, тыйнак кызлар үстергән Әлфия апа. Оныклары – Казандагыларымы, Мәскәүдәгесеме, Америкадагысымы – барысы да тәрбияле, татар җанлы балалар!



Рабит БАТУЛЛА,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе,
Татарстанның халык язучысы

Безнең чор – Әлфия Авзалова һәм Илһам Шакиров чоры. 60 ел дәвамында татар моңнарын тараткан, татар милләтен саклауга ифрат күп көч куйган бу ике шәхесне Гиннесның рекордлар китабына кертерлек!

Бу эш Татарстан Президенты аппараты, яисә Татарстан Мәдәният министрлыгы тәкъдиме белән тормышка ашырылырга тиеш! Без нинди битараф халыктыр инде. Безнең төп гаебебез – бөек шәхесләр исән чагында аларга аз игътибар бирү, тере тарихларны барламау. Мин үзем, кулымнан килгәнчә, Әлфия апа турында күп видеоязмалар, бик күп аудиоязмалар эшләп калдым. Әлбәттә, алар югары сыйфатлы түгел, һәвәскәр дәрәҗәдә генә. Әмма мин моны киләчәктә Әлфия Авзалова турында зур видео, яисә аудиоальбомнар чыгарганда менә дигән файдалану материалы булыр, дип уйлыйм. Мин төшергән аудиоязмаларда Әлфия апабызның сурәте генә түгел, сөйләме дә бар бит, болары киләчәктә аның турындагы кинолар төшергәндә файдала-

нылыр. Минем аудиоязмаларда бер капчык тарих, бу бик тә кыйммәтле материал, дип уйлыйм.

Соңгы көненә кадәр Әлфия апа белән булган һәрбер очрашуны язмаларга теркәп бара алуыма шатланам. Авыр операция кичереп, чәчләре коелып беткән вакытта да, ул үз җырын тыңлаганда кабат яшәрә иде, үзенең язмаларына кушылып җырлаулары бүгенгедәй күз алдымда. Шифаханәдә, артыннан барып, аның ишектән кереп китүләре, сүзсез генә табигать кочагында хозурланып йөрүләре – барысы да минем тасмаларда урын алган. Электән үк үземнең дә, тормыш иптәшем Рузиянең дә Әлфия Авзаловага хөрмәтебез чиксез зур булды, иҗатын яратып, мөкиббән китеп яшәдек. Вакытыбыз, җаебыз булганда бу бөек җырчы чыгыш ясаган бер генә концертны да калдырмаска тырыштык. Шөкер, халыкның аны ни дәрәҗәдә яратуын, елап-елап, аягүрә басып алкышлауларын да мәңгеләштердем.

Бервакыт шундый югары дәрәҗәдәге артистлар катнашында опера һәм балет театрында булган зур концерт күңелебездә уелып калды. Җырның илаһи көче – халык күңеленә үтеп, аның күңел кылларын тибрәтүдәдер. Әлфия апаның җырлары шундый иде. Зал тулы халык, җыр тәмамлануга ук, дәррәү басып, аны алкышларга, чәчәкләргә күмә, һәркемнең күзендә яшь... Ул концертта шулай ук бик күпләрнең яраткан җырчысы, «Тары җире, киндер җире» дигән җыры белән тарихта эзе калган Хәнәфи Шәйдуллин да бар иде. Ул да матур итеп, сузып-сузып моңлы халык көйләрен башкарды. Хәзер дә татар җыр сәнгатендә танылган артистлар күп, әмма берсе дә Әлфия апа, Илһам абый дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Андый җырчылар юк инде. Әлфия Авзалованың иҗат биеклеген бөек рус җырчысы Алла Пугачева белән тиңләргә була. Алар җырламый, образ тудыра, шул җырда яши, башкаларны яшәтә, рухландыра, сагайта, юата, моң дулкынына күмә... Алар тамак җырчысы гына түгел. Хәзерге җырчылар, күп дигәндә, 10–20 ел буена сәхнәдән төшмәскә мөмкин, ә Әлфия Авзалова белән Илһам Шакиров, 60 ел тавыш ташламыйча, сөйгән халкына хезмәт итте. Әмма аларның да нигәдер СССРның халык артисты исеме юк. Алар бит җылы, уңайлы машиналарда йөрмәделәр. Арбада, чанада, билгеләнгән урынга таш яуса да барып җитеп, чыгыш ясадылар. Алар халык алдында җавапчыллык тотты. Алар булмаган төбәк, картада алар аяк басмаган урын калмагандыр! Өчәр сәгать буе, һәрбер җирдә, көненә 3-4 концерт биргән бу легендар җырчыга һәйкәл куярлык! Нинди зур талант бирелгән һәм ул аны тулысы белән халыкка калдырып китте. Әле аның иҗатын әллә ничә буын кешеләре өйрәнер. Әлфия апа иҗаты турындагы беренче китапны танылган шагыйрә, язучы, иҗатташ дусты Гөлшат Зәйнашева язып калдырды. Ул китап «Үзем турында» дип атала. Бу китап өчен Гөлшат апага чиксез рәхмәт! Киләчәктә дә бөек җырчының иҗат юлы турындагы альбомнар, китаплар дөнья күрергә тиеш. Килер буын аның җырларында тәрбияләнсен иде, ул – безнең мәдәниятебезнең үткәне, бу бөек шәхесләрне һич тә онытырга ярамый!

Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстанның халык шагыйре



Мин – бик бәхетле җырчы

(Әлфия Авзалова белән 2000 нче елдагы әңгәмә)

Бармы соң безнең татарның
Хәсрәтсез торган чагы?! –
Хәсрәтләрне оныттыра
Моңлы Актаныш ягы.

Күк капусын гомергә бер
Безгә дә Ходай ачты, –
Иңдерде Актанышка ул
Иң моңлы сандугачны.

Иртә-кич сайрый да сайрый –
Юана татар җаны.
Шулай ярата икән ич
Сандугач кына аны.

Ул сандугач дигәнебез –
Әлбәттә, Әлфиябез.
Мең яшә, безнең бәхеткә
Ходайдан иңгәнебез!

Сайрый күр! Җиде... юк, җитмеш
Миллион татар тыңлар!..
Синең җырың җыр гынамы? –
Сандугач сузган моңнар!..

(Разил Вәлиев)

Әлфия апа, шагыйрьләр менә шулай Сезне сандугачка тиңләп шигырьләр яза. Сезне һәр җирдә яратаалар, татар халкы арасында Сезне белмәгән, Сезнең җырыгызга гашыйк булмаган кеше юктыр. Әмма, уйлабрак карасаң, Сезнең гомер гел уйнап-көлеп, сайрап-сайрашып кына үтмәгән бит. Биш яшьтән әнисез калып, ятимлек ачысын тату, аннары әтиегез сугышка киткәч, кеше кулында яшәү... Ятимлек өстенә ачлык-ялангачлык, өйдән өйгә йөреп хәер эстәүләр... Шуларны уйлагач, тәннәр чымырдап киткәндәй була... Ә Сезнең биографияне, Сезнең тәрҗемәи хәлне белмәгән

кеше сәхнәгә гел балкып килеп чыгучы Әлфия Авзалованы бөтенләй башкача күзаллый торгандыр.

Р.В. Әлфия апа, ятимлектә үткән балачак елларыгызны еш искә төшерәсезме? Әллә искә төшермәскә, ул турыда уйламаска, онытырга тырышасызмы?

Ә.А. Әгәр дә мин шундый кайгылар күрмәсәм, рәхәттә, әти-әниле булып, әзергә-бәзер булып кына үссәм, моңым да булмаган булыр иде. Ышанычым булмагач, бала вакыттан ук үземә тырышырга туры килде.

Р.В. Сезне сандугачка тиңләсәләр, сандугач белән чагыштырсалар да, минем күңелгә Әлфия Авзалова моңлы кәккүк булып кереп калган. Сез олы сәхнәгә Солтан Габәшинең «Кәккүген» җырлап килеп кердегез бугай. Аңа инде бик күп еллар үтсә дә, «Кәккүк»не Әлфия Авзалова кебек йөрәкләргә үткәреп җырлаучы юк әле.

Яшь чакта үзешчән сәнгатьтә катнашып, җырлап йөрүчеләр күп була, әмма аларның бик сирәге генә җырчы булып китә. Әлфия Авзалова кебек чая, үткен, тырыш кеше кайда да югалып калмас, үз дигәнен итәр иде. Әмма Сез язмышыгызны җыр белән, сәхнә белән бәйләгәнсез. Моңа нәрсә сәбәпче булды икән, Сез ничек җырчы булып киттегез?

Ә.А. Мәктәптә укыганда мине өченче класстан агитбригадага йөрттеләр. Миңа «Кәккүк»не кем өйрәткән соң? Беркем дә өйрәтмәде. Мин Казанга 17 яшемдә килдем. 17 яшем тулып өч ай узгач, мине Җыр һәм бию ансамбленә китерделәр. Аның җитәкчесе Татарстанның атказанган артисткасы Зөләйха Әхмәтова иде.

Күрәсең, мин бик оялчан да булмаганмындыр. Бөтенесенең каршына басып Габәшинең «Кәккүген» җырлап җибәрдем. Мине бишкуллап алдылар.

Р.В. Сезнең нәселдә җырга-моңга хирыс кешеләр бар идеме? Әниегез Миңьямал апа, әтиегез Афзал абыйның җырлаганнарын хәтерлисезме?

Ә.А. Мин әнине хәтерлим. Аның мине кочаклап, сөеп утырганын түгел, кыйнаганын хәтерлим. Ә менә җырлаганын белмим. Әтием көтүче иде. Җырлый иде, бик көчле тавыш белән җырлый иде. Аның нинди сүзләр белән җырлаганын белмим, шуны беләм – урамнан җырлап кайта иде.

Р.В. Сез, Актанышта агитбригадада йөреп таныла башлаган кеше. һәрбер авылда диярлек агитбригада бар иде. Әмма андагыларның барысы да җырчы булып китмәде. Әлфия Авзалованың җырчы булып китүенең сәбәпләре күптер, дип саныйм. Беренчедән, ачы язмыш күргән, чыннан да, күңелгә моң салынган. Икенчедән, Ходай Тәгалә биргән талант, сәләт булган. Әмма өченчесе, иң әһәмиятлесе – Сез нәрсәгә тотынсагыз, шуны булдырасыз...

Ә.А. Мин кечкенә чактан ук агитбригадага йөргән вакытта колхозчы булып калам дип уйладым, җырчы булырмын, дип күз алдыма да китермәдем. Шул чакта Актанышка райком секретаре булып Камалиев дигән абый килде. Ул минем җырлаганны бик яратты һәм бик зур ярдәм кулы сузды. Мин әле паспорт та алмаган идем, 15 яшьлек чагымда: «Әйдәгез, бу баланы киенде-

рик. МТСка эшкә куйыйк. Тракторчыларга гәҗит, китап ташысын, бераз акча эшләсен», – диде. Ул мине Казанга да җибәрде.

Р.В. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай, ачынып, бер шигырендә: «Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим», – дип язган. Сез дә какканны вә сукканны күп күргәнсездер... Шулай да югалып калмагансыз, атаклы җырчы, халыкның иң сөекле балаларының берсенә әверелгәнсез. Димәк, тормышыгызда яхшы кешеләр, миһербанлы, ярдәмчел кешеләр дә очрагандыр...

Ә.А. Яхшы кешеләр очрады инде. Менә, әйтеп үткәнемчә, – райком секретаре Камалиев абый.

Мине әниемнең бертуган апасы карап үстерде. Авырлыкларны күп күрдем, әмма аларны бик тиз җиңдем, чөнки шаян булдым. Бергә хәер сорашырга чыккан Нәсимә исемле кыз бик елак иде. Мин үзем бер сынык икмәк эләксә дә, җырларга-биергә тотына идем.

Үземне-үзем мактарлыгым бар. Үткен булдым, ялган сөйләшмәдем, туры булдым.

Р.В. Без бәләкәй чакта ел саен авылга Казан җырчылары килә иде. Алар һәммәсе дә сәхнәдә туп-туры басып, кулны күкрәккә кушырып җырлый иде. Сез дә баштарак шулай җырлагансыздыр. Әмма безнең авылга инструменталь ансамбль белән килеп, Сезнең бөтен халыкны шаккатырганыгыз әле дә хәтердә. Без-яшьләргә болай җанлы-хәрәкәтле җырлау, электрогитаралар, дыңгырдык барабаннар бик ошаса да, өлкәнрәкләр башта моны аңлап, кабул итеп бетермәгәннәр иде. Чөнки бу – татар сәхнәсе, татар җыр дөньясы өчен яңалык, үзенчә бер революция иде. Ничәмә-ничә гасырлар буе кубыз-курай, аннары гармун-баянга



кушылып җырланган татар җырын эстрада кысасына кертүчеләрнең, һәр җырны кечкенә спектакль итеп уйнаучыларның иң беренчесе Сез булдыгыз бугай...

Ә.А. Мондый ансамбльне оештырырга мин бик курыктым. Концертка бит яшьләр дә, олылар да килә. Барабанны «чиләк төбе кагалар» дип әйтәләр иде. Аңа инде 30 ел үтте. Минем бәхеткә, ансамбльгә институт белеме алган Кәрим Габидуллин килде. Мәскәүгә гастрольгә барабыз, бик күп җырчылар гармун белән генә бара. Алар килеп: «Кәрим, безгә дә уйна инде», – дип сорыйлар. Ә ул: «Әлфия Авзалова кебек җырласагыз – уйнармын», – ди.

Р.В. Әлфия апа, Сез – татар җырчыларыннан беренче буларак мондый инструменталь ансамбльгә кушылып җырлый башлаган кеше. Аннары Сез җырлап кына калмадыгыз, һәрбер җырдан бәләкәй генә спектакль ясап, сәхнәне тутырып йөри идегез. Моңа шактый кыюлык кирәк булгандыр. Чөнки халык бит аңа өйрәнмәгән иде, әбиләргә башта ошамагандыр.

Ә.А. Ошамады. Ансамбль үзеннән-үзе сикертеп, дәрт бирә бит ул.

Р.В. Әлфия апа, Сезгә музыка мәктәпләрендә уку, консерваторияләрдә белем алу бәхетләре тимәгән. Сез һәммәсенә үзегезнең Ходай тарафыннан бирелгән талантыгыз, тырышлыгыгыз аша гына ирешкәнсез. Ә шулай да Сезнең җыр, музыка серләрен өйрәтүче укытучыларыгыз булмыйча калмагандыр. Кемнәр иде алар?

Ә.А. Безнең филармониягә сәнгать җитәкчесе булып Рәисә Волкова килде. Ул өч ел буе миңа дәрес бирде. Нотага да, дикциягә дә өйрәтте.

Икенчесе – миңа Илһам Шакиров булышты. Мин башта Зифа Басыйровага охшатып җырлый башлаган идем. Илһам: «Әлфия, син тамак төбе белән җырларга тырышма, бу әйберне ташла. Синең үзеңнең дә тавышың әйбәт бит», – диде.

Мин көненә дүртәр концерт бирә идем. Репертуарымда 120 җыр. Үз бригадам белән Уфага барганда, шалтыратып әйтәләр иде: «Билетлар сатылып бетте, һәр мәдәният сараенда бишәр-унар концерт була. Көненә өчәр концерт җырлый аламы ул җырчы?» – дип. Ул чакта мин көненә өч-дүрт концерт куя идем.

Р.В. Дөнья булгач, дус бар, дошман бар, диләр. Ә менә минем үземә Сезнең бер дә дошманнарыгыз юктыр кебек тоела... Ә дусларыгыз исәпсез-сансыз. Чыннан да шулаймы ул?

Ә.А. Дошманнар күп. Яшьләр арасыннан юк. Мин Салаватны бик нык яратам. Үзенә генә бирелгән моң белән җырлый һәм Хәнияне яратам. Алардан беркайчан да начар сүз ишеткәнем юк. Алар минем белән мактаналар, мин бик шатмын. Зәйнәб белән Зөфәрне, Габделфәт Сафинны да яратам, бик матур җырлыйлар.

Р.В. Гадәттә, артист кеше, җырчы кеше хакында гайбәт сөйләмичә калмый. Артист нихәтле талантлырак булса, гайбәте дә шулхәтле күбрәк була. Сезнең тирәдә дә гайбәт шактый булгандыр инде, Әлфия апа?

Ә.А. Безнең турыда анекдотлар бик күп бит инде. Мин аларны ишетәм. Элегрәк яшь вакытымда сөйләгәнгә ояла идем, чөнки безне гел сөйләп тордылар.

Авыр сүзләр ишетеп, йөрәк яна иде, бер-ике сәгатьтән үзгәрә идем.

Минем өстән гайбәт бик күп булды. Ә мин яңа җырлар белән һәрвакыт үземне күтәреп тордым, көрәштем. Алар гайбәт сөйләп торды, ә мин һаман алга барырга омтылдым. Менә нинди акыл булды миндә!

Р.В. Кеше, бигрәк тә иҗат кешесе, мәхәббәтсез, сөюсез яши алмый. Сезнең дә мәхәббәт утларында янган-көйгән чакларыгыз булгандыр. Сезне гомер буе Илһам Шакировка мәхәббәт тоткан, хәтта чак кына Илһамга кияүгә чыкмыйча калган, дип тә сөйләделәр.

Ә.А. Бусы гайбәт түгел, дөрес. Аны яшереп булмый. Кияүгә бармадым, ләкин Илһам минем яшьлек мәхәббәтем булды.

Р.В. Җырчы, никадәр талантлы булса да, баянчылардан, музыкантлардан башка җырлый алмый. Аннары, гадәттә, концертта биючеләр, сүз осталары да катнаша. Бу яктан караганда да, Сез бик бәхетле булдыгыз бугай, Сезнең концертларда, Сезнең тирәдә гел талантлы кешеләр генә чыгыш ясый иде. Сез аларны үзегез җыя идегезме, әллә алар Сезне үзләре эзләп таптылармы?

Ә.А. Иң элек мин Нәҗия Минкина белән чыгышлар ясый башладым. 30 ел бергә эшләдек. Аннары аны миннән Илһам тартып алды.

Музыка ансамбле җитәкчесе Кәрим Габидуллин белән дә 30 ел эшләдем. Габидуллин ничек түзгән, минем дә үзенчәлекле холык бар бит. Түземле кеше булды, чөнки иҗатта сүз әйткәләшергә вакыт калмады, өчәр-дүртәр концерт биреп йөрдек.



Р.В. Кайвакытта талантлы гына җырчылар, репертуар төзи белмәү аркасында, тамашачыга барып җитә алмыйлар, яисә аларның сәхнә гомерләре бик кыска була. Үз тавышыңа, үз мөмкинлекләреңә туры килә торган репертуар төзү – гаҗәеп катлаулы нәрсә. Ә Сезнең репертуарда татар халык җырлары да, композиторларыбыз әсәрләре дә, такмаклар да, озын көйләр дә, дөнья халыклары җырлары да бар... Репертуар төзергә кем булышты Сезгә? Әллә үзегезнең махсус сценарий язучыларыгыз, махсус киңәшчеләрегез, махсус режиссерларыгыз бар идеме?

Ә.А. Махсус язучы юк иде. Мәрхүм Фасил Әхмәтов, җырлар язгач та, миңа китереп бирә иде. Мин аның «Назлы гөлкәем» җырын халыкка чыгардым. Мин композиторлардан тавышыма туры килә торган җырларны сорап ала идем.

Р.В. Әлфия апа, Сез һаман шаян, һаман көләч, һаман матур итеп киенәсез. Кыскасы, картаерга һич кенә дә исәбегез юк. Картая белмәүнең сере нәрсәдә икәнне безгә дә әйтмәссезме?

Ә.А. Картаймаска өйрәтеп булмый инде анысы. Ләкин авыр сүзләр ишетсәң дә, йөрәгеңә алмаска кирәк.

Р.В. Кичләрен ялгыз калып, моңаеп утырганда, Әлфия апа, нәрсә турында күбрәк уйлыйсыз? Үткән гомерне ешрак искә төшерәсезме, бүгенге мәшәкатьләр күңелегезне борчыймы, әллә киләчәк хакында: балаларыгызның, оныкларыгызның язмышы, аларның киләчәге хакында уйлыйсызмы?

Ә.А. Бөтенесен дә уйлыйм. Балаларымны уйлыйм, оныкларымны уйлыйм, һәрвакыт әйбәт булсыннар, акыллы булсыннар, дим. Ике кыз үстердем, икесе дә акыллы, балалары да акыллы күренәләр. Аллага шөкер!

Рәүфәл МӨХӘММӘТҖАНОВ,
Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының директоры, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре



Башкалабызда җыр һәм бию ансамбле төзелүгә Казаныбызга төрле авыл-шәһәрләрдән артист булу теләге белән кыз-егетләр агылды. Шуларның берсе – Әлфия Авзалова. Гадәттә, кеше чит җиргә килгәч, үзенең күңел халәтенә туры килердәй кеше белән аралаша, дуслаша. Минем әнием Разыя Тимерханова белән дә Әлфия апаның дуслыгы шул күңел халәтләренең тәңгәл килүеннәндер, дип уйлыйм. Әни Әлфия апаны бик тә якын итте, алар – ахирәтләр, дуслар иде. Мин әле ул чакта кечкенә идем, 4 нче класста укыган вакытларым булгандыр. Кечкенәдән шаяртырга, әртисләнергә ярата торган идем. Әлфия апа да,

әни кебек, җор телле, шаян, бер дә юктан кызык табып күңелне күтәрә торган кеше иде. Минем сәләтемне ул шул чакта ук күреп алгандыр, дип уйлыйм. Ул, ни кылансам да, мине үсендереп, яле тагын шулай ит әле, дип, мине каткат сәхнәгә чыгаргандай, әйткән кызык сүзләремне кабатлата, аннары бергә-бергә рәхәтләнеп көлешә идек.

Әлфия апа кеше яхшылыгын бер дә онытмый торган юмарт, ярдәмчел, хәерхаклы ханым иде. Ул әнине бик тә хөрмәт итте. Аңа ничек тә булса яхшылык эшләргә теләп, үзенең матур киемнәренә кадәр бирә торган иде. Алар әни белән бер-берсен тулыландырдылар, дисәм дә, ялгыш булмас. Аларның холкына кадәр бер төрле иде. Бу позитив энергетикалы ике ханым күрешкәндә, очкыннар чыга, алар бер-берсе белән бик килешәләр иде. Алар көлешә башласа, әтием Сабир аш бүлмәсеннән, хәтта, чыгып китәр иде. Минем әнием Разыя Тимерханова үзе пианинода уйный, үзе күренекле җырчы иде. Әлфия апа әнидән күп кенә вокал дәресләре алып, үзенә зур тәҗрибә туплаган җырчы буларак, гел яңалыкка омтылды. Ул вакытта һинд кинолары бик тә популяр иде бит. Әлфия апа шул һинд җырларын нәкъ кинодагыча итеп башкаруга иреште, иң беренче тапкыр инструменталь ансамбльгә кушылып җырлый башлады. Ул үсте, үз тамашачысын тапты, бер-бер артлы биек-биек үрләр яулады, халкыбызның яраткан җырчысына әверелде. Болар барысы да – табигый талантны үстерү өстендә эшләү, тынгысызлык, максатчанлык нәтиҗәсе. Мин Әлфия апаның ижат күтәрелешенең тере шаһите булдым, дисәм дә ярый. Без фатир алгач, Әлфия апаның, безгә килеп, фатирга сокланып: «Әй, берәр кайчан минем дә мондый фатирым булырмы икән?» – дип торганы исемдә. Ул, мин өйләнгәндә, безнең туебызда булды, матур җырларын бүләк итте. 1981 елда мине Татар Дәүләт опера һәм балет академия театры җитәкчесе итеп билгеләделәр. Миңа бер 55 яшьләр тирәсе булгандыр, моннан бер 14 ел элек, ул минем эш бүлмәмә хәл белергә килеп керде, калкансыман бизе авыртуыннан зарланды. Үзем дә бу авыру белән интеккән кеше буларак, аңа үзем белгән файдалы киңәшләремне бирдем, тынычландырырга тырыштым. Кызганычка каршы, кеше гомерләре чикле. Исән булса, быел әниемә 100 яшь тулган булыр иде. Әлбәттә инде, без әниебез, җырчы Разыя Тимерхановның матур, җырлы гомер юлын, ижатын искә алып китәчәкбез. Ә Әлфия апаның быел октябрь аенда зур Халыкара җыр фестивале булачак. Бу ике шәхеснең ижат юлы һәм тормыш юлы һәрвакыт кисеште һәм бу дөньядан киткәч тә, алар – аерылгысыз.

Рафинат СӘЛАХОВ,
музыкант, һәвәскәр композитор,



Халкыбыз мәхәббәте лауреаты

«Язмыштан узмыш юк» дигән төшенчә күп вакытлар кешеләрне уйланырга, дистәләрчә елларга чигенеп, узган гомерләрен яңадан барлап чыгарга мәҗбүр итә. Чөнки һәр адәми зат, үзенә генә хас булган тормыш юлын – балачак, яшьлек, өлгерү елларын үтеп, өлкәнәю чорына җитә. Менә шундый фикерләүгә таянып, биредә Әлфия ханым Авзалованың да тормыш мизгелләреннән берсен искә төшереп үтәсем килә.

Мин 1975 елда Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең эстрада бүлегендә, мәшһүр җырчы Габдулла абый Рәхимкулов концерт бригадасында (ул елларда – «бригада» дип йөртәләр иде, ә хәзер – «группа» дип әйтелә) баянчы-инструменталист, концертмейстер булып, иҗади хезмәт юлын башлап җибәрдем. Баянчылары, музыкантлары ниндидер сәбәпләр белән гастрольгә бара алмаган бригадаларга, бу вакытта инде гастрольдән әйләнеп кайткан музыкантларны кушып, концертлар куярга чыгарып җибәрәләр иде. Филармониядә унсигез ел эшләү дәверендә, миңа да төрле бригадаларда эшләргә туры килде. Ә инде төп эш урыннарым: Габдулла Рәхимкулов, Флюра Сөләйманова һәм Илһам Шакиров бригадаларында булды.

Миңа Әлфия апа Авзалованың концерт бригадасы белән, 1976 елның май-июнь айларында, Түбән Новгород өлкәсенең Уразовка районында ун көн буе җәйге гастрольләрдә булырга туры килде. Ул көннәрдә безне район урта мәктәбенең интернатында яшәттеләр; концерттан соң шул яшәү урынына кайтып, ял итеп, чираттагы чыгышларыбызга әзерләнә идек.

Көннәрдән бер көнне безнең янга, ягъни интернатка, үзе белән яшүсмер кыз баланы ияртеп, бер ханым килеп керде. Хәл-әхвәл сорашып, якыннан танышканнан соң, алар – Чинбәли авылыннан укытучы Венера ханым Хәбибуллина һәм аның әле быел гына 10нчы сыйныфны тәмамлаган кызы Роза булып чыктылар. (Искәртеп үтим: Чүнбәли – татар халкының мәшһүр җырчысы Хәйдәр Бигичевның туган авылы).

Ә инде Әлфия апа шикелле данлыклы шәхес янына бер дә белмәгән кешеләрнең буш вакытларын сарыф итү өчен генә килеп йөрмәгәнлеге яхшы билгеле. Аралаша торгач, әниле-кызлы Хәбибуллиналар эшнең нидә икәнен тәфсилләп аңлаттылар. Әлеге яшүсмер кыз бала Әлфия апасының җырларын бик яратып тыңлап, үзе дә җырчы булырга хыяллана икән.

Шуннан соң, Әлфия ханым белән бергәләп, аның җырлавын тыңлап карарга булдык.

Розаның чишмәдәй челтерәп аккан, үзенә генә хас булган сопрано тавышы, башкарган җырлары безне сокландырды. Ул инде мәктәп, авыл сәхнәләрендә үткән төрле чараларда катнашып, үзен җыр өлкәсендә сынап караган икән. Ә менә зур сәхнәгә, җыр сәнгатенә якынаерга, кайда нинди белем алырга кирәклеген иң беренче булып Розага аңлатучы, аңа юл ачучы Әлфия Авзалова булды.

Шулай итеп, алар үзара аңлашып, бер-берләреннән бик канәгать булып, вакытлыча аерылыштылар.

Ә инде башкалабыз Казанга юл алган Роза Хәбибуллина иң элек, Әлфия апасы киңәше буенча, Казан дәүләт консерваториясенең ишекләрен шакый. Ул анда 1976–1978 елларда әзерлек курсларын үтеп, 1978 елда Әүхәдиев исемендәге Казан дәүләт музыка училищесының икенче курсына кабул ителә. Ә 1981 елда аны уңышлы тәмамлап, 1981–1983 елларда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә зур сәхнәгә беренче адымнарын ясый. Казан шәһәрендә яшәү дәверендә Роза Әлфия апасы белән якыннан аралашып яши, дуслык җепләре тагын да ныгый һәм инде аның сәхнә эшчәнлегендә, репертуар сайлау мәсьәләсендә Ә. Авзалованың йогынтысы зур була.

Җыр-бию ансамблендә эшләгән чорда Роза үзен татар халкына солистка-вокалистка буларак таныта һәм тамашачылар каршында дан казана. Үзе хезмәт куя торган коллективта кешеләр белән килешеп эшләү, оештыру сәләте-осталыгы барлыгын да ачыклый.

1983 елда Р. Хәбибуллинаны Мәскәү шәһәренә, «Москонцерт»та оештырылган «Хыял» ансамбленә чакырып алалар, ул анда унике ел буена солистка-вокалистка булып эшли. Шул ук елларда Роза, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Ренат Ибраһимовның «Җыр театры» чыгышларында актив катнашып, Россиянең төрле өлкәләрендә җырчы буларак таныла. Шулай ук ул Мәскәү татарларының милли-мәдәни үзәге саналган Асадуллаев йортында үз урынын табып, анда ижат түгәрәкләре белән эшли.

1994 елда Мәскәү шәһәрендә талантлы татар балалары өчен махсус мәктәп ачыла. Әлеге уку йортының беренче көннәреннән үк, балалар өчен эшли торган түгәрәкләрнең берсендә, Роза «Ай-Кай» вокал төркемен җитәкли, ә соңрак шул ук мәктәптә директор урынбасары булып та эшли. Бу мәктәпне оештыручыларның берсе – Розаның әнисе Венера Исхак кызының бертуган сеңлесе Лэмма ханым Гыйрфанова була. Ул озак еллар, лаеклы ялга киткәнче, мәктәп директоры булып эшли. Ә менә Әлфия апабыз үзенең хәер-фатыйхасын биреп, олы тормыш юлына чыгарган кыз бала – Татарстанның атказанган артисткасы Хәбибуллина Роза Җәфәр кызы инде үзе, 2016 елдан башлап, патриот-шагыйрь Муса Җәлил исемен йөртә торган, 500ләп баланы үз канаты

астына алган татар мәктәбен җитәкли, шулай итеп, ул яшь буынны тәрбияли, аларга киләчәккә якты юл күрсәтә.

Инде үзегез күргәнчә, кеше гомеренең бер мизгеле төрле язмышларга үзләренчә тәэсир итә. Әлфия апаның гомер юлында мондый мизгелләр күпме булганын ул үзе белмәскә дә мөмкин. Кешеләргә ул эшләгән яхшылыклар инде бүгенге көндә аның якты рухына изге дога булып кайткандыр шикелле тоела миңа...

P.S. Менә бу араларда, Әлфия Авзалованы искә алган көннәрдә, аның истәлегенә эшләнә торган китапны чыгаруга күп көч куеп йөрүче, гастрольләрдә әнисе кырында, сәхнәдә үскән кызы Зөлфия – бу эшләрне оештырып йөрүчеләрнең берсе (башында торучы) Нигъмәтҗанова Зөлфия Гомәр кызы, узган гасырның сиксәненче елларында Казан театр училищесын уңышлы тәмамлап, эстрада сәхнәсендә әнисенең уң кулы, якын булышчысы булган. Нигъмәтҗанов Равил Әхәт улы белән тормыш корып, алар ике кыз бала үстерделәр. Соңрак ул Казанда юридик институт – ТИСБИны тәмамлый, җырчы Әлфия Авзалованың ижатын барлап, тәртиптә тота торган фондны булдыра.

Бүген инде ике кызлары, биш оныклары булган Нигъмәтҗановлар гаиләсе, дистә еллар дәвамында чит илләрдә, Россия илчелекләрендә хезмәт итеп, Казаныбызга әйләнеп кайттылар...

Халкыбыз мәхәббәте лауреаты Әлфия Авзалова истәлегенә багышланган фестивальләр киләчәктә дә дәвамлы булсын, бихисап күңелләрне, тылсымлы салават күпередәй балкып, гел үзенә тартып торсын иде...



Резидә һәм Илдар
ХӨСӘЕНОВЛАР,
якын күршеләр

Без бу йортка Әлфия апаларга кадәр үк килеп урнашкан идек, әле фатирга ремонт ясап, күченеп кенә йөргән чагыбыз иде, хәтта ишектә кыңгырау төймәсе да юк. Бер көнне ишек шакыйлар, ачсам – күршебез, танылган җырчы Әлфия Авзалова басып тора. Аның: «Исәнме, күрше!» – дип сәламләвенә, мин: «Әйдәгез, үтегез, керегез!» – дип каршы алдым. Бик тә күңелгә ятышлы, ачык йөзле апа иде бит ул.

«Йомыш бар идеме әллә?» – диюемә ул: «Әйе, менә балаларым Америкадан кайта иде. Пешеренергә йөрим, күкәй беткән, сездә юкмы?» – ди. «Кызганычка каршы, күкәйнең юк чагы, менә тәмле торт бар, әйдәгез, чәй эчик!» – дидем. Ул каршы килеп тормады, без гәпләшеп, рәхәтләнеп икәү чәй эчтек, татар эстрадасының бүгенге хәле, сәнгать, иҗат яңалыклары, хәзерге җырчылар турында уртага салып сөйләштек. Күршем белән беренче очрашуда ук шулкадәр җылы аралашу булганына сөенеп бетә алмадым. Мин артистлар тормышын бөтенләй башкача күз алдыма китерә идем, ә монда мин күзаллаганның киресе: кешеләр белән дустанә, гади, аралашучан, кунакчыл, тыйнак. Ул бик гади тормыш рәвеше алып барса да, булганына шөкер итә белә, ике кулына биш сумка тотып, азык-төлек ташучы гади татар хатыны иде. Ул беркайчан да, беркем турында да начар сүз сөйләмәде. Шуңа күрә, Әлфия апаны, матур җырлавы өчен генә түгел, нәкъ менә шушы кешелек сыйфатлары өчен дә бөтен халык яраткандыр дип уйлыйм. Ул үз гомерендә бик күп илләрне, чит җирләрне гизгән җырчы бит, аны һәркайда колач җәеп каршы алдылар, аның килүен сагынып көтеп тордылар. Мондый шәхес белән көн дә аралашып яшәү бәхете бит күпләргә эләкми, менә без шул бәхетләләрнең берсе идек. Аның юклыгына күнел ышанмый, телевизордан Әлфия апаны җырлата башласалар, күзгә яшь тыгыла. Бик тә якын кешебезне югалттык! Күршең үзеңнән яхшы булсын, диләр. Менә безнең Әлфия апабыз нәкъ шундый иде. Аның өчен «Күрше хакы – Алла хакы» мәкале иң беренче урында булды. Күрше ул – туганнан да якын, диләр, туганны әллә нигә бер генә күрсәң, күршең белән көн дә бергә, безгә дә Әлфия апа якын туганыбыздай кеше иде! Соңгы көннәренә кадәр бергә йөрештек, аралаштык, якын дуслар булдык. «Матур да инде сез, бигрәкләр дә пар килгәнсез», – дип Резидә белән безгә карап әйткән җылы, мактау сүзләре бүген дә күнелдә җылылык уята. Ул соңгы көненә кадәр үз-үзенә хыянәт итмәде: ниндидер гаделсезлек күрсә – күзенә бәреп әйтте, сөенсә – сабыйдай сөенде, чит кешеләр кайгысын үзенеке итеп кабул итте. Өлкәннәрнең менә шушы асыл сыйфатларын без балаларга бирергә тиеш, дип уйлыйм. Алар һәрвакыт ярдәмләшеп яшәде, барына шөкер итә белде, балаларын милли рухта тәрбияләде, барысы да үз телендә сөйләште. Алар безгә алып килеп җиткергән шушы асыл сыйфатларны без инде үз балаларыбызга тапшырырга тиешбез. Бу – бик тә зур бурыч.

«Милләтебезне, телебезне саклауга һәрбер татар кешесе Әлфия апа куйган кадәр көч куйса, безнең миллилеккә чик-чама булмас, рухи дөньябыз күптән гөлбакча булыр иде», – дип, бик тә юксынып искә алды Әлфия апаны йорт хуҗасы – якын күршесе Илдар әфәнде.

Тормыш иптәше Резидә дә Әлфия апа белән тәүге күрешүләрен бик тә дулкынлану белән искә төшерде. «Безгә Әлфия апа белән күрше булып яшәү бик тә рәхәт булды – чөнки ул гаҗәеп ачык, гади, эчкерсез, юмарт иде. Без аның юбилей концертларында да олы кунак булып, беренче рәтләрдә уты-

ра идек. 80 яшьлек юбилей концертында да ул бөтен кеше сокланырлык матур, сөйкемле, шаян телле иде. Таң калып, күзләр тимәсен, дип кайттык. 80 яшенә дә матур, яңа күлмәкләр тектереп, сәхнәдә сөенеченнән җил-җил атлап йөргән әниемдәй якын кешем өчен чын-чынлап куандык. Ни кызганыч, гомеркәйләр чикле шул, ашыкты... 85 яшен күрми китте... Ярый әле, мәңге үлмәс җырлары калды! Аны сагынганда, юксынганда Әлфия апаның язмаларын тыңлыйбыз. Аның җырлары илаһи зур көчкә ия, бу җырларда ниндидер сихри яшәү рәвеше бар!»

Рәзинә СӘЕТГӘРӘЕВА,
журналист, шагыйрә



Әлфия апага

Ак чәчәкләр кебек карлар ява,
Күңелләрне айкый моңнарың...
Өзелепләр сине сагынганда,
Юатадыр моңлы җырларың.
Әлфия апа, бер уч йөрәгеңдә
Галәм тиклем урын – җыр-моңга!
Сандугачлар, җырларыңны отып,
Өзеп-өзеп сайрый таңнарда!
Халкым сине Алиһәгә тиңли,
Ай кызына тиңли, йолдызга!
Син тугансың икән бу җиһанга,
Күңел күкләрендә балкырга!
Ак чәчәкләр кебек карлар ява,
Күңелләрдә эри моң булып...
Яшисең син халкым күңелендә
Тыңлап туймас моңлы җыр булып!

Рәис НӘҖИПОВ,
Татарстан Республикасы «ТИСБИ» идарә университеты» дәүләти булмаган югары профессиональ белем бирү учреждениесенең Чаллы филиалы директоры



Мин Әлфия апаны беренче тапкыр балачагымда, туган авылымда – Чирмешән районындагы Бәркәтә авылының агач клубында күрү бәхетенә ирешкән идем. Авыл зур, халык Кытайдагы кебек күп, агач клубка эләгә алмаган олылар да, балалар да урамда ачык ишек-тәрәзәләрдән аның концертын тыңладык, киткәндә үзен дә күреп калдык. Ул елларда татар тарихын бик өйрәтмиләр, аңлатмыйлар иде. Тукайны, Арчаны белә идек, һәр авыл өендә диярлек «Серенада» радиоалгычы бар иде. Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров пластинкаларын тыңлап, Актаныш, Сарманны яраттык.

20 елга якын Зәй төбәгендә эшләдем. Зәй – халкыбызга бик күп күренекле шәхесләрне биргән, үз кочагына сыендырган бәрәкәтле төбәк. Бу турыда күренекле язучы Аяз ага Гыйләҗев: «Гомерем буе Зәй халкының күңел җылысын тоеп яшәдем», – дип язды. Республикада күренекле җитәкче урыннарда эшләгән, чыгышы буенча Чүпрәле, Аксубай якларыннан булган Рәшит Хәмәдиев тә: «Иң матур елларым Зәйгә бәйле, мине менә шушы Зәйнең кулларын кызышканчы сыер сауган керәшен апалары кеше итте», – дип әйткән иде. Зәй Әлфия апаны да бик үз итте. Ул Зәйгә бик еш килә иде. Халык аны зарыгып көтеп ала торган иде. Озаграк килми торса, җитәкчеләр аша чакыртып алалар иде. Әлфия апа концерт белән килсә, бөтен авылларны йөреп чыга. Өлкәннәр дә, яшьләр дә яратып йөриләр иде аның концертына. Клубларда алма төшәрлек тә урын калмый. Якты Күл авылында бер олы яшьтәге әбинең сәхнәгә менеп әйткән сүзләре хәтердә: «Әлфия кызым, бу яшемдә инде сине кабат күрермен, дип өметләнмәгән идем. Аллага рәхмәт, насыйп булган икән, чәчәкләрем юк, үземә тектерермен, дип алган менә шушы ситсам бар иде, шуны сиңа бирәм, төсем булсын. Сине күреп, җырыңны тыңлагач, инде тынычлап үлсәм дә ярар», – диде ул. Бөтен халык басып, елый-елый кул чапкан иде. Менә шулай яратты Зәй халкы Әлфия апаны.

Зәйдә КамАЗның автоагрегат заводы бар. Анда күп еллар буе директор булып гаҗәеп шәхес, рус милләте кешесе – Мишин Вадим Георгиевич эшләде. Ул үзе дә искиткеч матур җырлый иде. Татар җырына, мәдәниятенә зур игътибар бирде. Вадим Георгиевич Әлфия апаның бер генә концертын да калдырмады. Концерттан соң, аны үз өенә кунакка алып китә. Сәгатьләр буе сөйләшеп, җырлашып утыралар. Тора-бара алар гаилә дусларына әйләнде.

Әмма ул гади генә дуслык түгел, алар профессиональ яктан да бер-берсенә терәк, этәргеч булдылар. Вадим Георгиевич заводка татар теле укытучысы алдыртты. Аннан ул татар җырларын русчага тәрҗемә итте. Үз тәрҗемәсендә берничә китап чыгарды. Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде. Ул күп вакытта Әлфия апаны машина җибәреп тә китертеп, халык соравы буенча концертлар куйдырта иде. Шундый җитәкчеләр күбрәк булса, мәдәниятебез инде әллә нинди биеклекләргә күтәрелер иде, матди яктан да, рухи яктан да күпкә баерак булыр идек, дип тә уйлап куям.

Дөрес, Әлфия апаны Зәйнеке иткән кеше Рәшит Сәет улы Хәмәдиев булды. Зәй, Минзәлә, Чаллыда хакимият башлыгы булып эшләмәсә, ул, мөгаен, үзен сәнгать өлкәсендә тапкан булыр иде. Мәктәп, институтта укыган елларыннан сәхнәдә җырлап үскән, мәдәният кешеләрен җаны-тәне белән аңлаган, олы йөрәкле кеше иде ул. Әлфия апаның җырлавын, җырларын, күркәм холкын, зирәк акылын ярата иде. «Әлфия ападагы акыл әйтеп бетергесез», – дип әйтә иде ул. Кулыннан килгәнчә Әлфия апаны хөрмәтләргә тырышты. Аңа берәр яхшылык эшли алса, сабыйдай шатлана иде. Зәйнең башка күренекле шәхесләре турында да кайгыртты. Аяз Гыйләҗев, Олимпия чемпионы Федор Симашовларга коттеджлар салдырганнан соң, Әлфия апага да Зәйдә үз йортын салдыру нияте белән йөри башлаган иде, тик Әлфия апа үзе генә: «Рәхмәт, улым, мин каршы, актанышларымны үпкәләтәсем, рәнҗетәсем килми», – дип кырт кисте. Гомумән, Рәшит Сәетович, яхшылыкны мөселманча, кешеләргә белдертмичә генә эшләргә тырыша иде. Ул Әлфия апаның авыр вакытларында үз әнисен кайгырткандай кайгыртты. «Улым, тавышым бетәр, дип куркам, ничектер, үземне начар хис итәм», – дигәч тә ул, мин мал дохтыры булсам да, врач кеше, үзем карыйм әле, дип, башка районда концерт биргән җиреннән Әлфия апаны Зәйгә кайтартып, хәлнең мөшкеллеген аңлап, тиз арада Казанга барырга кирәклеге турында әйтте. Соңрак Әлфия апаның: «Алар минем хәлемне белми, мин аларныкын беләм», – дип җырлаган һәр җырыннан соң, кешегә сиздермәскә тырышып, әкрен генә елый иде. Әлфия апа Рәис Сәетовичка бик рәхмәтле булды. «Рәшиткәем, улым!» – дип кенә эндәшә иде. Аксубайга, Иске Кыязлыга, аның авылдашлары янына кайтып, махсус бүләк концерты да куеп кайтты. Рәшит Сәетовичка багышлап махсус җыр да башкарды. Һәрвакыт халык алдында аның турында үзенең җылы сүзен әйтергә тырышты. Әлфия апаның сүзе һәрвакыт үтемле, саллы була иде. Ул бервакытта да намусына, җырларына хыянәт булырдай сүз сөйләмәде. Әлфия апа нинди генә катлау кешеләр арасында булса да югалып калмады, милләттәшләренә, башка милләт халкына булган тирән хөрмәте аша үзенә дә хөрмәт тудыра белде. Рус кешеләре аптырап тормасын дип, бервакыт рәхәтләндереп русча җыр сузып җибәрмәсенме, әлбәттә инде, руслар да җырны күтәреп алды. Үз милләттәшләре белән генә түгел, милләтара дуслык күперләрен дә салган шәхес ул Әлфия апабыз. Ул минем күңелдә менә шулай матур, соклангыч булып калды.

Рәфкать САБИТОВ,
музыкант,
Ирина САБИТОВА,
биюче



Якты йолдыз, кабатланмас шәхес

Мин Татар дәүләт филармониясенә музыкант булып 1969 елда урнаштым. Мине Илһам Шакиров бригадасына билгеләделәр. Без – бертуганым Рәшит белән, икебез дә электр уен коралларында уйный идек. Мин – бас-гитарада, Рәшит – соло-гитарада. Репетицияләр вакытында күрше бүлмәдә шөгыльләнүче музыкантлар белән дә аралаша идек. Алар Әлфия Авзалова бригадасы музыкантлары булып чыкты. Безнең янга еш кына җырчы үзе дә керә торган иде. Ул һәрвакыт шат күңелле, кергәндә нинди дә булса кызык сөйләп, күңелне күтәрә. Илһам абый белән җырлар турында бәхәсләшәләр. Икесе арасындагы иҗади дуслык сизелеп торды. Әлфия Авзалова ансамблендә ярымклассик инструменталь уен кораллары: кларнет, контрабас, барабан һәм ритм-гитара бар иде. Әлфия Авзалова – татар җыр сәнгатенә яңалык керткән, инструменталь ансамбльгә кушылып җырлаучы иң беренче җырчы. Аңа кадәр татар артистлары бары тик баянга гына җырлый иде.

1970 елда башкалабыз Мәскәүдә «Татарстан көннәре» гөр килеп узды. Без – Илһам Шакиров һәм Әлфия Авзалова бригадалары – бергә бардык, чыгыш ясадык, бер кунакханәдә яшәдек.

Кеше кайда эшләсә, кайда йөрсә, тормыш иптәшен дә шунда таба бит. Минем дә тормыш иптәшем – иҗат кешесе, биюче Ирина Сабитова. Бу бәйрәмгә алар да Татар Дәүләт опера һәм балет театрыннан килгән иде. Торабара иҗади дуслык олы мәхәббәткә әйләнде һәм без аның белән гаилә кордык. Соңыннан Иринага данлыклы Әлфия Авзалова төркемендә эшләргә насыйп булды. Әлфия апа – күңелдә иң якты хатирәләр генә калдырган, бөек, мәшһүр җырчы. Аның иҗатына әле киләчәк буыннар да кабат-кабат кайтыр, аның моңлы җырларында әллә ничә буын тәрбияләнер, дип уйлыйм. Илһам абый белән алар – икесе дә иҗат күгендәге якты йолдыз, кабатланмас шәхесләр, йөз елга бер генә туа торган моң ияләре!

Рәшит МОСТАФИН,
музыкант, композитор,
Татарстанның халык
артисты



Мин танылган җырчы Әлфия апа бригадасында баянчы булып эшләдем, филармониядә – 1964 елдан бирле. Ае, ае белән гастрольләргә акча эшләргә, концертлар куярга чыгып китә идек. Башка бригадаларда эшләгәндә аена 50–60 сум акча алсам, Әлфия апа бригадасына күчкәч, бер айда – бер еллык хезмәт хакы алдым..

Бигрәк тә Оренбург өлкәсендә көзге уңыш җыю вакытындагы гастрольләр күңелдә уелып калган. Көненә 2-3 концерт бирә идек, программаның дәвамы өчәр сәгатьтән дә ким түгел.

Без – музыкантлар, арып беткәндә дә, Әлфия апа дәрт-дәрманлы булып кала бирде. Кызык сүзләре белән безнең күңелләрне күтәреп, бригаданы җитәкләп, һәрберебезнең тормышы өчен көенеп яши торган олы җанлы җитәкчебез дә, җырчыбыз да, юлдашыбыз да иде ул. Хатын-кызлардан торган джаз ансамбле җитәкчесенең юбилей концертында чыгыш ясаганы әле дә хәтеремдә. Ул хәйрия концертларына да бик җаваплы карый иде. Әлфия апа сәхнәгә ялт итеп килеп чыкса, әйтерсең, бөтен тамашачы уяна, тамаша залы сихри моңга күмелә. Аның дәртлелегенә карап, без дә гармунны ныграк, дәртлерәк итеп суза торган идек.

Әлфия апа моңны шулкадәр нечкә тоемлый иде, аңа без тырышып-тырышып уйный идек, тиешенчә уйнамыйча һич тә булмый. Ул безне бер гаиләдәй дус, тату яшәтте. Аның белән эшләгән еллар, өзелмәс бер моң булып, күңел түрендә саклана. Менә, килеп керер дә: «Әйдәгез әле, егетләр, сыздырып уйнап җибәрегез!» – дияр кебек. Сагындыра Әлфия апабыз, бригададагы музыкантлар. Бик күңелле вакытлар булган, төштә күргән кебек кенә. Әлфия апаның язмаларын карап-тыңлап бик еш уйга талам. Нинди бөек, легендар җырчы янында йөрткән безне язмыш? Төрле чаклар булгандыр, әмма Әлфия апабыз безне беркайчан да ким-хур итмәде. Гаебебез булса – күзгә карап ачуланды, кирәк урында аркадан сөеп канатландырды. Әлфия апа моңнары беркемне дә туйдыра торган түгел, аларда халык кайтавазы, рухи кичереше, тирән моңы. Татар җырчылары арасында иң дәрәҗәле урынны

алып торган җырчының гадилегенә дә сокланырлык. Ул бөтен кешене тигез күрде. Моң яшәсә – милләт яшәр, дигән максат белән илләр гизде, узмастай тоелган киртәләрне узды, авырлыкларга бирешмәде, сынмады, сыгылмады. Бүгенге җырчыларга Әлфия апаның бик күп сыйфатларына өйрәнәсе бар. Аның җырларын үз репертуарларына алсалар, милләтебез яшәр, телебез югалмас, милли җәүһәрләребез сакланыр, дип уйлыйм.

Рәшит САБИРОВ,
нәфис сүз остасы,
Татарстанның халык артисты



Мин укыган (1972–1976 еллар) һәм бик күп артистлар тәрбияләп чыгарган Казан театр училищесы, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе белән беррәттән, Гоголь урамында урнашкан.

Училищеның студентлар театры тәрәзәсеннән без, артист булырга хыялланучылар, бигрәк тә яз айларында кояш җылы нурларын сибеп иркәләгән, агачлар яфрак ярган, тирә-як яшеллеккә чумып, табигать уянган чорда филармония ишегалдына җыелган атаклы артистларны күзли идек. Бигрәк тә Май бәйрәмнәреннән соң, җәйге гастрольләргә таралышыр алдыннан, алар бирегә еш җыелалар. Әнә, моң, җыр патшасы Илһам Шакиров капкадан кереп бара, әнә, бөтен филармония ишегалдын көр тавышы белән шаулатып, сүз остасы Фәйзи Йосыпов, әнә, култыклашып, Флюра Сөләйманова белән Габдулла Рәхимкулов килә, күп тә үтми, Римма Ибраһимова белән Таһир Якуповны күреп алабыз. Үзенең затлы шарфын кыңгыр салып, җиңелчә плащ кигән Әлфия Авзалова белән Хәнәви Шәйдуллин сөйләшеп тора. Без-студентларга кызык та, мавыктыргыч та. Эх, шулар кебек бөтен халыкка таныласы, зур артист буласы иде, дип теләк телибез... 1976 елда язмыш мине филармониягә, әнә шул атаклы җырчыларның берсе, бөтен дөнья татарларының яраткан сандугачы – Әлфия Авзалова бригадасына алып килде. Ижатымның башлангыч чорында зур талант, легендар җырчыбыз Авзалова белән филармониядә эшләвемә мин үземне бик бәхетле саныйм. Әлфия ханым минем өчен үзе бер зур тормыш мәктәбе булды, рәхмәт аңа!

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе элеккеге СССРның һәм хәзерге Россиянең теләсә кайсы шәһәрендә саф татар телендә концертлар бирә алды. Чөнки ил буйлап таралып яшәүче татар милләте – сан буенча, руслардан кала, икенче урында булган зур, көчле милләт. Татар көен юксынып

яшәүче милләттәшләр үзенең җырчыларын, артистларын һәр төбәктә илче һәм зур кунак итеп каршы ала иде.

Әлфия Авзалова үз концерт бригадасы белән чыгыш ясамаган бер генә авыл, бер генә шәһәр дә калмагандыр. Аның артистлык тормышы 1952 елда Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә башлана. Кая гына барса да, ул татар сәнгатенең илчесе булды. Бөтен дөньяда яшәүче татарлардан аның исемен белмәүче юктыр, мөгаен.

Әлфия Авзалова гомере буена татар халкының йолаларына, традицияләренә тугрылыклы булып, мәңгелек темаларны яктыртты. Аның репертуарындагы җырларда туган якка, ата белән анага мәхәббәт, гомер һәм яшәү мәгънәсе бер җепкә тезелеп бардылар. Аның җырлавы яшәргә көч бирде, иң катлаулы вакытларда күңелләргә канат куйды. Әлфия Авзалова үзен һәрвакыт иркен тота, халыкның эчке ихтыяҗларына, рухи халәтенә юл сыза, халык белән уртак телне тиз таба белде. Аның тагын бер сыйфаты бар иде: ул башка милләт җырларын да гаять зур осталык белән башкарды.

Аның «Дөнья халыклары җырлары» исемле концерт программасы белән чыгышлар ясавы яки һәр концертта диярлек үзбәк, казах, әзәрбайҗан, гарәп, һинд, башкорт, болгар һәм башка халык җырларын башкаруы милләтләрне туганлаштыруга керткән өлеше итеп кабул ителде. С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Р. Яхин, А. Ключарёв, С. Садыйкова, А. Монасыйпов кебек күренекле композиторларыбызның әсәрләре белән бергә, үзешчән композиторларыбызның әсәрләрен дә халыкка җиткерүче булып торды. Аның йөрәккә үтеп керерлек итеп җырлаган «Зөләйха», «Гөлҗамал», «Казан сөлгесе», «Шахта», «Кәккүк» һәм башка әсәрләре халык күңелендә югалмас эзләр калдырды.

Филармониянең актлар залында сәнгать әһелләренең җыелышлары даими булып тора иде. Бервакыт 200ләп җырчы-музыкантлар утырган язгы җыелышта урынымнан торып бастым да: «Татарлар яши торган араларны бергә кушкан, сәнгать күгендә якты йолдыз булып калыккан олы шәхесебез Әлфия Авзалованы халык үзе үстерде. Ул да, үз чиратында, халыкка тугрылыклы булып, гомерен туган халкына багыш-



лады. Халык кызы, халык җырчысы Әлфия Авзалованы, әйдәгез, быелгы Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидат итеп күрсәтик», – дидем. Залдагылар минем бу тәкъдимемне көчле кул чабулар белән каршы алды. Шул ук елны филармония аны Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт бүләгенә тәкъдим итте, шул ук елны Татарстан Хөкүмәте моны рәсмиләштерде.

Әлфия апабыз көтмәгәндә арабыздан китеп барды. Бу хәл миллионнар өчен зур югалту, кайгы булды. Йөрәкләр елый, күңелләр аны сагына. Ләкин Әлфия Авзалова озын гомерле җырчы булып, халык күңелендә мәңге яшәячәк! Әлфия дигән исем үзе үк «мең яшәр кыз» дигән мәгънәне аңлата.

Рәшит ШӘҺИДУЛЛИН,
тавыш режиссеры

Җырчы Әлфия Авзалова бригадасына мин очраклы рәвештә килеп эләктем. Дустым Мансур Хәсәнов Әлфия апа бригадасының «Казан утлары» инструменталь төркемендә музыкаль җитәкче булып эшли, шул ук вакытта үзе органда да уйный иде. Бервакыт ул мине үзләренең репетицияләренә чакырды. Ул көнне репетиция Гоголь урамындагы 4 нче йортның икенче катында, 3 нче класста узды. Шартларны инде үзегез беләсез, чамалыйсыздыр: ул чорда сыйфатлы яңгырашлы инструментлар



Артта басып торучылардан (сулдан – уңга) өченче – мин үзем

белән мактанырлык түгел иде бит ул. Булган инструментларны саклап кына, кадерләп кенә, ватылса, төзәтеп шөгыльләнәсең. Ә монда бер дигән япон аппаратурасы! Бу аппаратураны Әлфия апага Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев бүләк иткәнлеген әйттеләр. Ул вакытта Әлфия апада тавыш операторы булып Кузнецов фамилияле кеше эшләгән. Әмма ниндидер сәбәп аркасында, тавыш операторы репетициягә килмәгән иде. Шул ук көнне аларга ватылган микрофонны рәтләштем. Шуннан соң алар мине үз яннарына эшкә чакырдылар. Ул чакта проект институтында эшли идем – перевод белән филармониягә күчтем. Бу 1982 елның 9 нчы май тирәләре иде. Минем Әлфия апа бригадасында беренче гастрольләрем Сарман, Мөслим, Актаныш якларына булды. Искиткеч матур, җылы яз! Без – бөтен бригада артистлары, автобуска төялеп, Сарман якларына юл тоттык. Эшли башласам да куркыта, үземдә зур җавапчыллык тоям. Минем борчылганымны күреп, Әлфия апаның уң кулы – Кәрим Габидуллин миңа бурычларымны аңлатты, эшнең асылына төшендерде. Күңелем тынычланды, эшли алуыма ышаныч туды. Чынлап та дус, тату коллектив мине үз итте, матур гына бергә эшләп кайттык.

Бүгенгедәй хәтердә, әлеге маршрут белән баргач, без барлыгы 100 концерт бирдек. Һәрбер өч ел саен шушы маршрут кабатланып, һәрчак 100дән дә ким булмаган концерт бирә торган идек. Кая гына барсак та, безне колач җәеп каршы алдылар. 80ләп концерт биреп, Әлфия апаның туган ягы – Актанышка юл тотканда, Әлфия апаның тамак төбе шешеп, бик нык авырды. Кәрим Әлфия апага күпме генә, кайтып китик, авырыйсыз бит, дип ялынса да, Әлфия апа тыңламады. «Куелган планны үтәмичә кайтмыйбыз», – дип, кырт кисте. Табиб чакырып тамак төбен дәвалаганнан соң, без гастрольләрне дәвам иттек. Әлфия апа, каты авырган килеш, 20ләп концерт бирде. «Минем авырганлыгымны сиздермә, тавышны яхшылап көйлә, кирәк җирендә сузып тор», – дип боерды. Мин ул кушканча, шулай эшләдем. Әлфия апа һәрвакыт халык өчен, тамашачысы өчен борчылды. Элек бит аның концертына билетлар алдан ук сатылып бетә торган иде. «Халык безне көтә, тамашачыны алдап булмый», – дигән сүзләре хәзер дә колак төбендә яңгырап тора.

Хәтердә бик тә уелып калган тагын бер вакыйганы искә алып китмичә булмый. Кукмара районнары буйлап гастрольләрдә йөргән вакыт. Юллар пычрак, саз, яңгырлар. Бер авылдан бер авылга көчкә барып җитәбез, автобуслар батып калу очраклары да еш булды. Без барасы урында өч концерт билгеләнгән. Берсе – 16:00 сәгатьтә, икенчесе – 18:30да, соңгысы – 21:30да. Без юл газаплары белән концертка килеп җитешмәдек. Бу авылга бик соң барып җиттек. Әмма халык безне төн уртасына кадәр көткән, таралмаган. Барып җиткәч, өйләренә кайтып киткәннәре дә, кабат килеп, без сәгать 11дә концертны башладык. Концерт иртәнге 01:30да тәмамланды. Урак өсте иде, күп колхозчылар ул көнне йоклап та тормыйча басуга киттеләр. Ә без бер-

нинди яшәү өчен шартлар булмаган колхозның бер агач бинасында таң аттырдык. Шунда да Әлфия апа ник бер арыганлыгын сиздерсен, ник бер зарлансын?! Киресенчә, безнең күңелләребезне күтәрергә, кызык сүзләр сөйләп көлдерергә ярата иде ул. Авырлыкны шулай уен-көлке белән үткәреп җибәрә алуы бездә гомергә соклану уятты.

Ә төньяк башкаласы – Ленинградка гастрольләр белән без, гадәттә, көз көне – октябрь, ноябрь айларында бара идек. Без килүгә һәрвакыт бөтен билетлар сатылып беткән, тамаша залы халык белән шыгрым тулы. Андагы тамашачы бик тә зәвыклы, татар теленә, моңына сусаган милләттәшләр булганлыктан, безнең концертлар бигрәк тә җылы, дулкынландыргыч уза иде. Билет сата торган маржа хатыннарына кадәр Әлфия апа җырларын тын да алмыйча тыңлыйлар. Аны татарның Людмила Зыкинасы дип, үзара мактауларының тере шаһиты булырга туры килде. Ул зур, чиста яңгырашлы, матур залларда Әлфия апаның моңлы тавышы тагын да серлерәк ишетелә торган иде. Аны бөтен милләт вәкилләре дә үз итте, яратты, чөнки ул чын мәгънәсендә җырчы иде.

Мин Әлфия апа бригадасында барлыгы биш елга якын эшләдем. Бервакыт шундый коточкыч хәл булды, без юл-транспорт һәлакәтенә очрадык. 1985 елның ахыры иде, тиздән Яңа ел җитә, дип куанышып йөрибез. Бу хәл Мари-Эль Республикасында, Йошкар-Ола шәһәренә концерт белән барганда булды. Без иң элек электричка белән Йошкар-Олага килдек. Аннан безне ПАЗ автобусы каршы алды. Руль артында яшь кенә егет. Вакыт кичке 7ләр тирәсе. Безнең концерт башланырга 1 сәгать вакыт бар. Кафега кереп, кефир, корысары алып тамак ялгадык та юлга кузгалдык. Бозлавыклы юлдан шофер чаба да чаба, янәсе, безне вакытына илтеп җиткерә. Шулчак ул каршыга килә торган машиналар юлына чыгып, алдагы машинаны узасы иде, безнең автобус каядыр барып бәрелде. Минем күземне бик нык яктылык яктыртканын гына беләм, калганын хәтерләмим, аңымны югалтканмын. Мин кулымнан тотып автобустан чыгарганда гына бераз айнып киттем. Баштан кан ага, чатнап баш авырта, берни хәтерләмим. Урамда чатнама суык. Ә Гыйләҗев Минхәмәт белән Кәрим хатыны Сания, автобус тәрәзәсе ватылып, урамга ук чыгып очканнар. Сания, җирдә ятканда айнып киттем, дип сөйләнде. Кәримнең кул башы имгәнгән иде. Әлфия апабыз алдагы утыргыч артына кинәт бик нык итеп күкрәге белән бәрелгән. Безнең барыбызны да шул тирәдәге дәваханәгә алып киттеләр. Беренче ашыгыч ярдәм күрсәттеләр, урын булмаганлыктан, беренче көнне коридорда яттык, икенче көнне палаталарга күчерделәр. Бер өч-дүрт кешегә генә зыян тимәде. Инде болай гына котылуыма сөенеп бетә алмадым, чөнки анда минем өстемә бөтен аппаратуралар ауды бит, белмим, ничек исән калганмындыр?! Ул көнне Әлфия апа эчтән янып-көйсә дә, бернинди гауга чыгармады. Кызларына да телефоннан шалтыратып: «Балакайларым, борчылмагыз, берни дә булмады, без берәр атнадан кайтып җитәбез», –

дип тынычландырды. Хәтта безне Казан больницасына күчерергә дип, вертолет та бирмәкче булдылар, әмма Әлфия апа ул ярдәмне дә кире какты. Без бер атна дәваланганнан соң, өйләребезгә кайттык. Минем башымда, Минхәмәтнең маңгаенда, иреннәрендә бу вакыйганың җөе мәңгегә калды. Өйгә кайтып озак та тормадык, кабат җыенып гастрольләргә чыгып киттек. Әле безнең яралар да ныклап төзәлеп бетмәгән иде. Шул авыр мизгелләрдә дә Әлфия апа үз күңелен үзе күтәрергә рухи көч тапты, кызык сүзләр эзләде, үз алдына сөйләнде, көлде, юатты. Шул ук вакытта каты холыклы, көчле рухлы, үтә дә таләпчән ханым иде ул. Ул хөрәсәннәргә, эчкечеләргә бервакытта да якты чырай күрсәтмәде. Уттан алып суга салып орышырга да күп сорап тормый иде. Тәртип бозганнарны бора да, кире кайтарып җибәрә. Шуңа күрә дә безнең бригадада һәрвакыт коры тәртип булды. Аның өчен иң мөһиме – концертка килгән халыкның күңелен күрү, югары сыйфатлы чыгыш ясау, халык күңелен моң белән сугару, тамашачы мәхәббәте иде. Ул һәрвакыт безгә: «Сез бит халык каршына чыгасыз, матур итеп киенегез!» – ди торган иде. Чыннан да, җир тырмашып, нәтиҗәле эшләдек. Безнең филармониядә бөтен бригадаларның эш күрсәткечләре язылган стенд тора иде. Анда күпме план бирелгәнлеге, ул күпмегә үтәлгәнлеге күрсәтелә. Бу саннар әле дә күз алдымда торалар. Әлфия Авзалова бригадасы – 1нче урында. 205 концерт бирергә тиеш булып, без аны 250 итеп үтәгәнбез! Филармония казнасына – 60 мең сум керем керткәнбез!

Кайда гына чыгыш ясасак та, тамашачы Әлфия апаны бик тә җылы кабул итте. Сәхнәгә кат-кат чакырып җырлаталар, көчле алкышларга, чәчәк бәйләмнәренә күмәләр. Халыкның күплегеннән залда тын да алып булмый. Әлфия апаның чәчләреннән, битләреннән тамчы-тамчы тир тама... Менә шулай тырышып эшләп алды ул ипиен! Менә шулай яратты ул халкын, телен, милләтен!!!

Ул бервакытта да бер генә җырга да концертны кыскартмады. Югыйсә бит, көненә ничәмә-ничә концерт бирә иде. «Без бик әйбәт чыгыш ясарга тиеш, халык хәләл акчасын түләп керә», – ди торган иде ул.

Гадәттә, артистлар турында халык телендә күп гайбәт йөри. Әлфия апа да искәрмә булмады. Белсәләр дә, белмәсәләр дә сөйли ачы телләр. Әлфия апаны да сәхнәгә «кабып» чыга дип әйтергә дә телләре чирканмады. Күрәсең, бу Әлфия апаның сәхнәдә һәрвакыт шат булуына, сикерә-сикерә, бии-бии җырлап йөргәненә аптырап та сөйләнгәндер, дип уйлыйм. Без аның белән һәрвакыт бергә булдык, аның беркайчан да, хәтта зур банкетларда да бер генә чәркә исерткеч эчемлек капканы да булмады. Көнгә дүртәр-бишәр концерт биреп, аягында басып тора алмаслык дәрәҗәгә җитүе дә азык булгандыр усал телләргә. Әйе, кеше хәлен кеше белми. Ул көрәш мәйданында түгел, сәхнәдә батырлык кылды! Үлем хәленә җитеп авырган чакта да, авызыңны ерып, сикереп, биеп, җырлап тор әле син! Бу эшне Әлфия апа кебек бөек шәхесләр генә

башкара ала! Шулай ук безнең арада яман гадәт – көнчелек тә яши. Ул халыклар арасында да, артистлар арасында да чәчәк аткан. Нәкъ шул филармониядә зал тутыра алмаган, тавышлары, моңнары чамалы җырчылар Әлфия апа турында яман сүзләр чыгарырга, аяк чалырга җөрьәт иттеләр. Шушы халәттә дә Әлфия апа югалмады, үз югарылыгында балкыды, кыйбласына тугры булып калды. Югыйсә бит, ул шул артистларның тутыра алмаган планнарын үтәшеп, аларга хезмәт хакы ясаган бөек шәхес! Аның вөҗданы һәрвакыт чиста булды, ул кеше сөйләмәде, мине сөйлиләр, дип сүз җөпләп йөрмәде. Ул канат астына алган балалар да, үзе кебек, гадел, киң күңелле, уңган-булган, кешелекле булып үстеләр. Үз балаларын гына түгел, ятимә калган туган балаларын да үз канаты астында җылытты ул. Әйе, ул ятимлекнең бөтен авырлыгын, ачысын-төчесен үз җилкәсендә татыган, җирдән күтәрелгән якты йолдыз бит!

Ренат ХАРИС,
Татарстанның халык шагыйре



Дөнья эстрада сәнгатендә туктаусыз үзгәреш давылы хөкем сөрә – җырларның асылы, аларны башкару ысуллары, модалар, стильләр уздырыштан үзгәрәләр, сәхнәләр, фән һәм техниканың иң яңа казанышларын файдаланып, җырчылар тирәсендә фантастикага якын дөнья барлыкка китерәләр. Бәхеткә, араларында үзләренең сәнгати биеклекләрен, кабатланмас осталыкларын маякка әверелдергән җырчылар да бар. Татар музыкасы дөньясында шундыйларның берсе – Әлфия Авзалова.

Бездә дә татар эстрада сәнгатен заман таләпләре дәрәҗәсенә күтәрү максаты белән башланган «Үзгәреш җиле» музыкаль фестиваленең икенчесе узды. Беренчесе узгач, матбугатта да, «ың-шың радиосында» да бәхәс болытлары куерган иде, кискен тәнкыйть яшеннәре чатнады – янәсе, «Үзгәреш җиле» татар эстрадасын үзенең милли нигезеннән тайпылдыра, янәсе, аны, Рәшит Вахапов, Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова салган традицияләрдән аерып, ялгыш юлга алып кереп бара.

Фестивальнең икенчесеннән соң мондый гаепләүләр кимеде. Татар җыры, үзенең нигезен саклаган хәлдә, яңача, дөньякүләм музыка сәнгатендәге казанышлар ярдәмендә баеп, хәтта бераз катлаулана төшебрәк яңгыраса да, бераз

сискәндерсә дә, музыка сөючеләр аны тынычрак, музыка көченә бирелебрәк, ләззәтләнебрәк кабул иттеләр кебек. Бүген «Үзгәреш җиле»ндә яңгыраган җырларның иң уңышлыларын дөньяның теләсә кайсы эстрада сәхнәсендә яңгыратып, татар музыка сәнгате белән шаккатырып була, дип уйлыйм мин. Фестивальнең өченчесе, һичшиксез, татар эстрада сәнгатен халыкка тагы да якынайтачак.

Татар җырын фольклор дәрәҗәсеннән, үзешчәнлектән профессиональ сәнгать югарылыгына әнә шул Баһаповлар, Шакировлар, Авзаловалар күтәрделәр, аны фортепьяно һәм инструменталь музыка белән, оркестрлар белән куштылар, аңа яңача яңгыраш бирделәр. Тальян гармун, баян тавышына кушылып җырлауга күнеккән күңелләр алда әйтелгән артистларның яңалыкка омтылышларын да, дөресен әйтсәк, заманында сәерсенебрәк, сискәнебрәк кабул иттеләр һәм тора-бара үз иттеләр. «Үзгәреш җиле» белән дә шулай булачак. Ләкин Баһаповларны, Кудашеваларны, Шакировларны, Авзаловаларны, Рәхимкуловларны, Бигичевларны, Вафирә Гыйззәтуллиналарны сагыну калачак. Уйлап, җиренә җиткереп эшләнгән яңарыш беркайчан да үткәндәге казанышларны инкяр итми, ә аларны үзенә трамплин итә.

Әлфия Авзалованың тавышын мин иң беренче мәртәбә радиодан ишеттем. Бөек Ватан сугышыннан соң без шәһәрләрдән шактый ерак, электр да килеп җитмәгән татар авылларында тимерчыбыксыз да сөйли торган детекторлы радиоалгычлар белән мавыктык. Ул елларда электр үткәргеч баганалар телеграф баганалары дип атала иде. Кара катыргыдан ясалган репродукторлар әнә шул баганалар ярдәмендә генә сөйли иде. Көннәрдән бер көнне әтием зур, авыр аккумуляторлы, төрле дулкыннарны тота торган чын радиоалгыч алып кайтты. Шуны боргалап утырганда, өйне тутырып, «Кәккүк» җыры яңгырады. Ул җыр мине тетрәтте, таң калдырды, мәңге юылмаслык булып күңелемә сеңде. Соңыннан гына бу җырның башкаручысы Әлфия Авзалова икәнен белдем. Солтан Габәшинең Әхмәт Ерикәй шигыренә язган «Кәккүге» Әлфия Авзалова башкаруында мине ниндидер башка, гүзәл, серле, сихерле дөньяга алып кереп китте. Кушымталы куплеттан соң гармун йә баян тавышы ишетергә күнеккән күңел өчен, бу озын, дәртле, торган саен көче арта барган ташкын булып агылган монолог минем музыкаль зәвыгыма зур йогынты ясаган иң беренче әсәр булгандыр. Бу җырны Әлфия апага кадәр дә башкарганнар, аңардан соң да күпләр башкарды һәм башкара, ләкин «Кәккүк»не бөек җыр итүче җырчы, минем фикеремчә, әлбәттә, Әлфия Авзалова. Ул җыр әлегә кадәр минем йөрәгем хәтерендә фәкать Әлфия апа тавышы булып саклана. Мин бу әсәрне ниндидер бер киеренке сюжетлы операның кульминациясендә җырлана торган ариясе белән тиңләр идем.

Җырның тәне – шигырьдә, җырның җаны – көйдә, аларны бергә кушып мәгънәле гүзәллеккә әверелдерүче илаһи зат – җырчы. Җыр – җырчы тавышында яши. Әлфия апа озын иҗат гомерендә бик күп җырларны кабатланмас

гүзәллеккә әверелдерде. Шундый җырлар арасында, минем уйлавымча, композитор Резеда Ахиярованың Ренат Харис шигыренә язган «Кар сулары» дигән җыры да бар. Ул радио фондында «Сагындыра» дигән исемдә саклана.

Бу җырны Әлфия апа тавышына еллар бәсе утыра башлаганда җырлады. Аның тумыштан көчле, иң куе һаваны да ерып үтә торган, зур залларның иң соңгы рәтләренә барып җитә торган, кабатланмас тембрлы күкрәк тавышына аккош кебек моңлана белгән, бөркет булып коркылдый алган сандугач оя корган иде.

Сагындыра,
кар сулары булып гөрләп аккан,
Сине тапкан бәхетле яз
сагындыра, –

дигән сүзләрне ул ниндидер битараф тынычлык белән башлый. Ләкин:

Нигә, нигә кабат минем хәтеремә
кар сулары кагылдылар? –

дигән сүзләрне җырлаганда Әлфия апа Шекспир трагедияләрендә генә була торган үтә фаҗигале мохиткә эләккән трагик ханымга әверелә.

Икенче куплетта ул шул сагышлы, ләкин сагынычлы атмосферадан чыга алмыйча аптырап, гасабиланып, үзенә-үзе сораулар биреп яши:

Әллә алар
сеңмиләрме кара җиргә?
Чишмәләргә нигә алар агылмыйлар?..

Соңгы куплетны да Әлфия апа философларча тыныч кына, уйланып кына, бик мөһим вакыйгага әзерләнеп башлый. Ул үзенә-үзе, шул ук вакытта безгә дә, хафалану-уфтануларының, үкенечләренең серен ачарга тиеш. Һәм ул аны шулай эшли дә – йөрәгендә кар сулары булып яшәгән хатирәсен бәян итә:

Инде гомер җәем аша үтеп барам.
Күз алдымда һаман моңлы чагың тора.
Сагындыра,
кар сулары булып гөрләп аккан,
Сине тапкан
һәм югалткан
моңлы язым сагындыра! –

дип, күз яшьләренә йотлыга-йотлыга җырлый Әлфия апа. Аның тетрәнүле тавышы беркемне дә битараф калдырмый, моңлы дулкын булып күңел кылларына кагыла.

Минем белүемчә, бу җырны репертуарларына кертергә теләүчеләр булган, ләкин Әлфия апа башкаруын тыңлаганнан соң, берсе дә алынмаган.

Бер елны Рәшит Вahапов исемендәге җыр фестивале Уфада узды. Фестивальнең оештыручысы Рифат Фәттахов Уфага Әлфия апаны һәм мине үзенең җиңел машинасында алып барды. Озын юлны без бик күп нәрсәләр турында сөйләшеп үткәрдек. Актаныш җирләре дә, Ык, Сөн сулары да артта калды. Бер кафега кереп чәй эчкәндә Әлфия апа әнә шул «Кар сулары»н искә төшерде.

– Резеда Ахиярованың теге «Сагындыра» дигән җыры синең сүзләргә бугай... Шулай бит?

– Минем сүзләргә, Әлфия апа... – дидем мин.

– Ул җыр тач минем турында бит, – диде Әлфия апа, авыр сулап. – Мин аны сәхнәдән берничә тапкыр гына башкардым... Аны еш җырлап булмый...

– Ник, Әлфия апа?

– Аны җырлаганда хәтеремә ике нәрсә килеп төшә... Берсе... Мин гомерем буе бер кешене генә өзелеп сөйдем... Ул да һушыннан язарлык булып мине яратты... Аның назына сусап, гастрольләрдән кайтуларым, безнең кавышулар – әкият тә, драма да... Ләкин мин аны, йөрәк итен кисеп ташлаган кебек, үземнән өзеп ташларга мәҗбүр булдым... Көч таптым... Шулар искә төшә. Икенчесе – мин сабый чагымда, артык тамак булып, кеше кулында калганмын... Чарасызлыктан, бу сабый ачлыктан интекмәсен дип, миңа бозлы сөт эчергәннәр... Билгеле, моны хәтерләмим, миңа моны сөйләделәр... Мин чирләгәнмен, ләкин исән калганмын... «Кар сулары» дип әйтүгә, мин бозлы сөт эчкән кебек булам да, бугазым туңа, тамак тыгыла, тавыш киселә...

– Сезне Ходай безгә диеп саклаган, Әлфия апа, – диде Рифат Фәттахов. – Сез бүген безнең белән Уфага барсын, дип...

– Шулай микән?.. – дип куйды Әлфия апа һәм тынып калды.

– Билгеле, шулай, Әлфия апа! – дип дәвам итте Рифат. – Уфага барып, бөтен Уфа тамашачысын тагын аякка бастырып, Сезне дә, безне дә алкышларга күмдерсен, дип...

– Бар иде андый чаклар, бар иде, – дип уфтанды җитмешенең аръягына чыккан Әлфия апа...

Без сәфәрне дәвам иттек. Әлфия апа шофер янында утыра, без – арттагы урыннарда. Бик озак сөйләшмичә бардык. Машина салонында авыр тынлык. Шофер музыка җибәргән иде, Әлфия апа радионы туктатырга кушты. Шактый гына вакыт тынлык бушлыгында интегеп баргач, Әлфия апа, бөтен гәүдәсе белән кабат безгә борылып:

– Ул җырны мин тагын җырлыйм әле, барыбер җырлыйм, – диде, – симфоник оркестрга кушылып, «Кар сулары» дип җырлыйм мин аны...

Беравыктан, катгый фикергә килгән интонация белән, дәвам итте:

– Юк, элеккечә – скрипка һәм фортепьяно белән генә җырлыйм мин аны... «Кар сулары»н шулай гына ишетәм! – диде...

Римма ИБРАҺИМОВА,
җырчы, Татарстанның халык артисты



Әлфия апа хәтле тынгысыз, тиктормас, янып эшләп торган кешене мин, гомумән, хәтерләмим. Аның үз-үзен тотышы, итагатьлелеге, зәвык белән киенүе без-яшьләргә һәрчак үрнәк булды. Аның белән якыннан очрашуым, танышуым чираттагы концертыбыз вакытында булды. Безне – бер төркем яшьләрне, филармониядән Мәскәүгә укырга җибәрделәр.

14 кеше эстрада группасын тәмамлап кайттык та, үзебезнең яшьләр бригадасын төзеп эшли башладык. Яшьләр Спорт сараенда концерт куярга килгәч, безнең белән бер сәхнәгә Әлфия Авзалова белән Илһам Шакиров чыкты. Бу безнең өчен зур имтихан иде. Сәнгатебезнең ике моң чишмәсе, алтын баганалары, буй җитмәс бөек җырчылар алдында чыгыш ясавы икеләтә дулкынландыргыч хәл бит. Безнең чыгышыбызга нинди бәя бирерләр, дигән уй башыбыздан чыкмады. Нәтиҗәдә, без, Әлфия апа белән бер гримеркада туры килдек. Ул гаҗәеп аралашучан, ачык күңелле, искитмәле шаян ханым булып чыкты. Берсеннән-берсе кызыклы вакыйгалар, анекдотлар сөйләп, безнең күңелләребезне күтәрде, калтырап торган тезләр кире үз урынына утырды. «Әле йөри-йөри, үзегез дә шомарырсыз, анекдотлар да өйрәнерсез, тормыш ул!» – дип, кинәт кенә җитдиләнеп куйганы әле дә күз алдымда. Ул көнне Әлфия апа үзе белән термоска салып чәй алып килгән иде. Бөтенебезне җыеп, кайнар, тәмле, хуш исле, мәтрүшкәле чәе белән сыйлады. Аннары, бу бөек шәхесләр белән бергә, илебезнең башка шәһәрләрендә дә чыгыш ясарга туры килде. Аларның Илһам абый белән ничек җылы мөгамәләдә икәнлекләрен күреп сокланмый мөмкин түгел иде. Гомумән, өлкән буын җырчыларының бер-берсенә карата булган тирән хөрмәтендә тәрбияләнеп үстек без! Әлфия апа без чыгыш ясаганда пәрдә читеннән карап торыр иде дә: «Сеңлем, менә бу җырыңны, менә болайрак итеп башкарып кара әле син», – дип, җайлап кына киңәшләрен би-

рер иде. Үзен өскә куеп, яшь җырчыларны түбәнсетү, гомумән, булмады. Аның әниләрчә яратып, дусларча үз итеп биргән киңәшләрен тота-тота, үзебез дә сизми, Әлфия апаның сәнгать һәм тормыш мәктәбен уздык. Без гастрольләр вакытында да бер гаилә кебек дус, тату идек, сез яшьләр дип, безне Әлфия апа беркайчан да читкә этәрмәде, ана каз кебек, барыбызны җил-яңгырдан ышыклап, гел үз канаты астында йөртте. Тора-бара Әлфия апам сәхнәдәш кенә түгел, ә әниемдәй якын сердәшчемә, җан дустыма әйләнде. Гастрольгә барган чакта хәтта поездда да бер купеда барырга мине сайлавы, аның да мине үз итүе, яратуы, хөрмәт итүе турында сөйли. Әлфия апа белән икебез ике бригадада эшләсәк тә, гомуми концертларда бик еш очраштык. Ул үзенә биргән күчтәнәчләр белән зур чәй өстәле ясап, барыбызны җыеп сыйлый. Ул күңелдә һәрвакыт кояштай нурлы йөзле, ачык, саф күңелле, шаян сүзле булып истә калды.

«Мәк чәчәге» җырын үз репертуарыма алып башкаргач та, ул аңа зур бәя бирде. «Мин бу җырны бары тик синең башкаруда гына кабул итә алам, бу синең җыр!» – дигән мактау сүзләре «Мәк чәчәге» җырын ишеткән саен искә төшә.

Соңгы тапкыр без аның белән Башкортстанга, Салават Фәтхетдиновның туган авылына бардык. Ул чагында инде Әлфия апа хәйран өлкән яшьтә иде. Юл газабы – гүр газабы, дип тикмәгә әйтмәгәннәр бит инде. Аның шул вакытта да тамашачыларны күрү теләге искиткеч зур иде. Ул юлда барганда гел: «Мин сәхнәдә үлсәм дә үкенмимен!» – дип кабатлады. Бөтен гомерен, җанын сәхнәгә биреп, соңгы көненә кадәр тамашачыларның бик яраткан җырчысы булып, бик көчле алкышларга күмелеп яшәгән, иң бәхетле, озын сәхнә гомерле җырчы, диясем килә Әлфия апаны.

Ринат ҖӘЛӘВЕТДИНОВ,
эшмәкәр



Ни гажәп, без Әлфия апа белән якыннан чит илдә – Венгриядә сәфәр вакытында таныштык. Ә аңа кадәр, әлбәттә инде, аның концертларында булып, башка меңләгән тамашачы кебек үк, аның талантына, моңына сокланып, әсирләнеп утырган зат мин. Минем әнием бик тә матур җырлый иде. Ул татар халык җырларын бик матур, моңлы итеп акапеллага башкара иде. Татар халык җырларына карата мәхәббәтне дә бездә ул тәрбияләде. Әлфия апа катнашындагы концертларга баруны да

ул оештыра иде. Без, әни белән, Әлфия апаның 4-5 концертына барганымны хәтерлим. Горький урамындагы Татар театрында Илһам Шакиров белән берлектә узган зур концерт программасын да караганым истә.

Минем дустым Рифкать, ничектер, Илһам Шакиров белән бик дуслар иде. Бервакыт ул мине үзе белән Карл Маркс урамындагы бер йортка алып китте. Аның әйтүенчә, анда татар җырчылары җыелачак икән. Шулай итеп без танылган җырчылар, музыкантлар арасына килеп кердек. Аралашып, сөйләшеп, якыннан танышып киттек. Утыра торгач, тиздән мондагы күп кенә артистларның чит илгә – Венгриягә сәфәргә барасылары турында белдем. Анда барасы кешеләрнең исемлеген күргәч, баш күккә тиде, алар белән мин дә бу ерак сәфәргә барырга дип карар кылдым. Инде ныгытып без Әлфия апа белән ерак сәфәрдә – Венгриядә таныштык. Без аның белән сәгатьләр буе, озаклап, тормыш-яшәеш турында, милләт киләчәге, татар җырлары турында сөйләштек. Әлфия апаның сүзгә кесәгә кермәгәнлеген белсәм дә, аның бу кадәр кызыклы әңгәмәдәш икәнлеген чамаламаганмын икән. Якыннан аралаша торгач, аның искитмәле зирәк акыллы фикер йөртүче, талантлы, олы җанлы ханым икәнлеген аңладым. Аңа карата хөрмәтем тагын да арты. Бу сәфәр әгәр дә Әлфия ападан башка булса, аның бер генә дә кызыгы булмас иде. Бу минем өчен генә түгел, ә бәлки, бергә барган барлык делегация вәкилләре өчен дә, хәтта ки венгр дуслар өчен дә шулай булды. Безнең өчен соңгы көнне чегәннәр ресторанында зур табын, кичке аш әзерләгәннәр иде. Ул ресторанда кунаклар өчен берничә аерым бүлмә бар, без-татарларны шуның бер бүлмәсенә кертеп утырттылар. Алга тәмле ризыклар китереп торалар. Без башта моңаеп утырмаска дип, үзебезнең татар җырларын сузмакчы булдык. «Әй, алмагачлары»н суздык, бераз утыргач, ашап-эчкәч биеп тә алдык. Тик барыбер кыздырып булмый халыкны. Шунда Әлфия апаны җырларга кыстый башладык. Әлфия апа бик озак кыстатып тормады. Татар, үзбәк, рус җырларын җырлаганнан соң, элеккеге венгр романсын сузып җибәрде. Иң элек шаулап торган ресторан тынып калды, аннан соң бөтен бүлмәләрдән без утыра торган бүлмәгә агыла башлады халык. Ул да булмады, башка бүлмәләрдә уйный торган музыкантлар, инструментларын күтәреп, безнең янга күченделәр. Алар Әлфия апа белән һөнәри музыкантлар телендә сөйләшә башладылар. Әле Әлфия апаның беркайчан да бу кадәр инструментка кушылып җырлаганы булмагандыр. Ул көнне хәтта пешекчеләр дә эшләрен ташлап тамаша кылды. Хәтта ки ресторан дивар ларының да бу кадәр шау-шулы, рәхәт бәйрәм күргәне булмагандыр?! Әлфия апага «Журавли» дигән әлеге романсны берьюлы җиде мәртәбә җырларга туры килде. Инде Әлфия апа үзе дә, туеп: «Җитте инде, мин бит һәрбер җырлаган саен ул җырга күңелемне биреп җырлыйм, аны бит күңелеңне бирмичә җырлап булмый», – дигәч кенә, тындылар. Ресторан директоры безгә баздан яхшы винолар ташый башлады. 2 сәгать ярымга исәпләнгән кичке аш вакыты төнгә

кадәр сузылып, безне гидлар ресторанна кәчкә алып чыгып киттеләр. Бу Будапешт шәһәрендә Әлфия Авзалованың дөнья күрмәгән, планлаштырылмаган зур концерты булды!

Венгриядән Казанга кайткач, безнең дуслыкның икенче өлеше башланды. Ул безне үзенең концертларына чакырды. «Аннары аның белән берничә мәртәбә ресторанда очраштык. Һәм иң кызыгы шул: ике елдан соң мин янә Венгриягә киттем. Әлбәттә инде, минем бу илне сайлавымда Әлфия апаның өлеше зур дип уйлыйм. Чөнки без аның белән анда нинди генә могҗизалы урыннарда булмадык, без күрмәгән, йөрмәгән урыннар аз калгандыр Венгрия башкаласы Будапешт шәһәрендә. Бу минем хәтеремдә мәңгелеккә уелып калыр. Ул кешене ниндидер көч белән, магнит кебек үзенә тарта. Әлфия апаның кияве Равил Әфганстанга киткәч тә без аралашуны ташламадык, киресенчә, мин аларга терәк булырга тырыштым. Ул миңа гаҗәеп тормыш тарихлары сөйләде. Башыннан үткәннәрен дә, башка кешеләр язмышы турында да күп сөйләштек. Ул үзенә теләсә кемне якын китермәде, аннан хәтта кайберәүләр куркып торалар иде. Ул үз янына ышанычлы, тугры дусларны сайлый белде. Мин шул бәхетлеләрнең берсе булуыма куанып бетә алмыйм. Без Әлфия апаның җырларын киләчәк буыннарга илтеп җиткерергә тиеш. Бу сандугач алар күңеленә дә оя корсын! Аның сихри моңы зур көчкә ия, ул – чын табигать баласы. Ходай Тәгалә аны безгә бүләк итеп җибәргән!

Мин еш кына әти-әниемнең каберләре янына барам һәм, ни гаҗәп, минем юл өстендә бөек җырчыбыз, дустым Әлфия апа кабере тора. Мин беркайчан да Әлфия апа белән исәнләшмичә, аның белән серләшмичә юлымны дәвам иткәнем юк. Балаларым белән барганда, алар белән, тукталып, Әлфия апа турында, аның нинди бөек җырчы булганлыгы турында сөйлим, кайткач, җырларын тыңлатам. Әйе, еллар узар, минем балаларым бу изге урынга тукталып, аның турында оныкларыма сөйләрләр. Буыннар чылбыры өзелмәсен дә, еллар тыныч, имин булсын! Ул безнең якты истәлегебез, матур үткәнебез. Татар моңы аша милләтебезне бер дәвер яшәткән олуг җырчы – Әлфия Авзалова исемен, аның җыр-моңнарын онытырга безнең хакыбыз юк!

Ринат СИБГАТУЛЛИН,
музыкант

Аналарча кайгыртты



Армиягә кадәр үк, мин Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләдем, армиядән соң да, икеләнмичә, шунда, яраткан эшемә кайттым. Бу 1978 ел иде. Әмма мин эшләгән бригадалар таркалган иде.

Армиядә вакытта кулга баян бик сирәк алынды, шуңа да бармаклар йөгереп тормый. Мине Әлфия Авзалова төркеменә сынау срогы белән эшкә алдылар. Иң беренче гастрольләребез Башкортстан, Урал якларына булды. Ул вакытта гастрольләр ике-өч айга сузыла торган иде. Киткәндә, фәлән айга фәлән концерт куясыз, дип план биреп җибәрәләр. Кайтканда, бригаданың бөтен юл чыгымнарыннан кала, без дәүләт казнасына керем акчасын да алып кайтырга тиешбез. Бу бик авыр хезмәт, әгәр дә тулы заллар җыелмаса, концертыңа халык йөрмәсә, син бригадаңны тота алмыйсың һәм бригада таркалуга дучар була. Әлфия апа бригадасына эләгү кемгә дә зур мәртәбә булганлыктан, тырышып-тырмашып сынау срогын үттем, аннан соң да ике-өч ел бергә эшләдек әле.

Кызыклы, истә калырлык вакыйгалар, хәтердә уелып калган истәлекләр бик күп. Әле дә исемдә: 23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне, безнең репетиция вакыты иде. Ул мине башкалардан аерып: «Ринат, сине Ватанны саклаучылар көне белән котлыйм!» – ди. Мин мондый аерым игътибардан югалып калдым. Ул, сизенгәндәй: «Әле башкалар моңа лаек түгел», – дип куйды.

Һәрберебезгә кушамат тагып, шул исем белән эндәшеп, күңелләрне күтәреп, шаяртып йөрүләре бер дә онытылмый. Минеке – «Хмени» иде.

Озакка сузылган гастрольләрдә ул безне җыйнап, барыбыз турында аналарча кайгыртып йөри торган иде. Ул безне гадилеге, кешелеклелеге, таләпчәнлеге белән дә таң калдырды. Югыйсә, бөтен халык ни эшләргә белми торган дәрәҗәле җырчы, ә безнең белән гел дусларча, үзебезчә, гади иде ул.

Әлфия апаның җырларын татар халкы гына түгел, башка милләт халкы да яратып тыңлады. Ул бик күп телдә җырлый, һәрбер җырын күңел биреп, җан атып, яратып башкара. Мәскәүдә узган концертларга руслар да яратып килә торган иде. «Волга-реченька» дигән җырын башкаруга, руслар, аягүрә басып,

гөр килеп алкышлый. Бервакыт, зур мәйданда ике урында концерт бара. Берсе – безнеке, бездән читтәрәк мәйданда София Ротару чыгыш ясый. Әлфия апада зал шыгрым тулы, ә София Ротаруда ярты гына зал халык. Менә шушы мисал гына да Әлфия апаның ил буенча нинди зур дәрәҗәле җырчы икәнлеге турында сөйли бит! Кайларда гына булмадык, өчәр ай гастрольләрдән кайтып керми торган идек. Күп бригадалар айлар буе йөреп үз чыгымнарын да каплап бетерә алмый, ә без башкалар биреп бетермәгән акчаны да каплый торган идек. Берсендә музыкант Игорь Иванов бер концертка бик күп халык җыелгач: «Әлфия апа, әйдә, план да үтәлер, бу концертны ике концерт бирдек, дип язабыз», – дигән иде, Әлфия апа ризалыгын бирмәде.

Бервакыт концерт вакытында ут сүнде. Ул чакта да концертны өзмәде, керосин лапмасы яктысында гармунга сыздырды гына! Нинди генә хәлдән дә чыгу юлын табар иде ул. Хәзерге артистлар бер-ике атна гастрольдә булсалар, арып-талып кайталар. Ә без ике-өч ай буе, көненә әллә ничә җирдә чыгыш ясап та, ару-талуны белмәдек. Безгә, күрәсең, Әлфия апаның бетмәс дәрте, рух күтәренкелеге, илһам чаткысы күчкәндер инде. Без-баянчыларга, Әлфия апа: «Концерт вакытында багана кебек басып тормагыз, җырның эчтәлегенә карап образга керегез!» – дия торган иде. «Әйдә, иркәм, алып барам, чишмәләргә, суларга», – дип култыклап, безне сәхнә алдына ук китереп бастыра, елмайта, кирәк булса, баяныңны куйдырып биетә дә иде. Әлфия апа мәктәбе безне күп нәрсәгә өйрәтте. Якын итеп: «Кая әле, минем Ринатым?» – дигәннәре күңелне һаман да җылытып, сагындырып тора.

Бик тә кешелекле иде Әлфия апа. Кибетләрдә кием-салым, ашамлыкларның дефицит чагы. Кайда гына барсак та, бөтен бригадага җитәрлек итеп оншикәрен, балын, чәен, итен, маен юллап табар иде. Шул ук вакытта таләпчән



дә була белде. Бервакыт бик кысан бер авыл клубында җәй көне концерт бирәбез. Ишекләр бары да ачык, без – артистлар, чиратыбызны көтеп, урамда басып торабыз, кемдер чирәмлектә утыра, сөйләшәбез, көлешәбез. Күрәсең, үзара сөйләшә торгач, онытылып киткәнбез, сүз остасы Нажия апа чыгышын тәмамлаганнан соң, сәхнәгә чыгучы юк икән. Бервакыт Әлфия апа: «А нука, керегез әйдә!» – дип, массаж тарагы белән керә-керешкә, берәм-берәм эләктереп тә алды. Безгә генә түгел, иң элек үз-үзенә карата таләпчән була белде ул. Аның сөйләм телендә, гомумән, авырдым дигән сүз юк иде. Тәне 40 температура белән янамы, хәлсезме ул, тамашачысы янына һәрчак елмаеп чыкты. Башкаларны да кызганып, баштан сыйпап тормады, аның өчен иң мөһиме, тамашачының күңелен күрү иде. «Знать не знаю!» – дигән сүзен әйтсә, аның белән карышу бернинди дә нәтиҗә бирмәячәге көн кебек ачык иде.

Концерт вакытында төрле кызыклы номерлар уйлап чыгару, яңалык кертү дә аның бай фантазиясеннән чыгып эшләнде. Берсендә барабанчы белән биюче үзләре Әлфия апага сюрприз ясадылар. Әлфия апа «Казан утлары» инструменталь ансамбленә кушылып, «Яр-яр» дигән үзбәк җырын җырлый башлауга, барабанчы таякларын биючегә тоттырып, Әлфия апа янына йөгереп чыгып бии башлады, ә биюче егет барабан кагарга тотынды. Билгеле, Әлфия апа мондый хәлне көтмәгән иде. Соңыннан барабанчы белән биючене бераз «утлы таба»га бастырмакчы иде дә, «чүәкләр, булдырдыгыз», диюдән үтә алмады. Күрәсең, үзенә дә көтелмәгән, кызыклы яңалык булды, ахрысы.

Концертлардан соң, кич ашап-эчкәч, кәрт уйнап алулар бер дә онытылмый. Әлфия апа җиңми торып, уен тукталмый торган иде. Кызык итеп, тиенмиен акчага да уйнап, бер-беребезгә бирәчәк әҗәтләрнең исәбен дә алып барып маташтык.

«Чит җирдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул», – дигән мәкальне еш кабатлый торган иде. Репетицияләр юлда булыр иде. Концерт саен тамашачылар өчен яңа җырлар өйрәнә торган иде, иң элек гармунга җырлый, аннан ансамбльгә кушылып башкара. Туган ягы Актанышны бик яратты, елына өчәр, дүртәр мәртәбә бара торган идек.

Бик тә кече күңелле, олы җанлы иде Әлфия апа. «Кая, егетләр, юасы күлмәкләрегез, киемнәрегез юкмы?» – дип, без йоклаганда күлмәкләрне юып, чайкап куя иде. Соңыннан 16 яшьлек кызы Зөлфияне концерт күлмәкләрен үтүкләргә үзе белән бергә алып йөри иде. «Күлмәк якаларын, җиңнәрен кер сабыны белән ышкып 10 минут тотканнан соң, яхшылап юасы, аннан өч мәртәбә чиста суда чайкыйсы дип», – колагына киртли-киртли, кызын эшкә өйрәткәне бүгенгедәй күз алдында. Әле бит су ташыйсы, түгәсе... Иркәлекнең ни икәнлеген белмәде кызлары, гел юлда, үзе белән эшләп, чыныгып үстеләр.

Минем өчен Әлфия апа бригадасында узган өч ел гомерем зур тормыш мәктәбе булды. Аңа барысы өчен дә чиксез рәхмәтлемен. Күңелемдә аның турында якты истәлекләр мәңге сакланыр!

Рифат ФӘТТАХОВ,
продюсер, Р.Вәһапов фонды директоры, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре



Әлфия Авзалова мәктәбе

Бу дөньяда бернәрсә дә юктан бар булмый. Бүгенге гамәлләреңә, эш-нәтиҗәләреңә дә нигез инде күптән салынган була. Заманында миңа Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхәбиева кебек мәшһүрләребез белән якыннан аралашып, хезмәттәшлек итү насыйп булды. Әйтик, әле студент чагымда ук, үзебезнең Нижгар якларында Әлфия Авзалованың 32 концертын оештырдым. Оештыручы-администратор гына түгел, концертны алып баручы да үзем булдым. Хәзер, еллар үткәч, бу хакта уйланам да, шаккатып, таңнар калам: концертсәхнә тирәсендә әле беренче, ышанычсыз адымнарын гына ясаучы япь-яшь җилкенчәк егет өчен нинди зур дәрәҗә, нинди зур тәҗрибә булган бит бу! Бөек Әлфия Авзалова концертлары бит бу! Ышанычсыз, дигәннән, Әлфия апа тарафыннан миңа бик зур ышаныч та булган икән бит – бик зур рәхмәт аңа!

Әлфия апа белән эшләү шулкадәр рәхәт, күңелле иде. Татар халкы аны шашып ярата, концертларына агылып йөри, кайбер авылларда көненә 2-3шәр концерт бирәбез. Тик бу җәһәттән бер чыгарма булды: бер авылга барсак, анда безне беркем көтмәгән, клубта йозак эленеп тора, билетлар сатылмау түгел, хәтта бернинди афиша да күренми, клуб мөдирен дә табып булмый. (Бүгенгедәй мобиль телефоннар, элемтә чаралары юк иде бит әле). Шул чакта кайбер артистлар миңа бик нык ташланды: «Менә оештыра алмагансың, концертны яндырдың, әйдә, безгә «неустойка» түлә», – диләр. Мин бик уңайсыз хәлдә калдым. (Студент кына, бала гына бит әле.) Әмма минем хәлне бик тиз сизеп алган Әлфия апа мине яклау чарасын тапты: «Бер дә борчылма, энекәш, – ди. – Бик әйбәт булды әле бүген концертның булмавы. Югыйсә, бик арылган иде, ичмасам, бер көн ял булыр». Әлфия апа үзе шулай әйткәч, теге артистлар да тынып калды. Кайбер кешеләр бүген: «Авзалова бик гади иде», – диләр. Булыр сиңа Авзалова гади! Тәжрибәле психолог кына түгел, бик оста дипломат, акыллы сәясәтче дә иде ул. Менә шул көнне мине үземне генә читкәрәк алып китте дә, болай ди: «Энекәш, син бит инде безнең начальник. Чыннан да, матур булмады бу. Син хәзер колхоз рәисенә бар, хәлне аңлат, Авзалованы урамда калдырмаслар», – ди.

Нәкъ шулай булды да. Колхоз рәисен эзләп таптым, хәлне аңлаттым, ул бик уңайсызланды. Ә үзе татар сәнгатен, Әлфия апаны бик хөрмәт итүче

кеше булып чыкты. Тиз арада безне кундыру, ашату-эчертү мәсьәләләрен хәл итте, ә икенче көнне, көндез колхоз исәбенә, гарантиягә концертыбызны да оештырды. Без барыбыз да канәгать калдык. Соңыннан Әлфия апа, очрашкан саен, гел шаярта иде: «Ну теге көнне ял шәп булды бит, энекәш», – дип.

Әнә шундый кешелекле дә, акыллы хәйләкәр дә иде Әлфия апа! Күпне күргән, күпне кичергән шул. Әлфия апа белән эшләгән көннәремне мин бүген дә бик сагынып, горурланып искә алам, зур тормыш мәктәбе буларак кабул итәм.

Соңыннан да Әлфия апа белән күп тапкырлар аралаштык. Баһапов фестивале концертларында да ул бик теләп, яратып катнашты. Казанда гына түгел, Уфа, Түбән Новгород, Ульяновск, Ижау һәм башка шәһәрләрдә дә бергә булдык.

Безнең фестиваль составы зур. Әмма Илһам абый белән Әлфия апага аерым игътибар, аерым хөрмәт иде. Әйтик, алар уртак автобуска утырмый. Илһам абый мәрхүм Рөстәм Вәлиев машинасында йөрергә ярата, ә Әлфия апа – минекендә. Ул юл буе Әлфия апа сөйләгән хәлләр, мәзәкләр хәзер дә хәтердә. Бик шук телле, юморга бик хирыс иде бит ул. Әлфия апа сөйли, ә безнең шофер (яшь егет Алмаз иде) түзә алмыйча, эчен тотып көлә. Бервакыт хәтта көлүеннән машинаны йөртә алмас дәрәҗәгә җитте. Машинаны туктатып, урамга чыгып көләргә мәҗбүр булды. Аның каравы, көлә-көлә зур юл сизелми дә, үтә дә китә. Әлбәттә, юл буе көлешеп кенә үтми, Әлфия апа белән җитди темалар турында да сөйләшәбез. Татар сәнгате, татар җыры, җырчылар турында һәм, әлбәттә, Рәшит Баһапов турында. Рәшит Баһаповны Әлфия апа аерым бер хөрмәт, ихтирам белән искә ала иде.

Чөнки Әлфия Авзалова язмышында да бу шәхеснең роле бик зур. Әйтик,



балачактан Әлфия апа Баһапов җырларын радиодан хозурланып тыңлый. Ә бер елны Рәшит Баһапов Актанышка концерт белән килгәч, авыл укытучылары, клуб җитәкчеләре аңа Әлфия Авзалованы тыңлаталар. Легендар артист яшь җырчыны игътибар белән тыңлый, аның табигый моңына югары бәя бирә, мактап, канатландырып җибәрә. Ә инде Актанышка икенче килүендә Рәшит Баһапов Әлфия Авзалованы үзе эзләп таба, аңа катгый рәвештә Казанга, профессиональ сәхнәгә килергә киңәш итә. Казанга килгәч тә Баһапов яшь җырчыны игътибарыннан ташламый. Әйтик, Җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Зөләйха Әхмәтова белән дә аны Баһапов таныштыра. Алай гына да түгел, беренче зур гастрольләргә дә Әлфия Авзалованы Рәшит Баһапов алып чыга. Бу җәһәттән архивта сакланган бер документ игътибарга лаек. Ул – филармония директоры М.Ф. Боголюбов приказы. 1954/55 елларга гастрольләр турында. Әлеге приказдан күренгәнчә, Рәшит Баһапов бригадасына нәфис сүз остасы Әзәл Яһудин, биюче Зәйтүнә Фәтхуллова, баянчы Гали Җәмлиханов һәм җырчы Әлфия Авзалова кергән. Әлеге приказдан күренгәнчә, бер концерт өчен Рәшит Баһаповка 225 сум түләнсә, Әлфия Авзаловага исә – 50 сум. Бу бригадага түбәндәге маршрут билгеләнә: Ульяновск, Сызрань, Куйбышев, Чкалов, Актүбә, Уральск, Саратов, Сталинград, Астрахань, Грозный, Джаздзикау, Махачкала, Баку, Ростов һәм Украинаның Ворошиловград, Днепропетровск, Сталин өлкәләре. Димәк, профессиональ сәхнәдә беренче зур чирканчыкны да Әлфия Авзалова Рәшит Баһапов канаты астында ала. Әлфия Авзалова үзе дә бөек остазының якты истәлеген күңелендә кадерләп саклады, инде алда әйтелгәнчә, Баһапов исеме белән бәйле чараларда бик теләп катнашты.

...Әледән-әле Әлфия апа турында, аның белән үткән концертлар, ул биргән тормыш сабаклары, ягъни сәхнә серләре турында уйланам. Бер генә мисал. Концерт бара. Әлфия Авзалова җырлый. Җыр тәмам. Халык котырынып, шашынып кул чаба. Шул вакытта мин сәхнәгә килеп чыгам да, «Әлфия Авзалова!» – дип кычкырам. Янәсе, Әлфия апаны күтәрергә, матуррак күрсәтергә тырышам. Әлфия апа, минем бу «тырышлыкларыма» берничә көн түзеп торды да, мине сүгеп атты: «Син нәрсә, энекәш, киләсең дә чыгып басасың сәхнәгә, Гитлер кебек, киләсең дә чыгып басасың. Күрмисеңмени, халык, Әлфия апаң, дип котыра, Әлфия апаңа ничек кул чаба?! Ә син миңа шул алкышларда коенырга ирек бирмисең! Алып баручы бик сак булырга, сәхнәгә кирәк вакытта гына, кирәк җирдә генә чыгарга тиеш». Әлфия апаның бу сүзләре күңелемә гомергә уелды.

Иманым камил: Әлфия Авзалованың тормыш юлы, иҗади мирасы бүгенге яшьләр өчен профессиональ осталык буенча махсус дәреслек, өстәл китабы булырга тиеш.

Роза АВЗАЛОВА-САФИУЛЛИНА,
Әлфия Авзалованың бертуган сеңлесе
Флүрәнең кызы

Әниемдәй якын, кадерле кешем

Әлфия апа – минем өчен әниемдәй якын, кадерле кеше. Ул, әниебез үлгәч, без – алты бала өчен җанын бирердәй булып, тырышып безне үстергән, башлы-күзле, йорт-җирле иткән кеше. Мин әнием үлгәндә әле бик кечкенә булганмын, әниемне җирләгәннәрен бөтенләй хәтерләмим. Ә менә 4 нче сыйныфта, балалар йортында тәрбияләнгәндә Әлфия апаның безнең янга бик еш концертлар белән килгәнен, безнең барыбызга да тәмле-тәмле күчтәнәчләр төяп килгәне бүгенгедәй хәтеремдә. Ул мине бик еш үзләренә кунакка алып кайтып китә иде, мин озаклап аларда яшәдем, әзрәк үсә төшкәч, ул мине үзе белән гастрольләргә алып йөри башлады. Миңа аның белән гастрольләргә чыгу зур бәйрәм иде. Моңа бәйле күп кызыклы вакыйгалар истә калган.

Автобусыбыз юлсыз урыннарда батып калып, аны тракторлар белән тарттырып чыгарулар, кечкенә авыл клубларында мине билет тикшереп то-



Зөлфия апам, басып торучысы – мин үзем һәм кызы Иделия белән Гүзәл апам. 1983 ел

рырга куюлар, мине санламыйча, олы абыйларның концертка билетсыз кереп китүләре хәзер кызык булып тоелса да, ул чакта күңелне киткән иде, әлбәттә. Ул һәрвакыт миңа ышаныч белән карады. Син, кызым, үҗәт, бик тырыш, тормышта югалып калмассың, Алла боерса, ди торган иде ул, мине кочагына кысып. Хәзер уйлыйм да, нинди олы йөрәкле ана булган Әлфия апабыз. Ул бит ялгыз үстергән ике баласы янына безне дә сыйдырды, беркайчан да ташламады. Әниебез үлгәч, кайгы-хәсрәттән хәтта аның тавышы бетә. Ә ул шуннан соң да үзендә көч табып, кабат сафка баскан, яраткан эшенә – халыкка хезмәт итүгә алынган. Без – алты ятимәгә мәхәббәтен тигез итеп бүлгән Әлфия апабызга нинди генә рәхмәтләр әйтсәк тә аз. Сеңлем Света кияүгә чыгып бәбәй табарга йөргәндә, ул аны фатирлы итү өчен нинди генә түрәләрнең ишеген шакымады. Нәтиҗәдә, аны бер бүлмәле фатирлы итте. Мин кияүгә чыкканда да, миңа бөтен бирнәләрне әзерләп, зурлап олы тормыш юлына озатты. Әле бүген дә диваныбызда ул бүләк иткән, күз явын алырлык бәйләгән кызыл япма – аның төсе, истәлеге булып тора. Ул безгә һәрвакыт, кызым, улым, дип дәште. Минем аларда аерым үз шкафым бар иде. Мин килгәндә һәрвакыт анда яңа өс киеме, яки яңа аяк киеме торыр иде. Кайда барса да, кызларына алган киемне безгә дә алды. Без аның кызлары белән бер төрле пәлтә, күлмәк, итек, түфли, башлык киеп, әннәкебез пешергән тәмле ризыкларны ашап үстек. Без киләсе көнне өстәл – затлы кунакларга әзерләнгән табын төсле, яңа пешкән пироглар, тәмле әйберләр белән тулы булыр иде. Хәзер уйлыйм-уйлыйм да: «Әлфия апа булмаса, безнең балачак нинди булыр иде?» – дим. Безгә ятимлек ачысы күрсәтмәде ул, үзе дә ятимә булып үскәнгә, шулкадәр тырыштымы икән?! Юк, аның күңеле шундый, алтын йөрәкле иде ул Әлфия апабыз!

Гаиләле булгач та, еш кунакка йөрештек, араларны беркайчан да суытмадык. Бергә-бергә пилмәннәр ясый торган идек. Әнә, балалар, мин сохари ясадым, пилмән ашын яңа икмәк белән ашамагыз, ашказаныгызны бозарсыз, сохари белән ашагыз, ди торган иде ул безгә. Ул һәрвакыт шулай безнең сәламәтлегебез турында кайгыртты. Тормышка чыккач миңа яшәве бик җиңел булды, чөнки Әлфия апа мине вак итеп токмач кисәргә дә, камыр куярга да, ашарга пешерергә, кер юарга да өйрәтте. Әлфия апаның фани дөньядан киткән соңгы минутларында да мин янәшәсендә идем. Соңгы төнендә Әлфия апа бөтенләй йоклый алмады, бик тә борсаланды, нидер әйтәсе килде, әмма, ни кызганыч, бер сүзе дә аңлашылмады. Хәле авырайгач, без аны балалары белән шулай чиратлашып карадык. Иртән иртүк бөтен балалары, оныклары килеп җитте. Ярдәм итәргә теләп ары-бире чабышсак та, явыз әҗәл каршында без дә, табиблар да көчсез идек. Бик тә авыр булды миңа бу мизгелдә. Мин бу дөньяда кабат әнисез, ятим калдым...

Розалия ЗӘКИЕВА,
нәфис сүз остасы



Бәгърем...

Ай кебек калкыды,
кояш кебек балкыды.
(Татар халык әйтеме)

Күптән инде, күптән....

Кичке көзге урамнарны гармуннар белән яңгыратып, шау-гөр килеп, әнкәй белән әткәй туганнарны, дусларын ияртеп, җырлашып кайтып керделәр. Кайдан? Әлфия Авзалова концертыннан. Әнкәй кабат-кабат, шатлыгын яшерми, концерттан соң сәхнә артына кереп Әлфия апа белән танышканын, үзенең дә Актаныштан икәнлеген әйткәнне сөйли. Әлфия апа шунда, көлеп: «Бәгърем, ничек килеп чыктың монда?» – дип сораган. Әйе, Актаныш кайда да, Буа кайда?

Алар яшь иде...

Алар инде бу дөньяда юк. Тик ул кичне табыннар корып, түгәрәк өстәл янында уен-көлке белән концерттан алган тәэсирләре белән җырлашып, күңел ачып, Әлфия апа җырларын җырлап утырганнары һаман да истә... Берәр заман, балачакта тыңлап үскән, яраткан җырчым Әлфия апаның концертларын алып барырмын дип, кем уйлаган?! Миңа Әлфия апа белән бер сәхнәдә эшләү бәхете насыйп булды. Халкымның сәнгать тарихына исемнәре алтын хәрефләр белән язылган Әлфия Авзалова, Габдулла Рәхимкулов, Вафирә Гыйззәтуллина, Зиннур Нурмөхәммәтов, Рафаэль Ильясов кебек мәшһүр җырчыларыбыз белән бергә иҗат итүемә бәхетлемен!

Әлфия апа барысыннан да үзгә шәхес иде. Ул мәхәббәтле иде, ул якты, сөйкемле иде, ул «бәгърем» диеп елмаеп дәшә иде. Әнә шул бәгъреннән чыккан җырларын тыңлаучының бәгъренә тия, моңнары күңелләрнең бар кылларын чиртә иде. Ул ярата, гашыйк була белә иде! Аңа табынучылар күп булды! Яратуын ул яшермәде. Гашыйк булу хисе аңа искиткеч күңел күтәренкелеге, дулкынлану, бетмәс-төкәнмәс сихри көч бирә иде. Шулай яңа җырлар туды. Һәр җыр – энҗе бөртеге. Хәтерлисезме: аның, микрофон тотып, ничек матур, затлы күлмәкләрдән, башын аз гына янга ташлап сәхнәгә чыгу мизгелен? Килеш-килбәте, елмаюы, нәзакәтле кыланмышы – ул Ходай биргән хатын-кыз асылын ача белә иде. Әгәр Әлфия Авзалова, иманым камил, Голливуд актрисасы булса, ул, һичшиксез, «Икона стиля», «Мәхәббәт эталоны» булыр иде! Ул җырларында да, мәхәббәттә дә, балаларында да иксез-чиксез иде! Минем хәтеремдә ул «бәгырь» булып саклана..

Рөстәм МАЛИКОВ,
җырчы, музыкант, Татарстанның халык, Башкортстанның атказанган артисты



Мин, Әлфия апа белән Илһам абый җырларын тыңлап үстем. Аларның җаннарны әсир итәр моңнары минем өчен ниндидер бер могҗиза иде. Тора-бара үзем дә җыр сәнгатенә кереп киттем. Уфа филармониясеннән кайткач, Казан филармониясендә үз бригадамны төзергә рәхсәт алдым. Әмма 1990 елгы, үзгәртеп кору чорында халык концертларга йөрми башлагач, бригадамны таркатырга мәҗбүр булдым, шуннан соң мине танылган җырчы Әлфия Авзалова үз бригадасына алды. Мин җыр сайлауга бик таләпчән, кайбер җырчылар репертуарындагы җырларны еш кына ошатмыйм, күңел кабул итми. Әлфия Авзалова төркеменә килгәч, миңа ошамый торган җырларны Әлфия апа башкаруында тыңлап шаккаттым. Шул чакта үзем өчен, хикмәт җырда түгел, ә башкаручыда икән, дигән ачыш ясадым. Миңа Әлфия апа көчле рухлы булуы, тормышны яратуы белән ошый иде. Әйтүемчә, 1990 еллар, кибеттә бернәрсә юк. Ә без концерт куеп кайтканда гаиләләребезне туендырырга капчык-капчык азык-төлек: ит, ярма, шикәр комы һ.б алып кайтабыз. Бервакыт мин кызык өчен, юри генә, Зәйтүнә Яруллина автобустан төшкәндә, ул алып кайткан ризыкларның исәбен чутладым: бер кешегә – 16 тартма ризык! Авыл җирлекләрендә концерт куеп йөрүләр – үзе бер онытылмас хатирә. Әлфия апаны хөрмәтләү йөзеннән, күп колхоз рәисләре безнең өчен махсус мал чалдыра. Итне чабып, өлешләргә бүлеп куялар да, берәү артка борылып, бу кисәкнең кемгә икәнлеген атый. Менә шундый гадел, кешелекле, киң күңелле иде ул безнең Әлфия апабыз. Шуңа күрәдер, Әлфия апа бригадасыннан бер генә артистның да китәсе килмәде. Безнең төркемдә һәрвакыт дуслык, татулык, бердәмлек хөкем сөрде.

Истә калырлык кызык вакыйгалар бик күп булды инде. Бервакыт Әлмәттән кайтыр юлга кузгалдык, без төялгән автобусны ниндидер бер кәттә машина куып тотты да, ике ир-ат исерткеч эчемлекләр тутырылган ике тартманы кертеп, «Сезгә күчтәнәч», – дип, Әлфия апа янәшәсенә куйды. Кайтып җитүгә, Әлфия апабыз шул шешәләрне тигез итеп барыбызга бүлеп бирмәсенме?! Шунда аның юмартлыгына исебез китеп: «Без булсак, бүлеп

тормас идек», – диеп көлештек. Бер шешә бирмәсә дә, үпкәләми идек. Ул бит, югыйсә, аңа аталып бирелгән күчтәнәч.

Әлфия апа белән эшләп йөргән еллар күңелле, рәхәт вакыйгаларга бай булды. Бервакыт Актанышка барып 22 бәлеш ашап кайттык, көн саен – ике бәлеш! Күп кеше очын-очка ялгый алмаган заманнарда телне йотарлык тәмле бәлешләр генә аша әле син бөтен бригадаң белән! Бу нәрсәне аңлата соң?... Әлбәттә инде, Актаныш ягы үз газиз баласын, моңлы сандугачкаен шулай ныклы яратканын аңлата!

Күп җирләрдә йөрдек, концертлар планын үтәп кенә калмыйча, хәтта арттырып үти торган идек. Кайда барсак та, кибеткә йөгерәбез, кем нәрсә ала. Берсендә баянчы Равил Закиров бер тартма тимер кыстыру җайланмасы (плоскогубцы) алды. Аны ничек күтәргәндер, ул авыр тартманы күтәреп ничекләр кайтып җиткәндер?.. Болар барысы да рәхәт тормыштан түгел, вакытына карап, без дә алыпсатарларга әверелдек, ничек булса да тормышны алып барыр өчен тырыштык.

Әлфия Авзалованың ижатына килгәндә, ул һәрбер җырның үз образын тудыра белә иде, аның һәрбер җыры – бер тамаша, спектакль! Бүгенге җырчылар арасында да аңа охшатып җырларга теләүчеләр күп, әмма Әлфия апага талант күктән дә иңгән, тормыш тәжрибәсе белән дә алган, ул җырның сулышын тоя. Укып, үз өстендә эшләп, яши-яши җырны җаны белән тоемлаучы җырчылар да байтак кына, әмма Әлфия апа кебеген табу мөмкин түгел, андыйлар йөз генә түгел, мең елга бер генә туа! Хәзерге тамашачылар белән элеккеге тамашачыларны да чагыштырып булмый. Бер сүзне кабатлап торган эчтәлексез җырларны да тамашачы бүген алкышларга күмә. Бу бер көнлек җырларны халыкның яратуы күңелгә шом сала. Җыр өлкәсендә Әлфия апабыз, чыннан да, халык күңелен яулаган бөек җырчы! Күңелгә Әлфия апаның моңнары, Илһам абыйның җырлары тансык. Алар икесе дә – кабатланмас талант ияләре! Ә без – шул бөек җырчыларны тыңлап үскән бәхетле буын. Әле бүгенгедәй исемдә: минем кечкенә вакыт, Әлфия апа безнең авылга концерт куярга килде. Өстендә шундый матур, кыска итәкле, караңгы кызыл төстәге күлмәк, ике кулына чәчәктәй итеп киендергән ике кызын җитәкләгән. Әлфия апа дигәч, гел күз алдыма ул шушы халәттә килеп баса. Әйе, ялгыз канат ике кыз бала үстергән, моңнарында бөтен татар халкын тәрбияләгән бу олуг затка баш имичә нәрсә эшлисең?.. Бу юлны, ул узган юлларны үтәр өчен тимер аяклы, ат йөрәкле, галәмнең үзе кебек киң күңелле булу кирәк! Әлфия апа татар хатын-кызларының өлгесе, сабырлык күрке, моң дәрьясы! Урының оҗмахта булсын, бик тә сагынабыз сине, Әлфия апа! Синең якты истәлегең безнең күңелләрдән мәңге китмәс! Син үзеңнең матур җырларыңда, үлмәс моңнарыңда яшәрсең!

Рузалия МОСТАФИНА,
Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты, Татарстанның атказанган артисты



Әлфия апа, гадәттә, гастрольләргә чыкканда, кунакханәдә үзе генә яши иде. Мине ни өчендер үз итте. Икебез бер бүлмәдә урнаша идек. «Җаныкаем, матурым» дип дәшкәне әле дә колагымда яңгырап тора. Автобуста да алгы, яхшы урыннарда гына утырта, егетләрне арткарак җибәрә иде. Элек, асфальт юллар булмаганда, язын-көзен пычрак ерып йөргән чакларда, кечкенә авылларны да читләтеп үтми идек. Халык шуның өчен, и безнең бәләкәй авылга да килеп җиттегез бит, дип рәхмәт укыды.

Шулай бервакыт концертка соңга кала яздык. Караңгы төште. Елга аша салынган кечкенә генә күпер аша чыгасы бар. Әлфия апа автобус тәрәзәсеннән әллә кайдан гына табылган фонарь белән тәгәрмәч эзләрен яктыртып, көч-хәл белән күперне чыктык. Тәки соңга калмадык, өлгердек. Халык көтә бит: ничек борчылмыйсың?!

Бер тапкыр яңа кунакханәгә урнаштырдылар. Юлдан килгәч, арылган. Юынып, коенып аласы килә. Әлфия апа тиз генә киемнәрен алыштырды да: «Без сине аста көтәбез», – дип, кызы Зөлфияне җитәкләп чыгып китте. Эссе җәй вакыты бу. Безнең исәп: тиз генә коенып, су кереп кайту. Киемнәремне алыштырып аска төшсәм, кунакханә хезмәткәрләре тезелеп диярлек баскан. Болар мине Әлфия апа дип көтә икән. Мин әйтәм: «Әле ул берничә минут кына элек, баласын җитәкләп, чыгып китте; мин Әлфия Авзалова түгел!» Пляж башмагын, кызының панамасын кигәнгә, гади генә күренгәнгә, болар бөек җырчыбызны танымый, абайламый калган икән. «Без аңа Әлфия дип дәшкән идек, ул арттарак калды, хәзер чыга!» – дип әйтте ич, диләр. Ул бик шаян иде, шуңа күрә, бергәләп сәфәр чыгулар бик җиңел булды. Дөрес, музыкантларга таләпчән иде. Тәртип таләп итмәсәң, тугарылып китүләре дә бар! Үз чиратында, музыкантлар: «Әлфия апа!» – дип үлеп торды. Юлда төрле хәлләр килеп чыга, авариягә дә очрадык. Коллектив җитәкчесе булгач, иртән, юлга чыкканчы, бөтенесен ашатырга, эчертергә кирәк. Кичен, килеп җиткәч, урнашу, туклану мәсьәләсен хәл итәсе бар... Әлфия апа шуларның барысын үзенчә, гади генә ерып чыга иде.

Фердинанд СӘЛАХОВ,
җырчы, Татарстанның халык артисты



Чабаталы сандугач

«Актаныш таңнары, ул минем йөрәк серемне аңлармы», – диеп җырлады туган ягы турында татар җырының чын легендасы Әлфия Авзалова. Чынлап та, бу җырчының үз серләренә, аның югары сәнгать олимпына менә алу серләренә ничек төшенергә?! Күп миллионлы татар халкы йөрәгенә иң кадерле зат булып кереп урнаша һәм шунда алтмыш елдан артык сакланып калу серләренә ничек төшенергә?! Әлфия Авзалова иҗатын, шәхесен, Ходайның татар халкына бүләге итеп кабул итәргәме, дөньяда мондый тавышларның сирәк тууына ишарәләргәме, әллә милләт үзе җырчыны үстергәнме? Сораулар, серле сораулар күп. Шуларны аңлар өчен, әлеге серле йомгакны сүтеп карыйк мәллә?..

– Мине ятимлек моңлы итте, – дия иде Әлфия апа. Ни кызганыч, ятимнәр күп бит дөньяда, әмма алар бары да моңлымы соң? Ятимлек ачысы үзәгенә үткәнгә, соңгы көнгә кадәр ятим үскәнлеге турында әйтә килде. Йөрәгендә төзәлмәс яра калдырган бәхетсез балачагы турында мәзәкләп сөйләргә дә көч таба алган Әлфия апа тормышта җылак ханым булмады. Шулай да мин, утыз елдан артык бергә сәхнәдә эшләү елларында, аның бер генә тапкыр күз яшьләрен күрдем, нибары бер. Китап сөючеләр белән очрашуда. Әлфия апа китап сөючеләргә үзе турында сөйли: «Хәерчелек инде, юклык, әти-әни юк, Җыракай (әнисенең апасын «Җыракай» дия иде) төрмәдә, мәктәпкә озатучы юк, минем аякта ике төрле чабата, берсе – утыз җиделе, берсе – кырык икеле». Һәм җырчыбыз сүзен дәвам итә алмады, күз яшен сөртте. Аякта чабата, әмма җаны тулы алтыннардан, иң зиннәтле асылташлардан кыйммәт, адәмнәр аңын актарырлык моңлы аваз – җыр катламнары. Мин шунда Әлфия апаның ни өчен үзе турында «чабаталы сандугач» диеп шаяртырга яратканын аңладым. Сәхнәләрдә, тамашачылар булсын, я берәр котлап сүз әйтүче: «Әлфия – безнең сандугачыбыз, җыр чишмәбез» һ.б. диеп тезгәндә, «Ие, чабаталы сандугач», – диеп, әкрен генә пышылдап, үзеннән-үзе көлеп, безне – хезмәттәшләрен көлдереп торыр иде. Бу язмамны да шуңа күрә «Чабаталы сандугач» диеп атадым. Гаҗәпләнмәгез: бу кимсетү түгел, һич тә юк. Әлфия апаның үз авызыннан чыккан гыйбарә. Хәер, апабыз сәхнәдә дә, тормышта да гыйбарәләрнең теләсә ниндиен төзи ала иде. Бусы турында, бәлки, еллар

узгач, аерым бер китап та туар әле. Аның һәрбер җөмләсе – анекдот, афоризм, мәзәк, спектакль иде.

Ни өчен бөек җырчы Әлфия Авзалова алтмыш елдан артык сәхнәдә тамашачы каршына бик тансык сәнгатькәр булып чыга алды? Иң төп сер – тавышының тембрыдыр, минемчә. Тембр – тавышның төп нигезе, төсләр байлыгы, гүзәллеге, колачы, иң әсир итәр көче. Мондый тембрлы тавыш татарда бүтән юк. Бик югары ноталар белән җырлый алучылар – моңлылар, йөрәкне учларына куеп җырлый белүчеләр, вокал осталыклары камил булганнары бар, әмма Авзалова тембрына тиңдәшләр юк. Юк, тумаган! Табигать әлегә мондый тавышны бирмәгән. Авзалова тавышын бернинди музыка коралы тавышы, чишмәләр, кошлар җыры белән дә чагыштырып булмый. Бу илаһи, галәми, күләмсез, бернинди үлчәүләргә сыймаган, алтын җепләр белән нәкышланган, бизәк тавыш. Теләсә нинди җырны йөрәгенә төреп, моңга манып, җан көчен салып, аңа гына хас дәрт кертеп тыңлаучысы күңеленә изге орлык итеп сала белү серләрен ул үзе генә белә иде. Без моны берничек тә сер итеп кабул итмибез, бары Әлфия Авзалова җыры итеп кенә тыңлый беләбез. Аны тыңлаган саен, тыңлыйсы гына килә. Чөнки ардырмый, ялыктырмый, дәвалый торган шифалы, алга, яктыга чакыра торган кабатланмас бай тавыш.

Аның иҗат биографиясе Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамблендә унсигез яшьлек кыз бала буларак башланып китә. Бернинди музыкаль белемсез, махсус әзерлексез унсигез яшьлек баланың кәсеби сәхнәгә менүе үзе бер гаҗәп. Әлбәттә, талантын, тавышының сирәклеген күрә белүчеләргә рәхмәт белдерәсе килә. Ансамбльдә эшләгән елларында музыка училищесына кереп сигез ай белем ала, тавышын югалта язып, училищедан китеп бара. Тавышы терелеп, яңадан ансамбльгә кушылып җырлый башлый. Үз өстендә эшли, вокал дәресләре ала, нота өйрәнә. Аңа вокал серләренә төшенергә ул елларда гы ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Волкова Рәйсә Кәрим кызы ярдәм итә. Авзалова репертуарында булган бөтендөнья фонотекасын баетырлык югарылыкта торган әсәрләре Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләү елларында туган. С.Габәшинең «Кәккүге» – үзе бер сәнгать әсәре, симфония, роман. Киләчәк буын җырчылары өчен уку әсбабы, үрнәк булып торырдай бу язма, Ходайга шөкер, бик еш булмаса да, ишетелеп куя.

Әлфия Авзалованың репертуар байлыгы үзе аерым сүз сорый. Чөнки әле татар дөньясында бер концерт эченә унҗиде милләт җырын сыйдырып җырлаган җырчы юк. Ул – бердәнбер. Мәскәүдә Ирма Яунземда да вокал дәресләре алган бит әле җырчыбыз. Рус, һинди, үзбәк, яһүд, гарәп һ.б. бик күп телләрне өйрәнеп, татар җырчысына милли бизәкләрен җуймый башкара белү аерым талант сорый. Бу таланты да бар иде. Төмәндә гастрольдә йөргәндә җирле җитәкчеләр берничә җырчы-солистны ресторанга чәйгә алып барды. Ресторанда төрле халык, төрле милләт, чит илләрдән дә кешеләр булганын

соңыннан белдек. Каян белдекме? Җырчылардан, һәрберебездән берәр җыр башкаруны сорадылар. Әлбәттә, сорау канәгатьләндерелде (җырламый кара, партия заманы, кире кагу партиягә каршы бару булып чутлана торган чор). Авзалова Марк Бернес репертуарыннан «Журавли»ны җырлады. Ни булганын күрсәгез?! Бөтен ресторанның асты-өскә килде, алкышлар ява, һәрберсе үз өстәле янына чакыра. Әлфия апаны югославлар икенче катка күтәреп алып киттеләр. Бу җырны мин бик күп башкаруда ишеттем, әмма аны Авзалова дәрәҗәсендә Авзалова гына җырлый ала! Югославлы дуслар апабызны, төркемнәре белән, кабат урынына озата төштеләр. Әлфия апа, гадәттәгечә, безне көлдерә инде, без моны гел көтеп кенә йөрибез. «Сестра (без аңа «Сестра» дия идек, Илһам абый – «Абзый»), ни хәлләр булды икенче каттагы өстәлдә?» – дибез. «Бүләкләделәр», – ди, үзе көлә. Кызык бит: «Нәрсә соң бүләгең?». «Курчак бите сөртә торган сөлге бирделәр». Бу – Авзалова стиле, моны беркем әйтә дә, эшли дә белми. Бу Авзалова – үзе аяклы мәзәк. Чөнки бүләккә кулъяулык кадәр сөлге ише тукыма иде һәм өстәде. «Болар – САРАНскийлар», – диде. Эх, «Сестра», яраттык та инде сине, бөтен булмышың белән. Яраттык, әле дә яратабыз. Яратмый мөмкин дә түгел. Мәзәгең, җырың, моңың, гадилегең өчен генә түгел, кешелеклелегең өчен дә. Кешеләрне ярата белгән өчен дә хөрмәтләдек!

Бер мисал. Татар җыр сәнгатендә кырык елдан артык бер музыкант белән эшли алган җырчы – Әлфия Авзалова. Кәрим Габидуллин һәм аның җәмәгате Сания ханым вә ахирәте шагыйрә Гөлшат Зәйнашева белән биш дистәгә якын ел, бер гаилә булып, туганнар, иҗатташлар, дуслар, сердәшләр булып яшәделәр. Ул тугры кеше иде. Безнең бит, артист халкының диюем, холыкларыбыз бик җиңелләрдән түгел. Кичерә, аңлый, кабул итә белергә дә кирәк. Әлфия апа бу рольне дә бик оста, инсафлы, гадел булып башкарды. Үз иҗат төркемендә эшләгән һәрбер артистның язмышын, өс-башын, ризыгын кайгыртып, уртаклап бүлешә дә белә иде. «Миңа гына», – дигән нәфеслелек аңарда бөтенләй булмады. Юлда йөргәндә хәвефләргә, бәла-казаларга тарыганы да булды. Шулай да юл йөрүдән зарланмады. Сәхнә, юл, тамашачысыз яшәүне күз алдына да китермәде. Чын халык җырчысы, хезмәтчесе, хөрмәтлесе була белде. Боларны ул үз көче белән төзеде.

Әлфия Авзалованы соңгы юлга озатканда, Минтимер Шәрип улы Шәймиев һаман бер сүзне кабатлады: «Әлфиябез, безнең Әлфиябез!» Актаныш якташлыгы өчен генә түгел, гомумән, күп миллионлы татарның Әлфиясе булуына басым ясап, кайта-кайта, җылы ярату сүзләрен әрнеп, югалту ачысын тоеп хушлашты. Дәүләт күләмендә югары бәяләнгән мактаулы исемнәре, орден-медальләре хакында Минтимер агаебыз бер сүз дә әйтмәде. Иң югары исеме – Әлфия Авзалова икәнен җыелган халыкка җиткерде. Җырчының үз исем-фамилиясе бөтен дәүләт бүләкләрен күмеп киткәнен шәп аңлый Беренче Президентыбыз. Мондый югары бәягә һәр иҗатчыбыз менә ала микән? Юк-

тыр! Әлфия Авзалова югары титулын, авылдан – авылга, шәһәрдән – шәһәргә, илдән – илгә сәяхәтләп, фатирдан – фатирга күчеп яшәп, репертуар байлыгы, тырышлыгы, матур мәгънәдәге әрсезлеге белән, үзе булдырды.

Татар җыр сәнгате үсешендә дә Авзалованың үз сүзе, үз яңалыклары бар. Баян-гармуннарга кушылып җырлаган татар сәхнәсенә «Казан утлары» вокал-инструменталь ансамблен беренчеләрдән менгезүче дә әлеге бәләкәй генә, җыйнак гәүдәле Әлфия Авзалова булды. Заман өчен бу алдынгы, кыю адым булып тора. Сәнгатьтә башка баскычтан атлавын халык күтәреп алуына ышанырга кирәклеген дөрес аңлап хәрәкәт иткән җырчы. Моңа кадәр ишетелеп килгән композиторларыбызның, халкыбыз җырлары башка бер үрнәктә яшәп киткән чорның төп героинясы – Әлфия апа. Бүгенге күз белән караганда бик гади булып күренгән бу кыю алымнар, ул заман, партия чорында вак иләк аша шуып узарга да ярдәм иткән.

Авзалованың иҗат гомере гаҗәеп, кызыгырлык, горурланып искә алырлык озын һәм бәхетле була алды. Соңгы елларда аның иҗат гомерен игелекле, Әлфия апаның үзе бик хөрмәт иткән җырчысы Салават, озынайтыргадәвамларга күп көч куйды. Олуг шәхесебезне Салават, үз анасыдай тәрбияләп, кайгыртып, канат астына сыендырып, сәхнәдә яшәтте. Сырхаулаганда Әлфия апаны кирәк-ярагы белән тәэмин итеп торучысы да шул ук Салават булды. Без апабызның терелеп сәхнәгә чыгасын читтән карап көтеп кенә утырдык. Сырхау тигәч тә, Авзалова үз репертуарында, үзенчә, батырларча, җиңәм диеп, яши белде. Татар тамашачысы җырчы Әлфия Авзаловасын бүген дә догадан калдырмыйдыр. Чөнки ул һәрбер тамашачыга бәхет теләп, яратып аралашып, догада калып, сәхнәдә булды. Аның иң изге кылган догасы – галиҗәнаб татар җыры булды. Ул вафатыннан соң да бу дога халкы күңеленә Авзалова язмаларында гасырлар дәвамында укылыр әле. Бу дога Коръән аятьләреннән түгел, Әлфия апа җырларыннан, аның моңлы мәкаме – Авзалова сүзләре булыр.



Сер йомгагын сүтеп карадык. Әмма бер генә сер ята икән монда. Хәтта, сер дә түгел бугай әле. Гап-гади ике җөмлә җитә аңлаган башка. Әлфия Авзалова булып туарга, яшәргә, көрәшергә, иҗат итәргә, халкыңны сөяргә, яманлык кылмаска, кулыңнан килгәнчә кешеләргә ярдәм

итәргә, шәхес булып үсәргә генә кирәк икән. Шәхесләрне милләт үзе сайлап, сөеп, саклап, бәяләп үстерә. Бу – шиксез. Чабаталы ятим балачагын хатирә итеп саклап, сәхнә түрендә патшабикә булып, тормышта үз балаларын, ятим алты бала үстереп, җырлап, уйнап-мәзәкләп, кадер-хөрмәт күреп, милләтенә дан китергән, җырлардан һәйкәл салган шәхес – Актаныш кызы Әлфия Авзалова турында киләчәк буыннар гыйльми эшләр язарлар. Бу хезмәтләрне халкы сорар. Чөнки үзен, милләтен, ил-җирен, ватанын күкләр биеклегендә үстереп данлый белгән сәнгать бөркетләрен оныту зур гөнаһ булыр иде. Мондый бөтен бер зур милләтне яшәтә алган җырчылар бездә бер-ике генә. Алар күп була да алмый. Җыр сәнгате күгендә Әлфия Авзалова да берьялгызы, канатларын киң җәеп, иркен һава иңләде. Бу – табигый, бөркетләр төркем булып очмый.

Фердинанд ФӘТХИ,
җырчы, Татарстанның халык артисты



Әнием кырык ел Арча районының Иске-Ашыт авылы мәдәният йорты директоры булып эшләде, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Әнием мәдәният йортында эшләгәч, аны бөтен филармония һәм театр артистлары белә иде. Әнием белән Әлфия апа бик дус булды. Әлфия Авзалова концерты килә, дисәләр, әнием әбиемә кайтып әйтә иде. Әни өй идәннәрен юа, әби белән икесе Әлфия апаның килешенә өйне чиста-пөхтә итеп җыештыралар, матурлыйлар иде. Ул килгән көнне мунча ягып, тәмледән-тәмле ризыклар пешереп, Әлфия апаны көтә идек. Безнең йортта Әлфия апага зур ихтирам, кадер-хөрмәт булды.

Әлфия апа үзе дә безне бик яратты. Сезгә килсәм, туганнарыма кайткан кебек булам, дип әйтә торган иде. Әлфия апа әбиебезне бик якын итте. Әнием көндез клубта булганда, алар әби белән икесе самавырны гөжелдәтеп чәй эчә торганнар иде. Әлфия апа элек күргәннәрен, нинди авыр тормыш кичергәннәрен бәйнә-бәйнә сөйли. Көлешеп тә, елашып та алалар. Әбигә ул өйдә җырлап та күрсәтә. «Агъәби син, Галия апа!» – дип әйтә торган иде ул әбиемә.

Әлфия апа концерты бездә көндезге берләр турында һәм кичен була торган иде. Клуб эче халык белән шыгрым тула. Авыл халкы Әлфия апаны түземсезлек белән көтеп ала. Әлфия апа концертлары авыл халкы өчен зур бәйрәм була иде. Сәхнәгә чыкканда ук, Әлфия апа тамашачысы белән исәнләшә иде. Ха-

лык каршында матур итеп елмаеп, тамашачыны хөрмәтләп баш ия, тамашачы аны көчле алкышларга күмә. Әлфия апа концертларында тамашачыны көлдерә дә, елата да иде. Ул үзенең җырлары белән һәр тамашачының йөрәгенә үтеп керде. Авыл клублары агачтан, кышын бик җылы булмый. Утын белән ягылган вакытлар. Әни әле дә, Әлфия Авзалова сәхнәне сәхнә итә, тамашачысын хөрмәтли белде, ди. «Ул бер вакытта да, кайбер җырчылар кебек, салкын клубларда гамаж, яки җылы оектан чыкмады. Капрон оек белән түфлиен киеп чыга иде. Әлфия ул – татар халкының бәхетенә туган җырчы, талантлы җырчы», – дип әйтә әни. Ул бездән икенче авылга концерт куярга киткәч, өебез, урамнар – бөтен авыл бер мәлгә күңелсез кала иде. Чөнки һәр кешенең колагында, күңелендә – Әлфия апа җырлары.

Әлфия апа бервакыт шулай тагын безнең авылга концерт белән килде. Ул вакытта мин Казан дәүләт культура институтын тәмамлап кайткан идем. Концерты башланганчы, Әлфия апа мине җырлатып карады. «Энекәш, әйдәле, бер халык җырын җырлап күрсәт әле, Кирам, ал баяныңны», – диде. Әлбәттә, бу ике шәхес каршында мин азрак каушадым да. Шулай итеп мин «Озату» җырын җырладым. Әлфия апа бик дикъкать белән тыңлап утырды да, миңа болай диде: «Энекәш, тавышың матур, буең бар, чибәрлегең җитә, сиңа җырчы-артист булырга кирәк. Талантыңны күрсәт. Авыл клубында кайчан да эшләргә була. Син җырчы булырга тиеш. Авыл җирендә күп талантлар югалып кала. Синең киләчәгең бар. Исән булсак, Әлфия апа, рәхмәт сиңа, бик дөрес әйткәнсең икән диярсең», – диде.

Дөрестән дә, Әлфия апага нәкъ шул сүзләрне әйтү насыйп булды. 1990 елда Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшли башладым. Ансамбльнең сәнгать җитәкчесе – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Лима Кустабаева һәм хор җитәкчесе – Татарстанның халык артисты Венера Гәрәева, тавышымны тыңлап, сәнгать советы белән килештереп, мине эшкә алды. Дүрт ел ансамбльдә эшләдем. Ансамбль минем өчен зур сәнгать мәктәбе булды. Ә инде 1994 елда Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә күчтем. Ун ел филармониядә бригадам белән эшләдем. Татарстанның атказанган артисты исеменә лаек булдым.

Аннан соң «Казан» милли-мәдәни үзәге каршындагы Казан шәһәр филармониясенә эшкә килдем. Бүген дә шунда эшлим. Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исемгә лаек булдым. Әлфия апа филармониядә эшләгәндә, соңрак та миңа киңәшләрен биреп торды. Нәрсә булса да иң беренче аның белән фикерләшә идем. Рәхмәт аңа!

Мин – аның шәкерте. Әлфия апа: «Минем шәкертем, минем Фердинандтым син», – дип, күргән саен аркамнан сөя, елмая иде. Рәхмәт, Әлфия апага! Ул җырчы булырга тәкъдим ясамаган булса, бәлки, мин җырчы һөнәрен кыйблам, мәсләгем, яшәү рәвеше итмәс идем. Әлфия апаның шәкерте булуым белән чиксез горурланам!

Фәридә ТӨХФӘТУЛЛИНА-ВӘЛИӘХМӘТОВА,
тележурналист



Йөрәкләрне айкап җыр яңгырый. Әлфия апа моңы. «Сагынам, дуслар, илкәйне!» җыры. Аңа икенчесе ялгана – «Хәтфә», тагын берсе – монысы «Яратам, дисең син». Бу җырларның беренчесе тасмаларда яңгыраса, калганнары күңелдә үзеннән-үзе яңара. Әлфия апа моңы бит ул, татар моңы, татар җыры!

Әлфия апа исемен ишетүгә, җырларын тыңлый башлауга, аңа бәйле матур истәлекләр, язгы хәтфә үләндә яңа баш төрткән чәчкәләр сыман, хатирәләр дәфтәрен бизи. Шуларның берсе – «Татарстан-Яңа Гасыр» каналының иртәнге тапшырулар бүлегендә, «Хәерле иртә» тапшыруында хезмәт куйган чагыма бәйле.

Җитәкчелек бик матур, эчтәлекле видеоязма эшләргә кирәклеген җиткерде. Мин, әлбәттә, бик куанып алындым бу эшкә. Әңгәмә кору, съемкалар турында сөйләшү өчен, Әлфия апаның үзенә шалтыраттым. Ул мине фатирына чакырды. «Якшәмбе көн кулайрак булыр», – диде. Ял көннәрендә, әнисе янына ашкынучы авыл кызы буларак, иртә таңнан торып килергә тиеш булсам да, бик сөендем, мәшһүр җырчы белән күрешергә барам бит! Әле Әлфия апа белән әңгәмә яздырырга тиешлегемне белгәч, әнием Хажирә дә, әдәбият-сәнгать дөньясыннан хәбәрдар кеше буларак, аның концертларына йөрүен, яраткан җырларын тагын бер кат күңелендә яңартты. Мин дә (әле ул вакытта интернетның популярлаша башлаган вакыты гына), эфирлар өчен тупланган материаллар папкасын актарып, аңа бәйле истәлекләр, үзенең газета-журналларда басылган әңгәмәләрен барладым. Дулкынлануым да бар иде, билгеле. Ни дисәк тә, Әлфия апа белән аралашу – яшь журналист өчен зур мәртәбә дә, җаваплылык та.

Операторыбыз белән килешенгән вакытка Әлфия Авзалованың фатирына килеп тә җиттек. Иртәдән үк күшектереп сибәләп торган яңгыр, үтәли җил, җырчыбызның йорты бусагасыннан атлап керүгә, башка җиһанда калган сыман булды.

«Килеп җиттегезме, сеңлем, әйдүк! Мин бит әле җыенып та өлгермәгән. Сез урнаша торыгыз, чәйләп тә алырбыз, мин хәзер», – дип, безне кунак бүлмәсенә озатты. Төшерүче егетебез камерасын көйләгән арада, икенче

бүлмәдән: «Сеңлем, Фәридәкәй, яныма килче», – дип, мине чакырып алды. Бүлмәсенә килеп керсәм, Әлфия апа берсеннән-берсе матур күлмәкләрен караваты өстенә тезеп салган да, кайсын киергә белми аптырап тора. «Ничек уйлыйсың: моның кайсысы экранда яхшырак күренер икән, сез бит – яшьләр, әйбәтрәк беләсез. Бигрәк ныкдулкынланам, телевидениегә төшү ул – халкым белән очрашу бит, матур да күренәсе килә», – ди. Җыйнак гәүдәле, мөлаем, олпат җырчыбызның, әле хезмәт юлын күптән түгел генә башлаган журналист белән шулай гади, ачылып китеп сөйләшүе мине башта бик гажәпләндерде. «Даһилыкның сере – гадилектә», диләр. Мин аның шушы гадилегенә сокланууымны яшерә алмыйча, «Әлфия апа, сез бит «модный» ханым, мин әйткән генә килешерме, менә бу күлмәгегез, миңа калса, бик уңышлы», – дип, бәрхеттән тегелгән күлмәген тәкъдим иттем. Күлмәген җәһәт кенә киеп куйды да, чәч ясалышына канәгатьсезлек белдереп: «Сеңлем, кара әле, мондый чәч килешеп бетмәс», – дип, бөтенләй икенче төрле итеп тарый башлады. Мин дә ярдәмгә килдем. Бик җайлап кына прическа ясап, иннек-кершәннәрен яңартып алдым. Без кунак бүлмәсенә чыгып, матур гына әңгәмәне башладык. Балачак, ачлы-туклы үткән авыр еллар, Казан каласына килү турында... Шактый аралаштык. Төшерүче егетебез: «Кадрда бик матур күренәсез», – дигәч, мәзәк сөйләп, көлдереп тә алды Әлфия апабыз. Без аралашкан арада, дус хатыны чәй табыны әзерләп куйган иде. Фотоларны барлап, төшерү эшен тәмамлагач, бергәләп көлешә-көлешә, аның мәзәкләрен тыңлап чәй эчтек. Матур очрашу иде бу. Онытылмаслык очрашу. Йөрәккә уелган якты хатирә. Ул чакта күңелләргә Әлфия апа белән күрешүдән иягән яктылык урамнарга да таралды сыман. Күшектергеч яңгырын, үтәли җилен дә тоймадык. Сюжетны да бик тиз һәм ниндидер бер талпыну белән эшләгәнемне хәтерлим. Сөекле җырчыбызның гадиле, олпатлыгы, ачык күңелле булуының тәэсиредер. Әле бүген дә Әлфия апа исемен ишетүгә, шушы күрешү, аның тыз-быз килеп күлмәк сайлавы, чәч ясавыбыз, бизәнү, аралашу, чәй өстәле янында сөйләшү, җете күзләре әле кичә генә булган кебек хәтердә җанлана. Оптимистик рухлы сүзләре колакта яңгырый, сүзләргә җыр өстәлә – «Картаямыни соң йөрәк?..».

Фәрит ГОМӘРОВ,
«Алмаз» зәркән заводы
генераль директоры



2018 нче елның 21 нче октябрендә Әлфия Авзалова исемендәге I Халыкара фестиваль үткәрү тарихка кереп калды. Бу киң колачлы, грандиоз вакыйга зур уңыш белән узды. Чит илләрдән дә бик күп кунаклар килгән иде. Алар барысы да бөек татар җырчысының – безнең Әлфия апаның репертуарындагы җырларны башкарды. Әлеге зур чараны әзерләүгә өлеше кергән һәркемгә рәхмәтем, хөрмәтем зур! Мин, гомумән, үзебезнең телебез, милли легебез, гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз белән чиксез горурланам, сәнгатебезне, мәдәниятебезне үстерүгә күп көч куйган бөек шәхесләргә сокланам. Ә Әлфия апа белән Илһам абый ижатына табынып яшим. Бу фестиваль Әлфия апаны искә алу кичәсе генә түгел, ул – милләтебезнең, мәдәниятебезнең яшәешен, аның тирәнлеген, бөеклеген күрсәтүче чара. Күп илләргә телевидение-радио аша трансляцияләнгән әлеге вакыйганы миллионлаган тамашачы карап хозурлангандыр, дип уйлыйм. Бу эзлеклелек – Әлфия апа нигез салган җыр сәнгатенең тагын да биеккәрәк күтәрелүе, татар телен саклау, милләтебезне яшәтү, кыйблабызга туры бару ул.

Без бу дөньяга киләбез дә китәбез, беркемнең дә мәңге калганы юк. Безне тарих, үткәннәр яшәтә! «Үткәнен белмәгәннең – киләчәге юк!» – дигән мәкаль бик тә дөрес. Бөек рус язучысы Достоевский: «Дөньяда бер генә милләт тә ипи җитмәгәннән, ризык җитмәгәннән үлмәгән. Милләт – теле, гореф-гадәте, йолалары, мәдәнияте югалгач бетә!» – дигән. Әлфия апаның максаты, ижатының, яшәешенең, тырышлыгының төп мәгънәсе – җыр-моң аша телебезне, милләтебезне саклап калу иде. Без, үз чиратыбызда, хәзерге яшь буынга шушы дөрес юнәлешне күрсәтергә тиешбез. Еш кына концертларга баргач сөенеп кайтам: халык зал тутырып йөри, сәхнәгә моңлы яшьләр килә. Ижат бер урында тормый, аларның җыр-моңнары да бөтен милләт вәкилләре кызыксынып тыңларлык итеп яңача көйгә салына, җырларга яңа сулыш өрелә, «Үзгәреш җиле» аша татар җыр сәнгате алга бара. Шул ук вакытта яшьләр элеккеге татар моңнарын да онытмый, үз репертуарларына кертә, нәтиҗәдә, телебез, моңыбыз югалмый. Сәнгать кешеләре – милләтнең сакчылары алар. Моң эстафетасы югалмаса, телебез дә, милләтебез дә яшәр! Әлфия апаның хезмәтләрен, бөеклеген әле яши-яши өйрәнәсебез бар. Иң мөһиме: аны киләчәккә илтү, яшь буынга өйрәтү. Киләчәк – яшьләр кулында!

Фәрит ХАТЫЙПОВ,
музыкант, композитор,
Татарстанның халык артисты



Әлфия Авзалова – сәнгатебез күгендә балкыган, мәңге сүнмәс якты йолдыз, моң иясе, татар халкының йөзек кашы ул. Күпме буын җырчылары аннан үрнәк алып үстеләр.

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләгән чорда, миңа да Әлфия апага уйнарга, аның белән эшләргә насыйп булды. Сәхнәдә андый җырчыларга уйнап тору – үзе бер дәрәҗә; горурлык хисе уяна, моң дөньясына чумасың. Шуңадыр да минем иҗатымда моңлы җырлар күп. Әлфия апа да җырларымны яратып башкара иде. Әйтик, Фәнис Яруллин сүзләренә язылган «Сакладым сине күңелемдә»:

Кайгыларның барын оныттырып,
Юатасың тик син юатсаң.
Кемгә барып серем сөйләрмен мин,
Кемем калыр, сине югалтсам...

Татарстан радиосына барып яздырмакчы идек, сүзләре пессимистик дип, бу җырны үткәрмәделәр. Хәзер булса, үткән булыр иде. Әлфия Авзалова ул җырны барыбер сәхнәләрдә җырлап йөрде. «Бу дөньяда» җыры (Равил Фәйзуллин сүзләре) радио фондында саклана. Илдар Юзеев сүзләренә язылган «Озайт, Ходай, бераз гомеремне» дигәне Әлфия апаның радиога, телевидениегә язылган соңгы җыры булды. «Салават театры» Әлфия Авзалованы зурлап, концертларында катнаштыра башлагач, шул җырны башкара иде:

Аңлыйм да соң, җиргә бер кеше дә
Мәңге яшәр өчен тумаган.
Озайт, Ходай, бераз гомеремне,
Китәселәр килми дөньядан!

– Шушы җырга Уфада, Мәскәүдә басып торып алкышладылар, – дип сөйләгән иде Әлфия апа.

Бервакыт Уфадан, Башкортстанның халык артисты, җырчы Зәки Мәхмүтов, шалтыратып: «Әлфия Авзалова яңа җырыңны җырлады, халык бик ошатты, миңа да шул җырны җибәр әле», – диде. Җибәрдем, бер айдан Зәки Мәхмүтов якты дөньядан китеп барган. Бик кызганыч хәл, яхшы кеше, яхшы җырчы иде. Урыны оҗмахта булсын.

Әлфия апа төркеме белән Мамадыш, Чаллы якларына гастрольгә чыгып киттек. Казан белән Мамадыш арасындагы заправкага тукталдык. Безгә бензин дип, су салганнар (моны без соңыннан гына белдек, йә җир астындагы бакларына язгы су төшкән булгандыр?!.) Ярты юлда машина ватылды. Йөк машинасына тагып, Мамадыш тукталышындагы автосервиска алып килдек. Бишкә кадәр генә эшлибез, иртән карарбыз дип, бикләп китеп тә бардылар. Концертка өлгермәдек, халык көткәндер инде. Кунакханә бар икән, без шунда кундык. Иртән килеп автобусны карадылар, сүттеләр, тикшерделәр. Автобус төзек, диделәр. Ә автобус кабынмый. Бактагы суны агызып бензин салгач, кузгалып киттек.

Начар юлларда бату, яисә буран аркасында андый хәлләр булгалады. Әле дә истә: бер авылда төнге уникедә концертны башладык. Ерактан безнең автобусның батканын күргәннәр дә, барыбер киләләр дип, халык көтеп торган. Заманасы башка иде...

Әлфия Авзалова турында күп язарга була. Ул – бик тә кешелекле, мактауга, хөрмәткә лаеклы, бөек җырчы!

Хәйдәр САФИН,
музыкант,
Татарстанның атказанган
мәдәният хезмәткәре



1974 елда, күренекле баянчы Марс Макаров тәкъдиме белән, Әлфия Авзалованың концерт бригадасы составында җәйге гастрольләргә чыгу бәхете тәтеде. Бу минем өчен көтелмәгән бәхет иде.

Грампластинкаларын тыңлаганга, концертларын күргәнгә, аның репертуарын яхшы белә идем. Шунысы да куанычлы: гастрольләр туган ягымда – Апас, Буа, Тәтеш, Кама Тамагы районнарында узды. Бик куркып кына барсам да, имтиханны яхшы уздым шикелле. Чөнки укуымны тәмамлагач, Әлфия Авзалова мине үз бригадасына эшкә чакырды.

Без аның белән элекке Советлар Союзын аркылыдан буйга йөреп чыктык диярлек. Әлфия апаның иң сокландырганы: ул беркайчан да зарланмый иде.



Ятимлек ачысын татып үскәнгәме, ул безгә һәрдаим ярдәмчел булды. Өстәвенә, ул юморга бик бай иде. Магнитогорск каласында чәчәк бүләк иткәч, монда чәчәк үсәмени, дип сораган иде. Ә бервакыт бер генә роза чәчәге бүләк иткәч, каян белдегез минем ялгыз икәнемне, диде. Менә шундый җор телле, кече күңелле булып хәтеремдә калды ул.

Хәмдүнә
ТИМЕРГАЛИЕВА,
җырчы, Татарстанның
халык артисты



Әлфия апа Авзалова – гасыр җырчысы ул. Халкыбызның күңел көзгесе, Ходай аны җир йөзенә үз халкына илаһи, илһамлы зат итеп җибәргән. Сәнгатебездә ничә буын җырчылары аның җырлавында тәрбияләнде. Аның җырлары һәр кешенең күңеленә кадерле бер мөһер булып сеңгән. Мин Әлфия апаның җырларын табигатькә тиңлим.

Халык кемне ярата? Табигый, ихлас кешене. Әлфия апаның холкында масаючанлык, ясалмалылык, ялагайлык, ялганлау беркайчан да булмады. Мондый сыйфатлар аңа ят иде. Ул башкаларга гына түгел, үз-үзенә дә бик таләпчән булды. Туры сүзле һәм шул ук вакытта серле дә, җор күңелле, акыллы, кыскасы, бөек шәхес иде. Әлфия апа – халкыбызның батыр кызы, хатын-кыз буларак та, чын ана ул.

Сабый чагыннан тормышның ачысын-төчесен, ачлык-ялангачлыкны, сугыш еллары михнәтләрен күрсә дә, сынмаган, сыгылмаган Әлфия апабыз. Аның көчле ихтыярлы булуы – таң калырлык, уйларга сыймаслык.

Мин җырчы буларак аның җырларында тәрбияләндем, аның җырларын тыңлап үстем. Җырчы булып формалашуымда аның роле бик зур. Минем өчен үрелеп буй җитмәслек, олы шәхес белән бергә сәхнәдә эшләүне Ходай Тәгалә насыйп иткән. Әлфия апаны без сабый чактан шундый яхшы җырчы бар икән дип белә идек. Чөнки мин үскән Котлыяр авылы кечкенә, радио-телевизор юк иде. Аның янәшәсендә җырлап йөрермен дип кем уйлаган?! Шаккатырлык шәхес иде Әлфия апа. Ул бик күп кешеләргә тормыш маягы, яшәеш үрнәге булды. Көчле булып яшәр өчен менә кемнән үрнәк алырга кирәк. Сәнгатьтә чын йолдыз шундый буладыр! Халкыбызга шундый зат бүләк иткәне өчен язмышка рәхмәтле булыйк. Әлфия апага рәхмәтем, хөрмәтем чиксез. Урыны оҗмахта булсын иде.

Энгель ФӘТТАХОВ,
Актаныш муниципаль районы башлыгы

Мине үз улы кебек якын итте



Талантлы шәхесләр үлми, диләр. Хак икән. Әлфия апа күңелләребездә яшәвен дәвам итә. Мәдәнияте, сәнгате бренд дәрәҗәсе югарылыгына күтәрелгән туган ягында – Актанышта бигрәк тә. Без – аны, ул Актанышны яратты. Чиксез горурлана иде туган ягы белән. Елына бер тапкыр кайтып, аскы Актаныш урамнарын урап, данлыклы Актаныш басмаларыннан яңа төзелгән Актанышка күтәрелмичә калмый иде. Биеклектән Иске Идел, әрәмәлекләр, Аскы Актаныш уч төбендәге кебек күренә.

– Их, Актаныш бит ул, җырламас җиреңнән җырларсың, – дип, җыр да сузып җибәрә иде. Актаныштагы дуслары белән аралашып, күрешеп, яшьлек хатирәләрен яңартып, яшәреп, илһамланып китә иде. Рәхәт иде аның белән. Гади, ихлас, мактап та куя, кирәк икән, шелтәләп тә ала. Турысын да бәреп әйтә, аңа нишләсә дә килешә иде. Район башлыгы булып эшләгән елларымда аралар тагын да якынайды. Казанда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгында министр булып эшләгән елларымда да элемтәдә тордык. Әлфия апаның рухы алдында күңелем тыныч: соңгы көненә кадәр аралашып яшәдек, шәһәрнең 7 нче хастаханәсенә – гомере өзелергә санаулы минутлар калганда да бәхилләшергә кердем, аның кырында булдым. ТР Сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков ул вакытта баш табиб иде, өчәү бергә фотога да төштек.

Кайта-кайта уйланам. Татар халкы яшәгән ерак төбәкләргә кадәр барып, һәр авылда диярлек концерт куеп, аларның ничек яшәгәннәрен, шатлык-сөенечләрен, уй-борчуларын аннан да күбрәк белүче булды микән?! Концертлардан соң да, табын күрке мичтә тәгәрәткән бәрәңге булган чорларда да, һәммәсенең күңелен күтәреп, шаяртып, көлдереп, һәр кешене үз тавышы белән сөйләп, кәмит ясаучы да бит әле ул. Аның сөйләгән сүзләре, мәзәкләре искә төшкән саен, үз алдыма елмаеп куям. Җитәкче камытын салып, күңелем белән ял иткәнмен, алынырга да куркып торган яңа эшләргә көч туплаганмын икән аның янында! Әткәй-әнкәй янәшәсендә торучы якын кешем ул ми-

нем. Әлфия апа мине үзе дә улы кебек күрде. Туган авылым Чишмәнең агач клубында аның сәхнәдән җырлаганын без – кечкенә малай-шалайлар, агач эскәмияләр алдына чыгып, идәнгә утырып караган идек. Пластинкалардан, радиодан ишетелгән җырларын авылга килгән тере Әлфия апаның үз авызыннан ишетү авыл халкы өчен могҗизага тиң иде. Җыр-моңга, сәнгатькә гашыйк гаиләбездә Әлфия апаның җырларын әти-әнием эшләгән эшләреннән туктап тыңлый иде. Үзем дә, кулга гармун алып, аның моңнарын гармун телләрендә чыгарырга омтылдым, шул рәвешле Әлфия апа миннән гармунчы ясады. Район башлыгы булып эшләгән елларымдагы аралашулар аша аның кеп-кечкенә, нәфис иңнәрендә никадәр җаваплылык, милләт язмышы булуын аңладым. Һәрвакыт актанышлылар, район тормышы турында сораша, матур үзгәрешләргә бала кебек сөенә иде:

– Балам, ул кадәр цифрны, барысын да ничек исеңдә тотасын, мин иртән нәрсә ашаганымны да хәтерләмим, – дип шаяртып, уңышларны хуплап, аркадан сөя иде. Ятимлектә үскән, ата-ана назы күрмәгән җырчының аналарча аркамнан сөюе минем күңелемне тетрәндерә, хисләремне нечкәртә иде. Ир кеше, җитәкче кеше хисләрне йөгәнләп, салкын акыл белән эш итәргә өйрәнә. Әлфия апа алдында күңелемнең биге юк иде. Шул күңел халәте, җырчыга хөрмәт йөзеннән, Әлфия апа исән вакытта ук, аның исемен мәңгеләштерү юнәлешендә күп эшләр эшләп калырга этәргеч бирде. Актанышта, беренчеләрдән булып, аның исемендәге җыр бәйгесенә башлангыч бирдек. Аның хәер-фатихасын алып, киңәшен тыңлап эшләдек. Әлфия апаның үзе кебек гади, ихлас, җылы бәйге үткәрү өчен бар нечкәлекләрне дә уйлап бетерү кирәк иде. Аның исемендә үткән бәйге дә халыкта шундый фикер уятырлык булсын дип тырыштык. Аның уй-фикерләрен күңелдән үткәргәч кенә, карарларны кабул иттем.

– Әлфия апа! Синең исемне атауга, балачак хатирәләрем яңара. Аның иң беренчесе: патефон, Әлфия апа җырлары язылган пластинка, – дип, үзенә дә әйтә идем. Сөенә, рәхәт иде аңа ижатына булган хөрмәтемне күрүе. – Синең пластинка олы бүләк иде. Җырлары да нинди бит әле аның: «Кәккүк», «Болын», «Беренче мәхәббәт». Балачагымның тагы бер якты истәлеге – авылдагы концерт, – дим.

– Дөньяның читенә барсам да, шулай диләр. Сөенеп яшим, гомерем заяга узмаган. Безнең оныклар патефон тыңламас шул, Энгель улым. Татар моңын ничек яшәтергә? Хәзер кеше акча артыннан йөгерә, бары да бизнес белән шөгыльләнә. Олыны – олы итү, кечене кече итү бетте. Дөнья усаллашты, Илһам әйтмешли, әзрәк кенә кабахәтләнде. Кеше – кешене күрми, күрше – күршене белми. Кеше яхшылык эшләргә курка хәзер, – дип җавап кайтара иде ул.

Шундый аралашулар аша Әлфия апаның гадилеге, халыкчанлыгы фестивальләргә күчте. Район күләмендәге бәйге үсеп, төбәкара статусын алды,

хәзер аны бар дөньяга танытырга җыенабыз. Бәйгеләргә татарның мәшһүр шәхесләрен жюри итеп чакырдык, шул ук вакытта алар бәйгеләрдән соң мастер-класслар да үткәрде. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, һәвәскәр композиторлар берлеге рәисе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының традицион мәдәниятне үстерү үзәге фәнни хезмәткәре Риф Гатауллин да җырчыларга мастер-класслар уздырды. Нәтиҗәдә, конкурста катнашучыларыбыз озын көйле җырларны җырлый башлады. «Карурман», «Әллүки», Тәфтиләү», «Сибелә чәчәк»не җырлыйлар хәзер. «Кәккүк» җырын җырлаучы юк иде. Ул да сәхнәгә кайтты.

Татарстан Республикасының Беренче Президенты Минтимер Шәрипович Шәймиевкә, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановка Актанышта Әлфия Авзалованың исемен мәңгеләштерүне дәвам итүдәге планнарыбызны әйтеп киңәшләштек, фикеребезне белдердек. Мәдәният министрлыгы һәм «Салават» җыр театры белән берлектә эш башланды. Бүгенге көндә район мәдәният йорты җырчы исемен йөртә. Мәдәният паркына үзе исән вакытта ук бюст куйган идек. Киләчәктә аерым һәйкәл куярга планлаштырабыз. Актаныш Туган як музеенда Әлфия апа бүләк иткән күлмәкләр, түфлиләр, мәрҗәннәр, алган бүләкләре, орден-медальләре сакланa. Татарстанда бердәнбер булган – сәләтле балалар укучы Актаныш татар гимназиясендә дә Әлфия Авзалова музеен эшлибез. Балалар өчен, тәрбия өчен, класс сәгатьләре үткәрү өчен кирәк ул. 26 март көнне Әлфия Авзалова исемендәге район мәдәният сараенда балалар өчен тәүге тапкыр «Халкым моңы» республикакүләм ачык фестиваль уздырдык. Мондый бәйгеләрдә балалар бер-берсеннән күреп өйрәнәләр, репертуар сайлау җәһәтен дә башлыйлар. Зуррак бәйгеләрдә үзеңне сынап карау өчен дә этәргеч. Әлфия Авзалова исемендәге фестивальнең дәрәҗәсен дөнья югарылыгына күтәрәбез. 30-31нче июнь көннәрендә Актанышта узачак фестивальдә чит илләрдән дә килгән татарлар катнашыр дип көтелә.

Әлфия апа безнең арада, ул безнең эш-гамәлләребездә, күңелләрдә, иҗатыбызда яши!

Юсыф ВӘЛИТОВ,
музыкант

Эчке дөньясы матур, кояшлы, аяз иде



Мин башта Татар дәүләт филармониясенең рус коллективында музыкант булып эшләдем. Ул вакытта филармония белән Михаил Первин җитәкчелек итте. Ярты елдан безнең коллективны таркаттылар, Геннадий Евстегнеев дигән барабанчы музыкант белән мине Әлфия Авзалова бригадасына куйдылар.

Әлфия – бик тә тынгысыз, үз максатына кыю атлаучы, батыр йөрәкле, шаян, чая ханым иде. Аңа карата булган кайнар сөю хисләрем аны беренче күрүдән үк уянды, дисәм, бер генә дә ялгыш булмас. Аңа гашыйк булмаска мөмкин түгел иде. Ул беренчедән – бөек җырчы, икенчедән – искиткеч олы йөрәкле, яшьнәп яши белүче кеше иде! Без гастрольләрдән кайтып кермәдек диярлек. Иң беренче чыгышыбыз Уфада булды. Билетлар без килгәнче үк сатылып беткән, залда алма төшәр урын да юк. Алгы рәттә татар, башкорт халкының иң абруйлы шәхесләре, композиторлар, язучылар утыра: Бәхти Гайсин, Фәридә Кудашева һ.б. Әлфиянең дулкынланганы сизелеп тора. Ул бу гастрольгә чыккančы өр-яңа программа әзерләгән иде. Концертны вальс музыкасы белән башларга җыенабыз. Пәрдә ачылырга, аннары Әлфия чыгарга, без проигрышны уйнарга, ул «Эштә үткәндер көнегез, ямьле булсын кичегез», – дип, җырлап-биеп җибәрергә тиеш иде.

Пәрдә ачылды, Әлфия чыкты, шулчак халык дәррәү кул чабарга тотынды, без икенче кабат кереш өлешен уйныйбыз, халык аягүрә басып, дәррәү кул чабуга күчә һәм без шулай берничә мәртәбә кереш өлеш уйнаганнан соң гына, Әлфия җырын җырлап китте. Үз гомеремдә күпме җырчылар белән йөреп, мондый хәлне күргәнем булмады. Әлфиянең тамашачыларын яратуы исә аңа гына хас бөек хис, ул аның яшәеше иде!

Бүгенгедәй хәтеремдә: 1965 елның сентябрь ае иде. Без Әлмәт шәһәрендә Төзүчеләр көне уңаеннан чыгыш ясадык, аннары Казанга һава юлы белән кайтырга дип, Бөгелмә аэропортына килдек. Мин самолетка контрабасымны сөйрәп кереп җиткәнче, урыннарның бары да тулган иде инде. Миңа урын калдымы, дип сөрән салуга, Әлфия ханым яныннан урын тәкъдим иттеләр. Юл буе сөйләшеп, шаярышып, көлешеп кайттык. Бөтен кыюлыгымны җыеп:

«Әлфия, әйдә, бер өч көннән мин сине берәр җиргә ял итәргә алып китәм», – дим. Ул елмаеп куйды, аның күз карашыннан ризалыгын аңладым. Ул вакытта минем «Москвич» машинам бар иде, юлда ватылып кала күрмик дип, мин аны тагын бер кабат карап, тикшереп чыгарга слесарьларга бирдем. Ремонт эшләре төн уртасына кадәр барды. Мин төнге сәгать 2дә Әлфияләр яши торган Космонавтлар урамындагы 3 нче йорт янында идем инде. Икенче катка күтәрелеп ишек шакыдым, үзем икеләнәм: чыгармы-юкмы, дим. Тып-тын, ишек ачучы булмады, мин кабат машинама чыгып утырдым. Кире уйлагандыр, күрәсең, дим, әмма өйгә кире кайтып китәсем дә килми. Җитмәсә, өйдән чыгып киткәндә әнигә, иптәш малайлар белән балыкка барабыз, дип әйткән идем. Мин утырдым-утырдым да, кабат кердем, тагын шакыдым, эчтә кемнеңдер аяк тавышы ишетелде. Ишек ачылды, ишек төбендә чемоданнар, сумкалар тора. Минем эчкә җылы йөгерде, димәк, бара, дим. Ул тиз генә әзерләнде дә, машинага чыгып утырды, бу минутта бездән дә бәхетле кеше юктыр кебек иде, без – ике мәхәббәт кошы, төнге билгесезлеккә очтык. Искиткеч якты хатирәле, могҗизалы сәяхәт булды ул! Адлерда дустым яши иде, без диңгездә ял итәргә карар кылдык. Ростовтан килгән аквалангистлар белән бергә кыргый пляжда хәл җыеп, коенып, кызынып, гастрольләрдә арыганнарны бетереп, рәхәтләнеп ял итеп кайттык, хәтта су астында фотоларга төштек. Яшь парларның баллы ае кебек, татлы, рәхәт, онытылмаслык булды ул сәяхәт!

Әлфиядә кешелеклелек дигән сыйфат биш кешегә бүлеп бирерлек иде. Берсендә бик тә салкын, яңгырлы көн иде. Без үзебезнең бригада белән Әстерхан аэропортына килеп төштек. Безне каршылап гостиницага алып килделәр. Әле бушаган номерлар булмаганлыктан, без кунакханәнең алгы бүлмәсендә, кем кайда – вакытлыча урнаштык. Бер номер бушагач, Әлфиягә люкс ачкычын тоттырдылар. Шулчак ул читтә – җылыткыч батареясы янында бала кочаклап утырган бер хатынны күреп алды. Сабый берөзлексез көйсезләнә, елый. Әлфия теге хатын янына барып, аның хәлен сорады. Баксаң, теге хатынның ире бөтен акчасын алып, хатыны белән баласын калдырып, каядыр киткән булып чыкты. Әлфия боларны үзенә бирелгән номерга алып кереп ашатып, эчертеп, җылытып, икенче көнне юлларына акча биреп озаттылар. Менә шундый иде ул бөек җырчы, гади авыл кызы – Әлфия Авзалова!

Татарстан, Башкортстан авылларында Әлфия аяк басмаган сәхнә калдымы икән, юктыр?! Элек бит күп авыл клублары иске мәчетләрдә иде. Бер почмакта тимер мич, ул яксаң да, якмасаң да юньләп җылытмый. Утны әйтәсе дә юк, лампочкалар урынына, керосин лампалары пыскый. Ул иске мәчет сәхнәләре шулкадәр тәбәнәк, мин контрабасны уйнарга дип алып чыксам, аның башы түшәмгә тиеп, контрабас үзе басып торыр иде. Гадәттә, Әлфиянең концертларына – 100 урынлы клубка 300 кеше кереп тулар иде. Ул чакта клубта тынчу, сулар һава бетә. Әмма Әлфия, бер генә җырын да кыскартмыйча,

үзен яратып килгән авыл тамашачысына өч сәгатькә якын концерт бирер иде. Мәскәүнең данлыклы 2 мең 500 тамашачы сыярлык «Россия» кинозалында да – 3 сәгатькә якын, авылларда да. Аның өчен иң беренче урында тамашачы иде. Аны тамашачысы да, туры мәгънәсендә, күтәреп йөртте.

Хәтерем ялгышмаса, 1966-67 еллар иде бугай. Түбән Новгородта концерт биреп, арттагы запас ишектән чыгуга, аны, коридор ясап, чәчәкләр белән каршы алдылар, ул алар белән саубуллашып, Мәсгут абый машинасына кереп утыруы булды, көчле, егәрле татарлар, мишәрләр дәррәү машинаны өскә күтәреп «чөйде». Бу – халык яратуы, тамашачы мәхәббәте иде! Ятим калып, балалар йортында тәрбияләнгән, үз-үзен күтәргән бу кызның эчке дөньясы әйтеп-аңлатып бетермәслек матур, кояшлы, соклангыч, аяз иде! Анда интеллигентлык сыйфатлары да, аристократлык чаткылары да ярылып ятты.

Аның иҗатыннан һәрбер халык үзенә җим тапты, ул күп телләрдә җырлый иде. Бервакыт Мәскәүдә концерт вакытында ул «Волга-реченька»ны җырлап, Людмила Зыкинаның үзен шаккатырды. Җыр тәмамлангач, бөек татар җырчысы Әлфия Авзалованы Людмила Зыкина шәхсән үзе басып алкышлады!

Тора-бара гастрольләргә чыгу күңеллеләнә башлады, авылларда 350-400 урынлы, киенү, чишенү бүлмәләре булган яңа клублар сафка басты. Әлфиянең чыгышы вакытында тамашачыларның, ким дигәндә, 10 рәте уч төбендәге кебек күренеп тора. Әлфия борынгы моңлы көйләрне җырлый башласа, тамашачылар, кулъяулыкларын алып, күз яшьләрен сөртә башлар иде.

Әлфиянең иҗатын хәзерге Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның әтисе Нургали абый да бик яратты. Без Саба ягына концерт белән баргач, Лесхозда Нургали абый Әлфия Авзалова хөрмәтенә искиткеч сый-хөрмәт әзерләгән иде. Ул чакта әле Рөстәмнең кечкенә чагы, әлбәттә инде, алар өстәл янына килмәделәр, читтә уйнап йөрделәр. Менә шундый олы иҗат юлы узып, күпме кешеләрнең йөрәгенә җыр-моңнары белән үтеп кереп, мәңгелеккә яшәп калган, яраткан җырчыбыз ул – безнең Әлфиябез!

Әлфия Авзал кызы Авзалованың биографиясе һәм тормыш юлы

Әлфия Авзал кызы Авзалова Башкортстан Республикасының Калтасы районындагы (хәзер Краснокама районы) Яңа Кабан авылында 1933 елның 15 гыйнварында дөньяга килә. Әлфиягә – 5 яшь, сеңлесе Флүрәгә 3 яшь тулганда, кечкенә кызлар әтисез дә, әнисез дә кала. Алар Актанышта тәрбияләнә.

Кечкенәдән ул бик моңлы бала була. Үсә төшкәч, төрле районкүләм мәдәни чараларда катнаша башлый, тәүге җиңүләрен яулый. Бервакыт Актанышка Татар дәүләт филармониясеннән Рәшит Вәһапов җитәкчелегендәге бер төркем артистлар килә. Танылган артист Әлфиянең җырлавын тыңлап, аңарда табигый талант барлыгын әйтә. Актанышка килгән башка җырчылар да аңа артист һөнәрен сайларга тәкъдим итә. Әлфия 1951 елны Казанга килеп Татар Дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбленә эшкә керә.

Гади авыл кызы тамашачыларын искиткеч матур, кабатланмас тавышы, табигый моңы белән әсир итә. Аның репертуарында 200дән артык халык жыры, композиторларның 500дән артык әсәре һәм 17 чит телдә башкарган җырлар бар. Ансамбльдә ике ел эшләгәннән соң, Әлфия музыка училищесына укырга керә. «Төрлесе төрлечә укыта: берсе миннән халыкчан җырлавымны таләп итә, икенчесе опера җырчысы итеп укытмакчы», – дип яза ул соңрак бу хакта «Үзем турында» дигән китабында. Училище директоры Ильяс Әүхәдиев табигый тавышын саклауны, үзлегеннән уку-өйрәнүне киңәш иткәч, ул кире филармониягә кайта.

1957 елда Мәскәүдә Татарстан Республикасының сәнгать һәм әдәбият декадасы үтә. Анда Әлфия Авзалова да чыгыш ясый. Аның җырлавын мәскәүлеләр югары бәяли, бу аның иҗат юлында зур борылыш була.

1960 елны филармония җитәкчеләре, яшь башкаручылар – Илһам Шакиров белән Әлфия Авзалова катнашында, «Сәхнәдә – яшьләр» дигән төркем оештыра. Әлеге төркем бик уңышлы чыга, һәр җирдә көтеп алына.

Төркем таркалганнан соң, Әлфия, яңа иҗат дулкынында рухланып, татар сәнгатендә беренче булып, «Казан утлары» дигән эстрада ансамбле оештыра. Шул рәвешле ул татар сәнгатендә эстрада юнәлешенә нигез сала. Инструменталь төркемнән тыш, ансамбльгә солист үзе, нәфис сүз осталары, биючеләр дә керә.

Шушы бердәм, сәләтле иҗат әһелләреннән тупланган бригада белән ул төрле шәһәрләр, авыллар буйлап гастрольләргә йөри башлый. Ике айлык гастрольләр барышында 100дән артык концерт биргән мәшһүр җырчыны татар халкы гына түгел, бөтен Россия халкы үз итә, ярата. Аның концертлары һәрвакыт тулы зал, аншлаг белән үтә. Гастрольләр географиясе Россия тамашачысы белән генә чикләнми, аны союздаш республикалар халкы да яратып кабул итә.



Олы кызы Гүзәл туенда. Август, 1975 ел

Ватан һәм халкыбыз алдындагы фидакарь хезмәтен югары бәяләп, Әлфия Авзалованы ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Советлар Союзы Дуслык комитетының «Актив иҗат тормышы һәм халыклар арасындагы дуслыкны ныгытканы өчен» дигән Мактау грамотасы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләләр. Әлфия Авзал кызы Авзалова – Татарстан Республикасының халык артисты, Россиянең атказанган артисты. Казан шәһәренең Дан аллеясында Әлфия Авзалова исемендәге мәрмәр йолдыз уеп куелган.

Әлфия Авзалованың ике кызы – Гүзәл белән Зөлфиясе бар.

Озакка сузылган каты авырудан соң, 2017 елның 15нче июнендә Әлфия Авзалова вафат була. 17нче июньдә, зур кайгы һәм тирән тетрәнү кичереп, халкыбыз мәшһүр җырчысын соңгы юлга озатты. Аның мәңгелек йорты – Казан шәһәренең Яңа Бистәдәге татар зиратында...

Биография и творческий путь Альфии Авзаловны Авзаловой

Альфия Авзаловна Авзалова родилась 15 января 1933 года в деревне Новый Кабан Калтасинского района (ныне Краснокамского) Башкирской АССР. В пятилетнем возрасте Альфия и ее трехлетняя сестренка Флюра остались сиротами. Дальнейшая судьба детей была связана с детским домом в селе Актаныш, Актанышского района Татарской АССР.

Альфия с детства любила петь. Со временем, она начала участвовать в различных культурных мероприятиях районного уровня. Однажды в Актаныш приехала группа артистов под руководством Рашида Вагапова Татарской государственной филармонии. Известный артист, послушав Альфию, сказал, что у девушки талант от природы. Приезжавшие в район с концертами известные татарские певцы также пророчили ей большой творческий путь. В 1951 году Альфия приехала в Казань, где была принята в состав ансамбля песни и пляски Татарской государственной филармонии.

Обыкновенная деревенская девушка пленила зрителей своим красивым, неповторимым голосом, его природным звучанием. В ее репертуаре было более 200 народных песен, свыше 500 произведений профессиональных композиторов и песен на 17-ти языках народов мира. Проработав в ансамбле два года, Альфия поступила в музыкальное училище. Позже в своей книге «О себе» она писала: «Все учат по-разному: одни требуют, чтобы я пела в народном стиле, другие в оперном жанре». Альфия приняла решение заниматься самообразованием и продолжить творческую деятельность, вернуться в филармонию.

В 1960-м году руководство филармонии создает группу «На сцене – молодежь» при участии молодых исполнителей Альфии Авзаловой и Ильгама Шакирова. Этот проект оказался очень успешным и востребованным.

После распада группы Авзалова на новом творческом подъеме создает впервые в истории татарского искусства эстрадный ансамбль «Казан утлары», тем самым став основательницей эстрадного направления в татарском искусстве. В этот ансамбль вошли также артисты художественного слова и группа танцоров. С этим коллективом она начинает гастрольную деятельность.

Альфия становится одной из популярных эстрадных певиц, которая за два месяца гастролей проводила более 100 выступлений. Концерты проходили при полных залах, с аншлагами. География гастролей не ограничивалась только российскими зрителями, ее с удовольствием слушали и в союзных республиках. В 1957 году прошла «Декада татарского искусства и литературы в Москве», в которой приняла участие и Альфия Авзалова. Ее выступление было высоко оценено московской публикой, и стало серьезным поворотом в ее творческой жизни.



1985 ел

Творчество Альфии Авзаловой и ее вклад в культуру и искусство страны и татарского народа получили высокую оценку. Она была награждена двумя орденами Трудового Красного Знамени, Почетной грамотой Советского комитета защиты мира «За активную творческую жизнь и работу по укреплению мира между народами», Государственной премией Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая. Альфия Авзаловна Авзалова – Заслуженная артистка России, Народная артистка Республики Татарстан. На Аллее звезд в Казани установлена мраморная звезда с ее именем.

У Альфии Авзаловой две дочери – Гузель и Зульфия.

15 июня 2017 года после продолжительной болезни Альфия Авзалова ушла из жизни. Татарский народ понес невосполнимую утрату. Многотысячные почитатели таланта Альфии Авзаловой проводили любимую певицу в последний путь со сцены Татарской государственной филармонии, где она проработала более 50 лет. Похоронена певица на Ново-татарском кладбище г. Казани.

BIOGRAPHY OF ALFIA AVZALOVNA AVZALOVA

Alfia Avzalovna Avzalova was born in the village of Novy Kaban, Kaltasinskiy District (now Krasnokamskiy) of the Bashkir ASSR on January 15, 1933. At the age of 5 she and her three year old sister Flura became an orphan and were brought up in orphan asylum in the village of Aktanysh, Aktanyshsky district of the Tatar ASSR, and then her mother's sister took her to family. From childhood Alfia was distinguished by her remarkable musical abilities. At the age of 15, being a schoolgirl, she actively participated in various concert amateur programs. One day a group of artists of Tatar State Philharmonia, headed by then-noted singer Rashid Vagapov, came to the village. He heard old folk Tatar songs, performed by Alfia, and immediately discovered her remarkable natural talent. In the same year a troupe from the State Song and Dance Ensemble of Tatarstan invited her to join their group, where subsequently she became the solo singer.

The former village girl conquered the capital of Tatarstan and was the first who created the new development in the Tatar art - performing variety songs on Tatar and other languages accompanied by the instrumental group «Kazan Utlary» - «Kazan Lights». Alfia Avzalova had songs of famous composers on 17 languages on her repertoire; it had more than 500 songs. Singer's popularity was so phenomenal that Alfia could give more than 100 concerts during bimonthly tour. She toured all the cities of the Soviet Union and Union Republics, and then Russia, foreign countries.

Alfia Avzalova is decorated by numerous state awards and titles: Honored Artist of Russia, Honored Artist of Tatarstan; twice awarded the Order of the Red Banner of Labour, the Order of Merit of the Republic of Tatarstan, State prize winner. She was a mother of two daughters Guzel and Zulfiya.

Alfia Avzalova after a long illness passed away on June 15,2017, buried at the Novo-Tatarskiy cemetery of Kazan.



1978 ел



1960 ел



1968 ел



1970 ел



1971



1974 ел



1980 ел

Бер очрашу – үзе бер гомер













Илһам Шакиров белән







Салават:
«Моңа хәтле татарның Әлфия апа кебек халыкчан җырчысы, юк иде, юк һәм булмаячак та!»







Әлфия апа һәм Разил Вәлиев



Гөлшат Зәйнашева һәм Иделия белән



Айрат Сибагатулин гаиләсе белән



Баянисты Ринат Сибгатуллин




Азнакай. 7 август, 2008 ел



Мәскәү. 1993 ел



2003 ел







Казан «Пирамида» КАҮ
2009 ел



Мәскәү 1995 ел





Сәхнәдәшләре: Винера Ганиева; Зөһрә Шәрифуллина



Филармониядә
Кадим Нуруллин,
Айдар Фәйзрахманов
белән.
2014 ел



Рәшит Сабиров Әлфия
Авзалованың юбилеенда



Гөлшат Зәйнашева һәм
Рабит Батулла белән



Ләйсән Фәтхетдинова, Зөлфия Шакирова
Чаллы шәһәрендә





Илһам Шакиров һәм Рамил Чурагулов белән



Илшат Әминов янәшәсендә



Фәрит Гомәров янында



Интервью вакытында



Китап әзерләүчеләр – Зөлфия һәм Равил Нигъмәтҗановлар,
Әлфия Һадиева, Рөстәм Сәрвәров. 2018 ел

Әлфия Авзалова исемендәге I Халыкара фестивальнең Гала-концерты мизгелләре, 2018 ел



















1996 ел

Кечкенә Зөлфия Җыракай белән.
1965 ел



1990 ел



1997 ел



2000 ел



2003 ел



2012 ел



2011 ел



2014 ел



2014 ел



2018 ел



2005 ел



2016 ел



2017 ел





1996 ел



2016 ел



2018 ел



2015 ел



2006 ел



2013 ел



2008 ел



2009 ел




ӘЛФИЯ АВЗАЛОВА РЕПЕРТУАРЫННАН ЙӨЗ ҖЫР

(сүзләре, ноталары)

ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ

Авыл көе




1. Һавалардан очып үтте
Күгәрчен көтүләре;
Әле дә булса исләремдә,
Сау бул, дип китүләре.

2. Кызарып кояш чыкканда,
Нурлар төшә түтәлгә;
Күзем төшсә, күңелем төшми
Синнән башка бүтәнгә.

3. Урман буе салкын чишмә,
Суын эчеп туймадым;
Аерылганда кул бирмәдем,
Күрешербез дип уйладым.

Агыйдел каты ага




1. Агыйделдә йөрсәң иде,
Камыштан көймә үреп;
Былбыл булып, гөлгә кунып,
Сөйләшсәң иде күреп.
Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә;
Сөя микән, сөйми микән,
Шуны беләсем килә.

2. Аклы күлмәк җиңе тар,
Җиң очында хаты бар;
Хатын укып карагачтын –
Сөям дигән сүзе бар.
Агыйдел күпере,
Чуенмы әллә чылтырый;
Каш астында ике күзе
Энҗе кебек елтырый.

3. Агыйделдән көймә килә
Кылдай нечкә эз белән;
Җаным, нигә хәтрең калды
Уйнап әйткән сүз белән?!
Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә;
Сөя микән, сөйми микән,
Шуны беләсем килә.

Ай былбылым




1. Ай былбылым, вай былбылым,
   Агыйделнең камышы;
   Таң алдыннан чут-чут килә
   Сандугачлар тавышы.

2. Ай былбылым, вай былбылым,
   Агыйделдә таң ата;
   Таңнар ата, өзелә үзәк,
   Җырлата да елата.

3. Ай былбылым, вай былбылым,
   Кунып сайрый талларга;
   Синең хакта серләремне
   Сөйлим сандугачларга.

Ай, җаный, суларда



1. Әйдә, иркәм, алып барам
Чишмәләргә, суларга;
Чишмәләрдән су алганда
Су чәчрәтеп уйнарга.
Ай, җаный, суларда (ла)
Су чәчрәтеп уйнарга.

2. Өй эчләренә керәсең,
Гөлләргә үреләсең;
Гөлгә карыйм, сиңа карыйм –
Син матур күренәсең.
Ай, җаный, күз нурым,
Син матур күренәсең.

3. Атлар җиктем мин чанасыз,
Чыгып киттем чарасыз;
Күрер күзгә зур да түгел,
Чибәрлеккә чамасыз.
Ай, җаный, күз нурым,
Чибәрлеккә чамасыз.

4. Абау, бәгърем, керфегең,
Бирче миңа бөртеген;
Бик еракларга китәм ич,
Төсең итеп йөртермен.
Ай, җаный, керфегең,
Төсең итеп йөртермен.

Ак калфак[1]



1. Ай, әле бик ерактa идек без,
Илле чакрым җирне килдек без.
Ак калфакның табылган чагы,
Туганнарның сагынган чагы.

2. Илле чакрымны якын итеп без,
Бер күрешер өчен килдек без.
Ак калфакның табылган чагы,
Туганнарның сагынган чагы.

3. Ырынбурдан мамык шәл алдым,
Алтын тәңкә бирдем жәлләми.
Ак калфагым төшердем кулдан,
Безнең дус-иш белән ил тулган.

4. Алтын тәңкә бик зур мал түгел,
Бер дә күрешүләр әллә ни.
Ак калфагым төшердем кулдан,
Безнең дус-иш белән ил тулган.

[1] Җыр текстының бер варианты.

Актаныш басмалары




1. Агыйделдән күренеп тора
   Актаныш басмалары шул;
   Кызлар чәчен үреп салса
   Җилферди тасмалары.

2. Апрель җитми, агып бетми
   Агыйделнең бозлары шул;
   Мул уңышлар яулап ала
   Егетләре, кызлары.

3. Каян барсаң, шуннан туры
   Актанышның юллары шул;
   Хезмәтләрдә җиңү яулый
   Безнең район уллары.

Арча




1. Арча якларына карыйм,
   Дустым Арча ягында.
   Арча ягы бигрәк матур
   Кош сайраган чагында.

2. Арчаларга барсаң, бәгырем,
   Ал гөлләрне үзәрсең.
   Үзәгемне бик үзәсең,
   Үзең ничек түзәсең?

3. Китәм, бәгырем, китәм, бәгырем,
   Каласың Арчаларда.
   Онытырлык ярым түгел,
   Утларга салсалар да.

4. Арчаларга баруларым
   Гөл-сирень өчен генә.
   Януларым, көюләрем
   Гел синең өчен генә.

Ашхабад



1. Әй дусларым, дусларым ла,
Дусларым, дус-ишләрем.
Сез дуслардан аерылсам,
Ялгыз башым нишләрмен?

2. Алма булса, шундый булсын,
Берсен бишкә бүләрлек.
Дустың булса, шундый булсын,
Синең өчен үләрлек.

3. Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар ераккa.
Сез дусларны охшатамын
Пешкән виноградка.

4. Уйсу җирдә дым була,
Дым бар җирдә су була.
Яшь вакытта уйна да көл,
Картайгачтын соң була.

5. Урман эчләрендә урман,
Ничек чыгармын инде?
Сез дуслардан аерылсам,
Ничек чыдармын инде?

6. Чылтырап аккан чишмәләрдә,
Туктыйк әле, дусларым.
Чишмә кебек моңландырып
Җырлыйк әле, дусларым.

Әллүки

Г. Тукай сүзләре

Салмак, моңлы




1. Ишеттем мин кичә: берәү җырлый,
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Әллүки, бәллүки,
Чын безнеңчә матур, милли көй.

2. Башка килә уйлар төрле-төрле,–
Әллә нинди зарлы, моңлы көй;
Әллүки, бәллүки,
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

3. Түзәлмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Әллүки, бәллүки,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»

4. Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, Әллүки!»
Әллүки, бәллүки,
«Бу көй була, диде, Әллүки».

Әй, икегез, икегез



1. Әй, икегез, икегез,
   Икегез дә бертигез;
   Икегез дә пар килгәнсез,
   Тигез гомер итегез.

2. Самавырны тиз кайната
   Кызыл миләш күмере;
   Килен белән яшь кияүнең
   Озын булсын гомере.

3. Сокланып карап туймассың
   Зифа буегызга да.
   Рәхмәт, безне чакыргансыз
   Матур туегызга да.

4. Агыйделгә сал килгән,
   Сал килгән җир тар килгән.
   Сайлап алган алмалар күк,
   Икегез дә пар килгән.

5. Сандугачлар ояда,
   Оялары пыяла;
   Сандугач кебек сайрашып,
   Шат яшәгез дөньяда!..

Әпипә



1. Бас, кызым, Әпипә,
   Син басмасаң, мин басам.
   Синең баскан эзләреңә
   Мин дә китереп басам.

2. Бас, кызым, Әпипә,
   Син басмасаң, мин басам.
   Әпипәнең калачларын
   Ашап калам ичмасам.

3. Бас, кызым, Әпипә,
   Идәннәре селкенсен;
   Идәннәре селкенсен дә,
   Кияү күңеле җилкенсен.

4. Бас, кызым, Әпипә,
   Сындыр идән тактасын;
   Сындырсаң идән тактасын,
   Кияү түләр акчасын.

Әтнә көе



1. Шушы көйне матур итеп
Әйтәләр Әтнәләрдә.
Үзәкләремне өзәләр
Исемең әйтәләр дә.


2. Иртә торсаң моңсу була
Әтнә су буйларында.
Югалган чәчәгем кебек
Син генә уйларымда.

3. Матур итеп кошлар сайрый
Әтнә су буйларында;
Ятсам – төштә, торсам – истә,
Син генә уйларымда.

4. Кызарып кояш чыкмыйча,
Уйсу җирдә су кипми;
Көлемсерәп карауларың
Күз алларымнан китми.

5. Җырлыйк Әтнә көйләренә,
Җырчыларга таралсын;
Мул уңышлар үстерүдә
Безнең Әтнә дан алсын.

Богады авылы көе



1. Аклы ситса күлмәгемне
   Бер генә кигән идем;
   Тик торганчы бер эш булсын
   Дип кенә сөйгән идем.

Кушымта:
Их, Мәккә-Мөкәррәмә, Мәдинә-Мөнәвәрә;
Эчеңдәге серләреңне сөйләмә берәүгә дә.

2. Агыйделне чыккан чакта,
   Камышлыктан юл салдым;
   Сине уйлап, бәгырькәем,
   Камыштан нечкә калдым.

Кушымта.

3. Аклы ситса күлмәгемне
   Кими башлаган идем;
   Рәхмәт яусын ташлавыңа –
   Сөйми башлаган идем.

Кушымта.

4. Кибетләргә үлчәү кайткан
   Челтәр бәйләүчеләргә;
   Телләренә сөял чыксын –
   Безне сөйләүчеләргә.


Кушымта.

5. Сандугачның балаларын
   Тоталмадылар әле;
   Чәйнәп-чәйнәп карадылар –
   Йоталмадылар әле.

Кушымта.

Бөрлегәнем – бер генәм

Уртача тизлектә




1. Бакчаларда чәчәк ата
Син утырткан бөрлегән.
Ул да сине көтә сыман,
Ник килмисең, бер генәм?
Бөрлегәнем, бөрлегән,
Сагындырдың бер генәм.

2. Бүген төнлә төшләремдә
Сине күрдем, бер (гөл) генәм.
Син тал, имеш, ә мин, җаным,
Гүя кара бөрлегән.
Бөрлегәнем, бөрлегән,
Бик сагындым бер генәм.

3. Бөрлегәндәй күзләреңне
Бик сагындым, бер генәм;
Сөям, дигән сүзләреңне
Кабатлыйм мин җыр белән.
Бөрлегәнем, бөрлегән,
Син бит минем бер генәм.

Вәгъдә



1. Гашыйк булган яшь егеткә дөньяда
Керсез күңел, саф мәхәббәт, көч кирәк.
Иркәң хыянәтче булгач,
Үз вәгъдәсен үзе бозгач,
Газапланып әрни яшь йөрәк.

2. Вәгъдә биргәч кирәк иде көтәргә,
Нигә инде хыянәтләр итәргә?
Зәйтүн гөлем дигән идем,
Гомерлеккә сөйгән идем –
Шат тормышта гомер итәргә.

3. Миндә кайгы, миндә хәсрәт, моңланам,
Синең утларыңда янам мин һаман.
Яшь йөрәгем, син ярсыма,
Давылдан соң диңгез тына,
Хәсрәтләрең бетәр берзаман.

4. Көзге ачы салкын җилләр истеләр,
Болыннарда чәчәкләр дә сулдылар.
Януларым, көюләрем,
Чын күңелдән сөюләрем –
Барысы да әрәм булдылар.

Гармунчыга



1. Гармуныңны уйныйсың да,
Тәрәзәмнән үтәсең:
Күз карашларың бик матур,
Үзәгемне өзәсең.

Кушымта:
Әттәгидер генәме,
Гармунчыгыз өйдәме?
Өйдә булса килсен әле,
Биетеп китсен әле.
Үпкәлибез, үпкәлибез,
Үпкәлибез, килмәсә.
Гармун күтәреп йөрмәсен,
Бию көен белмәсә.
Ялындыра, ялындыра,
Ялындыра, килми ул.
Килер иде, уйнар иде,
Бию көен белми ул!

2. Гармунчылар күп уйнаса,
Бармакларын талдыра;
Кемнәрең бар? Кемне уйлыйсың?
Кемнәрең сагындыра?

Кушымта.


3. Урамнарда берәү йөри,
Гармуны беләгендә;
Белсәң иде, шул егетнең
Нәрсә бар йөрәгендә?

Кушымта.

4. Гармунчылар гармун ала
Гармунда ярышырга;
Ярышларда җиңеп чыксам
Уйлыймын танышырга.

Кушымта.

Дим буе




1. Димдә тудым, Димдә үстем,
   Җиләк җыйдым тугайда,
   Әй, матур Дим буе,
   Бик сагындым бу юлы.

2. Күп хәсрәтләр күрдем мин,
   Сер бирмәдем шулай да.
   Әй, матур Дим буе,
   Бик сагындым бу юлы.

3. Былбыл да бар, кондыз да бар
   Димнең таллы ягында.
   Әй, матур Дим буе,
   Бик сагындым бу юлы.

4. Хәсрәт тә бар, кайгы да бар
   Читтә йөргән чагында.
   Әй, матур Дим буе,
   Бик сагындым бу юлы.

Җаныем, бәгырем



1. Иртә буран, кич тә буран,
Мамык шәләңне уран шул,
Мамык шәләңне уран.
Кигән киемең күрсәм дә,
Җаныем, бәгырем,
Үзең күргәндәй булам.

2. Ишегалдында йөримен,
Карлар яуса көримен шул,
Карлар яуса көримен.
Синнән башка ямь табалмыйм,
Җаныем, бәгырем,
Ямансулап йөримен.

34. Тимер чана карлар яра,
Бу йөрәгем ник яна шул,
Бу йөрәгем ник яна?
Бу йөрәгем белеп яна,
Җаныем, бәгырем,
Сөйгәнем ятка кала.

Жомга



1. Тал бөресе, тал бөресе,
Тал бөресе талларда;
Сандугачым, әйтеп сайра:
Сөйгән ярым кайларда?

2. Сандугачым, очасыңмы,
Кипте инде күлләрең;
Синең янга барып кайта
Һәр көнне күңелләрем.

3. Акрын искән җил селкетә
Агыйдел камышларын;
Кем аерылмый, шулар белми
Аерылу сагышларын.

4. Агыйделләр дулкынлана,
Дулкынлана, комлана;
Басып сайрар талы сынса,
Сандугач та моңлана.

5. Моңлы кичтә тальян гармун
Кемнәр уйнатыр инде?
Син булмагач, күңелемне
Кемнәр юатыр инде?

6. Гармуныңны тартып уйна
Үрләргә менгәндә дә;
Онытасым юк үлгәндә дә,
Гүрләргә кергәндә дә.

Зиләйлүк

Г. Тукай сүзләре.




1. Сөялгәнсең чатта баганага,
Яфрак төсле сары йөзләрең.
Кызганмыйча күңелем чыдый алмый,
Бигрәк моңлы карый күзләрең.

2. Атылган кош, адаштырган эттәй,
Үткәннәргә мәэюс карыйсың;
Күрәм, ике иренең селкенәдер:
Кайсы татар баен каргыйсың?

3. Сизмисең бит син дә синең яннан
Нечкә күңел шагыйрь узганын.
Синең болай мескенләнгән хәлең
Аның күңелен ничек өзгәнен.

Их, карап торулары



1. Кашың кара, кашың кара,
   Каралткангадыр инде.
   Карыйм, карыйм, карап туймыйм,
   Яраткангадыр инде.

Кушымта:
Их, карап торулары,
Күз сирпеп алулары,
Синнән генә булды инде
Йөрәгем янулары.

2. Кашың кара, күзең зәңгәр,
   Керфегең каралтасың.
   Күз карашың магнитлы,
   Гел үзеңә тартасың.

Кушымта:
Их, карап торулары,
Күз сирпеп алулары,
Синнән генә булды инде
Йөрәгем янулары.

Казан сөлгесе




1. Казаннан Мәскәү күренә, диләр,
   Биек манарадан карасаң.
   Калды ич, калды ич Казан сөлгесе, (2 тапкыр)
   Апасыннан матур сеңлесе.

2. Үткән гомерләрем кайтыр микән,
   Сандугачлар булып сайрасам?
   Ник ак була икән ташпулат? (2 тапкыр)
   Маллар кыйбат түгел, баш кыйбат.

3. Яланнарда җәйләр ямьле була
   Ак чатырлар корып җәйләргә;
   Алып эчтем суның салкынын, (2 тапкыр)
   Ул да басмый йөрәгем ялкынын.

4. Кайда гына барсаң, дусың булсын,
   Каршы чыгып атың бәйләргә.
   Ник ак була икән ташпулат? (2 тапкыр)
   Маллар кыйбат түгел, баш кыйбат.

Китәм дисең



1. Китәм дисең, китәм дисең,
Гел китәрсең микәнни?
Синең авыр хәсрәтеңне
Мин күтәрим микәнни?

2. Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде Ташкентка.
Китәм инде Ташкентка, шул,
Сине ятка ташлыйм да.

3. Китәм дисең, китәм дисең,
Китсәң мине калдырма.
Мин таянган иңбашыңа
Ятларны таяндырма.

4. Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде Донбасска.
Китәм инде Донбасска, шул,
Сүз бирик ташлашмаска.

5. Китәм дисең, китәм дисең,
Китәм дисең көньякка.
Ул көньяклар бик еракмы,
Әллә Ленинградмы?

6. Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде каласың.
Мин киткәчтен кемнәр сөяр
Син сандугач баласын?

Көймә килә




1. Әй жаным, хат язгансың,
Энҗе кебек тезгәнсең.
Энҗе кебек тезгәнсең дә
Үзәгемне өзгәнсең.

Кушымта:
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә,
Көймә генә килә генә, эзе юк.
Хаты гына килә генә,
Сүзе генә килә генә,
Сөйләшергә үзе юк.

2. Җиделе лампа фитиле
Янгач кала күмергә;
Алсу алмадай гүзәлне
Оныта алмам гомергә.

Кушымта.

Кошлар кебек




1. Һаваларда очкан кошлар кебек,
Ярсый-ярсый канат кагынып,
Туган илем, кайттым мин талпынып,
Күз нурларым, сезне сагынып.

2. Һаваларда очкан аккошларның
Канатлары җилдә каерылмый.
Яшәр идем, Туган илем, синдә,
Якын дусларымнан аерылмый.

3. Һаваларда очкан аккошлардан
Коела җиргә мамык тузаны.
Туган илдә сөйгән дуслар белән
Сизелми лә гомер узганы.

4. Һаваларда очкан аккошларның
Каурыйлары коела җилләрдә.
Туфрагына алтын чәчсәләр дә
Җитми икән туган илләргә.

Күбәләгем




1. Күбәләк гөлләргә кунса,
Гөлләр тибрәнә микән?
Ул да мине сагынганда,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Җырлап җибәрә микән?

2. Күбәләккәй гөлгә кунган,
Гөлдә булгач оясы;
Минем күңелем сиңа тарта,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Син бит күңелем кояшы.

3. Тау астында, тал астында
Салкын чишмә түгәрәк;
Очып барып кайтыр идем,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Әгәр булсам күбәләк.

Минзәлә



1. Барасызмы Минзәләгә,
Мин барам Минзәләгә шул;
Минзәләне күрер өчен,
Йөрәгем өзгәләнә.

2. Минзәләгә барганым юк,
Юллары такыр, диләр;
Такыр юлда йөреп үскән
Кызлары матур, диләр.

3. Минем иркәм Минзәләдә
Туып үскән бер матур;
Минзәләгә баралмасам,
Аны кемнәр юатыр?!

4. Минем иркәм Минзәләнең
Урамнарын балкыта.
Үзенең уңганлыгы белән
Тирә-якка дан тота.

Нигә яна йөрәгем?



1. Сандугачлар ияләшкән
Су эчәргә миләштән.
Борчуларым бетәр иде,
Сине күреп сөйләшсәм.
Их, тала, тала, тала,
Тала ике беләгем.
Нигә тала, нигә яна
Икән минем йөрәгем?!

2. Агыйделгә басма салдым
Каенын сайлап кына.
Яннарыңа барыр идем
Кош булып сайрап кына.
Их, тала, тала, тала,
Тала ике беләгем.
Нигә тала, нигә яна
Икән минем йөрәгем?!

3. Агыйдел суы тирбәлә
Уртасында сал булса.
Суга салсаң калкып чыгар,
Безгә насыйп яр булса.
Их, тала, тала, тала,
Тала ике беләгем.
Нигә тала, нигә яна
Икән минем йөрәгем?!

4. Агыйделкәйне кичкәндә,
Җырлыйм ишкәк ишкәндә.
Өзелә үзәк, яна йөрәк,
Җаныем искә төшкәндә.
Их, тала, тала, тала,
Тала ике беләгем.
Нигә тала, нигә яна
Икән минем йөрәгем?!

Олы юлның тузаны




1. Олы юлның тузанын
Үзем күрдем тузганын.
Белми калдым, сизми калдым
Яшь гомеремнең узганын.

2. Олы юлның тузанында
Калды минем эзләрем;
Кайда икән яшьлегем, дип,
Шул юллардан эзләдем.

3. Олы юлның тузанында
Югалттым эзләремне.
Их, кайтарып алыр идем
Узган гомерләремне.

4. Олы юлдан атлар килә,
Безгә кала тузаны.
Алда гомер бардыр барын,
Сагындыра узганы.

Сагыну




1. Бездә биек таулар бар ла,
   Тау астында таллар бар;
   Талда яфрак, миндә сагыну,
   Сездә нинди хәлләр бар?

2. Тау астында салкын чишмә
   Агып төшә улакка;
   Сагынуымны әйтер идем,
   Җил дә исми шул якка.

3. Алмалар өзәр идем лә,
   Бауларга тезәр идем;
   Янмаса бу йөрәккәем,
   Сагынуга түзәр идем.

4. Өстәлләргә алма куйдым
   Алып ашарсыз микән?
   Бик сагынып хатлар язсам,
   Сездә язарсыз микән?

Сания апа



1. Сания апа суга бара,
   Яшел чиләген асып.
   Сандугачлар чут-чут сайрый,
   Көянтәсенә басып.

2. Сания апа суга бара,
   Көянтәсе алмалы.
   Алмалы көянтәсенә
   Кунмаган кош калмады.

3. Сания апа суга бара,
   Алма-алма чиләге.
   Чиләгенә караганда,
   Үзе кура җиләге.

4. Сания апа, чиләгеңнән
   Суларың түгелмәсен;
   Башкалар сүзенә карап,
   Күңелең сүрелмәсен.

5. Кая бардың, Сания апа,
   Кайдан кайтып киләсең?
   Киләсең дә гел китәсең,
   Бик ямансу итәсең.

Сарман




1. Сандугачлар кунып кайда сайрый?
   Сарман буйларында тирәктә шул,
   Сарман буйларында тирәктә.
   Сиңа булган яшьлек мәхәббәтем
   Үрелеп чәчәк ата йөрәктә.

2. Сарман буйларыннан үткән чакта
   Тыңларсыңмы, җырлар җырлармын шул,
   Тыңларсыңмы, җырлар җырлармын.
   Күзләреңне тутырып карарсыңмы,
   Зәңгәр таудан яулык болгармын.

3. Сарман буйларында яшел алан,
   Печәннәре җитәр берзаман шул,
   Печәннәре җитәр берзаман.
   Кавышулары, иркәм, бик күңелле,
   Әмма аерылышу бик яман.

Сәрвиназ



1. Көн аяз, килә яз,
Чәчәккә күмелеп.
Син дә кил, Сәрвиназ,
Шатлыклы көн кебек.

2. Кил, иркәм, нур сыман
Балкып кил янына.
Ягымлы җыр сыман
Рәхәт бир җаныма.

3. Син килсәң, Сәрвиназ,
Күңелемдә җылы яз.
Шатлыгым, бәхетем зур,
Хәсрәтем, кайгым аз.

4. Кил, бәгърем, бергәләп
Кырларга чыгарбыз.
Илнең саф һавасын
Иркенләп сулырбыз.

Сибелә чәчем




1. Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
   Сибелә чәчем, тарала.
   Йә утка сал, йә суга сал,
   Йә кайгымнан арала.

2. Уйсу җирнең агым суы
   Ага икән таң белән.
   Узар, ахры, яшь гомерем
   Гел сагыш, гел моң белән.

3. Сандугачлар су эчәләр,
   Агыйделгә тезелеп.
   Нигә болай сагынам икән,
   Үзәкләрем өзелеп?!

Су буйлап




1. Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Караңгы төн, болытлы көн –
Без аерылган көн бит ул.

2. Идел бит ул – бик мул елга,
Ул бит диңгезгә китә.
Аккан сулар, искән җилләр
Йөрәгемне җилкетә.

3. Идел буйларына барсам
Әйтер идем Иделгә,
Минем кайгыларымны да
Алып кит, дип, диңгезгә.

4. Су буйлары моңсу иде,
Без айрылган чагында;
Тормыш дулкыннары безне
Кушар әле тагын да.

Су юлы



1. Су буенда акбүз атлар
Бар да каеш нукталы;
Сагынмам дип әйтмә, җаныем,
Сагынырсың, тукта әле.

Кушымта:
Ай, җаныем, су юлы,
Бик сагындым бу юлы.
Ай, җаныем, суларда,
Су чәчрәтеп уйнарга.


2. Суда сусар йөзә микән,
Сыртын суга салмыйча?!
Син бәгыремне сагынып көтәм,
Юлдан күзем алмыйча.

Кушымта.

3. Суда сусар йөзәдер,
Сулары сай булса да.
Бәгырем, хатлар язсана,
Өч кенә юл булса да.

Кушымта:
Ай, җаныем, су юлы,
Бик сагындым бу юлы.
Ай, җаныем, суларда,
Су чәчрәтеп уйнарга.

Талы, талы




1. Тал әйләнә, тал әйләнә,
Талга ефәк бәйләнә.
Күргәнче сүзем күп була,
Күргәч, телләр бәйләнә.
Талы, талы,
Талы бөгелеп тора;
Тагын бер күрәсе килеп,
Үзәк өзелеп тора.

2. Тал тирәкләр утыртканнар
Агыйдел читләренә.
Алсу алма суы тамган,
Бәгырем, битләреңә.
Талы, талы,
Талы бөгелеп тора;
Тагын бер күрәсе килеп,
Үзәк өзелеп тора.

3. Былбыл булсам, бакчаларда
Бер тирәк сайлар идем.
Шул тирәктә сине мактап,
Иртә-кич сайрар идем.
Талы, талы,
Талы бөгелеп тора;
Тагын бер күрәсе килеп,
Үзәк өзелеп тора.

Тәфтиләү

Г. Тукай сүзләре



1. И мөкатдәс, моңлы сазым!
   Уйнадың син ник бик аз?
   Син сынасың, мин сүнәмен,
   Айрылабыз, ахрысы!

2. Очты дөнья читлегеннән
   Тарсынып күңелем кошы,
   Шат яратса да, җиһанга
   Ят яраткан Раббысы.

Туган тел




1. И туган тел, и матур тел,
   Әткәм-әнкәмнең теле.
   Дөньяда күп нәрсә белдем
   Син туган тел аркылы.

2. Иң элек бу тел белән
   Әнкәм бишектә көйләгән,
   Аннары төннәр буе
   Әбкәм хикәят сөйләгән.

3. И туган тел! Һәрвакытта
   Ярдәмең берләп синең
   Кечкенәдән аңлашылган
   Шатлыгым, кайгым минем.

4. И туган тел! Синдә булган
   Иң элек кыйлган догам:
   Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
   Әткәм-әнкәмне, Ходам!

Фирдәвескәй




1. Кашың кара, буең зифа,
Керфегең бөгеләдер;
Синең өчен җанкисәгем,
Фирдәвескәй, кара күзкәй,
Үзәгем өзеләдер.

2. Каш карасы күзеңдә лә,
Буй зифасы үзеңдә.
Ай туганда тудың мәллә,
Фирдәвескәй, кара күзкәй,
Ай нуры бар йөзеңдә.

3. Кашың кара, күзең күк,
Сиңа сөйләр сүзем күп;
Сөйләр идем дә сүземне,
Фирдәвескәй, кара күзкәй,
Сирәк күрәм үзеңне.

Шахта



1. Китәм инде, китәм инде,
   Китәм инде Донбасска;
   Мин китәм инде Донбасска,
   Сүз бирдек ташлашмаска.


2. Шахтёр егет күмер кисә,
   Кемнәр ала исәбен?
   Гомерем бетеп, таш басмаса
   Ташламам, җанкисәгем.

3. Шахтёр кия шапкасын,
   Кулына ала лампасын;
   Көннәр буе җир астында
   Күрми дөнья яктысын.

4. Шахтёр егет ятып йоклый,
   Одеялын ябынып;
   Төннәр буе йоклый алмый,
   Туган илен сагынып.

Шома бас

Г. Насрый сүзләре



1. Уйнат, уйнат гармуныңны,
Биесеннәр егетләр.
Безнең илнең егетләре
Бары да бөркет кебекләр.
Их, шома басабыз,
Биеп күңел ачабыз.

2. Сайрат, сайрат гармуныңны,
Җилкенсеннәр яшь кызлар.
Безнең кызлар нурлы йөзле,
Әйтерсең лә йолдызлар.
Их, шома басабыз,
Биеп күңел ачабыз.

3. Шаулат, шаулат бию көен,
Ашыксыннар барсы да;
Яшь егетләр чакырсыннар,
Кызлар чыксын каршыга.
Их, шома басабыз,
Биеп күңел ачабыз.

4. Әйдә, әйдә, катырак бас,
Биегәнне күрсеннәр;
«Баскан җирдән ут чыгара
Безнең яшьләр», – дисеннәр.
Их, шома басабыз,
Биеп күңел ачабыз.

Ямьле Агыйдел буйлары




1. Агыйделкәйләрне, ай, кичкәндә,
Бер җырладым ишкәкләр ишкәндә.
Ямьле Агыйдел буйлары шул
Бетерәдер хәсрәтле уйларны.

2. Бер җырладым, бәгърем, бер еладым,
Туган җирләр искә лә төшкәндә.
Ямьле Агыйдел буйлары шул
Бетерәдер хәсрәтле уйларны.

КОМПОЗИТОРЛАР ӘСӘРЛӘРЕ

Аерылмагыз

Г.Зәйнашева сүзләре Ч.Зиннәтуллина музыкасы



1. Су буенда (күл өстендә) ялгыз аккош,
   Каерылган канатлары.
   Канатларны каера ул
   Аерылу газаплары.

Кушымта:
Аерылмагыз, аерылмагыз,
Булса да сәбәпләре.
Канатларны каера ул
Аерылу сәгатьләре.


2. Ят кошны пар итмәс аккош,
   Ялгыз канат какса да.
   Без дә бергә булалмабыз,
   Сулар үргә акса да.

Кушымта.

Аккошлар

Р.Фәйзуллин сүзләре

Ф.Әхмәтов музыкасы



1. Көзләрдән соң язлар килми,
   Алда – салкын, ак кышлар.
   Китәсез дә мени,
   Китәсез дә мени,
   Китәсез дә мени, аккошлар?

2. Әллә ничек үтте яшьлек,
   Соң очрашты язмышлар.
   Хушлашырга безгә
   Иртәрәк бит әле,
   Иртәрәк бит әле, аккошлар!


3. Бездә әле бу дөньяга
   Күңел тулы алкышлар.
   Китәсез дә мени,
   Китәсез дә мени,
   Китәсез дә мени, аккошлар?

Ак күлмәгем

Ш.Җиһангирова сүзләре

И.Дәүләтшин музыкасы

Уртача тизлектә



1. Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Бер киюдә каралттым.
Яратмавыңны белсәм дә,
Әллә нигә яраттым.
Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Итәге зәңгәр бизәк.
Каерылган кош канатыдай
Әрнеп өзелә үзәк.


2. Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Алларга манам инде.
Чәчәге сынган гөлләрдәй
Ялгызым калам инде.
Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Алмаштырмам карага.
Дөрли-дөрли янсын әйдә,
Сулар сипмә ярага.

3. Мин караны кими диеп,
Син дә акны киярсең.
Гомер узгач, күлмәк тузгач,
Бәлки син дә сөярсең.
Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Бер киюдә каралттым.
Яратмавыңны белсәм дә,
Әллә нигә яраттым.

Әгәр белгән булсам

Ш. Биккол сүзләре

Ә. Бакиров музыкасы



1. Кайгылар да баса алмас иде
Йөрәгемдә ташкан шатлыкны,
Әгәр белгән булсам (2 тапкыр)
Бу дөньяда синең барлыкны...


2. Алларыңа чыгып торыр идем,
Тик син булыр идең көткәнем,
Әгәр белгән булсам (2 тапкыр)
Сукмагыңның кайдан үткәнен...

3. Һичкемгә дә бүләк итмәс идем
Яшьлегемнең тәүге таңнарын,
Әгәр белгән булсам (2 тапкыр)
Сине очратачак таң барын...

Әйткән идең

Х.Туфан сүзләре

Ә.Бакиров музыкасы



1. Әйткән идең:
«Әгәр сөя калсаң
Миннән башка берәр бүтәнне,
Сөй... бары тик миннән яхшыракны,
Сөймә ләкин миннән түбәнне...»


2. Юлыктым мин,
Лулу, бер чәчәккә,
Көтмәгәндә, уйламаганда,
Нәкъ синдәйгә,
синең шикеллегә,
Әйтерсең лә синең дәвамга...

3. Тормышымның
синнән соңгысында
Тапканым юк иде һичкемне.
Нишләргә соң?
Бир бер киңәш миңа:
Ул һәръяктан синең шикелле.

4. «Нишләргә соң?» –
дигән сорау белән
Киләм менә рәсемең каршына...
Үзең булсаң әгәр,
мондый уйлар
Килер идемени башыма?!

Әйтмә син авыр сүз!

Р.Чурагулов сүзләре — Р.Хәким музыкасы



1. Беркайчан әйтмә син авыр сүз,
Бик кыска, әй, кыска гомерләр.
Син минем гомерлек юлдашым,
Син чәчкәм, йолдызым, сөйгән яр.

Кушымта:
Әйтмә син авыр сүз, әйтмә син!
Йөрәк бит болай да яралы.
Җырларны шаулатып җырлыйсы,
Гөрләтеп яшисе бар әле.

2. Бик авыр минутлар булса да
Тап миңа шулвакыт җылы сүз;
Авыр сүз әйтәсең килсә дә
Әйтмә син, сөеклем, әйтмә, түз!

Кушымта.

3. Иртәсен, кичен дә миңа син
Кызганма карашың җылысын.
Шул чакта сөюем артуын
Йөрәгең белән син тоярсың.

Кушымта.

Әлдермешкә кайтам әле

Т. Низами сүзләре

У. Рәшитов музыкасы



1. Сая елгалары ага,
   Текә ярларга тулып.
   Агар идем шул якларга,
   Чишмә моңнары булып.

Кушымта:
Кайтам әле Әлдермешкә,
Чишмәгә төшәм әле.
«Һаман сине сөям», – диеп,
Серемне чишәм әле.

2. Су чәчрәтеп уйнап үстек
   Сөйдеркә буйларында.
   Тере су тамчыларыдай
   Калдың син уйларымда.

Кушымта.

3. Эчсәң Сөйдеркә суларын,
   Сизмәссең дә салкынын.
   Яшәү көчең, дәртең артыр,
   Дөрләр йөрәк ялкының.

Кушымта.

4. Әлдермеш якларын бизи
   Мәхәббәт үзәннәре,
   Ут йөрәкле егетләре,
   Тиңдәшсез гүзәлләре.

Кушымта.

Әниемә

Г.Каербеков сүзләре
Г.Әхмәтҗанов тәрҗемәсе

Ш.Калдаяков музыкасы



1. Биргәнсең син миңа
ал нурын таңнарның,
Җыйгансың син миңа
бар гөлен даланың,
Биргәнсең канатлар
талпыныр чагымда,
Балалык рәхмәтем
җырымда чагыла.

Кушымта:
Кадерләп үстергән
мин синең җимешең,
Куеның – гөлбакча,
назлы җил – сулышың.

Инде буй җитсәм дә,
мин сиңа сабыймын,
Күңелең назларын
күзеңнән таныймын.

2. Боларга бәрабәр
ни генә бирәем,
Бердәнбер бүләгем –
тугры йөрәгем.
Итә күр канәгать,
риза бул шушыңа,
Үзеңә аталган
җырымны кушып ал.

Кушымта.


3. Бурычлы сиңа мин,
әнкәем-алтыным,
Сиңа дип эзләдем
дөньяның асылын.
Ай белән кояшны
бирим дип уйладым,
Үрелеп алырга
җитмәде буйларым.

Кушымта.

Әниемнең җылы кочагы

М. Мазунов сүзләре

Ә. Бакиров музыкасы



1. Сөекле әниемнең
Борчыгандыр җанын
Күңелемнең көйсез һәр чагы.
Еласам – юаткан,
Иркәләп уйнаткан
Әниемнең җылы кочагы.


2. Уйнаудан туйганда,
Талчыгып калганда,
Ял сорагач керфек очларым,
Җыр көйләп, тирбәтеп,
Йоклаткан изрәтеп
Әниемнең җылы кочагы.

3. Давыллы көннәрдә,
Ышыклап җилләрдән,
Күкрәгенә кыскан кем тагы?
Кадерләп үстергән,
Яшәргә көч биргән
Әниемнең җылы кочагы.

Әнкәй

Р.Миңнуллин сүзләре

С.Садыйкова музыкасы



1. Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,
   Сөн суында юган иң элек.
   Бишек җырын җырлап төннәр буе,
   Без үскәнне көткән тилмереп.

Кушымта:
Без биш бала үстек әнкәй белән,
Тик үсмәдек иркә кочакта.
Без әнкәйнең биш шатлыгы идек,
Биш кайгысы булдык кайчакта.

2. Без үскәндә күпме борчылулар
   Күргән әнкәй гомер эчендә.
   Онытмабыз, әнкәй, мәңге сине,
   Рәхмәт яусын барысы өчен дә.

Кушымта.

3. Хәзер инде җиткән балалар без,
   Кунак кына әнкәй янында.
   Әнкәйләрнең олы йөрәгенә
   Изгелекнең сыйган барсы да.
   Санап кына бетерерлек түгел
   Әнкәйләрдән күргән игелек.
   Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,
   Сөн суында юган иң элек.

Бәхет

Ә. Атнабаев сүзләре А. Монасыйпов музыкасы




1. Минем белән бергә бәхтем туган –
Өлешемә тигән көмешем.
Шул бәхтемне эзләп, юлга чыктым,
Шул бәхтемне эзләп килешем.
Шул бәхтемне эзләп тапканым юк,
Инде таптым дисәм – югалтам.
Якын дустым – мескен өмет белән
Үз-үземне тагын юатам.
Якын дустым – мескен өмет белән
Үз-үземне тагын юатам.

2. Юлларымда бәхет күп очрады,
Тик берсе дә түгел минеке.
Юл чатында әнә көтеп торган
Ул аныкы яки синеке.
Ә минеке, бәлки, мине көтеп,
Кайгырадыр әллә кайларда...
Ул бәхетсез икән, мин бәхетсез,
Мин табарга тиеш, табарга!
Ул бәхетсез икән, мин бәхетсез,
Мин табарга тиеш, табарга!

3. Минем белән бергә бәхтем туган –
Өлешемә тигән көмешем.
Шул бәхтемне эзләп юлга чыктым,
Шул бәхтемне эзләп килешем.
Шул бәхтемне эзләп китеп барам,
Юлым сикәлтәле, әремле...
Җиңел килгән бәхет – бәхет түгел,
Эзләп тапкан бәхет кадерле
Җиңел килгән бәхет – бәхет түгел,
Эзләп тапкан бәхет кадерле.

Беренче мәхәббәт

Ә.Рәшитов сүзләре С.Садыйкова музыкасы



1. Хәтердә ул тыныч айлы кичләр,
Хәтердә бормалы су юлы.
Онтылмый беренче саф мәхәббәт,
Онтылмый Агыйдел сылуы.


2. Ул мине утларда яндырды да,
Тилмертте аерылу газабы.
Нигә соң чәчәктәй яшь гомернең
Кавышу булмады азагы?

3. Юлларда киртәләр очратсагыз,
Күңелегез булса да яралы,
Сез искә алыгыз яшьли сөйгән,
Беренче яраткан ярларны.

Бик сагындым, авылым

М.Латыйфуллин сүзләре

Р.Сафиуллин музыкасы



1. Туган як, көн саен
Искә төшәсең;
Күңелемнән чыкмыйсың,
Төшкә керәсең.
Сагындым, сагындым,
Бик сагындым
Без үскән авылның
Айлы тын кичләрен,
Былбыллы бакчаның
Шомырт исләрен.

2. Онытalмыйм камышлы
Аккош күлләрен,
Битемнән иркәләп
Искән җилләрен.
Сагындым, сагындым,
Бик сагындым
Без үскән авылның
Хуш исле урманын,
Кырларда сайраган
Сабан тургаен.

3. Күңелем ашкына
Туган якларга,
Йөрергә җиләкле
Яшел аланда.
Сагындым, сагындым,
Бик сагындым;
Йөрәгем җилпенеп
Көтә таң атуын.
Кыр казы шикелле
Очып кайтырмын.

Гармунчы

Г.Зәйнашева сүзләре

З.Гыйбадуллин музыкасы

Уртача тизлектә



1. Нихәл итим, гармунчыбыз
Гашыйк булды үземә;
Гармун уйнарга онытып,
Карап тора күземә.
Дөньясын онытып йөри,
Уйлап гел минем хакта.
Кичә гармунын онытkан
Концертка килгән чакта.

2. Әйтәм инде, иркәм, димен,
Гел мине уйлап йөрмә.
Гел мине уйлап йөреп, син
Концертны өзә күрмә.
Яшь кенә егет булса да
Хәтере юк иркәмнең;
Онытмаса ярар иде
Миңа гашыйк икәнен.

3. Абау, бәгырем, гармунының
Ялтырый сәдәпләре.
Гармуны да үзе кебек –
Бар сәер гадәтләре.
Кызлар күңелен җилкетеп,
Ялтырап балкып тора.
Эчендә магниты бардыр,
Үзенә тартып тора.

Гөлләр иле

Г.Зәйнашева сүзләре С.Шәмсина музыкасы



1. Туган ягым – гөлләр иле,
Гөлләр, сөмбелләр иле.
Гөлгә кунып сайрап кына
Үскән былбыллар иле.

Кушымта:
Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.

2. Туган ягым – гөлләр иле,
Гөлгә тиң таллар иле.
Ефәк кебек сызылып кына
Аткан ал таңнар иле.

Кушымта.


3. Туган ягым – гөлләр иле,
Борынгы Болгар иле.
Бүген көрәштә, хезмәттә
Җиңгән батырлар иле.

Кушымта:
Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.

Гүзәлия җыры

(«Утлар яна учакта» пьесасыннан)

С.Сөләйманова сүзләре М. Имашев музыкасы



1. Таң атканда уйланам,
Су акканда моңланам.
Таң нурында син йөзәсең,
Утларында мин янам.

2. Биек тауга менимме,
Агым суга керимме?
Дусларыма сөйлим микән,
Үзем генә белимме?

3. Таулар текә, су тирән,
Тирән булса да керәм.
Ерак икәнен дә беләм,
Нигәдер якын күрәм!

Җидегән чишмә

Г.Бәширов сүзләре

С.Садыйкова музыкасы



1. Җидегән чишмәләрдә
   җиде улак, җиде улак,
   Челтер-челтер ага көмеш су.
   Көмеш сулар ага, кошлар сайрый,
   Шул чакларда бигрәк,
   Шул чакларда бигрәк ямансу.

2. Җидегән чишмәләргә
   йөзек салдым, йөзек салдым,
   Җидегән йолдыз күреп калсын, дип.
   Җанкай-җанаш алсын да куансын,
   Вәгъдәләрем булып,
   Вәгъдәләрем булып калсын, дип.

3. Җидегән чишмәләргә
   чиләк куйдым, чиләк куйдым,
   Пар чиләгем тизрәк тулсынга.
   Без сөябез, җаный, яр булсынга,
   Без йөрмибез вакыт,
   Без йөрмибез вакыт узсынга.

4. Җидегән чишмәләрнең
   талы бөгелә, талы бөгелә,
   Акрын искән җәйге җилләргә.
   Сез каласыз инде, без китәбез,
   Без китәбез ерак,
   Без китәбез ерак илләргә.

Җиз кыңгырау моңнары

Ә. Атнабаев сүзләре — В. Хәбисламов музыкасы




1. Урап-урап карлар күмә
Кышның озын юлларын,
Чың-чың итә, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын.
Җиз кыңгырау, көмеш моңнар
Уйлата синең хакта,
Синең хактагы уйларым
Яшьлеккә алып кайта,
Уйлата синең хакта.

2. Чың-чың итә, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын.
Кая алып бара икән
Кышкы озын юлларым?
Җиз кыңгырау моңнарында
Үткәннең тавышлары,
Очрашулар, кавышулар,
Аерылу сагышлары,
Үткәннең тавышлары.

Җиз кыңгырау тагып кына,
Атларда чабып кына,
Килер идем яшьлегемнән
Тик сине алып кына,
Атларда чабып кына.

Йәнбикә[1]

Р. Сафин сүзләре — Ш.Колбарисов музыкасы



1. Базарларга барсаң, ак тула ал,
Хаккынасын үзем түләрмен.
Әҗәлләрең җитсә, әйт үземә,
Йәнбикәм, Йәнбикәм,
Синең өчен үзем үләрмен.


2. Урманнарга керсәм адашмамын,
Менгән атым акбүз ат булса.
Авыр юллар үтеп, мин кайтырмын,
Йәнбикәм, Йәнбикәм,
Көтәм дигән сүзең хак булса.
Сөям дигән сүзең хак булса.

[1] Җыр текстының башка варианты да бар.

Казан кичләре

Х. Туфан сүзләре

С. Садыйкова музыкасы



1. Кил әле, Иделнең җиләс җиле,
Юлларга чәчәкләр сип әле.
Ак булып, саф булып
истә калсын
Казанның кадерле кичләре.

2. Туган ил чакырган зур юлларга
Китәрбез таңнарда без моннан.
Озатып калырсың безне, Казан,
Баласын очырган кош сыман.


3. Яшәрбез туган җир туфрагында,
Кырларда, Иделдә-диңгездә.
Исән-сау булсыннар
балалар, дип,
Хәерле юл телә, Ил, безгә.

4. Иделгә сузылган айлы юлдан
Тын гына, моң гына җыр ага.
Сагынырбыз, дуслар, бу кичләрне
Чәчләргә чал кергән чорда да.

5. Ал гөлләр сибегез безнең юлга,
Иделнең иртәнге җилләре.
Мәңгегә, гомергә истә калсын
Казанның кадерле кичләре.

Картаямыни соң йөрәк?!

Г.Нуруллин сүзләре — С.Ибраһимов музыкасы



1. Әкрен генә, сиздермичә,
Яшьлек гомерем үтә.
Күңелем бер дә картаймый,
Һаман да нидер көтә.

Кушымта:
Картаямыни соң йөрәк,
Маңгайлар сырланса да.
Үтте яшьлек-жүләрлек, дип,
Жырларда жырланса да.

2. Нигә соң болай үземне
Канатлыдай хис итәм?!
Әллә яшьлегем кичләре
Әйләнеп кайтты микән?

Кушымта.

3. Мәхәббәт яшьләрдә, диләр,
Була ул һәркемдә дә.
Мәхәббәтсез яшәп булмый
Олгайган көннәрдә дә.

Кушымта.

Кемгә салыйм башны таңнарда?

Г.Ахунов сүзләре М. Имашев музыкасы



1. Көтмәгәндә килде бу кайгылар,
Көтмәгәндә килде бу сагыш.
Күңелемдә минем әрнү, ярсу,
Ник аяусыз икән бу язмыш?

Кушымта:
Ник ашыктым, үземә тиңне
Ник табалмадым?
Дусларымнан тик бер киңәш
Ник сорамадым?


2. Дәрья суы ярсып чайкалганда,
Дулкыннары кага ярларга.
Синнән башка кешем юк шул,
Кемгә салыйм башны таңнарда?

Кушымта.

Кошларым

Н. Йосыпова сүзләре

В. Әхмәтшин музыкасы




1. Кайткан кошларым, кабат китмәгез,
Ерак илләрдә иркен, димәгез.
Туган ил ямьле, сулары тәмле,
Сызылып аткан таңнары ямьле.

2. Китәсе булгач, нигә кайтасыз,
Ерак илләрдә туктап каласыз.
Туган илемдә үскән кошларым,
Шатлык көенә мәңге сайрагыз!

3. Киткән кошларым кабат кайтырлар,
Зәңгәр күкләрдә канат кагарлар.
Канат кагарлар, туктап сайрарлар,
Туган илкәйне алар сагыналар.

Кичер мине, әнкәй, гафу ит

Г. Идрисов сүзләре Р. Хәсәнов музыкасы



1. Кайтырмын дип, хатлар язуыма
Көннәр түгел, айлар үттеләр;
Әмма юлларым, сиңа илтмичә,
Еракларга алып киттеләр.

Кушымта:
Бер кайтмасам, әнкәй, бер кайтырмын,
Утыңны сүндермичә, мине көт;
Сине көттереп тә кайталмасам,
Кичер мине, әнкәй, гафу ит.

2. Көтәсеңдер син мине, кайтыр дип,
Тезелешеп кошлар кайтканда;
Улым, дип, син ишек ачасыңдыр,
Көзге җилләр тәрәз какканда.


Кушымта.

3. Көтәсеңдер хат ташучы килсә,
Кош теледәй сәлам бардыр дип;
Хат булмаса, өмет итәсеңдер:
Иртәгә, бәлки, булыр дип.

Кушымта:
Юлга чыгам, әнкәй, кайтыр юлга,
Утыңны сүндермичә, мине көт;
Шушы юлда тагы озакласам,
Кичер мине, әнкәй, гафу ит.

Кукмара

Г.Зәйнашева сүзләре М.Имашев музыкасы



1. Каршы ала, озатып кала
Поездларны Кукмара.
Поездлар ерак китсә дә
Ерагаймасын ара.

Кушымта:
Их, Кукмара, Кукмара,
Ерагаймасын ара.
Сагынырсың, саргаерсың,
Читләргә китеп кара.

2. Ярсып поездлар узганда
Тетрәп кала таулары.
Җәйге таңда үзәкне өзә
Сандугач сайраулары.

Кушымта.

3. Туган җирнең бик күңелле
Бер төбәге Кукмара.
Кукмара кешеләренең
Эшләре гөрләп бара.

Кушымта.

Күл буена килсәң иде

Г.Зәйнашева сүзләре

З.Гыйбадуллин музыкасы



1. Ялгыз үскән бер төнбоек
Тирбәлә суда.
Төнбоек та сине сагына,
Сине юксына.
Күл буена килсәң иде,
Уйларымны белсәң иде;
Ялгыз төнбоек шикелле
Юксынам сине.

2. Бөдрә таллар яшел ефәк
Күлмәген кигән.
Таллар да, никтер моңаеп,
Башларын игән.
Күл буена килсәң иде,
Уйларымны белсәң иде;
Башын игән тал шикелле
Юксынам сине.

3. Кыр үрдәкләре кычкыра
Куе камышта.
Зифа буйлы камышлар да
Төшкән сагышка.
Күл буена килсәң иде,
Уйларымны белсәң иде;
Зифа камышларга карап
Юксынам сине.

Кыр казлары киткәндә

Р.Гәрәй сүзләре

Ә. Бакиров музыкасы

Уртача тизлектә



1. Кыр казлары оча җылы якка,
   Күз күрмәгән ерак җирләргә.
   Тын һавада моңсу тавышлары
   Сәлам булып җилдә тирбәлә.

2. Саубуллашу җиңел дигән сүзне
   Ишетмәдем әле беркемнән.
   Бер кыр казы калган аерылып
   Үзе очып килгән төркемнән.

3. Иптәшләрен куып җитәлмәсә,
   Ялгыз башы кая сыеныр?!
   Аңа карап тирән уйга чумдым:
   Туган җирсез яшәү кыендыр.

Кышкы романс

Н. Нәҗми сүзләре

Р. Хәсәнов музыкасы



1. Акты ташып, акты ярсып
кар сулары,
Шулдыр инде язның
ташып ярсулары.
Акты безнең кар өстендә калган эзләр,
Акты елап, икәү бергә
салган эзләр.

Кушымта:
Син – гомер агышларым,
Син – минем сагышларым,
Син – минем шатлык идең,
Югалту, табышларым.
Син – минем сагышларым.

2. Язлар килә, язлар китә, сулар ага,
Көннәр ага, айлар ага, еллар ага.
Суларның да, айларның да,
елларның да
Агышыннан эзләр кала, эзләр кала.

Кушымта.


3. Менә инде тагы җиргә карлар ява,
Бөтен нәрсә туңган төсле
кар астында.
Ага сулар, айлар ага, еллар ага,
Сине күрәм айлар, еллар карашында.

Кушымта.

Оныттың бугай

Г. Рәхим сүзләре

Г. Ильясов музыкасы



1. Сине уйласам, мине моң баса,
Борчылып йөрим инде ничә ай.
Күңелем сизә, назлы язларны
Оныттың бугай, оныттың бугай.


2. Ераста калды, дәртләнеп, ярсып,
Без җырлап үткән ул яшел тугай.
Кабатлап булмый торган чакларны
Оныттың бугай, оныттың бугай.

3. «Сөй!» – дип үтенмим, ләкин үкенмим
Яшьлектә сине сөйгәнгә шулай.
Син мине түгел, яшьлекнең үзен
Оныттың бугай, оныттың бугай.

Сагыну җыры

Г. Идрисов сүзләре

Р. Хәсәнов музыкасы




1. Ак чәчәкләр кебек кар ява,
   Хәтерләтеп ямьле май кичен,
   Шомырт чәчәк аткан тугайда
   Йөргән идек икәү нур кичеп.

2. Тормыш юлларыбыз шул кичтә
   Аерылды төрле якларга;
   Ә шулай да иркәм гел истә,
   Алыштырмам аны ятларга.

3. Араларда озын юллар бар,
   Үләр идем дә бит арымый,
   Күрешергә ничә еллар бар,
   Ничек түзәрмен соң сагынмый.

Сандугач керде күңелгә

Р. Әхмәтҗанов сүзләре — И. Хәбибуллин музыкасы



1. Мәхәббәт мәхәббәт инде,
Кайларга куйыйм аны?
Авырмыни сагынырга
Өзелеп сөйгән ярны?

Кушымта:
Талларга качты сандугач –
Мин аны эзлиммени?
Сандугач керде күңелгә –
Жырламый түзиммени?!

2. Синең күлмәгең алсу дип,
Кызарып торыйммыни?
Яратам диеп әйтергә
Рөхсәтләр сорыйммыни?

Кушымта.

3. Сандугачларны ишетми
Йөримме карурманда?
Тамчылар күрмиммени соң
Шаулап яңгыр яуганда?

Кушымта.

Сәяхәтче җыры

Г.Зәйнашева сүзләре — З.Гыйбадуллин музыкасы




1. Таныш түгел юллар буйлап
Мин озак йөрдем.
Туган ягым күренерме дип,
Тауларга мендем.
И гүзәл туган ягым,
И ямьле туган ягым,
Тау башында бакча булып,
Төшемә кердең.

2. Туган яктан ерак китеп,
Диңгезләр кичтем.
Сагыш дигән тирән күлнең
Суларын эчтем.
И гүзәл туган ягым,
И ямьле туган ягым,
Тальян гармун моңы булып,
Җырыма күчтең.

3. Туган яктан ераста да
Дуслар очраттым.
Ләкин яшьлек дустым калган
Илемә кайттым.
И гүзәл туган ягым,
И ямьле туган ягым,
Бәхетемне читтә түгел,
Мин синдә таптым!..

Син кайтмадың

С. Урайский сүзләре М. Мозаффаров музыкасы



1. Бакчаларда гөлләр чәчәк атты,
Тормышыбыз кебек ямьләнеп.
Урман күлләренә аккош кайтты,
Сандугачлар килде әйләнеп.

2. Сандугачлар килде, аккош кайтты,
Син кайтмадың киткән җиреңнән.
Аккош китәр урман күлләреннән,
Син китмәссең минем күңелемнән.

3. Дошман явын тар-мар иткән чакта,
Йөрәгеңнән кайнар кан тамды.
Үзең үлсәң, матур исемең калды,
Киң Ватанга даның таралды.

Синең өчен

Ж.Дәрзаман сүзләре — Г.Ильясов музыкасы



1. Синең өчен һәрчак аяз,
Зәңгәр һава,
Синең өчен сәйләп сыман
Карлар ява.
Сәйләп карлар бар хәятне
Били акка –
Табигатьне сафлык күмә
Синең хакка.

Кушымта:
Елга, тугайлар – синең өчен,
Кырлар, тургайлар – синең өчен,
Җир һәм йолдызлар – синең өчен,
Сөюең калсын минем өчен.

2. Таң кояшы нурлар сибеп
Көлгән чакта,
Күңелемдә җырлар туа
Синең хакта.
Җырлар илтсен сиңа минем
Назларымны,
Илтсен сиңа назлар тулы
Язларымны.

Кушымта.


3. Синең өчен ал гөлләрем
Чәчәк ата,
Синең өчен сайрап туймый
Сандугач та.
Исемең яңгырый бер моң булып
Тирә-якта –
Мин бәхетле бу дөньяда
Син бар чакта.

Кушымта.

Сине уйлап янам

И. Юзеев сүзләре

С. Ибраһимов музыкасы



1. Җәйләүләрдә тугай,
Тугайларда тургай
Җилләргә лә каршы баралмый.
Сине уйлап янам,
Ник килмисең һаман,
Күңелем эзли сине, табалмый.


2. Карурманга таба
Чишмә чыңлап ага,
Җил көчәйтә аның агышын.
Мин утырам тыңлап,
Шул сулардай чыңлап,
Агып китәр микән сагышым?

3. Җәйләүләрдә тугай,
Тугайларда тургай
Канатларын җилпи җилләрдә.
Сине уйлап янам,
Ник килмисең һаман,
Күңелләрең синең кемнәрдә?

Сок буйлары

Һ.Сафина сүзләре

М. Имашев музыкасы



1. Кояш баткан чакта, Сок буенда
Синең җырларыңны җырладым.
Сайравыннан туктап, сандугач та,
Сандугач та сагынып тыңлады.

2. Сокның дулкыннары алып китте
Синең тарафларга моңымны.
Әллә кайтасыңмы туган якка?
Сок буйлары көтә җырыңны.

3. Иңнәреңнән кочып, тал-тирәкләр
Минем хисләремне сөйләрләр.
Күзләреңнән үбеп, ал чәчәкләр:
«Ул бит көтте сине», – диярләр.

Солдатым

М.Нигмат сүзләре С. Садыйкова музыкасы



1. Кыр казлары китте
Диңгез буйларына,
Кыр казлары китте тезелеп.
Син дә, бәгърем, киттең,
Бик ямансу иттең,
Мин озатып калдым өзелеп.

2. Карлы салкын кышта,
Торасыңдыр постта,
Уйлыйсыңдыр туган якларны.
Ә мин иртә-кич тә,
Онытмыймын һич тә
Бергә йөргән матур чакларны.


3. Хатлар язам сиңа,
Сәлам юллыйм сиңа,
Таң җилләре тизрәк илтсеннәр.
Нык бул хезмәтеңдә,
Мәхәббәтең көн дә
Сине генә көтә, дисеннәр.

4. Айлар агылып үтәр,
Кайтыр көнең җитәр,
Тормышыбыз матур, илдә тын.
Күрешербез тиздән,
Бәхет китмәс бездән,
Зифа буйлы батыр солдатым!

Соңлама, кил инде

Р. Янбулатова сүзләре

Б. Гайсин музыкасы



1. Ак чәчәк ата балан,
   Күмелгәч гөлгә алан.
   Яшь йөрәк еш тибә,
   Искән җилләр миңа:
   «Сөйгәнең килә», – дисә.

Кушымта:
Кил, кил, кил,
Кил, иркәм, мин көтәм.
Соңлама, кил инде,
Елмаеп көл инде,
Сагындым, бәгърем, сине.

2. Алып кил син, дускаем,
   Сандугач тавышкаен,
   Мәхәббәтнең сафын,
   Энҗеләргә хасын,
   Алып кил, аккошкаем.

Кушымта.

Сыерчыклар

Р. Мөслимов сүзләре

Р. Хәсәнов музыкасы



1. Өметем өзелгәч,
Кайгыдан түзмәдем,
Нишләргә белмичә,
Киңәшче эзләдем.
Сез очып кундыгыз
Тәрәзәм төбемә,
Китәбез инде, дип
Әйттегез үземә.

Кушымта:
Сыерчыклар, сыерчыклар,
Канатлы дусларым,
Бирегез киңәш сез!
Ярамны төзәтми,
Ник ташлап китәсез?

2. Көзләрен моңаеп,
Мин сезне озатам.
Килерсез әле дип,
Күңелне юатам.
Киткәндә ераккә
Алыгыз искә сез;
Мин калдым бу якта
Ялгызым, иркәсез.

Кушымта.

Тагын, тагын, тагын да

М.Латыйфуллин сүзләре С. Ибраһимов музыкасы



1. Үрмә гөлләр утырттым мин
Зәңгәр Идел ярында.
Гөрләп торсын диеп тормыш
Тагын, тагын, тагын да.

2. Гөлләр үсте, кил син, бәгърем,
Сүнмәс яшьлек таңында,
Иркәләрсең син аларны
Тагын, тагын, тагын да.

3. Булса идем зәңгәр чәчәк
Син үрелгән чагында,
Шаулар иде, яшьлек таңым
Тагын, тагын, тагын да.

Тамчылар

Г. Зәйнашева сүзләре

А.Монасыйпов музыкасы



1. Тамчылар, тамчылар!
Әйтегезче, тамчылар!
Нигә язгы кичләрдә
Яшь йөрәкләр ярсыйлар?..
Нигә язгы кичләрдә
Яшь йөрәкләр ярсыйлар?..

Кушымта:
Тамчылар, тамчылар,
Җырлый-җырлый тамасыз;
Илдә туган яз шатлыгын
Матур көйгә саласыз.

2. Тамчылар, тамчылар!
Юрагызчы, тамчылар!
Бу матур язда мине
Нинди бәхет каршылар?..
Бу матур язда мине
Нинди бәхет каршылар?..

Кушымта.

3. Тамчылар, тамчылар!
Беләсезме, тамчылар?!
Яз җиткәч, яшь йөрәкләр
Бәхет көтеп ярсыйлар.
Яз җиткәч, яшь йөрәкләр
Бәхет көтеп ярсыйлар.

Кушымта.

Тамчы гөл

Р.Зарипов сүзләре

Р.Зарипов музыкасы



1. Сөңге бозлардан тамчы коела,
Тал бөресенә кошлар сыена.
Тамчы гөлләрдәй сылу елмая,
Ашкына күңел, белмим мин, кая?

Кушымта:
Тамчы гөл, тамчы гөл,
тамчы гөл,
Ә-ә-әй тамчы гөл.
Сине уйласам өзелә күңел,
Өзелә күңел, тамчы гөл.

2. Кояш елмая, кырлар карала,
Бозларда ярсып учаклар яна.
Арада дәрья, син аргы ярда,
Ашкына күңел синең яныңа.


Кушымта.

3. Гөрләвек ага җиргә сарылып,
Чуер ташларның битләрен юып.
Тамчы гөлләр дә сине сагына,
Кайт, чибәрем, кайт минем яныма.

Кушымта.

Туган авылым

Н.Иделбай сүзләре Т.Шәрипов музыкасы




1. Туган авылым минем,
Куеныңда синең
Гөрләп үтте үсмер елларым.
Кырларың хуш исле,
Һәрчак язлар төсле,
Шунда туды тәүге җырларым.

2. Инеш буең ямьле,
Суларың да тәмле,
Җилләрең дә назлы, ягымлы.
Айлы кичләрең дә
Әле исләремдә, –
Яратам мин туган ягымны.

3. Яланнарың иркен,
Авылымның күрке –
Сызылып аткан алсу таңнарың,
Һаман синдә күңел,
Онытырлык түгел
Сайрар кошларыңның моңнарын.

Туган җирем – Татарстан

Г. Зәйнашева сүзләре А.Ключарёв музыкасы



1. Идел ярларына нурлар сибеп,
Матур булып ата бездә таң.
Таң шикелле якты Туган илем,
Бәхет биргән җирем – Татарстан.
Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым
Иделем таңнарын.


2. Биш диңгезгә карап елмайгандай
Балкый безнең Казан ерактан.
Коры җирне шаулы диңгез итә
Хезмәт сөйгән халкың, Татарстан.
Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым
Иделем таңнарын.

3. Күпме җырлар җырлый халкым бүген,
Туган җирем, синең турында.
Мин бәхетле сине сөюемне
Әйтә алсам шушы җырымда.
Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым
Иделем таңнарын.

Туган җиремә

Г.Зәйнашева сүзләре

З.Гыйбадуллин музыкасы




1. Тугай ярып аккан чишмәләр кебек,
Саф хисләрем җырыма талпына.
Җырым кайнар чишмә булса,
Татлы суын үзем эчми,
Бирер идем хезмәт сөйгән халкыма!

2. Һәрбер шатлык кояш нурлары булып
Үрли минем күңелем түрендә.
Йөрәк җырларым да шулай
Кояш кебек якты нурлар
Сипсен иде туып үскән җиремә!

Туй күлмәге

М. Шиһапов сүзләре М. Имашев музыкасы



1. Килү белән язлар,
   һәр кич назлап,
   Пар сандугач жырын тыңладык.
   Язлар бәхет бүләк итте безгә,
   Туй күлмәген алдык нәкъ шул көздә,
   Тик киергә насыйп
   булмады.


2. Мин еш киләм чишмә
   аккан жиргә –
   Яшьлек эзем, татлы хыялга.
   Чишмә ага чакрымнарын иңләп,
   Минем хисләр без танышкан жирдә;
   Ник килмисең, иркәм,
   шул ярга?

3. Яшьлегемә кире кайтыр идем,
   Кабатланмас булса ялгышлар.
   Башкаларны йөрәк кабул итми,
   Күз алдымнан буй-сыннарың китми,
   Күңелемдә әрнү, сагышлар.

4. Чишмә жыры бик ямансу була,
   Бигрәк моңсу була көзләрен.
   Януларым, көюләрем белән
   Сагынганда туй күлмәген киям,
   Һәм юлларда була күзләрем.

Утыр әле яннарыма

Ш.Галиев сүзләре — И.Хисамов музыкасы




1. Оныт мәшәкатьләреңне,
Оныт инде беразга,
Сыйпап-сыйпап чәчләремне,
Бер иркәлә, бер назла.
Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма.

2. Йөзләреңә төбәп карап,
Килә бер сөенәсем,
Килә бер иркәләнәсем,
Килә бер сөеләсем.
Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма.

3. Күзләремә ашыгып кына
Салкын карап үтмә син;
Өстәп тор сөю ялкынын,
Гел өсти тор, бетмәсен.
Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма.

Үз илемдә

Г. Зәйнашева сүзләре С.Садыйкова музыкасы



1. Яз да сайрый, көз дә сайрый
Бер нәни кош бакчамда.
Шул кошны сагынып кайтам,
Кая гына барсам да.

2. Бакчам гади, үсми анда
Кипарислар, хөрмәләр.
Миңа таллар кипаристан
Матуррак күренәләр.


3. Исем китми читтә үскән
Әфлисунга, бананга.
Ачы булса да, гашыйк мин
Миләш белән баланга.

4. Мин гашыйк илемдә үскән
Талларның барчасына.
Үз илемдә ямьле миңа
Бәрәңге бакчасы да.

Хуш инде

И.Юзеев сүзләре

Ф.Мортазин музыкасы



1. Хуш инде, мәңгегә
Хуш инде.
Китә яз, китә наз —
Кыш инде.
Тагын бер текәлеп
Карыймчы,
Рәсемеңне күңелемә
Алыймчы.


2. Ул китә, мәңгегә
Дип китә.
Соң килде мәхәббәт, —
Ник китә?
Чаналар кузгалып
Киттеләр,
Йөрәкне өздереп
Үттеләр.

3. Эзләрен кар-буран
Сылады.
Юлларга җил ятып
Елады.
Хуш инде, мәңгегә
Хуш инде.
Үтте яз, буранлы
Кыш инде.

Хушлашырга ашыкма

Ф.Сафин сүзләре

Р.Гатауллин музыкасы



1. Хушлаштың да китеп бардың,
   Аерылу авыр бит...
   Күзләреңнең нурын
   Йөрәгемә салыйм,
   Тукта, дустым, сабыр ит!

2. Гомер буе ярсу йөрәк
   Сине сагынып сулкылдар.
   Иделләрдә дулкын, –
   Чү, ашыкма, дустым!
   Күңелдә ул дулкыннар!..

3. Сайрар кошлар синсез нишләр,
   Ничек агар бу сулар?
   Урман ничек шаулар,
   Ишелмәсме таулар?
   Икебез дә моңсулар...

Һаман да көтәсең

Р. Закиров сүзләре С. Ибраһимов музыкасы



1. Бер кайтырбыз, диеп киткән юлдан
Китсәләр дә, алар кайтмады.
Алар өчен бары җилләр генә (3 тапкыр)
Ачып-ябып йөрде капканы.

2. Алар өчен янды ялгыз гына,
Күз нурларын сирпеп еракка.
Тик ил өчен, геройларча, дигән (3 тапкыр)
Хәбәр генә кайтты бу якка.

3. Хәбәр генә кайтты бу якларга
Ядкарь булып газиз анага...
Һәм ир даны кайтты югалмыйча, (3 тапкыр)
Мәңгелек ут булып янарга.

Чыгарсыңмы каршы алырга?

Д. Гарифуллин сүзләре

В.Әхмәтшин музыкасы




1. Тыңларсыңмы яшьлек хисләремне,
Җырларыма кушып җырласам?
Каршы төшмәссеңме, йөрәгеңне
Мәхәббәтем белән чорнасам?
Минем белән тормыш сукмагыннан
Риза булырсыңмы үтәргә?
Аерылганда вәгъдә бирерсеңме
Кабат кайтуымны көтәргә?

2. Ашкынулы йөрәк көтә көн дә
Уртак таңның сызылып атканын.
Яшьлегемне җырга салган чакта
Кушылып җырларсыңмы, аппагым?
Кайткан чакта Сарман буйларына
Яннарыңда мәңге калырга,
Кырык эшең ташлап кырык якка,
Чыгарсыңмы каршы алырга?

Ялгыз аккош күлләрдә

Р.Ханнанов сүзләре Р.Хәсәнов музыкасы



1. Күл өстендә ялгыз аккош йөзә.
   Нигә ялгыз, нигә пары юк?
   Парсызларның күңелләре моңлы,
   Парлыларның гына зары юк.

Кушымта:
Минем дә бар иде аккошкаем,
Җан дускаем, очар канатым.
Әллә инде артык яратканга,
Юлларымда аны югалттым.

2. Парсыз калса кабат кайтмый, диләр,
   Кайта икән, кайта аккошлар.
   Кошларны да, кешеләр шикелле,
   Үзе белән йөртә язмышлар.

Кушымта.

3. Төннәрендә йөрәк өзгеч тавыш
   Телеп үтә күлнең өсләрен.
   Аңлау өчен аккош сагышларын,
   Белү кирәк сөю телләрен.


Кушымта.

Ялгыз көймә

Ф.Сафин сүзләре

Р.Гатауллин музыкасы

Хәрәкәт белән



1. Берни сорама, тын гына
Күземә кара, ярым:
Күзләрдән дә белеп була
Күңелдә ниләр барын.

Кушымта:
Ялгыз көймә бөтерелә
Һәм чайкала Иделдә.
Зур дулкыннар күтәрелә
Күңелемдә минем дә!

2. Синең өчен диңгезләрне
Кичәргә дә әзермен! –
Дигән идең, әллә шул сүз
Хак булганмы, кадерлем?..

Кушымта.


3. Җанда дулкын, сүзсез сорау:
– Ник йөрәкләр ялгышты?
Тик сабырлык җиңә ала
Хәзер безнең сагышны!

Кушымта.

Яшь гомер

Г. Зәйнашева сүзләре — З.Гыйбадуллин музыкасы

Вальс темпында




1. Яшь гомер бер узгач
Кайтмый ул яңадан.
Тик минем яшьлек никтер кайтыр кебек;
Яшьлектә сөйгән яр,
Сагындым, килеп ал,
Сине көтәм һаман,дип әйтер кебек.

2. Юк, кайтмас яшь гомер,
Калды ул ераста,
Зәңгәр томан артында сагыш булып;
Яшьли сөйгән яр да
Ятка калды анда,
Әллә язмыш, әллә бер ялгыш булып.

3. Ялгышны төзәтеп,
Язмышны үзгәртеп
Яшәсәң, яшьлек кире кайтыр кебек;
Яшьлек бит күңелдә
Иң матур җирендә
Вакытлыча туктаган бер җыр кебек.

Яшьлегем тугае

Ф.Шәфигуллин сүзләре З.Гыйбадуллин музыкасы



1. Ничәнче мәртәбә
Нурланып яз килде,
Тургайлар канатын кагынды.
Күзләрең сагышлы,
Дип әйтте бер тургай,
Нишлим соң, тургаем, сагындым.

2. Ничәнче мәртәбә
Тургайлар килделәр.
Тугайлар яшәрде, ямьләнде.
Өздереп сайрады,
Сайрады бер тургай,
Читендер сагыну хәлләре.


3. Өздереп сайрама,
Хәлемне сорама –
Ул үзе аңлар бер, тургаем.
Минем күк сагынып
Кайтыр ул, тургаем:
Онытмас яшьлеге тугаен.

Яшьлегем хисләре

(«Сибелә чәчәк»драмасыннан)

Г.Сәгыйдуллин сүзләре Ш.Мәҗитов музыкасы

Уртача тизлектә



1. Сахраларда ялгыз йөргән чакта
Яратам мин чәчәк исләрен.
Бүләк итәм, бәгырем,
Ал, тартынма, ал син
Яшьлегемнең кайнар хисләрен.

2. Сахраларда ялгыз йөргән чакта,
Мин дә сөям чәчәк исләрен.
Тап төшермәм, бәгырем,
Тап төшермәм аңар,
Шаһит булыр барлык дусларың.

3. Сахраларда ялгыз йөргән чакта,
Җилләр исеп чәчне тарата.
Бәхет бит ул, дуслар,
Шуны онытмагыз, –
Ул саф йөрәкләрне ярата.

Җырларны тупладылар: *Винера Ганеева, Гөлмира Бабаева, Лилия Бородовская*
Җырларның ноталарын компьютерда җыючы: *А.Захаров*

MP3 Дисктагы Әлфия Авзалова башкарган 100 җыр тәртибе

1. Һаман да көтәсең. С. Ибраһимов музыкасы, Р. Закиров сүзләре.
2. Авыл көе. Татар халык җыры.
3. Ай, җаныем, суларда. Татар халык җыры.
4. Ак күлмәгем. И. Дәүләтшин музыкасы, Ш. Җиһангирова сүзләре.
5. Актаныш басмалары. Татар халык җыры.
6. Актаныш таңнары. С. Садыйкова музыкасы, М. Ногман сүзләре.
7. Ашхабад. Татар халык җыры.
8. Бер генә сүз эзлим. Р. Гатауллин музыкасы, Ф. Яруллин сүзләре.
9. Бик сагындым, авылым. Р. Сафиуллин музыкасы, М. Латыйфуллин сүзләре.
10. Болын. Татар халык җыры.
11. Бөрлегәнем. Татар халык җыры.
12. Бу дөньяда. Ф. Хатыйпов музыкасы, Р. Фәйзуллин сүзләре.
13. Галия җыры. Р. Хәсәнов музыкасы, Г. Идрисов сүзләре.
14. Гармунчы гашыйк булган. З. Гыйбадуллин музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре.
15. Гармунчыга. Татар халык җыры.
16. Гөлҗамал. Татар халык җыры.
17. Гөлләр иле. С. Шәмсина музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре.
18. Гүзәлия җыры. М. Имашев музыкасы, С. Сөләйманова сүзләре.
19. Дустыма. Татар халык җыры.
20. Җидегән чишмә. С. Садыйкова музыкасы, Г. Бәширов сүзләре.
21. Җомга. Татар халык җыры.
22. Зөлхиҗҗә. Башкорт халык җыры.
23. Зәйнәп җыры. М. Имашев музыкасы, Х. Сафина сүзләре.
24. Идел буе каеннары. И. Шакиров музыкасы, Ә. Ерикәй сүзләре.
25. Илдарым С. Садыйкова музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре.
26. Йокла инде, курчагым. З. Гыйбадуллин музыкасы, Ә. Бикчәнтәева сүзләре.
27. Казан сөлгесе. Татар халык җыры.

28. Кайт инде. С. Вәлиева музыкасы һәм сүзләре.
29. Карашларың синең. Ш. Колбарисов музыкасы һәм сүзләре.
30. Картаямыни соң йөрәк? С. Ибраһимов музыкасы, Г. Нуруллин сүзләре.
31. Кемгә салыйм башны таңнарда? М. Имашев музыкасы, Г. Ахунов сүзләре.
32. Кил, чибәрем. Р. Яхин музыкасы, Ә. Ерикәй сүзләре.
33. Кил, иркәм. Б. Гайсин музыкасы, Р. Янбулатова сүзләре.
34. Күбәләгем. Татар халык җыры.
35. Күзләрем тик сине эзлиләр. Р. Яхин музыкасы, М. Ногман сүзләре.
36. Кукмара. М. Имашев музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре.
37. Күл буена килсәң иде. З. Гыйбадуллин музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре.
38. Күңел җыры. К. Хөснуллин музыкасы, Ф. Хисмәтуллин сүзләре.
39. Күңелләрем сине эзли. Ф. Әхмәдиев музыкасы, халык сүзләре.
40. Кыз күңеле. Т. Шәрипов музыкасы, Г. Афзал сүзләре.
41. Кыз сәламе. И. Шәмсетдинов музыкасы, халык сүзләре.
42. Кәккүк. С. Габәши музыкасы, Ә. Ерикәй сүзләре.
43. Миндәдер күңелләре. Ә. Хәйретдинов музыкасы, Р. Ишмөхәммәтов сүзләре.
44. Минзәлә. Татар халык җыры.
45. Мәхәббәтем. Ф. Латыйпов музыкасы, Ә. Ерикәй сүзләре.
46. Назлы гөлкәем. Ф. Әхмәтов музыкасы, Я. Кәрим сүзләре.
47. Ник соңладың? С. Садыйкова музыкасы, И. Ганиева сүзләре.
48. Нәфисә. Татар халык җыры.
49. Өзелә бит үзәгем. Татар халык җыры.
50. Почтальон. Т. Кәримов музыкасы, Ш. Насыйров сүзләре.
51. Сагынам, дуслар, илкәйне. Татар халык җыры.
52. Сагындым авылымны. Р. Тимербаев музыкасы, Р. Тимеров сүзләре.
53. Сагындыра. Р. Ахиярова музыкасы, Р. Харис сүзләре.
54. Сагындыра шул чакта. Татар халык җыры.
55. Сагыну җыры. Р. Хәсәнов музыкасы, Г. Идрисов сүзләре.
56. Саубуллашу. И. Закиров музыкасы, Ш. Тәһирова сүзләре.
57. Син кайтмадың. М. Мозаффаров музыкасы, С. Урайский сүзләре.
58. Син түгел шул. Р. Кузнецов музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре.
59. Синең өчен. Г. Ильясов музыкасы, Ж. Дәрзаман сүзләре.

60. Солдатлар. Ф. Әхмәдиев музыкасы, Р. Әхмәтҗанов сүзләре.
61. Солдатым. С. Садыйкова музыкасы, М. Ногман сүзләре.
62. Сөясеңме дип ник сорыйсың. С. Хәбибуллин музыкасы, Ә. Ерикәй сүзләре.
63. Сүнмәс дәрт. Татар халык җыры.
64. Сәлимәкәй. Башкорт халык җыры.
65. Сәяхәтче җыры. З. Гыйбадуллин музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре.
66. Тамчылар. А. Монасыйпов музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре.
67. Төнбоек. С. Вәлиева музыкасы һәм сүзләре.
68. Тугайларым. С. Садыйкова музыкасы, И. Ганиева сүзләре.
69. Туган авылым. Т. Шәрипов музыкасы, Н. Иделбай сүзләре.
70. Туган авылым. Х. Әхмәтов музыкасы һәм сүзләре.
71. Туган авылым Чынлы. С. Садыйкова музыкасы, М. Ногман сүзләре.
72. Туй күлмәге. М. Имашев музыкасы, М. Шиһапов сүзләре.
73. Тәзкирә. Татар халык җыры.
74. Тәнәкәй. Башкорт халык җыры.
75. Хәтфә. А. Хөсәенов музыкасы, Р. Юнысов сүзләре.
76. Чыгарсыңмы каршы алырга? В. Әхмәтшин музыкасы, Д. Гарифуллин сүзләре.
77. Шахта. Татар халык җыры.
78. Шома бас. Татар халык көе, Г. Насрый сүзләре.
79. Әйткән идең. Ә. Бакиров музыкасы, Х. Туфан сүзләре.
80. Әйтче, дөресен. Ә. Габдрахманов музыкасы һәм сүзләре.
81. Элмәлек. Башкорт халык җыры.
82. Әниемнең җылы кочагы. Ә. Бакиров музыкасы, М. Мазунов сүзләре.
83. Әниемә. Ш. Калдаяков музыкасы, Г. Каербеков сүзләре.
84. Әнкәй. С. Садыйкова музыкасы, Р. Миңнуллин сүзләре.
85. Язлар җиткәч кайтырмын. Н. Галиев музыкасы, Ш. Биккол сүзләре.
86. Янбикә. Ш. Колбарисов музыкасы, Р. Сафин сүзләре.
87. Яныңа үзем киләм. Татар халык көе, Н.Ибәтов сүзләре
88. Яратам, дисең син. А. Монасыйпов музыкасы, Ә. Давыдов сүзләре.
89. Яшь гомер. З. Гыйбадуллин музыкасы, Г. Зәйнашева сүзләре.
90. Яшь наратлар. Җ. Фәйзи музыкасы, И. Юзеев сүзләре.
91. Яшьлегем тугае. З. Гыйбадуллин музыкасы, Ф. Шәфигуллин сүзләре.

92. Яшьлегем хисләре. Ш. Мәҗитов музыкасы, Г. Сәгыйдуллин сүзләре.
93. Кил безнең авылга. Е. Брусиловский музыкасы, Х. Бикхуҗин сүзләре.
94. Торади. Корея халык җыры.
95. Шаян җыр. Үзбәк халык җыры.
96. Сурәя. Азербәйҗан халык җыры.
97. Айлы кич. Һинд халык җыры.
98. Яр-яр. Үзбәк халык җыры.
99. Гүзәл кыз. Гарәп халык җыры.
100. Юл җыры. Род Стюард репертуарыннан.

Эчтәлек

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов мөрәҗәгате.....3
Кереш сүз (З.Нигъмәтҗанова-Авзалова).....4

I кисәк
Әлфия Авзалова. Үзем турында

Кереш сүз.....8
Яшьтән бирле хәсрәт йотып.....9
Шәмдәлләрдә генә утлар яна.....40
Яшьлегем чәчәк атканда.....50
Таныш түгел юллар буйлап.....77
Туганнарым, балаларым, оныкларым һәм дусларым.....114
Җыр ничек туа? Репертуар ничек барлыкка килә?.....156
Уңышлардан башым әйләнмәде.....168
Бенефис.....184
Картаямыни соң йөрәк?.....191

II кисәк
Әлфия Авзалова турында истәлекләр

Минтимер Шәрип улы ШӘЙМИЕВ.....196
Илсур МЕТШИН.....199
Гүзәл АВЗАЛОВА.....201
Зөлфия НИГЪМӘТҖАНОВА-АВЗАЛОВА.....204
Равил НИГЪМӘТҖАНОВ.....217
Азат ХАМАЕВ.....225
Азат ХӨСӘЕНОВ.....226
Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА.....228
Айгөл НУРИСЛАМОВА.....231
Айсылу НАСЫЙБУЛЛИНА 232
Айдар ГАЛИМОВ.....233
Александр ЧУГУНОВ.....234
Алсу НӘБИЕВА.....235
Алсу ХӘКИМОВА.....236

Алсу ШӘЙБӘКОВА....238
Альбина НАСЫЙРОВА....238
Альбина ШАҺИМОРАТОВА....239
Әгъзам ГОБӘЙДУЛЛИН....240
Әлифә ВӘЛИЕВА....241
Әскәр АВЗАЛОВ....246
Әсхәт САФИН....248
Винера ГАНИЕВА....251
Вәсим ВАХИТОВ....254
Владимир ЛАПШИН....255
Гамирә ГАДЕЛШИНА....260
Гүзәл ВАФИНА....265
Гүзәл ЛАТЫЙПОВА....268
Диләрә ИЛЬЯСОВА....269
Дүсинә ӘХМӘДУЛЛИНА....272
Зәлинә ХӘЙРУЛЛИНА....275
Зәйнәб ФӘРХЕТДИНОВА һәм Зөфәр БИЛАЛОВ.... 276
Земфира һәм Тәлгать САНАТУЛЛОВЛАР....278
Зилә ВӘЛИЕВА....279
Зилә СӨНГАТУЛЛИНА 282
Зөлфия һәм Җәвит ШАКИРОВЛАР....286
Зөһрә СӘХӘБИЕВА....289
Зөһрә ШӘРИФУЛЛИНА, Азат ХӘЛИМОВ....291
Зөфәр ГАЯЗОВ....294
Иделия ИСХАКОВА....296
Илдар КЫЯМОВ....298
Илзирә ВӘЛИУЛЛИНА....304
Инсия ЗАРИПОВА....306
Илдар һәм Айрат БИККИННАР....307
Ирек ШӘРИПОВ....309
Исламия МӘХМҮТОВА....312
Искәндәр БИКТАҺИРОВ....315
Кадим НУРУЛЛИН....316
Кадрия ИДРИСОВА....318
Кәрим һәм Сания ГАБИДУЛЛИННАР....321
Кирам САТИЕВ....328
Ләйсән һәм Рената НИГЪМӘТЖАНОВАЛАР....331
Ләйсән ХӘМИТОВА-МОСТАФИНА....333
Лилия һәм Әхмәт ДӘҮЛӘТЪЯРОВЛАР....335

Мансур ХӘСӘНОВ....338
Мәсгуть ИМАШЕВ....340
Мирсәет СӨНГАТУЛЛИН....341
Мөнәвәрә, Данил һәм уллары Ранил НУРИЕВ....343
Нәфкать НИГЪМӘТУЛЛИН....345
Рәмзия СӘЛАХОВА....345
Рабит БАТУЛЛА....346
Разил ВӘЛИЕВ....348
Рәүфәл МӨХӘММӘТЖАНОВ....353
Рафинат СӘЛАХОВ....355
Резидә һәм Илдар ХӨСӘЕНОВЛАР....357
Рәзинә СӘЕТГӘРӘЕВА....359
Рәис НӘҖИПОВ....360
Рәфкать САБИТОВ, Ирина САБИТОВА....362
Рәшит МОСТАФИН....363
Рәшит САБИРОВ....364
Рәшит ШӘҺИДУЛЛИН....366
Ренат ХАРИС....370
Римма ИБРАҺИМОВА....374
Ринат ҖӘЛӘВЕТДИНОВ....375
Ринат СИБГАТУЛЛИН....378
Рифат ФӘТТАХОВ....381
Роза АВЗАЛОВА-САФИУЛЛИНА....384
Розалия ЗӘКИЕВА....386
Рөстәм МАЛИКОВ....387
Рузалия МОСТАФИНА....389
Фердинанд СӘЛАХОВ....390
Фердинанд ФӘТХИ....394
Фәридә ТӨХФӘТУЛЛИНА-ВӘЛИӘХМӘТОВА....396
Фәрит ГОМӘРОВ....398
Фәрит ХАТЫЙПОВ....399
Хәйдәр САФИН....401
Хәмдүнә ТИМЕРГАЛИЕВА....402
Энгель ФӘТТАХОВ....403
Юсыф ВӘЛИТОВ....406
Әлфия Авзал кызы Авзалованың биографиясе һәм тормыш юлы....409
Фотосурәтләр....414

Кушымта
Әлфия Авзалова репертуарыннан йөз җыр
(сүзләре, ноталары)

Халык җырлары

Авыл көе..... 432
Агыйдел каты ага..... 433
Ай, былбылым..... 434
Ай, җаныем, суларда..... 435
Ак калфак..... 436
Актаныш басмалары..... 437
Арча..... 438
Ашхабад..... 439
Әй, икегез, икегез 440
Әллүки (Г.Тукай сүз.)..... 441
Әпипә..... 442
Әтнә..... 443
Богады авылы көе..... 444
Бөрлегәнем – бер генәм 445
Вәгъдә..... 446
Гармунчыга..... 447
Дим буе..... 448
Җаныем, бәгърем..... 449
Җомга..... 450
Зиләйлүк (Г.Тукай сүз.)..... 451
Их, карап торулары... 452
Казан сөлгесе..... 453
Китәм, дисең... 454
Көймә килә..... 455
Кошлар кебек..... 456
Күбәләгем..... 457
Минзәлә..... 458
Нигә яна йөрәгем? 459
Олы юлның тузаны..... 460
Сагыну..... 461
Сания апа..... 462
Сарман..... 463
Сәрвиназ (Ә.Ерикәй сүз.)..... 464

Сибелә чәчем..... 465
Су буйлап..... 466
Су юлы..... 467
Талы, талы..... 468
Тәфтиләү (Г.Тукай сүз.)..... 469
Туган тел (Г.Тукай сүз.)..... 470
Фирдәвескәй..... 471
Шахта..... 472
Шома бас (Г.Насрый сүз.)..... 473
Ямьле Агыйдел буйлары..... 474

Композиторлар әсәрләре

Аерылмагыз. Ч. Зиннәтуллина – Г. Зәйнашева..... 475
Аккошлар. Ф. Әхмәтов – Р. Фәйзуллин..... 476
Ак күлмәгем. И. Дәүләтшин – Ш. Җиһангирова..... 477
Әгәр белгән булсам. Ә. Бакиров – Ш. Биккол..... 478
Әйткән идең. Ә. Бакиров – Х. Туфан..... 479
Әйтмә син авыр сүз! Р.Хәкимов – Р. Чурагулов..... 480
Әлдермешкә кайтам әле. У.Рәшитов – Т. Низами..... 481
Әниемә. Ш. Калдаяков – Г. Каербеков..... 482
Әниемнең җылы кочагы. Ә. Бакиров – М. Мазунов..... 483
Әнкәй. С. Садыйкова – Р. Миңнуллин..... 484
Бәхет. А. Монасыйпов – Ә. Атнабаев..... 485
Беренче мәхәббәт. С. Садыйкова – Ә. Рәшитов..... 487
Бик сагындым, авылым. Р. Сафиуллин – М. Латыйфуллин..... 488
Гармунчы. З. Гыйбадуллин – Г. Зәйнашева..... 489
Гөлләр иле. С. Шәмсина – Г. Зәйнашева..... 490
Гүзәлия җыры. М. Имашев – С. Сөләйманова..... 491
Җидегән чишмә. С. Садыйкова – Г. Бәширов..... 492
Җиз кыңгырау моңнары. В.Хәбисламов – Ә. Атнабаев..... 493
Йәнбикә. Ш. Колбарисов – Р. Сафин..... 494
Казан кичләре. С. Садыйкова – Х. Туфан..... 495
Картаямыни соң йөрәк? С. Ибраһимов – Г. Нуруллин..... 496
Кемгә салыйм башны таңнарда? М.Имашев – Г. Ахунов..... 497
Китмәгез, кошларым. В. Әхмәтшин – Н. Юсупова..... 498
Кичер мине, әнкәй, гафу ит. Р. Хәсәнов – Г. Идрисов..... 499
Кукмара. М. Имашев – Г. Зәйнашева..... 500
Күл буена килсәң иде... З. Гыйбадуллин – Г. Зәйнашева..... 501

Кыр казлары киткәндә. Ә. Бакиров – Р. Гәрәй..... 502
Кышкы романс. Р. Хәсәнов – Н. Нәҗми..... 503
Оныттың бугай. Г. Ильясов – Г. Рәхим..... 504
Сагыну җыры. Р. Хәсәнов – Г. Идрисов..... 505
Сандугач керде күңелгә. И. Хәбибуллин – Р. Әхмәтҗанов..... 506
Сәяхәтче җыры. З. Гыйбадуллин – Г. Зәйнашева..... 507
Син кайтмадың. М. Мозаффаров – С. Урайский..... 508
Синең өчен. Г. Ильясов – Ж. Дәрзаман..... 509
Сине уйлап янам. С. Ибраһимов – И. Юзеев..... 510
Сок буйлары. М. Имашев – Һ. Сафина..... 511
Солдатым. С. Садыйкова – М. Ногман..... 512
Соңлама, кил инде. Б. Гайсин – Р. Янбулатова..... 513
Сыерчыклар. Р. Хәсәнов – Р. Мөслимов..... 514
Тагын, тагын, тагын да. С. Ибраһимов – М. Латыйфуллин..... 515
Тамчылар. А. Монасыйпов – Г. Зәйнашева..... 516
Тамчыгөл. Р. Зарипов – Р. Зарипов..... 518
Туган авылым. Т. Шәрипов – Н. Иделбай..... 519
Туган җирем – Татарстан. А. Ключарёв – Г. Зәйнашева..... 520
Туган җирем. З. Гыйбадуллин – Г. Зәйнашева..... 521
Туй күлмәге. М. Имашев – М. Шиһапов..... 522
Утыр әле яннарыма. И.Хисамов – Ш. Галиев..... 523
Үз илемдә. С. Садыйкова – Г. Зәйнашева..... 524
Хуш инде... Ф. Мортазин – И. Юзеев..... 525
Хушлашырга ашыкма. Р. Гатауллин – Ф. Сафин..... 526
Һаман да көтәсең. С. Ибраһимов – Р. Закиров..... 527
Чыгарсыңмы каршы алырга? В. Әхмәтшин – Д. Гарифуллин..... 528
Ялгыз аккош күлләрдә. Р. Хәсәнов – Р. Ханнанов..... 529
Ялгыз көймә. Р. Гатауллин – Ф. Сафин..... 530
Яшь гомер. З. Гыйбадуллин – Г. Зәйнашева..... 531
Яшьлегем тугае. З. Гыйбадуллин – Ф. Шәфигуллин..... 532
Яшьлегем хисләре. Ш. Мәҗитов – Г. Сәгыйдуллин..... 533

MP3 дисктагы Әлфия Авзалова башкарган 100 җыр тәртибе..... 534
Эчтәлек..... 538

АЛЬФИЯ АВЗАЛОВА
(воспоминания певицы и почитателей её таланта
на татарском языке)

ӘЛФИЯ АВЗАЛОВА
Истәлекләр

Проектның авторы һәм китапның төзүчесе:
Зөлфия Нигъмәтҗанова-Авзалова
Мөхәррирләре: *Рәшит Минһаж, Рәзинә Сәетгәрәева,*
Музыкаль мөхәррире: *Әлфия Һадиева*
Рецензенты: *Равил Нигъмәтҗанов*
Бизәлеш мөхәррире, техник мөхәррире,
компьютерда битләргә салучысы: *Азат Яшәр*
Корректоры: *Фирая Маликова*
Җаваплы мөхәррире: *Рөстәм Сәрвәров*

+ 16 Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436-ФЗ

Басарга кул куелды 30.01.2019. Форматы $70\times100^{1}/_{32}$.
«Times» гарнитурасы. Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 34,0.
Тиражы 1000 данә. Заказ

ООО «Халкыбыз мирасы» нәшрияты
Казан, Спортивный урамы, 33, офис 1
Тел. 8(843) 246-2-246, 89046-746-246
http://aksu.tatar
e-mail: 2959308@mail.ru

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият
комплексында басылды.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.